Сайланма әсәрләр

ГАРИФ ГОБӘЙ

Г. ГОБӘЙ

2

ГАРИФ ГОБӘЙ

Сайланма әсәрләр

өч томда

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

ГАРИФ ГОБӘЙ

Сайланма әсәрләр
повестьлар

2
том

КАЗАН 1969

Редакторы *Р. Вәлиева*

Художнигы *И. Субаев*

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

7-6-3
214М 69

ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ



Беренче кисәк

1 САБАНТУЕ ТҮГЕЛ БУ...

— Хәлим!

Хәлим, шомырт кара чәчле, җете кара күзле малай, сискәнеп китте, һәм каушаганын йөзенә чыгармаска тырышып, укытучысының күзләренә тыныч карап, урыныннан күтәрелде.

— Каюм!

Иң алдагы партадан Каюм (тырпаеп торган кызыл чәчләре өчен Керпе кушаматы алган малай) күтәрелде.

Аннан укытучы тагы ике малайга эндәште:

— Мотыйк! Җәләлетдин!

Малайлар икесе берьюлы борыннарын тартып куйдылар. Икесе берьюлы урыннарыннан тордылар. Болары да, башларын аска иеп, аяк очларына карадылар.

— Сез, ялгышмасам, кичә дәрестә булмадыгыз шикелле?

Шаһгәрәй абзый «ялгышмасам» белән «шикелле»не мәзәк күреп кенә әйтте. Башларын түбән иеп, борынарын мышнатып басып торган дүрт малайның кичә дәрестә булмаганлыкларын ул яхшы белә иде.

Карт укытучы «ялгышмасам» белән «шикелле»не бик еш куллана, бигрәк тә балаларны оялтырга кирәк булганда сүз арасына кыстырып җибәрергә ярата иде. Мәсәлән, болай ди иде ул:

— Атның аягы, ялгышмасам, дүрт була шикелле. Ә синең рәсемдә өч кенә; өч белән дә аумас эле дидеңмени? Төзәт, дустым.

Яки:

— Ялгышмасам, элегә кадәр бакалар җирдә яшиләр иде шикелле. Синең рәсемдә һавада очып йөриләр. Әллә берәр яңа төрле бака уйлап чыгардыңмы, Әхмәтҗан?

Малай ык-мык итә, ә укытучы рәсемне малайга кайтарып бирә:

— Төзәт, дустым.

Хәлимнәр, укытучының бу гадәтен белгәнгә, «ялгышмасам» белән «шикелле»не искә алмыйча, башларын ия төштеләр. Укытучы класс журналын ябып куйды да күзлеген маңгаена күтәрде. Урыныннан әкрен генә торып, парталар арасындагы юлга керде. Кулларын артка куйды.

— Ягез, дусларым...

Гаепле икәнлекләре йөзләренә чыккан малайлар берберсенә карашып алдылар.

Хәлим, иптәшләре «бутап ташлаудан» куркып, авызын кыймылдатты:

— Колмәмәт батыр елгасына ат сакларга барган идек тә, сары биянең колынын җуйдык.

— Әһә... Шуннан?

— Урманга кереп адашкан...

Укытучы, сизелер-сизелмәс нечкә елмаю белән:

— Алай, алай...— дип торган булды.

— Шул колынны эзләп йөрдек.

— Һәм сез, ялгышмасам, ул колынны райком секретаре кабинетыннан эзләдегез?

Хәлим җыерылып килде:

— «Каптым!» — диде ул эченнән генә. Иптәшләренә текәлгән күзләре дә шуны ук әйттеләр: — «Каптык, малайлар».

Класста уңайсыз тынлык урнашты. Балалар өчен, бигрәк тә, укытучының хөкемен көтеп, башларын түбән иеп торган дүрт малай өчен, бик озак булып күренде бу тынлык. Алар бу вакыт ничек кенә булса да акланып калу юлын эзләделәр. Ә калган балаларның кайберсе Хәлимнәрне кызганды, кайсы берсе: «Ну, кирәкләрен бирә хәзер...» — дип кызык көтте.

Ләкин кызык булмый калды. Укытучы Хәлимнәрнең «кирәкләрен бирмәде». Дөрес, ул инде имән бармагын югары күтәреп селкергә әзерләнгән иде, кире уйлап, яңадан өстәле янына килеп утырды, күзлеген маңгаеннан күзләренә төшерде һәм класс журналына, гаепле

малайларның исемнәре турысына, нәрсәләрдер сызгалап куйды.

Тагын торды.

— Беләм мин, барысын да беләм, башсыз малайлар! Ләкин бу турыда сезнең белән соңыннан сөйләшербез,— диде ул һәм бернәрсә дә булмаган кебек алгебра китабыннан мәсьәлә укыды, тыныч кына итеп аңлатты, аннары Хәлимне тактага чакырып чыгарды, аның җилкә чокырында бөтерчекләнеп торган чәченә күзлеге өстеннән карап, сөйләнеп куйды:

— Барысын да беләм мин, башсыз малайлар.

Һәм дөрестән дә, бу дүрт малай турында укытучы, барысын булмаса да, кайбер нәрсәләрне белә иде...

Хәлимнең әтисен сугышның беренче көннәрендә үк алдылар. Колхоз председателе иде аның әтисе. Атна-ун көн дигәндә Нәни абыйсына да чират килеп җитте. Нәни абыйсы тракторчы иде. Ә олы абыйсын, фин сугышыннан орден тагып кайтканын, алмый торганнар иде дә, анысы да озакламый бер җаен табып, китеп барды. Алар китү белән Хәлим дә фронтка шылу турында хыялланып йөри башлады. Менә аңар үзе шикелле иптәшләр дә табылды, һәм алар, үз авыллары каралмый торган көнне туры китереп, беркемгә бер сүз әйтмичә, таң-иртәдән район үзәгенә, хәрби комиссариатка чыгып киттеләр.

— Хуш, авыл! Юлга әзерләнү өчен берәр көнгә кайтырбыз әле без сиңа!.. Бәлки, кайтмабыз да...

Район үзәгенә килеп кергәч, малайлар аптырап калдылар. Урамнарда, сабантуе диярсең, төркем-төркем кешеләр йөри. Хәрби комиссариат алдындагы мәйданга халык сибелгән; тарантас, арбалар бик күп... Атлар кешни, дегет, печән исләре... Ләкин сабантуе түгел бу. Яшел, зәңгәр, ал буяулы кечкенә кибетләр юк мәйданда, карусель юк. Кулларына уенчыклар, кызыл билле прянниклар, чуклы конфетлар тотып йөгереп йөргән сабый балалар күренми. Сабантуе көннәрендә була торган шат авазлар яңгырап тормый мәйдан өстендә... Гармонь уйныйлар — көйләре моңлы, җырлыйлар — җырлары сагышлы... Яшьләрнең кайберләре инде төшереп тә өлгергәннәр, ләкин алар, сабантуендагыча, аз эчкән килеш күп исереп йөрмиләр, күп эчкәннәр, ә аек күренергә тырышалар... Әнә анда, тәртәләре югары күтәреп бәйләп куелган ике арбада, егетләр, кызлар. Алар, бер-берсенә

елышып, кулларын берсе икенчесенең иңенә салып утырганнар да, аякларын жыр көенә әкрен генә тирбәтеп, бер жыр жырлыйлар. Кайдан чыга шулкадәр моң, сагыш? Кайда тапканнар алар бу жырны? Хәлим, дөньяда мин белмәгән жыр юк, дип йөри иде. Бөтен тирә-як авылларда жырлана торган жырлар язылган иде аның дәфтәренә. Ә кай арада кем чыгарган да, кем өйрәткән аларга бу йөрәк өзгеч жырны? Берсе беренче сүзләрен көйли башлауга, бөтенесе кушылып китә:

Кара көчләр килә ил өстенә,
Шәһәр, авылларны яндырып.
Газиз аналарны дарга асып,
Балаларны ятим калдырып.

Канга кан, үлемгә үлем,
Мылтык ал, иптәш,
Зур көрәш бүген...

Жыр кешеләрне магнит кебек үзенә тарта. Жыр кешеләрне әйдәмичә, кул изәмичә үз тирәсенә жыя. Кеше күбрәк жыелган саен, гармоньчы бармакларын ныграк баса, гармонь мехы кинрәк сузыла, жыр көчлерәк яңгырый. Менә, сабантуендагыча, егетләр кызларга, кызлар егетләргә атап жырлый башлыйлар. Ләкин монысы да моңлы, сагышлы:

Су буйларына төшкәч тә,
Унга каерылгач та,
И, дускаем, рәхәт яшә
Миннән аерылгач та.

Егетләр шулай ук сагышлы, моңлы итеп жавап бирәләр:

Сарман буйлары ла яшел алан,
Печәннәре житәр бер заман.
Бергә торган чаклар рәхәт иде,
Аерылышулары бик яман.

Жыр кыза, жыр көчәя. Жырлый белгәне дә, белмәгәне дә кушыла жырга. Яшьләр янына килергә базмыйча, бер читтән боегып карап торган бала жанлы әниләрнен, әбиләрнең күзләрендә яшь күренә башлый.

«Ә-ә, әле сез шулаймы!..» — Менә гармоньның иң нечкә телләре, дөньяда без дә бар бит әле дигән кебек итеп, тавыш биреп куялар. Гармоньчы егет гармонь бакасына шаян басып ала. Башын күтәрә гармоньчы егет; эре, ләкин килешле тешләрен күрсәтеп, киң елмая.

— Их-хма-а!..— ди ул күңелле итеп, һәм үзе уйнап, үзе җырлап җибәрә:

Иртә дә кил, кич тә кил,
Тәрәзәмне чиртә кил...

Әниләрнең, әбиләрнең башлары әкренләп күтәрелә. Аларның яулык читләре, алъяпкыч итәкләре яшькә чыланмый кала. Кызлар элеп алып китәләр:

Чиртүеңнән танырмын да...

Гармоньчы егет, дәртле дулкынланып, арбадан сикереп төшә. Гармонен иптәшенә бирә:

— Мә әле, Харис. Даешь әпипә... Их, их, ихма-а-а!

Егет инбашларын уйнатып ала, бер кулын җилкәсенә, икенчесен биленә куеп, оста биеп китә. Менә бер кыз, итәк читләрен бармак очлары белән генә чеметеп, аңар каршы чыгып бии башлый. Егет чүгеп биюгә күчә. Тагы бер пар арбадан төшеп биеп китә. Гармоньга гармонь, биючегә биюче кушыла.

Бас, бас эзенә, күз тимәсен үзеңә...

Ләкин яшьләрнең аяклары кызып та җитми, бөтен хәрәкәт, кискен команда булгандагы шикелле, туктап кала — телеграмм баганасындагы радио телгә килә:

— Тыңлагыз, тыңлагыз, Казан сөйли...

Казанның сугыш башланганнан бирле шатлыклы хәбәр сөйләгәне юк иде. Ул көн дә шушы минутта телгә килә, көн дә Кызыл Армиянең я теге, я бу шәһәрдән чигенүе турында хәбәр итә иде. Шуңар күрә «Казан сөйли...» дию гә үк кешеләрнең кашлары җыерылды.

«...Совет информбюросыннан,— диде Казан.— Бүген, 21 нче октябрьда, безнең гаскәрләр, каты сугышлардан соң, Харьков шәһәрен калдырып чыктылар...»

Кешеләр, бер-берсенә карарга уңайсызланып, башларын түбән иделәр.

— Тагы алганмыни? — дип сорады колакка катырагы берсеннән.

Күршесе, башын күңелсез чайкап, кулын селтәде:

— Әйтмә инде, туганый...

— Ай, туктый да белмәде, дөмеккере!

Гармоньчы егеткә монысы да ошамады — аның мәйдандагы халыкны күңелсезләндерәсе килми иде. Ул,

гармонен мәзәк шыгырдата-шыгырдата, сөйләнеп куйды:

— Без... Без барганны көтә ул, Нурия җиңги... Ихлас шулай. Менә күр дә тор, барып та җитәрбез, и Гитлер тәртәсен кире борыр. Борыр бит, яшьти?

— Борыр,— диде гармоньчының яшьтие. Ләкин ул моны үзе дә ышанып җитмичә әйтте һәм хәрби комиссариат алдындагы зур карта янына килде дә, Харьков шәһәрен эзли башлады.

Егет Харьковны дөрес эзләмәде: аның бармагы кайдадыр Ленинград тирәсендә сәяхәт итә иде. Хәлим, тиз генә килеп, Харьковны төртеп күрсәтте:

— Менә, Фәхретдин абый.

Фәхретдин Харьковка түгел, аны табып бирүчегә, Хәлимгә борылып карады.

— Бәлеш, син нишләп йөрисең әле монда, кемне озатасың?

«Кемне озатасың?» — Хәлим бу сүзләрне үзен кимсетү дип аңлады:

— Беркемне дә озатмыйм... Хатын-кызмыни мин солдат озатып йөрергә? Үзем китәм, доброволь булып китәм.

— Ә әниең барамы соң?

— Әни нишләп барсын?

— Ә анда кем итәгенә ябышып йөрерсең соң, апаем?

Фәхретдин шулай диде һәм кычкырып көлде. Башкалар да елмаештылар.

Ә Хәлимнең йөрәгенә бу сүз хәнҗәр булып кадалды. Ул Фәхретдингә бик ачулы итеп җавап кайтармакчы булды, ләкин тыелып калды. «Ярар инде, ул да китәсе кеше, мин дә китәсе... бәлки, бер окопта ятарга, бер котелоктан ашарга туры килер», дигән булып, бер дә ачуы килмәгән шикелле шаярып җавап бирде:

— Окоптан чыгарга куркып ятмасаң, синең кикригеңә ябышып йөрермен, Фәхретдин абый...

Хәлим ипле томалады. Кечкенә чакта Фәхретдинне Әтәч Фәхри дип йөриләр иде. Чөнки ул, сугышканда, үзе сукса да, үзенә суксалар да, әтәч шикелле сикереп-сикереп куя иде. Ахры шул исләренә төште, кешеләр көлеп җибәрделәр. Фәхри уңайсыз хәлдә калды. Дөрес, ул үзе дә кешеләргә кушылып көлгән булды. Ә эченнән Хәлимнең тетмәсен тетеп ташлады. Гармоньчы егет, әллә болай

уйнyйсы килеп, әллә Фәхрине уңайсыз хәлдән чыгару өчен, гармонен тартып җибәрде.
Тагы бию башланды, тагы җыр китте:

Китәм, дуслар, китәм инде,
Китәмен еракларга.
Туган илне, изге җирне
Фашистлардан сакларга!

2 АЛАЛАР, АЛАЛАР...

Хәлим җырларны, отып алу өчен, күңеленнән кабатлап барды. Шул чак, чәч төпләренә кадәр тирләп чыккан, шуның белән бакыр-кызыл чәчләре тагы да кызарыбрак киткән Каюм, Хәлимне халык арасыннан эзләп табып, җиңеннән тартты һәм, әйтәсе сүзен зур сер күреп, пышылдап куйды:
— Әйдә тиз бул.
— Кая?
— Әнә тегендә баганага меңәләр. Шинельле кеше багана башына менеп җиткәннәрне язып тора.
— Ник икән?
— Менә тагы... алганда шуңарга карап алачаклар...
— Кит аннан?..
— Честное пионерское менә!
Хәлим белән Каюм кыңгыраулы, шоп-шома нарат багана янына йөгереп килделәр. Берәү, багананың яртысыннан да уза алмыйча, кире төшеп килә иде. Хәлим, итекләрен апын-төпен салып атты да, аюдан куркып агач башына үрмәләгән кеше кебек, каушый-каушый, баганага менеп китте. Ләкин, яртысына житүгә арып, тукталый башлады. Аяклары шуды, кулы шуды. Ләкин биредә сынатырга ярамый, сабантуе түгел бу. Шуңар карап алмый калулары бар... Әнә шинельле кеше, Каюмнан Хәлимнең исемен дә сорады бугай, армиягә яраксыз, дип язып куюы бар... Хәлим, эз генә ял итеп алды да, бөтен осталыгын, бөтен көчен салып, югары үрмәләде. Һәм, тырыша торгач, менеп җитеп, багана башындагы кыңгырауны какты да атылган кош тизлеге белән җиргә шуып төште.
Карап торучылар Хәлимне мактадылар. Багананың яртысыннан уза алмыйча төшкән егет Хәлимнең аяк табанын, уч төпләрен тотып карады:
— Аларга ышаныч юк, нарат сагызы сылыйлар бит

алар,— диде ул һәм, бернәрсә дә сыланмаган икәнен белгәч, әкрен генә Хәлимнең борынына чиертте:

— Кайсы авыл?

Хәлим үз колхозының исемен әйтте:

— «Ватан».

Шинельле кеше Хәлимне исемлеккә өченче кеше итеп язып куйды. Баганага Каюм ябышты. Ләкин баганаының яртысыннан уза алмаган егет аны, чалбар төбеннән тотып аска өстерәде.

— Төшеп тор. Без киткәч менәрсез. Кил әле, Хәсәнша, күрсәт әле Ташлы Ярда нинди егетләр үскәнен...

Хәсәнша Ташлы Ярда нинди егетләр үскәнен күрсәтә алмый калды: хәрби комиссариат ишеге як-якка ачылып китте. Аннан нәзек озын буйлы бер хәрби кеше кәгазь тотып чыкты да кычкырып укырга тотынды.

Бар да шунда таба агылды.

Каюм, йөгерә-йөгерә, Хәлимгә пышылдады:

— Сине карап та тормыйлар, болай булгач. Алалар.

— Ник?

— Алалар, ышан үземә... унлап кеше менеп карады, бары син дә, тагы ике кеше менеп житте. Мине дә алалар... Мин мылтыктан аттым. Гитлер сурәтенә. Өч пуля. Берсе шалт маңгаена!.. Ә менә Җәләй белән Мотыйкны нишләтерләр инде...

— Ник, Каюм?

— Йөгергәннәр иде дә...

— Соң?

— Җәләе әйбәт кенә килә иде, штаны төшә башлагач, туктап калды. Ни кычкырам, туктама, менә шулай итеп тот та йөгерә бир, дим. Юк бит... Ә тегесе, әллә инде бер казан бәрәңге ашап килгән, корсагын күтәрә алмады...

— А-а...

— Ә үзең белән мине шушы сәгатьтән кызылармеец итеп исәплә...

Каюмның ышандырулары бөтенләй нигезсез түгел иде. Ул шулай дип ишетте. Асылда исә баганага менүнең дә, Гитлер сурәтенә тидерүнең дә көче булмаячак, болар барысы да осоавиахим тарафыннан оештырылган физкультура уеннары гына иде.

Хәлимнәр килеп житкәндә хәрби комиссариат кешесе язуын укып бетергән иде инде.

Ул:

— Тәртип белән генә! — диде дә парадный ишектән кереп китте.

Каралырга килгән кешеләр аның артыннан өерелеп керә башладылар.

— Калма,— диде Каюм Хәлимгә,— артка калсаң, я бик сайлый башлар...

— Добровольләрне алдан уздырырлар әле, бәлкем, ә Хәлим?

— Әй, шулай булса...

Малайлар дүртесе дә хәрби комиссариат коридорының бер караңгы почмагына җыелдылар. Итекләрен салып, үкчәләренә печән тыгып яңадан киделәр. Һәм шул кыяфәттә йөреп карадылар.

— Сизелмиме?

— Юк, юк.

— Ә минеке?

— Юк. Ләкин син алай куркып басма...

Буйны зур күрсәтү өчен уйланылган бу хәйлә, башка җирдә булса, бәлки ярап та куяр иде, ләкин биредә аның ярдәме тия торган булмады: каралу бүлмәсеннән әлеге хәрби кеше чыгып нидер әйтүгә, кешеләр анадан тума чишенеп ташладылар.

Малайларның бар өметләре киселде. Барысы да кинәт күңелсезләнеп киттеләр.

— Әйттем мин сезгә, чишендереп карыйлар дип...

Хәлим иптәшләрен тынычландырырга тырышты:

— Буйга карамыйлар. Без бит разведчик булабыз. Разведчикка буй нигә? Аңар, энекәем, никадәр кечкенә булса, шулкадәр яхшы, фашист күрми. Теге мин укыган газетадагы разведчик малай бездән дә кечкенә булган әле.

— Булган сиңа!

— Честное пионерское менә! Моның шае гына...

Малайлар, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, Хәлимгә карап тордылар да итек эчләрендәге печәннәрне алып мичкә ыргыттылар. Ул арада бер кеше инде каралып та чыкты. Призывниклар аны сырып алдылар.

— Я, ничек?

— Годен.

— Яшә, егет. Кая?

— Обозга...

— Әйй...— Сорау бирүче кулын селтәп куйды.— Соң шушы кыяфәтең белән... Кит инде...

Обозга алынып чыккан кеше үзе дә риза түгел иде бугай, киенеп тә тормыйча, «бернәрсә дә белмәгән» докторларны яманлап, сукранырга кереште.

Ул да түгел каралу бүлмәсеннән икенче бер егет чыкты.

— Булдымы, парень?

— Ничек кенә әле.

— Кая?

— Кавалериягә!

— Һай, авызыңа бал да май, егет.

Егет тәмәке төрә башлады. Берсе аның авызына папирос китереп каптырды:

— Бик нитәме, малай?

— Бигрәк нәрсәне нитә?

Хәлимне егетнең җавапларыннан бигрәк, буе кызыксындырды.

— Миннән артык түгел бит моның буе. Каюм, син ничек уйлыйсың?

— Түгел шул.

— Миннән дә артык түгелдер әле...

Хәлим иптәшләренә күз кысып алды да кавалериягә алынып чыккан егет янына барып басты. Егет бу вакытта штанының бер балагын кигән, икенчесенә аягын тыгып тора иде. Хәлим килеп орынуга, егет мәтәлеп китте. Егет күреп алып ачуланырга өлгергәнче, Хәлим, кешеләр арасыннан иелеп үтеп, иптәшләре янына килде.

— Чамаладыгызмы?

— Кыскарак әз генә.

— Күпме?

— Дүрт бармак иңлеге булыр.

— Күп түгел... Аны менә ничек итәбез.— Хәлим, итекләрен салып ташлап, аяк очларына басты.

— Үкчә идәннән күпме күтәрелеп тора. Үлчә әле, Каюм.

Каюм, тегүче кием үлчәгән шикелле, идәнгә тезләнеп бик тиз үлчәп алды.

— Дүрт бармак иңлеге.

— Сиздегезме?

Малайлар барысы да, итекләрен салып, аяк очларына басып йөреп карадылар. Үкчә белән идән арасын үлчәделәр. Бу хәйлә карангы төшкәч тагы да уңышлырак чыгар әле дигән уй белән үзләрен юатып, кич җиткәнне көтә башладылар.

3

«КИТ, ТЕШЕМНЕ КУЗГАТТЫҢ!»

Көткәндә көн әкрен үтә...

Никадәр кеше каралып чыкты инде. Хәлимнәр әллә ничә тапкыр «алырлар» дигән уйга, әллә ничә тапкыр «алмаслар» дигән уйга килергә өлгерделәр. Аптыраганнан кибетләргә кереп йөрделәр. Әнә кеше куен дәфтәре ала, күпләп-күпләп хат кәгазе, конверт ала, болар да алдылар; кеше калай кружка, кашык ала, болар да алдылар; кеше пәке ала, болар да дүртесенә бер пәке алдылар һәм аны, иртәгә шушы вакытка кадәр үзендә йөртү өчен, Хәлимгә тапшырдылар.

— Аннан соң мин йөртәм, берсекөнгә син, синнән соң Мотыйк, Мотыйктан соң тагы Хәлим...

Кибеттән чыктылар да, инде алынып чыккан, озату мәҗлесен кемдә, кайчан уздыру турында сөйләшә-сөйләшә ат җигеп йөргән бәхетлеләргә кызыгып карап тордылар. Аннан малайлар тагы хәрби комиссариат коридорына, элеккеге урыннарына кереп бастылар.

Кеше сирәгәйгән иде инде.

Болай да бик якты булмаган коридор шактый караңгыланып өлгергән. Шуңа күрә малайлар хәзер үзләрен иркенрәк тоттылар. Иркенәеп китүгә тагын бер сәбәп чыкты: бүселеп торган сул яңагын ак яулык белән бәйләгән бер хәрби кеше, каралу бүлмәсеннән чыгып, коридордагыларның барысын да күзеннән үткәреп кереп китте. Моны күреп, малайларның авызлары ерылды.

— Санады,— диделәр алар,— безне дә санады...

Ә шул ук кеше, икенче чыгуында малайлар янына килеп: «Сез, егетләр, барыгыз, чыгып торыгыз»,— дигәч, малайлар шомлана калдылар.

— Менә сиңа мә!..

Ләкин Хәлим яңагын бәйләгән кешенең бу сүзләрен дә начарга юрамаска тырышты:

— «Чыгып китегез» димәде бит, «чыгып торыгыз» диде.

Каюм Хәлимгә куәт бирде:

— «Егетләр» диде ич әле ул тагын, «малайлар» димәде.

Малайлар сүтелә башлаган өметләрен шуның белән ямаштыргалап куйдылар. Ул да түгел, өметләрен нытытуга тагы бер сәбәп туды: каралу бүлмәсеннән типсә тимер өзәрдәй бер егет чыгып, китапка сыймый торган

сүзләр белән сүгенеп алды. Төрә башлаган тәмәкесен җиргә бәрде ул һәм көтеп торган авылдашына зарланып әйтте:

— Вәт син аны, пүчтәкне! Чистый каныкты бит... Тора-тора да, күзең, ди, тора-тора да, күзең, ди... Соң мин үзебезнекеләрдән немецны аера алмыйммы инде, җә?.. Шулай булгач, җитмимени миңа, җә!.. Юк, ул миңа әллә нинди вак хәрефләр күрсәтеп маташа. Мәрҗән тезергә кермим ич мин, немец кыйнарга барам лабаса!..

Егет кайгысы малайларга берьюлы ике шатлык булып ишетелде: моны алмаганнар, димәк, аның урыны безгә калды. Икенчедән, буйга карамыйлар икән, күз кирәк икән, ә күз малайларның берсенең дә сыната торган түгел...

— Сиздегезме, дуслар?

Дуслар Хәлимгә киң елмаю белән җавап бирделәр. Алар инде хәзер посып торган караңгы почмакларыннан кеше арасынарак чыктылар. Ә Хәлим ябылып җитмәгән ишектән башын тыгып караудан да тартынмады. Әнә тагы бер кешенең күзен карыйлар. Бүлмә уртасына бастырганнар да стенадагы хәрефләрне күрсәтәләр. Кара, бусы да рәтләп күрми ич... Ә Хәлим бит аны моннан торып та укый ала! Малай чак кына шулай дип кычкырып җибәрмәде. Ул түземсезләнеп ишекне ачты. Сүз әйтмәделәр. Керде. Ишек төбендә язып утыручы кеше янына, бүселгән яңагын ак яулык белән бәйләгән кеше янына килде.

— Фамилияң? — диде бу кеше, башын күтәрмичә генә...

Хәлим фамилиясен әйтте.

Яңагын бәйләгән кеше ниндидер сары кәгазьләрне актарырга керешге. Ниндидер кенәгәдән карады.

— Ничек дисең әле фамилияңне?

— Арсланов Хәлим.

Яңагын бәйләгән кеше иңбашларын җыерып куйды.

— Повесткаңны бир әле.

Хәлим беравык җавап бирмичә торды. Аннары, баштагы кыюлыгын җуеп, әйтте:

— Юк ул минем... повесткам юк...

Кеше башын күтәрде һәм, үзенә-үзе ышанмыйча, күзләрен җемелдәткәләп, Хәлимгә карап торды да көлеп җибәрде. Көлгәндә, күрәсең, сызлаган тешен кузгатты, кинәт туктап, бәйләгән яңагын тотып торды.

— Менә фәлән-фәсмәтән малай!.. Мин бит сине призывник дип торам.

— Юк, мин доброволь. Добровольләрне кем карый, абый?

Яңагын бәйләгән кеше, түзеп торды-торды да, тагын көлеп җибәрде һәм, кинәт көлүдән туктап, янә яңагын тотты.

— Бар, чыгып кит, тешемне кузгаттың!

Хәлим чыкмады.

— Син минем яшемә карама,— диде ул,— буема да... Мылтыктан атканны күрсәң иде син минем... Бая баганага менгәнне күргәнсең дә, бәлки... Чүп тә түгел миңа анда менү... Ә нидә йөгергәндә мин беркемгә дә ал бирмим. Теге язуны мин аны утны сүндерсәгез дә укый алам... Укыйммы хәзер?..

— Чык!

Хәлим үз файдасына тагын нәрсәдер әйтмәкче иде дә, теге тагы да катырак кычкырып салды:

— Чык! — һәм, кинәт яңагын учына куеп, көйсез баласын тирбәткәндәй тирбәтә-тирбәтә:— Мал-лай актыгы! — дип өстәде.

Хәлим онытылып үкчәсенә баскан иде, сискәнеп яңадан аяк очларына күтәрелде.

Түрдә утырган ак чәчле кеше (бусы — хәрби комиссар иде) ялт күтәрелеп карады.

— Кем ул малай актыгы, сержант?

— Менә, иптәш комиссар.

Комиссар өстәл артыннан чыкты:

— Шушымы малай актыгы?

— Узган атнада да берсе килеп йөдәтеп бетергән иде, иптәш комиссар... Фронтка китәргә сорыйлар.

— Һәм шуның өчен сез аларны малай актыгы дисезме?

— Эшне калдыралар бит, иптәш комиссар.

— Ә сез аларга рәтләп кенә аңлатыгыз. Бүген аның фронтка омтылуы бер дә гаҗәп түгел, сержант. Дөрес, ул сугышның нәрсә икәнен белеп бетерми, ләкин ул моны ил өстенә куркыныч килгәнен аңлап эшли. Кисәтеп куям: кешеләр белән икенче алай тупас сөйләшмәгез.

— Есть, икенче тупас сөйләшмәскә.

— Кил әле, чибәр егет. Ни исемле син?

— Хәлим.

— Так, Хәлим илтәш. Шулай итеп, син солдат булырга исәп иттеңмени?

— Разведчик.

— Нишләп разведчик? Синнән бик әйбәт артиллерист чыгар.— Комиссар чал сакаллы чандыр докторга карап куйды.— Сезнеңчә ничек, Сергей Сергеич?

— Дүрт елдан.

— Мин дә бүген димим. Дүрт елдан. Ә, бәлки, өчтән... Гәүдә бик әйбәт бит.

Доктор малайның беләкләрен, корсак мускулларын тотып карады.

— Пәһлеван була бу дүрт елдан. Үндүрттәме син?

Хәлим төзәтмәде, «алай биш елдан дияр»,— аяк кагып куйды.

— Менә шулай, дүрт елдан кил, яме?

— Хәзер алыгыз сез безне. Военный дәрес гел отлично безнең.

— Безнең?

— Әйе. Без дүртәү... Алып керимме?

— Бар әле, бар...

Минут үтүгә дүрт шәрә малай строевой адым белән хәрби комиссар алдына килеп бастылар, ә тагы бер минуттан, комиссар командасы астында, ишеккә таба юнәлделәр.

— Барыгыз, кайтыгыз, әйбәт кенә укыгыз, ә хәзергә — шагом арш!

Малайлар, аяк очларына баскан хәлдә, яхшы ук оста атлап, ишеккә таба киттеләр. Каралу бүлмәсендәгеләр көләргә дип авызларын ачканнар иде, комиссар, тиз генә аларга таба борылып, бармагын иреннәре өстенә куйды:

— Тс-с...

Ә малайлар чыгып киткәч, канәгатьләнеп, тирән сулады:

— Әйбәт балалар, совет балалары...

Әйбәт балалар коридорга чыккач та әле аяк очларына басып бардылар. Әле каралырга өлгермәгән берәм-сәрәм кешеләр аларны көлеп каршы алдылар:

— Без уйнаганда мондый юк иде лә...— диде бер шаяны,— ай-яй, боларга нинди не өйрәткәннәр...

— Ха-ха-ха...

Малайлар, уңайсызланып, үкчәләренә бастылар. Хәзер аларның елап җибәрәселәре килә иде. Ләкин елама-

дылар. Бу йомшаклыктан аларны бергә булу тыеп калды. Сөйләшмичә генә киенделәр, сөйләшмичә генә чыгып киттеләр.

4 КЕРМИК БЕЗ АНДА...

Тышта ярты төн житеп килә иде инде. Өйләрнең күбесендә ут сүнгән. Мәйдан да баягы кебек гөрләп тормый. Егетләр, аларга ияреп килгән кызлар, аналар, әбиләр юк хәзер анда. Мәйдан бушап, тынып калган.

Малайлар да, хәрби комиссариат алдындагы канау аша салынган күпер кырыена тын гына тезелеп утырдылар. Хәзер алар инде үз уйларының эшкә ашмаганын ачык күрә иделәр. Ләкин бу күңелсез хакыйкать турында сөйләшү түгел, аерым-аерым уйларга да оялдылар алар. Шулай да, беравык сүзсез торганнан соң, Җәләй, Каюм әйтүенә караганда, бая йөгергәндә штаны төшә башлагач туктап калган Җәләй, әйтеп куйды:

— Нишлибез инде, малайлар?

Ул моңар каршы иптәшләренең: «берни дә эшләп булмый, кайта башлыйк» диюләрен көтте, ләкин алай диюче булмады. Каюм, мәйданны әйләнеп чыгып станциягә таба сузылган олы юлга карап-карап торды да, дары кебек кинәт кабынып:

— Китик тә барыйк, малайлар, шушы килеш кенә,— диде.

— Ничек?

— Шулай, өйгә дә кайтып тормыйбыз. Китәбез дә барабыз. Туп-туры...

— Булмый ул.

— Нишләп, Хәлим?

— Мин икенче нәрсә уйладым әле. Райкомга керик без. Секретарь янына...

Шулай диюгә Каюм, бозлы суга чумырып алдылармыни, куырылып килде. Ләкин, курыкканын иптәшләренә сиздермәскә теләп, гади генә итеп әйтте:

— Юк, Хәлим, кермик без анда...

— Нишләп, Каюм?

— Барысы да бер сүздә алар.

— Түгел, түгел...

— Бик усал нәмәрсә диләр аны, безнең белән сөйләшеп тә тормас ул.

— Сөйләшә. Үзебезнең малай дип йөри иде аны безнең әти.

Ниһаять, Каюм секретарь янына керергә теләмәвенең чын сәбәбен иптәшләренең хәтерләренә төшерде...

...Җәйге имтихан вакыты иде. Балалар арифметика эшлиләр. Ә Каюмның чыкмый. Башка вакыт булса, ул инде алдагы партадагы малайга әкрен генә төртеп куяр иде, малай борылып аңар эшләү юлын пышылдар иде. Хәзер кая ул төртү... Район кешеләре бар. Каюмның кулын гына түгел, һәрбер чәч бөртегенә кадәр күзәтеп торалар кебек... Ләкин, ничек кенә булмасын, болай утырып булмый бит инде. Әнә иптәшләре, эшләп бетереп, чыга да башладылар... Каюм, кыюлыгын җыеп, парта астыннан алдагы малайга әкрен генә тибеп алды. Малай Каюмның хәленә төшенде, озак та үтмәде, җилкәсен кашыган булып, үзенең пиджак якасына уч төбе кадәр генә кәгазь кыстырып куйды. Каюм, комсызланып, бөтен гәүдәсе белән кәгазьгә сузылды һәм андагы цифрларны тиз генә күчереп алды да Шаһгәрәй абзыйга илтеп бирде. Укытучы дәфтәрне алып караган иде, көлеп җибәрде. Комиссиядә утыручылар да көлделәр. Каюм әллә җилкәдәге кәгазьне ялгыш күчергән, әллә малай юри шулай язган, мәсьәләнең җавабы: 1 малай басуда 40 сукыр тычкан үтергән диясе урынга, 1 сукыр тычкан 40 малайны үтергән булып чыккан иде. Комиссиядәге бер кеше, көлде-көлде дә, әйтеп куйды: болай кеше җилкәсенә ышанып яшәсәң, ул сукыр тычкан синең үзеңә дә җитешер әле, диде... Моны әйтүченең райком секретаре икәнен белгәч, Каюм җир тишегенә кереп китәрлек булып оялды. Су буена китте дә караңгы төшкәнче авылга кайтырга оялып йөрде...

— Юк, кермик без аның янына.

— Әй-й, танымый ла ул сине.

— Таныр. Күзләре бик очлы аның, Хәлим.

— Арттарак торырсың, күп шыпылдамассың...

Каюм, артта тору, күп шыпылдамау шарты белән, райком секретаре янына керергә риза булды. Башкалардан күрмәкче, калай кружкасын бил каешына бәйләде дә, баскан саен секретарьга якынайганы турында уйлап, иптәшләре артыннан китеп барды.

Хәлим зур йортның парадный ишегендәге звонокны тартты. Җавап бирүче булмады. Тагын тартты. Тагын җавап булмады.

Бикле түгел икән. Хәлим икеләнеп кенә ишекне ачты. Башын коридорга тыгып карап алды да бер читтәрәк басып торган иптәшләренә тамак кырды. Малайлар Хәлим артыннан караңгы коридорга керделәр. Күпердә утырып туңган малайларга коридор бик җылы булып тоелды. Борыннарына әле генә мичтән чыккан кайнар ипи, кайнар ит исе килеп бәрелде. Бу тәмле ис кичә, бүген каралырга керү хыялы белән канатланып йөреп тамактан калган малайларның борыннарын рәхәт кытыклады. Авызларыннан сулар килде аларның.

Каюмның гына борыны сизмәде бу исне. Аның әле һаман да үз кайгысы кайгы иде. Ул, Хәлимнең җиңенә ябышып өстерәлгән хәлдә, пышылдап куйды:

— Әллә кермибезме, Хәлим, ә?

— Юк, юк, керәбез.

— Бик куркам мин, Хәлим.

— Курыкма...

— Шырпы сыз, ичмаса, Хәлим.

Хәлим шырпыга дип кесәсенә тыгылды. Нәкъ шул чакта нәрсәгәдер килеп бәрелде. Самовар икән. Самовар мәтәлеп китеп суы малайларның аяк асларына түгелде, утлы күмерләре чәчелде.

— Кәҗә, ристан! — диде кайдандыр эчтән хатын-кыз тавышы.

Хәлим самовар тавышы белән бу сүзләрне ишетмәде. Ул самоварны утыртып куйды, күмерләрен җыйнаштырды да, куркып калган иптәшләренә эндәште:

— Әйдәгез, бернәрсә дә юк.

— Кемдер кычкырды, Хәлим.

— Юк, юк.

— Кычкырды инде...

— Юк ла. Әйдә, калмагыз,— диде Хәлим һәм берике атлауга тагы нәрсәгәдер килеп бәрелде. Нәрсәдер (чиләкме, кастрюлямы) чыңлап, идән буенча тәгәрәп китте.

Кайдандыр эчтән тагын:

— Һай, ристан гына икәнсең, сөтемне харап иттең, ристан кәҗә! — дип кычкырдылар.

Бусын Хәлим дә ишетте. Сүзләре артыннан ишектән бер хатын атылып килеп чыкты. Ул эчке күлмәктән, чәчләре тузган, ә кулында шактый юан саплы табагач иде. Күрәсең, кәҗәне бер дә кызганмыйча каезларга

уйлаган, күзләре яман усал иде. Ләкин, кәҗә урынында кешеләр күргәч, сүзен дә әйтә алмыйча, катып калды.

— Ялгыш кергәнбез,— диде Хәлим,— таегыз, тай, малайлар!..

Малайлар, абына-сөртенә, нәрсәләргәдер бәрелә-сугыла, кире йөгерделәр. Берсе инде торып килгән, гөнаһсызга җәбер сүзләр ишеткән кәҗәгә абынып егылды. Хәлим дә кәҗә аша мәтәлеп китте. Каушап калмады (инде парадный ишек якын иде, дилбегә киңлеге генә ябылып җитмәгән ишектән коридорга бераз якты төшкән иде) Хәлим, кул астына туры килгән бер иптәшен өстерәп, урамга ташланды.

— Калмагыз!

Башкалар да Хәлим артыннан урамга атылдылар һәм, берсен-берсе узып, зур урам буйлап йөгерделәр дә, беренче тыкрыкка борылып керделәр. Хәлим тыкрык чатыннан башын сузып карады. Юл тыныч, куа чыгучы юк иде.

Бар да койма буена, ботаклары шәрә бер карама төбенә чүгәләделәр. Утырмадылар, чүгәләделәр, райком ягыннан берәр кеше килгәнне күрсәләр, торып йөгерү өчен шулай иттеләр алар.

— Танып калмады микән, Хәлим?

— Һәй, таныймы соң? Күрүенә шыр җибәрде ич.

— Райком булмады ахры ул, Хәлим.

— Булмады, күрәсең. Бер дә ялгышмаган кебек идем. Әти белән җәй башында гына килгән идек әле без анда,— диде Хәлим һәм иптәшләрен яңадан барып эзләп карарга өндәде. Малайлар баш тарттылар. Иртәгә кич, теге хатын күрсә-нитсә танымаслык итеп, кыяфәтләрен өс-башларын үзгәртеп килергә исәп итеп кайтырга чыктылар.

Ә бераз баргач, малайлар ике катлы зур йорт алдында туктап калдылар. Бу йортның ишеге өстендә райком вывескасы булып, тәрәзәләреннән урамга йомшак кына яктылык сибелгән, алдында җиңел автомобиль, берничә җигүле ат тора иде.

— Ә-ә... бирегә күчкән икән,— дип сузды Хәлим.— Керәбезме, малайлар?

Каюмнан башкалар керергә булдылар. Кыстый торгач, Каюм да күнде. Хәлим, тиз генә баскычка менеп, звонокны тартты. Эчтән аяк тавышлары ишетелде.

— Кем бар?

— Без, апа, ач әле.

— Кем соң сез?

— Бу — без, «Ватан»нан.

Парадный ишеге ачылып китте.

— Әчәч, нишләп йөрисез бу вакытта? Кара, син «Ватан» Зиннәт төпчеге түгелме соң?— диде ишек ачкан әби, райкомның уборщицасы.

— Нәкъ үзе, Хәмдия әби.

— Әллә авылыгызда берәр хәл бармы?

— Военный тайна, Хәмдия әби...

— Ә-ә,— дип торды әби.— Кемгә карама, шул хәзер — ваянный тайна,— диде һәм, сукыр лампасының күгелҗем ялкынын учы белән ышыклап үз бүлмәсенә кереп китте. Коридор караңгыланып калды.

— Райком секретаре кирәк иде бит безгә, Хәмдия әби.

Әби, лампасын бүлмәсеннән әз генә сузып, коридорны яктыртып алды.

— Әнә. Икенче ишек.

Хәлим икенче ишекне ачты.

Зур, якты бүлмә иде бу. Түрдәге өстәлдә яшь кенә бер кыз эшләп утыра. Әле кәгазь өемнәрен актара да зур, ак кәгазьгә нидер сызгалый, әле икенче бер өемне караштыра да счет төймәләрен тарткалап, шул ук зур кәгазьгә берничә цифр язып куя. Әле шалтыраган телефонга берничә сүз белән генә җавап бирә дә тагы кәгазьләренә күмелә. Яки үзе берәр колхозга шалтырата: «Бу кем? Әле исән генәме, Әкбәр агай! Райкомнан... Түгел-лә, секретарь ярдәмчесе Идрисова...»

Малайлар башта аңар эндәшергә кыймый тордылар. Менә кыз бер кәгазьне тиз генә укып чыкты да, туктап, бераз уйланып торды. Хәлим, шул вакыттан файдаланып, ишек төбеннән түргәрәк атлады һәм кыюсыз гына эндәште:

— Безгә райком секретаре кирәк иде, апа.

Кыз, ялт күтәрелеп, Хәлимгә карады:

— Нинди райком? Комсомол райкомы әнә каршы ишектә.

— Юк, безгә шушы райком кирәк, зурлар райкомы...— диде Хәлим. Партия райкомы дигән сүзләр аның исенә килмәде.

— Ә кем кирәк?

— Секретарь абый.

— Кайсысы?

Хәлимгә бүлмәнең сул ягындагы ишеккә кадакланган язу ярдәм итте:

— ВКП(б) райкомының беренче секретаре кирәк безгә.

— Нәрсәгә?

— Кирәк инде...

— Нәрсәгә?— диде яшь кыз тагы бер тапкыр. Гүя ул сорау бирмәде, ә кәгазьдәге сүзне укыды.

Хәлим бер адым алга атлады.

— Зур эш... әйтергә ярамый...

Кыз, авызын әз генә кыйшайтып, елмаеп куйды.

— Иртәгә килерсез. Иртә белән.

— Безнең ашыгыч...

Кыз бер сүз дә әйтмәде. Тагы кәгазьләренә чумды. Хәлим ни әйтергә дә белмичә аптырап калды. Бүлмәдә тулы тынлык урнашты. Шундый тын булып торды, кыз кулындагы кечкенә сәгатьнең йөргәненә кадәр ишетелә иде.

Шул чак кинәт кенә секретарь бүлмәсендә кемнеңдер йодрык сугып кычкырганы ишетелде:

— Җебедең син! Кешеләр сугыш башлану белән ныгыды, ир йөрәкләнде, ә син җебеп төштең! Шуның өчен генә дә сине!..

— Тукта, мин дә җебеп торам түгелме соң?— диде Хәлим үзенә үзе һәм кыюланып кызга таба атлады. Шул чак Хәлимнәр кергән ишек ачылып китте.

— Ай, Сәлимә җаным, үтерәләр дип торам!..

Кыз башын күтәрде.

Ишектән керүче хатын, Хәлимнәр яныннан җилтерәп узды да, кыз өстәле каршындагы скамьяга килеп ауды.

Бу Хәлимнәргә табагач күтәреп чыккан, алтын тешле, теше кебек үк алтын чәчле хатын иде.

Хәлим үзен бик тиз кулга алды. Һәм, хатын сөйли башлагач, кулларын олыларча артка куйды да башын күтәреп стеналардагы плакатларны, рәсемнәрне, портретларны карап йөргән булды.

Рәсем — эшче белән крестьян. Иңгә-иң басканнар. Икесе дә уйчан. Бераз сагышлы да бугай. Шул ук вакытта бернинди куркыныч алдында каушап калмаслык тыныч. Илне саклап калу юлында очравы мөмкин булган һәртөрле кыенлыкларны үтеп чыгарлык көчле, кыю, зирәк.

Плакат. «Үлем фашист илбасарларга!» Бу сүзләр зур

кара хәрефләр белән язылган. Әйтерсең, хәрефләр жансыз түгел — хәрәкәт итәләр, күкләр күкрәтеп, фашистлар өстенә баралар...

Тагын плакат. Кызылармеец. Корыч каскадан. Тынгысыз күзләре белән Хәлимгә караган, бармагын туп-туры Хәлимгә төбәгән. Кычкыра: «Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең?»

Хәлим, уңайсызланып, күзен плакаттан алды.

— Бернәрсә дә эшләмәдем, ә эшләрмен,— диде Хәлим күңеленнән,— эшләрмен...

Аннан ул бер почмакка кереп сыенган Каюмга һәм, әгәр алтын тешле хатын: «Менә шушы юньсезләр иде инде алар»,— дия башласа, чыгып йөгерергә хәзер торган Җәләй белән Мотыйкка, курыкмагыз дигән мәгънәне аңлатырга теләп, күз кысып куйды. Үзе икенче стенадагы плакатларны карап йөри башлады.

Хатын, ире кайткан төшкә аш пешереп йөрүен, аны көтеп, бераз ятып торуын сөйләде. Аннары тезеп китте:

— ...Сикереп торып чыксам, коридорда биш-алты ир. Берсеннән-берсе тазалар, Сәлимә жаным... Бөтен әйберне алып чыгып китәргә җайлап куйганнар, кәҗәне суймакчы булганнар ахры: аякларын бәйләп салганнар... Икесе безнең ишекне каерып ята... Ярый әле каушап калмадым. «Давыт! Караклар бар, тиз булыгыз!»— дип кычкырган идем, барысы да чыгып йөгерделәр. Кулларында пычаклар, Сәлимә жаным... Давыт биредә түгелме?

Кыз Давытның биредә, бюрода икәнен әйтте. Хатынга графиннан су салып бирде дә үзе тиз генә райком секретаре кабинетына кереп китте, һәм аннан бик тиз бер кеше нәртеп чыкты. Бу әлеге хатынның ире — Давыт иде. Хатын аңар барысын да сөйләп бирде, ир телефон трубкасын алды:

— ...Әле яңарак кына. Алты-җиде кеше. Әйтмә дә инде, бөтен тирә-якта булмаган хәл... Прошу... Тоткач миңа хәбәр итәрсез. Мин бюрода. Рәхмәт.

Бу вакытта Хәлим пырхылдап көлеп җибәрергә әзер торган иптәшләрен ишарәләр ясап тыеп калды.

5 ГАДӘТТӘН ТЫШ АШЫГЫЧ

Менә кабинет ишеге ачылып китте. Аннан тәмәке төтене һәм күп кенә кешеләр чыкты. Секретарь ярдәмчесе-

нең бүлмәсендә ыгы-зыгы башланды. Хәзер кыз Хәлимнәрне генә түгел, биш-алты каракны өркеткән хатынны да онытты. Хәлимнәр, моменттан файдаланып, кешеләр арасыннан этелә-төртелә, кабинетка кереп киттеләр.

Ишек төбеннән түргә таба озын өстәл сузылган. Өстәлнең түр башында кызыл сукнолы, лампасы яшел абажурлы тагы бер өстәл. Бусы райком секретареның эш өстәле. Өстәл артында ике кеше нәрсә турындадыр шыпырт кына сөйләшә иделәр.

Малайлар керүләренә ишекнең уң ягындагы стенага килеп сыландылар. Хәлим, үзләре турында белдереп, борынын тартып куйды. Кешеләрнең берсе өстәлдән башын күтәреп карады. Ләкин, әллә күе тәмәке төтене аша күреп җиткермәде, әллә күреп тә әһәмият бирмәде, сүзен дәвам итте.

— Секретарь кайсы икән?

— Утырганы,— диде Каюм.

Һәм, аның белән күзгә-күз очрашудан куркып, берәрсенең артына кереп посарга теләде. Ләкин малайлар белән стена арасында Каюм сыенырлык түгел, энә төртерлек тә урын калмаган иде.

— Мин чыгып торыйм булмаса, күңелгә әлләниләр килә,— дип пышылдады Каюм.

Хәлим аның итәгеннән тотты:

— Чыкмыйсың!

— Ай, таныр бит, Хәлим...

Хәлим җавап бирмәде. Менә кешеләрнең ярты гәүдәсе белән өстәлгә ятканы кузгалды, секретарь белән саубуллашты да тиз-тиз ишеккә килде. Ул малайларга нидер әйтмәкче булып бераз тукталып торды да, кире уйлап, тиз генә чыгып китте.

Хәлим тагын борынын тартты.

— Кем анда?— диде райком секретаре, башын күтәрмичә генә. Һәм искиткеч тизлек белән нидер язуын дәвам итте.

— Без идек, секретарь абый...— диде Хәлим, бик үк мескен дә, бик үк батыр да булмаган тавыш белән.

Райком секретаре ни дип тә әйтмәде. Тагы да тизләтте бугай ул язуын. Соры тупас кәгазь өстендә каләменең каты кыштырдавы ачык ишетелеп торды.

Менә секретарь язуыннан туктап, каләмен өстәлгә

куйды һәм, күз иярмәс тизлек белән телефон тоткасын әйләндереп, трубканы алды:

— Квартираны!.. Нәсимә? Хәзер кайтам. Юк, юк, кызым, инде бусында кайтам. Ә син өстәлгә алып куй да ят...— диде ул һәм урыныннан торды.

— Китә,— диде Хәлим, өметсезләнеп.

— Китә,— диделәр башкалар да.

Райком секретаре өстәлдән бер өем кәгазь алып папкасына салды, аннан малайларга карады һәм телефон аша сөйләшкәндәгечә тиз генә итеп:

— Ни йомыш?— диде.

— Без...

Хәлим әйтеп бетерергә өлгермәде, кара пиджагына икс яклап җиз төймә тезелгән берәү ишекне бик тиз ачып, бүлмәгә атылып керде һәм берничә атлауда секретарь өстәле янына килеп җитте.

— Телеграмма. Гадәттән тыш ашыгыч. Иптәш Сталиннан.

Җиз төймәле кеше телеграмманы райком секретарена бирде. Секретарь ашыгып, дулкынланып укый башлады. Ул телеграмма өстендә күзләрен шундый тиз йөртте, гүя ул укымый, үзенә кирәкле сүзне генә эзли иде.

— Һ-м...— диде ул, укып бетереп.— Фронтта хәлләр без уйлаганнан катлаулырак, күрәсең.

— Неужели монда хәтле килеп житәр инде?

Секретарьның күзендә усал очкын кабынып китте. Җавап бирмәде ул. Бераз уйлапып торды да өстәлендәге звонок кнопкасына басты. Ишектә элеге яшь кыз күренде.

— Бюро членнары биредәме әле?

— Таралдылар инде.

— Җыегыз. Ярты сәгатьтән биредә булсыннар.

Яшь кыз башын иеп чыгып китте.

Телефон шалтырады.

— Тыңлагыз әле,— диде секретарь җиз төймәлегә. Тегесе трубканы алды.

— Кызыгыз, иптәш Вәлиуллин.

— Әйтегез, хәзер кайтам.

Вәлиуллин кискен хәрәкәт белән урыныннан торды.

— Сез, иптәш Вафин, барыгыз, тиз генә радионы хәзерләгез. 5.30 да чыгыш ясыйм.

— Иртәнге 5.30 да?

— Әйе,— диде секретарь һәм сәгатенә карады.— Ашыгыгыз.

Җиз төймәле кеше кергәндәге шикелле үк тиз чыгып китте.

Секретарь папкасын алды һәм, боегып карап торган малайларны күреп, яңадан өстәлгә куйды.

— Ә сез нишләп йөрисез бу вакытта? Нинди кайгы төште башыгызга?

Көтелмәгән сораудан Хәлим каушап калды: «Нидән башларга икән?»

Ләкин күп уйлап торырга ярамый. Бая кемнедер җибәргән дип орышучы шушы булгандыр әле... Безне дә җибәргәннәр дип чыгып китүе бар. Шулай дип уйлады Хәлим һәм сөйләп китте:

— Сталин хәзер бөтен нәрсә фронт өчен, ди, ә алар безгә экият сөйлиләр.

Секретарь малайларга якынрак килде.

— Төшенмим, нәрсә сөйлиләр, кемнәр сөйлиләр?

— Кемнәр дип, барысы да... Әле кичә Күзлек болай ди...

— Тукта, тукта... кем дидең әле?

— Күзлек.

— Кем инде ул Күзлек?

— Кем булсын. Укытучы, билгеле. Шаһгәрәй абзый.

— Әһә. Ә нәрсә сөйли?

— Җыен юк-барны. Кичә әллә нинди вертикаль сызыклар, горизонталь сызыклар турында сөйләде.

— Әһә... ә аңладыгызмы соң? Мәсәлән, вертикаль сызык нәрсә ул?

— Тыңламадык та без аны.

— Әһә. Тагын нәрсәләр сөйли?

— Гипотенуза ди, катет ди...

— Әһә.

— Җыен чүп-чар... Тагын берсе әллә нинди җөмләләр яздырды. Куш җөмлә диме...

— Кушма ди.

— Анда Гитлер килә, без шуларны ятлап утыр.

— Ала-ай... Кызык, кызык,— диде секретарь. Әле генә кигән фуражкасын салып, чөйгә элде.— Әйдә, түргә узыгыз инде болай булгач.

Малайлар, нишлибез дигән мәгънәдә, Хәлимгә карадылар. Хәлим берникадәр вакыт үзе дә нишләргә белми

торды. Аннары иптәшләренә алга узарга ымлады һәм үзе дә кыюсыз гына урыныннан кузгалды.

Райком секретаре үзенең эш өстәле артына кереп утырды.

— Ә сез якынрак килегез. Бирегәрәк. Менә шулай.

Малайлар бар да өстәлнең бер ягына, бер-берсенә сыенышып утырдылар. Каюм үзенә урынны арттарак сайлады һәм бер читтә торган буш графинны әкрен генә үз алдына таба шудырды да, хәйләсеннән канәгатьләнеп, иркен сулап куйды.

Секретарь звонок бирде.

— Су кертегезче.

Яшь кыз кереп графинны алып чыгып китте. Каюм алдында бер стакан гына калды.

Суга батучы саламга ябыша диләр. Каюм борынын стакан артына яшереп, булдыра алган кадәр, түбән иелде. Ләкин бик тиз әйләнеп кергән кыз, узып барышлый, Каюм алдыннан стаканны да эләктереп алып китте һәм сулы графин белән бергә секретарь алдына куйды. Сугышчы ачык кырда, ут астында калды. Секретарь, стакан тутырып су эчкәч, малайларга эндәште:

— Я, шуннан?

— Безнең ул әкиятләрне тыңлап утырасыбыз килми.

— Ә нишләмәкче буласыз?

— Фронтка китәбез без.

— Фронтка? Нәрсәгә?

— Разведчик булырга.

— Әһә.

— Ә хәрби комиссариат җибәрми.

— Ник җибәрми?

— Яшь дигән була. Ә анда олы булу нигә? Без барыбыз да яхшы ата беләбез. Түш белән шуышып та йөри беләбез. Военный дело безнең һаман отлично.

Каюм үзенең «Ворошиловча атучы» значогына игътибар иттерү өчен күкрәген алга чыгарды.— Ә «моны сиңа сукыр тычкан өчен бирделәрме әллә» дисә? — Малай тагын җыерылып килде.

— Сорарга онытып торам икән, кем дип белик үзегезне?

Хәлим үз исемен әйтте. Аннары иптәшләренекен тезеп китте.

— Сез хәрби комиссариатка әйтегез, җибәрсен ул безне.

— Әһә. Кайсы колхоз әле сез?
— «Ватан».
— Кайсы «Ватан»?
— Никкүчтем, билгеле.
Секретарь көлемсерәп куйды.

Никкүчтемнең тарихында бер кызык урын бар. Бу авылның кешеләре, җир җитмәгәнгә күрә, Акбуа исемле бер зур авылдан аерылып чыгалар. Урманын кисеп, чирәмен күтәреп, зур мәшәкатьләр чигеп беренче уҗымны чәчүгә, революция була. Акбуалар алпавытны куалар, җирләре чамасыз күбәеп китә. Моны күреп, күчеп чыгучылар бик каты үкенәләр.— «Их, азапланып йөрүебез генә калды...»— Ә бер тапкыр, имештер, бер исерек башы базардан кайтып килешли, Акбуа басуында атын туктатып, кычкырамы-кычкыра: «Ник кенә күчтем мин, э, ник күчтем мин?!» — ди. Моны Акбуаның ат саклаучы малайлары ишетеп калмасынмы! Әлбәттә, чәчми-түкми кайтып сөйлиләр. Шуннан соң күчеп чыккан авылның телдә йөри торган исеме Никкүчтем булып китә.

Ләкин секретарь көлемсерәгәндә бу турыда түгел, Каюмны инәдә утырткан вакыйга турында уйлады һәм шуны малайларның исләренә төшерде. Каюм (әйтерсең секретарь аны кызыл чәчләреннән эләктереп бозлы суга чумдырып алды) куырылып килде: «Бетүем шушы икән...»

Ләким Каюм бетми калды. Секретарь бу турыда күп сөйләмәде, ул әз генә көлеп торды да, нәрсәдер исенә төшеп, телефон трубкасын алды. Кире куйды. Аннары малайларга карап әйтте:

— Ә беләсезме нәрсә, егетләр, сез юкка тузгыгансыз... Гипотенуза, катет, вертикаль, горизонталь сызык... Болар берсе дә әкият түгел, фән; ә фәнсез кешелек дөньясын алга җибәреп булмый, аңлыйсызмы, фәнсез коммунизм төзеп булмый... Бер эшегез ошады миңа: сез партия мөрәҗәгатен укыгансыз...

— Күңелдән беләбез без аны.

— Бик яхшы. Ләкин шунысы кызганыч: сез аны дөрес аңламагаң. «Барысы да фронт өчен»— бу һәркем сугышка китсен дигән сүз түгел. Биредә дә сугыш. Менә мин райкомда эшлим — мин фашистлар белән сугышам. Телеграм кертеп чыккан элемтә начальнигы да, барлык колхозчылар да сугышалар... Сез дә сугышасыз хәтта, аңлыйсызмы, сез дә. Яхшы укыйсыз икән, димәк, сез

дошманны җиңүгә булышасыз... Әйе, әйе, мин арттырып әйтмәдем. Менә тыңлагыз. МТСның никадәр тракторын фронтка җибәрдек, автомобильләрен, атларын... Кайтса дә бик әзе кире кайтыр. Димәк, хәзер биредә алар урынына яңаларны булдырырга кирәк... Гитлер үзе басып алган шәһәр, авылларны көйдереп килә. Сугыштан соң безгә аларны яңадан төзергә туры киләчәк. Һәм бу эшне башкару өчен бик күп белгечләр кирәк булачак. Яхшы укысагыз, сез шуларны төзүче булып җитешәчәксез... Хәзер «Күзлек» турында...

Малайлар коелып төштеләр. Секретарь нидер исенә төшеп, күн тышлы куен дәфтәренә берничә сүз сызгалап куйды да дәвам итте:

— Нәрсә, ул сезгә берәр малай-шалаймы, әллә сезнең күзләрегезне ачучы, сезне дөньяга өстерәп чыгаручымы? Кемгә ябышканнар бит, ә!? Беләм мин аны, Шаһгәрәй абзыйны. Минем дә укытучым иде ул. Бу эшкә яраклы кеше итеп мине башта ул, Шаһгәрәй абзый, тәрбияләде...

Малайлар бу кадәресенә ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. «Бөтен район башлыгы бит бу! Шул кеше кайчандыр Шаһгәрәй абзыйдан укып йөрсен әле!.. Әнә нинди икән ул безнең Шаһгәрәй абзый!..»

Секретарь сүзен дәвам итте:

— Ә сез беләсезме, ничә агроном, врач, инженер башлап аңарда укыган?.. Сездән дә партия, хөкүмәт эшчеләре, белгечләр әзерләргә керешкән ул. Ә сез, тәти егетләр, аның шундый бәя биреп бетергесез хезмәтләре өчен, тоткансыз да аңар кимсетеп кушамат таккансыз. Менә шушы тупаслыгыгыз өчен генә дә мин сезне фронтка җибәрмәс идем...

Яшь кыз керде, ул бюро членнарының җыелып бетүләре турында хәбәр итте.

— Әйтегез, керсеннәр,— диде секретарь кызга.— Ә сез барыгыз, авылыгызга кайтыгыз. Укуыгызда уңышлар телим.

Әле генә таралган бюро членнары яңадан кабинетка кереп тулдылар. Райком секретаре аларга урын тәкъдим итте һәм үзе, тиз генә торып, гимнастеркасын, бил каешын рәтләде, гәүдәсен турайтты. Хәзер аның ак чырасна әз генә алсулык сибелде. Ябык бите бераз тулыланып киткән төсле булды. Йокысызлык белән кызарган, тоныкланган күзләре нурлана төште. Әле генә чәй янында

балалары белән сөйләшеп утырган атаны хәтерләтә иде ул, хәзер исә — һөҗүмгә әзерләнгән сугышчы кыяфәтенә керде:

— Сез мине гафу итегез... Гадәттән тыш мөһим мәсьәлә.— Секретарь телеграмны кулына алды.— Фронтта хәлләр без уйлаганнан киеренкерәк, күрәсең. Иптәш Сталин Казан шәһәре әйләнәсенә оборона рубежы төзергә әмер бирә... Ә сез барыгыз, бар, егетләр, Шаһгәрәй абзыйга сәлам әйтегез. Башлангыч классларны укытмыймыни ул хәзер?

— Укыта. Бездә ул Кураев абый сугышка киткәч кенә...

— Сугыш, сугыш... Яхшы, хушыгыз...

Малайлар, башларын иңнәренә яшерә төшеп, чиктән тыш күңелсезләнеп кабинеттан чыгып киттеләр.

Тышта таң беленеп килә иде инде. Тын. Җирне, каралты түбәләрен беренче кырау бизәгән. Тәгәрмәч эзләрендә җыелып яткан яңгыр суларының өсләре бозланган. Еракта, авыл очыннан, әллә кичә алынып кайткан, әллә бүген каралырга барачак бер егет, гармонь уйнап, җырлап килә:

Чулпан калка, таң ата,
Кыз сөйгәнен озата-а:
«Исән йөреп, исән кай-йт,
Фашистларны җиңеп кайт.

Малайларның күзенә кырау бизәкләре күренмәде, колакларына җыр кермәде. Алар райкомнан чыгуга, киңәшеп тә тормыйча, Никкүчтемгә таба юл алдылар. Әле кызу-кызу бардылар алар, әле әкрен генә атладылар. Кырга чыккач кына бераз тынычландылар малайлар. Бер чишмә янында туктап кибеттән алган калай кружкалары белән су эчтеләр дә йөгерергә тотындылар.

— Мәктәпкә өлгерсәк кенә ярар иде...

6 НУЛЬЛӘР, ЦИФРЛАР...

Такта алдында басып торган Хәлимнең күз алдыннан бу вакыйгалар кинокадрлар кебек тезелеп үтте.

«Каян белгән? «Күзлек» турында да белгән микән? Анысын гына белмәсен иде, ичмасам...»

Шаһгәрәй абзый мәсьәләне кабат укырга тотынды. Хәлим, беренче цифрларны тактага язып кую өчен, башын күтәрде. Йокламау, тәүлектән артык ашамыйча йө-

герәп йөрү талчыктырган иде аны. Авызының тәме юк, күзләре әчетә, башы аңгы-миңге, гүя миен бушатып алганнар да, тыгызлап чүбек тутырып куйганнар инде. Цифрлар Хәлимнең күз алдында сикергәләп тордылар да ерагая башладылар. Бөтенләй югалып китмәсеннәр дип, Хәлим аларны тизрәк тактага язып куйды. Икенче, өченче саннарны ишетте Хәлим. Ләкин аларын язып өлгерә алмады, укытучы дүртенчене әйтте. Цифрлар күз алдына килеп тезелделәр. Башта алар тик кенә тордылар, аннан сикерешә башладылар. Ике җиделе цифр, ыргаклары белән Хәлимнең күз кабакларына асылынып, башын аска өстерәде. Калганнары, Хәлимнең аяк астына төшеп, бии башлады. Нульләр, туп шикелле, бер менделәр, бер төштеләр. Хәлимгә хәтта аларның тавышлары да бар кебек тоелды. Аннары нульләр бик күп булып үрчергә тотындылар. Нульләр бөтен класска тулдылар. Берсе, бик зурысы, очып йөрде-йөрде дә, класс журналына, Хәлим исеме турысына барып кунды.

Хәлим сискәнеп, авырайган күз кабакларын күтәрде. Таркалышкан цифрларны башына җыярга теләде. Ләкин кая ул!..

Малай ниндидер ят тавыш белән:

— Гафу итегез... тагын бер тапкыр кабатламассыз микән, Шаһгәрәй абзый?— диде.

Укытучы күзлеген маңгаена менгерде.

— Тукта, тукта, кайсы тимерче игә китергән әле моның телен? — диде укытучы, гаҗәпләнеп.— Ә, әйе.— Ул мыек астыннан гына елмаеп куйды һәм ишеттереп әйтте:

— Мөмкин,— диде ул һәм мәсьәләне кабатлап чыкты. Аны эшләү кичә дәрестә булмаган Хәлим өчен ансат түгел иде: цифрлар тагын урыннарыннан кузгалыша башладылар. Хәлим, тагын бер атласа ярдан мәтәлеп төшеп китәчәк кеше кебек, дерелдәп куйды һәм тиз генә башын күтәрде. Бөтен уйларын, хәтта фронтны да башыннан чыгарып ташлап, мәсьәләне чишәргә керешә. Мәсьәләне томалап торган пәрдә югары төште. Күңелендә аны эшләүнең планы өлгерә башлады.

7 ТЕГЕЛӘР ЧИШКӘН

Малайлар каралырга чыгып киткәндә, әниләре шикләнмәсен өчен, үзләре белән сумкаларын гына түгел, тимер көрәкләр дә алганнар иде. Янәсе, бүген мәктәптә

дәрескә кадәр өмә була... Һәм бөтенесен авыл башындагы күпер астына күмеп калдырганнар иде. Сумкаларын «каралып» кайтышлый ук төшеп алдылар. Ә кирәкләрен алырга икенче көнне кич кенә төштеләр. Юлда очрап бер-берсен оялтмас өчен, һәркайсы соңрак төшәргә уйлады.

Каюм килеп җиткәч, берәрсе юк микән дип, күпер ярыгыннан карады. Ярый әле карады, Хәлим анда иде. Ул туфрактан көрәген казып маташа, бераз тынып тора да, үз-үзенә сөйләнеп, сызгыргалап куя һәм хәрби комиссариат алдында ишеткән җырның сүзләрен, өйрәнергә бирелгән шигырьне ятлаган кебек, кабатлый иде:

Канга кан, үлемгә үлем.
Мылтык ал, иптәш,
Зур көрәш бүген...

Хәлим бу сүзләрне еш кабатлый, дәртләнеп китеп, җыр көенә китерә башлый. Ләкин, әллә ишетерләр дип шикләнеп, әллә көен рәтләп белмәгәнгә, шигырь итеп кенә көйли иде:

Канга кан, үлемгә үлем...

Хәлим көрәген казып алып, өскә күтәрелә башлауга, Каюм күпернең икенче ягыннан посып кына аска төшеп китте.

Хәлим турында Каюм:

— Юк, тәүбә итмәгән бу,— дип уйлап алды һәм, иптәшенең инде кайтып киткән булуына ышангач кына, өскә менде. Ләкин Хәлим китмәгән, күпердән нибары бишүн адымда туктап, район үзәге өстендәге шәфәкъ кызыллыгына карап тора иде. Каюм искәртмәстән килеп чыккач, ул сискәнеп китте.

Иңнәренә көрәк салган ике малай, беравык ни әйтергә белми тордылар. Болай тору уңайсыз иде, шуңар күрә Каюм, көндез күрешкән булсалар да:

— Исәнме, Хәлим,— дигән булды.

— Исәнме.

Тагын уңайсыз тынлык урнашты. Алар, бер-берсен әйдәп тә тормыйча, урам буйлап китеп бардылар.

— Кайдан белде икән ул аны, ә, Хәлим? Без кайтып җиткәнче үк белгән бит.

— Райкомнан Шаһгәрәй абзыйны Акбуа телефонына чакырып әйткәннәр дип ич.

— А-а!.. Сиңа эләктеме, Хәлим?
— Ә сиңа?
— Булды бераз... Шаһгәрәй абзый әнигә үзе кереп әйткән.
— Каты эләктеме?
— Һәй, хатын-кызның катысы ни дә, йомшагы ни... Менә елаулары белән үзәкне өзәләр алар.
— Минем елап-интеп тормады. Рас, рас!..
— Кыйнады?
— Кай җирен кычыта. Идән астына ябып куямы дип торам.
— Әллә япканы бар?
— Ничек кепә әле!.. Бер тапкыр ике сәгать тотты, малай. Уен түгел, кыштырдыйлар... Күзләре елтыраган төсле була, койрыклары тәнгә тиеп-тиеп китә.
— Әллә күсе...
— Әйтмә, әйтмә. Укшытасың.
Авыл советы янында кемнәрдер сөйләшеп тора иде. Малайлар, аларга очраудан уңайсызланып, урамның икенче ягына чыктылар.
— Әтигә язам, дип куркыта әле, җитмәсә.
— Минеке дә.
— Менә сиңа фронт!..
— Зарар юк, бер җае чыгар әле. Теләге булгач...
— Теләк дип...
— Нәрсә, әллә син?..
Каюм, Хәлимдә туа башлаган шикне таратырга ашыгып, җавап бирде:
— Син минем өчен борчылма, туган.
Хәлим, шулай микән дигән мәгънәдә, иптәшенә карап алды һәм шунда ук кул бирде:
— Хуш. Ләкин сиздерә күрмә, малай.
— Тыныч бул...
Каюм өенә кереп калды. Хәлим дә «Канга кан» көенә сызгырына-сызгырына өенә кайтып китте.

Районга сәяхәт тәмам йончыткан иде Хәлимне. Ашап та тормады, урын-җирен кече якка алып кереп җәйде дә башын мендәренә төртте. Малларын карарга чыккан әнисе әйләнеп кереп: «Аш учакта әнә, үзең алып аша», дигәндә, Хәлим изелеп йоклый иде инде.

Шәмсия җиңги, ашны учактан алып куяр өчен, кече якка керде. Шуның өчен генә керде ул кече якка. Ләкин алай тиз гепә чыгып китә алмады.

Әй ана, ана!.. Баладан да якын, баладан да кадерле зат бармы соң дөньяда синең өчен! Менә ул карангыда күзләре белән улын эзләде. Тәрәзә буена, тәрәзә төбе буе гына булып, бөгәрләнеп яткан иде Хәлим. Кичә дөньядагын калдырмый әйтеп орышкан, бер-икене төшергәләп тә алган ана хәзер әкрен генә килеп, чиксез кызгану һәм сөю белән, аның аякларын сузып, җайлап яткырды, озак кына яңакларыннан сыйпап торды һәм суккан-орышканнары өчеп үкенеп, елап җибәрде. Елыйелый өйалдыннан үз юрганын алып кереп улының өстенә япты, елый-елый әкрен генә олы якка чыгып китте.

Ә Хәлим бу вакытта татлы төшләр күреп ята иде: имеш, аны армиягә алганнар... «Мин сине беркөн сынар өчеп генә алмый җибәрдем»,— ди ак чәчле комиссар; ул Хәлимгә солдат итеге, солдат фуражкасы киертә. Аннары түгәрәк солдат ипие, селедка, бер бик зур шакмак шикәр тоттыра да поездга утыртып җибәрә... Фронтка килгәч, Хәлим озын бау табып алып, юл буендагы бер агач башына менеп утыра һәм бер-бер артлы тезелеп килгән фашист мотоциклетчыларының муеннарына бау ташлап бик каты тартып ала, фашист мотоциклет өстеннән чәнчелеп килеп төшә. Ә Хәлим аны өстерәп алып, агач ботагына бәйләп куя. Кырыклап фашистны асып куя ул агач ботакларына. Менә кайдандыр Хәлимнең әнисе килеп чыга. Фашистлар, улыңа әйтә күр, апакай, безне җибәрсен, дип ялыналар. Ялыналар, ә үзләре, тотып алып буып ташларга чамалап, кулларын гел Хәлимгә сузалар... Хәлим сискәнеп уянып китә.

Уянып китсә, өйдә чыннан да кемнәрдер кычкыра иде. Берсе Җәләй әнисе икән, икенчесе Мотыйкныкы, Мотыйк әнисе үзе кычкыра, үзе елый.

— Шул аздырып йөри бөтен авыл малаен, синең шайтаның! — диде ул елый-елый.— Ярый әле озатып куймаганнар... Кәгазь-конвертларына хәтле булган бит, әдәм имгәкләренең... Янәсе, юлдан безгә хатлар җибәреп тормакчы булганнар. Калай кружкаларга кадәр сатып алганнар, котелокларга кадәр әзерләп куйганнар бит. Менә син, ә, менә син!.. — диде ул һәм барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп китте...

— Чишкәпнәр, Мотыйк белән Җәләй чишкән. Кайдан вырттем соң шул сатлык җаннарны!..— дип уйлады Хәлим һәм, хатыннарның чыр-чуларын ишетмәс өчен, башыннан ук бөркәнеп ятты. Ә тавыш барыбер ишетелде. Хәлим шыпырт кына торып киенде дә тәрәзәдән өй түрләрендәге рәшәткәле бакчага сикерде. Каюмнар турысына җитеп, су трубаларын песи кебек тырнап, ике-өч тапкыр мияулап куйды. Бу Хәлимнең Каюмны аеруча әһәмиятле эшләр буенча тышка чакыра торган шартлы сигналы иде. Озакламый тәрәзәләрнең берсендә Каюм күренде, һәм тиз арада капкадан атылып килеп тә чыкты.

— Теге тишек авызлар изгәпнәр бит эшне,— диде Хәлим. Һәм бөтенесен сөйләп бирде.

— А-а... — Каюм телен шартлатып куйды.

— Әйдә тизрәк! — диде Хәлим.— Әниләре бездә әле аларның.

— Нәрсәгә?

Хәлим йодрыгын күрсәтте.

— ...Китмисең икән, китмә. Ә серне нигә чишәргә!

Каюм теләмичә генә Хәлим артыннан иярде. Менә алар Мотыйклар өй түренә килеп туктадылар.

— Чык әле, Мотыйк дус!— диде Хәлим.

«Дус»ның ни мәгънәдә әйтелгәнен аңлаган Мотыйк эндәшмәде.

Хәлим тәрәзә дөбердәтергә тотынды, тавышын күтәрә төште:

— Чык, Мотыйк — кыт-кытыйк!..

Шул чак кемнеңдер көчле кулы аның җилкәсеннән эләктереп алды. Кем бу? Хәлим борылмакчы булды, борыла алмады. Менә кул җилкәне бераз бушатты. Хәлим борылып карады. Аның җилкәсеннән, шулай ук Каюмныкыннан пожарный Сабир эләктереп алган иде.

— Ваянный бриме икәнне беләмсезме?..

— Беләбез.

Пожарный Сабир малайларның җилкәләрен ычкындырды:

— Таегыз!.. Тай!..— диде ул тамагы карлыккан каз тавышы белән. Башка сүз әйтмәде. Малайлар шыпырт кына үз урамнарына шылдылар.

Каюм бик үк ашыкмады. Ул, чатка җиткәч, кинәт туктап:

— Кыйна мине, Хәлим,— диде.

Хәлим аптырый калды:

— Ник?

— Кыйна.

— Син дә сөйләп йөрдеңме?

— Юк, мин сөйләмәдем и сөйләмәм дә. Мин... антымны боздым, Хәлим.

— Шыр җибәрдең? Кабынуыңа сүндең? Их, син, порох!.. Чәчрәп чыккан булды бит әле: имеш, военкоматсыз гына китәбез дә барабыз...

Каюмның башы салынып төште.

— Кыйна,— диде ул елак тавыш белән.

Хәлим иптәшен бер якка этеп җибәрде дә, күңелсезләнеп, нидер эзләгән шикелле аска карап, әкрен генә өйләренә таба атлады. Каюм бер урында кузгалмыйча басып торды да йөгереп килеп Хәлим каршысына чыкты.

— Кыйна син мине, кыйна, Хәлим.

Хәлим, кулларын кесәләренә тыккан килеш, Каюмны читләтеп узмакчы булган иде дә, тегесе үҗәтләнеп Хәлимгә таба этелде.

— Юк, кыйна син мине...

— Сугышасың киләме?

— Мин сугышмыйм. Син генә кыйна, Хәлим.

Хәлим, түземен җуеп:

— Кит юлдан!..— дип кычкырды.

Ул шундый ярсып, шундый куркыныч итеп кычкырды, Каюм үзенең бу бәйләнүе белән иптәше алдында ярлыкау казана алмаганын, бәлки аның ачуын гына кабартканын аңлап, читкә тайпылды.

Хәлим әкрен генә, теләр-теләмәс кенә караңгы урам буйлап өйләренә таба атлады. Артта башын иеп калган җан дустының ихтыярсыз елап җибәргәнен ишетте ул. Һәм Хәлим, инде бер иптәшсез дә калган Хәлим, тәрәзәдән кереп, өстен дә чишенмичә, урынына йөзтүбән капланды да, үксеп елап җибәрде. Бераз тынычлангач, аның күз алдында соңгы көннәрдә башыннан үткәннәре тезелә башлады.

...Мәйдан. Радио. Военкомат. Янагын бәйләгән кеше. Ак чәчле военком. Райком секретаре...

Ә ул барысыннан да әйбәт. Хәлимгә аның фронтка җибәрмәве генә ошамады. Тукта әле, ул кемнедер, җибәргән, дип орышты бит. Кара, Хәлим дә җибәп бара түгелме соң?..

Хәлим торып утны күтәрде. Китап киштәсеннән таушалып беткән бер газета эзләп алды. Менә ул кат-кат укылган «Партизан улы» исемле очерк. Хәлимне фронтка ашкындырган, фашистлардан үч алырга әйдәгән коточкыч очерк шушы бит инде.

...Петя исемле бер рус малаеның этисен немецлар асып үтерәләр. Әнисеннән тирән итеп кабер казыталар. Көч-хәл белән казып бетергәч, Петяның әнисе кулын өскә суза. Немецлар кычкырып көләләр һәм ирен дә шунда төртеп төшерәләр. Петянең әнисе, немецларның уйларына төшенеп, җан әчесе белән кычкырып җибәрә. Немецлар кычкырып көләләр һәм... чокырдан чыгарылган юеш ком белән һичнәрсә аңышмыйча уйнап утырган кечкенә кызчыкны (Петяның сеңелесе) әти-әнисе янына алып аталар.

Ана йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып баласын кулына ала, икенчесе белән кабер читенә ябыша. Кул шул килеш кала. Немецлар чокыр өстенә бүрәнәләр салып ком өяләр.

— Ничә сәгать чыдарлар?— ди берсе.

— Егерме дүрт.

— Ә, минемчә, кырык сигез.

Ана белән баланың тавышы бары өч тәүлек үткәндә генә тына. Чокырны ачып карасалар, ана, сабыен күкрәгенә кысып, чокыр төбендә ята. Ә бала ананың муенын нәни, ябык куллары белән урап откан да...

Урманда партизан булып йөргән Петя, бу турыда ишетеп, авылга кайта. Немецлар штабына килә. Сакта торучы немецка: — Мин партизаннарның кайда ятканнарын беләм, шуны әйтергә килдем,— ди. Уникe яшьлек малайны, шикләнмичә, штабка кертәләр. Өстәл янында җиде немец утыра...

— Йә, әйтеп кара, кайда партизаннар?..— дип сорый күкрәге орден белән тулы немец Петядан.

— Менә ич!— ди Петя һәм, куенынннан алып, немецлар өстенә граната ыргыта. Немецлар кәкрәеп кенә төшәләр. Ләкин Петя үзе дә үз гранатасыннан һәлак була...

Хәлим газетаны пөхтәләп төреп куйды да, һәрвакыттагы кебек, уйларга чумды:

— Ә менә нигә үзе дә һәлак булды икән ул? Котылырлык булмады микәнни? Гранатаны ыргыткач, чыгарга

да йөгерергә иде аңа. Мин булсам, шулай иткән булыр идем. Немецны җиткерәмме соң мин артымнан, пүчтәкне...

Хәлим очеркны тагын бер кат укып чыкты һәм Петяның кыяфәтен күз алдына китереп бастырды. Менә ул жиде фашистның башына җиткән батыр йөрәкле рус малае: кечкенә генә, яланаяк, өстендә кыек якалы ал сатин күлмәк, киндер чалбар, билендә бау. Йомшак саргылт чәчләре тузган, күзләре зәңгәр һәм зур, акыллы...

— Эх, әрәм булгансың, Петя...— диде Хәлим,— Каюмнар урынында син булсаң икән ул... бирер идек без синең белән немецның кирәген!..

Хәлим ярты төн авышканда гына йоклап китә алды. Төшендә тагын сугыш белән саташып чыкты. Иртән дәрес вакытында да шул турыда уйланып утырды. Тәнәфес вакытында класстан да чыкмады Хәлим. Чыгып нишләсен? Кем белән сөйләшсен? Бу турыда сөйләшерлек иптәше юк ич инде аның хәзер!..

Шулай уйланып утырганда, аның янына бер кыз килде. Гөлгенә исемле иде бу кыз.

Ул:

— Иртәгә мәктәптә кичә үткәрәбез. Акбуалар да килә. Гармонь уйныйсыңмы, җырлыйсыңмы?— дип сорады һәм кулындагы кәгазен Хәлим партасына куеп, язарга хәзерләнде.

Хәлим, башын күтәреп, Гөлгенәгә кимсетүле карап алды, җавап бирмәде. Иң арттагы партадан күзәтеп утырган кызлар — ике игезәк, бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган Гөлчәһрә белән Гөлзәһрә — елмаешып, нидер пышылдашып алдылар. Гөлгенә уңайсызланды, ләкин Хәлим яныннан китмәде.

— Абау, сөйләшәсе дә килми.

— Килми шул,—диде Хәлим, башын да күтәрмичә.

Күзәтеп утырган кызлар тагын пышылдашып алдылар. Гөлгенә аларны ишетмәмешкә салышты:

— Ә ник килми, Хәлим?

— Килмәгәнгә күрә килми! Бар, кит әле. Комачаулап йөрмә!

— Абау, бернәрсә дә эшләмисең ич әле

— Эшләмәсәм, уйлыйм.

— Нәрсә уйлыйсың?

— Чистый сагыз булдың!.. Йолдызларыңны нинди үлән суы белән сүндереп булыр икән дип уйлыйм...

Гөлгенәнең битендәге сипкелне усал малайлар йолдыз дип йөриләр иде. Бик күп иде Гөлгенәнең битендә сипкел. Кечкенә вакытында да күңелен китек иткән сипкел, үсә башлагач, кызны бик нык борчыды. Әнисе аңар инде кырыкмаса-кырык төрле үлән эчереп карады, файдасы тимәде. Таң суы белән юып карады, аңысының да файдасы булмады. Бу табигый житешсезлеге белән балалар аны гел кимсетеп килделәр. Ләкин Гөлгенәдәге искиткеч күркәм сыйфат — сабырлык — үсмер яшькә керә барган саен, тагы да көчәйде; ул хәзер усал малайларның:

— Исемнәрем Гөлгенә,
Эчкәнем үлән генә,
Үлән түгел, чорт эчсәм дә,
Бетми бит сипкел генәм,—

дип мыскыл итүләренә каршы елмаю, янсә эндәшмәү белән җавап бирә торган булды. Тик менә үзенә карата андый усал телле булмаган Хәлимнең бүген кинәт шулай авыр итеп әйтүе Гөлгенәнең җәрәхәтенә бер чеметем тоз салды. Аның шат йөзе, Хәлимнеке шикелле үк җете кара күзләре тоныкланып китте. Йөзе кызарып чыгып, сипкелләрен тагын да куертып җибәрде. «Нигә син дә шулай кимсетәсең инде, Хәлим?»—диде кызның йөрәге, ә теле алай димәде. Ул үзен бик тиз кулга алды:

— Үләннәр турында соңыннан уйларсың, Хәлим. Ә хәзер син миңа әйт: гармоньмы, җырмы?

Кызның шулай тыныч сөйләшүенә Хәлим аптырый калды. Ул, Гөлгенә бер сүз дә әйтмичә үпкәләп китеп барыр, яки берәр чәнечкеле җавап кайтарыр, дип уйлаган иде.

Хәлим кызга күтәрелеп карады. Ләкин тавышы гына шулай тыныч булган икән кызның, ә күзләрендә ниндидер зар иде. Хәлим тупасрак әйтеп ташладым ахры дип уйлап алды һәм бары кызның күңелен табар өчен генә ризалык бирде:

— Әйдә, яз инде алайса, гармонь уйнармын.

— Уйна шул... Ә нинди көй уйныйсың, Хәлим?

— Яз шунда үзең белгәнне.

Игезәкләр тагын пышылдашып куйдылар: «Үзең белгәнне?..»

— Сарманны языймы, Хәлим?
— Яз...— дип сузды Хәлим.
Гөлгенә яза-яза:
— Ә теге шигырьне сөйләмисеңме, Хәлим?— диде.
— Сөйләргә дә ярыймыни?
— Бәй, нишләп ярамасын!
— Алайса мин уйнамыйм, сөйлим.
— Сөйлә шул!..— Кыз, җәберсенүен тәмам онытты, сикергәләп, кулларын чәбәкләп алды.— Шул шигырьнеме, Хәлим?
— Түгел... «Партизан улы» дигән хикәя сөйлим.
— Сөйлә, сөйлә, Хәлим, бик кызганыч бит ул...
— Кызганыч кынамы?..
Гөлгенә «Партизан улы»ның әчтәлеген исенә төшерергә тырышты:
— Кызганыч инде... тагы нәрсә соң?
— Кызганычтан бигрәк, герой ул,— диде Хәлим, Петя өчен горурланып.— Петя герой, менә шул сиңа... Аннан, хикәя дә түгел әле ул, очерк. Булган эш. Ышанмасаң, әнә Шаһгәрәй абзыйдан сора...
Гөлгенә кәгазен партага куйды да яза башлады.
— Укый димә, сөйли дип яз.
— Күңелдән сөйлисең, әйе?
— Күңелдән булмыйча...
— Абау, озын ич ул. Шул хәтлене ятлап буламы?
— Телисеңме, хәзер сөйләп бирәм...

9 ЯҢА ДУСЛАР

Хәлим Гөлгенә алдында бераз арттырып җибәрде. Очеркны күңелдән белми иде әле ул. Хәлим дәресен дә рәтләп хәзерләмәде, кара төнгә кадәр шуны ятлап утырды. Әнисе чыгып киткән саен, сәкегә басып репетиция ясады. Тәэсирле итеп, матур итеп сөйлисе килде аның. Һәм сөйләде дә. Кичәдә балаларның да, алар белән килгән аналарның да Хәлимнең сөйләвенә исләре китте. Тик сөйләгәндә, кемнедер эзләп, күзләрен халык өстендә йөртүен генә яратмадылар...
«...Зәңгәр күзле, йомшак сары чәчле, ямаулы күлмәк, киндер чалбар кигән, яланаяклы Петя, кечкенә гәүдәле, зур йөрәкле баһадир Петя, үзе ташлаган гранатадан үзе дә һәлак булды. Хуш, минем җан дустым»,— дип бетерде Хәлим үзенең сөйләвен. Кешеләр кул чабарга тотынды-

лар. Ә Хәлим, укытучы өйрәткәнчә кулын күкрәгенә куеп, елмаеп, халыкка баш иеп тору урынына, күзләрен тагы да комсызландыра төшеп, халык эченнән кемнедер эзләвен дәвам итте.

«Бу нишләвең? Кем кирәк сиңа, Хәлим?»

Әнә анда, хатыннарга ияреп, ике малай елый. Кул да чаба алмыйлар, сөйләгәндә дә гел елап утырдылар. «Ай мескеннәр, ай мескен Петя», ди торганнардыр инде... Хәлим карашын аларда туктатмады. Әнә берсе, муенын алга суэган, авызын ачкан да күзләрен җемелдәтә-җемелдәтә, тик утыра. Монысы, бик уза китсә: «Дөньяда шундый кызыклар да бар икән», ди торгандыр. Юк, аңарда да туктатмады Хәлим карашын. Әнә берсе авызын ерган да аягын дөбердәтә-дөбердәтә кул чаба. «Молодец, Хәлим, ну булдырдың», ди торганнардыр. Хәлимнең күзләре аны да йөгереп кенә үтте.

Ә әнә теге малайлар (берсе күрше авылныкы, Фазыл, икенчесе Хәлим белән бергә укучы Мәгъсүм) сөйләгәндә, Петя әти-әнисе, нәни сеңелесе өчен үч кайтара алырмы дигән кебек куркып утырдылар. Кеше кул чапканда шашып кул да чапмадылар. Берсе бармагын, икенчесе иренен тешләп, уйланып утырды. Хәлимнең күзләре шушы малайларга тукталды.

Ул, ниһаять, иркен сулап куйды һәм сәхнәдән күтәренке күңел белән чыгып китте. Хәлим чыгуга, залда кул чабу тагы көчәйде. Концертны алып баручы Гөлгенә Хәлимгә яңадан сәхнәгә чыгып халыкка баш иергә кушты. Хәлим чыгып баш иде. Фазыл белән Мәгъсүм һаман да шулай уйланып утыралар иде әле.

«Таптым,— диде Хәлим, аларга карап,— нәкъ менә сез кирәк идегез миңа. Әллә хатыннар елату өчен сөйләдемме мин Петя турында? Юк, Петя өчен янып, аның шикелле батыр булу турында хыялланучыларны эзләп табу өчен сөйләдем мин...»

Халык кул чабудан туктады, ә Хәлим, онытылып, Фазыл белән Мәгъсүмгә караган килеш, әле һаман сәхнәдә басып тора иде. Гөлгенә, зур чәчәкле чаршау ертыгыннан кечкенә кулын тыгып, Хәлимне чакырды:

— Чык инде, Хәлим, чык...

Хәлим шунда гына йөгереп чыгып китте. Сәхнә артында чыгыш көтеп торган артистларны ырып-ерып залга узды. Ишек төбендә ул Каюмга килеп бәрелде. Каюмның өсте-башы, кыяфәте тантаналы: күлмәк якасын чыгарып

кигән, чәче җитеп мае белән майлап таралган, беләгендә кызыл чүпрәк иде. Күрәсең, үзен әле һаман гаепле саный, Хәлимне күргәч, кыюсыз гына эндәшеп, аңа алдагы сафта урын күрсәтте. Хәлим исә моңар каршы кимсетүле елмаеп куйды: «Нәчәл булган, имеш...» һәм Фазыл белән Мәгъсүмгә таба бара башлады. Ул арада Гөлгенә тәнәфес игълан итте. Фазыл белән Мәгъсүм этелә-төртелә үзләре үк Хәлим янына килеп бастылар.

Фазыл Хәлим белән кул биреп күреште.

— Исәнме, Хәлим?

— Ару гына әле. Безнең кичәне дә күреп китик диденмени?

— Әйе. Бездә болай әйбәт булмый. Сезнең шәп... Син бик яхшы сөйләдең.

Хәлим ни дип җавап бирергә дә белмәде.

— Әйдә, мәктәпне күрсәтеп килим,— диде ул. Әллә теленә башка сүз килмәгәнгә шулай диде, әллә инде чыннан да салынып бетеп килгән, сугышка күрә тукталыбрак торган ТБУМнары белән мактанасы килде.

Ләкин Фазылны икенче нәрсә кызыксындырды.

— Күрсәтерсең әле,— диде ул.— Хәзер сөйләгән хикәяңне миңа биреп тор әле, малай.

— Нишлисең аның белән?

— Укыйм, үзем укып карыйм әле бер.

— Әллә ошады? — дигән булды Хәлим, сизмәмешкә салышып.

— Бик.

— Мә. Алып китмә түлке.

— Юк-юк,— дип сузды Фазыл.

«Хуш, минем җан дустым»,— дигәнне Хәлим үзеннән өстәп сөйләгән икән. Фазыл бу турыда әйтеп, Хәлимне оялтасы килмәде, комсызланып очеркны укый башлады.

— Андыйлар миндә тагы бар.

— Кит әле?

— Бер кочак.

Хәлим Фазылларны сәхнә артына алып керде дә өелеп яткан киемнәр арасыннан үзенең сумкасын тартып чыгарды. Ник бер китап булсын, бөтен сумка газеталардан кисеп алынган сугыш хикәяләре дә очерклар белән тулы иде. Тагын Кызыл Армия уставы, ике петлица һәм җиңгә тага торган ике кызыл йолдыз... Хәлим хикәя һәм очеркларны Фазыл белән Мәгъсүмгә бирде.

— Менә бусы исемсез бер батыр малай турында,— диде Хәлим.— Исеме булгандыр инде аның, белми калганнар... Немецлар кергәч, бөтен авыл партизан булып урманга китә. Авылда кечкенә балалар да, бик бетәшкән карт-корылар гына кала. Әлеге малай да партизаннар белән киткән була. Сеңелесе авыргач, әниләре аларны авылга кайтарып җибәрә. Немецлар малайдан: «Партизаннар кайда?» — дип сорыйлар. Малай әйтмәгәч, өйләренә ут төртәләр дә сеңелесен ут эченә ыргыталар. Малай утка атылып барып керә һәм сеңелесен алып чыга.

Кара син аны нинди фидакарь көчек!.. Немец малайга акаеп карый да нәни кызны тагын утка ата. Малай тагы ут эченә кереп китә һәм кире чыга алмый, сеңелесен кочкан килеш янып...

Фазыл күңелсезләнеп башын читкә борды:

— Барысы да үлә...

— Барысы да түгел, Фазыл. Менә монысы үлми. Көтүче малай була бу. Бер тапкыр шулай, кич белән көтүен алып кайтып барганда, урман өстендә самолет күрсенә. Шунда ук парашют ачылып китә...

— Ярый, Хәлим, сөйләп бетергәч укырга кызыгы калмый. Укыйк.

Укырга гына дип торганда, сәхнә артына тагын бер малай килеп керде.

— Әллә баттыгызмы? Шул көннән бирле...— диде ул Фазыл белән Мәгъсүмгә.

— Ул да тыңласынмы, Хәлим?

— Кем соң ул?

Малай үзе җавап бирде.

— Исәнме, Хәлим! Әллә танымыйсың? Нәҗип ич... Кара, өченче ел безнең сабантуенда капчык киеп йөгерешкән идек бит!

Хәлим Нәҗипкә теләмичә генә кул бирде. Бик ябык, шадра, кулларына кадәр шадра иде бу малайның. Гәүдәсе, әле генә озак авырудан терелеп чыккан кешенеке шикелле, эленке-салынкы.

— Миңа кул нәмәрсә түгел бу,— дип уйлады Хәлим бер күз төшереп алу белән.— Ярый инде, кунак кеше ич. Тыңласын...

— Әйдә, утырыгыз.

Малайлар барысы да сулы кисмәк артына түгәрәкләнеп утырдылар.

— Үзем укыйммы, Хәлим?

— Әйдә, укы.

Фазыл укыганда Хәлим аңардан күзләрен алмады, ә Нәҗипкә онытканда бер генә карап куя иде. Йоклап китәр төсле оеп утырды Нәҗип. Ә хикәя кызып киткәч, аның урынына икенче малай китереп куйдылар диярсең — алмашынып китте. Күзләре ялтырый башлады, гәүдәсе турайды. Көтүче малай турындагы хикәяне Хәлим үзе укырга тотынган иде дә, яңадан Фазылга бирде, үзе Нәҗипнең күзләренә кереп батты.

«...Немецка бүтән юл калмады, парашютын кисеп калдырып, киеме-ние белән елгага сикерде һәм, калкып чыкты да, колач салып йөзә башлады. Көтүче малай аңар таш ыргытты — тимәде, тагын берне ыргытты — тагы тимәде. Немец хәзер елганы йөзеп чыгар да аргы як ярдагы урманга кереп качар... Юк, үлгәндә дә моңар юл куярга ярамый! Көтүче малай тиз генә чишенеп немец артыннан суга сикерде һәм, куып җитеп, аның бугазына ябышты. Алар икесе дә баттылар, калыктылар, тагы баттылар. Бу юлы немец калыкты һәм йөзеп китте, ә көтүче малай калыкмады... Ул баткан турыда су күбекләнеп...»

Нәҗип урыныннан сикереп торды. Бу вакытта аның күзләре атылып чыгарлык булып зурайган иделәр.

— Укыма! — дип кычкырды ул.— Кайдан таптыгыз җыен шундыйны!..

Ул шундый кычкырды, Фазыл кисәк укуыннан туктады. Хәтта сәхнәдә җырлаучы кыз да бүленеп калды. Концертны алып баручы Гөлгенә килеп малайларны орыша-орыша куа башлады. Хәлим башта Гөлгенәне, аннары Нәҗипне тынычландырды:

— Сабыр ит, тыңлап бетер... Укы, Фазыл.

«...Менә күбекләр як-якка таралып китте. Су астыннан көтүче малай башы калыкты. Ахры, немец тешләгәндер: малайның беләге каный иде. Калкып чыгуга немецны куып китте ул һәм, куып җитеп, тешләрен немецның бугазына батырды. Алар тагы баттылар... Бу юлы су астыннан малай калыкты, ә немец... немец калыкмады».

Нәҗип, ахрысы, ышанмады, Фазылдан тартып алып, очеркка күз йөртеп чыкты, аннан иркен сулап куйды. Бер сүз дә әйтмәде ул. Күрәсең, артык дулаганына уңайсызланды — бераз кызарып, яңадан идәнгә төзләнде.

«Менә сиңа ябык, менә сиңа кечкенә, шадра...» дип гаҗәпкә калды Хәлим.

— Ошадымы, Нәҗип парень?

Нәҗип җавап урынына үкенечле итеп әйтеп куйды:

— Аларның эш көйле...

— Кемнәрнең, Нәҗип?

— Барысының да, фронтка якын авыл малайларының.

— Ник?

— Немец үтерәләр... Мәктәптә бака эчен актарып ятмыйлар... Сездә юк әле ул, кәтегез, киләсе елга керер...

Хәлим аңа астан гына карап:

— Актармый нишлисең? — диде.

— Нишлимме? Актармыйм, шул гына.

— Һәй, пүчтәкне,— диде Хәлим һәм тагын астан карап алды.

— Пүчтәк булмый соң... Минем әни юк. Елар дип, военкомат ишеге төбеннән борылып кайта торган түгел...— диде Нәҗип.

Хәлим моның үзенә әйтелгән киная икәнен аңлады. Ачуы килде аның, ләкин елмайган булды:

— Ташың минем бакчага төште, Нәҗип.

— Белеп төшкән,— диде шадра малай, кимсетүле елмаеп.

Хәлим уңайсызланды. Шулай да ул шат иде. Ул эченнән генә:

— Менә бу — иптәш! Менә бу сүзендә торыр. Фронтка гына түгел, фронтның аргы ягына да китеп булачак моның белән,— дип уйлап куйды.

10 АВЫЗЫҢНАН ҖИЛ АЛСЫН...

Шул кичтән башлап Хәлим укуга бөтенләй күңел бирми башлады. Ул хәзер мәктәпкә, әни сизмәсен дә, укытучы ачуланмасын, дип кенә йөрде. Ә күңеле белән фронтта иде инде ул. Аның яңа дуслары да, сәхнә артында очрашкан сәгатьтән алып, бары тик фронт турында гына уйлап йөри башладылар.

Хәлим һәм аның иптәшләре, шулай да, ике дәресне бик бирелеп укыдылар: сугыш эше, география. Алар СССРның көнбатышындагы шәһәр исемнәрен күңелдән ятладылар: бу шәһәрләрне картадан, үз капкаларын тапкан шикелле, ансат таба иделәр. Тәнәфес вакытларында коридордагы зур карта яныннан китмәделәр. Ни гомер яңа килеш эленеп торган карта, өстендә бертуктаусыз бармак бите, линейка йөреп торудан тузып бетте.

Хәлимнәр каршында сугыш дәресе аеруча почетлы иде. Тик шунысы кызганыч — ул бик сирәк була. Аны малайлар, бәйрәм көткән кебек, көтеп алалар. Берәр сәбәп белән башка дәресләр булмый калса, класс җитәкчесеннән военрукны чакырттырырга тырышалар. Класс җитәкчесе: «Барыгыз, алайса, алып килегез» дисә, хәзер чыгып йөгерәләр иде.

Өенә барып та тормыйлар военрукның. Өенә ул хәзер йокларга да ашарга гына кайта. Мәктәптән бушандымы — хәзер колхоз эшенә яки (финдә яраланып кайтканчы бик зәһәр тимерче иде ул) комсомолецларны тимер эшенә өйрәтә, алар белән бергәләп стена газетасы чыгара, яки фермага, ындыр табагына барып чыга. Анда ул колхозчыларны җиңү хөрмәтенә үз-үзеңне аямыйча эшләргә өнди.

— ...Читен икәнен беләм, Хөршидә җиңги, ләкин анда мең кабат читенрәк. Түзәргә туры килә, җиңгиләр... Әйе, 4 ай... кирәк икән, 4 ел да түзәрсең. Гитлер төрмәсенә барып керергә теләмәсәң, дар агачына асып китүләрен теләмәсәң, түзәрсең, Халикъ абзый,— ди ул һәм зур бүрекле кечкенә картны җиңелчә генә бер читкә этәрә дә барабанга баса.

— Әй, малай, атыңны куа төш... Давай, давай!..

Хәлимнәр аның сөйләп бетергәнен, сыңар кулы арып, барабанга көлтә биреп торудан туктаганын көтәләр. Шунда гына үзләре турында белдереп, борыннарын тартып куялар.

— Мине алырга килдегезме?

— Әйе, Җәүдәт абый.

— Нәрсә булды тагын?

— Тәскирә апа шимбә көн госпитальгә бүләк илтә киткән иде, кайтып җитми әле, Җәүдәт абый.

Мәктәпкә җиткәнче аның вак калибрлы мылтыгын, кыр сумкасын малайлар, чиратлашып, үзләре күтәреп баралар. Шинеленнән, петлицасындагы өчпочмаклардан, бүрегендәге кызыл йолдыздан күзләрен алмыйлар. Күбрәк кеше күреп калсын өчен, аннан юл яхшы дигән булып, военрукны әйләнечтән, олы урамнан алып китәләр.

Военрук та Хәлимнәрнең хәрби занятиеләр өчен янып йөрүләрен сизә, аларга тиешеннән артык берәр патрон аттыргалап куя иде. Уеннары да хәрби хәзер малайларның, мәктәптән кайткач, сугыш-сугыш уйныйлар һәм бу уенга һәр ике авылның малайлары катнаша иде. Алар,

дәресләр бетүгә капыл-копыл ашап чыгалар да, кылыч дигән булып, билләренә чыра тагып, мылтык дигән булып, иңнәренә себерке сабы асып, граната дигән булып, билбауларына озынча түгәрәк шакмаклар кыстырып, шау-гөр килеп, ике авыл уртасындагы тауга таба китәләр. Тауга бер яктан «Ватан»нар һөҗүм итә, икенче яктан «Акбуалар». Түшләре белән шуыша-шуыша куаклыклар арасына менеп җиткәч, сугыш башланып китә. Сугыш хәрәкәтләре белән «Ватан» ягыннан Хәлим җитәкчелек итә, «Акбуадан» — Фазыл. Алар үзләре сугышмыйлар, калкурак җиргә басып, команда гына биреп торалар:

— Кылычың белән чап!.. Сынса, штык нигә бирелгән сиңа? Чәнчеп үтер!..

— Әй, Шәпи дим. Шәпи! Гранатаң белән тондыр!.. Я, тондыр инде!

Шулай да була, кайчак «полководецлар» үзара әйткәләшеп тә алалар:

— Әй син, солдатларыңны кара: аяк чалмасыннар!

— Ә син, агай-энем, үзеңнекеләрне өйрәт, әнә Зөфәрең минемИрекнең башын граната белән төеп ята. Җыен уен уйнамаган солдат синең армиядә!

— Синең бик уйнаганнар инде. Әнә Вагыйзең, «үлгән» килеш, минем Сәминең аягыннан тартып екты!..

Ә кайчакларда «полководецлар»ның әйткәләшүләре зурга китә. Алар, басып торган урыннарыннан төшәләр дә, бер-берсенә каршы китәләр. Аларга берсенең замполиты — Мәгъсүм, икенчесенең — Нәҗип ияРә. Мондый чакта балалар, сугыштан туктап, ну хәзер бирешәләр дип, кызык көтеп торалар. Ләкин полководецлар сугышмыйлар. Аларның сәхнә артында биргән антлары бар: «Бер-беребезгә тырнак белән дә чиертмәскә, башка малайлар кыйнарга ябышса, бер-беребезне яклашырга...»

Сугыш уены башка малайлар өчен бер күңел ачу булса, Хәлимнәр өчен чын сугышка хәзерлек тә иде. Якшәмбе көннәрдә алар зур походлар оештыралар. Походка иртә таңнан торып китәләр. Марш атлыйлар, йөгерәләр, түш белән шуышып йөриләр. Окоплар казыйлар. Тәмам арып-талып беткәнче, караңгы төшкәнче шулай йөриләр алар, һәр сугыш азагында «Гитлер»ны тотып асалар һәм бусы уенның иң кызык җире була иде.

Олы юл буенда телеграм баганасы, баганада аркылы агач. Агачка элмәкле бау тагылган. Багана төбендә зур кисмәк. Менә «Гитлер»ны тотып китерәләр. Күзләре тиле,

мыегы җирән, фуражкасы иләмсез биек, бер учма чәче маңгаена төшкән, куллары артка каерып бәйләнгән. Аны кисмәккә бастыралар да муенына элмәк эләләр. «Гитлер» башта, җибәрегез инде, моннан болай сезгә каршы сугыш ачмас идем, дип ялына, аннан кычкыра, тиргәнә башлый, гасабиләнеп тыпырчына. Малайлар шаркылдап көләләр. Кул чаба-чаба көләләр. «Гитлер»га барлык төр коралларданн (балчыклар, ташлар) аталар...— «Из дионец измәсен!..»

Ләкин бер тапкыр бу уеннан уймак чыга язып калды... Кайбер көннәрдәге кебек бүген дә бер малай Гитлер булудан баш тартты. Һәм аны алыштырырга теләүче табылмады. Уенның кызыгын җибәрдең дип, малайны тиргәп торганда, сугыш кырына идарә кучеры Муллаәхмәт абзый килеп туктады. Ике егетне армиягә озатып кайтып килеше икән, поезд көткән арада, тегеләр бераз салдырганнар икән. Кызмача.

— Тимәгез малайга, үзем Гитлер булып күрсәтәм,— диде кучер,— настоящий Гитлер булам мин сезгә хәзер...

Малайларга җан керде:

— Бул әле, бул, Муллаәхмәт абзый!..

Муллаәхмәт абзыйны ике малай куаклык арасына алып кереп, Крокодил журналына карап, Гитлер кыяфәтенә керттеләр, мыегы артык озын иде, бөтерелеп үскән иде, үзе сизмәгәндә генә оч-очын керт-керт кисеп алдылар. Кулын бәйләделәр дә багана янына алып килделәр:

— Вәт бу — Гитлер!

— Нәкъ үзе!

— Абау, мәхәббәтсез!..

— Артист кына буласың бар икән синең, Муллаәхмәт абзый!

Муллаәхмәт абзыйны кисмәккә менгереп бастырдылар, муенына элмәк кирттеләр. Муллаәхмәт абзый Гитлер булып кычкыра башлады. Кызмача вакытында урынлыга да, урынсызга да беренче бөтендөнья сугышы вакытында пленда чакта колагына кереп калган немец сүзләрен әйтә-әйтә сүгенергә ярата иде ул, шуларны кычкырды. Бер типте кисмәккә дагалы итек үкчәсе белән, ике типте, өч типте һәм... кинәт телсез-авызсыз калды. Йөзе чөгендер булып кызарды аның. Күзләре үлгән сарыкныкы шикелле калайланып китте.

— Менә бу булдыра, ичмасам,— диделәр малайлар:

— Булдыра, булдыра...

— Карагыз әле, малайлар, телен дә тешләгән, каный...

Ярый әле, теленә генә түгел, аякларына да карап торучылар бар икән, кычкырып җибәрделәр. Муллаәхмәт абзый тибә-тибә кисмәкнең төбен җимереп төшергән, аяклары бушлыкта асылынып тора икән.

Фазыл тиз генә килеп кисмәкне этеп җибәрде дә аның урынына үзе килеп чүгәләде. Муллаәхмәт абзый, аяклары белән капшанып, аның иңбашына басты. Хәлим авызына пәке кабып тиз генә баганага үрмәләде һәм бауны кисеп җибәрде. Муллаәхмәт абзый шап итеп җиргә килеп төшге. Айныган иде инде ул бу вакытта...

— Кешегә тарата күрмәгез инде, оланнар,— диде ул тарантасына күтәреп салганда.— Гомергә китәр.

— Ярый, ярый,— диделәр малайлар. Ләкин аларның авызларында сүз торамыни!.. Хәбәр авылга Муллаәхмәт абзыйның үзеннән алда кайтып җиткән иде. Атын конюшняда тугарып, өенә кайтканчы карчыгына да ирешгергәннәр иде инде.

Карчыгы Муллаәхмәт абзыйны елмаеп каршы алды.

— Вакыты җиткәч үзе дә асылыныр иде әле, аның өчен асылынып йөрмәсәң...

Ләкин Муллаәхмәт абзыйның эше уен-көлкелек түгел иде әле. Ул, күгәреп чыккан муенын ике куллап тоткан хәлдә, күзен карчыгына ачулы әйләндереп карады:

— Әй, бу юлы гына ырылдамый калсаңчы!..

Балаларның тагын бер яратканы — кичләрен Акбуа авылына барып, радио тыңлау иде. Хәлим анда Мәгъсүм белән бара. Алар килгәнне күреп, Фазыл белән Нәҗип тә авыл советына керәләр.

Ярты авыл шунда була. Кешеләр иң тәҗел эшләрен калдырып киләләр. Күзләр иске эшләпә кебек яньчелеп беткән түгәрәк кара кәгазьдә.

— Тыңлагыз, тыңлагыз! Казан сөйли...

— Ай, хәерлесен генә сөйләсен иде инде. «Совет информбюросыннан...» — дип башлый да: «Бүген безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң...» дип авыр югалтулар турында сөйләп китә.

Авыл советы йортында эчпошыргыч тынлык урнаша. Кешеләр, әйтерсең, шәһәр бирүдә башлап үзләре гаепле, бер-берсенә карарга уңайсызланып утыралар. Гүяки, дошман аларның үз авылларына килеп җитте, гүяки га-

сырлар буенча ата-бабаларын ризыкландырган, хәзер үзләрен ризыкландырып яткан мөкатдәс туфракларына басты канлы Гитлерның канлы итеге, гүя болыннары, кырлары дәррәү көя башлады — хәбәрне шулай авыр кичерәләр.

— Кайчан да бер чигенүе турында ишетербезме икән бу зобаниның?

— Чигендерә башлагач ишетербез, Хәдичә килен.

— Нинди чигенү... Мәскәүгә җиткән ди бит инде.

— Мәскәү дисең син. Аның Казаны да инде...

— Нәрсә Казаны да?

— «Ялгыз Каз»ның Мостафа Бәдернисасыннан хат килгән. Алар көздән бирле шунда икән. Җиде ат, жиде кыз киткән булганнар. Ну вәт шул, окоп казыйбыз дигән. Бер дә харап, ди, анда, бөтен дөнья купкан, ди...

— Нужәли инде шунда кадәр...

— Шулай булмый соң!.. Карт башың белән юкны юрап утырма әле син анда, яме!

Карт урыныннан тора.

— Юрыйм мин, юрамаган кая!.. Миңа интирисне бит немецның килүе!..— ди ул җәберсенеп. Аннары стенадагы картага таягы белән төртеп күрсәтә.— Ну, әйтми булмый, йөрәк әрни... Менә бу җирләрнең барысында немец бит инде. Бу төшкә дә тыкты бит инде ул дуңгыз борынын!

Аны түр стена буенда, көн дә шул бер урында, иягең таягына куеп утыручы икенче бер карт булә. Картның өстендә тузып беткән борынгы солдат шинеле, башында шул заманның солдат бүреге, күкрәгендә Порт-Артурны японнан саклаганы өчен бирелгән медаль.

— Дөрес сөйләмисең, кордаш,— ди ул.— Борын тыгу белән эш бетми...— Керүеңнән алда чыгуыңны уйла, дип өйрәтә иде безне этиләр. Ну бу этнең, күрәсең, андыйны өйрәтер этисе булмаган... Син уйлап кара. Әйтик, ул хәзер менә монда, безнең авылга килеп житте, ди...

— Авызыңнан җил алсын!

— Мин примерга гына әйтәм, Халисә килен.

— Берничек тә әйтмә!

— Ну, я, әйтмим,— ди карт солдат, ә сөйли башлагач, онытып тагы кабатлый: — менә монда, безнең авылга килеп житте, ди. Йә инде, син түзеп торасыңмы шуңар, минме?

— Шулай, шулай. Сталин иптәш әйткән ди бит инде...

— Нәрсә әйткән ди?

— Хәзер, хәзер... Кая, кызым, кичә укыганыңны тагын бер укып күрсәт әле минем кордашка.

Өстәл артында, счет төймәләрен шалтыратмыйча гына йөртеп, исәпләп утыручы авыл советы секретаре, түгәрәк йөзле яшь кыз, шкафтан бер газета ала. Ул Сталинның 22 июнь көнне сөйләгән, безгә җиңү юлларын күрсәткән, безне көрәшкә рухландырган речен укый.

«...Безнең эшебез хак эш — җиңү безнең якта булыр!» — дип бетерә кыз укуын.

— Һай, рәхмәт төшкере!..

— Һәм ул шулай булачак та. Безнең өчен билгеле мәсьәлә ул,— ди әлеге бабай, гражданнар сугышы көннәрен күз алдына китереп. Ул Сталинның сүзләрен ятлап алырга теләгәндәй, авыз эченнән кабатлый:

— «Безнең эшебез хак эш,— җиңү безнең якта булыр!» — әйбәт әйткән.

Хәлим тыңлап утыра-утыра да түземен җуя. Өстәлгә сикереп менеп кычкырасы килә аның.

— Ул әйткән әйтүен дә, шушы хәтле кеше авыл советына җыелып, тәмәке тартып, җиңгәнне көтеп утырырлар дип уйламаган,— диясе килә.— Никадәр халык бит биредә! Ә анда, газетада язган: кырык немецка каршы җиде кызылармеец сугышты, дигән. Я, менә бу халык шул чак җиде кызылармеец янында булса, начар булыр идеме? — диясе килә һәм иптәшләренә әйтә: — Сталин белмидер инде бу хәлне, белсә боларны монда сүз көрәштереп утыртмас иде, бөтенесен фронтка җибәртер иде.

—Билгеле, җибәртер иде...

Менә бер почмактан колхоз агитаторы күтәрелә. Ул яланбаш. Кулын халыкка таба сузып, тавыш басылганны көтеп тора. Хәлим аңар, аның шинеленә, шинелендәге җиз төймәләренә чиксез ихтирам белән карый. Аның «җанга җылы сүз» әйтүен көтә.

— Тимерша бабай дөрес әйтте,— дип башлый агитатор сүзен.— Тыккан борынны аласы да бар бит әле аны...

Шуңарга бәйләп, ул немец тылындагы партизаннар хәрәкәте турында сөйли... Аннан информбюро сводкасына анализ ясый:

— ...Шәһәр бирү — җиңелү дигән сүз түгел әле ул, иптәшләр,— ди агитатор.— Ник кергәннәренә генә түгел, ник туганнарына үкенәчәк әле алар. Әйе, әйе.— Аннан соң агитатор алда торган бурычларга күчә:

— Бөтен халык сугышы бу, Ватан сугышы. Бу изге сугышта бөтен халык катнашырга тиеш...

— Менә, менә... Хәзер әйтә. Бөтенегез дә сугышка китегез, дип әйтә хәзер,— дип пышылдый Хәлим иптәшләренә. Ләкин агитатор Хәлим көткәнне әйтми:

— Тыл халкы бу сугышка күбрәк корал, икмәк, җылы кием бирү белән катнашырга тиеш,— ди ул.

Хәлимнең очкынлана башлаган күзләре кинәт сүнеп китәләр.

— Син дә шул!.. Җитмәсә, үзең Финдә йөреп кайткан булдың,— ди ул эченнән генә һәм кулын селтәп куя.— Җылы бияләй белән генә җиңеп булса иде... Әйдәгез, малайлар! Сәмигә син инде ник җиде кат бияләй киертмисең, барыбер чөям мин аны!..

— Чөясең, кәнични...

11 МИН АНЫ ЮККА ҖӘБЕРЛӘДЕМ

Көннәрдән бер көн Хәлим өйалларына кайтып керүгә, әнисенең үз-үзенә сөйләнә-сөйләнә елаганын ишетеп, туктап калды.

— Бу яхшыга түгел... Ай, әллә тагын сизенгән микән?.. Тукта, нигә гел Хәсән абыйны телгә ала әле ул? — Хәлим, шомланып, ишекне тартып ачты.

— Әни, ник елыйсың, әни?

— Әй, улым...— Ана, сүзен дә әйтеп бетерә алмыйча, үксеп җибәрде. Хәлим өстәлдә яткан хатка ташланды.

«Сезнең улыгыз танкист Хәсән Арсланов, Мәскәүне Гитлер өереннән саклаганда...»

Хәлимнең ышанасы килмәде.

Әле генә, менә хәзер генә кебек бит... Таң алды иде. Озынча зур бите, юан муены, өсте-башы майга буялып кайтып керде. «Бетерми китмим, дидем, и тәки бетердем, энекәш, үз өлешемә тигән җирне сөреп бетердем!.. Инде китсәң дә була...» Аннары, мунча кереп, чиста киемнәрен киде дә котомкасын алды. «Әйдә, атны тот, энекәш!..» Басу капкасын чыкканчы озата килгән хатын-кызлар, аның чамасыз киң җилкәләренә, юан муенына, арбадан сөйрәлер-сөйрәлмәс барган аякларына карап, әйтеп калдылар: «Алла җаным, күз генә тимәсен, немецны танкысы-ние белән таптап китәр бу...» Хәлим, дилбегәсен арба башына чорнап куйды да, гармонь уйнады, ә Хәсән

абыйсы яңа гына чабылган яшел печәнгә чумып ятты да җырлады...

Урак урган җирләрем,
Печән чапкан җирләрем...

Урманга кереп бераз баргач, Хәлимне кайтарып җибәрде: «Бар инде, энекәш, кайт. Сугыштан кайткач, мин сине тракторчы итәм. Тракторчы буласың киләме? Килсә шул, тракторчы итәм мин сине...»

Хәлим хатны тагын бер тапкыр алып карады.

Аның һаман да ышанасы килми иде.

— Бәлки, дөрес түгелдер, әни. Әнә Рәхим абыйның шулай булды ич...

Ана бер сүз дә әйтмәде. Ул инде еламый иде. Күзләрендә яшь беткән иде аның. Башын селкеп тик торды, ләкин бу вакытта ул елаганнан битәр кызганыч иде. Хәлим, әнисенең аяк очларына килеп тезләнде дә, үзе белгән иркә сүзләр белән аны юатырга, иркәләргә керешге. Бу авыр кайгыны уртаклашырга тирә-күршеләр кереп тулгач, Хәлим ишек алдына чыгып әле кайчан гына әтисе белән Хәсән абыйсы яңа өйгә дип ташыган бүрәнәләрне коча-коча елады. «Әй, абыем җаныем...» Аннары тиз генә урамга йөгереп чыкты һәм Мәгъсүмнәр тәрәзәсен шакыды:

— Акбуага йөгер. Минут тормый килеп җитсеннәр.

— Китәбезме әллә, Хәлим?

— Килгәч сөйләшербез. Безнең мунчага керә торсыннар.

Мәгъсүм Акбуага йөгерүгә, Хәлим, өйгә кереп, семья өстенә төшкән бәхетсезлек турында әтисенә һәм исән калган абыйсына хатлар язды:

«...Көчеңне, патроннарыңны кызганма, Хафиз абый, яме!— диде Хәлим хатының азагында.— Мин үзем дә иртәгә фронтка китәм. Мине баргач та сугышка кертмәсләр әле. Кызылармеецларга патроннар, снарядлар ташып йөрермен. Ә инде разведчик булып киткәч, Хәсән абый өчен фашистлардан үч алырмын! Үчне ничек итеп алырга икәнен үзем беләм мин...»

Хәлим, хатларны Каюмнар белән каралырга баргач алган конвертларга салып ябыштырды да, почтальонның өенә илтеп бирде һәм, кайтышлый иптәшләрен очратып, алар белән мунчага керде.

Хәлим иртәгә кич белән өйдән чыгып китәргә тәкъдим ясады. Иптәшләре бик шатланып риза булдылар.

— Иртәгә ш1
«Таң» колхозынмбә булу бик җайлы. Кич белән өйдән
Дүшәмбе көн ирә концерт куярга дип чыгып китәбез.
эзли чыгулары ә белән генә кайтырбыз, дибез. Югыйсә,
Юлга нәрсә ихтимал...
торасы юк иде. Ълу, ничек киенү турында киңәшләшеп
һәм һәркайсыныру турыда берничә тапкыр сөйләшенгән
тирән күмеп ку юл әйберләре әллә кайчан печәнлеккә
— Барыгыз, әлган иде.
актык тапкыр йниләрегез җәеп биргән йомшак урында
эклагыз да...
Шулай да ирт
деләр. Уку өчен эн Хәлим белән Мәгъсүм мәктәпкә кил-
дип кенә килү идегүгел, әлбәттә, сизенә башламасыннар
утырдылар. Тәнәф бу. Дәрес вакытында алар бик әдәпле
йөрмәделәр. Укытестә дә дулкынланып, ыгы-зыгы килеп
ланмаска тырышьучының, иптәшләренең күзләренә таш-
шып утырды аларп, әчке кичерешләрен яшерергә тыры-
мы соң!.. Мәгъсүм. Ә аны, эчке кичерешне, яшереп була-
торды, аннары ип1 башта озак итеп укытучысына карап
Быел язын Хәлимәшләрен берәм-берәм күздән кичерде.
әледән-әле карап ε белән бергәләп утырткан алмагачка
үсәр икән? Су сибла иде. Без әйләнеп кайтканчы күпме
бәлки, алма да биүче булыр микән үзенә?.. Без кайтуга,
Ни сак Хәлимдрә башлар инде...
Мәгъсүм күзәткәнә дә сизелә иде эчке кичереш. Ул да
Әллә инде классынәрнең барысын да күзәтеп чыкты.
Яңа эленгән стена гің һәрбер бүрәнәсен күздән кичерде...
хәрефләр белән «Газетасының буеннан буена зур кызыл
фронттагы этиләрел «отлично» да «яхшы» га гына укып
Хәлим почеркыннагбезне сөендерик» дип язылган иде.
бигрәк шуңар күрн таныды: бу Каюм эше иде. Бәлки,
күренде. әдер, лозунг аңар буш сүз булып
«Укуың белән кь
релеп карагач, искеярырсың инде. Керпе...» Ә үзенә күтә-
күренде. «Кара, кү дусты аңар кызганыч, мескен булып
түгелме соң мин аңз төбе күгәреп чыккан... сукмадым
инде, күгәрүен күләңар?.. Әллә суктыммы? Хәйләкәр дә
кыйнатасы килде согәләү өчен, чәчен ничек тараган. Ник
юасы килгәндер индән аның миңа? Шуның белән гаебен
йөрдек бит без аныңе... Кызганыч шундый... Гомер бергә
өч-дүрт тапкыр сугы белән, гомер дус булдык. Җыенысы
мин аның штанына ыштык микән... Берсе — су кергәндә
минекенә ясаган өчеказ боты ясаган өчен, икенчесе — ул
н... Башкалары истә калмаган...»

Парта капкачында Каюмның башы төшерелгән иде. Тырпайган чәче, курнос борынына кадәр аныкы! Мәзәк шундый... Хәлим карап торды-торды да пәкесе белән уеп алды. Ни әйтсәң дә, иске дус бит...

Аннары Хәлим озаклап Гөлгенәгә карап торды. Кара, аңар кызыл яулык килешә төшә икән. Сипкеле дә артык кычкырып тормый. Тукта, элек тә кызыл иде түгелме соң аның яулыгы? Әллә акмы?.. Ә мин аны юкка җәберләдем, тик торганда бит. Өенә кайткач елагандыр инде. Гафу ит, яме, Гөлгенә, дип язып бирим микән әллә үзенә?

12

ХУШ, АВЫЛ!

Карангы төшүгә малайлар укучыларга бераз таныш булган күпер астына җыйналдылар. Һәркайсының аркасында котомка итеп бәйләгән капчык иде. Ә Нәҗипнең — чын солдат капчыгы иде. Ат ашатырга кергән узгынчыдан үзләренең биш потлы яңа киндер капчыкларына алыштырып алды ул аны. Дөрес, капчык тузыбрак киткән китүен, ике-өч ямавы да бар. Аның каравы, чын солдат капчыгы! Ямавы күренми дә әле аның ерактан...

Нәҗип кенә түгел, качкыннар барысы да, мөмкин кадәр, гаскәриләргә охшарга тырышканнар. Башларында я гражданнар сугышыннан бирле кайдадыр аунап яткан шлем, я пилотка. Өс киемнәре төрле-төрле булса да, төймәләре барысының да бер: менә дигән гаскәри төймәләр. Җиз. Алар аны — «сугыш-сугыш уйнарга кирәк ул безгә» — дигән булып, әлеге Муллаәхмәт абзыйдан, үзләренең сөяк төймәләренә һәм Нәҗипнең әтисеннән калган бер бәйләм яфрак тәмәкегә алмаштырып алганнар иде. Төймәләр бик искергәннәр, тутыгып беткәннәр иде. Малайлар аларны ком белән чистарттылар, сукнога ышкып ялтыраттылар. Төймәләр җитеш түгел. Һәркайсының киемендә икешәр-өчәр генә. Ләкин малайлар шуңа да канәгать. Бик пөхтә итеп, пиджакларының иң күренә торган җирләренә — өстән икенче, өченче урыннарга тагып куйганнар, әллә кайдан ялтырап күренеп торалар... Һәркайсының биләндә каеш. Болары кайсыныңдыр өендә аерым хуҗалык вакытыннан бирле ятып күгәреп беткән дилбегәдән кисеп эшләнгән иде.

Хәлим, үзенең һәм иптәшләренең өс-башларын күзеннән кичерде дә, канәгатьләнеп әйтеп куйды:

— Әйбәт булган, егетләр. (Кичә сүз куешу буенча,

бүгеннән башлап алар инде бар да «егет» иделәр. Инде монда килегез,— диде Хәлим тавышын да егетләрчә чыгарырга тырышып.— Мә, Нәҗип, син шырпы сызып тор. Хәзер ант итәбез. Башларыгызны салыгыз...

Малайлар гаҗәпләнеп бер-берсенә карашып куйдылар. Хәлим эчке кесәсеннән дүрткә бөкләнгән бер кәгазь алып, утка якын китерде:

— «Ант...»

Малайлар, нишли соң бу Хәлим, дигән мәгънәдә тагы бер-берсенә карашып куйдылар. Хәлим дәвам итте:

— «Без, «Ватан» һәм «Илшат» доброволецлары, ант итәбез: Гитлер яуларын илдән себереп түгәргә. Теләгебезгә ирешү өчен каныбызны да кызганмаска. Дошман ягына чыкмаска, дезертир булып йөрмәскә. Әгәр мин шушы антымны боза калсам, иптәшләрем мине тотып алып үтергәнче кыйнасыннар... Бу антка мин каным белән кул куям».

Хәлим, антны укып бетерде дә, шлемыннан инә алды. Һәр көн эшләнә торган гади эш шикелле, бер дә каушамыйча, бармагына кадап кан чыгарды һәм шул каны белән «ант» астына исемен тырнаштырып куйды.

— Антны бозармын дип курыкканнар кул куймый, әнисе янына кайтып китә,— диде Хәлим.

Ләкин качкыннарның берсендә дә андый теләк юк иде. Алар барысы да Хәлим кулындагы инәгә үрелделәр. Барысы да, «ант» ны укып чыктылар да, каннары белән кул куйдылар. Хәлим «ант» ны дүрткә бөкләп, эчке кесәсенә салып куйды. Инәне шлемына кадады да оста гына итеп җебен чорнады.

— Инде кузгалсак та ярый. Әйберләрегез онытылып калмадымы?

— Юк.

— Киттек, егетләр. Шулай, кичә сөйләшкәнчә, урманга җитеп кунабыз.

— Җитәбез, җитәбез!

Малайлар (әйдә инде, аларча булсын, егетләр) күпер астыннан күтәрелеп менделәр, үргә җиткәч, буран пәрдәсе артында шактый ерак булып күренгән авылларына борылып карадылар.

— Әнә безнең өй, Хәлим.

— Күрәм. Әнә безнеке дә.

— Безнең ут яктырак икән, Хәлим.

— Юк, Мәгъсүм, безнеке яктырак..,

Бу сөйләшүдән Фазыл белән Нәҗипкә күңелсез булып китте. «Хәлимнәрнең утлары күренеп тора, ә безнеке күренми шул инде...»

Хәлим, күрәсең, аларның хискә бирелә башлауларын сизенде, тиз генә борылды да эре-эре атлап китеп барды.

Ә бераз баргач, котомкасын төзәткән булып, артка калды һәм тагын күзләре белән авылын эзләде. Ләкин авыл күренми иде инде.

— Хуш, авыл... хуш, әни! Рәнҗемә, әни!.. Әй, җырлагыз, егетләр!—диде ул, һәм кинәт туктап, шыпырт кына эндәште:

— Шып бул! Олау. Ындырга!..

Егетләр мөмкин кадәр нелеп, әз генә читтә калган ындырга кереп постылар. Ярый әле постылар, Хәлимнең олау дигәне кечкенә чаналар тартып станциядән кайтып килүче «Илшат» апайлары булып чыкты. Алар узып киткәч, егетләр ындырдан чыгып юлларын дәвам иттеләр.

— Менә инде җырлагыз,—диде Хәлим һәм шунда ук тагын җырламаска ишарәләп кулын күтәрде:

— Шып бул!..

Малайлар яңадан ындырга кереп постылар. Болары басуда калган сабаннарны кар астыннан казып алып кайтып килүче өч-дүрт ир иде. Ирләр әкрен генә үттеләр, егетләргә байтак посып ятарга туры килде. Хәлим аларны мыскыл итеп калды:

— Эшем кешеләре!.. Әллә нинди эш кырып йөриләр дип белерсең... Әй-й... Әйдә, җырла, егетләр!

Кышкы юлда толыпка төренеп, чанага кырын ятып барганда җырлавы күңелле була. Ә аркага капчык асып, кар күмгән юлдан салкын буранга каршы җәяү барганда аның кызыгы юк. «Шулай да, Хәлим кушкач, ярамас. Ул бит безнең командир», диделәр малайлар һәм Әтнә көен сузып җибәрделәр:

Китә казлар, китә казлар,
Китәбез, абзыкайлар.
Киткән казлар кире кайта,
Кайтырбыз, абзыкайлар...

Шактый баргач, алда эт өргән тавышлар ишетелде. Берничә ут җемелдәде.

— «Кызыл маяк»!

— Әйе.

«Кызыл маяк» басу капкасы төбендә малайларны патруль туктатты. Малайлар икәнен күргәч, язу-фәлән сорап тормыйча, уздырып җибәрде.

— Кайсы авыл?

Малайлар ерак бер авылны әйттеләр.

— Кая барасыз?

— Ремесленныйга.

Авылны чыккач, Хәлим иптәшләренә пилоткаларын салып бүрек кияргә әмер бирде. Малайлар бу турыда үзләре дә уйлап баралар, тик Хәлимнең: «Һәй, нинди солдат соң сез — пилотка белән авыл арасында да түзмәгәч,— дип әйтүеннән куркалар иде. Әмерне ишетүгә, бер дә кыстатып тормыйча, капчыкларыннан җылы бүрекләрен алып киделәр.

— Ә сугышта бүрек кияргә ярый микән, ә?

— Ә киез итек, Хәлим?

Малайлар сугыш турында, андагы тәртипләр турында бер-берсеннән сораша-сораша бардылар. Кайбер мәсьәләләр буенча бәхәсләр дә чыккалады. «Ә менә бик зур снарядлар була ди, ул да һавадан пуля шикелле күренми килә микән?..» Мондый чакларда малайлар Хәлимнең авторитетлы сүзен көттеләр. Хәлим дә белмәгәч, кем белсен аны! Әтисе гражданнар сугышында булган, Хафиз абыйсы фин сугышыннан орден тагып кайтты...

Хәлим җавабы дөрес булмаудан, малайлар сугышка барып җитеп үз күзләре белән күргәч, ялганы тотылудан курка иде. Шуңар күрә малайларның уйларын гел икенче якка юнәлтергә карады. Сугыш эпизодлары, сугыш хикәяләрендә чагылган батыр һәм тапкыр солдатлар турында сөйләп барды.

Бара-бара малайларның тавышлары әкренрәк, сирәгрәк ишетелә башлады. Тагы да бераз баргач бөтенләй тынып калдылар.

«Бәрәңгене күбрәк алдым ла... Ипинең дә яртысы житкән булыр иде. Фазыл ич... юлда күп ашала дигән булды...»

«Якын станцага гына чыгасы калган ла, юкка бусына киттек... Хәлим ич, эзебезгә төшмәгәйләре дигән булды...»

Билгеле, алар бу турыда һәрберсе аерым-аерым уйладылар. Әйтергә ярыймы соң! Иптәшләрнең: «Нинди кызылармеец син шуңарга да түзмәгәч!» диюләре бар...

«Бик күп килдек бит инде».

«Ун гына чакрым түгел бу урман, егерме бардыр, әй».

«Әллә адаштыкмы икән?»

Хәзер шундый уйлар килде малайларның башларына. Ләкин һичберсенең бу турыда башлап сүз кузгатасы килмәде, сынатасы килмәде.

Алар хәзер җырлашып, хикәяләр сөйләшеп килгәндәге шикелле бер саф булып түгел, аллы-артлы тезелешеп чана табаны эзеннән бардылар. Атлавы җиңелрәк. Ләкин чана эзе дә урыны-урыны белән генә калган; аны да буран күмгән иде. Малайлар бер эздән икенчесенә чыктылар. Ат эзеннән дә барып карадылар алар, ләкин атның адымы әре шул аның. Малайлар яңадан чана эзенә төштеләр. Төзәтенгән, кагынган булып, бер-берсен уздырып җибәрделәр. «Кар да күп утыргандыр инде котомка өстенә...» Малайлар селкенгәләп куйдылар. Кар коелды, ләкин аның белән генә җиңеләяме соң!

Хәлим дә арыган иде инде. Ләкин ул сер бирмәскә тырышып гел алдан барды. Барды-барды да көйләп җибәргән булды. Гәүдәсен туры тотарга, аякларын нык басарга тырыша. Малайлар аңар сокланып карадылар:

— Арымый. Әйбере дә безнекеннән күбрәк бит әле аның. Берданка, гармонь... Ну егет тә икән...

Аңар карап башкалар да түзде. Ләкин түзүнең бер чиге бар. Фазыл һәрберсе хуп күреп күтәреп алачак тәкъдимне әйтергә булды.

«Егетләрне бераз ял иттереп алу турында уйламыйсыңмы, Хәлим? Арый башладылар шикелле...»— Фазыл шулай дияргә авызын ачты. Ярый әле әйтеп салмады. Хәлим кычкырып җибәрде:

— Егетләр, урман!

Буранга каршы башларын иеп барган малайларга җан керде.

— Урман, урман!..

Барысы да Хәлимне куып җитеп, тагын аның белән янәшә бара башладылар.

— Ай-яй, тиз килеп җиттек ә, Хәлим?

— Тиз...

— Мин сизми дә калдым.

— Мин дә.

— Ерак түгел бит инде, Хәлим?

— Юк инде,— диде Хәлим, ә эченнән: «Анда җиткәнче күзең күгәрер әле», дип уйлап алды. Ләкин күз күгәрерлек калмаган иде инде урманга. Буран пәрдәсе аша гына шулай ерак күренгән ул. Урман, үзе дә зур-зур

атлап каршыга килгән шикелле, якынайды. Бераз баргач, тар юл качкыннарны урман эченә алып керде.

Алар, кичә кицәшкәндә, матуррак урын сайларбыз, дигәннәр иде. Әллә инде шушы урынны матур күреп, әллә арыганга, туктарга булдылар. Котомкаларын салдылар да бик юан бер чыршы төбенә тезеп куйдылар. Һәм, чүгәләп, котомкаларына таяндылар.

Кыш җәй түгел. Ләкин аның да үз матурлыгы бар. Бу матурлыкны җәйнең эссе көннәрендә күз алдына китерсәң, сагынмый калмыйсың. Чыршы катнаш каен урманы бу. Каен һаман ак, матур, нәфис. Чыршы, нарат ылыслары җәйдәгечә үк ямь-яшелләр. Күзләргә ял бирә торган матурлар алар, үпкәләргә шифа була торган җиңел, саф исләләр. Ылысларның өсләренә юка гына кар яуган. Кар, әйтерсең, яумаган, ә ылыс белән бергә үскән. Чыршының табигый бизәге төсле. Һаман шулай торыр, бер дә бетмәс төсле... Кырдагы җил-буран да юк биредә. Әкрен генә, урманның сихри тынлыгын бозудан курыккандай тирбәлеп кенә, тоңкә карлар төшә һавадан. Кар шулкадәр ак: аңардан айсыз төннәрдә урман эченә бертөрле җанга рәхәтлек бирә торган якты җәелә. Ул җылы төсле, җанлы төсле... Төз, мәһабәт чыршылардан, кәкре-бөкре каеннардан кар өстенә, сизелер-сизелмәс кенә булып, күләгәләр сузылган. Алар да җанлы төсле, хәрәкәтләнәләр төсле... Ә өстә, югарыда, озын наратларның, биек чыршыларның башлары, син килгәнгә куангандай, сине тәбрикләгәндәй җиңел генә иеләләр, әкрен генә, бик әкрен генә шаулашалар...

Котомкасы яныннан беренче булып Хәлим күтәрелде. Ул, әллә шушы сихри матурлыкны бозудан, әллә иптәшләренең татлы хисләрен чуалтудан сакланып, пышылдап кына әйтте:

— Учак ягыйкмы инде, егетләр?

Өч малай берьюлы сикереп тордылар:

— Ягыйк, Хәлим, ягыйк! Әйдәгез, чытыр җыябыз!..

Берничә минут үтүгә, чатный-чатный учак яна башлады. Тирә-якка сары-кызыл яктылык сибелде. Ялкын телләре, учактан аерылып очып китәргә теләгәндәй, бер озынаеп, бер кыскарып, югары сикерделәр. Малайларның кайсысы учак өстендә котелок һәм чәйнек белән кар эретте, кайсысы бәрәңге әрчеде, кайсысы таган асты. Озак та үтмәде, һавада суганлы бәрәңге шулпасы исе аңкып, малайларның борыннарын кытыклый башлады. Ма-

лайлар зур кашыкларын алдылар, исне читкә җибәрәселәрс килмәгән шикелле, борыннарын тартып-тартып иснәделәр. Телләрдә сүз, башларда уй бетте. Алар бар да Хәлимнең «пеште, егетләр», дигәнен көтеп, аның күзләренә карап утырдылар, Хәлим әледән-әле ашның тәмен татып караганда, төкерекләрен йотып тордылар. Менә Хәлим ашның өлгерүе турында хәбәр итте. Малайлар дәррәү котелок өстенә иелделәр:

— Ну, тәмле дә булган, егетләр...

— Ай-яй...

— Хәлим малай, әллә син моңар берәр нәрсә салдыңмы, ә?

Кашыклар бик тиз котелок төбенә төшеп шакылдый башладылар.

— Әз булды ла бу.

— Кече телемә дә йокмады.

— Әйдәгез, тагы пешерәбез.

Котелок тагы бер тапкыр бушагач, малайлар, асларына ылыслар сындырып салып, учак тирәли тезелеп утырдылар. Әллә никадәр әкият сөйләнде, авыл кызыклары хәтерләнде. Башта алар төне буе шулай утырып чыгарга булганнар иде, ләкин.. гәүдәләре бик тиз бөгелә башлады. Башлар, рәхәт минрәп, котомкаларга төртелде. Күзләрне йому — рәхәт, ачу — михнәт иде хәзер. Күбрәк йомылдылар алар хәзер, азрак ачылдылар. Аннары бөтенләй йомылдылар күзләр. Озак та үтмәде, Хәлимнән башкалар бар да бер көйгә, әкрен генә гырылдый-мышныйй башладылар. Хәлим аларның өсләренә ылыслар сындырып алып япты.

13 СЕРЛЕ ЯУЛЫК

Барысы да йоклап беткәч, Хәлим шомлана калды. Башына төрле уйлар керде аның. Учактан читкәрәк китеп (чөнки ут яктысында торып, караңгы җирне күреп булмый), тирә-якны күзәтте: «Бүре эзләре күренмиме? Хәзер күп, ди, ул якта. Бу як кешеләренең төшләренә дә кермәгән боланга кадәр бар, ди, хәзер... Сугыш җирләреннән качып килә, ди...»

Хәлим учакка чыбык-чабыкны күп итеп салды. «Бүре килмәсен». Ут көчәеп китте, учак әйләнәсендә кар күзгә күренеп эреде. Җирдән, көзен коелган яфраклардан җы-

лы пар күтәрелде. Яфрак араларында картайган бака яфраклары, саргаймый калган яшь үләннәр күренә иде.

Утыра-утыра бернинди дә шомлы аваз ишетелмәгәч, тынычлана төште Хәлим. Берданкасын тезләреннән алып, ботакка элде. «Әни яткандыр инде. Берни белми бит әле ул. Иртәгә кич көтә башлар. Урынны да җәеп куяр... Сизеп торам. Ашка каз ите сала инде ул. Ә иртәгә дә, берсекөнгә дә кайтмагач...»

Хәлим башын түбән иеп хискә бирелеп торды һәм капчыгыннан кәгазь-карандаш алды да, берданка түтәсенә куеп, әнисенә хат язарга кереште:

«Әни, мин фронтка киттем. Мәскәү ягына, әти сугышкан җиргә. Бу хатны алганда, мин инде сугышып йөри дип бел. Минем өчен борчылма, әни, яме? Сугышның куркыныч җиренә кермим мин.

Шак-шок баса алмачуар,
Дагасы корыч булса,
Без дә болай йөрмәс идек,
Замана тыныч булса.

Хуш, әни. Улың Хәлим».

Хәлим хатны конвертка салып, адресын язды һәм, станциягә җиткәч, онытылып калмасын өчен, тышкы кесәсенә тыгып куйды. Эш беткәч, тынычланып та киткәч, аңа да йокы һәҗүм итә башлады. Хәлим аны качыру өчен күз кабакларына кар куеп торды. Беренче һөҗүм кире кайтарылгач, эш юктан эш булсын әле дип, капчыгын бушатып, әйберләрен ипләп тутырырга уйлады. Иң аска гармоньны салып калдырсын әле, анысы поездга утырмыйча кирәк булмый. Аның өстенә бәрәңге, бәрәңге өстенә ипиләрне салыр. Хәлим шулай сөйләнә-сөйләнә капчыгын бушатырга кереште һәм... «Чү, бу нихәл инде тагын?..» Хәлим кайсын төртеп, кайсын селкеп, малайларны уятырга тотынды.

— Әй, торыгыз әле, тор!..

Тегеләр бер-бер артлы сискәнеп уяндылар. Каушаган, аптыраган, бераз курыккан Хәлимгә ни әйтергә белми күзләрен уа-уа, гаҗәпләнеп карап торалар иде алар.

— Карагыз әле, берәрегезнең әйбере югалмаганмы?..

Малайлар, капчыкларын чишеп, әйберләрен барлап чыктылар. Кесәләрен барладылар. Бүрекләренә кадаган инә-җепләргә кадәр тотып карадылар.

— Юк, югалмаган.

— Ник алай дисең, Хәлим?

Хәлим ник икәнен әйтмәде.

— Шулай кирәк... Военный тревога... Ятыгыз...

Соңгы командага бер Нәҗип кенә буйсынды. Ул астындагы ылысларын кызу костерга якынрак күчереп, иплəбрәк ятты да күзләрен йомды. Ә эчләренә суык төшкән Мәгъсүм белән Фазыл ятмадылар. Алар, тешләре тешкә бәрелгәнне бер-берсенә сиздермәскә тырышкан хәлдә, көн дә кич белән әниләре җәеп бирә торган йомшак урын-җирне сагындылар. «Урманда кунарга уйлап ялгыштык бугай ла без. Тукта әле, теге җиде баһадир йорты шушы тирәдә генә иде түгелме соң?» Малайлар йортны күзләре белән эзли башладылар.

Җиде баһадир йорты дигәннәре — тарихи йорт. 1918 елны, гражданнар сугышы көннәрендә җиде кызылармеец, шул йортка бикләнеп, тәүлек буена үзләрен камап алган акларга каршы торалар. Алка кысылганнан-кысыла бара. Тәрәзә пыялалары күптән коелып төшкән, ишек, хәтта өй бүрәнәләре чәрдәкләнеп бетә. Кызылармеецлар җидедән алтыга, бишкә... икегә калалар. Икенең дә берсе авып төшә. Соңгы берсе үзенең һәм иптәшләренең патроннарын атып бетергәч, соңгы ике пулясының берсе белән әле генә авып төшкән ишектән беренче булып атылып кергән ак офицерны чәнчелдерә, икенчесен үз маңгаена җибәрә. Һәм иптәшләре арасына авып төшә.

Туп тавышлары тынгач, ак банда изге җиребездән себереп түгелгәч, тирә-як крестьяннары җиде баһадирның сөякләрен җыеп алып, шул йорт каршындагы яшь чыршы төбенә күмәләр, кабергә кәз җәяләр, рәшәткә тоталар. Ә гражданнар сугышына кадәр урман каравылчысы торган әлеге өйне төзәтәләр, тәрәзәләрен куялар. Казаннан килеп, тышкы стенасына мемориаль такта кадаклап китәләр.

Бу йорт олы юлдан байтак читтә, урманның куе бер җирендә. Ләкин аңар сугылмыйча киткән узгынчы бик сирәк. Эше ашыгыч кеше өй турысыннан, һич югында адымын әкренәйтеп, бүреген салып, баш иеп үтә, ә ашыкмаган — керми калмый. Шунда ашап-эчеп чыга, кайберләре йокларга да кала. Миче һәрвакыт төзек, берәр нәрсә пешереп алырга теләсәң, учагы да, казаны да бар. Хәтта керосин лампасына кадәр хәстәрләп куелган.

Карчык-корчык өчен, бигрәк тә гражданнар сугышын-

да үзләренең ирләрен яки улларын югалткан карчыклар өчен бу — изге йорт. Алар бирегә хәтта ерак авыллардан килеп, елый-елый намазлар укып, догалар кылып китәләр. Бу йорт пионерлар өчен дә изге. Карлар китеп, беренче умырзая чәчәкләре төртеп чыккач та, алар бирегә барабаннар кагып, быргылар кычкыртып киләләр. Кабер өстенә чәчәкләр утырталар, җиде баһадир хөрмәтенә костер яндыралар, баһадирларга атап чыгарган шигырьләрен укыйлар. Укытучылары аларга бу үлемсез баһадирлар турында сөйли.

Тукта әле, нигә безнең юлчыларга да шунда кереп, бераз җылынып чыкмаска? Фазыл белән Мәгъсүм берберсенә карашып алдылар һәм берсен-берсе сүзсез дә аңладылар.

— Әйдә, Мәгъсүм малай, кереп чыгабыз, ә?

— Әйдә соң.

Әлбәттә, Нәҗип тә аларга кушылды. Хәзерге минутта бөтен уе капчыктагы серле әйбердә булса да, Хәлим дә иптәшләре белән кереп чыгарга булды.

Әйе, ул да башкалар кебек үк, кереп чыгарга гына булды, ләкин җиделе лампа кабызылгач, мич ягылгач, аның җылысы инде җылыта башлагач, урманга, салкын карга чыгып ятарга теләмәде. Ә бүтәннәр инде күптән шулай... Алар, «Бераз утырыйк әле... Тагын бераз утырыйк әле»— дип, бер-бер артлы йокыга талдылар. Иптәшләренең күзләре йомылгач, Хәлим тагын капчыгына тыгылды. Ипи телемнәре арасына тәмәке янчыгы кадәр генә ят капчык кереп кысылган иде. Капчык юка ак киндердән тегелгән, үзе нинди тугәрәк нәрсәләр белән тулы. Хәлим, һаман да ятсынып, бераз шикләнеп капчыкны чишеп җибәрде. Әбәү! Хикәяләрдә генә укыганы бар иң Хәлимнең мондый хәлне! Капчык тулы чикләвек! Хәлим бер чикләвекне ватып карады. Менә дигән, тәмле итеп киптерелгән, тук төшле урман чикләвеге! Мондый чикләвекләрне кызлар егетләр өчен берәмләп сайлап киптерәләр дигәнне ишеткәне бар иде Хәлимнең. Ләкин Хәлим егет түгел бит әле. Чү! Ә бусы нәрсә? Яулык иң! Чиккән яулык!.. Хәлим яулыкны бер алды, бер салды. Әллә төшме бу!.. Юк, төш түгел. Хәлим, бераз тынычлангач, яулыкны сүтеп карады. Аның читенә, чәчәкләр эченә, бик матур итеп бер хәреф — «Г» хәрефе чигелгән иде. Капчык иясе дер инде... Ә кем булыр икән бу «Г»?

Гөлчәһрә? Галимә? Әллә Гөлзәһрәме? «Г» хәрефенә башка кызлар юк бездә. Ә, Гөлгенә бар бит әле...

Хәлим кызларның дүртесен дә күз алдына китереп бастырды. Ул аларның һәркайсына, син түгелмс дигән кебек, күз йөртеп чыкты. Кызлар, кайсы елмаеп карап куйды, кайсы тик кенә басып торды. Гөлгенә иде бу тик басып торганы. Ә берсе оялып башын түбән иде. Бусы әллә Гөлзәһрә, әллә Гөлчәһрә иде.

Аннан кызлар тагын дүртесе бергә жыелып көлеп җибәрделәр. Хәлим аларның көлүләрен дә ишеткәндәй булды.

«Кайсыгыз эше бу? Ничек салдың син аны минем капчыкка?..»

Хәлим, никадәр уйласа да, очына чыга алмады. Күзләрен йокы баскач, торып әрле-бирле йөрде, мичкә утын өстәде, ләкин ни генә эшләмәсен, серле капчык белән чикләвек, матур чигелгән кулъяулык Хәлимнең уеннан китмәде.

Төн пәрдәсе юкарды. Таң атты. Урман өсте алсуланды, ә аста эңгер-меңгер эреп бетмәгән иде әле. Төне буе экрен генә шаулап торган урман, рәсемдәге шикелле, тынып калган иде. Малайлар, бер-бер артлы уянып, башларын күтәрделәр. Берсеннән күрмәкче берсе урманга чыгып битләрен кар белән юып керделәр. Татлы йокыдан соң була торган изрәү бетеп китте. Юлчылар тагы котелок белән чәйнекләренә ябыштылар.

Уен-көлке, төш сөйләү, алда торган рәхәт көннәр...

— Ә Нәҗип ник тормый?

— Нәҗип, тор инде!

Нәҗип тормады. Ул авырый иде. Өченче көн, китү турында киңәшкәндә үк, авырый иде инде ул. Бармаска хәйләли диюләреннән яки калдырып китүләреннән курыкмаса, ул иптәшләрен берәр көн сабыр итәргә дә өндәгән булыр иде. Әз генә дә зарланмыйча, эз генә дә сиздермичә, шушында кадәр килеп житте. Һәм хәзер дә әле үзен сәламәт күрсәтергә тырышты. Торды, көлгән, шаярган булды. Башкалардан күреп ул да урманга чыгып битен кар белән юды. Ләкин артык түземе калмады, тәмам хәле бетеп, башын капчыгына төртте.

Калтыранды, теше тешкә бәрелде малайның. Иптәшләре бишмәтләрен салып, аның өстенә яптылар, баш астына салдылар.

— Ашап кара әле, Нәҗип.

Нәҗип ашамады. Чәйне бер-ике генә йотты да урынына ауды. Ә бераздан инде йокы арасында саташаук башлады. Малайлар хафага төштеләр:

— Нишлибез инде?

— Нәҗип, без сине кайтарып куйыйк.

Нәҗип сискәнеп аякларына басты, ләкин хәзер инде аны аяклары чак күтәреп тора иделәр. Шул хәлендә дә малай үзенең хәле авыр икәнен яшереп маташты.

— Терелэм мин... Әз генә ятып торам да терелэм... Мин бара алам, дуслар...

Юк, Нәҗип бара алмады. Өйдән чыгып берничә адым китүгә, чайкала башлады. Аны иптәшләре култыгыннан җитәкләделәр. Нәҗип барган саен иптәшләренә салына төште. Ниһаять, Нәҗипнең аяклары сөйрәлеп бара башладылар.

— Юк, кайтарып куйыйк без сине, Нәҗип.

— Үтерсәгез дә кайтмыйм мин. Миңа сезнең белән рәхәт, дуслар. Бер үзем өйдә ятып акылдан язам мин...

— Их, Нәҗип, Нәҗип...

Хәлим котомкасын Фазылга бирде дә авыру иптәшен аркасына күтәрде.

Туктый-туктый, Нәҗипне әле берсе, әле икенчесе аркасына күтәреп барганга, юл бик әкрен кыскарды. Малайлар станциягә караңгы төшкәндә генә барып керделәр.

— Нишләтәбез, егетләр?..— диде Хәлим, Нәҗипне вокзал скамьясына кертеп салгач.

— Больница бар ди бит биредә...

— Бар.

— Шунда илтик.

Бу киңәшне ишеткәч, Нәҗипнең күзләренә яшь килде. Больницага керсәң, берсүзсез алып калачаклар... Ул үзенең тиз терeләчәгенә иптәшләрен тагын бер тапкыр ышандырырга тырышып карады. Ләкин инде аңа ышанмадылар.

— Анда бер-ике көннән терелтерләр, без сине көтеп торырбыз,— дип ант иткәч кенә, Нәҗип больницага кереп ятарга риза булды. Ләкин Нәҗипнең эше бер-ике көнлек кенә түгел иде. Үпкәләре шешкән иде аның.

— Өч-дүрт атнасыз да аякка баса алмас,—диде врач.

Бу минутта Нәҗипне кызганмаска мөмкин түгел иде. Гүя башкалар күкләргә күтәрелергә тора, ә моның бер-

үзен упкынга ташларга хөкем иттеләр — күгәренде, телсез-авызсыз калды.

— Сез китәсез инде, әйе?— дигән сүзләрне, басылган кеше кебек, көч-хәл белән генә әйтә алды ул.

Малайлар уңайсызланып бер-берсенә карашып куйдылар.

Ялганларга? Авылга кайтып торабыз, дияргә? Юк, кирәк түгел.

— Әйе, без китәбез, Нәҗип. Без, барып җиткәч, сиңа хат язарбыз, Нәҗип. Терелгәч үзең килерсең, Нәҗип...

Малайлар үзләренең поездда ашап барырга билгеләнгән каз итләрен, атланмайларын, кабартмаларын капчыкларыннан чыгарып Нәҗип алдына куйдылар да исәнләшеп чыгып киттеләр.

Мондый минутлар олы кешеләр өчен дә ямансу була. Нәҗип өчен, бала өчен, сугышның беренче көннәрендә үк әтисез калган, озак та тормый әнисен дә җирләгән ятим бала өчен, бу ямансулык берничә тапкыр көчлерәк иде, ул үксеп елап җибәрде.

14 КҮҢЕЛСЕЗ БУЛМАДЫ

Ах, гел син уйлаганча гына булып торса!.. Хәлимнәр, поезд килер, утырырбыз да китәрбез дип хыялланганнар иде, өч-дүрт көннән барып та җитәрбез, дигәннәр иде. Булмады. Пассажир поездлары килделәр, утыртмыйча узып киттеләр. Гаскәри эшелоннар да килделәр, аларына якын да җибәрмәделәр.

Ләкин малайлар өметне өзмәделәр.

— Берәрсенә эләгербез әле...

Алар хәзергә өс-башларын хәрбиләштерүне дәвам иттерделәр. Хәлимнең өстендә өр-яңа сукно бишмәт иде. Ул аңар станция базарыннан кыршылып беткән яшел пиджак алмаштырып алды. Гражданнар сугышыннан бирле очырмада яту, аңарчы өч ел буена әтисе башында җилдә, яңгырда, кояш астында йөрү сәбәпле, шлемының кызыл йолдызы уңып калган иде. Фазылның күлмәге кызыл икән, итәк читен кисеп алып, шлемга яңа йолдыз тектеләр. Хәзер инде аның чалбары гына хәрби түгел. Ләкин зарарсыз. Бара-тора анысы да җайланыр әле... Мәгъсүм үзенең сукно чалбарын, юа-юа агарып беткән, эт өрде исә тетелеп китәргә торган яшел галифега алмашты. Әле бер хәреф тә язмаган шәмәхә карандашын,

ике дәфтәрен бер канаты китек кызыл йолдызга алмаштырып алды. Йолдызны пилоткасына кадады да китек канаты урынына кызыл карандаш белән пөхтә генә итеп канат ясап куйды.

— Әз генә дә беленми. Әй, булды да соң!.. Арттан килеп кире алмас микән, дуслар?

— Булыр да...

— Әйдә, поезд кузгалып киткәнче урманга кереп торыйк...

Юк, малайларга станциядә күңелсез булмады. Төннәрен вокзалга кереп йокладылар. Бирелә төрле милләт кешеләре булып, күбрәк Мәскәү, Ленинград шәһәрләреннән эвакуация тәртибендә ерак тылга күчеп баручы хатын-кыз һәм бала-чага иде. Алар арасында баш астына котомкаларын куеп, коры скамьяда яки идәндә йоклавы үзе бер хозур булды. Биредә аларның аякларын, башка пассажирлар рәтендә таптап киттеләр, аларга да башкалар рәтендә, «товарищ пассажир», дип эндәштеләр, «әй, подвинься, гражданин», дип кычкырдылар. Ә Хәлимгә бер әби, хәтта, «товарищ военный», диде. Я инде, авылда кайчан күрер иде малайлар бу хөрмәтне!..

Вокзал артында гына урман. Малайлар иртән тордылар да шунда чаптылар. Анда алар учак ягып, бәрәңге шулпасы пешереп ашадылар. Әнинең бәйрәмнәрдә пешерә торган тәмле ашларыннан да тәмлерәк иде бу шулпа... Аннары егетләр куян атарга киттеләр. Кайткач янә бәрәңге шулпасы... Ә куян?.. Шулай да, бер тапкыр алар (кичке эңгер-меңгер куерып җиткән иде инде), артык та түгел, ким дә түгел, берьюлы өч куян атып кайттылар. Тәҗрибәле аучылар өчен дә сирәк очрый торган бу хәл малайларны әйтеп бетергесез шатландырды.

Ләкин иртә шатландылар малайлар. Әй, тидерә алмаган булсалар!.. (Ялгыш әйтеп ташладым, монысы турында соңыннан...)

Алар куяннарның берсен, иң симезен, пешереп ашадылар. Арт санын, иң тәмле җирен, Нәҗипкә керттеләр. Икесен сатарга алып чыктылар. «Әнә анда нинди кызыл алмалар тезеп куйганнар. Куяннарны сатабыз да алма алып ашыйбыз, симәнке дә алабыз».

Малайлар куяннарны базарга аның өчен генә дә алып чыкмадылар. Үзләренең мылтыкны тиккә генә асып йөрмәгәнлекләрен дә күрсәтергә кирәк ич! Югыйсә, сөтче ха-

тыннар узган саен: «Әй, хәсрәт аучылар, куяныгыз кайда?» — дип кычкырып калалар, минә күрсеннәр инде...

— Озаграк йөртик, яме, Хәлим, бар да күрсен.

— Тегесен дә элек базарда йөртәсе калган, шаккатсыннар иде.

Сөтче хатыннар икесенә дә җитәрлек шаккаттылар. Ә бер кеше, җиз төймәле, кызыл фуражкалы кеше, җәнлекләрне әйләндерә-әйләндерә карады да мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Ерак барып йөрергә дә туры килмәгән, күрәм?..

— Юк... әнә, теге йорт янына килгәннәр иде... Бах та бах без аларны!..

Кызыл фуражка Хәлимнең башыннан сыйпады:

— Булдыргансыз, булдыргансыз, әйтәсе дә юк... Ә беләсезме, сез бу җәнлекләрегезне Фәррах абзыйга алып керегез, станция начальнигына. Ул алар өчен сезгә, сорасагыз, поездын да кызганмас.

— Поездын да кызганмас? Ул, бәлки, шуның өчен безне утыртып та җибәрер әле?!

Малайлар, шатлыкларыннан кая басканнарын да белмичә, вокзалга, станция начальнигы кабинетына атылып килеп керделәр.

Начальник калын кенәгәгә нидер язып утыра иде, малайларны күрүгә башын күтәрде.

Хәлим, дулкынлануыннан бер урында таптана-таптана:

— Абый, сезгә куян кирәкме?— диде.

Начальник башта Хәлим кулындагы җәнлекләргә/күзен ача-йома карап торды, аннары зур корсагын, ике кулы беләп тотып, рәхәтләнеп көлде:

— Беренчедән, болар куян түгел, шайтан алгырлары, ә йорт куяннары,— диде ул көлүеннән бераз айнып,— икенчедән, Бәдерниса җиңгәгезнекеләр!.. Берсен кая куйдыгыз?..

Хәлим эшнең нәрсәдә икәнен бик тиз төшенде. Бер кызарынды ул, бер агарынды, җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрлек булып оялды һәм бик мескенләнеп җавап бирде:

— Без анысын ашаган идек инде, абый...

— Ашаган идегез?..

Начальник телефон шалтыратты:

— Квартираны... Бәдерниса, бүреләрне каһәрләүдән тукта! Кроликларың табылды... Ә, юк, мәшәкатьләнеп

йөрергә туры килмәс... Әйе... Өчесен дә... Берсен суйган өчен алып калганнар... Ә мин аңладым... Кереп ал. Бик өнмез күренәләр. Теге китек колаклысы жаркойга бик җилле булыр төсле...

Начальник трубканы элде дә тагын бер җәелеп көлде:— Ах, фәлән-төгән нәмәрсәләр...— диде начальник.— Беләсезме, сезне моның өчен нишләтергә кирәк иде? Ярый инде, көне андый түгел. Бәйрәм бүген, әле генә тапшырдылар... немецны Москва яныннан фчт!.. Барыгыз, Бәдерниса җиңгәгез килеп җергәнче, ычкыныгыз... Югыйсә, ул мин түгел...

Инде беттек дип, ябып куя икән дип, тын алырга да куркып торган аучылар, мондый хөкемне ишетүгә, чигенә-чигенә артлары белән ишеккә килеп бәрелделәр. Коридор буенча берсен-берсе этә-төртә йөгергәндә, тышкы ишектән кереп килүче бер хатынны (мөгаен, начальник хатыны булгандыр) чак бәреп екмадылар. Тимер юлның теге ягында көлешеп торган сөтче хатыннар һәм әлеге җиз төймәле, кызыл фуражкалы кеше кычкырып калдылар:

«Ничәшәрдән саттыгыз?»

«Ха-ха-ха».

«Акчагыз төшеп калмасын...»

Хәлимнәр, алга-артка карамыйча, урманга шылдылар.

Килгән чакта иңне баскан капчыклар бөтенләй җиңеләеп калганнар иде инде.

Башта бәрәңге бетте. Аннары ипи. Он да бик аз калды. Малайлар хәзер чамалап кына ашадылар. Хәлим, «азык бетәр дә иптәшләр кайтып китәр», дип куркып, бөтенләй аз ашады.

Бара-тора малайларның котомкаларында бернәрсә дә калмады. Серле куллар салган чикләвекне дә инде бүлгәләп ашап бетерделәр. Буш капчыклар кешене шиккә төшермәсен дип, малайлар урманнан агач ботаклары җыеп салдылар. Элеккечә вокзалга кереп, калай кубтан чылбырлы кружка белән кайнар су эчтеләр, чыктылар да поезд көттеләр. Сугыш кораллары төягән эшелоннарны карап йөрделәр.

— Ну корал да бар икән, ә...

— Бу танкны гына карагыз әле, малайлар.

— Ул нәрсә-ә... Әнә теге пушка берүзе ике платформага көчкә сыйган...

— Әй, көпшәсснә генә ятып барырга...

— Қара әле, Хәлим, болары җимерелгән.

— Немецныкы. Әнә фашист билгесе.

— Ай-яй, белен булганнар... Аларны кая алып баралар икән?

— Эретеп яңаны коярга.

Малайлар, эшелоннар тирәсендә йөрделәр-йөрделәр дә, больницага кереп, сестралардан Нәҗипнең хәлен сораштылар. Бер тапкыр шулай, Нәҗип, иптәшләренең тавышын ишетеп, коридорга чыкты һәм инде чыгып китеп барган иптәшләре артыннан тышка йөгерде. Аягында больница чүвәкләре, өстендә одеал иде аның.

— Мин сездән калмыйм, дуслар,— диде ул.— Мин терелдем инде. Ятмыйм мин анда, бик күңелсез анда...

Иптәшләре аны больницага кереп ятарга үгетләделәр. Нәҗип больница сүзен ишеткән саен күбрәк сыкранды һәм туктап торган поездга таба омтылды. Иптәшләре аны җибәрмәделәр.

— Әйдә, кер, Нәҗип.

— Юк, кермим... Минем антым бар. Мин аны каным белән яздым. Минем үчем бар. Иң явыз дошманда, мине әтисез калдырган дошманда минем үчем... Барып антымны үтимче, әтием өчен үчемне алыймчы...

Вакыйга шуның белән бетте: сестралар килеп чыгып, Нәҗипне тотып алдылар һәм больницага алып кереп киттеләр.— «Ә сез, марш моннан!..»

Хәлимгә Нәҗип бу минутта аеруча кызганыч булып тоелды. «Сат та сат» дип, килгәннән бирле аптыратып бетергән теге җиз төймәле, кызыл фуражкалы кешене эзләп табып, аңа берданкасын сатты һәм бөтен акчасына базардан алма, мандарин, пряник, чикләвек алып сестрага кертеп бирде:

— Нәҗипкә бирегезче шуларны, апа.

15 ЯРЫЙМЫНИ, АБЫЙ!..

Бары дүртенче тәүлеккә чыкканда гына Хәлимнең куллары беренче тапкыр вагон тоткасын тоту хөрмәтенә ирештеләр.

— Егетләр, калмагыз!

Поезд кузгалып китте.

Хәлим тагы иптәшләренә эндәште:

— Фазыл, Мәгъсүм!

Җавап булмагач, Хәлим өерелеп кереп килгән халыкны ырып-ерып, кередән вагон тамбурына чыкты, ләкин иптәшләре анда да юк иде.

— Бүтән вагонга эләктеләр микәнни?..

Хәлим, этелә-төртелә, вагоннан вагонга кереп йөрде. Бөтен вагоннарны йөреп чыкты ул. Ләкин Фазыл белән Мәгъсүм беркайда да юк иде.

— Эләгә алмаганнар... Эх!..

Хәлим, чиктән тыш күңелсезләнеп, беренче станциядә төшеп калды. Мәскәү ягыннан килә торган поезд баскычына ябышып, янадан үз станцияләренә кайтты. Фазыл белән Мәгъсүм анда да юк иде. Хәлимнән мылтык сатып алган Кызыл фуражка аларның күптән түгел генә Мәскәү ягына бара торган гаскәри поездга утырып китүләрен әйтте. Бу кеше Хәлимне кызганды һәм шул ук кичне аны поездга утыртышып җибәрде. Ләкин, берничә станцияне үтүгә, төшереп калдырдылар. Хәлим тагы утырды, тагы куып төшерделәр.

Арыды, ачыкты малай.

Ачлык, йокысызлык, шуның өстенә проводникларның орыша-төртә төшереп калдырулары Хәлимнең дәртен суытып җибәрде. Ләкин ул боларның берсенә дә әһәмият бирмәскә тырышты. Ә менә ялгызлык аны бик борчыды. Иптәшләреннән калу көнләштерде:

— Мәгъсүмнәр әллә кая барып житкәннәрдер инде...

Һәм шунда ук үзен кулга алды:

— Зарар юк. Мин дә житәрмен, житәрмен. Төшерсәләр, тагы утырырмын, баскычына ябышып барырмын...

Ләкин ул елларда кешеләр поезд баскычларын балга кунган чебеннәр кебек сырып ала иделәр. Хәлим анда эләгә алмады, я эләгүенә очырып төшерделәр. Бу очырулар бик күпкә киткәч, Хәлим янәдән утырырга омтылмады. Ул инде тәмам хәлдән тайган иде. Ә вагоннарга менү өчен хәл кирәк, талашып, даулашып, кешеләрне этеп-төртеп менәргә кирәк. Хәлимдә анлык көч юк иде шул инде. Ул юл-юл сузылып яткан шома рельслар аркылы, аякларын көч-хәл белән күтәреп ала-ала, вокзалга таба атлады. Вокзал читендәге базарда нинди генә ашамлык юк иде. Хәлим аларны күрмәс өчен, башын иеп, аска карап барды. Ләкин тәмле исләр аның борынын ярып керде, башын әйләндерде, тәмам исертте. Хә-

лим түземен җуеп башын күтәрде. Әнә бер хатын зур табак белән ит күтәреп килә. Кайнар ит, булары чыгып тора. Ай, исе нинди тәмле!.. Хәлимнең әнисе дә итне шулай тәмле итеп пешерә торган иде. Бүген дә пешергәндер әле. Бәрән суярга калган иде бит ул. Суйды микән? Әллә, Хәлим кайтмагач... Әнә бер зур хатын кечкенә-кечкенә ипиләр күтәргән. Ух, нихәтле күп!.. Ай-яй, бәрәңге котлеты! Ничек кызарып пешкән...

Хәлим ризыкларга артык карый алмады.

Бер минутта ул, капчыгыннан гармонен алып сатарга да, ит, ипи, бәрәңге котлеты алып, туйганчы ашарга уйлады. Икенче минутта бу уеннан кайтты. Узган сабан туенда бирделәр бит ул гармоньны Хәлимгә. Көрәштә җиңгән өчен.

— Өч-дүрт елдан әтиең буласың икән, молодец, егет! — диде аңар авыл советы председателе.— Мә, егет, җилкендер яшь йөрәкләрне!..

Хәлим гармонен яңадан капчыгына салды. Ә борынын тәмле исләр кытыклады да кытыклады. Авызыннан сулар килде. Менә ул, кинәт кенә исенә төшеп, каушый-каушый, эчке кесәсеннән серле куллар салган яулыкны тартып чыгарды.

Сигезгә бөкләп салынган яулык таралып китте. Нинди нәфис ефәк!.. Ой, нинди нечкә итеп кызыл белән чигелгән аның читләре! Ә бер читендә бигрәк нәфис роза чәчәге.

Кечкенә ипиләр күтәргән зур хатын һәм башка тутәйләр яулыкка игътибар иттеләр.

— Сатамсың, малай?

— Мә, кил, егет, ит бирәм.

— Юк ла, кәбестә пирогы ярата ич ул...

— Мә, кайнар сөт эчеп җибәр. Күмәч белән...

«Нәрсә бирсәгез дә ярар. Тизрәк бирегез генә...» Хәлим яулыкны беренче очраган тутәйгә сузды. Шул чак яулык читендәге матур «Г» селкенеп куйган кебек тоелды... «Г» — бик чибәр бер кыз башына әйләнде. Гөлчәһрә!.. Юк, Галимә ич!.. Гөлгенәме әллә?.. Кыз «оятсыз, оятсыз...» дигән кебек башын чайкап торды. Хәлим, аны әйбәтрәк күрү өчен, күзләрен зур ачты. Кыз юк булды.

Хәлим яулыкны кире алды, яулык иясе аңар кинәт якын булып китте. Якын, бик якын... Ләкин — кем соң ул, кем?

Һәрвакыттагыча назлы көлә-көлә, Гөлчәһрә йөгереп

узды. Гөлзәһрәсе телен чыгарып, Хәлимне үчекләп куйды. Бик тез, бик ак тешләрен күрсәтеп, Галимә шаркылдап көлде. Уйчан, сипкелле, матур кара күзле Гөлгенә бераз сагышлы елмаеп торды да томаига әйләнеп күздән югалды.

Хәлим керле кулларыннан тап төшермәс өчен яулыкны бармак битләре белән генә бөкләде дә яңадан эчке кесәсенә, хат кәгазьләре, конвертлар арасына салып куйды. Кинәт ниндидер көч аның аякларын хәрәкәткә китерде. Инде Хәлим тук иде. Гомер буена йокламаса да түзәр, поезддан тугыз түгел, туксан тапкыр төшерсәләр дә, үзендә туксан беренче тапкыр утыра алырлык көч табар кебек иде...

Менә ул вокзал баскычына килеп утырды. Капчыгыннан гармонен алды да башын бер якка салып, күзләрен тәмле йомып уйнап җибәрде:

Кай илләргә барып коя икән
Борылып-борылып аккан агым су?
Бергә торган чаклар рәхәт иде,
Аерылышу бигрәк ямансу...

Эх, җыр! Җыр!.. Нәрсә тиң соң сиңа ялгыз калган чакларда, эч пошкан минутларда!..

Хәлим тагын берне сузды.

Менә ул үзенең алдында аяклар — киез итекләр, күн итекләр, галошлар күрде. Алар торган саен күбәя бардылар. Хәлим оялып гармоненың мехларын кысты.

— Я, тагы нит әле, кабәм...

— Я инде, йөрәк маем...

Хәлим бармакларын, шаян йөртеп, гармонь телләрен өстән аска таба оста сирпеп төште. Һәм... Их-х-ма-а!..

Идел бит ул, тирән бит ул!..
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн
Без аерылган көн бит ул.

— Һай, рәхмәт төшкере.

— Атәме?

— Вота, кәбәм, бу атә...

— Пичункаларны нитеп-нитеп йибәрә.

— Да-а...

Хәлим башын гармонена сала төшеп тартып җибәрде. Һәм шул чакта бик калын, бик көчле бер тавыш ишетте:

— Һәй-й, мала-ай!..

Хәлим башын күтәреп тавыш килгән якка карады.

— Малай, кил әле, бире кил!

Хәлим, гармонен кысып, урыныннан күтәрелде. Чакыручы кулың изәде.

— Бире кил, малай, бире!..

Хәлим, гармонен ике кулына тоткан килеш, чакыручыга таба китте. Кызылармеец иде ул. Ишеге ачык пассажир вагоннарының берсенең баскычына утырган да сиһәнке яра иде. Хәлим килеп җитәрәк, сикереп төшеп янәшә рельс янына чүкте:

— Утыр әле, егет, шунда. Сызып җибәр әле берне, йөрәккә үтеп керә торганны.

— Баягы ишене.

— А по-нашенский не тово-сь?..

Хәлим аңа сораулы карады. Хәлимне чакырып китергән кызылармеец аңлатып бирде:

— Уйна, уйна, егет. Әйбәт уйный икән ди ул.. Ты молчи, Чтапан...

Хәлим сызып җибәрде:

Аклы ситсы күлмәгеннең
Якаларын кем уйган,
Эх...
Исемең матур, кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган.

— Әт-тә-тә-тә...

— Ну, өздерәсең икән, малай!

— Гармонь шәп аның.

— Гармонь што, моң бар егеттә, моң...

— Сат, малай, гармонеңны.

Хәлим гармонен кукрәгенә кысты.

— Кайда бара икән, сора әле.

— Мәскәү ягына ди бит.

— Безгә утырмас микән?

— Утыр безнең вагонга, малай.

Моны әйтүченең петлицаларында өчәр дүртпочмак иде. Бер ягында наган, икенчесендә мәктәп военругыныкыннан да әйбәтрәк полевой сумка.

Хәлим урыныннан сикереп торды. Күзләре кинәт очкынланып китте.

— Ярыймыни, абый?

— Кемгә юк, кемгә ярый.

Хәлимнең авызы колакларына җитте. Ул ни дип тә әйтергә өлгермәде, арттагы вагоннар янында свисток

бирделәр. Поезд кыска гына кычкыртып куйды. Вагоннар бер-бер артлы шалдыр-шолдыр кузгала башладылар. Кызылармеецлар тәмам каушап калган Хәлимне вагонга тартып менгерделәр.

Поезд станциядән чыгуга, вагон ишекләре ябылды. Шунда ук бер кызылармеец зур чиләкләрдән котелокларга аш бүләргә кереште. Икенчесе зур-зур телем итеп ипиләр кисеп куйды.

— Ашыйсыңмы, малай?

— Нинди малай булсын ди ул! Гармончы — значит, егет. Сал гармоньчы егеткә куерагын... Ипинең дә зуррагын куй. Аннан соң ул безгә китәр...

Хәлим, ач дип белмәсеннәр өчен, башта комсызланмый гына, әдәп белән генә ашады, ләкин бик тиз онытылып, кызып китте. Итек кунычында ни гомер эшсез яткан зур өрәңге кашык хәзер котелок белән авыз арасында күз иярмәс тизлек белән йөри иде.

Ашап туйгач, Хәлим гармонен сузып җибәрде. Иртәгесен дә, көндез дә, кич тә... Казан инде әллә кайда калды. Кызылармеецлар хәзер күбрәк Мәскәү турында сөйләшә башладылар.

Ләкин Хәлим Мәскәүгә барып җитә алмады...

16 ДЕРЖИ, СЫНОК!

Паровоз озын сузып кычкыртты. Вагон тәгәрмәчләрен тормозлар кысты. Эшелон туктый башлады.

— Станца-а!

Берсе шаяртып куйды:

— Тезелеп киткән без конца!..

Паровоз, аның артыннан яшел вагоннар, дөбердәшеп, станциягә барып керделәр.

— Озак торамы, иптәш командир?

— Әз тора, төшмәгез.

— Төшмәгез, әй! Төшмәскә ди!

— Төшмәскә-ә!..

Чыгып, бераз саф һава сулап керү турында уйлап килгән кызылармеецлар тамбурдан борылып керергә өлгермәделәр, сирена улый башлады. Шунда ук берничә җирдә өлгер зениткалар телгә килде.

— Тревога!..

Хәлим бу сүзне узган станцияләрдә дә ишеткәләгән иде. Анда да, шулай, эчпошыргыч итеп сирена улаган

иде. Анда да берничә тапкыр аткалап куйганнар иде. Шуңа күрә, Хәлимнең бу сүзләргә хәзер әллә ни исе китмәде. Җылы вагон, куе тәмәке төтене, селедка исе аны тәмам изрәткән һәм ул йоклап китү алдында иде инде.

Ләкин ату биредә узган станцияләрдәге шикелле генә булмады. Нәрсәдер, әкиятләрдәге дию пәрие шикелле, бик тиз, бик каты сызгырып узды. Нәрсәдер җиргә төшеп гөрселдәде. Тагын гөрселдәде. Монысында вагон тәрәзәләре челпәрәмә килеп коелды, вагон стеналары дерелдәп куйды һәм ниндидер көч Хәлимне сәндерәдән кызылармеецлар өстенә алып бәрде.

— Һава-а!.. Төшәргә!..

— Төшәргә, ди, әй-й!..

Хәлимнең, сугыш башыннан бирле телендә йөртеп, ниһаять, үз колагы белән ишетә алганы — бомбежка иде бу. Хәлим өчен аның беренче секундлары, әлбәттә, кызык тоелды. Ә кызылармеецлар өстенә очып килеп төшкәч, аларның бәрелеп-сугылып йөри башлаганнарын күргәч, әнә теге, юл буе төрле уен-көлке сөйләп, бөтен вагонны көлдереп килгән кешенең дә йөзе агарып киткәч, малай хәлнең җитди икәнен аңлады.

— Һава-а! Төшәргә-ә!

Кызылармеецлар ишеккә ташландылар. Хәлим дә, сәндерәдән үзе белән бергә очып төшкән котомкасын култыгына кыстырып, кайсының култык астыннан, кайсының аяк араларыннан үтеп чыгып ишеккә килде. Һәм арттан килгән солдатлар белән этелеп, вагон баскычларына аягы да тимичә, каралып бозланган җиргә егылып төште.

— Ки котомканны! Йөгер!..

Хәлим, каушый-каушый, котомкасын киде.

Ә кая йөгерергә?

Хәлим күтәрелеп караганда, аңар йөгерергә кушкан солдат юк иде инде. Хәлим каушап, нишләргә белмичә, бер тын аптырап торды.

Зур станция иде бу. Һәр якта поездлар тезелешеп тора. Бертуктаусыз паровозлар кычкырта. Тавышлары башка станцияләрдәге шикелле тыныч түгел: ниндидер шомлы, куркыныч, елак... Әнә бик зур паровоз. Ул калын тавышлы, батыр кычкыра. Гүя башка паровозлар моның балалары һәм ул аларга курыкмаска әйтә.. Ләкин паровозлар тынмыйлар:

— Уу!

— Ууу!

— Уууу!

Караңгы, яныннан кем узып киткәнне дә аерырлык түгел. Алты-җиде урыннан һавага нечкә озын ут көлтәләре бәркелә. Көлтәләр һавада югалуга, шартлаган тавышлар ишетелә. Бу — зениткалар. Алар станция өстенә житеп килгән дошман самолетларына аталар. Самолетлар үзләре күренми, тик ямьсез үкерүләре генә ишетелеп тора. Менә самолет тавышлары бик якыная. Хәлим аларның барысын бер ноктада, үзенең баш очында шикелле итеп тоя.

Малай һавадан самолетларны эзли, ләкин анда һичнәрсә күренми. Самолетлар улавы ерагая. Кешеләрнең, хафаланып, әрле-бирле йөгергәннәре ачыграк ишетелә башлый. Сүнгән фонарь тоткан берәү, зур паровозга таба йөгерә.

— Топканны томала!— ди ул. Аннары, ялгызы пышпыш сулап торган паровозга таба борылып кычкыра:— Томала топканны! Нәрсә син, дөньяга бүген килдеңме әллә?!

Әнә Хәлимне вагонга чакырып керткән командир. Ул рельска баскан да, атыш тавышлары аша ишетелсен өчен каты кычкырып, кызылармеецларга төрле приказлар биреп тора. Юл буе вагоннан-вагонга кереп йөри-йөри бик тирләгән иде ул. Көн салкын булуга карамастан, бүреген салып кулына тоткан. Зенитка утлары җемелдәп куйганда җилгә тузгыган саргылт чәчләре, авызыннан чыккан булары күренеп кала.

Кызылармеецлар, аның әмеренә буйсынып, кайсы кайда йөгерәләр, нәрсәләрдер күтәреп чабалар, кемнедер орышалар, үзара әйткәләшеп тә алалар.

Кая йөгерәләр соң алар, кемне орышалар, нәрсә ташыйлар? Хәлимнең дә алар шикелле хафаланасы, алар шикелле йөгерәсе килә, кемне булса да орышасы килә. Ә кемне орышырга, нәрсә ташырга, кая йөгерергә?

Менә тагын әкияттәге дию пәрие шикелле итеп һавада нидер улый башлады. Улау бик тиз көчәеп, колак барабаннарына хәтле дерелдәтергә тотынды. Хәлим яныннан узып барган берәү аның җилкәсеннән тотып аска иде.

— Ят, малай актыгы! — диде ул.

Хәлим карышып, яки ятаргамы-ятмаскамы дип уйланып торырга ярамаганны аңлады. Ул, тиз генә җиргә

сыенып, башын рельска терәде. Хәлимне вагон сәндерәсеннән очырып төшергәндәге кебек көчле шартлау тагы ишетелде.

Хәлим солдат булырга йөрсә дә, бала иде шул әле. Ул, башын күтәреп, күзләрен як-якка йөртеп алды:

«Бу бомба инде, ә!.. Әй, төшкәнең карап торырга»,— диде ул. Ятарга әмер биргән кеше Хәлимнең башына сукты. Тимер белән диярсең, шундый каты төшерде. Хәлим бер сүз дә әйтмәде.— «Шулай кирәктер инде...» дип, башын яңадан салкын рельска терәде.

Ул да түгел, Хәлимгә ятарга кушкан кеше:

— Тор! — диде. Үзе ялт сикереп торды да, гомеренә вагон асларыннан чыкмый йөргән кеше шикелле оста хәрәкәт итеп, бер товарный вагон астына кереп китте. Хәлим аның артыннан ташланды. Кеше вагон астыннан чыкты да янәшә юлда торган икенче вагон астына керде, аннан өченчесенә, дүртенчесенә... Хәлим аның артыннан җитә алмады, күзеннән югалтты.— «Очы-кырые бармы соң бу вагоннарның?»

Ниһаять, ул ачыклыкка килеп чыкты. Аның алдында вагоннар юк, бары тик тау чаклы зур кара бер бина гына калкып тора иде. Вокзалдыр... Хәлим шунда йөгерергә дип торганда, аркасына ниндидер каты әйбер килеп бәрелде. Носилка тоткасы икән...

— Кит юлдан, малай!..

Хәлим бер якка тайпылды.

Носилканың ике башыннан ике кеше тоткан, анда бер кызылармеец булып, бик каты сызланып ята иде.

Хәлим аны кызганды: «Яраланган...» — һәм үзен күрәсе килеп, носилкага таба бара башлады. Ләкин арттан килгән икенче бер носилка тоткасы Хәлимне төртеп екты. Кемдер аның өстеннән атлап чыгып китте.

Ул да түгел, зениткалар тагын телгә килделәр. Һавада бер-бер артлы берничә урында нечкә, озынча ут көлтәләре күренеп китте. Гөрселдәү тагы ишетелде. Хәлим җиргә ятарга өлгермәде, тик башын иеп күзләрен йомды. Менә аның битенә җылы һава килеп бәрелде. Ә күзләрен ачып карауга, дәһшәтле гөрселдәү ишетелгән якта кибән кадәр ут күтәрелгән, тирә-як тәмам яктырып киткән иде.

Хәлим янына сырган пиджак, сырган чалбар кигән ике хатын-кыз йөгереп узды:

— Тидерде, ләгънәт!

— Тидерде...

— Ах, баш-шы беткере!

— Санпоездга бит.

— Ну, харап итте инде, алайса...

— Исән калган вагоннарын алып китсеннәр иде, ичмаса...

— Ә юл? Җиденче стрелканы каерып ташлаган дим ич мин сиңа.

— Ах, баш-шы беткере!..

Хәлим ут кибәненә таба йөгерде. Кибән бик тиз кечерәйде. Ул хәзер, авылда җилсез караңгы кичләрдә янып утырган мунча шикелле, тыныч кына яна, чатнавы ишетелми иде. Якынрак килгәч, Хәлим янгын тирәсендә кешеләр күрде. Теге хатыннар белеп әйткән икән: бер-бер артлы тезелеп киткән яшел вагоннарның стеналарында зур-зур кызыл тәреләр күренә, ә бер вагонның бер башы яна, икенче ягыннан һәм янмый торган вагоннардан носилкалар белән яралы кешеләрне ташый иделәр.

Яралыларны вагоннардан алып чыгалар да җиргә куялар, һәм икенчеләрен алырга кереп китәләр. Яралыларның кайберләре носилкаларыннан торып, култык таякларына таянып, Хәлим килгән якка таба китеп баралар. Мондыйлар аз, күбрәге сызланып, носилкаларында ята бирәләр.

— Тизрәк алып китегез,— ди аларның берсе күккә ишарәләп.— Тагы килә ул монда. Әнә, элеп куйды инде...

Хәлим күтәрелеп күккә карады. Күк йөзе шундый матур, аннан җиргә үлем яуганга һич кенә дә ышанырлык түгел иде. Йолдызлы зәңгәр күк фонында, әллә ничә урында, бик матур булып, әкрен генә чайкалып, кызыл, сары утлар әлгеп тора иде. Хәлим, бомбежка икәнен дә, куркыныч икәнен дә, яралыларны да онытып, шул утларга сокланып карап торды.

— Әй, малайларны алып килеп күрсәтергә...— диде Хәлим, ләкин шул чакта яралыларның ыңгырашкан, сызланганнарын ишетеп, күзләрен санпоездга төшерде.

Санитарларның аяк-куллары урынында, әйтерсең, ниндидер җитез машиналар — шулай тиз хәрәкәт итәләр, шулай да өлгерә алмыйлар, вагоннардан носилка күтәреп чыккан саен: — «Әй, кем бар анда, ярдәм итегез!» — дип кычкыра иделәр.

«Ә ничек ярдәм итәргә?» — Хәлим, каушый-каушый бер носилканың ике токасына ябышты. Ялгыз күтәреп булмый, әлбәттә. Носилкадагы кеше «өстерә генә, өстерә-

гез, булмаса», дип өзгәләнә башлады. Хәлим өстерәргә дип торганда носилканың икенче башы күтәрелеп китте.

— Держи, сынок! — диде носилканы күтәргән кеше. Бу — бөрмәле каеры тун кигән, шакмаклы калын шәл бәйләгән бер әби иде. Ул тагын нәрсәдер әйтте. Хәлим аңлап бетермәде. «Тизрәк» дигәндер инде, әнә тагын самолетлар улый башлады бит...

Хәлим белән әби носилканы куеп ял итә-итә бардылар. Әллә инде унлап поезд юлын аркылы чыктылар алар. Алда ап-ак кар ябынган кыр җәелеп ята иде. Хәлимнәр шунда чыгып, тар сукмак буенча бара башладылар. Бераз баргач, аларны шулай ук носилка күтәргән таза-таза ике кеше узып китте:

— Тизрәк, тизрәк,— диделәр алар.

Әби аларга сукранып нидер әйтеп калды. Ә тегеләр әз генә бардылар да, носилкаларын уйсу җиргә куеп, киредән станциягә таба йөгерделәр. Уйсу җирдә тагы берничә носилка булып, кызыл тәреле сумка кигән яшь кенә бер кыз аларның берсеннән-берсенә чабып йөри иде. Хәлим белән әби дә носилкаларын шунда китереп куйдылар. Әби носилкадагы кешенең өстенә иелеп, русчалап, нидер сорады. Яралы кеше, зәгыйфь тавыш белән, нидиптер җавап кайтарды. Хәлим кызылармеецның кай җире яраланган икәнен беләсе килеп, баш очына тезләнде. Бәлкем, ул аның өстендәге шинелен, одеялын да ачып карарга батырчылык иткән булыр иде, әби ашыктырды:

— Пошли, пошли, сынок! — диде әби һәм, уңын атлаганда уңга, сулын атлаганда сулга янтаеп, башлары кәкрәеп килгән зур соры итекләре белән карга шыгыршагыр басып, ашыга-ашыга китеп барды.

Хәлим әз генә икеләнеп торды да аның артыннан йөгерде.

Бу әби белән ул тагы бер яралыны кырга чыгарып куйды. Монысы шактый җинел иде. Кире борылып станциягә кайтканда, әби аның ике аягы да өзелгән икәнен аңлатып, үзенең ике бот төбен дә кулы белән кискән шикелле итеп күрсәтте.

Хәлим бу вакытта арыган иде инде. Ул рельсларга аз гына сөртенеп киткәндә дә егыла язып калды. Ләкин, ай, нинди зур эш эшли бит алар. Яралы солдатларны кабат яраланудан, ә бәлки үлемнән коткаралар... Хәлим.

аруы турында онытырга теләп, өченче бер носилканың сапларына тотынды.

Әби елмаеп:

— Силен паренек,— диде һәм үзе дә носилканы күтәреп алды.

— Айда, милый!

Алар тагын рельслар аша кырга таба атладылар. Ә һавада самолет тавышы тынмады. Хәлим беренче баруында, аларны күрәсе килеп, күккә карый-карый барган иде, хәзер әллә ни исе китмәде. Бигрәк күңел кайтаргыч уладылар шул. Ә берсе алай каты уламады. Анысы бик якын, бөтенләй баш очыннан гына очып китте. Хәлим аның катлаулы молотилка коры бодай көлтәсен чәйнәгән кебек тавышын ишетте, хәтта җилен дә сизгән шикелле булды.

Менә тагы берсе. Монысы, фчт-фчт итеп, сәер сызгырып узды. Анысы нәрсә икән? Әби нидер әйтә-әйтә ашыга башлады. Хәлим дә аның артыннан өстерәлде. Алар инде вокзал артына чыктылар. Әнә тагы бер самолет. Монысы Хәлимнәрне махсус эзләп йөри диярсең, туптуры килә һәм бик яман улый иде. Бу да фчт-фчт итеп узып китте. Китте дә тагы әйләнеп килде.

Фчт-фчт-фчт...

Менә носилканың алды, әби күтәргән башы, төшеп китте. Әби әкрен генә җиргә тезләнде. Сөртенде дип уйлады Хәлим һәм, носилкасының үз башын да җиргә куеп, әбинең торганын көтте. Ләкин әби тормады. Хәлим, аның янына килеп, күзләренә карады. Әбинең күзләре йомылган, гәүдәсе хәрәкәтсез иде.

— Әби, әби!..

Әби җавап бирмәде. Менә аның шакмаклы калын шәле астыннан кан килеп чыгып, чигәсе буенча ага башлады.

— Абау, әби үлгән ич!.. Әби үлгән! — дип кычкырып җибәрде Хәлим. Бу — Хәлимнең кеше үлгәнне гомерендә беренче тапкыр күрүе иде. Аңар яман да куркыныч булып китте.

Ул, еларга җитеп:

— Нишләтик инде аны, абый? — дип, носилкадагы солдатка эндәште, солдат җавап бирмәде.

— Әллә инде монысы да?..— Юк, солдат исән иде, әнә ул сызланып куйды.

— Әй, әби, әби, сине кешеләр, бомбежкадан куркып качып барганда үлгән дип уйлар инде. Әй, әби, әби!..

Хәлим әбинең, беришди мәҗбүр итүсез, үз тормышын куркыныч астына куеп, өч кызылармеецны кабат яраланудан, ә бәлки үлемнән алып калган әбинең, әле суынып та өлгермәгән кулларын носилкадан ала башлады. Хәлим аның кулларын әкрен генә алырга тырышты, ләкин куллар носилканы нык кысып тоткан иделәр. Хәлим аларны каерып ычкындырды. Куллары носилкадан ычкынгач, әби йөзтүбән авып төште. Хәлим аны, кеше икәнен күрсеннәр, таптап китмәсеннәр дип, чалкан яткырды. Мескен, мескен!.. Бәлкем, ул да, Хәлим шикелле, тревога булгач берәр поездлан төшкәндер. Аны, бәлкем, өендә «әби, тиз кайт, мәми алып кайт»,— дип, кечкенә кызы көтеп калгандыр... Хәзер кечкенә кыз, тәрәзәләренең бозын сулышы белән эретә-эретә, әбисенең кайтыр юлына карап көтә торгандыр...

17 ӘТИ ТӨСЛЕ СОЛДАТ

Самолет тагын очып килде, тагын фчт-фчт итте. Инде Хәлим бу фчт-фчтның үлем икәнен аңлый иде. Ул, әбине калдырып, каушый-каушый носилканы өстерәргә керешге. Биредә станциядәге шикелле түгел, кар ап-ак, сукмак таптала-таптала шомарып беткән иде. Шулай да носилканы өстерәп бару Хәлим өчен бик читен булды. Ул, унбиш-егерме адым китүгә, тирләп чыкты. Котомкасын иңнәреннән алып, кызылармеецның аяк очына куйды, пиджагын салып, аның өстенә япты. Аннары тагын өстерәргә тотынды.

— Ә баягы носилкалар кайда соң? Нигә юлда бер кеше дә очрамый?

Хәлим үзенең ялгыш сукмакка кереп киткәнен аңлап алды. Ләкин зарар юк. Әнә урман. Анда ук җитеп булмас булуын. Ә менә бу юан чыршы төбенә җитәргә кирәк... Хәлим, актык көчен салып, носилканы шунда өстерәде. Бер этеп, бер өстерәп байтак газап чиккәннән соң чыршы төбенә килеп җитте һәм, тәмам хәле бетеп, карга егылды. Ә бераз сулу алгач, тезләре белән атлап, яралының баш очына килде. Яралы әле һаман бер гамьсез йоклый иде.

Биредә тыныч. Самолет тавышлары алай бик якын ишетелми, карангы да. Станциядәге кебек куркыныч

түгел. Ләкин суык. Яралы туңар. Хәле бик авыр булса кирәк, кузгалып та карамады, мескен. Ничек итеп җылытырга икән үзен? Эх, учак ягып җибәрергә... ярамас шул...

Хәлим чыршы кәүсәсе буйлап өскә үрмәләде. Аннан ул бик күп итеп ылыс сындырып төшеп, чыршы төбенә өеп куйды да носилканы шуның өстенә өстерәп менгерде. Тагы чыршы башына менеп, ылыслар өзде. Боларын яралының өстенә япты. Һәм үзе туңмас өчен носилка әйләнәли тиз-тиз йөрергә тотынды. Ләкин 1941 ел декабренең рәхимсез җиле юка чалбар, җылы фуфайка аркылы бик тиз үтеп керде. Хәлим шулай да шат иде. Ул, хәтта, үзенең юлы өзелүгә дә әллә ни борчылмады. «Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең?» дип, райком плакатындагы түгел, ә чын кызылармеец сораса да, хәзер Хәлим аның күзенә туры карап җавап бирә алыр иде.

Хәлим, үзенең файдалы эш эшләгәненә шатланып, әрле-бирле йөрде-йөрде дә, йодрыклангаи кулларын күкрәк турысында тотып, бер урында йөгереп торды.

— Бар да яхшы. Хәзер җылынам мин. Ә менә бүремазар килеп чыкса? Үзем агачка менеп кача алырмын. Ә бу абзый?.. Юк, аны ташлап качаммы соң?..

Хәлим яңадан чыршыга үрмәләп тирә-якны күзәтте. Ап-ак кыр. Бер якта бик кара урман... Урман шаулый кебек. Юк, урман шауламый, бүреләр улый кебек. Алар Хәлимнең һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торалар, менә хәзер утлы күмер төсле күзләрен ялтыратып, урманнан атылып килеп чыгарлар кебек...

Хәлим, теге уртак пәке белән киртли-киртли, шактый юан бер агач сындырып алып төште дә чыршыга поскан хәлдә урманга карап, беравык тыңлап торды. Һәм үзеннән-үзе оялып китте. Әнә анда, станция өстендә нинди ут өермәсе! Шундый утка каршы бүре киләмс соң! Бүре бит ул очкын күрсә дә... Хәлим, тынычланып, таягы белән бер ылысны кәшәкә таяк уйнагандагы шикелле сугып йөртә башлады.

Шул чак кызылармеец, авыр сызланып, уянып китте:

— Пить...

Хәлим аның баш очына йөгереп килде.

— Пить! — диде кызылармеец һәм иренеп чапылдатып куйды. Хәлим тиз генә флягасының пробкасын алып, суык суны кызылармеецның иреннәренә китерде. Кызыл-

армеец ике-өч йотты да күзләрен ачып карады. Ак, йөнтәс куллары белән Хәлимнең аркасыннан сөеп куйды.

— Где это мы, парень?

Хәлим сорауны аңлады, ләкин җавап бирә алмады. Эх, менә хәзер шушы кызылармеец белән бер рәхәтләнеп сөйләшү өчен генә дә рус телен бик яхшы итеп өйрәнер иде ул...

Хәлим җавап бирмәгәч, кызылармеец татарча эндәште:

— Татар малаемы әллә син?

Хәлим кызылармеецның битенә якын иелеп, күзләренә карады.

— Әти төсле солдат,— диде Хәлим беренче каравында, һәм аның маңгаендагы эзне — колхоз төзү елларының истәлеге булган зур җөйне күреп артына чигенде дә, ике яңагын тотып, елап җибәрде.

— Абау... Әти ич син... Минем әти! — диде ул һәм өстенә ташланырга омтылды. Әмма ярасын авырттырудан куркып, туктап калды.

Кызылармеец башын күтәрде. Ул әсәрләнеп Хәлимгә карады.

— Әти! Танымыйсыңмы әллә? Мин — Хәлим, синең улың...

— Саташам, ахры,— диде яралы һәм башын яңадан мендәренә куйды.— Мин кайда?

— Юк, әти, син саташмыйсың. Мин — Хәлим. Хәлим мин, әти. Кай җирең ранный булды, әти?

Яралы тагын башын күтәрде. Әз генә елмайды да шикелле. Аннары күзләрен йомып, башын яңадан мендәренә салды. «Әй дөнья...» диде ул. Хәлим аны хәзер үзе белән сөйләшә башлар дип уйлады. Ләкин яралы сөйләшмәде. Бераз ятты да саташа башлады:

— ...Тимә, тимә, якынрак килсен. Тагын бераз килсен... Инде ат! Менә шулай... Аңысы да килсен! Килсен, кабахәт... Инде ат. Ат!.. Ат!..

Хәлим, яралының әле бер, әле икенче ягына чыгып, кабаланып йөрде. Әле флягасының пробкасын алып, аның иреннәренә китерде, әле өстенә яхшылабрак япты. Җил каты килеп бәрелгәндә, гәүдәсе белән аны ышыклап торды.

— Әти, сөйләш әле, әти!

Яралы сөйләшмәде. Ул һаман да саташа, кемнәрнедер атакага өнди иде:

— За мно-ой!..

Хәлим нишләргә белмичә газапланып, йодрыгын тешләде.

— Нишләтим соң мин сине, эти? Үлмәссең микән, эти?.. Ай, яраң бик катыдыр, ахры...

Этисе жавап бирмәгәч, Хәлим як-ягына каранып алды да, таягын ни өчендер анын өстенә куеп, тиз генә станциягә таба йөгерде.

Җилгәндә бик ерак шикелле тоелган иде, алай ук түгел икән, ике-өч минуттан малай станциягә килеп керде.

Зениткалар туктаган иде инде. Станция өстендә самолетлар да уламый. Ялгыз паровозлар әрле-бирле чабышып, маневр ясап йөриләр. Баягыча түгел, кыска-кыска гына кычкырып куялар паровозлар. Ә теге батыр тавышлы бик зур паровоз, озын бер эшелон өстерәп, кара төтеннәрен бөркеп, каядыр китеп бара. Менә сирена кычкыртырга тотынды. Ә радио берничә сүз әйтүгә перронда кешеләр күренә башлады. Озак та үтмәде, зур станцияләрдә була торган ыгы-зыгы башланып китте.

— Чәнчелдергәннәр үзләрен дә. Поскып яталар,— диде Хәлим янында узып баручы өч кызылармеецның берсе.— Пилотлары парашют белән сикергән булган икән, аларын да эләктергәннәр.

Хәлим кызылармеецлардан санпоездны сорашты.

Кызылармеецлар караңгылыкка төртеп күрсәттеләр дә китеп бардылар:

— Бишенче путьта.

Хәлим шунда таба йөгерде һәм бик тиз товар вагоннарына таба носилка күтәреп барган ике санитарны куып җитте.

— Санпоезд шушымы, абый?

— Сиңа нигә ул?

— Тегендә бер яралы бар, абый. Минем эти. Бик тә авыр ята...

— Кызылармеец түгелмени?

Хәлим носилкадан калышмыйча йөгергән хәлдә җавап бирде:

— Юк, кызылармеец. Атыш башлангач, без аны бер әби белән илтеп куйган идек. Яна торган поездан төшергәннәр иде аны.

— Фамилиясе ничек?

— Зиннәт... Арсланов Зиннәт.
— Ә?
— Арсланов Зиннәт.

Санитарның йөзе яктырып китте. Ул алдан барган иптәшенә эндәште:

— Слышь, Арсланов нашелся!
— Да ну?

Санитарлар тагы да кызурак атлый башладылар. Алар кулларындагы носилканы тиз генә вагонга менгереп төштеләр.

— Арсланов кайда, егет?
— Әйдә, үзем алып барам.
— Значит, син безнең замполит улы? Әйбәт, әйбәт... Ә син ничек монда?.. Ә орденнарын күрдеңме әле этиеңнең? Икәү, ике орден, төшендеңме?
— Икә-әү... Ай-ай.
— Икәү шул. Аңар тагын бирсәң дә не жалко. Ләкин, аягын гына... Бу, сугышта ансыз булмый шул инде. Җитәбезме әле?
— Әнә генә...

Әйе, Хәлимнәр коткарган яралы — Хәлимнең этисе — Зиннәт Арсланов булып чыкты. Каны бик күп аккан ахрысы, чырае көл төсле ак, яңаклары батып кергән, куллары тире дә сөяк кенә иде. Ул бары вагонга алып кереп салгач кына саташудан туктады.

Бирсдә якты һәм жылы иде. Санитарлар аның өстен ачып, ашыгыч бәйләнгән повязкаларын чишә башладылар, дарулар алып килделәр.

— Ә син елама, егет. Әтиеңне хәзер терелтәбез аны...

Менә Зиннәт абзый сискәнеп күзләрен ачты. Башын күтәреп карады.

— Хәлим? — диде ул, бу юлы танып.
— Мин, мин, эти!..
— Син бугай шул... Ләкин бер дә ышанасым килми... Ә, юк, ышандым инде,— диде ул. Аның күзләренә бераз жан керде. Әллә артык дулкынланудан тире астындагы барлы-юклы каны тибешрәк йөри башлады, әллә тимер мичнен ут шәүләсе төште — йөзенә кызыллык җәелде. Зиннәт абзый, бума авырулы кешедәй сүз саен туктап хәл алып, сорау бирде:

— Ә син... ничек... бирсдә?
— Мин, эти...

Хәлим бу сорауны көткән иде. Һәм аңарда җавап та әзер иде инде: «Авылдан рәмесленнигә дип җибәргәннәр иде дә, йоклап Казанны узып киткәнмен...»

Хәлим әтисенә шулай димәкче булды. Ләкин бу минутта ул әтисен чиксез ярату белән ярата иде. Беркайчан да булмаганча якын иде әтисе аңар бу минутта. Ялганларга теле бармады, дөресен сөйләп бирде. Барысын да сөйләде ул. Аның сүзләрен бер татар солдаты русларга тәрҗемә итеп торды. Яралы кызылармеецлар Хәлимнең бөтен юл маҗараларын, елмаеп, кайбер урында ай-яй диешеп тыңлап тордылар.

— Да...— диде Зиннәт абзый Хәлим сөйләп бетергәч,— да-а...

Хәлим артка чигенеп куйды. Яхшыга түгел бу. Бик каты ачуы чыкканда гына әйтә иде Хәлимнең әтисе бу «да»ны...

— Да... вредитель син, больше ничего! — ди иде ул, усаллык беләнме, гамьсезлеге беләнме колхозга берәр зыян-зәүрәт китергән колхозчыга.

— Да... кил әле монда! Төшер әле штаныңны! — ди иде ул Хәлим берәрсенең авыз-борынын җимереп яки үзенекен җимертеп кайтса, яки башка берәр усаллык эшләсә.

Әгәр хәзер дә шулай дисә? Ой, ой... Хәлим тагын чигенә төште, әтисе аның нәрсәдән курыккаиын аңлады бугай, елмайды:

— Тимим, тимим... Я, кил инде...

Ата кызышкан кулы белән улының салкынча яңагын сыйпады, аның күзләрендә яшь иде.

18 МЕНӘ БӘХЕТ!

Таң атып килгәндә, санпоезд ерактан күренеп торган тау битендәге кечерәк кенә бер шәһәр читенә килеп туктады.

Зиннәт абзыйны шул шәһәрдәге госпитальгә салдылар. Поездда килгәндә ул кабат аның җуюдан, шул арада Хәлимнең, төшеп калып, яңадан фронт ягына китеп баруыннан курыккан иде. Хәлимнең гайрәтен чигерү өчен, сугышның дәһшәтләре турында, анда үлемнең күзгә күренеп йөрүе турында, үзенең әле менә кояш баеганда гына сау-сәламәт кеше булып, күз ачып йомганчы шушы хәлгә килүе турында сөйләп барган иде. Госпи-

тальдә сестралар ярасын бәйләп, жылы, якты бүлмәгә, йомшак урынга кертеп салгач та, Хәлимне үз янына чакыртып алып, поездда башлаган сүзен дәвам итте. Ә инде, Хәлимнең фронтка китү дәртен сүзләр беләп генә сүрә алмагач, үз яныннан җибәрмәү чарасына керешге. Ул госпиталь начальнигыннан Хәлимне, ничек кенә булса да, үз янында калдырып торырга рөхсәт сорады. Начальник риза булды.

— Ләкин берәр мавыктыргыч эш таба күрегез сез аңар, иптәш майор,— диде Зиннәт абзый.— Юкса, бирелә тормас ул... Атка бик хирес. Ат җигеп йөри торган эш булмасмы икән?

— Булыр,— диде начальник.— Ашханәгә ипи-күмәч ташыр, базага йөрер...

Шул көннән башлап Хәлим төшендә дә күрмәгән, башына да килмәгән кызыклы тормыш эченә кереп китте. Ул госпитальдә хезмәт итүче солдатлар белән бергә ишек алдындагы кечкенә өйдә тора башлады. Алар белән бергә ятты, бергә торды. Кичләрен, ашап-эчеп яки шашка, шахмат уйнап утырганда берәр командир килеп керсә, солдатлар белән бергә ул да сикереп торып смирно басты.

Ишек янагында тар гына озынча кәгазь бар. Шушы өйдә торучы солдатларның исемнәре язылган. Хәлимнең дә фамилиясен шунда язып куйдылар. Хәлим үз фамилиясеннән күзләрен алмады. Исемлекне көндез дә, эшен ташлап, әллә ничә тапкыр кереп карап чыга, хәрефләрен сөртеп тора иде.— «Тора бит... Бозмаганнар...» Көннәрдән беркөн, петлицаларына икешәр өчпочмак таккан командир кереп исемлеккә күз төшереп алды да:

— Арсланов, иртәгә син дежурный,— диде.

Хәлим шатлыгыннан кая барып бәрелергә белмәде. Әтисе яныннан әле генә төшкән иде, тагын йөгереп менде.— «Әти, мин иртәгә дежурный булам, әти!..» — Хәлим төнлә уянган саен шул турыда уйланып ятты.

— Ялгыш ишетмәдем бугай ла, Арсланов диде бит... Теге көн тишлы хәнҗәрне дә тактырырлар микән?.. Ух, менә сиңа, ә?!

Хәлим һәр көн таннан торып ат җикте. Госпиталь ашханәсендә эшләүче бер хатын белән пекарняга барып, чана тутырып ипи-күмәч алып кайтты. Яки базадан продукт ташыды. Кайткач атны үзе тугарды, үзе карады.

Чыгып шәһәр карап йөрде. Госпиталь каршысында гына революция музее бар. Бүген, терелеп килә торган солдатларга ияреп, шунда экскурсиягә кереп чыкты. Аннары, үзе турында, әтисе турында, әтисе белән ничек очрашуы турында әйтеп, әнисенә хат язды. Ләкин үзенең шәһәрдә, госпитальдә икәнен малайларга әйтмәскә кушты.

— Һәй-й... барып-барып сугышның эчендә йөрмәгәч, диюләре бар... Шурләгән, диюләре бар...

Хәлим госпитальдә татып бер бәхеткә тап булды. Рус теленә хирес иде ул, ә колхозда аны әйбәтләп өйрәнергә мөмкинлек юк, бөтенесе татарлар, районнан да гел татар вәкилләре генә килә иде. Рус теле укытучысы, әле үзе дә яңа гына курс тәмамлап кайткан апа, дәрескә бик сирәк керә, анда да, кайбер сүзне русча ничек була дип сорасаң, ниндидер калын китапка карамыйча әйтә алмый торган иде. Ә инде райбашкарма комитеты председателе Иван дәдә, колхозга килеп чыгып, Хәлимнең әтисе белән чәйгә кайтса, ул көнне Хәлимгә бәйрәм була иде. Хәлим әтисенең Иван дәдә белән сөйләшкәннәрен кече якта тыңлап утыра, күңелснә аеруча ошаган сүзләрне язып бара, Иван дәдә киткәч, әтисеннән сораша, ә мәктәпкә баргач, иптәшләренә сөйләп мактана иде. Ләкин айга-елга бер була иде андый бәйрәм авылда. Ә биредә көн саен!.. Бөтенесе диярлек руслар ич!

Хәлим рус теленә ике куллап ябышты. Аны өйрәнүдә малайга госпиталь повары Алексей дәдә күп ярдәм итте. Хәлим аның янына көн саен пекарнядан кайткач та керә, чандыр, озын буйлы, шат йөзле повар аны һәрвакыт көлемсерәп каршы ала иде. Ул, Хәлимнең рус теле белән мавыкканын күргәч, кухнядагы һәм ишек алдындагы әйберләргә тәрәзә аша күрсәтеп, русча исемнәрен әйтте:

— Нож,— диде ул, кайрый-кайрый йөзе тараеп, югарып беткән пычакны күрсәтеп. Аннары киң йөзле балтаны алды,— монысы топор.— Ишек алдын себереп йөрүче бабайны күрсәтте — работник.

— Мин аларны беләм.

— Беләсең? Менә молодец! — Повар күршедәге зур заводның тәрәзәдән күренеп торган бер корпусына төртеп күрсәтте: — завод.

— Анысын да беләм, татарски да завод.

— Ах, шулаймыни!.. Ул чагында менә нәрсә эшлик без синең белән...

Повар шул ук көнне Хәлимгә бик матур, бик күп рәсемле русча китап алып кайтып бирде һәм аркасыннан сөеп әйтте:

— Мә, Халимушка, укы.

Повар Хәлимгә ябышып ятты. Тырышып-тырышып аны үз янына ияләштерде. Буш вакытларында аңар үзе турында, сугыш турында сөйләде. Хәлим белмәгән сүзләрне кул хәрәкәтләре, мимика белән аңлатты.

— ...Безнең шәһәр границага якын иде. Сугышның беренче атнасында ук немецлар яндырып, җир белән тигезләп киттеләр. Бер кирпече дә исән калмады, иптәш. Әти-әнием дә шул вакытта һәлак булды. Улым бар иде минем, Ваня исемле. Синең шикелле матур иде. Аның да кашлары шулай бераз бөдрәләнеп тора иде. Өстенә яндыргыч бомба ташлап үтерделәр. Ә хатынымны кол итеп Германиягә алып киттеләр... Немецта минем үчем синеке ише генә түгел. Кулым шундый булмаса, мин...

Повар Хәлимгә ике бармагы киселгән сул кулын күрсәтте һәм, йөрәк ярасын басарга теләгәндәй кабаланып, газета-журналлар алып, кызыл почмакка менеп китте.

— Син укый тор, Халимушка. Мин сестралар белән политбеседа уздырып төшим.

— Я инде, шундый яхшы кешене ничек үз күрмәссең? — Хәлим поварга бик тиз иявәште.

Ә бер тапкыр, инде Хәлимнең үзенә тәмам ияләнеп җиткәнен күргәч, повар аңар шундый тәкъдим ясады:

— Син болай ит: миңа ярдәмче булып кер. Мин сине менә дигән повар итәм. Теләмисең? Юкка. Ә син беләсеңме, сине гел болай йөртмәсләр бит. Әтиең терелеп чыгу белән, әйдә пошел авылыңа! Әйе, әйе. Ә минем янда калсаң, сиңа беркем тимәс. Обмундирование бирерләр. Приказ буенча кызылармеец итеп үткәрерләр.

Хәлим повардан үзенең ниятен яшермәде:

— Фронтка китәсем килә бит минем, Алексей дәдә.

— Фронтка китәсең килә?

Повар бераз уйлап торды, аннары әйтте:

— Бик яхшы. Приказ буенча кызылармеец булып үткәч, сиңа анда китү чүп тә түгел.

Повар шулай диде һәм, як-ягына каранып алды да, Хәлимнең колагына иелде.

— Мин дә китәм фронтка. Ә бармак нәрсә-ә!.. Военком үз кеше минем... Менә кайтсын да... Командировкада әле... Бергә китәрбез, диде. Тик моны берәүгә дә

сиздерергә ярамый, төшендеңме?.. Әә, хәзергә миңа ярдәмче буласың. Ризамы?

Хәлим риза булды.

Кичен повар шул турыда Хәлимнең әтисе белән сөйләште. Зиннәт абзый бернәрсәне аңламады.

— ...Сезнең ярдәмчегез бар бит?

— Бар. Ләкин ул миңа ошамый. Бик гамьсез нәмәрсә. Әллә ничә тапкыр ашны бозды... Аннары, аның сугышыр чагы. Әнә кинди пәһлеван бит! Ә егеткә иртә әле.— Ул Зиннәт абзыйның колагына иелде.— Яраттым мин сезнең егетне. Аны саклап калырга кирәк... Зинһар, мин әйткәнне әйтмәгез, телендә гел фронт... Әрәм булуы бар. Мин бигрәк шуның өчен...

Болай дигәч, Зиннәт абзый да риза булды. Повар шунда ук госпиталь начальнигына рапорт язды. Ә иртән ярдәмче поварны, эшенә салкын карау нәтиҗәсендә ашны бозып пешергәне өчен эшеннән алу, аның урынына Хәлим Арслановны билгеләү турында госпиталь буенча приказ чыкты. Бер-ике көн үткәч, Хәлимнең өстендә инде гәүдәсенә карата зуррак булса да, солдат гимнастеркасы, яшел чалбар, башында йолдызлы бүрек, аякларында менә дигән солдат итекләре иде. Хәлим, ничаклы тырышса да, шатлыгын яшерә алмады: авызы колакларына житте малайның. Шатлыктан тәне кытыкланды, чәч төпләренә кадәр кытыкланды. Кайда көзге күрсә, шунда туктап, үзен карап торды, тәрәзәләрдән үзенең чагылышын карап узды. Кухняда зур кисмәк белән су тора иде. Кеше-кара күрмәгәндә әледән-әле шуның өстенә иелеп, үзен карады. Өйдә ялгызы калгач, сикерде, мәтәлчек атынды.

— Эх, малайлар күрсә, нәрсә әйтерләр иде икән хәзер?...

19 ХӘЛИМГӘ ЯМАНСУ БУЛЫП КИТТЕ

Хәлим, тойгыларын кем белән уртаклашырга белмичә, урамга йөгереп чыкты. Ул, гимнастеркасы белән киң сары каешы күренеп торсын өчен, пиджагын чишеп жибәрде. Теләгенә ирешә бит Хәлим!.. Болай булгач, әтине фронтка озатасы да, поварның:— «Әйдә, Хәлим, жыен, фәлән поезд белән китәбез»,— дигәнен генә көтәсе кала!..

Ул, шулай хыяллана-хыяллана, урам буйлап китеп барды һәм госпитальгә бөтенләй бүтән Хәлим булып кайтып керде.

Эш болай булды.

Хәлим, йөри торгач, бер мәктәп янына килеп чыкты. Аның бу мәктәпне беренче күрүе түгел, ул ат белән пекарнядан ипи-күмәч алып кайтканда гел шуннан уза, малайлар, тәнәфескә чыккан вакытлары булса, аңар берәр шаян сүз әйтми калмыйлар иде. Бүген исә малайлар Хәлимне кар йомарламнары белән каршы алдылар. Хәлимнең моңар ачуы килмәде генә түгел, хәтта бик күңелле булып китте.

Хәлимнәр дә бит, шундый җепшек көннәрдә мәктәптән йөгереп чыгалар иде дә, берәр атлы узып барганны күрсәләр, кар атып калалар иде. Узгынчы ачуланмаса, бөтен чанасын кар белән күмгәнче артыннан йөгерәләр иде... Хәлим, шап-шоп яуган кар йомарламнарыннан битен җиңе белән томалаган хәлдә, шул турыда уйланып йөгерде. Һәм аңар, ничектер, кинәт ямансу булып китте. Авылда да инде мәктәпкә җыелып беткәннәрдер. Шаһгәрәй абзый балаларны барлый торгандыр...

— Хәлим!— дигәч, малайлар әле һаман: «Ул юк»,— дип кычкыралар микән? Әллә инде Шаһгәрәй абзый, башсыз малай дип, исемлектән сызып ук ташлады микән?..

Бер читтәрәк витринадагы «Правда»дан сугыш эпизодлары укып торган зуррак малайлар кар атучыларга куәт бирделәр:

— О, о... парень из госпиталя!.. Шапка со звездочкой, гимнастерка, ремень... Так-так, с обновкой его!..

Ләкин аларга Хәлимне котларга туры килмәде, звонок тавышын ишетеп, барысы да мәктәпкә йөгерә башлады. Ә берсе (андыйлар Хәлимнәр мәктәбендә дә бар иде), күзге чебен шикелле, һич кенә дә туктамады. Ул, иптәшләре мәктәпкә кереп беткәч тә әле, Хәлимгә бертуктаусыз кар ыргытты. Әнә ул инде бөтенләй якынайды. Хәлим хәзер аның сулаганын да ишетә иде. Менә ул, куып җитте дә, Хәлимне аяк чалып екты һәм кулына зур итеп кар умырып алды да егылып яткан Хәлимнең битенә бәрде.

— У-у, юк инде, монысы артыкка китте!... Безнең авылда моның өчен...

Хәлим ярсып сикереп торды.

Малай куркып йөгерә башлады. Хәлим малайны куып китте. Куа-куа мәктәпкә барып керде. Малай Хәлимгә тоттырмады — ишеге ачык классларның берсенә ялт кереп шылды. Хәлим, берникадәр вакыт ишек төбендә туктап торды да, малайны танып калу, ә соңыннан очратып исәп-хисапны өзү өчен, класска башын тыгып карады һәм шунда ук кире алды. Класста дәрес башланган иде инде.

Укытучы бик кызыклы нәрсә сөйли иде, ахрысы, балалар барысы да аның авызыннан чыккан бер сүзне йотып баралар. Ара-тирә көлемсерәп тә куялар, ә кайберләре ай-яй дигән мәгънәдә башларын чайкап торалар иде.

Хәлимгә тагын ямансу булып китте. Ул хәзер мәктәпкә ни өчен кергәнен дә, бәйләнчек малайны да онытты. Бер тапкыр Шаһгәрәй абзый аңар, бер иске әлифбадан, мәктәптә укып утырган балаларга бер читтән кызыгып карап торган хәерче малай рәсемен күрсәткән иде. Хәлимнең исенә кылт итеп шул рәсем төште. Малайлар күрсәләр, әнә әлифбадагы малай, диярләр төсле тоелды. Хәлим мыштым гына ишек яныннан китте. Пыяла ишекле икенче бер класста, укытучы өстәлендә, кызыл, кара, зәңгәр сыекчалар тутырылган озын муенлы түгәрәк шешәләр күреп, туктап калды. Укытучы бер сыекчаны икенченә кушкан иде, өченче бер төс килеп чыкты. Ә кызыл сыекчаны карага кушкач, сыекча шунда ук бик матур зәңгәр төскә керде. Аннары укытучы, стенадагы әллә нинди хәрефләргә күрсәтеп, нидер сөйләде. Хәлим аның бер сүзен дә аңламады. Ник аңламады икән? Әнә балалар ничек бирелеп тыңлыйлар. Торып-торып башларын чайкап куялар. Димәк, укытучының сүзләре аларга кызык. Ә ник соң мина кызык түгел? Хәлимгә бер тапкыр әбисе: «Надан халык — сукыр тавык. Күзе бар аның, әмма ләкин һичнәрсә күрми. Күзле багана инде шунда...» дигән иде. Хәлимнең исенә кылт итеп шул сүзләр төште. Гүя әбисе хәзер дә ишек алларында тавык-чебешләргә җим сибә-сибә шулай дип сөйләнә һәм бу юлы ул, ни өчендер, Хәлимгә кинаяләп, аңар карый-карый сөйләнә кебек иде. Хәлим уңайсызланып елмаеп куйды. Шул минутта «Ленин», «учиться» дигән сүзләрне ишетеп, яңадан баягы класс ишегенә килде.

— Ленин бабай турында сөйли, ахры.

Укытучы сөйләми, диктант яздыра иде. Хәлимне чалып еккан, зур кар йомрысы белән битенә бәргән малай, такта алдында укытучының кабатлап әйткәнен көтеп тора иде.

Кечерәк буйлы, чандыр, ләкин бик тере, гел көлеп торган курнос борынлы бер малай иде бу. Хәлим аны күрүгә дерелдәп куйды. Ул хәзер такта янына житәрлек озын куллары булуны теләде. Шул куллары белән малайны тартып алып, якасына ябышасы килде...

Менә малай бик матур хәрефләр белән тактага:

— Ленин сказал,— дип язып куйды һәм, акбурын бора-бора ике нокта төртте. Нәкъ шул чакта, якында гына, йөрәк әрнеткеч ямьсез тавыш белән сирена кычкырта башлады. Кемдер, кайдадыр: «Граждане, воздушная тревога, граждане, воздушная тревога»,—дип кабатларга тотынды. Класстагы берничә бала беләкләренә тиз генә кызыл тәреле ак беләкчәләр киеп алдылар. Әллә кайдан санитар сумкалары китереп чыгардылар. Болар бар да яшен тизлеге белән эшләнде. Укытучы, шулай ук тиз генә, китап-дәфтәрләрен жыя-жыя балаларга дәресләрнең вакытлыча өзелеп торуы турында белдерде һәм барысына да бомбоубежищега төшәргә кушты. Менә укытучы әйтеп бетергәнче үк урыныннан кузгалган озын буйлы бер малай стенадан Шишкинның бик матур эшләнгән «Урман иртәсе» исемле рәсемен алып чыгып йөгерде. Аның артыннан башкалар да ишеккә ташландылар. Кечкенә буйлы, елмаеп торган курнос борынлы чандыр малай класста бер үзе калды.

— Кереп бәргәләп ташларгамы? Безнең авылда аякны менә болай чалалар аны, дияргәме?

Чү!.. Малай, тревоганы ишеткәч каушап, сүзләрен генә онытып торган ахры, ике ноктадан соң, хәрефләрен куерак итеп:

— *Учиться,* — дип язып куйды.

Иң соңгы кеше булып ишектән чыгып баручы укытучы аңар:

— Чык, Женя, соңыннан язарсың,— дисә дә, әз генә дә каушамыйча, *учиться* сүзе янына тагын ике тапкыр:

— *Учиться, учиться,*— дип язып куйды. Соңгы хәрефе үзенә ошамады ахры, бозып, яңадан язды, нокта куйды һәм үз язуына үзе сокланып карап торды да ишеккә таба йөгерде.

Язу Хәлимне әсир итте.

7*

— Ух, нинди матур яза!.. Сүзләре нинди тагын!..

Малай, кинәт нәрсәдер исенә төшеп, ишек төбендә бераз тукталып торды да арткы стенага таба йөгерде. Ә, борылып килеп, коридорга ташланганда аның кулында Буденныйның гражданнар сугышы вакытында атка атланып төшкән портреты иде.

Хәлимдә малайга карата булган ачу кинәт бетеп китте. Малай коридорга чыгуга Хәлим аңар узып китәргә юл бирде. Һәм үзендә аңар карата дошманлык беткәнен аңлатып, ягымлы елмайды. Малай исә шикләнеп туктап калды. Буденный портретын күкрәгенә кыса төште. Хәлим малайны тынычландырырга ашыкты: кулларын юри чалбар кесәләренә тирән батырып, стенага таба чигенде.

— Курыкма, малай, тимим...

Малай, әле һаман да шикләнгән хәлдә, күзләрен Хәлимнән алмыйча, каршы як стенага сыена-сыена, тышкы ишеккә таба уза башлады.

— Тимим,— дип сузды Хәлим.— Ай-яй матур яздың, молодчина... Син Женя бит, әйеме?

Малай бераз тынычлана төште:

— Женя,— дип җавап бирде ул,— ә синең исемең ничек?

— Хәлим.

Хәлим телен шапылдатып куйды:

— Ай-яй матур язасың икән... бик матур...

Женя да, Хәлимгә ниндидер яхшы сүз әйтмәкче булып, авызын ачты. Ләкин, ачулы кычкырган тавыш ишетеп, туктап калды.

— Нәрсә сез, дуслар, сезнең өчен аерым тревога кирәкме әллә?

Моны, вешалкасын бикләп чыгып баручы, тездән агач аяклы карт швейцар әйтте. Әйтте һәм шунда ук док-док басып, тиз-тиз ишек алдына чыгып китте. Инде Хәлимгә тәмам ышанып җиткән малай, йөзен куркыныч кыяфәткә кертеп, фашист дип, бомба дип, һавага күрсәтә-күрсәтә йөгерә башлады:

— Әйдә, калма, Халимка!

Хәлим, Женяны куып җитеп, аның белән бергә ишек алдына йөгереп чыкты.

Икешәр-икешәр булып тезелгән балалар, озынча ишек алдының биек стенасына ышыклана-ышыклана, каядыр йөгерәләр. Алар яныннан, тәртип сакларга өндәп, укыту-

чылар чабып үтәләр. Балаларның алгы сафлардагылары, улак буйлап аккан су шикелле, каядыр түбән төшеп югала баралар иде.

Женя Хәлимне, Хәлим Женяны әйдәп, азаккы саф артыннан килеп җиттеләр һәм алар да, алдагылар шикелле, стенага ышыкланып бер йөгереп, бер туктап бара башладылар. Алда текә баскычлы тирән подвал икән, Хәлимнәр җитәкләшеп шунда төшеп киттеләр. Әллә нинди бик тар, караңгы, идәне дә, түшәме дә, стеналары да таш, борма-борма коридорлар аша үттеләр алар. Ниһаять, бик күп балалар җыелып торган подвалга килеп керделәр.

Юеш ис анкый иде подвалда. Уты бик тонык. Соры стеналардан салкын бәреп тора. Йөрәк өзгеч тавышлар, сирена подвал эчен тагы да ямьсезли төшә иде.

Балалар үзләре белән класслардан алып төшкән портретларны, кызыл тәреле киндер сумкаларны стеналарга элеп куйдылар. Теге зур малай «Урман иртәсе» рәсемен түргә, лампочка астына бик саклык белән генә элеп куйды. Женя да Буденный портретын шулай ук хөрмәт белән китереп элде. Хәзер подвалга бераз ямь керен китте. Балалар иңнән-иңгә тезелеп киткән, ничек туры килде шулай юнып, ышкылмый гына кадакланган озын скамьяларга тезелешеп утырдылар. Кайсыберсе үзләре белән алып килгән әбәтләрен ашый башлады. Женя да сумкасыннан өстенә калын итеп бәрәңге боламыгы сылаган юка гына ипи кисәге алып, бер башын авызына капты. Һәм, кинәт туктап, шактый тирән баткан тешләрен ризыктан кире алды. Ул ипине бәрәнгесе белән кыл урталай сындырды да бер кисәген Хәлимгә сузды:

— Аша, Халимка.

Хәлим алмагач, Женя бәрәңгеле ипине аның авызына төртте:

— Мә инде...

— Кирәкми. Әле генә ашадым мин.

Балаларның якынрак утырганнары Хәлимгә борылып карадылар. Аны танып алгач, күңелле шаулаша башладылар.

— А-а... парень из госпиталя!..

Менә бер-беренә елышып утырган балалар әкрен генә җырлап җибәрделәр:

По долинам и по взгорьям
Шла дивизия вперед...

Хәлимнең танышы да, ипи белән бәрәңгесен күз ачып йомганчы ялтыратты да, җырга кушылды:

Чтобы с боя взять Приморье —
Белой армии оплот...

Хәлим русча җырлый белмәгәненә уңайсызлана, шул ук вакытта, кайбер сүзләрен аңлаганына сөенеп, эченнән көйләп утыра иде. Шул чак кемдер (укытучыдырмы, укучыдырмы) ике-өч сүз кычкырды. Хәлим төшенми калды, ә Хәлимнең яңа танышы Женя, әллә кычкыру белән бер үк вакытта, әллә инде аннан да алдарак, урыныннан сикереп торды һәм, балаларны этә-төртә, кайда идән буйлап, кайда скамьядан скамьяга сикереп, йөгерергә кереште. Ул, йөгерә-йөгерә барып, түрдә чыгышлар ясау өчен бисгәйтеп эшләнгән сәхнәсыман урынга менде. Аны йөгереп үтәм дигәндә, кинәт кенә нилдидер сәер шартлау ишетелде. Женя күтәргән аягын да атлый алмыйча калды, йөрәген тотып чалкан авып төште. Балалар, барысы да диярлек, урыннарыннан кузгалып, Женяга таба ташландылар. Ләкин арадан бер укытучы торып, аларны туктатты.

Хәлим бу вакытта Женя янына килеп җитә язган иде. Ул аны аермачык күреп торды. Күзләре йомылган, йөзе иләмсез булып чалышайган, бер ягын бая җырга кушылганда йотылмый калган бәрәңгесе төртеп тора иде.

Хәлим аны чын кызгану белән кызганды. Станциядә бомбежка вакытында үзе белән яралылар ташып йөргәндә егылып үлгән әби килде аның күз алдына.

«Женяга да шул хәл булды микәнни? Ник берәү дә йөгермәгәндә син генә йөгерден соң, ә?.. Берәрсе Женяларның өйләренә, әнисенә әйтергә китте микән әле? Әгәр кайда торганнарын белсәм, бернәрсәгә карамыйча, үзем чыгып йөгерер идем. Тукта әле, бу малайлар белә торганнардыр ич... Ләкин ничек итеп сорарга икән?.. Ах, бу русча белмәү...»

Хәлим шулай уйланып торганда, носилка тоткан, билләренә кызыл тәреле сумка аскан, җиңнәренә кызыл тәреле беләкчә теккән ике зур кыз килеп җитеп, Женя өстенә иелделәр. Кызлар, җайлап кына, ләкин гаҗәп бер тизлек белән, Женяның пиджагын салдырдылар, күлмәген дә салдырдылар һәм, сумкаларыннан ярты бүрек кадәр мамык алып, Женяның күкрәгенә куйдылар да тиз-тиз, ләкин бик пөхтә итеп, бинт белән уратып

бәйли башладылар. Җиңе кызыл тәреле ап-ак халат кигән бер олы кеше аларга, нидер әйтә-әйтә, күрсәтеп торды.

Менә кызлар Женяны сакланып кына носилкага күтәреп салдылар. Женя носилкага салганда ыңгырашып куйды.

— Ярый, терс икән әле...

Кызлар носилканы әкрен генә күтәреп алдылар да сәхнәнең икенче башына китереп куйдылар. Анда кеше озынлыгы бер ящик булып, өстендә ак җәймә һәм ак тышлы кечкенә генә мендәр иде. Женяны шунда алып салдылар, сакланып кына бинтын сүттеләр, бик сакланып кына мамыгын алдылар.

— Әтине ярган күк моны да яралар икән инде алайса. Эх, Женя, Женя...— Хәлим алга омтылды. Ләкин аны ике ягыннан ике малай тотып туктатты:

— Сиди, сиди!

Женяны ярмадылар. Кызлар марляларын төрек сумкаларына салдылар да халыкка таба борылдылар.

Чү, бу ни бу? Менә Женя да, футбол уйнагандагы тизлек белән, ящик өстеннән сикереп төште һәм кызларның урталарына килеп басты. Бу вакыт аның йөзе генә түгел, курносына кадәр көлә иде.

Бар да, укытучылар да, укучылар да шау-гөр килеп кул чабарга тотындылар.

Женя, сул яңагын төртеп торган бәрәңгесен теле белән каерып алды да, чап-чоп чәйни башлады. Хәлим, тәмам тынычланып, иркен сулады: «Юри-мари гына икән...»

Женя бәрәңгесен чәйни-чәйни сәхнәдән сикереп төште. Күзләре белән Хәлимне эзләп тапты да, көлә-көлә аның янына килеп утырды һәм егылганда чыннан да шешеп чыккан башын Хәлимгә тоттырып күрсәтте.

— Бульне?

— Не-е... Я каждый раз...

— Мин умирал дип торам.

— Не-е... Это же занятие сандружины.

Женя Хәлимгә кесәсеннән ун тиен көмеш кадәрле түгәрәк кәгазьләр алып күрсәтте. Кәгазьләрнең кайсына «Пулеметная пуля» дип, кайсына «Взрывная» дип, «Осколок» дип язылган иде. Женя, «Картечь» дип язылган бер кызыл кәгазьнең арт ягына лач итеп төкерде дә ботына ябыштырды һәм күзләрен акайтып, чыраен бозып,

сызланып куйды. Аннан «Винтовочная» дигән бер кәгазьне төкереклән маңгаена ябыштырды.

— Капут!

Күзләрен мәет шикелле итеп йомды Женя. Йөзеннән канын качырды һәм берничә секунд суламый торды. Аннары рәхәтләнеп көлде.

Хәлим дә көлде:

— Интирисне.

Кул чабулар туктар-туктамас, тагын җыр башланып китте:

То не тучи, грозовые облака...

Менә, җыр арасында, бая радио буенча мәктәптә ишетелгән калын тавыш яңгырап китте. Ләкин бу юлы инде ул алай шомлы түгел иде.

— Граждане, опасность миновала! Граждане, опасность миновала! — диде ул.

Балалар җырны дәвам иттерә-иттерә урыннарыннан кузгалдылар. Хәлим белән Женя да, күптәнге дуслар шикелле, бер-берсен җитәкләшеп ишеккә ташландылар. Ят, караңгы коридорлардан Хәлим тиз бара алмады: абынды, сөртенде. Балаларның җитезрәкләре аларны узып китте.

Хәлим алар турында: исән калганнарына шатланулары дыр, өйләренә ашыга торганнардыр, дип уйлаган иде, кая ул! Подвалдан атылып чыктылар да, килгәндәгечә тәртип белән түгел, абзарда озак ятып яшел болынны тансыклаган яшь тайлардай сикергәләп, мәктәпкә таба йөгерделәр.

Хәлим Женяны капкага таба өстерәде:

— Әйдә госпиталь...

Женя башын чайкап куйды. Һәм Хәлимне, кулыннан тотып, мәктәпкә таба өстерәде:

— Мәктәпкә керәбез. Хәзер безнең химия була. Эх, ничек күңелле! — диде ул һәм мәктәп түбәсенә төртеп күрсәтте. Аннан, мәктәп түбәсеннән, тимер баскыч буйлап, Женяның тел укытучысы һәм берничә өлкән укучы төшеп килә иде.

— Дружина ПВХО,— диде Женя, алар белән масаеп. Һәм дружиначыларның тревога булган саен шунда менүләре турында, бер тапкыр, түбәгә бер-бер артлы ике яндыргыч бомба төшкәч, келәшчәләр белән тиз генә эләктереп алып, ишек алдына ыргытулары турында сөйләр-

гә, кайсын-берсен кул хәрәкәтләре белән аңлатырга тотынды.

— Әйдә, алар хәзер безнең зениткаларның фашистларны һавадан ничек бәреп төшергәннәрен сөйлиләр.

Хәлим мәктәпкә кермәде. Үзенен хәзер повар ярдәмчесе икәнен әйтеп, эше күп икәнен аңлатып, госпитальгә кайтып китте. Капкадан чыгып барганда, мәктәпнең берничә тәрәзәсе ватык икәнен күрде һәм берсеннән үрелеп эчкә карады.

Бу Женялар классы иде.

Тәрәзәдән бөркелеп җылы һава һәм тамак төбен, күзләрне әчеттерә торган ниндидер аксыл тузан чыга иде. Класста, тузан эчендә, балалар ыгы-зыгы килеп йөри, түшәмгә күрсәтеп, нәрсәдер кычкыралар иде, Хәлим дә түшәмгә карады. Аның хәтсез зур җиреннән штукатурка кубып төшкән, тузан шуннан коела икән.

Менә бая Хәлимнәрне орышкан агач аяклы карт швейцар берничә себерке, көрәк, щетка күтәреп керде. Балалар, шулар белән коралланып, классны җыештыра башладылар. Берничә кыз бала авызларына су кабып һавага бөркегәч, бүлмәнең һавасы бераз чистарып китте, җиһазлар ачыграк күренә башлады. Портрет һәм плакатларны урыннарына элеп куйдылар. Киндер алъяпкычлы берәү кереп, тәрәзәнең коелган пыялалары урынына фанера такта кадакларга тотынды. Хәлим пыяласы исән калган тәрәзәгә килде. Менә, уборщица кереп, юеш чүпрәк белән парталар өстендәге акшар тузаннарын сөртеп чыкты. Кара такта янына килде, чүпрәген сулады да тактаны сөртә башлады.

— Ай, кирәкми, Маша түтәй! — диде Женя һәм парталар арасыннан сикереп чыгып, тактага сырышкан акшарны авызы белән өрергә тотынды. Өргән саен такта, кар астыннан чыккан кара җир шикелле, үзенең ялтыравыклы кара төсенә кирә барды. Женяның моннан берничә генә минут элек язган язуы ачылып килеп чыкты. Женя язуны җентекләп күзеннән кичерде дә тәэсирле итеп укый башлады:

— *Ленин сказал: учиться, учиться, учиться!*

Класска әле генә кереп тыңлап торган укытучы Женяның җилкәсенә җиңел генә итеп кулын салды.

— Молодец, Женечка, утыр, кадерлем,— диде укытучы һәм, үзенең дәфтәрен ачып, нидер сызгалап куйды. Женя, партасына таба үтеп барышлый, укытучының дәф-

тәренә үрелеп карады һәм канәгатьләнеп, биш бармагын киң җәеп, кулын югары күтәрде.

Укытучы тактага икенче бер баланы чакырды: аңа икенче бер җөмлә әйтеп яздыра башлады.

Хәлимнең күз алдына тагы әбисе килде. Ул бу юлы да тавык-чебешләргә җим сибеп йөри һәм Хәлимгә карап ала-ала сөйләнә иде:

«Надан халык — сукыр тавык. Күзе бар аның, әмма ләкин һичнәрсә күрми. Күзле багана инде шунда...»

Хәлим тагын уңайсызланып тәрәзә яныннан китеп барды.

Мәктәп каршындагы мәйданда пожар машиналары бик күп иде, пожарныйлар бомба казып ташлаган тирән чокырны як-якка чәчрәгән туң балчыклар белән күмеп йөриләр иде. Хәлим чокыр янында туктап тормады, госпитальгә йөгерде.

— Әллә чыннан да ялгыштым микән? Әллә райком секретареның сүзләре дөрес булды микән?

Хәлим, шулай уйлана-уйлана, госпиталь ишек алдына кайтып керде. Ишек алдында Хәлим җигә торган карт алаша чәчелеп калган яшел печәннәрне чемченеп йөри, ә табак-савытлар юучы хатынның дүрт-биш яшьлек малае, атның ялына ябышкан да, атланырга азапланып, әле бер, әле икенче аягын күтәрә иде.

Башка вакыт булса, бу акыллы, матур малайны Хәлим үзе күтәреп атландырыр һәм берәр җир буе йөртеп тә килер иде, ә хәзер аның яныннан ачулы кычкырып узып китте:

— Кит, кәтүк, хайван яныннан!

Һәм икенче этажга, кухняга йөгереп менде.

— Повар ачуланмасын тагын...

Повар ачуланмады. Әйе, ул кемгәдер ачулы иде, *кемнедер* телгә алып сүгенә иде, ләкин Хәлим кергәч ачылып китте.

— Ну, иптәш помощник, эшкә тотын, эшкә...

Хәлим пиджагын, бүреген салып чөйгә элде дә ак халат, ак калфак алып киде. Һәм, повар кушканнарны үтәп, плита тирәсендә ыгы-зыгы килеп йөри башлады.

20 МАСКИРОВКА ҖЕПЛӘРЕ

Һава тревогасы бу шәһәрдә еш булып торды. Ул күбрәк караңгы кичләрдә, болытлы төннәрдә була иде.

Лэкин, аларның барысы да диярлек, тревога көенчә кала килде. Безнең җитез истребительләр, шәһәр читенә урнашкан зениткалар, дошман бомбардировщикларын кире борылырга мәҗбүр иттеләр. Берәм-сәрәм үтеп кергәннәре безнең җирләрдә үзләренә кабер таптылар. Тик әллә нигә берләре генә үз максатларына ирешә алдылар: тыныч халыкка — хатын-кыз, бала-чага, карт-корылар өстенә — үлем яудырып киттеләр.

Һава тревогасы бер тапкыр Хәлим кинода чакта булды. (Кичләрен еш йөри иде ул кинога. Повар аны үзе әйтеп җибәрә, кайчакта, хәтта, билетны да үзе алып кайтып бирә торган иде.) Тревога башлануга тамашачылар кино астындагы подвалга төштеләр. Хәлим төшмәде. Бигрәк эчпошыргыч була ул подваллар... Лэкин тревога вакытында урамда йөрергә ярамый. Хәлим ишек алларыннан, койма башларыннан, капка асларыннан үтеп, госпитальгә кайтты. Ярый әле кайтты! Кухняның ишек алдына караган тәрәзәсеннән ут балкыган иде. Малай эсселе-суыклы булып китте һәм нишләрен белмичә, өскә йөгереп менеп, кухня ишегенә килеп бәрелде. Ишек һәр кичтәгечә бикле иде.

Хәлим, кесәсендәге икенче ачкыч белән каушый-каушый ишекне ачты да, тиз генә кереп утны сүндерде һәм маскировканы кормакчы булды. Лэкин аның җепләре өзелгән иде. Хәлим, ничек эләкте шулай ялгап, маскировканы корды. Утны яндырып торганда повар йөгереп килеп керде. Агарынган, каушаган иде ул. Әллә ничек зураеп, усалланып киткән күзләре карарга куркыныч иде. Ул кергән шәпкә бераз нишләргә белмичә торды, аннан Хәлимне кочып алып үпте:

— Нинди генә рәхмәтләр әйтим икән сиңа, Хәлим җаным,— диде ул.— Үзеңне дә, мине дә коткардың бит син. Начальник күргәнче торган булса, икебез дә харап була идек...

«Начальник күргәнче торган булса...» Хәлим коелып төште. Поварның, үзен аклау өчен, «Хәлим корырга тиеш иде, кормаган бит, юньсез»,— диюе бар ич... Хәлим калтыранып куйды.

Ә повар:

— Бу безгә сабак булсын. Зинһар, моннан болай яхшы карап йөрик инде, Хәлим. Тревога булдымы, ишек алдына чыгып карый торган булыйк,— диде.

— Йә.

— Монысы турында кешеләргә әйтеп тормабыз инде.. начальникка да...

— Йә.

— Кара аны, әтиеңә дә әйтмә...

— Йә.

— Әйдә, подвалга төшик, әнә тагы самолет тавышлары килә.

Хәлимнәр икенче каттан ишек алдына йөгереп төшүгә, усал улап, нәкъ баш очыннан гына самолет узып китте. Ерак та түгел, икенчесенең тавышы ишетелде.

Повар әллә ниләр әйтеп сүгенде. Хәлимнең беләгеннән тотып килә иде, никтер бик каты итеп кысып алды һәм Хәлимне подвалга ашыктырды:

— Кара, малай, үзеңне тыныч тот, әйтеп сала күрмә.

Икенче көнне, авыруларга иртәнге ашны ашаткач, повар маскировканың җепләрен шактый юан тасмалар белән алыштырды.

— Инде өзелмәс, инде тыныч йөрергә була,— диде ул тасманы тартып карап.

Ә Хәлим һич тә тынычлана алмады. Әгәр шунда күреп алып утны сүндереп өлгермәгән булсам, ничаклы яралының, әтисенең дә, үзенең дә, Алексей дәдәнең дә харап булуы мөмкин иде бит... Ә күршедәге завод тагын? Андагы машиналар? Кешеләр?!

Хәлим һәр көн, караңгы төшә башлау белән, кухня маскировкасын үзе кереп тикшерә торган булды. Төннәрен тревога була калса, өстенә дә киеп тормыйча, ишек алдына йөгереп чыгып, тәрәзәне карап керде. Маскировканың җебе һаман да җитәрлек нык түгел төсле күренде. Ул аңа тагы да юанрак тасма юнәтеп такты.

Повар көлде:

— О-о, әллә инде син ул тасмага мине тотып асмакчы буласыңмы? Күтәрер, мине дә күтәрер...

Ләкин куркыныч — күзеңә туры карап килгәндә генә куркыныч була. Үтеп киткәч, йөрәгеңне алай ук куырып алмый башлый. Маскировка куркынычы белән дә шулай булды. Атналар үтү белән, гомумән, шәһәрдә тревогалар сирәгәю белән, Хәлим тынычланып китте. Ул буш сәгатьләрендә тагын киногa йөрде. Бөтен күңелен биреп рус телен өйрәнде. Якын гына торалар икән — Женяларга кереп йөрде. Бер тапкыр Женяның әтисе эшли торган за-

водка да бардылар. Женяның әтисенә чиста күлмәк-штан киттеләр. Женяның әтисе сугыш башланганнан бирле бөтенләй диярлек кайтмыйча эшли, фашистлар өстенә яудыру өчен бомбалар ясый икән. Әнисе дә эштә. Анысы фабрикада парашютлар тегә һәм атна-ун көнгә бер кайтып китә икән. Женя өйдә кечкенә сеңелесе белән генә тора, мәктәптән кайткач ашарга пешерү, өй эшләрен карау, чиратларга йөрү, хәтта кер юу Женя өстендә икән...

Бу хәлне күргәч, Хәлимдә, авылны, мәктәпне сагыну тагы да көчәеп китте. Әнә, ничек кыен булса да, Женя укуын ташламаган. Ә мин?.. Тукта, әллә кайтып килсен микән шыпырт кына?.. Юк, шушында хәтле килеп җиткәч, кайтып китсәң, малайлар гына түгел, тавыклар көләр. Аннан, Хәлим укуны авыр булганлыктан ташламады ич. Абыйсы өчен үч алырга бара ич ул...

Хәлим фронтка барып җиту, һич булмаса, шунда барып сугышчыларга патроннар гына ташып йөрү турында хыяллана бирде. Беркөнне, яралыларга кичке ашны ашатып, кухняны бикләп чыгып китәргә торганда, бу турыда поварның да исенә төшерде:

— Кайчан китәбез инде, Алексей дәдә?

— Тиздән, Халимушка. Әтиең терелеп чыкканны гына көтәм мин. Ул терелеп чыгуга, начальникка рапорт язам.

— Әти терелә инде. Бүген әйтте: бер атнадан фронтка да китә алсам кирәк, диде

— Бик әйбәт. Ә ике атнадан без дә синең белән анда булырбыз.

Алексей дәдә шулай диюгә, Хәлим яктырып китте:

— Булырбызмы?

— Әйткән сүз — аткан ук диме әле синең әтиең?

— Шулай ди.

— Әйбәт мәкаль. Бар инде, кереп ят. Иртәгә эш күп булачак.

— Мин бераз укыйм әле. Алексей дәдә, менә кара, ничек укыйм мин хәзер...

Хәлим куеныннан «Пионерская правда» алып кухня өстәленә җәйде. Нәкъ шул чакта атна буена ишетелми торган әчпошыргыч сирена уларга тотынды. Повар: «Яле, яле, ничек укыйсын икән», дип газета өстенә иелгән генә иде, кинәт алмашынып китте.

— Ах, шайтан алгыры...— диде ул һәм сәгатенә карап алды да, икенче төрле борчылып әйтеп куйды:— Һм!.. Онытып торам икән, безнең иртәгә чәйгә шикәр дә юк бит әле...

Хәлим, маскировканың әз генә ачык калган җирен томалап килде дә, буфет ишеген ачты:

— Бал бар, Алексей дәдә, менә конфет та бар.

Повар, сәгатеннән күзен алмыйча, бәхәскә урын калдырмый торган итеп:

— Шикәр кирәк,— диде. Иртәгә иртән җиденче белән унберенче палаталар өчен какао кайнатабыз. Берни эшләп булмый, икебезнең беребезгә складка йөгерергә туры килә...

«Үзем барырмын, тревога бетсен дә үзем барырмын», димәкче булды Хәлим. Ләкин алай дисәң, поварның: «Ә хәзер барырга шүрлисеңә Эх, син, герой! Фронтка китәм дип йөргән буласың тагы!» дип оялтуы бар... Хәлим газетасын чалбар кесәсенә бөтереп тыкты да чөйдән пиджагын алды.

— Кая барасың?

— Шикәргә, Алексей дәдә...

Поварның йөзенә канәгатьләнү билгесе чыкты. Ул Хәлимнең аркасыннан сөеп куйды:

— Болай булгач, мин инде синең берниди сугыштан да курыкмаячагыңа ышандым, Халимушка. Очып бар, очып кайт, дустым.

Поварның мактавы белән канатланган Хәлим ишектән атылып чыгып китте. Турыдан, койма өсләреннән, капка асларыннан үтеп, складка чапты ул. Ах... завхоздан язу алырга оныткан ич... Хәлим, кире борылып, госпитальгә йөгерде. Һәм, ишек алдына килеп керү белән, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Кухня тәрәзәсеннән, гадәттәгедән дә яктырак булып, ут балкыган иде.

— Бу ни тамаша! Ой-ой!.. Әнә зениткалар ата да башладылар инде. Димәк, бомбардировщиклар якын... Хәлим, ишек алдын җан-фәрманга йөгереп үтте дә, баскыч буйлап кухняга менә башлады. Аның алдыннан кухняга тагы кемдер ашыга-ашыга менеп бара иде.

— Алексей дәдәдер, утны сүндерергә менеп барышыдыр,— дип уйлады Хәлим. Ул аңа: «Тизрәк булыгыз, зениткалар ата башлады»,— димәкче булды. Ул арада теге кеше икенче катка менеп тә җитеп, кухняга таба йөгерде:

— Маскировкагызны, әй-й!..

— Әнекәй генәм лә... Василий бабай ич бу! ПВХОчы. Түбәдән күреп төшкән. Башны бетертә икән инде...— дип уйлады Хәлим.

Василий бабай йөгереп килгән уңайга, тимер белән тышланган авыр ишеккә килеп бәрелде һәм футбол тубы шикелле кире атылып китте. Ишек бикле иде.

Василий бабай, ахры, ишекне ватып керү өчен берәр әйбер алып килмәкче булгандыр, кире йөгерә башлады һәм Хәлимне күреп туктап калды.

— Һәй, син, фәлән-төгән малай! Кайда йөрисең?! Ачкычың яныңдамы?..

Куркудан аңын җую дәрәҗәсенә җиткән Хәлим Василий бабайга бер сүз белән дә җавап кайтара алмады. Калтыранган куллары белән кесәләреннән ачкычын эзләп табып йозакны ачты да, ишектән атылып кереп, утны сүндерде һәм, тәмам хәлдән таеп, күкрәге белән өстәлгә капланды.

— Харап кына булдык бит, Василий дәдә!..

Хәлим өстәлдән башын күтәргәндә шулай диде. Ләкин бу вакытта Василий бабай кухняда юк иде инде.

Хәлим, исерек кеше шикелле алпан-тилпән атлап, тәрәзә төбенә килде:

— Бу нинди тамаша? Тагы нәрсә булган соң бу маскировкасына? Маскировканың тагын тасмасы өзелгән иде.

Хәлим ни дип уйларга да белмәде. Һәр көн тикшереп торды бит ул аның тасмаларын. Әле бая, ачык калган җирен томалап чыгып киткәндә дә, тартып карады. Әллә теге, минем урында эшләгән кызылармеец, Алексей дәдәгә үч итеп?.. Алай дисәң, ничек керсен ди ул монда? Бу йозакны бит Алексей дәдә ул киткәч әллә кайлардан эшләтеп алып кайтты. Ачкычын да кеше уйлап чыгара торган түгел. Беркемгә дә күрсәтмибез бит без аны... Әллә инде Алексей дәдә мине сынар өчен?.. О, юк, мондый нәрсә белән шаяртмыйлар... Әллә Алексей дәдә беркөн госпиталь начальнигы сөйләгән шпион шикелле... Һай, буламы соң... Хәлим шулай уйлана-уйлана, маскировканың тасмасын кулына алды.

Нәкъ шул чакта коридордан тиз-тиз атлап килгән аяк тавышлары ишетелде.

Бу повар иде. Ул, ишекне бәреп керде дә, калтыранган тавыш белән Хәлимгә эндәште:

— Хәлим, синме биредә?

— Мин.

— Тагы өзелгәнмени?..

— Әйе.

— Ах, шайтан икән!..

Хәлим поварның тавышында курку белән каушау гына түгел, әллә нинди яшерен усаллык ноталары да ишетте. Аның күңелендә хәзер «Әллә Алексей дәдә беркөн госпиталь начальнигы сөйләгән шпион шикелле кешеме?..» дигән шик өстенлек ала башлаган иде.

Хәлим саклык өчен артка чигенде.

— Самолетлар тавышы ишетелми әле, тиз генә тасмасын тагып алыйк,— диде повар һәм, капшанып килеп, включательне борды. Кухня эче күзне чагылдырырлык көчле якты белән тулды.

Хәлим (башына күсәк белән суктылармыни) чайкалып куйды.

— Ярамый... сүндерик, Алексей дәдә.

— Мин аның тасмасын хәзер тагып алам...

Повар маскировка тасмасын тотып нишләргә белми торган Хәлимгә таба килә башлады. Хәлим куркуыннан тасманы кулыннан төшереп җибәрде.

— Ярамый, сүндерик!— дип кабатлады ул. Һәм, чигенә-чигенә килеп, включательне борды. Ут сүнде. Кухня көчле яктыдан соң баз эче кебек караңгы булып калды. Повар шул ук секундта (менә сиңа кирәк булса!) тавыш-тынсыз гына Хәлимгә ташланды. Хәлим, вакытында сизеп алып, бер читкә атылып китте. Повар, бер селтәнүдә килеп җитеп, включательне борды. Көчле ут яктысында Хәлим поварның беренче тапкыр шундый ерткыч күзләрен күрде. Повар кулында хәнҗәр, әле күптән түгел генә чәчкә кабарлык итеп Хәлим үзе кайрап биргән хәнҗәр, ялтырап китте.

Малай ачы тавыш белән кычкырып җибәрде һәм өстәл артына атылып барып керде. Җебеп торырга ярамый. Әнә шәһәр читендәге зениткалар ата да башладылар инде. Димәк, үтеп керә алганнар... Тәрәзәдән төшкән утка карап, бик тиз килеп җитүләре мөмкин... Никадәр яралы солдатны, әтисен дә, үзен дә, күршедәге заводны да... Хәлим, өстәл артына керүенә стенада эленеп торган су чүмечен алып, лампочкага ыргытты. Ут сүнде. Бер үк

вакытта лампочка китекләре чүмеч белән бергә идәнгә коелып төште.

— Ах син, рус көчеге!..

Бу сүзләр белән бергә Хәлимнең битенә поварның сулышы килеп бәрелде. Хәлим өстәлдә яткан пычакны, повар рус теленнән беренче көн дәрес биргәндә «нож» дип күрсәткән, кайрый-кайрый йөзе тараеп беткән озын пычакны, кулына алды. Һәм повар өстәлнең бер башыннан килгәнче, икенче башыннан йөгереп чыгып:

— Үтерә, үтерә!..—дип кычкыра-кычкыра ишеккә ташланды. Ишек бикле иде. Хәлим плита өстенә сикереп менде. Повар да Хәлим артыннан плитага сикерде. Хәлим пычакны поварга ыргытты. Пычак поварның кай җиренәдер килеп тиде. Ул бик аз гына туктап торды да инде идәнгә төшкән Хәлим артыннан сикерде. Башка чара калмаган иде Хәлимгә, ул йөгереп килгән уңайга, пыялаларын башы белән сөзеп, бөтен тавышына кычкыра-кычкыра, тәрәзәдән тышка сикерде һәм дүрт почмаклы эре таш җәелгән, такыр итеп себерелгән ишек алдына килеп төште. Торып йөгермәкче булды ул. Ләкин тору түгел, тезләнә дә алмады. Әз генә кузгалуга аякларының сызлавына чыдаша алмыйча хәрәкәтсез калды.

Ләкин малайга биредә бер секунд та торырга ярамый иде. Поварның Хәлим өстенә сикереп төшүе, сикереп төшкәч хәнҗәрен Хәлимнең йөрәгенә чәнчүе мөмкин. Ул чакта кем үтергәнне дә белми калачаклар. Поварның усал ниятләре ачылмый калачак. Алай гынамы соң! Поварның гаепне Хәлим өстенә аударуы мөмкин. Аның: «Хәлим маскировка җепләрен өзеп чыгып бара иде, ярый әле, кереп җиттем...» диюе бик мөмкин...

Курку Хәлимгә көч бирде. Ул, һуштан яздырырлык итеп сызлаган аякларын өстерәп, ялан куллары белән салкын ташларга ябыша-ябыша шуыша башлады. Бертуктаусыз ярдәм, ярдәм дип кычкырды ул. Ләкин зениткалар шулкадәр еш аттылар, алар Хәлимнең тавышын томаладылар. Аның кычкырганын госпитальдәге яки бомбоубежищедагы кешеләр түгел, түбәдә постта торган ПВХО солдатлары да, капка төбендәге часовой да ишетмәде.

Хәлим тәрәзә турысыннан биш-алты адым шуышкач, бераз тынычланып, артына әйләнеп карады.

— Повар сикерми әле...

Повар сикермәде. Ул, баскыч буенча төште дә, стенага ышыклана-ышыклана, капкага таба китте. Хәлим дә, аны күреп, капкага таба борылды. Һәм бая үзе чыгып-кереп йөргәндә капка төбендә постта торган часовойның исемен әйтеп кычкыра башлады:

— Платон агай!.. Поварны чыгармагыз, Платон агай!..

Хәлимгә җавап кайтаручы булмады.

Бу вакытта повар капкага якын иде инде.

Платон агай, мылтыгын кочып, толыбына төренеп капканың юан имән баганасына ышыкланып торган часовой, поварны күрүгә селкенеп куйды. Часовой хәзер капканы ачачак та, поварны чыгарып җибәрәчәк...

Хәлим, булдыра алган кадәр көчле итеп, кычкырып җибәрде. Часовой тагы ишетмәде.

Менә повар капка төбенә килеп җитте. Часовой аның каршысына чыкты.

Кая барасың дип сораштыра башлады, күрәсең. Озаграк сораштырса гына ярар иде.

Ләкин часовой озак сораштырып тормады. Мылтыгын бер кулы белән кочты да, икенчесе белән толып чабуын кайтарып, чалбар кесәсенә тыгылды.

Ачкыч ала... Бар да бетте...

Юк, бетмәде... Хәлим кулларына таянып тезләнде. Ләкин, әйтерсең лә берьюлы бик күп инәгә тезләнде, авырту бөтен тәненә, йөрәгенә китте. Хәлим, шуңар да карамыйча, аякларына басты һәм бик әче итеп сызгырып җибәрде. Часовой борылып карады. Хәлим үзенең ак алъяпкычын тартып өзеп селкергә керешә, ләкин артык басып тора алмыйча салкын ташка авып төште һәм, әз генә дә тынып тормыйча, тагын капкага таба шуыша башлады.

— Әй, кем анда?

Хәлим часовойны ишетмәде. Хәлим өчен повар җавап бирде:

— Минем помощник. Мәзәк тә малай инде, шайтан алсын үзен!.. Мин кладовойга төшкән арада, шүрлектән портвейн алып эчкән. Күр әнә, аягына да басып тора алмый...

Часовой көлеп җибәрде. Повар да кычкырып көлде һәм, капкадан чыгып китәргә ашыгып, кабалана башлады. Ләкин часовой ашыкмый иде.

Ул:

— Нәрсә әле сез шушындый чакта бертуктаусыз керел-чыгып йөрисез? — дип сораштыра башлады.

Бу вакытта Хәлим дә капкага якын иде инде.

Ул:

— Чыгармагыз сез аны... чыгармагыз,— дип кычкырды.— Чыгармагыз, Платон агай!

Часовой тагын көлде:

—Ә син, исерекбаш, бар тизрәк бомбоубежищега төшеп ят,— диде ул һәм сырган чалбар кесәсеннән зур ачкыч алды.

Хәлимнең эче жу итеп китте. Ул мөмкин кадәр тизрәк шуышырга тотынды.

— Ник исерек дисез сез мине? Мин исерек түгел. Мин кухнядан сикергәндә аякларымны авырттырдым. Алексей дәдә үтерә башлагач, сикереп төштем мин кухнядан...— диде ул.

Часовой тагы да хозуррак итеп көлеп җибәрде.

— Ай да малайка! Ай да Халимушка!..

Ә повар, Платон агайга ияреп көлә-көлә, тиз генә Хәлим янына килде һәм ярым житди төскә керде:

— Ә син бар, туганкай, кереп ят, йә үзеңне бомба эзләп табар,— диде ул, үгетләгән булып кыланды. Һәм:—әйдә, мин сине илтеп куйыйм,— дигән булып, Хәлимнең беләгеннән тупас тотып алды да кирегә өстери башлады. Шул рәвешчә часовойдан читкә алып китәргә дә, хәнҗәр белән йөрәгенә кадап, эшен бетереп ташларга уйлады. Ләкин Хәлим бирешмәде.

— Китегез! Җибәрегез!— дип кычкырды ул һәм поварның кулын тешләп алды. Повар түзде, кычкырмады. Ә шулай да кулын Хәлимнән алды. Хәлим бөтен көчен җыеп тезләнде. Күтәрелмәкче булып дүрт аякланды. Ләкин шунда ук авып төште дә булдыра алган кадәр көчәнеп, тагын капкага таба өстерәлергә тотынды. Инде өстерәлерлек тә хәле калмагач, тәгәрәп бара башлады.

— Менә бит ул аракы дигәнең кешене нишләтә... Әле генә нинди чибәр егет иде...— дип сөйләнә-сөйләнә повар тагын Хәлимне артка өстерәү өчен иелде.

Бу вакыт Хәлим зур ачкычны капканың зур йозагына тыгып инде тагын бер тапкыр борырга өлгергән часовой янына килеп житте һәм, аның аякларына, зур соры итекләренә ябышып, елап җибәрде:

— Нигә сез миңа ышанмыйсыз? Карап итәсез бит!.. Дошманны качырасыз, Платон агай!..— диде ул, кайсын русча, кайсын татарча әйтеп.

Часовой Хәлимгә таба иелде. Әллә нәрсәгә түгел, исерек малайны күтәреп алып, үзенең будкасына кертеп салырга дип иелде, һәм аның авыз-борынында кан, өстерәлеп килгән юлында сузылып калган кан эзләрен күргәч, тәэсирләнә калды:

— Тукта... Тукта...

Хәлим часовойны ашыктырды.

— Качырасыз... качырасыз!.. Тотып алыгыз, кулын күтәртегез сез аның, Платон агай!.. Наганы бар аның, Платон агай!— диде Хәлим, хәлсезләнгәннән-хәлсезләнә барып. Һәм, часовой Хәлим өстенә иелүгә, ачкычны икенче кат үзе борырга өлгергән, инде капканың чылбыры астыннан чыгып китәргә дип иелгән поварның аягына чытырдап ябышты. Повар, тагын көлгән булып, Хәлимнең кулларын ычкындыру өчен иелде. Шул вакыт Хәлимнең исерек түгеллегенә ышанып җиткән, повар турында шикләнә калган часовой аның кулыннан эләктереп алды:

—Туктагыз әле... Бер генә минутка...

Повар, часовойдан көч белән ычкынып, урамга ташланмакчы булды. Ләкин Хәлим аның аягын җибәрмәде, поварның гәүдәсе урамга егылды, аяклары ишек алдында калды. Часовой ачуланып, мылтыгын ике кулына алды һәм штыгын поварның бугазына терәр-терәмәс:

— Тукта! — диде.

Һәм поварның кесәсеннән наганын алырга дип сузылган кулына итеге белән басты.

— Күтәр кулыңны!

Повар чалкан яткан килеш сыңар кулын күтәрде.

Нәкъ шул чакта өстән, тешли алмый калган эт шикелле усал улап, немец бомбардировщигы узып китте.

Икенче кисәк

1

ИСӘНМЕ, АВЫЛ!

Хәлим, тау читенә килеп җиткәч, туктап аска карады. Аста, куе караңгылык эчендә, авыл җәелеп ята. Хәлимнәр авылы. Ул кичерәеп киткән кебек, йортлары бер-берсенә тегелеп җиргә сеңгән кебек. Тын. Бер генә тавыш та килми авыл ягыннан. Этләр дә өрми хәтта. Бер генә өй тәрәзәсеннән дә, эчендә җан иясе барлыкны белдереп, ут балкымый. Сукыр лампа яктысы да төшми тәрәзәләрдән. Төндер шул инде. Хәлим поездан төшкәндә үк караңгыланып килә иде бит. Ә аның авылга кичкырын, морҗалардан ишелеп төтен бөркелгәндә, колхозчылар, идарә кызлары эштән кайтканда, карчыклар, бала-чагалар көтүгә каршы чыкканда, кайтып керәсе килгән иде, булмады...

Госпитальдә булган вакыйгадан соң Хәлим алты ай авырып ятты. Бары кызулыгы белән, балалыгы белән генә «повар» артыннан шуышып йөри алган икән, тәрәзәдән сикергәндә аның бер сыйрак сөяге чатнаган, икенче аягының тез капкачы зарарланган булган. Аны өч ай буена кыл кыймылдатмый гипста яткырдылар.

«Повар»га килсәк, аны атарга хөкем иттеләр. Хәлим, теләсә дә, аның судына бара алмады. Суд кешеләре үзләре Хәлим янына килеп «повар» турында сорашып киттеләр. Бу вакытта Зиннәт абзый аягына баскан иде инде. Ул судтан кайткач Хәлимгә барысын да сөйләп бирде.

«Повар» немец булып чыга. Сугыш вакытында төрле корткычлыклар эшләү өчен Гитлер Советлар Союзына үзенең күп кенә кешеләрен җибәрә. «Повар» да шундыйлардан була. Ул, Балтик буендагы шәһәрләрнең берсендә поварлар курсын бетергән рус кешесе

булган булып, чиккә якын гына бер кечкенә бистәгә килә һәм шундагы бер ашханәгә кереп урнаша. Менә сугыш башланып китә... Атна-ун көн дигәндә фашистлар бу бистәгә керәләр. «Повар», аныңча совет кешеләре белән бергә, эвакуацияләнеп өлгерә. Һәм Германиядә вакытта ук үзенә билгеләнгән әлеге шәһәрдә туктап кала. «Минем улымны, әти-әниемне фашистлар газаплап үтерделәр, хатынымны кол итеп Германиягә алып киттеләр,— ди ул хәрби комиссариатка килеп,— мине фронтка җибәрегез, мин алар өчен үч алырга телим». (Ул бу сүзләрне фронтка җибәрмәсләрен белеп әйтә. Советлар Союзына килгәч, сугышка алмасыннар өчен аның ике бармагы Германиядә үк киселгән була.) Елый-елый ялына торгач, «поварны» нестроевой хезмәткә алалар һәм, үзенең теләге буенча, әлеге госпитальгә повар итеп җибәрәләр. Бу госпитальдә йөзләрчә сугышчы дәвалана. Күбесе командирлар. Берничәсе Советлар Союзы Герое. Әзме фашист башына җиткәндер алар, әзме фашист башына җитәчәк алар... Юк, җитмәсеннәр әле. Менә мин хәзер үзем аларның башларына җитәм...— дип хыяллана «повар».

Ул ашларны тәмле итеп пешерә. Шуның өстенә җәмәгать эшләренә дә актив катнаша. Госпиталь башлыклары каршында авторитет, авырулар арасында ихтирам казана. Мөлаем, һәрвакыт кайгыртып торучан поварны сестралар да, техник эшчеләр дә яраталар. Ул аларга совет информбюросының белдерүләрен укый, сугыш хәлләрен сөйли. Үзенең семья кайгысы турында сөйләгәндә ул күз яше белән елый. Тыңлаучылар аны кызганалар, аңа тагы да җылырак карый башлыйлар... Шул ук вакытта повар госпитальгә үлем хәзерли, күршедәге хәрби заводка үлем хәзерли. Бу — аның өчен читен эш түгел. Йөзләрчә совет сугышчысының башына җитү өчен, фронттагыча әллә ничә мең пуля атып торасы юк. Шәһәр күрке булган госпиталь бинасын һәм фашистларга үлем әзерләүче заводны җир белән тигез итү өчен йөзләрчә кеше кушасы юк. Берәр «миссершмит»ның үкерүе ишетелә башлау белән, кухня тәрәзәсендәге маскировканың җебен генә өзеп җибәрәсең, лампочканы ике тапкыр берәр секундка сүндереп торасың да, яндырып калдырасың. Бу — һава разбойниклары телендә: «Бомбаларыңны шушында яудыр!» дигән шартлы сигнал. Бомбардировщик бу сигналны күрүгә

хәзер килеп җитәчәк... Тик менә ярдәмчесе үтә сизгер кеше. Повар өчен әнә теге авыл малае кулай булыр иде...

Ләкин, укучыга мәгълүм булганча, исәбендә ялгыша повар. Һәм әнә нинди хәлләр булып үтә...

...Хәлимнең батырлыгы госпитальгә генә түгел, бөтен шәһәргә таралды. Бу кыю, курку белмәс татар малаена солдатлары шушы госпитальдә дәваланучы хәрби частьләрдән рәхмәт хатлары килде. Аны «Батырлык өчен» медаленә тәкъдим иттеләр.

Озак та тормыйча Хәлимнең этисе, шундый ул үстерүе белән горурланып, фронтка китте. Ә Хәлимгә, шулай да, фронтка бармаска кушты...

— Колхозга кайт, улым. Бүген әле син анда файдалырак,— диде ул.— Тагы укуыңны онытма. Арслановлар нәселеннән дә бер галим чыксын әле. Әйе, әйе. Кимендә — агроном. Бәлки бу минем соңгы теләгемдер... Үтә син аны... Кил, сугыш хәлен белеп булмый, үбешик бер...

Госпиталь начальнигы да Хәлимне колхозына, энисе янына, мәктәбенә кайтырга үгетләде:

— Мин синең армиядә хәзердән үк файдалы булуыңа шикләнмим. Ләкин син әле бүген анда файдалырак,— диде ул.

Хәлим сәламәтләнеп чыкты да, этисенең һәм начальникның сүзләрен тыңлап, райком секретареның сүзләрен хәтерләп, өенә кайтып китте.

Менә хәзер, авылына кайтып җиткәч, энисеннән качып китүләре, урманда кунулары, поездда барулары, госпитальдә булган вакыйга — барысы да, барысы да бик күптән күрелгән төш кебек кенә булып калдылар.

Хәлим, шинель итәкләрен җыеп тотты да, яңгыр шомарткан текә тар сукмак буйлап таудан төшеп китте. Поездан төшкәндә генә кигән яңа итекләрен буямас өчен, җиргә сакланып кына басты ул. Сакланып басты, ләкин итекләре барыбер буялды. Чөнки ашыкты, кашады ул, тиз-тиз атлады. Ә аның үзенә бөтенләй алга бармый, гел бер җирдә таптанып тора кебек тоелды. Күпергә бая ук кергән иде бит инде ул, әле һаман да шул күпердән бара. Нинди бетмәгән күпер булды соң бу!?.

Хәлим йөгерергә тотынды.

Әнә янгын каланчасы, клуб, силос башнясы. Әнә басу капкасы, тимерче алачыгы, кое сиртмәсе... Фәрхиназ җиңгиләр, Гөлчәһрәләр, Каюмнар, Гөлгенәләр, менә — без...

Хәлим капка бигеп борды. Абына-сөртенә өй буен йөгереп үтте. Ә өйалдына кергәч, малай тәмам каушады: ишек шакырга ул әле уң кулын күтәрде, әле сулын. Аннары икесе белән берьюлы дөбердәтергә тотынды.

— Кем бар?

— Мин, әнием... Әнием, ач!..

— Ай аллам, Хәлим, син түгелме соң?..

Ана, улын тавышыннан танып, ишекне ачып җибәрде.

Ул Хәлимне, кечкенә вакытында суга баткач, коткарып алып кайтып килгән этисе кулыннан алган шикелле күтәреп алырга уйлаган иде дә, аның инде егет булып килгәнен, баштанаяк гаскәриләрчә киенгәнен күреп, бераз вакыт нишләргә белми торды, аннары үзе аның кочагына ташланды.

— Төшем генә булмаса ярар иде, ходаем... Өнемдәме мина шундый шатлык, ходаем!..

Хәлим әнисенең җылы сулышын сизде. Чиксез дулкынланудан тигезле-тигезсез типкән йөрәген сизде.

— Әнием, әни... Елама инде, әни... Хәзер мин беркая да китмим, әни... Син елагач минем дә елыйсым килә башлый, әни...— диде Хәлим һәм анасын тынычландырырга теләп, әле битеннән, әле чәчләреннән үбәргә тотынды.

Ана улының кайтканына шунда гына ышанып җитте. Кайгы гына түгел, шатлык та елата йомшак күңелләрне. Шәмсия җиңги тагын үксеп елап җибәрде.

Берникадәр вакыт үткәч, күзләрдә беренче яшьләр кипкәч, табын җәелде. Табын искәрмәстән кадерле кунак килеп төшкәндә генә чыгарыла торган татлы ризыклар белән тулы иде. Хәлимнең бер елдан бирле күргәне булмаган табын күрке самовар да өстәлгә менеп утырды. Капкач читләреннән пар бөркелә, тишекләрендә утлы күмер. Үзе шундый күңелле җырлый...

— Әйдә, житеш әле, улым.

Шәмсия апаның бу сүзне улына беренче тапкыр әйтүе иде. Ул Хәлимгә башта сәер, ят тоелды, кабат

шул ук сүзне әйтеп кыстагач, Хәлим үзе дә кунакларча җавап бирде:

— Җитешәм, әни,— диде ул һәм, кара, онытып тора икән ич... Чемоданын ачып, үзенең юл күчтәнәчләрен чыгарды. Консерв, пряник һәм зур-зур шакмаклы күгелҗем шикәрләрне әнисе алдына китереп өйде.

— Менә үзең дә җитеш, әни.

Бусы ана өчен шатлык өстенә шатлык иде.

— Ай, бәгърем, ай, җаным!..— Ана нишләрен, ни әйтерен белмәде. Чиктән тыш шатланып битен улының битенә куйды.

— Мин сине күреп тә тук инде, улым. Бер дә күрер төсле түгел идем...

— Менә күрдең инде.

— Ай, күңелем һаман ышанып бетми әле.

— Һе.

— Буй тарткансың, тазаргансың, улым, күз генә тимәсен...

— Ә син ябыккансың, әнием, кечерәйгәнсең дә дип әйтимме...

Хәлим, хатларында язган булса да, этисе белән ничек очрашуларын, госпитальдә булган вакыйганы сөйләде. Сөйләгәндә әнисенең күзләрендә яшь күренә башласа, сүзен икенчегә борып, берәр шатлыклы хәбәр әйтеп куя иде.

— Хатны укыгансың инде, әти терелеп чыкты, тагы фронтка китте. Ай-яй, ул хәзер... Герой ул безнең әти!..

— Исән-сау гына йөри күрсен инде, улым. Хафиз абыеңнан да бүген хат килде. Тик менә нәни абыең гына...

Ана әйтеп бетермәде, ул әле Хәсәпе турында, ни өчендер Хәлимнең кечкенә генә, бик-бик кечкенә генә булса да өметле сүз әйтүен көтә иде. Ләкин Хәлим андый сүз әйтмәде. Иреннәренә китергән чәен өстәлгә куйды да, тиз басып, Хәсән абыйсы исенә төшкән саен әйтә торган сүзләрен кабатлады:

— Мин синең өчен үч алырмын әле, абый. Бик каты итеп, Гитлерның күзләре акаерлык итеп алырмын үчне!..— диде, аннары утырды да, әнисенең хәсрәтле уйларын тарату өчен, куян вакыйгасын сөйли башлады:

— Без, әни, барышлый куян атып ашадык бит әле... Менә ничек булды ул...

Хәлим кечкенә шүрлеккә, китап-дәфтәрләре янына килде. Үзеннән ничек калган — шулай торган. Өсләрендә тузанның әсәре дә юк иде. «Әни карап торган», дип уйлап алды Хәлим һәм һәрберсенә күз йөртеп чыкты. «Монысы онытылган, монысы исемдә...» дип сөйләнәсөйләнә, китапларын сумкасына тутырды. Кара шешәсе ачык торган икән, карасы кибеп беткән иде, самовар борыныннан кайнар су агызып болгатты да язып карады. Канәгатьләнеп сумкасы янына бәйләп куйды. Һәм инде яшьләре кипкән, ак яулыгын арттан бәйләп, куанакуана, Хәлимемә иртәнге чәйгә өлгертим дип коймак изеп йөргән әнисеннән авыл хәлләрен, колхоз хәлләрен, мәктәбен, иптәшләрен сораштырды. Бик күп сөйләде инде әнисе, ә Хәлим һаман да тыңлап туймады.

— ...Колхозда эшләр бик үк мактанырлык түгел, улым, колхозыбыз ябыгыбрак китте әле,— диде Шәмсия җиңги.— Колхозыбыз колхоз гына түгел иде... Шул килеш күтәреп ал да күргәзмәгә илтеп куй,— шундый иде бит безнең колхоз.

— Эшләү начар булгандыр, әни...

— Түгел... Дөрес, былтыргысын әйтер хәлем юк, бик әйбәттән булмады. Былтыр минем ишеләрнең күбрәк вакыты елауга китте. Ә быел тырыштык инде, улым. Шул калган кеше белән дә бит хезмәт көне кырыгынчы елгыдан күбрәк эшләнде.

— Уңмадымыни?

— Уңмады шул. Арышның бик күбесен боз сукты... Дөрес, солы, борчак, арпага сүз әйтерлек түгел иде дә, бодай начар булды.

— Тәрбия җитмәгәндер, әни.

— Инде, улым, аңар кергән тәрбия, аңар куйган көч... Сирәк тишелде.

— Нигә икән?

— Кем белә аны... Агрономнар да әйтә алмады.

Аннары Шәмсия җиңги Хәлимгә шатлыклы яңалыкны белдерергә ашыкты:

— Мәктәбегезне салып бетерделәр. Әй матур да булды соң.

— «Мәктәп... ә мин нишләрмен... Мин бит... ай, нишләрмен инде мин?.. Яңадан бишенчегәме, бот буе балалар арасынамы? Юк!.. Хурланмыйча алар белән укыйммы соң!.. Алтынчыга керәм. Ничек тә тырышырмын. Йокламасам йокламам, ләкин Каюмнардан калыш-

мам...» — Хәзер Хәлим теле белән әнисенең сорауларына җавап бирә, ә күңеле шул турыда гына уйлый иде.

Шәмсия җиңги олы кунаклар килгәндә генә кузгатыла торган мамык түшәкне өйалдыннан алып керде дә кабарта-кабарта түр як сәкегә җәйде. Инде йоклап китәргә җитеп изрәп утырган Хәлимне шунда яткырды, өстенә йомшак мамык юрган япты.

— Йокла, улым, йокла, күз нурым...

Улының йомылган күзләренә, бер-берсенә кушылыр-кушылмас торган, әз генә бөтерелеп үскән нечкә кара кашларына, ябылыр-ябылмас калган калың керфекләренә карап утырды ул. Озынчаланып киткән алсу яңакларын йомшак кына сыйпады. Арыганчы, күзләре талганчы утырды ул шулай. Тышта беренче әтәч кычкырды. Шәмсия җиңги юрган аша сакланып кына Хәлимне кочып алды да тагын күз яшьләренә ирек бирде...

— И улым, и күз нурым!..

2 ХӘЛИМ КАЙТКАН, МАЛАЙЛАР!

Хәлим, табада беренче коймаклар чыжылдаган тавышка уянып, күзләрен ачты. Гөжләп янган мич, хуш исле карабодай коймагы, ап-ак алъяпкычлы әни, алъяпкычыннан да саф йөрәге, якты чырае, тәрәзә араларындагы кызыл башлы сөлгеләр, тырышып агартылган җиз самовар... Анда, ерак көнбатышта, Украина далаларында дәһшәтле сугыш барганга ышанасы килми, меңнәрчә аналарның баласыз, ун меңнәрчә балаларның ата-анасыз калуларына, адәм каны елга булып агуга, гасырлар үстергән калын-калын урманнарның, халыкның маңгай тирләре белән төзелгән шәһәрләрнең хәрабә хәленә килүләренә ышанасы килми. Ил эчендә яу булса, өй эче болай ямьле, болай тыныч булмас иде кебек. Чиккән сөлгеләр, гамьсез җырлап утырган самовар, ак алъяпкычлы әни, аның якты йөзе, карабодай коймаклары — болар барысы да, барысы да тыныч тормыш билгеләре ич! Станциядә бомбежка, дөрләп янган санпоезд, кайры тунлы әби, госпиталь, яралы әти, гранаталы Петя, шаян Женя, Женялар мәктәбе, Хәсән абый, аның кебек миллион-миллион корбаннар — төш кенә идеме әллә, югыйсә!..

Юк шул. Әнисенең якты йөзенә текәлебрәк кара әле, Хәлим. Әнә никадәр авыр кайгы эзләре яшеренгән аның йөзендәге шатлык күләгәсенә! Кичәге мәрмәр ке-

бек шома маңгаенда тирән җыерчыклар, карга канаты кебек җете кара толымнарында ак бөртекләр... Ә бит урталарындагы җәйге таң шәфәгы кебек алсулык кая киткән?.. Ой,ниләр генә эшләтмәде бу сугыш! Нинди ямьле, ничек зәвыклы иде бит яшәү! Язгы сабантуйлары, бәйрәмнәр, бәйрәмдәй шат-рәхәт хезмәт... Һәр яңа гектар, элеваторга озатылган, колхозчы бурасына кергән һәр өстәмә килограмм өчен, һәр кагылган казык өчен сөенеп йөргән эти... Кичтән бирелгән нарядларның үтәлешен тикшереп, кузгала алмый торганын кузгатышып җибәреп, үз теле белән әйтсәк: колхозны бер кат айкап кайтып керә иде ул көн дә шушы вакытта. Зур. Таза. Башы түшәмгә тияр-тимәс, басканда идән такталары сыгылып керә. Күңеле күтәренке. Сүзләре дә шундый чакта әйтелә торганнар: «Кая, анасы, нәрсәң бар? Тере чучка баласын тоз сипмичә кабып йотарга җиттем»,— ди иде ул. Аннан мич авызына иелә иде дә, табадагы яңа күпереп менгән, өсте кызарып торган кабартманы җилдә ярылган юан бармаклары белән чеметеп алып, учактагы кайнап торган сары майга манып, шапыр-шопыр кабып йота иде.

— Чү, тәкатьсез булма ул хәтле, хәзер табын әзерлим,— ди иде Шәмсия апа. Моны ул битәрләп түгел, өйрәнелгән гадәт буенча гына әйтә иде. Зиннәт абзыйның бу түземсезлеген хәтта хозур күрә иде бугай әле ул. Табын җәелеп, Хәсән белән Хафиз торып чыкканчы, Зиннәт абзый Шәмсия апага үзенең планнары турында сөйли-сөйли бит-күзен юа иде.

— Быел электростанция белән радиога тырышырга исәп, анасы. Аннан фонтан турында да уйлый башларга вакыт. Самовар куйган саен чиләк күтәреп чишмәгә йөгерү эш түгел. Краннан гына агызып ала торган булсын, шәһәр җирендәгечә.

Ул да түгел, әле бер, әле икенче бригадир килеп керә иде. Я завхоз, я тегесе-бусы, счетовод...

— Зиннәт абзый, нишлибез? Без теге Шакир солдат үзәнендәге бүген урылачак бодайны исәпкә алмаганбыз икән. Трудденьгә тагы бер килодан өстәлә болай булгач. Әллә халык белән сөйләшәсеңме? Яшьләр оркестр даулый бит.

— Белеп даулыйлар,— ди Зиннәт абзый.— Бәйрәм саен «Илшат»ларга ялыну эш түгел. Большой театр итик әле шул клубны, Мостафа!.. Нигә? Бер дә көлмә, ана-

сы... Өйрәтүенме? Һи-һи... Анысы хәзер анык. Инструменты булсын да, үзешчән Йосыфка исәнлек бирсен.

Ул да түгел, берәр күрше хатын керә.

— Бик яхшы булды, Зиннәт үзе дә өйдә икән әле, белеп китәр. Бүген, Шәмсия тугани, нәрәттән соң безгә, алла теләсә. Юк, юк, авызыңны да ачма, Зиннәт. Чәчкннән өстерәп алып керәм. Телеграм килде. Хәйдәр кунакка кайта. Юк, әллә кем булмый, Хәйдәр янына гына... Кем? Бер көе йөреп тора, шунда. Тәкә суеп калды әле.

Хәлим «гына»га өстәлгән тәкәнең мәгънәсен аңлый. Хәйдәр абзый янына ярты авыл җыйналачак. Әтиләр таң атканда гына кайтып керәчәк. Бүген әтинең йокысын коедан алып коенган ике-өч чиләк салкын су белән бер әбәт чиләге ипи куасы алыштырачак... Хәлим шуларны хәтерли дә, ай, төш кенә булсачы бу сугыш!.. ди. Менә хәзер әти, гәүдәсен ия төшеп, бусагадан атласачы тузанлы зур итекләре белән. «Ә минем Хәлим кайда әле?.. — Тормаган? — Әйт, торсын. Так и быть, быел Мәскәүгә, авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә алып барам үзен. Безнең колхоз күргәзмәгә катнаша быел, анасы»...

Хәлим, хискә бирелүдән куркып, хыялын икенчегә борды. Сәгать 6. Ә нигә караңгы? Һәм шунда ук, тәрәзәләрнең кайсында ашъяулык, кайсында калын шәл, кайсында капчык күреп, елмаеп куйды.

— Маскировка... Әнием, сездә дә маскировка бар икән. Нигә аны бу көнгә хәтле тотасыз?

— Бәй, ничек тотмыйк... Пожарный Сабир карап кына йөри аны. Кояш баюга корып өлгермәсәң, кояш чыкканчы алсаң, штраф дип хәзер кереп җитә.

— Һәй, пүчтәкне,— диде Хәлим һәм торып маскировкаларны сыдырып төшерде. Шәмсия җиңги куркып Хәлимгә карады.

— Ничего! Белми ул Сабир абый. Үзем сөйләшермен мин аның белән,— диде Хәлим һәм киенергә тотынды.

— Ят әле, улым. Бик аз йокладың ич.

— Житәр, әни. Без күп йокларга өйрәнмәгән.

— Абау-ау...

— Сугыш беткәч йокларбыз, әни,— диде Хәлим һәм аягына итекләрен киде, шинелен иңнәренә салды да ишек алдына чыкты. Баскыч төбендә җим көтеп

торган тавыклар, Хәлимне күрүгә: бу нинди ят дигәндәй, пырхылдашып як-якка сибелделәр. Казлар кыйгылдашып алды. Ә карт сыер, ахрысы, таныды: муенын сузып, башын артка ташлап ялкау мөгрәп куйды.

Хәлим урамга чыкты.

Авыл, авыл! Ул да әүвәлгечә үк тын, әүвәлгечә үк тыныч! Самолетлар очмый күгендә, зениткалар атмый котырып. Һәрнәрсәсе ничек булган — шулай калган. Һәр күздәгечә жиргә, к^нау кырыйларындагы әле саргаеп өлгермәгән үләннәргә, кук чәчәкләргә, шиңгән бака яфракларына, коелып калган салам бөртекләренә кырау төшкән. Кырау өй түбәләрен, бакча рәшәткәләрен көмешләгән. Еракта, авыл башында, көтүче Габделмән бабай моңлы итеп быргы уйный. Капкалардан, ялкау атлап, беренче сыерлар чыга, сарыклар... Әнә Хәтирә әби. Кәҗәсен чыгарды да, үзе шикелле үк бөкре таягына таянып, Хәлимне карый-карый, үтеп китте. Танымады. Хәлим дә эндәшмәде. Сөйләшә-сораша башлар, улымны күрмәденме дияр, кеше җыелыр... Кичен Хәлим үзе берәр шакмак шикәр белән берәр салырлык чәй алып кереп чыгар әле...

Хәлим өйгә керде дә күлмәген салып бил тиңентен юынды. Әнисенең теләге — Хәлимгә чәйне озаклап эчерү булган күрәсең, табында коймак күп, самоварның зурысы иде. Тансыклаган икән, Хәлим кыстатмады. Тамагы гына түгел, күзе дә туйгач кына торып китте. Әй, ана, ана! Аның әле һаман ашатасы, сыйлыйсы килә иде.

— Бу нишләвең, ашамадың ич!..

— Рәхмәт, әнием. Булды,— диде Хәлим һәм, сумкасын алып, китапларын карарга тотынды.

— Я, куй әле, улым, шул китапларыңны, сөйләшеп утырыйк бераз.

— Кайткач, әни. Мәктәптән кайткач, яме, әнием?

— Әбәү, берәр атна да ял итмичә, нинди мәктәп ди әле ул?..

— Ә, юк, әни, әле дә инде мин... Мин, әни, теге якка кереп укый торыйм әле...

Шәмсия җиңги төне буе керфек какмыйча әзерләгән сый-хөрмәтеннән кайберсен улының авыз да итмәвенә җәберсенсә дә, аның укырга хиресләнеп кайтуына сөенә иде. Ул табынны кече якка күчереп, Хәлимгә өстәлдә урын бирде.

— Ашыйсың килгәндә кереп ашарсың, алайса. Менә биргә куям, улым...

Авыл уянды.

Өй түреннән урам тутырып көтү үтте. Таш юлда тимерле арба, дага тавышлары ишетелде. Урамда әрле-бирле кешеләр йөрергә тотынды. Балалар, шау-гөр килеп, берсен-берсе әйди-әйди, мәктәпкә киттеләр. Кепка козырегын һәрвакыттагыча борынына кадәр төшереп, кантар тибә-тибә, бакыр чәчле Каюм узып китте. Түбән очкан торналарга этен өстерә-өстерә, Җәләй йөгереп үтте. Өй түрендәге миләшкә кунган чыпчыкларга рогатка төзәп, сак атлап, Мотыйк узды мыштым гына. Сумкаларын күкрәкләренә кысып, тату сөйләшеп, беренче класслар — Фәтхели белән Әптери узды. Шарык-шорык көлә-көлә игезәк кызлар Гөлчәһрә белән Гөлзәһрә узып китте. Тышта шактый суык булуга карамастан, ак яулыкларын арттан бәйләгәннәр. Чәч толымнарына үргән кызыл ленталары, бертуктаусыз ялт-йолт карап барганлыктан, яулык асларыннан чыгып, сәгать телләре шикелле, уңга-сулга селкенеп бара.

Хәлим, кызларга күренмәс өчен, бер якка тайпылды. Һәм китаплары янына килеп утырды. Бөтен күңелен салып укырга кереште ул. Ләкин аның күз алдында мәктәп иде инде, иптәшләре, укытучылары иде.

— Алтынчыга алырлар микән? Алмасалар нишләрмен?

Хәлим, үз уеннан үзе куркып, урыныннан торды.

— Ой-ой... җир тишегенә кер дә кит инде ул чакта...

Хәлим шул уй белән, бары шул турыда гына уйлап мәктәпкә китте.

Мәктәп ишек алдына кереп барганда елый-елый ике бәләкәй малай төрткәләшеп торалар иде, аларны аерып җибәрде.

— Китегез, нәрсә бүләсез! — Хәлим шулай дип, тиз генә мәктәпкә кереп китәргә булган иде дә, бәләкәйләрнең әле генә өй түреннән шундый тату сөйләшеп узган Фәтхели белән Әптери икәнен күреп, туктап калды.

— Кара, нигә сугыштыгыз әле?

— Минмени, әнә Калай Әтәч ич... Гитлер безнең авылга килеп җитә ди, кешеләр урманга партизанга китә ди. Эе-е...

— Җитә димәдем дә әле мин. Җитсә дидем. Эе-е...

— «Җитсә» дә димә! — Әптери ярсып килеп, Фәтхелигә ташланды, һәм Хәлим тотып калырга өлгергәнче, тегенең күкрәгенә төртеп алды. Фәтхели дә бурычлы булып калмады, Әптеринең иягенә чыркылдатты һәм акланып куйды:

— Минмени! Эе-е... Пожарный Сабир әнигә шулай дип әйтеп чыгарган ич. Алайса, бар, Сабир абыйга да ябыш. Эе-е...

— Ябышырбыз да...— Әптери әләгеп кенә торган, килеп орынуга кубып төшкән тешен эзләп табып, кесәсенә салып куйды.— Барыбер икенче бәбәгеңне дә чәршәмбегә каратмый калмыйм мин синең,— диде ул һәм сугыша башлаганда эт оясы түбәсенә ташланган сумкасын алырга китте. Фәтхели, күрәсең, һөҗүм яшен тизлеге белән булган, анда ташларга өлгермәгән, сумкасы чирәмдә ята, бер көтү тавык-чебеш, ипи сыныгын өстерәп чыгарганнар да талаша-талаша чукыйлар иде. Фәтхели тавык-чебешкә кизәнә-кизәнә сумкасын алырга йөгерде. Хәлим дә мәктәпкә кереп китте.

— Карагыз аны, сугышмагыз.

Киң, якты коридор элеккечә үк балалар белән тулы иде. Ләкин балаларда элеккеге җанлылык юк, элеккеге көр күңел юк. Элек тәнәфес вакытында балалар коридорның астын-өскә китереп уйныйлар, бииләр, җырлыйлар иде. Чиксез бәхетле, шат күңелле кечкенәләр, үзләренә бер компания булып, әйлән-бәйлән уйныйлар иде. Ә хәзер әйлән-бәйләнне бик аз бала уйный. Алар да, ничектер, кызыксыз, өсләрендәге бурычны төшерү өчен генә әйләнгән шикелле, хозурсыз әйләнәләр. Аяк атлауларында элекке дәрт юк аларның, хәрәкәтләрендә элекке рух юк.

Олыраклар, малае-кызы, карта янында. Алар инде хәрабә хәленә килгән, ләкин бирелмәгән Сталинградка ихтирам белән карап торалар. Ачыккан, ябыккан, хәлсезләнгән, шулай да бары җиңү турында гына уйлаган Ленинград шәһәренә гаҗәпләнеп карыйлар. Кемдер теләмичә генә бүген безнең гаскәрләр калдырып чыккан шәһәр исемен атый. Балалар бу шәһәрне эзләп табып, аның инде таланып, яндырылып беткән булуын күз алларына китереп күңелсез сөйләшәләр.

Кием элгеч янында берничә кечкенә малай. Берничә генә алар, ә тавышлары зур. Әтиләреннән, абыйларыннан, туганнарыннан, бер дә булмаса чыбык очы туган-

нарыннан, ул да булмаса тирә-күршеләреннән килгән хатлар турында сөйләшәләр:

— Безнең әти ике фашист үтергән, берсен атып, берсен мылтык түтәсе белән бәреп...

— Ә безнең әти, агай-энем, өчне. Дүртенчесен чәнчергә дип торганда, фашист тәре кулын күтәреп өлгергән, кул күтәргәч тиярга ярамый икән...

— Ә-ә...

— Әҗем Зарифы тел ташыйм дигән. Җиде тел алып кайттым инде дигән...

— Нинди тел?

— Мин кайдан белим... Немец теледер инде...

— Һа-а!..

— Прәме кычкыртып кисеп ала микән ул аны, ә?

Малай моңар белмим ни дип җавап биргән булыр иде, өлгерә алмый калды. Әле гено ишектән кергән берсе, боларның барысын да хозур күреп, элгеч кырыеннан посып карап торган Хәлимне төсмерләп узып китте дә, кулларын җәеп, зур тавыш күтәреп, кычкырырга тотынды:

— Һа-а, малайлар!.. Хәлим кайткан, малайлар!..

— Кайда?

— Әнә, әнә, военный кием кигән!..

Малайлар да, кызлар да ялт борылып карадылар. Баштанаяк гаскәриләрчә киенгән, медаль таккан, бер ел эчендә шактый үсеп, олаеп киткән Хәлимне башта танымый тордылар, танығач, камап алып, шаулаша, сорашсора башладылар:

— Һәй-й, кайттыңмыни, Хәлим?

— Нишләп кайттың, Хәлим, ә?

— Бөтенләйгәме?

Хәлим балаларның күбесе белән кул биреп күреште. Бераз уңайсызланды, бераз масайды да ул күрешкәндә. Һәм, башыннан үткәннәрен, ничек, ник кайтканнарын дәрестән соң сөйләргә ышандырып, директор бүлмәсенә кереп китте. Балалар, Хәлимнең директор белән сөйләшкәнен тыңлау өчен, ишек төбенә өерелеп килделәр. Ябылып җитмәгән ишеккә кайсы колагын, кайсы күзен куеп карый-тыңлый башладылар.

Хәзер мәктәп директоры — Хәлимне беренче класстан бирле укытып килгән, сезгә дә бераз таныш булган карт укытучы Шаһгәрәй абзый иде. Ул Хәлимне бик

гаҗәпләнеп, шул ук вакытта чын шатлану белән шатланып каршы алды:

— Оһо!.. Бөтенләй герой булып кайткансың ич син... Исәнме, исәнме, Арсланов! — Карт укытучы үзенең инде арыган, зәгыйфьләнгән, зәңгәрсу тамырлары бүртеп чыккан кулы белән Хәлимнең үзенә карата шактый зур кулын кысып күреште дә елмаюын киметеп болай диде:

— Сине бик нык кыздырырга кирәк иде дә инде, болай булгач, хәзергә калып торсын... Шулай да отряд сборында үзеңнең качып китүең турында... (Хәлим бу урында башын түбән иде), аның ярамаган эш икәне турында... (Хәлим башын тагын да ия төште) сөйләп бирерсең... Ә медалең белән тәбрик итәм,— директор Хәлимнең медален үбәргәнсыман итеп учында тотып торды, аннан сүзләрен укыды: — «Батырлык өчен!» — Директор, бик канәгать булып елмаеп, кабинетындагы укытучыларга эндәште:

— Күз алдыгызга китерегезче: «Батырлык өчен!» Зур бүләк бу, бик зур бүләк. Молодец, Хәлим. Я, укырга кайттыңмы, дустым?

— Укырга...— Хәлим хәтереннән укытучының олылау исемен эзләде.— Укырга,— дип кабатлады ул,— алсагыз, укырга, Шаһгәрәй Солтанович.

— Карагыз әле сез аңа, зинһар өчен, бөтенләй культуралы совет солдаты!.. Алабыз, әлбәттә, алабыз, рәхим ит. Ялгышмасам, син бишенчедә...

Хәлим, солдатлыгын җуеп, балаларча аска карады:

— Алтынчыга керәсе килгән иде шул минем, Шаһгәрәй абзый...

Укытучы кырт кисеп Хәлимне күңелсезләндерүдән курыкты, җайлап кына «киңәш бирмәс идем» кебек сүзләр кыстыргалап кына, аңар бишенчедә укырга кирәк булачагын әйтә башлады. Хәлим аны бүлде:

— Юк, сез алай димәгез. Алтынчыга алыгыз сез мине. Мин бишенче өчен дә укырмын, Шаһгәрәй Солтанович.

— Өлгерә алмассың бит, энем.

— Алам, өлгерә алам. Көн-төн укыйм мин. Алыгыз гына...

Директор укытучыларга сораулы карады.

Укытучыларның бик үк риза булмаячакларын сизеп, Хәлим запаста торган козырен чыгарып салырга ашыкты:

— Мин госпитальдә бишенче класс дәреслекләрен күп укыдым, Шаһгәрәй Солтанович, алыгыз инде, ә?

Хәлим дөрес әйтте.

Аны 5 нче класс дәреслекләрен укуга рус теленә булган хиреслек алып кереп китте. Көн саен диярлек хәл белергә кереп йөргән Женя Хәлимгә «Пионерская правда»дан сугыш эпизодлары, җиңел тел белән язылган кыска-кыска хикәяләр укый иде. Хәлимгә Женяның әдәбият дәреслегендәге «Уку дәрте»[1] исемле хикәя аеруча ошады һәм ул аны үзе укып чыгу өчен сорап алып калды. Шуны уку өчен генә алып калды ул Женяның әдәбият дәреслеген, ләкин әзләп-әзләп бөтенесен укып бетерде.

— «Ә мин тик ятканчы бөтен дәреслекләрне укып чыксам, кайткач 6 класска алмаслар микән?»

Хәлимнең бу уен Женя күтәреп кенә алды.

— Әлбәттә, алырлар, укы, Халимка! Мин сиңа ярдәм итәрмен.

Һәм Женя чыннан да ярдәм итте. Тик математика белән физикага җиткәч кенә көймә комга терәлде. Малай бу фәннәрне үзе дә чамалы белә иде. Ләкин ул аптырап калмады, госпитальгә үзенең бер иптәшен — бу фәннәрне отлично белүе өчен Лобачевский кушаматы алган классташын чакыртып китерә башлады.

Дөрес, бу 5 нче класс курсын үтү дигән сүз түгел иде әле, шулай да, хәзер Хәлимне бернәрсә белми дип тә әйтеп булмый иде инде.

Хәлим бу турыда сөйләп биргәч, директор тагын укытучыларга мөрәҗәгать итте:

— Я, ничек, коллегалар?

Укытучылар Хәлимгә бик күп тырышырга туры киләчәген әйттеләр. Директор, Хәлимнең ничек өзәләнгәнен күреп, аның соравын канәгатьләндерү ягына ава төште:

— Зиһенле егет ул үзе. Башлангыч мәктәпне миндә бетергән иде. Начар укымады. Ләкин, ялгышмасам, бик шук иде...

— Ә мин хәзер шук түгел, Шаһгәрәй Солтанович.

— Анысы әйбәт, ләкин...

Коридорда звонок шалтыратып уздылар.

---

[1] М. Горькийның «Малайлыкта» исемле озын повестеннан бер кисәк.

Укытучылар, китап-дәфтәрләрен алып, классларга таралдылар. Директор да, инде өстәле артыннан чыгып, класска керергә җыена иде.

— Зинһар, тынлый күрегез инде, Шаһгәрәй абзый.

Директор, Хәлимнең иягеннән тотып, башын күтәрде.

— Бар, утырып кара. Ләкин исеңдә тот, булдыра алмасаң, бишенчегә төшеп утырырга туры килер, дустым.

— Ә мин булдырам, Шаһгәрәй Солтанович.

— Мин бик шат булырмын, Арсланов. Югыйсә, кара аны, сиңа да, миңа да кызарырга туры килер.

Хәлим гаскәриләрчә төз басты. Ул бу вакытта ахыр чиктә җитди иде:

— Туры килмәс. Мин сезне кызартмас өчен генә булса да...

Хәлим директорны кочып алды. Башын аның күкрәгенә куеп өстәде:

— Ә былтыргы өчен гафу итегез инде... икенче кабатланмас,— диде ул. Һәм укытучының, теле белән әйтмәсә дә, күңеле белән гафу иткәнен аңлап, коридорга чыкты. Алтынчы классны табып ишеген ачты. Ишек төбендә туктап, үкчәләрен оста бәреп куйды:

— Р-рөхсәт итегез!

Военрук, барлавыннан туктап, башын күтәрде:

— А, Арсланов... Кайтканыңны ишеткәч, бик шатландым... Рәхим ит, рәхим ит. Димәк, укырга?

— Укырга, Искәндәр Вәлиевич!

— Әйбәт, молодец, утырырга мөмкин.

Хәлим, сайлап тормыйча, буш урыннарның берсенә килеп утырды. Ә класста буш урыннар күп иде. Әнә ике парта бөтенләй кешесез. Җәләй дә үзе генә утыра. Каюм да...

Балалар ник килмәгән соң?

Хәлим, шул турыда сорамакчы булып, алдагы малайның аркасына төртмәкче булды. Ләкин кайгысы улмыни аның хәзер!..

Хәлим партага килеп утырганчы гына, сумкасыннан дәфтәр белән ручка чыгарганчы гына тынып торган балалар гөжелди башладылар. Гадәттә тынычрак булучан кызларга кадәр пышым-пышым сөйләшергә тотындылар. Хәлимнең колагына керде: кызлар ике сүзнең берендә «Хәлим» диделәр. Хәлим күрде: кызлар анар-

дан күзләрен алмадылар. Элеккеге чак булса, Хәлим кычкырып та салган булыр иде: житәр инде сезгә, аю күрдегезме әллә! — дияр иде ул. Ә хәзер алай килешмәс шул...

Хәлим, кулларын колак яфраклары артына куйды да, бөтен күнелен салып, дәресне тыңларга керешге. Пышылдашуларны ишетмәмешкә, партасына ыргытылган язуларны күрмәмешкә салышты.

Звонок булуга, гадәттә, балалар берсе калмый коридорга чыгып чаба иделәр. Ә бу юлы бер бала да урыныннан кузгалмады. Укытучы чыгып китүгә, башта кыюраклары, аннары барысы да Хәлимне сырып алдылар.

— Нихәл, Хәлим!

— Исәнме, малай!

— Тәки барып, йөрәгеңне басып кайттың бит, ә?

— Кайларда булдың, егет, нишләп йөрдең?

— Әй, аптыратмагыз әле, сөйләве качмас. Карыйк әле үзенә бер туйганчы.

— Ну, Хәлим малай, шинелең!..

— Ә итеге начармыни?

— Әй-яй-й... Безнең военрукныкы ише генә түгел бу, ә?

— Бөтенләй үзеңәме инде болар, Хәлим?

— Әлбәттә, үзенә...

— Мылтык аттыңмы соң, Хәлим?

— Военный мылтыктан да аттырдылармы, Хәлим?

Хәлим, әле житди кыяфәткә керергә тырышып, әле асылына кайтып, җавап бирә барды. Ә сораулар яуды да яуды. Кече класслардан да балалар кергәч, бүлмәдә аяк басар урын да калмады.

— Ну каты шартлыйлардыр ул теге кәтүшә дигәннәре, ә, парин?

— Әй, нимәләремә генә дип кайттың, Хәлим, малай?

Шулай диюгә берсе калын тавыш белән кычкырып көлеп жибәрде.

Көлүче зур авызын ерып, күзләрен йома төшеп, башын як-якка йөртеп чыкты. Янәсе, ул хәзер Хәлимгә чәнечкеле сүз әйтәчәк, көләргә әзер торыгыз. Аннан, «л» урынына «р» әйтеп, сөйләп китте:

— Кайтасы булмаган ди ул, марайрар. Ну аңар әз дә түгел, күп тә түгел, бер бөтен үле немец күрсәткәннәр,

ха-ха-ха... Вәт шуннан куркып кайткан да киткән... Шулаймы, Хәлим, парин?..

Балаларның кайберләре көлүчегә кушылды. Кайберләре Хәлим өчен уңайсызланып куйды. Хәлим исә көлүчегә кул биреп күреште, ә сүзләренә исе китмәгән булып, усаллык белән түгел, уен сүз итеп кенә әйтеп куйды:

— Немецның тересен күрсәтер идем дә инде мин сиңа...— диде ул һәм сөйләвен дәвам итте.

Ләкин Хәлимгә алай да әйтергә кирәк булмаган икән... Көлүче — бәйләнчеклеге өчен Черки кушаматы алган Ибраһим исемле малай иде. Ул, Хәлим шулай диюгә, әче көлә-көлә, аның партасына ятты һәм башы белән Хәлимнең күкрәгенә төртә-төртә әйтте:

— Күрсәт әле, Хәлим, күрсәт инде, безнең бик күрәсебез килә аны, тере немецны...

— Ә менә безнең килми!..

— Татарга тылмач кирәкми, Җәләй энем,— диде Ибрай һәм бәйләнә бирде:

— Күрсәт инде, Хәлим малай, тере немец нинди була?..— диде ул һәм бу юлы Хәлимнең күкрәгенә башы белән шактый каты китереп төртте.

Хәлим, түземен җуеп, кайда икәнен дә онытып, сикереп торды да уч төбе белән Черки Ибрайның иягенә төртеп җибәрде. Тегесе, телен тешләп, алдагы партага чалкан барып төште.

Балалар чигенеп куйдылар. Бар да ах иттеләр.

— Ничек чигенмәссең!.. Ничек ах итмәссең! Аңар авылда бүгенгә кадәр бер малай да каршы чыкканы юк ич. Хәлим усал булса, Черки Ибрай аңардан ике өлеш усалрак ич. Хәлимне теләсә кайда тотып, теләсә никадәр кыйный ала ич ул!

Менә Черки сикереп торды. Күрер күзгә үк көчле йодрыкларын йомарлады, тешләрен шыкырдатып куйды. «Ну изә хәзер...» Ләкин Ибрай Хәлимне изә алмады...

«Җиңәр өчен көч кирәк, көчтән дә бигрәк кыюлык кирәк,— ди иде Хәлимнең госпитальдәге күршесе, әллә ничә орденлы, әллә ничә медальле өлкән яшьтәге майор, гражданнар сугышы ветераны.— Култык астына кыстырып китәрлек кешеләр герой булып чыга сугышта, ә ат кадәрлеләр, куркып, әнисе янына кача. Нигә алай? То-то шул: кыю бул син. Смелость города берет...»,— Хәлимнең исенә шул сүзләр төште һәм ул, парта ара-

сыннан чыгып, Ибраһимның күзләренә батыр карап каршысына бара башлады. Хәлимнең бу кыюлыгын күреп, Ибрай каушап калды һәм... Хәлимгә таба баруыннан туктап, йодрыкларын бушатты. Былтыр гына тегелгән пиджак җиңеннән әллә никадәр чыгып торган озын кулларын төшерде ул һәм, күзләрен зур ачып, артына чигенде.

Малайлар тагы ах итеп куйдылар. Ләкин ахның мәгънәсе бу юлы икенче иде инде.

— Әллә военный кием кигәч кешедә көч тә артып китә микән, малайлар, ә?

— Я шулайдыр әле...

3

БАРЫСЫ ДА ҖИҢҮ ӨЧЕН

Сагынылган икән шул!.. Хәлим дәресләр бетүгә, элекке кебек, урамга атылып чыкмады. Коридорда басып торды, классларны ачып-ачып карады. Иптәшләренең дә аны җибәрәселәре килми иде. Җилтерәтеп, табигать почмагына алып менеп киттеләр. Ул теле белән иптәшләренең сорауларына җавап бирде, күзләре белән үзенә таныш һәм якын булган, читтә йөреп кайткач, ничектер, тагы да якынаеп киткән әйберләрне күзәтте.

Әнә зур яшел читлектә пар песнәк. Аларның берсен Каюм рогатка белән атып төшергән иде. Канатына тигән булган, атна-ун көн оча алмады, аннан төзәлде. Ә икенчесенең тарихы кызык кына. Аны Хәлимнәр бакчага йөргәндә үк әле, мәктәп балалары тотып, тәпиенә «Ватан» сүзе уелган балдак киертеп очыралар. Ул малайлар күптән егет булып җиттеләр, хәзер өскә шинель киеп, кулга мылтык тотып, песнәк түгел, фашист аулап йөриләр. Кошларның хәтер сәләтләре турында кем нәрсә әйтә ала инде? Бер тапкыр читлектә утыруы, аягында балдак булуы турында ул көннән бирле песнәк, үзе, бәлки, оныткандыр да. Малайлар онытмадылар. Туган-үскән җиренә кайчан да бер әйләнеп кайтуын өмет итеп, көзләр җиткән саен аңар ау кордылар. Бер, ун, бик күп песнәк керде ауга, ә балдаклы песнәк күренмәде. Ниһаять, былтыр көзен малайларның өметләре акланды: чиктән тыш шатланган Җәләй мәктәпкә әлеге песнәк эләккән яшел читлекне күтәреп килеп

керде. Шуннан бирле балдаклы кошчык табигать почмагының иң кадерле кунагы.

Хәлим песнәкне сыйлау өчен кесә төпләрен актарып карады. Бер валчык та чыкмагач, уңайсызланып күзен кошчыктан алды.

Әнә мәче башлы ябалак карачкысы. Ябалакны Хәлимнең Хәсән абыйсы урманнан атып алып кайткан иде. Башта карачкы Хәлимнәрнең түрләрендә торды, табигать почмагы төзелгәч, Хәлим аны мәктәпкә алып килгән иде. Хәлим шкаф ишеген ачып җибәрүгә, карачкы, очып китәргә җыенгандай, селкенеп куйды.

Табигать почмагына йөгереп менүгә бераз тынып калган балалар, бигрәк тә кечкенә малайлар, тагы шаулаша, берсен-берсе бүлеп, Хәлимне табигать почмагының соңгы бер ел эчендә ирешкән байлыклары белән таныштыра башладылар. Теге ташны тегесе яр буеннан табып кайткан, һәм ул, имештер, Татарстанда сирәк очрый торган таш булып чыккан, ә бу чәүкә монысының капкынына эләккән, анысы да, имештер, гади чәүкә булмаска тиеш икән...

— Ә инде менә монысының кайдан килгәнен үзең бел, Хәлим!

Хәлим борылып карады һәм шкафта, пыяла калпак астында, әле генә өзелгән диярсең, табигый тузанчыгына кадәр сакланган бик зур бер әнис алма күрде.

Хәлимне бераз шаяртып торырга уйлаганнар иде дә, кая ул, әбер-чебер түзәме соң! Берсен-берсе уздырып кычкырырга тотындылар:

— Синең агач алмасы, синең агач алмасы!.. Дүртәү иде, тегеләре монысыннан да зуррак иде әле. Кич белән «эләкчеләр»нең күзләре Фәтхели белән Әптерине эзләделәр. Тегеләр бу хәлне көткәннәр иде күрәсең, вакытында сизеп алып балык өчен әзерләнгән аквариум артына постылар. «Эләкчеләр» Фәтхелиләрнең исемнәрен әйтеп өлгергәнче, Хәлим шатланып кычкырып җибәрде:

— Минем агач алмасы? Ә, әйе, Мәгъсүм белән утырткан идек... Хәлимгә кинәт чиксез рәхәт булып китте. Ул пыяла калпакны күтәреп, алмага үрелде, ләкин орынырга да кызганып, кулын кире алды.

— Быел без дә утырттык. Хәлим абый, без дә утырттык!

— Әйдә, безнекеләрне күрсәтәбез...

Малайлар, менгәндәге кебек җилтерәтеп, Хәлимне бакчага алып төшеп киттеләр. Монысы менеке, монысын мин утырттым, дип сөйләнә-сөйләнә, яңгыр белән юылган, рәт-рәт булып тезелеп торган өч-дүрт яшьлек алмагачлар янына өстерәп килделәр.

Салкын яңгыр сибәли иде. Шуңар да карамастан Хәлим, һәр агач янында тукталып, кайдан алулары, ничек утыртулары турында сорашмый калмаган булыр иде, әнисенең, башына яулык та салмаган килеш, болдырларына чыгып, кул изи-изи эндәшкәнен күргәч, кайтырга ашыкты.

«Тикмәгә чакырмый торгандыр...»

Шәмсия апа Хәлимне көтеп алды, һәм, килеп җитәрәк, бер-ике баскыч түбән төшеп, пышылдап кына болай диде:

— Танк ясатырга акча җыеп йөриләр, улым. Кичә дә бер кергәннәр иде. Бик кирәк ди... Мин инде биш йөз яздырган идем дә, күбрәк китмәде микән дип синең белән киңәшергә булдым. Ничшлик икән?..

Хәлим биш йөзнең нәрсә икәнен чамалый иде инде, гаҗәпләнми кала алмады.

— Биш йөз?.. Юк, юк, әнием, ник ул кадәр бирәсең диюем түгел, кайдан алдың димәкче идем... бик күп бит, әнием.

— Әтиең белән абыйларыңның яңа йортка дип җыйганнары, улым. Башлары исән булса, тагын табарлар әле.

— Дөрес, әни, бик, бик яхшы булган.

Хәлим ачылып китте һәм, әнисен шинель чите белән яңгырдан ышыклый төшеп, өйгә алып кереп китте.

Анда, өстәл артында авыл советы председателе Әфләтун абзый белән комсомол комитеты секретаре Мәрфуга утыра иде. Алларында байтак кына колхозчыларның исем-фамилияләре язылган исемлек. Исемнәр янында төрле цифрлар булып, председатель белән секретарь шуларны исәпли иделәр.

Хәлим алар белән исәнләшүгә, әнисе биш йөз турысына кул куюга, «ни бетмәгән яңгыр булды соң бу, сугыш галәмәтедер инде, чистый каныкты» дип, сукрана-сукрана, Хәтирә әби килеп керде. Ул акча җыючыларны, «кара, нигә миңа кермәдегез, санламавыгыз булгандыр инде үзегезгә калса», дип битәрләргә кереште.

Мәрфуга уңайсызланып китте. Әфләтун да:

— Ачуланма инде, Хәтирә әби, үзең карчык кеше, үзең ир-атсыз да булгач, без тагы...— дип акланып куйган булды. Ә эченнән: — керсәк бик ишәр идең инде,— дип кимсетеп көлә иде. Ул әбинең тизрәк чыгып китүен көтеп цифрларына чумды.

Хәтирә әби алай тиз генә чыгып китмәде. Куенындагы төргәкне өстәлгә куеп, сөйләнә-сөйләнә чишә башлады:

— Узган елның элеккегесендә кәмит уйнарга килүчеләр ни ялварып та сатмаган идем. Изге эшкә насыйпка күрә калган икән...

Әбинең изге эшкә адарынганы заман үтү белән шомарып беткән борынгы таңкәләр белән тулы күкрәкчә булып чыкты. Ул бөрешеп каткан кулларын таңкәләре өстенә куеп торды да күкрәкчәне Мәрфугага таба этәрде.

— Сатарсыз да акчасын шунда теркәп куярсыз. Карагыз аны, шәләйтли күрмәгез, риза бәхил түгел... Син тик кенә утыр, Әфләтун... Ай, бу хәтер дигәнең... Тукта, тукта... Менә монысы Гайнелгыйбат бабагыздан...— диде әби һәм кесәсеннән лимон кәгазенә төрелгән зур гына көмеш сәгать чыгарып Мәрфуга алдына куйды.

— Япуннан тагып кайткан иде, мәрхүм. Төсем итеп тот, бик авырга килсә генә сатарсың дигән иде...

Акча җыючылар, икесе дә аягүрә басып рәхмәт әйтергә, саңга сукмаулары өчен гафу үтенергә керештеләр. Хәтирә әби аларны тыңлап тормады, карты турындагы истәлекләр кузгаткан күз яшьләрен уч төпләре белән сөртә-сөртә кече якка, Шәмсия апа янына кереп китте.

Кайсыныңдыр өстәлдә авторучкасы онытылып калган икән, Хәлим, ашка хәтле илтеп кайтырга булып, авыл советына йөгерде. Анда танклар колоннасына акча җыюга каршы булмаган, ләкин бирү ягына килгәндә янчыгы чишелми торган бер-ике кеше белән әңгәмә бара иде. Ахрысы инде сүз күп булгандыр, Мәрфуга тынычлыгын җуйган, бит алмалары, колак яфраклары янып тора, Әфләтун исә бөтенләй чыгырыннан чыккан, кулларын артка куйган да:

— Вәт контр, вәт контрлар,— дип сүгенә-сүгенә идән буенча әрле-бирле йөри иде.

— Әллә мин кесәм кычытканга бирәмме? — ди ул бераз тынычлана төшеп.— Шулай булмый соң! Яшерен батырын түгел, һәркем авызыннан өзеп бирә, Зарифулла абзый.

Зарифулла абзый (аның турында алда сүз күп булыр) нидер мыгырданып куя, күрәсең, ачу китерә торган сүз булгандыр, Әфләтун тагы да кызып китә:

— Ә анда кызылармеец үз эшләреннән арынган арада гына чыгып сугышып керәмени, каны артык булганга агызамыни, җаны җиде булганга керәмени ул ут эченә? Вәт контр! Менә контрлар!..

Хәлим, авторучканы Мәрфугага бирде дә тыңлап торырга уңайсызланып, кайтып китте...

«Каның артык булганга агызамыни?..» Бу сүз Хәлимгә тәэсир итте. Ул кайткач та авыл советында ишеткәннәрен әнисенә сөйләде. «Син бик дөрес эшләгәнсең бит, әни, бик дөрес», диде ул сүзенең йомгагы итеп.

Иртәгесен мәктәптә дә тәнәфес саен сүз танклар колоннасына акча җыю турында барды. Әниләре күбрәк биргән балалар горурланып сөйләделәр, аз яки бөтенләй бирмәгәннәренең тавышлары алай көр чыкмады. Ә дәресләр беткәч, Фәрдәнә шундый тәкъдим кертте:

— Әйдәгез, иптәшләр, без дә җыябыз. Мин башлап ун тәңкә бирәм,— диде.

Мондый вакытта Черки Ибрай берәр әче сүз кыстырмый каламы соң! Шунда ук сикереп чыкты. Ул, зур авызын зур итеп ерды да, үзенә иярченнәр эзләп, күзләрен як-якка йөртә-йөртә, болай диде:

— Фәрдәнә апагызны ишеттегезме, марайрар? Ун тәнкә ди бит, ун тәнкә ди, күзен дә йоммый. Әй сөенерләр дә инде сугышта!.. Фәрдәнәнең ун тәнкәсенә танкның ниндиен арырга белмәсләр.

Мотыйк, тагын берничә бала, хозур күреп, көлештеләр, Гөлчәһрәләр дә елмаеп куйдылар. Ә Фәрдәнә тәкъдименә әсәрләнеп киткән пионерлар Ибрай мәзәген ишетмәмешкә салыштылар. Ибрай исә, мәзәгенең көткән нәтиҗәне бирмәгәнен күргәч, уңайсызланды. Ләкин, башына килеп торуын кара син!.. Әз генә дә каушамастан, тамак кырып куйды, күгәреп беткән тимерчыбыктан әмәлләнгән пыяласыз «күзлеген» киеп алды да, Шаһгәрәй абзыйга охшатырга тырышып, анынча сабыр һәм хаким тавыш белән эндәште:

— Мотыйгулла энем, тактага!..

Әлбәттә, берәр мәзәк уйлап чыгарган... Мотыйк бик рәхәтләнеп, кара такта янына килде. Ибрай Мотыйкка Шаһгәрәй абзыйча «күзлеге» өстеннән күз төшереп алды да:

— Хәзер без синең белән шундый хисап эшлибез, дустым,— диде.

Берничә бала, Фәрдәнә төркеменнән аерылып, такта янына килделәр. Ибраһим дәвам итте:

— Эһем, эһем. Ху-уш... Борын-борын заманда мәктәпләрдән бер мәктәптә булган ди бер кыз. Яман да юмарт булган ди инде бу. Көннәрдән беркөн әйткән дә салган ди: «Бу сугышларын миннән башка очлап чыга алмаслар ахрысы, ун сум акча бирим әле, танк алсыннар дигән ди. Шулай дип әйтүе булган, ун сумны чыгарып салуы булган. Бел әле, дустым, кызның ун сумына ничә танк тия икән. Бер танкмы? Ун мең сум тора.

Бу юлы көлүче күбәйде. Мотыйк, Ибрайга куәт биреп, җилкә чокырын кашып торган булды.

— Бик күп тими икән шул...

— Ха-ха-ха...

Әле чыгып китмәгән, китап-дәфтәрләрен җыю белән мәшгуль булган Тәзкирә апа, Фәрдәнәгә шатланып, яктырып киткән иде, Ибрай көлгәч, тагын шулхәтле бала да ияргәч, күңелсезләнде. Фәрдәнә инициативасының «ха-ха-ха»лар белән күмелеп калу куркынычын күрде ул.

— Ун тәңкә күп тими, анысы дөрес,— диде укытучы.— Бүген ун тәңкәгә бер шалкан да бирмиләр. Ә менә Ибраһим әйткән «мәктәпләрдән бер мәктәптәге юмарт кызның» акчасы ун тәңкә дә түгел, ун тиен генә булган булса?..

Барысы да көлде. Фәрдәнә үзе дә эченнән әллә инде ялгыш әйттем микән дия иде. Ул арада укытучы болай диде:

— Ибраһим акыллым, акбурны үз кулыңа ал әле.

Ибраһим таякның үз башына таба борылганын сизеп, авызын җыя төште. Ләкин урыныннан кузгалмады.— «Дәрес бетте ич инде».

— Ибраһим!

Ибрай теләмичә генә күтәрелде һәм алты кырлы акбурны алып бармак битләрендә әйләндерә-әйләндерә аяк йөзләренә карап торды.

— Тыңла, Ибраһим. Танк 10 000 сум тора. Син әйткән юмарт кыз танклар колоннасына бер тиен керткән. Ә аңардан күрмәкче, Советлар Союзындагы 30 000 000 укучы бала шулай ук бирәр тиен керткәннәр. Карап кара әле, бирәр танк алырлык җыелмый микән?

Ибрай механик рәвештә 30 000 000 тиенне сумнарга әйләндерде = 300 000 сум. 300 000 сумны 10 000 гә бүлде. Һәм хисапның җавабын 30 танк дип язып куйды.

Бер тиеннән утыз танк. Әллә Ибрай ялгыштымы? Бу шик күпләрнең башына килде. Балалар күзләрен тактадагы бер цифрдан икенче цифрга йөртеп Ибрайның эшләвен тикшереп чыктылар. Юк, Ибрай ялгышмаган иде.

Кара такта янында комачтай кызарып басып торган Ибрай цифрларын бозып чыгып китәргә җыенды. Укытучы аны туктатты.

— Сабыр. Сөртми тор. Ә 30 000 000 бала унар тиен биреп куйсалар?

Пионерлар, Ибрайның тактада эшләгәнен көтмәстән, хор белән җавап бирделәр:

— Өч йөз танк!

— Ә һәр бала бер сум бирсә?

— Өч мең танк!

Җәләй:

— Һәр бала ун сум бирсә...— дип башлаган иде, аны Тәзкирә апа бүлде.

— Әлбәттә. Ләкин шунда туктап, өч мең танкны күз алдыбызга китерергә тырышыйк әле. Өч мең танк. Җиңү өчен мәктәп балаларыннан өч мең танк. «Ил төкерсә, күл була»ның мәгънәсе менә шунда ачыла инде, Ибраһим...

Көлүчеләр шып булдылар. Ибрай үзе дә авызын йомган иде инде.

Гөлгенә Фәрдәнәне яклап сөйләде, үзенең ни бар акчасын — үтә күренмәле кызыл пыяла ручка алырга дип җыйган унике сумын бирергә карар кылганын әйтте һәм дәфтәреннән бер бит ертып алып, башына язып куйды:

Танклар колоннасына «Ватан» колхозы 6 нчы класс пионерларыннан:

1. Фәрдәнә — ун сум,

2. Гөлгенә — унике сум...

Сугыш вакытында һәрнәрсә ашыга, сугыш көтми.

тыл, хәтта балалар да шул ашыгычлыкка күнегеп житкән иделәр, бары шундук чыгарып салды, югы тәнәфес вакытында әнисенә, әти-бабасына йөгерде. Бу гүзәл башлангычны бүтән класслар да күтәреп алдылар. Икенче көн иртәнчәк Мәрфуга колхозчылардан җыелган йөз илле меңне йөз илле бер мең дип төзәтеп куйды. Бу соңгы төзәтү түгел иде әле. Әфләтун абзый акчаларны алып, районга китәргә дип кожаның киюгә ике бәләкәй малай кереп, өстәлгә ике сум чыгарып салдылар. Боларның берсе Әптери, икенчесе Фәтхели иде.

— Егетләрне теркәп куй, Мәрфуга. И соңгы нулены ике итеп төзәт.

4

ШӘПИ НИГӘ УКЫМЫЙ!

Хәлим, мәктәптән кайтып аш ашагач та, математика укытучысы өйгә биреп җибәргән мәсьәләне эшләргә утырды. Ләкин ни тырышса да, чыгара алмады. Минутлар үтте, сәгать тә үтеп китте, юк, мәсьәлә чыкмады. Хәлим борчыла башлады. Шәмсия җиңги дә сизде аның борчылуын. Ул, Хәлимнең урынында тыныч утырмавын, әлсдән-әле җилкәсен кашып куюын карап торды да, әрле-бирле йөреп комачаулый торганмындыр дип, өйдән чыгып китте. Озак йөреп кайтты ул. Хәлим әле һаман да шул кыяфәттә, бер сызып, бер бозып утыра иде.

Шәмсия җиңги, Хәлим башын күтәреп караганчы, ишек төбендә тын гына басып торды, аннары янына килеп утырды да чәчләреннән, битләреннән сөя-сөя әйтте:

— Чәең эч тә ят инде, улым, иртәгә карарсың.

— Иртәгә аның башкасы була бит,— диде Хәлим һәм, әнисенең хәтерен саклау өчен бераз тегене-моны сөйләшеп утырганнан соң, тагы сызарга-бозарга, теореманы укырга кереште. Шәмсия җиңги башын чайкап куйды. Ул, нидер исенә төшеп, тагын чыгып китте, бусында бик тиз әйләнеп кайтты:

— Булды, улым... Гөлгенәгә кергән идем дә, өйдә юк икән. Хәзер Гөлчәһрә керә.

— Нәрсәгә?

— Бәй, бераз аңлатыр.

— Ой, кирәкми, әни. Аның белән белгәнеңне дә онытырсың...— диде Хәлим һәм китап-дәфтәрләрен алып чыгып китте.— Мин Шәүкәт абыйга барып карыйм әле.

Укытучы Хәлимне шат чырай белән каршы алды.

— Нигә син бу кадәр коелып төштең әле, Хәлим?

— Чыкмый бит.

— Чыгар, нишләп чыкмасын... Дөрес, синең өчен бик үк ансат булмас. Ә бара-тора җиңеләер. Мин сиңа булышырмын,— диде укытучы һәм Хәлим кайтканчы үтелгән беренче дәресләрне сөйләде. Аннары шулардан берничә задание бирде:

— Менә шуларны эшлә, ә бүгенгесе калып торсын. Тора-бара анысына да житәрбез. Җитәрбез, Хәлим, һәм узып та китәрбез. Эш ул бер караганда немец шикелле. Курыксаң, ул сине җиңә, курыкмасаң син җиңәсең. Курыкмагач, син әнә нинди данлы эшләр эшләп кайттың...

Хәлим укытучының күзләренә гаҗәпләнеп карады.

— Ә мин беләм,— диде укытучы Хәлимнең ни өчен гаҗәпләнүен аңлап,— үзең кайтып кергәнче үк, госпиталь начальнигыннан директорга хат килде. Ул анда барысын да язган...

Хәлимнең күзләре яктырып китте.

— Начальник язган?.. Минем турыда?..

— Синең турыда. Шаһгәрәй абзаң иртәгә ата-аналар җыелышында укырга булды... Я, ярый, анысы синнән башка да эшләнер. Хәзер синең белән икәүләп торып менә бу теореманы кимереп карыйк әле...

Хәлим, госпиталь начальнигы һәм аның хаты турында күңеленнән чыгарып ташларга теләгәндәй, башын селкеп куйды, ләкин дулкынлануын алай тиз генә баса алмады.

Укытучы моны сизде. Ул, Хәлимнең игътибарын дәрескә юнәлтү өчен, аңардан җиңел генә бер мәсьәлә эшләтеп алды, аннары теореманы аңлатырга керешә.

Хәлимнең көннәре шулай бер-бер артлы тезелеп үтте. Исәбен дә онытты инде ул аларның. Хәзер аның бөтен күңеле укуда иде. Кыска тәнәфес минутларында да башын китабыннан алмады. Берәр тапкыр ат саклаpга барып кайтканда да әйбәт булыр иде дә, яки көзге урманга... юк инде, быелга торып торсын... Хәлим китап-дәфтәрләрен кыстырды да әле бер, әле икенче укытучысына йөгерде. Берсе теләмичәрәк булышса, икенчесенә барды ул. Бусы аңлата-аңлата арыса, аннан чыгып өченчесенә керде.

Тырышу әкренләп үзенең җимешләрен бирә башлады. Дөрес, алгебра, геометрия, физика кебек быел гына башланган фәннәрнең эченә Хәлим әле кереп китә алмады. Ә әдәбият, тел, тарих кебек электән килгән дәресләрдә ул инде беренче көннәрдәгедәй уңайсызланып утырмый иде. Укытучы, я кайсыгыз? дигәндә башын аска иеп калмый, күтәрелгән куллар арасында хәзер аның кулы да күренгәли иде инде.

Ә беренче чирек азагы җитеп килгәндә, аның дәфтәрләрендә кызыл сызык астына кызыл кара белән язылган беренче 3 ләр дә күренгәли башлады. Бүген исә, белмәгәннәрен сорарга баргач, тарих укытучысы контроль эшкә 4 куйганын әйтеп сөендерде.

Хәлим урамга чыккач нишләргә белмәде. Әле сукмактан, әле ат юлыннан кайтты ул. Аның җырлап җибәрәсе килде, берәр иптәшен очратып, шатлыгын сөйлисе килде...

Тышта кара төн иде инде.

Җир дә, күк йөзе дә кара. Озак яуган яңгырга күбенгән каралты, өй түбәләре дә кара. Тәрәзәләрдә маскировка — авыл сугыш режимын намус белән саклый. Тик кайбер тәрәзәләрдән генә җирдәге кара пычракка ут шәүләсе төшкән. Ул да бик тонык, бик кечкенә. Пожарный Сабир аларны таягы белән тәрәзәләргә шакыйшакый, томалатып йөри.

— Нәгыймә түтәй, урта тәрәзәңнең читен томалый төш,— ди ул.— Фәйрүзә килен, кичә кайсыгыз йортка фонарь кабызып чыкты? Ничек ярасын ди инде...— Аннары каршы яктагы зур йортның тәрәзәсенә, ни өчендер, катырак дөбердәтеп, катырак кычкыра.

— Матри, Зарифулла абзый, болай булса дуслыкны бозарга туры килер!

Бөтен авылда бер пожарный Сабир тавышы гына. Урамда аңардан башка кеше юк... Ә, юк, бар икән, әнә болай таба килә. Әллә Ибрай инде... Хәлимне саклап йөри микәнни?.. Булыр аңардан...

Хәлим кулларын кесәләреннән алды. Китап-дәфтәрен куенына тирәнрәк яшерде, фуражкасын батырып киде. Курыкты дип уйламасын тагын дип, җыелып торган суны турыдан ерып чыкты, һәм тыныч, шул ук вакытта сак атлап бара башлады. Ләкин саклану урынсыз булып чыкты, каршыга килүче, Ибрай түгел, Каюм иде.

Каюм, Хәлимгә ике-өч адым кала гына туктады. Хәлим дә туктады. Ләкин күтәрелеп карамады.

Каюм, узган ел Хәлим белән ара бозылып киткәннән бирле, гел борчылып йөрде... Хәлим киткәч, аның белән дусланасы килеп хат та язып салмакчы булган иде дә, Хәлим кушмаган икән, Шәмсия җиңги адресын бирмәде. Ниһаять, Каюм, Хәлимнең адресын почтальон аркылы белеп, озын бер хат язып салды. Хәлим җавап бирмәде. Ә кайткач, мәктәптә берничә тапкыр аның янына барырга омтылып карады, ләкин, балалар алдында әйтеп оялтыр, дип курыкты... Хәзер исә, Шәмсия җиңги, Хәлим сездә түгелме? — дип эзләп кергәч, дуслыкны яңартырга омтылып карарга сылтау булды: «Хәзер табып кайтам мин аны»,— дип чыгып йөгерде. Берничә балага, берничә укытучыга кереп чыкты инде ул. Хәзер аның, Хәлимне эзләп, тарих укытучысына барышы иде.

— Әнисең эзли чыккан сине,— диде Каюм килеп туктавына.— Әле бездә калды. Борчыла. Укуын алдыра алмыйча, тагын китеп бармаса ярар иде, ди.

Хәлим кулларын кесәләренә тыкты да, бер сүз дә әйтмичә, юлын дәвам итте. Каюм, уңайсызланып, аның артыннан карап калды.

— Болай булмый иде. Үзе әйтеп дуслана иде,— диде Каюм үз алдына һәм, авыр өстерәлеп, өйләренә таба китеп барды.

Ә эш Каюм уйлаганча ук өметсез түгел иде. Хәлим Каюмны күптән гафу иткән иде инде. Ә хәзер, бер сүз дә дәшмичә китеп баргач, шуның белән Каюмга тагын бер җәрәхәт өстәгәнен аңлагач, аның үзенә дә читен булып китте. Хәлим, үз гаебен төзәтү теләге белән, кинәт туктап, аңар таба борылды.

...Сүз кирәкми мондый чакта. Бер-береңне аңлау өчен күз карашы, йөз хәрәкәте дә җитә һәм ул ни житте сүздән тәэсирлерәк тә була. Каюм Хәлимнең йөрәген бик тиз аңлап алды һәм, рухланып, бераз каушап, тиз-тиз атлап иптәшенә таба килә башлады. Аннары кинәт туктап, башын түбән иде. Хәлим Каюмның беләгеннән йомшак кына тотып алды һәм шулай ук уңайсызланып аска карады:

— Мир алайса?

— Мир!

— Бир кулыңны!

Малайларга кинәт рәхәт булып китте. Алар моннан соң һич кенә дә ачуланышмаска ант итештеләр. Һәм, гүяки арада беркайчан бернәрсә булмаган: көлешә, шаян сүзләр әйтешә башладылар. Хәлим Каюмга шинель кесәсеннән бер уч эрбет чикләвеге, берничә конфет алып бирде. Янәсе, юл күчтәнәче... Каюм исә, былтыр көзен «каралырга» баргач уртакка сатып алынган пәксне чыгарып, Хәлимгә сузды. Сөяк саплы, баш-башы чын сәдәпле бу пәке дуслык бозылып китү аркасында, малайлар уйлаганча чиратлашып кулдан-кулга күчеп йөрмәде, Хәлимдә калды. Ә Хәлим аны китәсе көнендә соңгы тапкыр мәктәпкә килгәч Каюм сумкасына салып калдырырга уйлаган иде дә, җаен туры китерә алмагач, госпитальдән өс киемнәрен җибәргәндә, өч иптәшнең берәрсенә бирергә кушып, әнисенә җибәрде. Компаньоннар исә аны Хәлим кайтканчы саклау өчен, Каюмга биреп тордылар, ә Хәлимнең госпитальдәге батырлыгы турында ишеткәч, аңар бүләк итәргә булдылар.

— Карандаш та очламадык без аның белән,— диде Каюм.— Мә, бөтенләйгә сиңа булсын.

Хәлим каршы килеп караса да, Каюм пәкене кире алмады. Ул турыда сүз шуның белән тәмам икәнне аңлатып, Хәлим ишетеп өлгермәгән яңалыкларны сөйләргә кереште. Аннары Хәлим сораулар бирде, тегесе җавап биреп барды.

— ...Мәктәпнеме? Ансат булмады, парин, мичлек кирпечне станцадан «ухалла» белән ташыдык...

— Үзегез?

— Үзебез.

— Барысын да?

— Анысы нәрсә... балчык белән комына кадәр...

Каюм Хәлимне пожарный Сабир томалатып өлгермәгән тәрәзә төбендә туктатып, куен кесәсеннән бер рәсем чыгарды. Район газетасыннан кисеп алынган, кулдан-кулга йөри-йөри тузып беткәч катыргыга ябыштырылган бу рәсемдә унбиш-егерме бала булып, астына «Никкүчтем мәктәбен салуда актив ярдәм иткән пионерлар» дип язылган иде.

— Оһо, син иң алда!..

— 150 процентка үтәдем, иптәш,— диде Каюм һәм болай мактанып ташлавыннан уңайсызланып, сүзне икенчегә борды.

— Фазыл белән Мәгъсүм турында ишетқәнсеңдер инде?

— Ишеттем.

— Таһир турында?

— Ишеттем.

— Җан дустының Казанда икәнен белгәч, китте дә барды, шайтан!

— Шайтан түгел, эшчеләр сыйныфына булачак өстәмә.

— Булачак та түгел, булганнар инде. Бүген тагын хат алдык. Карточкаларын җибәргәннәр. Өчесенең дә кара шинель, значоклы фуражка. Фазыл белән Таһир станок янында. Анда да шул икән: авызлары колакларына җиткән. Ә Мәгъсүм әллә нишләгән: уйчан, олылар төсле булып киткән. Фәрдәнә, стена газетасына урнаштырабыз, диде.

— Молодцы. Нәрсә язалар?

— Шул, ремесленныйны бетерәбез инде, дигәннәр, военный заводта слесарь булып эшлиләр икән.

— Аһа!.. Хат язарга кирәк булыр үзләренә. Әйбәт егетләр.

— Әйбәт.

— Ә Нәҗиптән хәбәр юк икән әле, ә?

— Бетте инде ул...

— Нәҗипме? — Хәлим тавышын шундый күтәреп әйтте, Каюм сискәнеп китте.

— Хәбәре юк ич...

— Нәҗип бетмә-әс...— дип сузды Хәлим.— Менә хат язарбыз, хат аша эзләп карарбыз.

— Ха-ат,— диде Каюм шулай ук сузып.— Әллә без язмаганмы? «Илшат»лар, агай-энем, әллә кайларга язып бетерде. Кырыкмаса-кырык шәһәрнең адрес бюроларына яздылар, фронт штабларына, детдомнарга... Гыймай абыйлары Казанга баргач, военкомат аша да эзләтеп караган... Берәр хәл булмаса, үзе дә түзеп ята торганнардан түгел лә ул...

— Үлгән, димәкче буласыңмы? Ну, ю-ук... Тагын язарбыз.... Госпитальләргә язарбыз, ләкин тапмый калмабыз. Табарбыз, Каюм!

Нәҗип Хәлим күз алдына мәктәп сәхнәсе артында танышкандагы кыяфәтендә килеп басты. Аннары Хәлим хыялында Нәҗип, авызына хәнҗәр кабып, түше белән

шуышып, дошман тылына кереп китте. Хәлимнең йөзе яктырды, күзләре очкынландылар:

— Һе, шундый егет үлсен имеш!..— диде ул һәм Каюм уңайсызланмасын өчен, хисләреннән бүленеп, сүзне икенчегә борды. Ул аңа үзенең мажаралары турында, шул җөмләдән, Каюмның укуга дәрте бөтенләй сүнеп барганын күреп, Женялар мәктәбе турында сөйләп китте.

Каюм, булыр микән дигән шикелле итеп, гел Хәлимгә карап-карап ала иде. Хәлим, соңынтын, әйтеп куйды:

— Ышанмыйсың, әйе?

— Ышанам да...

Тын иде, кисәк җил исеп китте. Вак салкын яңгыр көчлерәк, кыеграк сибәли башлады. Малайлар, берберсен ашыктырып, сукмакка чыктылар.

— Әйдә, безгә кереп тор, Каюм.

— Әйдә соң.

— Ә ул «да»ны ташла син, Каюм. Икеләнүеңне ташла... Андый бала күрсәң, үзең укырга үгетлә.

Каюм эндәшмәде.

— Нигә, шулай түгелмени?

— Түгел шул. Ул күчән Гаязын ни дип үгетлисең инде, җә?

— Гаяз!.. Бар да Гаяз түгел... Хәйретдин Сәләхие нишләп укымый?

— Болай гына...

— Болай гына шул менә... Ә Шәпи нигә укымый?

Каюм кулын селтәп куйды:

— Әйттең сүз... Аларның хәле Гаязларныкыннан да начаррак. Әнисе авырып ята. Кечкенә балалары икәү. Мал-туарларына житәрлек итеп азык та әзерләп куя алмадылар. Хуҗалыкларын карарга өйләрендә Шәпидән башка кеше юк.

— Әнисе күптән ятамыни?

— Күптән.

Хәлим, зур бәхәстә җиңелгән кеше кебек уңайсызланып, сүзсез калды.— «Чыннан да, шулай булгач, ни дип үгетлисең инде ул Шәпине?..»

Хәлимгә кинәт күңелсез булып китте. Капка төбендә очраган әнисе аның уйларын бүлде:

— Әй, улым, ярты төнгә кадәр уку була диме инде...

Хәлим әнисен кочып алды.

— Аның каравы куып җитә яздым, әни. Вәли абый тарихтан 4 куйган!.. 4 бит, 4, әни! Ә син мин кайтмый торганга алай борчылма, әни...

— Борчылам шул мин, улым...

— Борчылма... Ашарга булдымы әле, әни?

— Инде учакта утыра-утыра куерып та беткәндер. Тукта, җылытып алыйм...

— Мин шул килеш кенә...

Хәлим сөйләшмичә, әкрен генә ашады. Ашаганда да, аннан соң, Нәҗипне эзләп табуда ярдәм итүен сорап госпиталь начальнигына хат язганда да, Гаяз белән Шәпи аның күз алдыннан китмәде.

— Шәпи, Шәпи!.. Агроном булам дип йөри иде бит ул... һәм була да иде. Гел 5 кә укып килде бит... Ә Гаяз тагын...

Хәлим Гаяз белән Шәпинең тормышлары турында Каюмга әледән-әле сораулар бирде. Ниһаять, Каюм әйтеп салды:

— Нигә син кеше өчен шулкадәр борчыласың, Хәлим, ә?

Хәлим ялт күтәрелеп Каюмга карады. Күзләре кинәт усалланып китте аның. Ул, сикереп торып, Каюмга берәрне салып җибәрер кыяфәттә иде. Ләкин Хәлим сугарга уйламады да, урыныннан да тормады. Аның күзләрендәге усаллык, кабынгандагы шикелле, тиз сүнде. Хәлим тыныч кына итеп сөйләп китте:

— Алай булмый бит, Каюм. Безнең иптәшләр ич алар. Бата башлаганнар икән, без аларны тизрәк тартып чыгарыйк. Сугышта шулай итәләр, бер кулын өздергән кеше, икенче кулы белән аяксыз калган иптәшен өстерәп алып чыга. Безгә дә шундый булу кирәк, Каюм...

Каюм Хәлимнең болай сөйләвенә сокланып куйды «мондый түгел иде бит бу...» һәм сорау бирде:

— Ә без нәрсә эшләтә алабыз соң аларны, Хәлим?

— Безме?

Хәлим «безме?»не шундый итеп әйтте, аның бу сүзеннән соң: «Менә болай итәбез...» дип тезеп киткәнен генә көтәсе калды. Ләкин сугыш елларының авыр басымы астында мәктәбен ташлаган Шәпи кебекләрне яңадан партага кертеп утырту алай ансат хәл ителерлек мәсьәлә түгел иде. Хәлим берничек дип тә әйтә алмады. Аны күнелсез уйлар газаплый башлады. Ул

шулардан котылу һәм иптәше алдында уңайсыз хәлдә калмас өчен генә «Минем башымда бер уй йөри әле, бүген соң инде, иртәгә сөйләшербез»,— дигән булды. Һәм сүзне икенчегә борып, сәкедәге ак япма ябып куелган ике рәтле гармонен алды.

— Бүләк. Госпиталь начальнигы бирде... Тыңла, мин сиңа нинди көй уйныйм. Женя көе:

То не тучи, грозовые облака-а...

5 БУ ЙОРТ БЕЗНЕҢ ШЕФЛЫКТА

Иртән мәктәпкә барышлый Каюм куып җиткәндә, Хәлимнең күңеле күтәренке иде. Ул тагы бер көнге кебек, тату җитәкләшеп барган Фәтхели белән Әптери артыннан аларның гөрләшеп сөйләшүләренә сокланып бара иде, бу ике дуспың сүзләрен бүлүдән, кәефләрен бозудан куркып, сакланып кына атлый иде, Каюмның аяк тавышларын ишетеп, артына борылып карады.

Каюм да шат, ләкин нигәдер дулкынлана, нигәдер ашыга, каушый иде. Ул хәтта үзенең сәламенә каршы сәлам да көтеп тормастан, Хәлимгә эндәште:

— Исәнме! Әйдә, малай, берәрсенә хәзер үк кереп чыгабыз, ә? Дәрескә иртә бит әле.

— Иртә.

— Иллә дә әйбәт була түлке, малай!..

Хәлим кулын иптәшенең иңнәренә салды.

— Син дә барып чыгар дисеңме?

— Ничек кенә әле... Ләкин нигә соң без моны үзебез уйлап тапмадык, ә? Инициатива тагын безнеке булмады инде болай булгач, өстән булды.

Хәлим дә, күңелсезләнә төшеп, дустының сүзләрен җөпләп куйды.

— Өстән...— Һәм, шунда ук ачылып китеп, болай диде: — Була бирсен! Сәбәпчеләре без ич. Оеткы безнеке ич.

— Безнеке,— диде тегесе шулай ук ачыла төшеп.— Әйдә, керик әле.

— Кемгә?

— Мәсәлән, Шәпигә.

— Әйдә соң...

Эш болай булды. Өченче көн кич Хәлим белән Каюм укуларын ташлаган иптәшләренә ничек ярдәм итәргә

белмичә утырганда, комсомол комитеты секретаре Мәрфуга килеп керде, аның йомышы Шәмсия апада иде, ләкин пионерлар әңгәмәсенә рәхәтләнеп кушылды: — «Шефка алыгыз сез аларны!» — «Ничек итеп?» — «Менә ничек итеп...» — Ә Хәлимнәрдән чыккач, Мәрфуга мәктәпкә барып, мәсьәләне Шаһгәрәй абзый алдына куйды.

Ләкин Шаһгәрәй абзый бик үк күтәреп алмады.

— Күркәм идея, әйе, әйе, бик күркәм,— диде ул.— Ләкин, ялгышмасам, узган ел бер омтылып караганнар иде инде алар... Әйе, әйе, караганнар иде. Барып чыкмады бит, Мәрфуга.

Аның каравы Мәрфуганы класс җитәкчесе Тәзкирә апа бик нык яклады.

— Ничек чыксын, Шаһгәрәй абзый,— диде ул,— үзебез әһәмият биреп җиткермәдек ич. Балалар усны итеп карадык. Минемчә, әйбәтләп җитәкчелек иткәндә, күп кенә баланы янадан мәктәпкә кайтарып булачак.

Мәсьәлә шунда ук педсоветка куелып, анда бердәм рәвештә уңай фикергә киленде. Ә менә пионерлар сборында бик үк шома узмады.

Башлап Гөлчәһрәләр каршы чыкты:

— Шул гына калган иде... ике аягымның берсен дә атламыйм. Кешенекен түгел, үзебезнең маллар артыннан да йөргәнебез юк әле безнең.

Гөлзәһрәсе туганына куәт бирде:

— Малларын гына дисәләр бер хәер иде әле, туганни, керләрен юарга, атнага бер тапкыр өйләрен җыештырып чыгарга ди бит алар.

— Япәсе, бер баланы мәктәпкә кайтару өчен, унунбиш бала аларга тәлинкә тотып йөрергә тиеш.

— Бик кирәге бар иде!

— Нәкъ!

Фәрдәнә каршы чыгардайларга башта ук сүз бирүе өчен үзен-үзе тиргәде, игезәкләрне туктату өчен әледән-әле звонокка үрелде, ә Тәзкирә апа аны гел тыя килде:

— Тимә, Фәрдәнә, сөйләсеннәр.

— Эшне бозып ташламагайлары дип куркам мин, Тәзкирә апа.

— Боза алмаслар, Фәрдәнә.

Менә залда берьюлы берничә кул күтәрелде. Фәрдәнә сүзне башта Хәлимгәме, Каюмгамы бирергә белми

торганда, Ибрай сүз алмыйча гына сөйләп китте. Фәрдәнә аны, тәртип бозасың дип, туктатырга ни тырышса да, малай үзенекен әйтеп бетермичә туктамады. Ул сүзен көлү белән башлап, мыскыл итүгә күчте.

Каюм түзмәде. Ул да шулай ук сүз алмыйча гына кыстырып куйды.

— Без дә без дисең. Кем исеменнән лыгырдыйсың соң син, Ибраһим? — диде.

Ибраһим:

— Пионерлар исеменнән,— дип башлаган иде дә, залдагыларның ризасызлык белдереп, шау-гөр килгәннәрен ишеткәч:

— Мәсәлән, үз исемемнән,— дип төзәтте.

— Шулай дисәң генә. Югыйсә берлек белән күплеккә бутый башлагансың. Кара аны, ана теленнән үзеңә казык утыртып куймасыннар.

Балалар көлештеләр. Ибрай кабынып китте.

— Нәрсә, нәрсә?..— диде ул, һәм күкрәген киереп Каюм каршысына килеп басты. Бу вакытта алар икесе дә бер-берсенә ташланырга торган яшь әтәч иделәр. Ибрай дошманын инде күкрәге белән этеп җибәрергә дә әзер иде, шул чакта Каюмның һәр ике ягына берберартлы берничә пионер килеп басты. Ибрай шүрләп артка чигенде:

— Я, сук. Сугып кара!..

— Уйлаганым да юк. Ләкин бел аны, безнең тәгәрмәчкә таяк тыга торган булсаң...

— Тотып кыйнармын, димәкче буласыңмы?

— Юк, кыйнарбыз. Һәм бик каты итеп, бел аны,— диде Каюм һәм залга карап сөйли башлады. Ләкин Ибрай, әле бер, әле икенче сүз кыстырып, аңар сөйләргә ирек бирмәде.

— Ә син юкка әтәчләнәсең, Ибраһим,— диде Хәлим кабынып китмичә генә.— Без сине, кирәм дисәң дә алмыйбыз. Без команданы иң алдынгы пионерлардан оештырабыз. Ә син...

Хәлим сөйли башлагач кына кереп, арттагы парталарның берсенә барып утырган, сүз алса да соңыннан гына алырга уйлаган директор кулын күтәрде.

— Юк, син хаклы түгел, Хәлим,— диде ул парталар арасыннан алга уза-уза.—Әйе, әйе, хаклы түгел. Киресенчә, әгәр сез «Труд облагораживает человека» дигән сүзләр белән килешәсез икән, командагызга ал-

дыпгы булмаганнарны да алыгыз. Әйе, әйе. Шулай иткәндә сез бер атуда ике куянга тидерерсез. Мәсәлән, Ибраһим җәмгыять өчен әзме-күпме эш эшләр — менә сезгә бер куян; коллектив эчендә, эш эчендә кайнавы белән үзендә хезмәткә мәхәббәт тәрбияләр — менә сезгә тагы бер куян. Һәм моңысы иң симезе, дусларым... Ә Гөлчәһрәләр белән Ибраһимга мин шуны әйтер идем. Социалистик җәмгыять шартларында коллективтан читтә яшәү, үзең өчен генә, үз тормышың белән генә яшәү — зур оятсызлык... Бер нишләп булмый, әгәр коллектив сине кеше иткән икән, коллектив эше өчен кайчакта кайбер шәхси интересларыңны корбан итәргә дә туры килә, дусларым. Данко үз халкының исән калуы хакына йөрәген кызганмаган ич. Ә Ленин? Самодержавие шартларында революцион эш алып барган большевиклар? Нәрсә өчен алар үзләрен аямыйча көрәшкәннәр? Хәлимнең абыйсы Хәсән һәм аның кебек миллионнар үзләрен кем өчен корбан иттеләр? Безнең өчен, Ибраһим. Аннан мин сезгә тагын шуны әйтим: хезмәт укуга, уку хезмәткә комачауламый, дусларым. Алар берсен-берсе тутыралар гына, әйе, әйе, тутыралар гына...

Ибраһим борылып утырды.

— Тутыра бирсен, ә мин язылмыйм.

Һәм Ибраһим язылмады. Гөлчәһрәләр дә язылмадылар. Тәзкирә апа аларның әниләрен күреп тә сөйләшеп карады, барыбер ярдәм итмәде. Ә Ибраһимның әнисе Тәзкирә апаның өч килүендә дә чоланга качып калды.

Шулай да Тимур командасы төзелде. Шул ук сборда команданың командиры итеп Каюм, аның урынбасары итеп Хәлим сайланды (ни өчен киресенчә түгел, диярсез. Хәлимгә әле иптәшләрен куып җитү өчен байтак тырышырга кирәк иде). Ә аларга ярдәмгә педсовет класс җитәкчесе һәм биология укытучысы Тәзкирә апаны билгеләде. Хәзер Хәлим белән Каюмның Шәпиләргә эшне нәрсәдән башлап җибәрүне чамалау өчен кереп барулары иде.

Хәлимнәр кергәндә Шәпи (чандыр, яшенә карата кечкенә, холкы белән оялчан малай) ишек алдында сарыклар, казлар ашатып йөри иде. Башмак тананы мөгезеннән токтан да абзарга өстери, тана керми, миңа

монда әйбәтрәк диган шикелле, мәгри-мәгри, артка әстерәлә иде.

Шәпи, Хәлимнәрне күргәч, үзенең кыяфәтеннән оялып китте. Аның чәчләре чигәсенә кадәр төшеп үскән, бите юылмаган, пиджагы эченнән керләнеп беткән күлмәк якасы күренеп тора иде.

«Мыскыл итәргә кергән инде болар...» дип уйлап алды Шәпи һәм танасын ычкындырды да, эш тапкан булып, абзарга кереп китә башлады.

— Нихәл, Шәпи малай!

— Ару әле,— диде Шәпи, Хәлимнәргә таба борылмыйча гына.

Хәлим, аның каршысына чыгып, кулын сузды. Шәпи берникадәр вакыт уңайсызланып торды һәм каралып, ярылып беткән кулын пиджагына ышкыштырып алды да теләмичә генә Хәлимгә бирде.

— Әниең авырый икән, Шәпи?

— Авырый.

— Тереләмс соң инде?

Малай, Хәлимнәрнең мыскыл итәргә кермәгәннәрен күреп, ачыла төште.

— Терелми шул әле, Хәлим.

— Доктор киләме соң?

— Килә дә...

Котылган тана, тартышуым бушка китмәде дигән кебек, сарыкларга салган печәнне актарып-тузгытып ашый башлады. Шәпи кулына таяк алды:

— Һайт!

— Тимә, тимә. Каюм, әйдә, тот әле...

Каюм тананы мөгезеннән эләктереп алды. Хәлим аны, артыннан куып, абзарга кертте.

— О-о, синең монда янгыр үтә икән ич, Шәпи.

— Үтә шул... Томалаган саен саламын җил алып ташлый.

Хәлим шинелен салып тырма тешенә элде дә, сәнәк алып, абзар түбәсенә менде.

— Саламың бармы, Шәпи туган?

— Салам бар анысы.

— Кая, бер биш-алты көлтә ыргыт әле.

Шәпигә сәер тоелды. Яшел гимнастерка, хәрби фуражка, өр-яңа хром итекләр, медаль... Ә үзе түбәдә, кулында сәнәк...

Хәлим түбәнен тишекләрен салам белән әйбәтләп томалады да бастырыклап куеп, ишек алдына сикерде:

— Уку калып торган икән, Шәпи, ә?

Шәпи башын түбән иде. Яз көне, «алтынчыга күчтем, мактау белән күчтем» — дип, энисе янына шатланып кайтулары, җәйдән үк әзерләп куйган, хәзер кайдадыр аунап яткан яңа китап-дәфтәрләре исенә төште аның. Агроном булам дип дәртләнеп йөрүләре исенә төште. Һәм күзләренә яшь килде.

— Уку калды инде, Хәлим...

Хәлимнең күңеле тулып китте. Ул, хисләрен тарату өчен, тиз-тиз әйтеп куйды:

— Борчылма, Шәпи туган, калдыртмабыз. Булышырбыз без сиңа...

Шәпи гаҗәпләнгән күзләре белән Хәлимгә карады. Хәлим, кулын аның иңенә салып, кабатлады:

— Калдыртмабыз, булышырбыз...

Хәлим, Шәпинең энисенә дә шулай диде. Ләкин аның янынннан чыкканда ул бик күңелсез иде. Җыештырылмаган өй, керләнеп беткән түшәктәге авыру ана һәм караңгы почмактан боегып карап торган берсеннән-берсе кечкенә балалар. Бу күренеш дәрес вакытында да Хәлимнен күз алдыннан китмәде. Ә тәнәфес вакытында ул үзенең күргәннәрен Фәрдәнәгә сөйләп бирде.

Фәрдәнә:

— Авыл советында бик рәтсез кеше шул безнең, Апрт Мөхәррәме. Алыштырсыннар иде инде, һич ярдәм итми шундыйларга,— диде.

— Әйтермен, алыштырырлар,— диде Хәлим һәм шунда ук җитди тонга күчте:

— Безгә район комсомол комитетына шалтыратып карарга кирәк, Фәрдәнә.

— Шалтыраттым инде.

— Соң?

— Бик хуп күрделәр.

— Шәпиләрдән башлыйбыз, Фәрдәнә.

— Ярый, Шәпиләрдән дә.

Шул ук көнне дәрестән соң тимурчылар үзләренең көчләренә чамалап, өмә планын төзеделәр. Ә иртән, яңа яктырып килгәндә, сигез кыз, алты малай һәм класс җитәкчесе Тәзкирә апа Шәпиләргә киттеләр. Балаларның кайсының кулында балта, көрәк, кайсында

чиләк, сабын, мунчала иде. Артта кибән шикелле очлап, биек итеп өелгән бер йөк печән, аның артыннан бер йөк утын килә иде. Алда, ике бала кулында, озынча комачка эре хәрефләр белән язылган лозунг:

ФРОНТОВИК СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМ ИТИК!

Бу сәер күренешне карау өчен хатын-кызлар сава торган сыерларын, яга торган мичләрен ташлап чыктылар. Капка төпләрендә кешеләр күбрәк күренә башлагач, пионерлар шаулатып җырлап җибәрделәр:

Без эштә дә, укуда да алдынгы яшьләр,
Алдынгы яшьләр...
Фронтовик семьяларына булышыйк, иптәшләр,
Булышыйк, иптәшләр...

Шул җыр белән балалар Шәпиләргә килеп керделәр. Шул җыр белән эшкә дә керештеләр.

Кайсылары утын кисте, ярып лапас астына өйде. Кайберләре сыер сырты тиярлек булып өелгән тиресне бәрәңге бакчасына чыгарды. Кызлар мичкә, казан астына ягып җибәрделәр, стеналарны, идәннәрне юарга тотындылар. Җирләрен юып, класс җитәкчесе төннән килеп яккан мунчага кертеп әлделәр. Аннары ике кыз авыру ананы, кечкенә кызларны мунчага алып кереп юындырды. Алар мунчадан чыкканда өй танымаслык төскә кергән: чистарган, җылынган, авыр исе беткән, идәннәр токмач кунасы шикелле сап-сары итеп юылган, мич яңа яуган кар кебек, ап-ак итеп агартылган иде. Берничә кыз бала тәрәзә өсләренә газета кәгазеннән матурлап эшләнгән челтәрләр, тәрәзәләргә әле генә юып үтүкләнгән ак пәрдәләр корып торалар иде.

Авыру ананы, әкрен генә алып килеп, кабартып җәелгән, чиста тыш киертелгән түшәккә салдылар. Тәзкирә апа казаннан бер тәлинкә тавык шулпасы сосып алып килде.

— Ягез, Мәчтүрә җиңги, шуны эчеп карагыз әле.

Авыруның көл шикелле төссез йөзенә хәзер бераз кызыллык җәелгән, болганчык су төсле тонык күзләре ачыла, җанлана төшкән иде.

Менә аның иреннәрендә елмаю чагылды. Күзләре дә берникадәр вакыт елмаеп тордылар. Аннары ул күзләргә яшь бәреп чыкты. Авыру ана ябык куллары белән Тәзкирә апаның беләген тотты.

— Нинди генә рәхмәтләр әйтим икән инде сезгә,— диде ул һәм хискә бирелеп елап җибәрде.

— Еламагыз, Мәчтүрә җиңги. Безнең класс сезнең семьяны шефлыкка алды. Иртәгәдән башлап улыгыз да укырга йөри башлар. Сезнең өй эшегезгә булышып торыр өчен дүрт пионер беркетәбез.

Авыру ана ак җәймә читенә күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Шатлыгымнан мин, Тәзкирә күгәрченем, шатлыгымнан, күгәрченнәрем...— диде.

Авыруның ябык иреннәре кайнар, тәмле, хуш исле шулпага тиде. Бу вакыт аның аяк очындагы кечкенә кызлар мунча кереп чиста күлмәкләр киеп алгач, берсеннән-берсе матурланып киткән сабыйлар, авызларын чапылдата-чапылдата, тавык ботларын кимерә иделәр.

— Синеке тәмлеме, Фәһимә?

— Тәмле.

— Әй, минеке тәмле ул, Назира...

«Ватан» колхозының алтынчы класс балалары бу бөек эшне, мактаулы эшне, ниһаять, безнең җиңүне хәл итүдә азмы-күпме роль уйнаган эшне, әнә шулай башлап җибәрделәр.

Эш беткәч балалар Шәпиләрнең капка баганасына шундый бер такта кадакладылар:

Бу йорт безнең шефлыкта

6 нчы класс балалары

Бу яңалык турында кичкә таба бөтен авыл шаулады. Берничә көннән, шул мәсьәләгә багышланып, мәктәптә стена газетасы чыкты. Район газетасының да алдагы саны шул турыдагы мәкалә бизәгән иде. Район башкарма комитетында да кызыксындылар бу вакыйга белән һәм бу тәҗрибәне барлык мәктәпләргә тәкъдим иттеләр. Ә авыл советы председателен, кызылармеец семьясын шундый хәлгә китереп җиткерүен тикшерү өчен, көннәрдән бер көндә, салкын буранлы кичтә, Райисполкомның чираттан тыш утырышына чакырдылар.

Атна уэуга Гаязлар капкасын да:

Бу йорт безнең шефлыкта

5 нче класс балалары

дигән такта бизәде һәм мондый такталар «Ватан» урамнарында артканнан-арта барды. Алар арткан саен Хәлимгә эш артты, алар арткан саен Хәлимнең йөрәге тынычлана төште. Госпиталь начальнигының һәм әтисенең: «Ә бүген син анда файдалырак», дигән сүзләренең мәгънәсе ачыла төште.

6 КЕМ СОҢ СИН?

Хәлим дәресләрен әзерләп бетердә дә китап шүрлеге янына килде. Шүрлектә байтак кына матур әдәбият китабы бар иде. Берсен, икенчесен актаргалап карады, берничә битенә күз йөртеп чыкты да кире куйды. Әкрен генә килеп гармонен кулына алды.

Әллә кайтканнан бирле тотмаганга, әллә инде, бармакларын каләм талдырганга, гармонь кузгалып китә алмаган арба шикелле, ямьсез шыгырдап торды. Аннары Хәлим гармоньны, бөтен бармакларын йөртеп, сузып җибәрде. Башта аның уенда бер анык көй дә юк иде әле. Ә гармонь яртылаш сузылгач, әллә ничек, үзеннән-үзе уйналып китте:

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар...

Хәлим сүзләрне авыз эченнән әйтеп барса да, мәгънәләренә әһәмият бирмәде. Ә җырның өченче куплетына житкәч, кинәт тәэсирләнеп китте.

...Син кем, белмим синең исемеңне...

Хәлим гармонен кырт кисеп туктатты.

«Чыннан да, белмим бит әле мин синең исемеңне, кем син? Пәри-җенме, әллә югыйсә? (Аптырагач әйтәм инде.) Һәм ни дип бирдең син миңа ул яулыкны? Кем син, ә? Кем син?..»

Менә аның күз алдына дүрт кыз килеп басты: «Г» — Гөлчәһрә, Гөлзәһрә, Гөлгенә, Галимә. Хәлим, бармакларын гармонь телләрендә тоткан хәлдә, яулык яткан кесәсен терсәге белән капшап куйды:

— Кайсыгызның эше бу, ә?

Кызлар барысы да бертөрле итеп, көлемсерәп куйдылар һәм барысы да берьюлы юк булдылар.

— Тфү,— диде Хәлим. Һәм гармонен тартып җибәрде. Ул яулык турында уйламаска, онытырга теләп тарт-

ты гармоньны, ә гармонь, үч иткән шикелле, әлеге жырны дәвам итте:

...Исемеңне белмим, кем соң син?..

Хәлим башын чайкап куйды, гармонен бер тезеннән икенче тезенә күчерде һәм, башыннан бөтенесен дә чыгарып ташларга теләп, Әпипәгә күчте. Башын кыеклап гармоньга салды да телләренә еш-еш басты, каты итеп басты:

Бас, кызым, Әпипә...

«Ах, шайтан гына икән, тәмам чәнчелдегез ич!..» — Дүрт кыз тагын әллә кайдан килеп чыгып, бар да бертөрле биеп киттеләр. Әйләнгәләп йөрделәр-йөрделәр дә, вак-вак тыпырдап, Хәлимгә таба килә башладылар...

— Шайтан гына икән,— диде Хәлим тагын бер тапкыр һәм гармоненың бакасына шундый усал басты, гармонь елак тавыш чыгарып, жыерылып килде. Хәлим, ихтыярсыз, яулык турында уйларга тотынды.

Укуы тыгыз булса да, серле яулык турында уйланырга вакыт таба иде Хәлим. Яулык аның исенә, арыганчы укып, йоклый алмый ятканда төшә иде. Исенә төшә иде, ләкин аның серенә төшенүгә өмете беткәннәнбетә бара иде Хәлимнең. Ул, авылга кайтканнан бирле караштырып йөрсә дә, әлеге дүрт кызда да, бүтәннәрдә дә серле яулыкныкы шикелле жеп белән чигелгән әйбер күрмәде.

Гөлчәһрә белән Гөлзәһрәнең алъяпкычлары сары ефәк белән чигелгән, кофталары зәңгәр белән, Гөлгенәнең дә шундый белән, ә Галимәнең бернәрсәсе дә чигеп эшләнмәгән. Кыскасы, серле яулыктагы шикелле куе кызыл ефәк берсендә дә юк иде.

Хәлим хәзер дә шул турыда уйлап, әйтеп куйды:

— Жеп очын оста яшергәнсең, нәрсә әйтергә...— диде ул үз-үзенә,— кайсыгызның гына кулыннан килә икән бу кадәр оста итеп сер саклау?..

Ул, яулык иясен табу өчен, бер тапкыр үзенчә хәйлә дә корган булды. Яулыгын чиккән ефәкне әз генә өзеп алды да, аерым-аерым очратып, әлеге дүрт кызның дүртесенә дә күрсәтеп чыкты:

— Синең шушындый ефәгең юкмы?

Кызлар «сиңа нигә ул?» дип дүртесе дә бертөрле итеп гажәпләнделәр. Дүртесе дә «юк», диделәр.

«Яшерәсең, синең эш бу»,— диде Хәлим эченнән. Ә үзләренә әйтергә йөрәге җитмәде. Икенче бервакыт, шунда сизеп алырмын дип, кызлар дүртесе бергә сөйләшеп торганда, яулыгын чыгарып борынын сөрткән булды һәм кызларның берсендә мөгаен чагылып китәргә тиеш үзгәрешне көтеп торды.

— Ай-яй яулыгы,— диде берсе.

— Хәлим, күрсәт әле, фронттан алып кайттыңмыни? — диде икенчесе.

Башкалары да шулайрак итеп әйттеләр. Кыскасы, Хәлим көткәнчә, яулыкка карап кызарып китүче, оялып аска караучы булмады. Дүртесе дә, бир әле, Хәлим, үрнәген генә күчереп алыйм әле, дип яулыкка үрелде.

Яулык иясе капкынның монысына да капмагач, Хәлим «әллә башка кызлар микән?» дигән уйга килде. Ләкин авылда «Г» хәрефенә башка бер кыз да юк иде.

— Кызык. Ник яшергән була соң ул? Капчыкның печәнлектә икәнен белә алган, хәтта шунда менеп капчык төбенә салып төшәргә дә курыкмаган, ә бүген килеп, үзен әз генә булса да сиздереп куярга курка... Әллә алай түгелме? Әллә инде биргән дә онытканмы?.. Мин дә онытыйммы? Юк, кызык бит, кызык кына да түгел әле, бер юаныч булды бит ул яулык миңа... Бигрәк тә ялгыз калгач, иптәшләрдән аерылгач... Юк, ничек тә белим әле мин аның кем икәнен...

Хәлим гармонен сәкегә куйды да ялт сикереп торды.

— Хәзер беләм мин аны, болай итәм: иң шиклесе — Гөлчәһрә аларның. Шул инде бик оста итеп астан гына карап-карап ала... Хәзер барам да чакырып чыгарам, һәм сорыйм: — Ни өчен син миңа яулык бирдең? — дим...

Ләкин шул чакта яңгыраган чаң тавышы аның зиһенен таратып җибәрде. Чаң ниндидер җыелышка чакыра иде. Чаң тынарга өлгермәде, тәрәзә чирттеләр. Чиртүче Хәлимне атап, колхоз җыелышына чакырды.

— Килми калма, Хәлим. Зрә важный мәсьәлә.

Бу Хәлимне җыелышка беренче тапкыр атап чакырулары иде. Хәлимгә күңелле булып китте. Ләкин ул ишетмәмешкә салышып утырды. Анасының чакыруны кабатлавын теләде. Һәм шулай булды да: Шәмсия җиңги, улының колхоз җыелышларына йөрерлек булып үсүенә сөенеп, әйтеп куйды:

— Хәлим, әллә ишетмәдеңме, чакыралар ич, сине җыелышка чакыралар...

Хәлим, дулкынлануын яшерергә тырышып, урыныннан торды. Аш әзер иде.— Тагын нәрсәгә икән инде,— дигән булып сөйләнә-сөйләнә, аннан-моннан гына капкалап алды да, шинелен киеп, ишектән чыгып китте.

Бу җыелыш Хәлимнең уйларын яулык тирәсеннән, дүрт кыз тирәсеннән читкә алып китте. Бу җыелыштан соң Хәлимнең алар турында уйларга вакыты да, теләге дә калмады.

7 «СИННӘН ТИЕШ ТҮГЕЛ, РӘХИМӘ...»

Хәлим, уеннарыннан бүленеп, үзенә килеп сарылган кечкенә балалардан көч-хәл белән ычкынды да, тиз генә колхоз идарәсенә кереп китте. Эх, Каюмны эзләп йөреп соңга калган икән, булмады... Юлда уйлап килгәнчә, кәс-кәс басып, шинелен җилфердәтеп, түргә узып китә алмады — идарә халык белән шыгрым тулы иде инде, җыелыш башланып китәргә тора иде.

Кайтканнан бирле беренче килүе бит әле, Хәлим идарә эчен яхшырак күрү өчен, аяк очларына күтәрелде.

Тәмәке төтене. Төтен эчендә бишле лампаның зәгыйфь яктысы тагы да зәгыйфьрәк булып күренә. Ишектән килеп керүгә күзләрне чагылдырып җибәрә торган утызлы лампа юк хәзер түшәмдә.

Лампасы гына түгел, идарәгә җыелган халкы да бүтән. Элек бу зал зур, таза гәүдәле, кызыл путалы ирләр белән тулы була иде, хатын-кызлар җыелышка сирәк килә, килгәннәре дә бер тирәгәрәк, күбесенчә, арткы сафларның эчке урыннарына кереп урнашалар иде дә, сагыз чәйни-чәйни, пышым-пышым юкны-барны сөйләшеп үткәрәләр иде. Тагы да кыюсызраклары мич арасына ук кереп кысылалар иде дә, үзләренә килеп бәрелгән малайларга сүз әйтергә дә базмыйча, тын гына торалар иде. Хәзер исә җыелыш асылда хатын-кызлардан гыйбарәт. Чөнки эштә дә шулар бит хәзер, сугышка кадәр җиңел эшләрдә генә йөргән хатын-кызлар бөтен колхозны алып баралар: ат җигәләр, сөрәләр, трактор йөртәләр. Әнә ике хатын сөйләшеп утыра. Шулар бит инде бүген Хәлим мәктәпкә барганда озын арбага салып бүрәнә тарттыра иделәр.

Берсе Марзия җиңги. Элек ул колхоз идарәсен җыештыра, йомыш-юлларга йөри иде. Икенчесе Фәүзия апа, аш-су остасы. «Том агай алачыгы»ндагы Хлоя түтәйдән бер дә ким түгел. Аның ашлары турында сүз чыкса: — Ул, җаным, иске чабатадан ләвәш пешереп ашатыр,— дип сөйлиләр иде. Берәрсенең туйга әзерләнүе турында хәбәр таралдымы, аш-суларын Фәүзия әзерләсә генә ярар иде дип кайгырта башлыйлар, ул икәнне белсәләр, бармас җирләреннән баралар иде. Ә ничек киенә иде ул! Бүген төшкән килен диярсең!.. Аякта биек үкчәле каюлы читек, башта крахмалланган ак яулык, өстә нәфис тегелгән зәңгәр чәчәкле ак күлмәк. Ә хәзер!.. Аякларда тупас солдат итекләре, өстә сырган пиджак, сырган чалбар, биләндә кызыл пута, тәмам ирләрчә итеп киндер бияләй кыстырган. Ахрысы, эштән генә керешедер: кулында чыбыркы. Ул аны шундый оста итеп тоткан, хәзер, на-а, малкай! дип ирләрчә оста шартлатып куяр кебек.

Әнә комсомолка Айсылу. Колхоз хисапчысы. Ай, гел шунда шалт-шолт счет төймәләрен генә тартып утыртырга! Юк шул. Колхозда ирләр азайгач, үз эшенә сеңелесен өйрәткәләде дә, ул да өстенә сырган пиджак, башына малахай киеп алды. Олаучы ул хәзер. Көзен элеваторга икмәк ташыды, хәзер кырга тирес чыгара.

Әнә әлеге үзе кебек бөкре таяклы Хәтирә әби белән Фаизә карчык. Кайчандыр намазлык өстеннән төшмәгән бу ике ахирәт, хәзер көн саен колхоз амбарлары янында. Күбәү була алар анда. Зур-зур гына бодай өемнәре тирәли аяк бөкләп утыралар да орлык чистарталар. Зур күрсәтә торган пыяла күзлек кигән күзләре, һәр бөртекне кысыр орлык китмәсен дип, җентекләп тикшерә, мондый вак эшне әллә кайчан оныткан бармаклары калтыранып әкрен кыймылдый...

Балалар да байтак җыелышта. Унөч-унбиш яшьтәгеләр. Аларның урыннары элек тышта, тәрәзә төбендә, баскычта, уза китсә — ишек төбендә була иде. Аннан да әле аларны, һайт, җир кортлары! дип куып чыгаралар иде. Бүген исә алар да үзләрен җыелышның тулы хокуклы кешеләре итеп беләләр һәм халык арасында үзләрен олыларча тотып, әдәпле генә утыралар.

Ил агасы — картлар бар да бер тирәдә. Алар алгы сафларның кырый урыннарына бер төркем булып утыр-

ганнар. Әнә Закирҗан бабай. Кайчандыр, сугышка кадәр колхозда кешеләрне эшләүчеләргә һәм эшләмәүчеләргә аерып йөрткәндә, ул соңгы исемлектә йөри иде. Аны бары мич башында да, кояшлы көннәрдә капка төпләрендә очратырга мөмкин иде. Сугыш башлангач, әйтерсең, аның яшен ун-унбиш елга киметтеләр, бер мәл йортындагы мал-туары тирәсендә кыймылдап маташты да колхоз председателенә килеп эш сорап алды. Шорник дияр аны хәзер, дилбегәсен, камытын, ыңгырчак, шлеясын шул карап тора. Хуҗалыкчан һәм бик кырыс карт. Шуның кызыгын карап торып бит инде бер көн Хәлим дәрескә соңга калды. Таягына таянып, үзенең өйрәнчегенә нәрсәдер тукып килә иде, артта майланмаган арба тәгәрмәчләренең иләмсез шыгырдауларын ишетеп, бөтен гәүдәсе белән борылды. Кемдер станциягә печән илтә икән. Бабай печән өстенә йөзтүбән капланган яшүсмергә текәлеп карап торды да эченнән генә: «Ах, синмени әле бу...» — дип куйды. Йөк килеп җиткәч, таягы белән тегенең кабыргасына төртте.

— Нәмәстә? — диде яшүсмер, бабайга усал һәм кимсетүле карап.

— «Нәмәстә» түгел, «исәнме», — диде бабай оныгын кызарту өчен. Һәм кыска гына итеп боерык бирде:

— Төш!

Онык ашыкмады.

— Төш!

Онык теләмичә генә шуып төште.

Бабай аның күзләренә сүзсез генә карап торды да гади генә итеп әйтте:

— Бар, бригадага барып дегет алып кил...

— Станцадан кайткач, баба-ай...

— Атның бер кабат җан тирләрен чыгаргачмы? Юк инде, хәзер майлыйсын.

Закирҗан бабай белән ярдәмчесе икәүләп оныкка арба майларга булыштылар. Арбаны майламый йөрүнең зарары турында бабай җелеккә шундый сеңдереп тукыды, ут астындагы оныгы гына түгел, бер читтән тыңлап торган Хәлим дә һичбер вакыт арбасын майламыйча йөрмәскә ант итте.

Аннары Закирҗан бабай йөктән коелып калган печән бөртекләрен күрде. Ул шулкадәр аз, йөк артыннан

чүпләнеп килүче кәҗә тәкәсе дә канәгать түгел иде. Бабай исә кашын җыерып, печәнне оныгына күрсәтте.

— Нәрсә бу?

— Ат аунаган җирдә төк калмый булмый инде, бабай. (Янәсе, син үзең дә шулай ди идең.)

Бабай бу кинаяне сизде, шуңа күрә тагы да усалрак итеп әйтте:

— Иске хикәят! Бу нәмәрсә, дим?

— Ну, үлән...

— Ә йөгең нәрсәдән өелгән, дилгез нәрсәдән мөлдерәп тулган?.. Станцага җиткәнче ни күрә инде синең бу йөгең?!. У-у, әниең яламаган малай!..— диде бабай һәм оныгы белән үзенең өйрәнчегенә печәнне бушатып, бер бөртеге дә коелмаслык итеп өяргә кушкач, картларча алпан-тилпән атлап, таягына юри каты таянып, амбарларга таба китте.

Сугыш киеренкелеге бер Закирҗан бабайга гына түгел, олысына-кечесенә йоккан, бу кешеләрнең һәрбер хәрәкәтләрендә сизелеп тора иде. Әнә яшелчә звеньевое. Бәрәңгесе, кишере, кәбестәсе, чөгендере алынган, заданиесе үтәлгән. Хәзер аның бернәрсәдә дә гаме булмаска тиеш кебек. Ләкин юк шул... Әнә нинди җитди ул, нинди сагышлы. Әйтерсең, ул нәкъ шундый булырга тиеш, әйтерсең, җитдилеген әз генә киметсә, киеренкелеген бушатса, дөнья җимереләчәк... Гүяки, бу нәрсәләр катгый тыела дигән боерык чыккан: кешеләрдә сүлпәнлек, гамьсезлек беткән. Мәгълүмегез Муллаәхмәт абзыйны гына күрегез, утыруы ук бүтән бит!.. Бар, хәзер аңар, Гитлер булып кылан әле дип әйтеп кара!..

Председатель, өстәл аркылы сузылып, картлар белән нидер киңәшеп алды да, урыныннан күтәрелде. Мыегын як-якка сыпырды ул һәм инде суы әчелеп беткән китек авызлы графинга мундштугы белән бәргәләп алды.

— Җәмәгать! — диде һәм сыек кара белән язылган соры кәгазьне лампага якын тотып караштыра башлады. Укый алмагач, сүгенеп куйды.

— Тфү, башың беткере!.. Болай яши идекмени без, башың беткере! — диде председатель һәм кәгазьне лампага тагын да якынрак китерде.

Ул «башың беткере»не беркемнең дә исемен телгә алмыйча әйтте. Ләкин аның бу сүзләрне кемгә карата әйткәнен барысы да белә иде.

— Әйтмә инде, Сәлимҗан,— диде Закирҗан бабай,— күз күрмәгән, колак ишетмәгән афәт булды бу.

— Ну бер тончыгыр әле үзе дә тончыгуын.

— Ул кайчан тончыгыр әле, ә бүген менә безне тончыктыра...

— Тончыктыра, мәлгун...

Председатель мундштугы белән тагы графинга бәргәләп куйды.

— Башлыйбыз, җәмәгать! — диде ул һәм, соңгы айларда үткәрелә торган һәр җыелыштагыча, халыкара хәлләр, фронт хәлләре турында сөйләп китте. Бу бик озак барды. Ул инде колхозчыларның күңелдән белеп бетергәннәрен дә кайта-кайта сөйләде.

Белмим, тагы күпме сөйләр иде, аны почта Гайнулла кереп бүлде. Гайнулла абзый, халыкны ырып-ерып алга үтте дә, сумкасыннан газеталар алып, председатель алдына өстәлгә салды һәм газеталар өстендәге дәфтәр бите кадәр генә кәгазьгә төртеп күрсәтте. Председатель игътибар итмәгәч, почтальон кәгазьне алып, аның күзләренә якын китерде. Тегесе бу юлы, сүзен бүлеп, күзләрен кәгазьнең беренче юллары өстендә йөртеп чыкты да, бөтен гәүдәсе белән өстәл аша лампага таба үрелеп, укый башлады:

«Совет информбюросыннан...»

Бу сүзләргә гадәтләнеп беткән кешеләр, күңелсезләнеп, башларын түбән иделәр. Ләкин председатель бу юлы гадәттәгечә, «Бүген безнең частьлар каты сугышлардан соң...» дип алып китмәде, көр тавыш белән, тантаналы итеп, яңа сүзләр әйтте:

«Соңгы сәгатьтә».

Зал ниндидер яңалык сизеп, хәрәкәтсез калды. Идарәдә чебен очканы ишетелерлек тынлык урнашты. Председатель, бер күз ташлау белән, халыкка карап алды да укып китте:

«Шушы көннәрдә Сталинград шәһәре районында безнең гаскәрләр...» — Председатель алдагы сүзне әйткәнче әз генә тукталып торды. Ләкин ул — көткән кешегә бик озак булып тоелды. «Әйт инде, әйт,— диде һәркемнең йөрәге,— сузма инде, Сәлимҗан!..» Председатель дәвам итте: «...безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмгә күчтеләр һәм, дошманны куа-куа, алтмыш-җитмеш километр алга киттеләр!»

Моны ишетүгә яшьрәкләр ура кычкырып кул чабарга тотынды. Кайсы берсе әллә төшенеп җитмәде, әллә кабат ишетергә теләп, ни булган да, ни булган дип, берберсеннән сораша иде.

— Дошманны куа-куа, дигән җирен тагын бер тапкыр укы әле, Сәлимҗан,— диде Закирҗан бабай.

Үзе дә кул чабуга күчкән председатель кабат укымады, үз сүзләре белән сөйләп бирде: — Сталинград янында безнекеләр — һөҗүмгә күчкән, менә шул... Тегеләрне куа-куа алтмыш-җитмеш километр алга киткән...

Кешеләр берникадәр вакыт, бу шатлыкны күз алларына китереп, йөрәкләренә сеңдереп, тынып тордылар. Аннары, алдан сөйләшеп куйганнар диярсең, бар да берьюлы кул чабарга, төрле шатлык авазлары кычкырырга тотындылар. Председатель графинга стакан белән шакый-шакый кычкырды:

— Безнең урамда да бәйрәм башлана, иптәшләр!

Председательнең сүзләрен ишетер өчен генә бераз тынып торган халык тагы да катырак шаулый башлады.

— Ура!.. Ура!..

— Кызыл Армия яшәсен!

— Ура!..

Председатель халыкны туктарга өндәмәде.

— Шатлан, шатлан! — диде ул эченнән генә.— Бу бит синең бик күптән хыял итеп йөргән шатлыгың...

Ә халык тына төшкәч, председательнең йөзе тагын уйчанланып, сагышланып китте:

— Ләкин, иптәшләр, кызыл армиянең бүгенге уңышы никадәр зур булса да, җиңүгә ерак әле. Кызыл Армия җиңүне яулап алсын өчен, безгә дә биредә, тиңсез батырлыклар күрсәтергә туры киләчәк. Авыл Кызыл Армиягә, илгә, бик күп, бик күп икмәк үстереп бирергә тиеш булачак. Ачык кына итеп әйткәндә, безнең колхоз алдагы елда бу бурычны үтәми калу куркынычы алдында тора... Ашерен-батырын түгел, туганнар, атлар начарланып китте. Колхозның аларны язга алып чыгарлык, сабанга яраклы итеп алып чыгарлык чамасы юк. Куркыныч менә кайдан башлана... Безнең кулда бер генә чара бар: без, колхозчылар, үз авызыбыздан өзеп булса да, алтмыш биш атның егерме биш башын язга кадәр үз икмәгебез белән тәрбияләп чыгар-

га тиеш булабыз. Без, ил агалары белән киңәшә торгач, шундый фикергә килдек...

Әйе, башка чара юк иде. Председательдән соң чыгып сөйләүчеләр дә бу фикерне якладылар. Сәлимҗан тагы күтәрелде:

— Башлап мин үзем, иң ябык атлардан бер атны язга кадәр үз келәтемнән ашатып чыгарга өстемә алам,— диде ул һәм «Тәрбиягә ат алучылар исемлеге», дип язылган озынча кәгазьгә үзен беренче итеп язып куйды.

Ат — песи баласы түгел. Ә колхозчының болай да авызын ачса, үпкәсе күренергә тора... Кешеләр бер-берсенә карашып алдылар. Мыек астыннан елмаеп куючылар да аз түгел иде. Ләкин бу авыр йөкнең, шул ук вакытта колхозны кимсетә торган гайре табигый чараның никадәр зарур икәне күпләр өчен көн кебек ачык иде. Агитаторларга әллә ни өндәргә кирәк булмады. Ике, өч, биш-алты кеше кушылып бер ат алырга теләүчеләр табылды.

Менә арткы рәтләрнең берсендә берничә хатын-кыз арасында кулына күкрәк баласын тотып утырган бер хатын күтәрелде.

Бу хатын берсеннән-берсе бәләкәй өч бала анасы булып, шушы көннәрдә генә иренең корбан булуы турында хәбәр алган иде һәм бу турыда халык инде белә иде. Хатын, баласын бер кулыннан икенчесенә авыштырды да, беравык башын түбән иеп, эндәшми торды. Кешеләр аны ире кайгысын әйтә дип көттеләр. Ләкин хатын бу турыда әйтмәде. Уйлады гына ул бу турыда. Уйлады да болай диде:

— Минем дә Гитлерда үчем бар. Үзегезгә мәгълүм, Хәмдия белән Рәшидәнең икесәтә. Без бу үчебезне алмый калмаска ант иттек... Әгәр без өчәүләп колхозның бер атын язга кадәр тәрбияләп чыга алсак, бу Гитлер йөрәгенә бер пуля булыр микән, ә, Сәлимҗан? Үч алу булыр микән? Без үзебез булыр дип уйлыйбыз...

Ат турында сүз кузгалуга ук күңелсезләнә башлаган Хәлим хатынның шулай дияюенә бөтенләй алмашынып китте. Ул колхоз председателенең хатынга җавабын, кешеләрнең, сездән тиеш түгел, Рәхимә, балаларыгызны карап, хуҗалыгыгызны бөтен итеп алып чыга алсагыз да бик җиткән дигәннәрен, һәм Рәхимә җиңгиләрнең шулай да, исемлеккә җиденче булып

язылуларын көтеп тормады, тәрбиягә ат алу турында әнисе белән киңәшү өчен, өенә йөгерде.

Башта ул әнисенә Кызыл Армиянең Сталинград фронтындагы уңышы турында сөйләде. Аннары үзенең уен әйтте:

— Менә бу, ичмасам, ярдәм дисәң дә ярдәм була, әни, фронтка бик зур ярдәм була, әни,— диде Хәлим яктырганнан-яктыра барып. Ләкин Шәмсия җиңги бу уйны, Хәлим көткәнчә, күтәреп алмады, шулай ук, кисәк әйтеп, Хәлимне күңелсезләндерәсе дә килми иде. Ул сүзен:

— Ай, улым, бу эш безнең кулдан килмәс бит,— дип башлады. Ләкин, Хәлимне мондый сүзләр белән генә җиңеп булмаячагын күргәч, чоланга алып чыгып, нибар онны, борчакны, ярманы күрсәтте:

— Менә бөтен байлык шунда, улым. Күрәсең, үзебезгә дә янага җитәр-җитмәс...

Аннары Шәмсия җиңги бәрәңгенең дә янага тартыпсузып торганда гына җитәрлек икәнен исәпләп күрсәтте.

Шәмсия җиңги дөрес исәпләде, ләкин Хәлим тынычланмады. Ул һаман үзенекен итте. Әнисе әз генә дә йомшамагач, кызып китеп, ана хәтерен калдырырлык сүз дә әйтеп ташлады. «Саран син, әни, менә шул!..» диде ул һәм шунда ук гафу үтенде дә әнисен үгетләргә керешге:

— Алайса бер генә ай ашатыйк, әни. Әни, дим, ә? Ашатыйк инде, әни... Ә ашатмасаң, алар кырыла, әни. Ат кырылса, колхоз да кырыла. Кызыл Армиягә ипи булмый. Ә ипиесез җиңеп булмый, әни җаным. Немец җиңә безне ул чакта...

Шәмсия җиңги, ачуланып, Хәлимне бүлде:

— Авызыңнан җил алсын. Нәрсә син!..

Хәлим әнисен бүлде:

— Җиңә шул менә...

Шәмсия җиңги уйга калды. Хәлим җәберсенеп әйтеп куйды:

— Рәхимә апа булып Рәхимә апалар эшләгәнне эшләмә инде, җә...

Шәмсия җиңги тәэсирләнеп башын күтәрде:

— Ник, Рәхимәләр кишләде?

— Мәчет яны Рәшидә, тагын түбән оч Хәмдия өче-

сенә бер атны — сабанга кадәр үз келәтләреннән ашатып чыгарга булдылар. Менә нишләделәр.

— Дөрес ишетмәгәнсендер, улым...

— Бик дөрес ишеттем, бөтен кешедән алда шулар торып кычкырды.

Шәмсия җиңгигә кинәт уңайсыз булып китте. Бер сүз дә әйтмәде ул. Һич кирәкмәгәнгә мич алдындагы самоварга барып тотынды. Һич кирәкмәгәнгә мич аралыгына кереп чыкты. Сукыр лампаны күтәрә төште, аннан тагын кысты.

— Ярый инде алайса,— диде ул бераз торгач,— берәр атна тырышып карыйк. Барып чыкмаса...

Хәлим кайтып кергәндәге шикелле үк яктырып китте, нишләрен белмәде. Йолдызлы бүреген бер киде, бер салды, әнисен килеп кочаклады:

— Барып чыга, әни, чыга. Түзәрбез, әни. Мин коры бәрәңге белән торырга да риза, әни, тик Гитлер гына җиңелсен...— диде ул һәм бияләйләрен алды да ишеккә йөгерде. Бусагадан атлагач, кире борылып килеп, тагын әнисен кочып алды. Үпте-үпте дә йөгереп чыгып китте.

8

ШӘЕХТАЙ, ШӘЕХТАЙ!

Хәлим колхоз идарәсенә килеп җиткәндә, җыелыш таралган иде инде. Идарәдә дежур әби йокы белән көрәшеп, бәйләү бәйләп утыра иде. Ул председательнең яңа гына кайтып киткәнен әйтте. Хәлим аның өенә йөгерде. Өендә, аны районнан Акбуага телефонга чакырттылар дигәч, шунда чапты. Хәлим Сәлимҗан абзыйны эзләп табып, аның «Илшат» колхозы председателе белән сүзе беткәнен көтеп торып, ниһаять, язу алып кайтканда ярты төн авышкан иде инде. Хәлим бер җамыяк катык ашады да, чишенеп, урынына ятты. Йокларга түгел, болай гына, ял итеп кенә ятмакчы булды ул. Ләкин, үзе дә сизмәстән, йоклап китте, ә уянганда кышкы таң атып килә иде инде. Хәлим, хәтта юынып та тормады, өстенә ни эләкте шуны эләктереп конюшнига йөгерде.

Конюшнянык аргы башында пыяласы корымланып беткән бердәнбер фонарь эленеп тора. Аның яктысы бик зәгыйфь булып, үз әйләнә-тирәсен генә яктырткан,

ике яклап тезелеп киткән ат бүлмәләре бөтенләй күренми дә иде.

Хәлим тар юл буйлап, нәрсәләргәдер абына-сөртенә, фонарьга таба йөгерде.

— Әхмәтҗан абзый!.. Әхмәтҗан абзый, дим!

— Әү, әү! Кем анда?

— Мин, Әхмәтҗан абзый.

Өлкән конюх Әхмәтҗан абзый кечкенә тәрәзә аша тышка тирес чыгарып тора иде. Кулын каш өсләренә күтәрде дә якынаеп килгән Хәлимгә таба сузылып карады:

— Зиннәт төпчеге дип әйтимме...

— Әйе, Әхмәтҗан абзый.

Өлкән конюх бер кулын авыртып киткән биленә куйды, икенчесе белән сәнәгенә таянды.

— Бәй, нишләп йөрисең әле син?

Хәлим каушамаска тырышты, ләкин каушады. Ул председатель язуын кесәсеннән бер алды, бер салды.

— Ат тәрбияләргә язылдым, Әхмәтҗан абзый,— диде ул чиксез дулкынланып.— Менә язуы да...

— Тәрбиягә дигән атлар беркетелеп бетте бит инде, энем.

Алайса, бик яхшы. Миннән калмады... Әнием дә тынычланыр, дигән уй килде малайның башына. Ә кичә өчесенә бер ат тәрбияләргә алынган солдаткалар күз алдына килгәч, уңайсызланып китте. Кеше ни әйтер? Ә эти, колхоз рәисе?..

Хәлим, кинәт кабынып, сәнәген тирес өеменә батырырга торган конюхның кул астына керде:

— Калгандыр әле, Әхмәтҗан абзый. Мин ярты төн житкәндә генә Сәлимҗан абзый янында булдым. Ул өч-дүрт атны әйткән иде.

— Һәй-й инде аннан бирле!.. Түбән оч Гыйлажи әлерәк кенә килеп соңгы алашаны өч атнага үзенә яздырып китте. Әнә бер Шәехтай гына...

— Соң шул Шәехтайны, Әхмәтҗан абзый...

Конюх, Хәлим әйтеп бетергәнче үк, көлеп җибәрде.

— Нигә көләсең, Әхмәтҗан абзый?

— Өметсез ул, энем Хәлим. Юк инде ул. Барга санама син аны. Тере хәсрәт.

— Шулай да, карап карыйк әле, Әхмәтҗан абзый, ә?

Конюх сәнәген тирескә кадады да ашыкмыйча гына тәмәке төрде, кесәсеннән бер тимер кисәге, чакма таш, мамык алып, ут чыгарырга кереште. Караңгыда инә очы кадәр генә очкыннар, тимерче утлы тимергә суккандагы шикелле, як-якка сибелеп юкка чыктылар. Мамыкка төшкәннәре дә, янып китә алмыйча, сүнә барды. Конюх чакмасын кесәсенә салып фонарь янына килде. Капкачын сакланып кына ачып, тәмәкесен кабызды да артында басып торган Хәлимгә таба борылды.

— Атаң дус кеше иде, дөресен әйтим мин сиңа, азапланып йөрмә, энем, син аның белән. Барып чыга торган түгел. Артык ипиең бар икән, әнә армия фондына тапшыр. Ә моңардан... (конюх кулын селкеп куйды). Моңардан сөт тә юк, йон да юк, энем. Шушы көннәрдә аяк сузса кирәк...

— Ә бүтән юкмы, Әхмәтҗан абзый?

— Бетте. Кичтән киләләр аны. Әйбәтләп ашатканда арслан була торганнар бар иде. Һа-а... мин бу хәл булмас дип белгән идем. Сугыш башлангач, халык әллә нишләп китте дип әйтимме... бер кич эчендә бит... Мыек Сәләхи белән Кубыз Яруллага кадәр икесенә берне яздырып киттеләр. Ә үзләренең каккан казыклары да юк.

— Шулай да, Әхмәтҗан абзый, карап карыйк әле шул Шәехтайны...

Конюх Хәлимне тиргәп ташларга уйлады. Яхшылап әйткәннең кадерен белмәгәч белмәссең икән, фәлән-төгән, димәкче булды, һәм шунда ук бу уеннан кайтты.

— Әйдә инде, күңелеңдә калмасын,— диде ул. Хәлимне күп бүлемнәрнең берсенә алып килде.— Менә кара инде алайса,— диде конюх, һәм фонарьны, элек башын күр, дигән төсле атның баш очында тотып торды. Аннары әкрен генә сырты буенча уздыртып, койрык өстендә туктатып торды һәм, арт аяклары буенча алып барып, тоякларына кадәр төшерде.

Хәлим, күзләрен фонарьга ияртеп, ат өстендә йөртеп чыкты һәм өметен тәмам өзеп, тел кагып куйды. Конюх фонарьны Хәлим битенә якын китерде:

— Я, күңелең булдымы инде?

Хәлим бер сүз дә әйтмәде.

Әгәр Хәлим, кайчан да бер, ат басып торган килеш тә үлә дип ишеткән булса, бу атны үлгән дип уйлар

иде. Әз генә дә җан әсәре юк иде аңарда. Колаклары шиңгән әрекмән төсле салынып төшкән, эренле күзләре шундый җансыз итеп йомылган, аларның кайчан да булса ачылачакларына ышану кыен иде. Аяклары, берәр юньсез балта остасы исерек чакта юнгалап куйган агач аяклар шикелле, килешсез иделәр: алгылары, һәр ике якка авуы мөмкин булган өйне терәткән терәүләр шикелле, атны як-яктан терәп торалар, ә арткылары бер ноктага басканнар да каккан казык шикелле катып калганнар. Иләмсез эре кабыргалары югарып калган тиресен төртеп торалар, кабыргалар торган саен тирене күбрәк этәләр кебек һәм менә-менә барысы берьюлы тирене ертып чыгарлар да ат дигәнебез таралып китәр кебек иде.

— Шәехтай, Шәехтай!..

Гадәттә ат, үзенең исемен ишеткәч, берәр хәрәкәт ясамый калмый. Яхшырагы кешнәп, гәүдәсен биетеп ала, иң юньсез дигәне дә, башын аз гына булса да борып, сиңа карап куя, һич югында койрык очын гына булса да селкетеп ала. Бу берсен дә эшләмәде.

Хәлим атның ял астына кулын тыгып, бераз сыйпап торды, һәм улактан бозланып беткән башакны куш учлап алып, атның авызына китерде. Китерде дә тәмам өметен өзде — ат, ичмаса, иренен генә дә кыймылдатып карамады.

— Булмый, җан кисәгем, бодай күмәчен чәйнәп бирсәң дә булмый инде ул бер вакыт үткәч...

— Кызганыч.

— Кызганып нишләтәсең инде аны?

— Мин бик кызганам, Әхмәтҗан абзый. Әле өченче елны гына мин, аңар атланып, малайлар белән ат сакларга барган идем. Мондый түгел иде әле ул чакта.

Хәлим шулай диюгә конюхның кәефе кырылды. «Малай, малай, ә кая таба каера!.. Янәсе, атны мин шушы көнгә калдырган...» дип уйлап алды. Ул моның өчен Хәлимгә, бәлкем, берәр усал сүз дә әйтеп салган булыр иде, шул чакта абзар ишеге шыгырдап ачылды. Тышта яктырып килә иде инде. Абзарга палас кадәр генә якты төште. Шул якты эчендә ишектән кереп килгән бер кеше күренеп калды. Ишек ябылгач, ат абзары тагын караңгыланып китте. Керүче караңгылык эчендә күздән югалды.

— Һәй, кайсыгыз анда?

— Мин идем лә, Шәйхаттар бабаң... Низам, синме сон?

— Түгел, Әхмәтҗан, Шәйхаттар бабай,— диде конюх һәм фонарен ишеккә таба сузды. Конюхның Шәйхаттар бабай дигәне тирес өеменә булса кирәк, мәтәлеп китте.

— Кая, кил әле бирегә,— диде ул, ачуланып,— егыла яздым ич, күзем күрми! Нәрсә карап торасың!..

Конюх ашыга-ашыга бабайны каршы алырга китте. Хәлим атка тагы бер эндәшеп карады да, тәмам өметен өзеп, кайтып китәргә кузгалды. Ә бабайның: «Шәехтай, Шәехтай, кайда син, бәбкәм!?» — дигәнен, атның моңар каршы тутыккан зәгыйфь тавыш белән пошкырып җавап биргәнен ишеткәч, туктап калды. Ә инде Шәйхаттар бабай килеп җитеп, ялыннан сыйпауга атның башын борып, сыңар күзен ачып карап алуын күргәч, тәмам гаҗәпләнде. «Синең дә исең китәме бу эшкә?» дигән шикелле итеп, конюхка карап торды ул. Аннары бабайга күтәрелеп карады.

Хәлим аның турында, үзен аз күргән булса да, күп белә иде, бик билгеле кеше ул. Үз гомеренә туры килгән сугышларның өчесендә дә булган: япон сугышында Порт-Артур капкасы төбендә сугышкан. Курку белмәс разведчик герман сугышында Георгиевский крест белән бүләкләнгән. Гражданнар сугышында Идел, Кама буйларында сугышып йөргән. Сальск сахраларына кадәр барып чыккан. Легендар командарм Буденный, полководец Фрунзе турында ниләр генә белми ул!.. Аларга ихтирамы шундый зур, рәсемнәрен шәмаиленең[1] якъягына элгән. Озак йөреп кайтып керсә күзе шуларда. Их, брат, брат! ди ул үзенең яшьли вафат булган командиры Михаил Васильевичның көләч йөзенә карап. Әле кичә генә кебек бит: — «Димәк, сугышырга килдек, картлач?..» — «Сугышырга, иптәш командир...»

Ә яшьли нинди пәһлеван була бу кеше!.. Көннәрдән бер көн авылга, ике тәгәрмәчле бизәкле арбага ишәк җигеп, илдән илгә күчеп йөрүче бер немец циркачы килеп төшә. Төрле фокуслар күрсәтә бу, ә азакта арбасы белән ишәген бергә күтәреп, бер урында таптанып тора.

---

[1] Рам эченә язып куелган дини текстлар, рәсемнәр.

— Их сии, цвай, драй!.. Шәйхаттар бабай кызып китеп, циркачны ишәге янына арбага утырта да, иңнәре белән күтәреп алып, урамның бер ягыннан икенче ягына чыгарып куя. Моны күреп халыкның гына түгел, циркачның да исе китә. Ул Шәйхаттарны үзе белән китәргә димли. Көрәшче итәм мин сине. Петербург, Берлин, Париж циркларында мәйдан тотарсың.

— Минем үз мәйданым да әйбәт...

Ләкин хәзер аның кайчандыр шундый булганлыгына ышану да кыен. Соңгы елларда бөтенләй бетәшә. Элеккедән бары бер буе гына кала картның.

Хәлим аның янында үзен кечерәеп киткән кебек сизде. Ат белән конюх та аның янында кечерәеп калдылар. Ул шундый озын буйлы иде, аның бер стандарт белән тегелгән телогрейка җиңе беләзеген чак томалаган, сырган чалбарының балаклары тубыкларыннан узып тора. Бабай, гүя аларның тагы да күтәрелеп китүләреннән курыккан, сүс белән бәйләп куйган. Билендә дә шундый ук сүс. Чишеп җибәрдең исә, зур-зур калак сөякләре, янбаш һәм иңбаш сөякләре барысы берьюлы коелып төшәрләр кебек.

Ә нишләп шулай бирешкән соң ул?

Ул бу турыда үзе сөйләп йөрергә яратмый, ә авылдашлары яхшы хәтерлиләр. Шәйхаттар бабай колхозлашу елларының активисты була. Көннәрдән бер көн кулаклар, аның шәһәрдән яңа машиналар төяп кайтканын саклап торып, бик яман кыйныйлар, аяк табаннарын кендек белән төяләр дә урмандагы бер тирән чокырга ташлап китәләр. Колхозчылар эзләп килеп тапканчы, ул шунда эрүсәгән кар эчендә ике тәүлек ята. Аның сәламәтлеге шуннан какшап кала. Бөек Ватан сугышы башланганда ул инде Казан арты авылларыннан бер авылда кызы белән кияве тәрбиясендә тора һәм үз сүзләре белән әйтсәк, кабер якасында була. Ә кияве белән оныгы фронтка китеп баргач, кызы Казанга барып ипи заводына эшкә кергәч, үз куышына, Никкүчтемгә әйләнеп кайта.

Бабай атның алдына чыгып, аның күзләрен томалап торган чәчен агач тырма тешләре шикелле озын, арык бармаклары белән тарый-тарый сөйләнеп куйды:

— Мин инде сине алып киткәннәрдер дигән идем. Кара, ничек сиңа бирсенең дә мәхәббәте төшмәде соң?

Үземә пасыйп, күрәсең, Әхмәтҗан, мә язуын. Мал итеп бирим әле шуны үзенә.

— Куй, Шәйхаттар бабай,— диде конюх, бабайның сүзләрен чынга алырга да, алмаска да белмичә.— Аны нәрсәң белән тәрбияләмәкче буласың?

— Аньсы минем эш. Мә язуын, минем исемгә язып куй,— диде Шәйхаттар бабай һәм кесәсеннән исләре аңкып торган бер телем йомшак ипи алып атка каптырды.

Моны күреп Хәлим елап җибәрергә җитте. Ул конюхның үзенә борылып каравын көтте. Алдадың син мине, Әхмәтҗан абзый, миңа бирәсең килмәгәнгә генә яманладың, димәкче булды. Ләкин конюх Хәлимгә әйләнеп карамады.

Ул арада бабай ат тирәсендә хуҗаларча кайгыртып йөри башлады. Астын көрәп чыгарырга уйлагандыр ахры, кулына тимер көрәк алды.

Хәлим, күп уйлап тормастан, һөҗүмгә күчте: атның ялына ябышты да, гасәбиләнеп, аны ишеккә таба бора башлады.

— Ат менеке, бабай. Мин аны кичә үк үземә яздырып куйган идем.

— Ничек?

— Шулай. Җыелыш бетүгә килдем дә яздырдым,— диде Хәлим. Ул конюхка, син дә шулай дип әйт инде, дигән шикелле, ялынулы карап торды.

Конюх Хәлимне аңлады. Бәлкем ул Хәлимне яклаган да булыр иде, Шәйхаттар бабай тотынды:

— Җыелыш бетүгә яздырып куйдың? Ә мин аны, балакаем, син туганчы ук яздырып куйган. Әле син белмисеңмени минем аны кайчан яздырып куйганны, ничек яздырып куйганны?

Билгеле, моңысын да ишеткәне бар иде Хәлимнең. Ләкин әллә кайчан, бакчага йөргәндә үк, анда да бабайның үз авызыннан түгел. Шуңар күрә ул эндәшмәде. Ә Шәйхаттар бабай киртә буендагы ярык улак башына килеп утырды да сораганны да көтмәстән сөйләп китте:

— Егерме ел гына түгел бугай инде аңар... Ә син утыр, егетем, арырсың, озын итеп сөйлим мин сиңа... Кая, Әхмәтҗан, үз кулың белән берне чоркап бир әле. Алай юан итмә, йөткертә. Җитәр, җитәр... Кая, утыңны да бир инде. Рәхмәт... Гражданнар сугышы вакытында

булды бу хәл. Сугыш бетеп килә иде, Деникин дигәннәре дә тәртәсен Кара диңгезгә таба борган иде инде. Бер заман, караңгы төшеп килгән чакта, бер рус егете белән мине разведкага чыгарып җибәрделәр. Башта атлап бардык, аннары җиргә ятып шуыша башладык. Йөз адым да китмәгәнбездер, бер карачкы ята. Иптәш күрде моны, мин дә күрдем. Ул миңа төртә, мин аңар. Безнең юлдан әз генә читтә, калкурак җирдә бу карачкы. Җан иясе: селкенә. Якыная төшкәч, иптәш колакка пышылдый: ат, ди, бу миңа. Карыйм — чыннан да ат. Иптәш хәнҗәрен алып авызына капты, мин дә каптым. Якынрак барып карамыйча белеп булмый, бәлкем, ул атның тиресе генәдер, бәлкем, аның эчендә дошман яшеренеп ята торгандыр... Ә Ярманда бер тапкыр шулай булды... Өч разведчик, Ярман ягыннан кайтып килгәндә, үлеп яткан бер ат күрәләр. Мескен дә мескен дип, яныннан узып барганда, менә сиңа мә! Шалт та шолт ат тиресе эченнән. Икесен үтерәләр, берсе көчкә кайтып егыла. Ә безнең алай булмады — чын ат. Үлеп ята. Бөтенләй кан эчендә. Яңа яралаңган, күрәсең, каны безнең юлга тикле саркып төшкән мескеннең. Хайван зирәк була шул, ни тавыш-тынсыз барабыз инде, шулай да сизде бит бу безне. Башын күтәрмәкче. Әллә ничек йөрәк өзгеч итеп кешни. Ярдәм итегез, дию булгандыр инде... Ә без аңа ничек ярдәм итик?.. Газапланып ятмасын, чәнчеп китим дип, якын бара башлаган идем, иптәш туктатты: — Нельзя!.. Ну, нельзя булса, нельзя инде... Караңгы төшүгә дошман позициясен үтеп чыгып, разведка ясадык. Иртәгесен бер кечкенә елгада камыш эчендә качып яттык та, кич булгач, кайтырга чыктык. Кайта-кайта, төн урталарында, теге ат үлеп калган җиргә җиттек. Каны юлга акмый иде инде... Яныннан узып китеп кенә бара идек, иптәш төртә миңа — кара, ди. Карасам, ат янында нидер кыймылдый. Кая, Әхмәтҗан, моның эше бик кечкенә булды ла, иплерәкне төреп бир әле... Якынрак килсәк, ни күзебез белән күрик... Вәт бусы ярый. Кая, утыңны да бир инде. Рәхмәт. Якынрак килсәк, ни күзебез белән күрик: ат янында тай...

Шәйхаттар бабай Хәлимгә карап куйды. Хәлимнең күзләре күптән бабайда иде. Ул хәзер үзенең бирегә ни өчен килгәнен дә оныткан, хыялы Шәйхаттар бабай

белән кайдадыр сугыш кырында, әлеге ат тирәсендә йөри иде.

Шәйхаттар бабай тәмәке төпчегенә төкерде дә, җиргә куеп, бармак бите белән басып торды. Бу берничә секундка гына барды, ләкин бу секундлар Хәлимгә бик озак булып тоелды. Ул, тәмам тәкатьсезләнеп, «шуннан нәрсә булды, Шәйхаттар бабай?» диярге торганда, бабай бармак башын тәмәке төпчегеннән алды да чалбарына ышкып, бияләен киде һәм дәвам итте:

— ...Әй кызганыч булды бу тай, зрә кызганыч булды. Әнисенең имиен капкан, бичара, очынып-очынып суыра. Беләә ул — дөньяда яшәү өчен имәргә кирәк икәнен белә. Әмма ләкин сөт килми. Тилмерәме тилмерә, мескен. Зәгыйфь үзе — вакыты җитмичә туган икәне күренеп тора. Тайның аркасыннан сыйпыйм, иптәш тә сыйпый. Ул да мал җанлы егет булып чыкты. «Кызганыч бит», дигән мәгънәдә башын чайкый. Мин дә чайкыйм. Сөйләшмибез инде үзебез, сөйләшү кая! Тезләнмибез дә, ятабыз гына... Шул чак минем башка килде генә бит бер уй: алып китәм мин моны, дим иптәшкә. Ишарә белән аңлатам, билгеле.— «Ничек итеп?» Мин, күп уйлап тормыйча, шинельне җәеп салдым да, башын гына чыгарып калдырып, тайны төреп бәйләдем. Ә бау бар инде бездә; баусыз йөрмибез. Бау безгә Деникин егетләрен бәйләп алып кайтырга кирәк була. Шул, тайны шинельгә төреп аякка тактым да әкрен генә шуышып китеп бардым. Ә йөз адым чамасы киткәч, чишеп алдым да күтәреп киттем.

Кайткач обозга бирдем үзен. Борындык егете бар иде анда. Мәхмүт исемле. Шул карап үстерде. Тайга ике атна дигәндә Деникинны бөтереп тыктык. Ул да түгел, безгә, картларга, кайтырга приказ чыкты. Командирлардан рөхсәт сорадым да, тайны авылга алып кайтып киттем... Бер ай кайттым мин аның белән. Арып беттем. Җитәкләп тә, күтәреп тә кайттым. Ә шулай да алып кайтып җиткердем... Башта аерым хуҗалыкта эшләдем үзе белән, аннары колхозга алып кердем. Бу, беләсең килсә, шуның кызы була инде, кара кашым, карлыгачым... Унбишләрдә бар бугай инде бусы да...

Әхмәтҗан конюх аныклап куйды:

— Унҗидедә.

— Шулай бардыр шул... Бу малның историясе менә шундый, энем...— диде Шәйхаттар бабай һәм Хәлимгә

карады: «Ә син кичә яздырып куюың белән мактанасың», димәкче булган иде дә, әйтмәде. Хәлимнең атка ничаклы хирес икәнен күрде ул. Бу турыда аңар колхоз председателе дә әйтеп җибәргән иде, «Зиннәт төпчеге алмаган булса гына...» дигән иде.

Шуңар күрә бабай артык каты бәрелмәде, бары:

— Мин аны әнә кайчан яздырып куйган, кара кашым, карлыгачым,— дип кабатлап куйды.

Хәлим бары шунда гына айнып китте. Шунда гына үзенең кайдадыр сугыш кырында түгел, әле генә туган тай янында түгел, ат абзарында икәнен, анда ни дип килгәнен исенә төшерде һәм бик мескенләнеп әйтте Шәйхаттар бабайга:

— Син аласынмыни инде, Шәйхаттар бабай? — диде.

Хәлим еламады. Ләкин Шәйхаттар бабай, аның йөрәге елаганын сизеп, аркасыннан кагып куйды:

— Без болай итик алайса, улым. Әйдә, дәртең почмаклансын. Атны сиңа язсыннар. (Хәлим салам өстендә боегып басып тора иде, сикереп төшеп бабай каршысына тезләнде). Ә мин кулымнан килгән кадәр сиңа булышырмын. Сиңа да җиңелгә килер... Үзең беләсең, һәммә кеше фронт өчен эшләгәндә, читтә каласы килми. Югыйсә, мин инде үземнең шул мич башымнан төшмәм дигән идем. Җан түзми. Сугышасы килә... Әгәр без атны язга кадәр тиешенчә тәрбияләп алып чыгабыз икән, бу да сугышкан шикелле була... Ник, шулай булмый ни!.. Бер аякка бастырып җибәрсәк, яз көне нихәтле сөрә ич ул, һәй юл-ләр!..

Хәлим шатлыгыннан нишләргә белмәде.

— Ярый, бабай,— диде ул. Сикереп торды да, эндәшә-эндәшә килеп, атны ялыннан сөеп торды. Шул ук вакытта бабайның әлеге фикердән кайтуыннан курыкты. Атны тизрәк үз исеменә яздырып куясы килә иде.

Бабай Хәлимнең теләген дә аңлаган шикелле, кулларына таянып урыныннан күтәрелде. Ул бу вакытта бер гамьсез, күңеле күтәренке иде. Ә конюх кулыннан фонарьны алып ат өстендә йөртә башлагач, кинәт алмашынып китте. Атның ыңгырчак астында ярты кәләпүш кадәр җире тирән чиләнеп тора иде.

— Әй, Әхмәтҗан, Әхмәтҗан, берәр вакыт янына килеп караганың бармы, ичмаса?

— Карале-е...— Конюх башын селкеп торган булды.— Соң бит әле өченче көн генә...
— Юк иде димәкче буласыңмы?
— Ипи эгәр...
Бабайның моңар тәмам ачуы килде:
— Ялганлама, яхшыдан яман туган нәмәрсә!.. Рәзе бу өч көнлек яра!.. Кайда, китер йөгәнен!..
Хәлим куркып Шәйхаттар бабайга карады. Бабай аңлатып бирде.
— Теге, сезнең арттагы иске абзарга күчә инде бу болай булгач. Кичә корчаңгы атларга урынны шунда әзерләп торалар иде... Өч кенә ат дигәннәр иде дә, болай булгач, бу дүртенче була инде...
Шәйхаттар бабай Әхмәтҗанга инде күтәрелеп тә карамады, теге дә, үзенең гаебен белеп, тиз генә йөгәнне алып килде. «Баладән баш-аяк...»— ул инде ничә айлардан бирле күргәне булмаган йөгәнне атның башына киертте дә аны ишеккә таба бора башлады. Ат башта: «Шушында гына үлим инде мин, борчып йөртмәгез инде», дигән шикелле, кузгаласы килмичә торды. Аннары алгы аякларын кузгатып куйды. Әйтерсең лә ул аякларын үзенең тәмам бетәшкәнлеген күрсәтү өчен генә кузгатты, кузгатканда, исерек кеше кебек чайкалып торды. Хәлим аны егыла икән дип курыкты, ләкин ат егылмады. Алгыларыннан соң арткы аякларын да кузгатты ул һәм, шуннан артык булмый миннән дигән кебек, хәрәкәтсез калды.
Шәйхаттар бабай төкереп куйды. Түзмәде, Әхмәтҗан абзыйга китап сыйдырмый торган берничә сүз дә әйтеп алды, аннан иркә сүзләр әйтә-әйтә, атның маңгай чәчләрен бармаклары белән тарады, ялларын сыйпады. Гүя ул Әхмәтҗанга түгел, атка сөйләде:
— ...Рәис булсам мин аны, фәлән-төгән нәмәрсәне, ат янына түгел, бәрәңге бакчасына карачкы итеп тә куймас идем,— диде ул, аннары, на, малкай! Һай, рәхмәт төшкере! кебек сүзләр әйтә-әйтә, атның башыннан тартты. Ат теләмичә генә борылды, теләмичә генә бүлемнән чыкты. Һәм, әкрен барган бабай артыннан әкрен өстерәлеп, китеп барды. Бик әкрен барды ат. Яңа сукырайган кеше кебек, куркып-куркып кына баса, аягы тигезсез җиргә туры килгән саен, янтаеп китә иде. Берәр нәрсәгә абынып егылуыннан куркып, Хәлим, яктыга чыкканчы, ат алдыннан фонарь тотып барды.

Атны өстери-этә иске абзарга китереп җиткергәндә яктырып беткән иде инде. Шәйхаттар бабай аны ишек алдында туктатты да тагы бер тапкыр күзеннән кичерде:

— Иһи-и... моның корчаңгысыз җире юк та икән, энем Хәлим. Кара әле бу төшен. Ә монысы нәрсә тагы... Хайванны тәмам расходка чыгарып куйган икән, фәлән-төгән нәмәрсә! Абзарга кертмик әле без моны, кем, Хәлим. Башта көн яктысында әйбәтләп бер дәвалап алыйк. Мин хәзер санитарга барып кәрәчин белән күкерт алып кайтыйм. Ә син әнә шул баганага илтеп бәйлә дә, Низам абыең белән урын хәзерли тор,— диде һәм, кабаланып, капкага таба китте. Бераз барды да кире борылып килде.

— Ә син мондый очраганга бер дә хафаланма. Комсомол бит син... ну, пионер. Пионер булсаң, менә шушындыйны мал итеп чыгар син и биспартийныйларга пример күрсәт... Ансатны аны кем дә булдыра. Юк, читенне эш ит син. Кичә, аңар карасаң, Хәсән Гатасы да үзенә берне алып кайтты. Дулкынчәчне. Ә аны хет иртәгә үк тот та җик. Юк, менә моны мал итик без, пионер таварищ... И без моны, алла боерса, мал итәрбез. Яз көне җир сөрәбез әле без моның белән, ипи әгәр, сөрәбез. Сөрмибезме соң, һәй юл-ләр...

Шәйхаттар бабай шулай диде һәм тиз-тиз атлап капкага таба китеп барды.

9 ИКЕ ДУС

Белем чишмәсе бик тирән катлауларда күмелеп ята. Һәм аны бернинди экскаватор белән дә казып чыгарып булмый, штурм белән алып булмый белемне. Хәлим исә штурмга исәп тотты. Ул эшне ничек тә тизрәк очлап чыгарга теләде. Иң кирәклесе, укыганны аңлау гына түгел, ныклап үзләштерә дә бару, сугышып алган территорияне ныгыта да бару турында уйламады. Укыганда, укытучы сөйләгәндә барысын да белеп бара кебек күренә иде. Ләкин бераз вакыт үтүгә, язгы ташу сулары фәкать чокыр-чакырларда гына җыелып калган кебек, Хәлимнең башында кайбер нәрсәләр генә торып кала иде.

Моның шулай икәненә малай үзе дә бик тиз төшенде. Физика дәресендә укытучы аңар җиңел генә бер

сорау бирде, Хәлим әйтә алмады. Икенче бер вакыт укытучы бөтен класска сорау бирде.— «Кем әйтә?» Сорау Хәлимгә бик ансат кебек тоелды. «Узганда җавап бирә алмавым өчен дә булыр...» дип, ул, кеше-кара калкып чыкканчы, ялт кулын күтәрде. Ләкин, сорау буенча сөйли башлагач, буталып бетте.

Укытучы Хәлимне дәрестән соң алып калып шундый киңәш бирде:

— Ашыккан ашка пешкән, дигәннәр борынгылар. Ашыкма син. Язга куып җитә аласың икән, бик әйбәт инде... Менә нәрсә эшлә әле син, энем. Әйткәннәрдер, укуы өзелеп торганнарны без аерым фәннәр буенча алдынгы укучыларга беркеттек. Кайсы консультация ди аны, кайсы буксир ди... Эш исемендә түгел. Класс җитәкчесеннән сора, сине дә берәрсенә беркетсен. Әйтте диярсең, файдасы зур булачак.

Ә, ю-ук инде, анысы торып торсын!.. Кайчан гына үзе башкаларны өйрәтеп килгән, өстәвенә шундый данга күмелеп кайткан Хәлим бүген Гөлгенә белән Гөлчирәгә, Каюм белән Җәләйгә барып, минс өйрәт әле, дисен, имеш!..

Монысы Хәлимнең икенче ялгышы иде. Тагын шунысы, бу ялгыш эчендә Хәлимнен масаюы үтәли күренеп ята иде. Әлбәттә, малай әкренләп игътибар үзәгеннән ераклаша барды. Шуңа җитте, бер көн дәрес вакытында аның партасына кәгазь күгәрчен очып килеп төште. Күгәрчен канатына шакмак хәрефләр белән шундый сүзләр язылган иде:

> «Мин димәгел, мин дигәч тә күп бәла,
> Мин димәк лә булды шайтан мөбталә».

Хәлим хәтта моның кем эше икәнен уйларга да онытты, гүя шигырь артыннан бөек шагыйрь үзе дә Хәлимгә елмаеп карап тора иде.

Малай җир тишегенә кереп китәрдәй булды. Җитмәсә, өйгә кайтып чәй янына килеп утыруына әнисе:

— Безнең ике авылга бер «мәптәгебез» дә, каешланып каткан кызыл фәсле, эчкә баткан күзле бер чехотка хәлфәбез бар иде. Гыйлемлек дәрәҗәсен шуннан чамала: хат саласы булса, адрес яздыру өчен Малиновкага йөгерә идек. Безгә әнә шул хәлфә бирә торган белемне алырга да насыйп булмады. Революция булып, белем ишекләре ачылгач кына, укый алдык. Бу вакыт-

та инде мин 35 яшьтә идем. Минем белән 50—55 яшьлек ирләр укыды. Ә кем укытты? Балалар. Ләкин без кимсенмәдек. Синең хәтле генә берәр малай керә дә: — фәлән бабай, тактага чык,— ди. Малай каршысына кәрәк сакаллы карт чыгып баса... Ә менә син үз иптәшләреңнән дә сорарга кимсенәсең. Дөрес эшләмисең, улым. Алар синең өчен үлеп торалар, ә син алардан ераклашырга итәсең...

Хәлим дәшми-тынмый гына кайбер китап-дәфтәрләрен күкрәгенә кыстырды да мәктәпкә килде. Бүген консультация география буенча иде.

Хәлим иелеп йозак тишегеннән карады. Шул-шул, консультацияне Каюм алып бара иде. Ләкин карагызчы, зинһар өчен, яңа роль малайны ничек үзгәрткән!.. Аның өстендә хәзер дә шул ук кыскарып калган чалбары, тараеп беткән пиджагы. Ләкин алар бүген, ничектер, пөхтәрәк киелгәннәр. Чәченең чылатып таралган булуы, күлмәк якасының әз генә дә керсез, галстугының үтүкләнгән булуы, аны олысымак итеп, бүтәннәрдән өстен итеп күрсәтә иде. Кайсыныңдыр соравына җавап биргәндә, күрсәткеч таякны алып карта янына килгәч, Каунас, Рига шәһәрләрен төртеп күрсәтә-күрсәтә, Балтик буе илләренең элек-электән бөек Русь җирләре булуын сөйләп киткәч, Хәлим үзе дә сизмәстән, класс ишеген ачып, «мөмкинме?» диде. Рөхсәт алгач, буш урыннар алда да күп булуга карамастан, иң артка барып утырды.

Хәлим кергәч, Каюм каушап тукталып торды. Балаларның сорауларына җавап биргәндә дә бик таркау сөйләде, кирәкле сүзен таба алмыйча, җавабын әледәнәле «эм-м, ни, ниткәннәр, ни инде...» кебек сүзләр белән чүпләп бетерде. Бер сүз урынына икенчене әйтеп салганда, «әй, фәлән дигәнем лә... әй, төгән дигәнем лә...» дип ялгышларын төзәткәндә, колакларына кадәр кызарып чыкты. Ә Хәлимгә күзе күнә төшкәч, Хәлим дә иптәшенә уңайсызлык тудырганын сизеп, күзләрен аңардан алгач, тагын роленә кереп китте. Җавабын очлап чыкты да иптәшләренә:

— Тагын кемдә нинди сораулар бар? — дип мөрәҗәгать итте. Ә күзләре янә Хәлим белән очрашкач, тагын аңар карап торды. Бәлкем Каюмның уенда да булмагандыр, ә Хәлим аның бу карашында, абзаңны күрдеңме, дингезнең кай җирләрендә йөзә, колачны ни-

чек иркен сала, ә син әле һаман әбер-чеберләр белән су читендә быкырдап ятасың дигән сүзләрне укыды.

Каюм сорауларга җавап биреп бетергәч, үзе берике сорау куйды:

— Я, кайсыгыз?

Каюм күзләрен иптәшләре өстендә йөртеп чыкты. Бераз Шәпигә карап торды, аннан тагын Хәлимгә текәлде.

Нишләвең инде бу синең, Каюм? Әллә Хәлимнән сорарга итәсенме?.. Тукта, тукта, нәкъ шулай булуы мөмкин бит: Каюм сорый, Хәлим җавап бирә алмый. Кайчандыр үзе Хәлимгә кереп, мәсьәлә чыкмый әле, малай, дип йөргән Каюм сорый, ә ничек эшләргә өйрәтеп чыгарган Хәлим җавап бирә алмый. Хурлык бит, билләһи... Хәлимгә ишек төбендә бик күп бала тыңлап тора кебек, алар Хәлим җавап бирә алмагач шаркылдап көлеп җибәрәчәкләр дә шаулашып класска килеп керәчәкләр кебек тоелды. Ул уңайсызланып түбән карады.

Ләкин Каюм иптәшенең хәлен белә иде, аны оялтырга исәбендә дә юк иде.

Каюмның консультациясе әйбәт узды. Балалар бар да канәгать булып калдылар. Хәлим дә. Кара, никадәр томан таралды аның башыннан, никадәр яңа нәрсә белде. Юк, моннан болай мондый консультацияләргә ул гел йөреп торыр...

Хәлим консультациядән алган хисләре турында кайтырга чыккач Шәпигә дә әйтте. Һәм:

— Кара син аны, Керпене! Укытучының миңа дигәне була бу. Билләһи, була,— дип куйды.

Шәпи эндәшмәде.

— Ник, шулай түгелмени?

— Шулай. Ләкин, буразнага өйрәнмәгән яшь ат шикелле, читкә чыккалап куя. География икән — география булсын инде, ә ул тарихка кереп китә. Имеш ул тарихны да белә. Ә ул аны бутый. Беркөн Сәми аңардан, Рим кайчан төзелгән, дип сорады. Әйтергә дә нокта куярга иде. Юк бит! Әй китте бу... Аның урта гасырда иң алдынгы ил булуы да калмады, варварлар тарафыннан җимерелүе дә калмады. Ә шунда иң кирәклесен әйтмәде. Рим иң кабахәт рәвештә колбиләүче

империя була. Һәм Рим җимерелү белән колбиләүчелек тә җимерелә. Аны җимерү кешелек дөньясын алга җибәрә.

— Син моны белеп сөйлисеңме?

— Урта гасырлар тарихын кара. 8 нче бит. Мин инде аны, агаенем...

— Алайса тарихны бозу була бит бу.

— Бозу шул.

— Әйтергә кирәк иде. Төзәтсен иде.

— Әйтерсең аңар.

— Нигә?

— Яратмый. Хәзер кайный башлый. Самовар да самовар, ул да самовар.

Хәлим кайту белән 8 нче битне ачып карады һәм, дустының ялгышканына ышанган хәлдә, иртә белән дәрескә барышлый бу турыда аның үзенә әйтте. Каюм чыннан да шунда ук кайнарга тотынды:

— Шуннан?

— Төзәтергә кирәк.

— Ягъни?

— Безгә тагын кайчан җыелырга әле? Менә шунда торасың да әйтәсең: гафу итегез, иптәшләр, теге вакытта мин шулай дигән идем, ялгышканмын. Аның дөресе менә болай икән...

— Әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен, яме!

— Хурланасың?

— Бу минем авторитетны какшатачак.

— Юк, син моны әйтми калма, Каюм. Бу намуссызлык булачак. Сиңа биш пионер ышанып тапшырганнар, ә син аларны ялгыш юлдан әйдәп, сазлыкка алып кергәнсең. Хәзер инде, сазлык икәнен белгәч, кире алып чыгарга ояласың.

— Оһа, син нинди остарып кайткан! Образлар белән эш итәсең. Ләкин башта үз борыныңны сөрт әле, яме. Аннан, шуны бел: кеше эшенә тыкшынганны китап мактап бетерми. Сау булып тор, ревизор,— диде Каюм тәмам кызып, һәм, һич кирәкмәгәнгә, бер капкага керен калды.

Шуннан алар ике-өч көн сөйләшми йөрделәр. Икенче бер консультация вакытында Хәлим Каюмга: дус күреп әйтәм, төзәт син теге хатаңны,— дип язып бирде. Каюм укыды да мыскыллап елмаеп куйды. Һәм Тәзкирә апа кереп килгәнне күреп, язуны кесәсенә яшерде.

Хәлим, әйтерсең ул үзе түгел, ә аны ниндидер көч хәрәкәткә китерде: сикереп торды һәм карандашын бутый-бутый:

— Тәзкирә апа, узган юлы Каюм бер хата ясаган, төзәтсен ул аны...— диде.

Каюмны кызарды дисәк аз булыр, чөгендер төсенә керде. Пөхтәлеге, өстенлеге кинәт бетеп киткән кебек булды. Пиджак җиңнәре, чалбар балаклары тагы да кыскара, килешсезләнә төшкән кебек булды.

— Каюм, нинди ялгыш ул, акыллым? — диде укытучы.

Каюм эндәшмәде.

— Хәлим?

— Үзе әйтсен, Тәзкирә апа.

Каюм тагы эндәшмәде. Класста күңелсез тынлык урнашты. Хәлим дустын инде кызгана башлады. Иптәш бит. Әллә юкка әйттем микән... Ә, юк, дөреслек дуслыктан өстен.

Бу вакытта Каюмның башында төрле уйлар туды. «Буксир булмыйм мин алайса. Әнә, алай бик беләторган булгач, Хәлимегез өйрәтсен, дим дә чыгам да чабам...» Аның соңгы карары шул булды... Һәм ул шулай эшләде дә.

Хәлим, Каюмны туктату өчен, сикереп торып ишеккә бара башлады. Тәзкирә апа исә, кулын күтәрә төшеп, ишарә ясады: «Кирәк түгел, соңыннан». Аннан Каюмның хатасын төзәтергә керешге.

Хәлим кайтып килгәндә, Каюм, өй йомышы белән булса кирәк, каядыр бара иде. Ул Хәлимне күрмәмешкә салышып узып китмәкче булган иде дә, Хәлим аның каршысына килеп басты:

— Юкка син, егет. Алай кирәкмәс иде.

— Ә сиңа шулай кирәк идеме? Җитмәсә, дуслык зур нәрсә ул, аны вак-төяк аңлашылмаулар белән җимерергә ярамый дип йөргән буласың.

— Әйе, булам.

— Син бит, сугышта бер кулы яраланган сугышчының сәламәт кулы белән аяксыз калган иптәшен сөйрәп чыгулар турында сөйләргә яратасың.

— Яратам.

— Ә үз башыңа төшкәч...

— Яклар урында әләкләдең, димәкче буласың, әйеме?

— Нигә, әллә шулай түгелме? Син бит...

— Стоп. Син минем батып барганымны күрсәң, тартып алыр идеңме? Алыр идең. Мин дә бары шуны гына эшләдем. Ә син үзең генә түгел, үзең белән башкаларны да...

— Ясама, чебеннән фил ясама!..

— Юк, Каюм, син үзең филгә чебен итеп карыйсың.

— Сөйләшәсем дә килми минем синең белән,— диде Каюм. Һәм, Хәлимне этәрде дә, үз юлына китеп барды.— Мин мәсьәләне шулай куям: консультация группасында я син, я мин. Ике тәкә башы бер казанга сыймый.

Хәлим елмаеп куйды. Ул иптәшенең кайтып төшәсен, андый мәсьәләне куймаячагын, куйса да, соңыннан үкенәчәген белә иде. Һәм Хәлим ялгышмады. Йокыга китеп бара иде инде, караңгы өйалдына абына-сөртенә Каюм килеп керде.

— Син, егет, мине гафу ит инде, мин иртәгә калдыра алмадым. Беләсең нәрсә, мин чыннан да ялгышканмын икән...— диде ул.

— Ничек болай тиз аңлады соң әле үзенең хатасын безнең бу остаз? — диде Хәлим әз генә ирония белән һәм торып утырды.

Каюм сөйләп бирде. Озын итеп сөйләде ул. Аның барлык сүзләрен китапка язып торуның хаҗәте юк, тик сүзнең асылын гына әйтеп үтик.

Каюм кайта да: я ул, я мин дип, директорга гариза яза. Һәм тиз генә илтеп бирү өчен бусагадан атлый. Нәкъ шул чакта бакчада ишетеп кайтканнарын әбисенә сөйләп утырган сеңелесенең:

— Йолдызларның җир хәтләләре дә була икән,— дигәне колагына керә. Каюм ачкан ишеген ябып, үзе дә сизмәстән, кычкыра башлый:

— Ни дисең, ни дисең? Җир хәтләләре? Их син, астроном!.. Белмәсәң бел инде алайса: күктә шундый йолдызлар бар, җир шары аның янында мәктәп янындагы кара савыты кадәр дә юк,— ди ул. Һәм, кинәт үзгәреп, урындыкка килеп утыра. Үзенең кеше ялгышын төзәтүе аның күзен ача. Ул гаризасын ертып ташлый да Хәлимгә йөгерә...

— Группаңнан да кумыйсыңдыр инде болай булгач? — диде Хәлим, шаяртып.

— Оялтма инде, оялтма...— Каюм иптәшен кочып алды.

Хәлим аны иңнәреннән алып үзе янына утыртты.

— Ә мин кусаң да китми идем.

— Мин китәм дисәң дә җибәрми идем.

Малайларның икесенә дә рәхәт булып китте.

— Әйдә бер дә, бер дә талашмый торган дуслар булырга сүз куешабыз, Хәлим?

— Ничәнче тапкыр?

— Юк, күр дә тор менә. Дуслык билгесе итеп мин сиңа...— Каюм әз генә уйланып торды да кесә фонарен чыгарды,— менә моны бирәм. Хәзер үк түгел. Башта менә бу төшенә игәү белән исемемне язам әле.

— Ә мин сиңа... Әнә шул гимнастерканы алып бир әле. Рәхмәт.— Хәлим мәктәптә кесәсеннән чыгарган саен балаларның күзләрен кыздыра торган бик матур авторучкасын иптәшенә сузды.

Каюм шатлыгыннан дустын кочып алды.

— Бөтенләйгә?

— Бөтенләйгә.

— Ну рәхмә-әт.

— Җуйма.

— Ю-ук. Мин аны бәйрәмнәрдә генә...

10 ИНДЕ НИШЛӘРГӘ!

Шәйхаттар бабай бар кадәр бәрәңгесен, оның тегесен-бусын төяде дә, «Атны мал итеп Әхмәтҗанга кайтарып биргәнче» торырга дип, Хәлимнәргә күчеп килде.

Хәзер ул бөтен вакытын ат янында, ат артыннан йөреп үткәрде. Бик тырышып корчаңгысын дәвалады. Белеп кенә ашатты, белеп кенә эчертте. Яшь баланы тәрбияләгәндәй тәрбияләде ул үзенең Шәехтаен. Шулай итә торгач, инде башактан да баш тарткан Шәехтай, алдында бетсә, түбә саламына да үрелә башлады. Аларга рәхмәтен белдереп, башын селкеп торды. Хәзер инде ул башагын уртаклашыр өчен улакка менгән тавык-чебешләрне башы белән төртеп төшерерлек хәлдә иде. Бүген исә абзарда тагы бер тамак пәйда булганга ризасызлык белдереп, бертуктаусыз ырылдап йөргән этне арткы аяклары белән тибеп очырды.

— Күрдең? Мал була бу, алла теләсә! — диде Шәйхаттар бабай һәм кин елмаеп куйды.

...Хәлим шулкадәр сөенде, чиный-чиный оясына таба китеп барган этне бераз кызганып торды да Шәехтайны муеныннан кочып алды.

Хәлим белән Шәйхаттар бабай кич белән табын янына утыргач та, шул турыда исләренә төшеп, сөйләшеп алдылар:

— ...Син шуны шәйләдеңме, энем, эт малкайга — вау, вау! Ә малкай тегенең ипи шүрлегенә — шалт!..

— Ха-ха-ха... Шәехтай бит, эни, Шәехтай шулай итте...

Улыннан килгән хатны укытырга кергән Хәтирә әби белән сөйләшә-сөйләшә аш бүлеп торган Шәмсия җиңги моңар каршы:

— Колхоз дигәндә бу кадәр атаңа ошарсың икән,— диде һәм шунда ук хафалы тавыш белән өстәде: — ләкин эшләр кыенлашып бара бит, улым.

— Ничек?

— Кәефегез кырылмасын дип әйтми килдем-килдем дә, булмый инде. Ат өчен бүлеп куйган он дүрт-биш кенә табак калды. Ә бәрәңгесен иртәгә актык тапкыр пешерәм...

Табынның яме, ашның тәме китте.

Хәлим белән Шәйхаттар бабай тәлинкәләренә сузылган кашыкларын кире алдылар. Шәмсия апа еларга җитеп күңелсезләнгән Хәлимне тынычландыру өчен тиз генә әйтеп куйды:

— Берәр сарыкны сатсак инде, шунсыз булмый, улым, теге бору мөгезлене...

Шәйхаттар бабай Шәмсия җиңгигә әйтеп бетерергә бирмәде:

— Ә, юк,— диде ул,— хуҗалыкны киметмибез, килеп... Итәк кисеп җиң ямаган күк була ул. Киметмибез...

— Киметми нишлисең?

— Табарбыз җаен...— диде Шәйхаттар бабай һәм уйга калды.

Беренче көннән барлык запас чамалап кына тотылган булса, атны дүрт айга, ягъни сабан өстенә кадәр утермичә саклап чыгып була иде. Ләкин аннан ни файда, атның сабан өстендә дә конюх Әхмәтҗан кулындагы хәлендә булуыннан ни файда! Алай бит ул,

эшкә түгел, бары җитәкләп йөртергә генә ярыячак. Ә Шәйхаттар бабай белән Хәлим атны, үлемнән саклап калу өчен генә түгел, сабанга җигәрлек итеп тәрбияләргә алдылар. Һәм, үзләре әйтмешли, киләндергәнче ашатырга булдылар. Бу уйга килгәндә Шәйхаттар бабайның бер исәбе бар иде: сугышка кадәр яхшы ук таза тормыш белән торган сеңелесенә, Татлы Күлгә барып, бераз он алып кайтырга уйлаган иде. Барды да ул анда, ләкин сорарга базмады. Сеңелесенең ире дә, улы да фронтта, итәк тулы яшь бала, колхозда берүзе эшли. Ул сеңелесендә туйганчы ашарга да тартынды. Бер кич кунды да, иртән чәй дә эчеп тормыйча, кайтып китте.

Хәзер нишләргә соң?

Бу турыда, Шәйхаттар бабайдан бигрәк, Хәлим борчылды. Шәйхаттар бабайның: «Табарбыз җаен», дигәннән соң йомылган иреннәренә карап,— «булды, Хәлим, болай итәбез...» дип сүз башлаганын көтеп утырды. Ә Шәйхаттар бабай андый сүз әйтмәде.

Эчпошыргыч тынлык иде бу. Аны Хәтирә эби бозды:

— Сезгә тиеш түгел иде, бәбкәйләрем,— диде эби,— әнә нинди кешеләр дә мондый эшкә керешмәде.

— Нинди кешеләр?

— Соң, Шәйхаттар, Мүкләк Зарифларга гына күз сал. Сугыш башлангач әүвәлгедән яхшырак тора башладылар, шулай да ат белән җыкланмыйлар.

Бабай кулын гына селтәде:

— Һәй, син инде, Хәтирә, әйтсәң, башка кешене әйт, ә Мүкләккә яхшы тору кайдан килгән ди?..

Хәтирә эбигә Шәмсия җиңги куәт бирде:

— Син күрмисең аны, Шәйхаттар бабай,— диде ул,— ә без кереп-чыгып йөрибез, безгә күренә... Һаман да шикле әле аларның эшләре.

«Шикле әле аларның эшләре» — бу сүзне авылда бер Шәмсия җиңги генә әйтмәде. Зариф абзый — теге вакытта танклар колоннасына акча кертүдән баш тарткан Зариф абзый — чәчүче иде. Быел ике бригаданың сабан бодае сирәк тишелгәч, колхозчылар «әллә Зариф шәләйтләде микән?» дигән шиккә төштеләр. Кайберләре бу сүзне «микән» сез генә әйттеләр. Ә кем күргән? Берәү дә күрмәгән... Шулай да имеш-мимеш әле һаман йөри иде.

— Ул шәләйтләмәгәч, нигә тишелмәде соң? Сайлап салган әйбәт, эре, кондицияле бодай иде бит ул. Ә җире тагы?..

Бу эш белән вакытында колхоз идарәсе дә, авыл советы да кызыксынды. Шуңар җитте, идарә, прокурордан санкция алып, Зариф абзыйның йортына тентү кертте. Ә инде тентеп-тентеп тә һичнәрсә чыкмагач, абзыйны тыныч калдырдылар. Шуңа күрә Шәйхаттар бабай Хәтирә әби белән Шәмсия җиңгинең сүзләрен юкка чыгару ягында иде.

— Алайса, әнә Низамый Вафасы нигә тәрбияләми? — диде Шәмсия җиңги аңар каршы.

— Менә аны әйтсәң дә була. Аның чыннан да бар. Ну бит, килен, бөтен кеше бертөрле булмый. Солдатта да шулай ул, кем, Шәмсия. Берәү яраланган килеш тә, җан-фәрманга ут эченә керә, ә икенче берәү, снаряд чокырына төшә дә, үлгән булып, янсә ярасыннан тора алмаган булып ята. Андыйларны без солдат чутында йөртмибез. Соры корт дибез без андыйларны. Атып үтерелергә тиешле кешеләр алар. Сугышта аталар да. Ну монда андыйларга хөррият... Колхозның аты ачтан үлә, ә ул, соры корт, он капчыклары өстенә менеп утырган да... Искә төшермә инде, килен...— диде Шәйхаттар бабай. Ул, сүзләренә өстәп, кулын селкеп куйды һәм үрмәләп мич башына менеп китте.

Хәлим дәресләрен әзерләргә утырды. Шәмсия җиңги, Хәтирә әбине озатып кереп, кече якта үзенә урын җәя башлауга, аны, тәрәзә шакып, авыл советына чакырып киттеләр. Шәмсия җиңги:

— Тапканнар вакыт, бу буранда йөртмәсәләр, яна торгандыр шул,— дип сукрана-сукрана тиз генә чыгып китте һәм байтак торып кайтты.

— Ну, бу авыл советын,— диде ул киткәндәге кебек үк сукрана-сукрана,— колхозыбыз нинди хәлдә бит, ә ул, урманга ди.

— Бәй, бездән барып кайттылар түгелме соң инде, килен?

— Куй инде. Имеш, районнан көз көне бармый калганнарны җыеп җибәрергә кушканнар.

— Ә-ә...

— Карышмыйм мин, Шәйхаттар бабай, ләкин ул чакта минем звеном нишли? Тиресен чыгармаган, көлен җыймаган. Орлыгын да берәмләп сайларга ди бит хә-

нер аның... Болай да җитешмибез, бер кешене икегә бүләргә җитеп йөрибез бит.

Хәлим, сугыш вакыты шул, әни, бер нишләр хәлең юк, димәкче булган иде дә, энисенең кай көннәрдә аш пешерергә дә вакыты булмаганны хәтерләп, эндәшми калды.

Шәмсия җиңги сөйләнә-сөйләнә кече якка кереп йокларга ятты. Хәлим дә, дәресләрен карап бетереп, тышка чыгып китте. Ул кайткан шәпкәрәк, китап өстендә озак утырып, ахыр чиктә арыганлыктан, яткач, йокыга китә алмыйча, газапланып чыга иде. Соңгарак, кайсыдыр бер укытучының киңәше буенча, йокы алдыннан берәр физик эш эшләп керергә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде. Ә кергәч, бил тиңентен салкын су белән юынды. Нәтиҗәдә, көннең-көн буена утырып оешкан әгъзалары язылып, киеренкеләнгән нервлары тынычланып, ятуга эреп китә торган булды. Бүген исә, чаңгыда йөрергә теләге булмады, ә утынның, кабат ярып өя-өя, энисе әйтмешли, башын авырттырып бетергән иде инде. Хәлим Хәтирә әбинең кыш башыннан бирле көрәк-себерке тимәгән ишек алдын көрәп чыкты. Ләкин, кереп яткач, барыбер йоклый алмады. Бик борчылды ул. Бу аның авылга кайтканнан бирле беренче тапкыр шулай нык борчылуы иде.

Фронтта бер кеше никадәр эш эшли ала... Бик күп эш эшли бер кеше фронтта. Ә монда икәүләшеп бер ат тәрбияләп булмасын әле!.. Шулай итеп туктатырга туры килер микәнни?.. Кит, юләр, ояты күпме булачак... Юк инде, андый көнгә калсам, авылдан чыгып качам мин... Ә соң нишләргә? Әллә, берсенә дә әйтмичә генә, шинель белән гармонын чыгарып сатарга микән?.. Ә бит аның икесенә аз дигәндә...

Чыннан да, шулай итсен микән әллә?..

Шулай уйлана-уйлана, инде йокыга китеп барган Хәлим Шәйхаттар бабайның мич башыннан әкрен генә дәшкәнен ишетеп, башын күтәрде. Һәм, сүнәр-сүнмәс җемелдәгән сукыр лампа шәүләсендә Шәйхаттар бабайның ишкәктәй озын кулын күрде.

— Кил әле, кил...

Шәйхаттар бабайның тавышында ниндидер өмет, ышаныч бар иде. Хәлим тиз генә торып, аның янына килде:

— Нәрсә, Шәйхаттар бабай?

— Әкрен, энкәкне уятмыйк. Мен минем янга. Менә шулай... Җаен табарбыз дип әйттем бит, и таптым да... Болай итик без. Син монда кал, атны кара, ә мин әниең урынына урман эшенә китим. Леспромхозга. Дөрес, мин инде дөнья җимертеп эшли алмам, ну шулай да...

— Аннан ни файда?

— Тау чаклы! Әниең үз звеносында эшли бирер, бу бер... Шуның өстенә, анда минем тамак үтә, мондагысы атка кала барыр. Белмәссең, бәлкем, бераз онлык акча да юнәтеп кайта алырмын әле...

— Ай, бабай, авыр булыр бит сиңа урман эше. Бик беткән бит инде син...

Хәлим шулай диде, ә үзе Шәйхаттар бабайның «минме беткән?» диюен теләде. Һәм Шәйхаттар бабай шулай диде дә.

— Беткән? — диде ул кимсенеп.— Мирни бриме өчен, дөрес, беткән инде мин. Ә заманына күрә алай чуттан чыгарып ук ташларлык түгел әле, энем, селкенә алам ич әле. Аннары, утын кисү генә димәгән. Анда, урманда, төрле эш була.

Хәлим, ачыла төшеп, Шәйхаттар бабайның шыр сөяк беләген тотты. Шунда ук тагы күңелсезләнде:

— Ләкин авыл советы авыз да ачырачак түгел. Кешене бик кызгана бит бу председатель. Әхмәтша абыйны әйтәм, иткән урман сиңа, дияр, мич башында ятуыңны гына бел, дияр...

Бабай үзе дә шикләнде. Хәлим исә ятып калганчы атып калырга булды. Ул торып киенде, тәэсир итмәсме дип (андый тәртип булмаса да) шинеленә медален алып такты һәм, Әхмәтша абзыйның ялгызын очратып сөйләшү өчен авыл советына китте. Ләкин аңар бабай өчен сорап йөрергә калмады, урамда өч иптәшен очратып сөйләшкәч, аның башына бүтән бер уй килде.

Бу малайларның да әниләре урман эшенә китәргә тиеш булганнар икән. Ләкин малайлар, мәктәп директоры һәм пионервожатыйдан рөхсәт алганнар да, каникул вакытында әниләре урынына үзләре барып эшләп кайтырга уйлаганнар. Малайлар дигәнем Мотыйк белән Җәләй — Хәлимнең элекке сугышчан дуслары һәм Ирек исемле тагын бер пионер иде. Алар әле генә авыл советыннан чыкканнар, председатель малайларның теләкләрен бик рәхәтләнеп яклаган. «Бер атуда ике куян ич бу!» — дигән председатель һәм секретарен

чакыртып китергән дә тиешле кәгазьләрне язып бирергә кушкан.

— Менә!..— диде Җәләй. Ул пөхтәләп дүрткә бөкләнгән кәгазьне бүрегеннән алып Хәлимгә күрсәтте.— Ирек белән Мотыйкның да бар. Күрсәт, Мотыйк.

Хәлим ә димәде, җә димәде, кәгазьләрен дә карап тормады. Авыл советы баскычы буйлап өскә йөгерде: «Мин хәзер, дуслар!..» Һәм ишек төбендә инде эшен бетереп чыгып килгән Әхмәтша абзыйга килеп бәрелде.

— Мин дә барам! — диде ул бераз каушап,— әни урынына. Зинһар, Әхмәтша абзый, каршы килмәгез инде. Югыйсә, аның звеносы кала бит, үзегез беләсез, хатын-кызның өйдә дә...

Хәлим өйгә тулган ай кебек яктырып кайтты.

— Булды бит, бабай,— дип пышылдады ул тиз генә чишенеп ташлап, мич башына менгәндә.— Берсекөнгә сәфәр. Урманга мин барам.

— Ягъни мәсәлән, ничек син?

— Шулай. Дүртәү, дүрт малай барабыз. Ә син биредә Шәехтайны...

— Ә, юк, алай булмый. Син инде укуны ташлама. Анысына кул куеп булмый, энем. Үзең әйтәсең бит әле...

— Алай түгел... уку бер генә көн калды инде безнең, бабай. Каникул. Унике көн була.

— Унике көн... Юк, син шулай да...

— Тукта әле, бабай, әгәр урманга икебез дә китсәк, ә?

— Начар булмас иде дә, ә соң син дә, мин дә киткәч, ат нишләр, кем карар атны?

— Әнигә әйтәбез, бабай. Аңар гына вакыт таба ала инде ул.

Шәйхаттар бабай кырын ята иде, торып утырды.

— Һм-м... Бу уй бик яхшы була бит безнең. Ул чакта атка азык та без кайтканчы җитә.

Хәлим Шәйхаттар бабайны кочып алды. Һәм шатланып әйтеп куйды:

— Әй, бабакай! Ничек башыңа килде!..

Хәлим белән Шәйхаттар бабай урман эшенә китү турында тагын бераз сөйләшеп яттылар. Баруның һәрбер детале турында, тын калып, аерым-аерым уйладылар да бергәләп киңәштеләр. Ничек китү, үзләре белән нәрсәләр алу турында, ни көн, кай вакыт китү турында

уйлаштылар. Аннары атның барлык запасын үзләре кайтканчыга җитәрлек итеп бүлделәр. Моның эченә ат өчен бүлеп куелган запастан тыш унике көн буена Хәлим белән бабай ашына салынмый калачак бәрәңгеләрне дә кертеп исәпләделәр. Бүлә торгач, зур гәүдәле, инде тамагы ачылып җиткән ат өчен бик кечкенә рацион килеп чыкты.

— Һемм... әлек булса, син моны дүрт көндә ашап бетерә идең дә... Әйдә ярар. Аның каравы без сине, кайткач, алла теләсә...— диде Шәйхаттар бабай, аты да мич башында шикелле итеп сөйләшеп куйды. Аннары Хәлимгә эндәште: — Әниеңә яхшылап әйттик инде, Хәлим. Син дә әйт, мин дә әйтим. Караудa эшнең башы. Карый белмәсәң, атны сольда яткырып та аяк суздырырга мөмкин, ә карагач, шул азык белән дә без аны әнә ни кыяфәткә керттек. Ат дигәнең әз-мәз булса да еш ашарга ярата. Бигрәк тә карт ат шулай. Аннары, җирсенә җиткереп әзерләп биргәнне ярата ат. Башак бирәсең икән, саламын вак тура син аның, йомшаганчы кайнат. Оның тигез сип. Тозны чамалап сал. Суны җылытмыйча эчермә. Ә кайнатсаң, ишшу да әйбәт...

Хәлим бабайның сүзләрен тыңлап бетерә алмады, күзләрен үз ирекләренә куйды. Аның күзләре башта бер ачылып, бер йомылып тордылар, аннары бөтенләй йомылдылар. Башы җил тибрәткән яшь агач шикелле, әкрен селкенгәләп торды да кыйшая-кыйшая, җылы морҗага, морҗадан бабайның күкрәгенә авып төште. Бабай аны, иплән кенә үз мендәренә салды. Үзе мич башыннан төшеп, казаннан чиләккә җылы су алды да ишекне әз генә дә тавыш чыгармыйча ачып, Шәехтай янына чыгып китте.

Ярты төн җитеп килә иде инде бу вакытта.

Өченче көнне таң атып килгәндә, Хәлим белән бабай һәм әлеге өч пионер юлга чыктылар. Хәлим, әнисе белән саубуллашкач, яңадан бер тапкыр Шәехтай янына кереп атның муенын кочып, битен аның ялына куеп торды. Атның аркасыннан ике куллап сыйпап чыкты.

— Бик әйбәтләп кара, әни, яме. Без озак тормыйбыз бит, укуга кайтып җитәсе бар безнең.

Шәйхаттар бабай юлга дип төргән озын, юан тәмәкесен кабызды.

— Шәмсия килен, зинһар, карый күр инде... Болай суыкка китсә, әйт, абзар ишеген бик ачмасыннар.

Карт сөяк жылы тели. Тукта әле...— Шәйхаттар бабай аркасына кигән чана бавын салды да, телогрейка төймәсен чишеп, изүенә тыгылды һәм озын киндерәгә таккан кечкенә генә ачкыч чыгарып, Шәмсия җиңгигә сузды.— Мәле, килен, минем аралыкта, кабык әрҗәдә подаука чамасы бәрәңге калган... Син аны бик әйбәтләп...

Шәмсия җиңги кинәт алмашынып китте. Ул, баласын юлга озатучы һәр ана шикелле, каушый төшкән иде, кинәт башын күтәрде.

— Әбә-әү... бигрәк мескенгә куйдың инде син мине, Шәйхаттар бабай. Әллә син мине, дәшми-тынмый торгач та...

Ул кызды. Аның һәрбер яңа сүзе алдагысыннан горуррак яңгырады.

— Мыскыл иткән шикелле булды инде бу. Әллә мин монда синең бер подаука бәрәңгеңә калганмы! Үләрсең гарьләнеп!..

Шәйхаттар бабай сузган ачкычын кире алырга да, алмаска да белми бераз уңайсызланып торды да аклананып куйды:

— Мин аңар түгел, килен. Барыбер өшеп бетәр диюем генә иде...

— Әйдә, барыгыз, өшемәс. Базыңа төшереп куярмын.

Хәлим әнисенең соңгы сүзләренең тирән мәгънәсен аңлады. Димәк, үзләре юкта ат өчен борчылырга кирәк булмаячак!.. «Әй, әни бәгърем!.. Әй, әни җаным!..» Аның әнисен кочасы, үбәсе килде. Тик Җәләйләр килеп килә иде инде, алар алдында килештермәде, хуш, әни, дию белән генә чикләнде.

— Хуш, улым, бар, исән-сау йөр.
— Хуш инде, килен. Рәхмәт, килен.
— Исәнлектә күрешик, Шәйхаттар бабай.
— Һай, рәхмәт төшкере!..

11

УН АГАЧ БУЛСА ДА...

Хәлимнәр станциягә килеп кергәндә караңгы төшеп беткән иде инде. Тимер юлны аркылы чыгып бераз баргач та, әнә теге ак каеннар артында, леспромхоз конторасы. Хәлимнәргә ничек тә занятие беткәнче барып җитәргә кирәк, ничек тә бүген кәгазь мәшәкатьләре

белән эшне бетереп куярга кирәк. Ул чакта иртәгә иртүк эшкә чыгарга мөмкин булачак. Шуңар күрә безнең юлчылар берсеп-берсе ашыктырдылар.

Ашыгу зыян итмәде. Эшкә язып утыручы кыз, агач тәрәзәсен ябып, китәргә җыена иде инде. Шәйхаттар бабай аңар авыл советыннан алган язуларын сузды.

— Безнең эшне бетереп кенә җибәр әле, таварищ. Кем дип әйтим, күренми... Ерактан килгән иек.

Зәңгәр буяулы агач тәрәзә артында утырган яшь кыз әле авыл советы белешмәләренә, әле Шәйхаттар бабайның туңып күгәргән зур борынына, юньләп сүзен дә әйтә алмас булып каткан иреннәренә карады. Карады да белешмәләрне кире үзенә бирде һәм, авызын кыйшайтып, кимсетүле елмаеп куйды.

— Нигә, әллә берәр җире килмәгәнме, кызым?

— Леспромхоз бит бу, бабай... Мә, малайларыңныкын да ал. Балалар бакчасына илтсеннәр бу белешмәләрен.— Леспромхоз кызы шулай диде һәм тәрәзәсен шалт ябып куйды.— Нигә дип җибәрә торганнардыр шундыйларны, җитмештән узган, ә малайларына ундүрт тулмаган.

Шәйхаттар бабай салкын җилдә яшьләнгән күзләре белән пионерларга карады.

— Бәй, бу ни булды инде, комсомол таварищлар? Бик каты әйтте бит әле бу.

Пионерлар эндәшмәделәр. Хәлим дә мескенәеп калды. Гәүдәсе салынып төште аның. Һәм шунда ук кыюланып китеп агач тәрәзәне шакыды.

Кыз эчтән тыныч кына итеп әйтеп куйды:

— Занятие бетте.

Хәлим ишетергә дә теләмәде.— «Сугышырга икән — сугышырга!..» — Ул тавышын күтәрә төшеп, «кире беткән нәмәрсә»гә эндәште:

— Ачыгыз әле, иптәш!

Кыз бу юлы бөтенләй җавап бирмәде.

— Ачыгыз, диләр сезгә!

Кыз да, ахрысы, мондый гына штурмнарны күргән, коелып төшмәде, тәрәзәсен ачты да шунда ук шап итеп ябып куйды:

— Занятие бетте. Сезгә татарча әйтәләр кажется.

«Алмаслар микәнни?» дигән шик килде Хәлимнең башына. Ләкин ул иптәшләренә сиздермәде. Тыныч күренергә тырышып, бабайның җиңеннән тотты:

— Әйдә, зуррагына керәбез, бабай.

Хәлим «керәбез»не шундый кыю итеп әйтте. Шәйхаттар бабай да батыраеп китте:

— Билгеле, керәбез. Иң зурысына. Менә син, әл.. Нинди җаваплы эшкә шундый юньсез нәмәрсәне утыртып куйганнар бит... Туктагыз әле, оланнар, укыгыз әле әнә шуны, нәрсә дигән?

— Директор дигән.

— Менә шунда керәбез.

— Бик зур... Орышмас микән, бабай?

— Орышмый. Орыша торган булса, андый җиргә утыртмыйлар аны...

Лесмпромхоз директоры Хәлимнәрне орышмады гына түгел, бик тә яхшы каршы алды. Башта әлеге яшь кызны чакыртып алып, җелегенә сеңдергәнче ачуланды. «Өстеңнән тагы чирек жалоба белән керсәләр дә, кухняга бәрәңге әрчергә!..» — диде.

Чыгып барганда кызның күзләре Хәлимнең яндырып ала торган кара күзләре белән очрашты. Кыз, тәҗрибәле кызларга гына хас булганча, бер караудa Хәлимне баштанаяк күреп алды. Ул аның кушылыр-кушылмас кус кара кашларын күрде. Җыйнак колакчыны астыннан маңгаена төшеп торган йомшак чәчен, килешле калын иреннәрен күрде. Шинелен төртеп торган киң күкрәгенә карады да эченнән генә әйтеп куйды:

«Язуында ундүрттә дигән, ә үзе әнә нинди. Белгән булсам мин...» Һәм бу уен йөзендә эз генә дә чагылдырмыйча, горур атлап чыгып китте.

Директор пионерларга стена буендагы скамьяларда урын күрсәтте. Шәйхаттар бабайны иңнәреннән тотып йомшак диванга утыртты.

— Зинһар өчен. Көнгә ун агач әзерләп бирәсез икән, ул да файда. Ун агач — снаряд төягән алтмыш вагонлы паровозны өч километр алып бара. Ягъни сез алтмыш вагон снарядны өч километр алга өстерисез булып чыга. Бу бик зур эш, чамадан тыш мактаулы эш бу, бабай... Без бит турыдан-туры фронт өчен эшлибез. Без кисә торган утынның күбесе хәрби паровозларны йөртергә китә. Үзегез беләсез, ташкүмер ягы кысылды. Донбасс бөтенләе белән теге зобаки кулында бит әле...

Аннары директор пионерларның һәркайсын күзеннән кичереп, болай диде:

— Тик менә сезнең бераз кәефегезне җибәрергә туры килә, аерырга туры килә сезне. Ягъни төрлегезне-төрле урынга куярга.... Ә юк, бергә булмый...— диде ул һәм звонок тавышына кергән хезмәткәргә боерык бирде:

— Бабай белән менә бу егетне (директор Хәлимне күрсәтте) хәзер беренче ашханәгә алып бар. Әйт андагыларга: әйбәтләп сыйласыннар. Бабай чәй ярата торгандыр әле, чәйнең куерагын, самовар түбенә утыртып... Аннары Славинны күр. Иртән берәр җайлы участок сайлап бирсен үзләренә һәм җиллерәк кадровик беркетсен... Ә сез...— Директор Җәләй, Мотыйк һәм Ирек каршына килеп утырды. Ул, сез әле яшьрәк, дип малайларны күңелсезләндерәсе килмәде, болай диде:

— Сез безнең өчен аеруча кирәк кешеләр булып чыктыгыз. Мастерскойда эшләрсез. Начинкалы конфет ящиклары, көрәкләр ясый торган җирдә...

Директор малайларның, ризасызлык белдереп, үзара пышылдауларына каршы зур итеп әйтте:

— Иһи-и, сез әле көрәкнең нәрсә икәнен белмисез икән. Монда килешли тимер юлны көрәп яткан хатын-кызларны күрдегезме? Күрсәгез, шул. Безнең телдә көрәк ул, энекәйләрем, эшелоннарны сугыш кырына тоткарсыз уздырып җибәрү дигән сүз. Без бу көрәкләр белән (директор стенада берәр мәшһүр полководец өендәге сугыш кораллары кебек эленеп торган төрле формадагы, эреле-ваклы көрәкләрне күрсәтте) бөтен Казан тимер юлын тәэмин итеп торабыз. Ә бу юл артык та түгел, ким дә түгел: бер мең биш йөз километр. Километрына берәр көрәктән күпме килеп чыга әле ул, математиклар? Шул-шул. Ә кайчакта буран карны шундый өеп китә, бер километрга унысы да аз була. Көрәк, егетләр, безнең телдә важный нәрсә ул... Ә начинкалы конфет ящиклары!.. Ярый, аларын, баргач, үзегез күрерсез...

Пионерларның чырайлары бераз яктырып китте, җан керде аларга. Директор, үзенең йогынты ясый алуына канәгатьләнеп, телефон шалтыратты:

— Хәйдәр! Синең машиналар мастерскойга кайчан китә? Отлично! Әйт үзләренә, өч егетне ала барсыннар. Минем янда. Әйе. Хәзер чыгалар. Давай. (Ул трубканы куйды да тагын пионерларга таба борылды.) Барыгыз, егетләр. Ашавын да шунда ашарсыз. Түгел, нибары егерме биш-утыз минутлык юл. Ә, юк. Срогыгыз тул-

Ганчы шунда торасыз... Әйдә, уникс генә көн Хәлимсез дә торырсыз әле. Ә аның каравы аннан сезне попутный машина белән туп-туры «Ватанга»!— Ул, тәрәзә пәрдәсенең бер читен чак кына күтәреп, тимер юл аръягына, ниндидер бер сарай кыегындагы тонык кына янган утка күрсәтте.— Әнә шунда барыгыз, сөеклеләрем.

Өч пионер саубуллашып чыгып киткәч, директор Шәйхаттар бабайның аркасыннан сөеп әйтте:

— Сезгә дә вакыт, бабай. Барыгыз, әйбәтләп ашагыз да, ятып йоклагыз. Ә иртәгә эшкә. Килүегез өчен бик рәхмәт,— диде ул һәм бабайның да, Хәлимнең дә кулларын кысты.— Шулай кергәли йөрегез.

12

СИН ДӘ БОТАК ЧАБУЧЫМЫ!

Икенче көн Хәлимнәр бaрактан торып чыгып эш урынына килгәндә бик иртә иде әле. Пычкы тавышлары анда-санда гына ишетелә. Пычкылар, станциядән яңа кузгалып китеп барган паровозлар шикелле, авыр чыжылдыйлар. Кайдадыр утын яралар. Якында гына ат пошкыра. «Әйдә, на-на-на, рәхмәт төшкере!» — ди кемдер. Ат кузгала, чана табаннары сыкрап куялар. Кемнәрдер сөйләшә, ләкин берсе дә күренми. Таң атып кына килә шул әле, урман караңгы. Шул карангылык эчендә урман кисүчеләрнең тәмәке утлары, бер кабынып, бер сүнеп торган ерак йолдызлар шикелле, күнелле жемелдәшәләр...

Хәлимнәрне барактан ияртеп чыккан күн тужуркалы кеше (Славин дигәннәре шушы икән), бераз чамалап торды да, аркылысы-буе житмеш-сиксән адым җир бүлеп алды.

— Участок шушы сезгә,— диде ул. Аннары, Хәлимнәргә беркетелгән кешегә, леспромхозның кадровый эшчесенә әйтте:

— Каушатма, кума син аларны, Мәннән агай, үз җайлары белән кыймылдый бирсеннәр,— диде һәм караңгылык эченә кереп югалды.

Билгеләнгән участокта иллеләп нарат күренә иде. Мәннән абзый балта түтәсе белән берничәсенә суккалап карады да башын чайкап куйды.

— Сугыш, сугыш. Кырамы-кыра агачны! Бигрәк упкын авызлы булып чыкты, каһәр. Дворец сала торган

агачлар бит болар, югыйсә. Ә без аны чаж-чож да, и әйдә паровоз миченә!..

— Быел гына киселмәс тә иде әле.

— Какуй! Утыз елсыз да...— диде Мәннән абзый.— Һәм шуның белән хисләрен таратырга теләгәндәй, үткен балтасын зур кизәнеп бер нарат төбенә чапты, тагы бер чабуга агач төбендә кырт киселгән кыек кирт пәйда булды. Мәннан абзый шул агач төбенә тезләнде дә шыңгырдап торган яңа пычкыны кирткә каршы якка куйды:

— Башлап карыйк алайса, бабай.

Шәйхаттар бабай да тезләнде.

— Хәерле сәгатьтә, якташ.

Үткен кайралган корыч пычкы, тигез яуган ак карга әз генә кыек ятып, коры нарат төбен кисә башлады. Хәлим, балтасын тоткан килеш, пычкы берничә мәртәбә сызуга келә төшеп, бабайның сулышын тыңлады: «Арымады микән? Бу кеше, синнән булмый, бабай, дип конторага кайтып китмәс микән? Абау, бигрәк таза шул бу кеше...»

Ләкин Шәйхаттар бабайның пары андый булып чыкмады. Ул, Шәйхаттар бабай ешрак сулый башлаганны сизгән саен, пычкыны туктатып торды.

— Ял итеп ал, бабай.

— Итим әле, күкрәк кыскан күк итә...

— Шулай булыр... Урман кискәнең бар идеме, бабай?

— Бу елларда гына юк. Кырык еллап булмый микән инде кисмәгәнгә.

Мәннән абзый, тәмәке төрүеннән туктап, әллә дөрес ишетмәдемме, дигән шикелле итеп, Шәйхаттар бабайга карап торды. Аннары әйтте:

— Уһу-у... Мин туганда син инде кисеп туктаган булгансың икән, бабай.

— Алаймы?

Бу сөйләшүдән соң Мәннән абзый пычкыны тагын да әкренрәк йөртә башлады.

Коры наратка ышкылган үткен корыч пычкы тавышы тын салкын һавада шундый матур зыңлап торды, Хәлим кызыгып куйды. Ләкин, юк шул, конторада аңар: «Син киселгән агачның ботакларын чабып, бер төшкә өя барырсың»,— диделәр. Шуңар күрә Хәлим агачның ауганын түземсезлек белән көтте. Пычкы да, Хәлимне

көттерәсе килмәгән кебек, сызган саен кирткә якынайды, якынайган саен Мәннән абзый сагайды, ул үзе сөйләде, үзе нидер тыңлады һәм пычкы белән кирт арасында кими барган араны күзәтте. Менә пычкы юлы, тәҗрибәле күзләр генә күрерлек булып, ачыла башлады. Мәннән абзый пычкыны тартып алды, бер үк вакытта Шәйхаттар бабай белән Хәлимгә читкә тайпыларга ишарәләде, үзе дә, сикереп торып, якындагы агач артына посты. Озын юан агач бераз чайкалып торды да акрен генә янтая башлады, һәм бөтен тавышларны: пычкы чыжылдауларын, сөйләшүләрне, ат пошкыруларын басып, каты гөрселдәп килеп төште. Төшкән уңайга җирдәге карны буранлатып һавага очырды. Хәлим, балтасын тотып, буран астына килеп керде дә, дәртләнеп, агач башындагы ботакларны чаба башлады.

— Егет җилле синең, җаен белеп алгач, менә дигән урманчы булыр,— диде Мәннән абзый һәм Хәлимгә кычкырды: — Син алай ашыкма, егет. Җае белән генә,— диде ул һәм егылган нарат төбендә ял итеп утырган Шәйхаттар бабай янына килде:

— Инде яткан килеш сызып карыйк, бабай.

Мәннән абзый метрлы таяк белән үлчәп алды да пычкыны куеп сызып җибәрде.

— Болай җиңел,— диде Шәйхаттар бабай.

— Да-а... Карт икәнсең инде, бабай.

— Картлык әллә ни зур түгел иде дә әле... Безнең әти 101 гә чыгып вафат булды. Үләренә өч көн калгач, кечкенә чана белән тегермәннән ике капчык он тартып кайтты, беләсең килсә... Дөнья, дөнья картайтты мине...

Яктырган саен урманда хәрәкәт көчәйде. Әле теге, әле бу якта яңа пычкы тавышлары ишетелә башлады. Балта тавышлары ешайды. Сөйләшкән, көлешкән тавышлар да ешайды. Менә, якында гына, пырхылдап көлеп җибәрделәр. Хәлим борылып карады. Ни күзе белән күрсен, анда көлә-көлә өч яшь кыз басып тора иде.

Уңайсызланды Хәлим. Иелде дә дәшми-тынмый гына ботак чабуын дәвам итте. Арыган иде инде ул. Кызлар пырхылдап җибәргәндә, ял итеп алырга дип тора иде. Ләкин артында ниндидер кызлар көлеп карап торганда, ничек туктыйсың! «Әкрен эшли торганмын, шуннан

көләләрдер...» диде Хәлим үз-үзенә һәм балтасын кызу-кызу йөртә башлады. Ләкин ни тиз йөртсә дә, балта ботакка тирән кермәде. Биш-алты чапты инде ул бер ботакка, ә ботак әле һаман бирешми иде. Кызлар бу хәлгә тагы көлеп җибәрделәр.

Менә икесе әз генә ары киттеләр дә егылган бик юан бер агачны кисә башладылар. Берсе, Хәлим янында калып, һаман да аңар көлеп карап торды. Бу, уналты-унҗиде яшьләрендә булса да, Хәлимнән кечерәк буйлы, ач яңаклы, карап торырга токмач кисүдән башкага ярамый торган бер кыз иде.

— Һәй, егет, егет, кая, бир әле апаңа,— диде ул һәм, мә, дигәнне дә көтмичә, балтаны Хәлим кулыннан тартып алды.— Менә болай чабалар аны...

Карале син аны!.. Ботак бер селтәнүдә киселеп чыкты. Икенче селтәнүдә икенчесе киселеп төште, өченчесе, дүртенчесе... Кыз агач башындагы ботакларны утап бетерде дә балтаны җиңел генә итеп наратка чапты.

— Йә, ничегрәк?

Хәлим ах итте:

— Син кем?

— Урман кисүче. Өчебез дә урман кисүче без. Исемем кирәк булса: Зәйтүнә.— Кыз, алга иелә төшеп, Хәлимнең күзләренә кереп китте. Малай уңайсызланып башын түбән иде.

«Ну, кыз! Көче кай җирендә икән соң моның?» дип сокланып куйды ул. Ләкин сокланганын кызга сиздермәде. Шинель кесәсендә килеш, имән бармагына кулъяулыгын чорнады һәм, әкрен генә чыгарып, балтага ябышты. (Янәсе ул бармагы авыртканга күрә генә шулай начар эшли...) Хәлимнең хәйләсе уңышлы чыкты. Кыз сорап куйды:

— Әчәч, бармагың нишләде?

— Шеште.

— Әбәү, шешкәч, нигә җибәрделәр?

— Җибәрмәделәр. Без үзебез килдек.

— Ә безне җибәрделәр. Ике айга дигәннәр иде, дүрт ай була инде. Кайтмыйбыз, уракка төшкәнче эшләргә булдык.

— Син дә ботак чабучымыни?

— Чабучы...— диде кыз, шаян көлемсерәп.

Хәлим аның көлемсерәвендә: «Әллә син ботак чабуны да эшкә саныйсыңмы?» дигән сүзләр укыды. Менә кыз иптәшләре янына килде дә әле генә кисеп чыгарылган бер метрлы юан наратны утыртып куеп, калкурак җиргә басты һәм калун балта белән китереп чапты. Ышанып сугылган калун тавышы яңгырап китте. Тагын чапты кыз, аннары чөй какты да чөйгә тукмак белән сугарга кереште. Суга торгач, нарат ике тигез кисәккә ярылып чыкты. Кыз ике яртыны тагы урталай ярды һәм дүртесен дә төнлә өстенә кар яуган шактый биек әрдәнәгә китереп салды. Хәлим тагы ах итте. Авызы, кыз балтаны кулына алганда ничек ачылган булса, шул килеш калды. «Миннән мәңге булачак түгел икән, үземнән көлдерергә генә килгәнмен икән»,— диде Хәлим. Аннары кинәт алмашынып китте. Ботакларны ничек әләкте шулай өйгәләп куйды да ярсып Шәйхаттар бабай янына килде:

— Бир, мин дә кисеп карыйм әле, бабай.

— Юк, син...

— Кисәм, бабай,— диде Хәлим һәм, эчке ярсуын яшерә алмыйча, пычкы сабын Шәйхаттар бабайдан талаган шикелле тартып алды.— Үлсәм үләм, кызлардан үземне мыскыл иттермим,— диде ул һәм, пычкыны каты басып, тиз-тиз ышкый башлады. Ботагын да чабам, кисәм дә.

Ә төштән соң, Хәлим әйтмәсә дә, эш шулайга әйләнеп китте. Мәннән абзыйны егылып кулын имгәткән чана тартучы урынына алдылар. Шулай итеп, егылганны гына түгел, төптән кисү дә Хәлимнәрнең үзләренә калды.

Күнекмәгән кешегә төптән кисү ансат эш түгел. Хәлим хафага төште. Җитмәсә теге кызлар, әледән-әле эшләрен ташлап, Хәлимнәр янына килделәр. Башта алар, бабайдан уңайсызланып, читтәрәк басып тордылар. Бабай якты чырай биргәч, якынрак елыштылар. Хәлим аларны күреп каушады. Тагын гаеп итәрләр инде, дип пычкысын каты басты, тиз-тиз йөртте. Ә кызлар киткәч, Шәйхаттар бабай Хәлимгә киңәш бирде:

— Алай кирәкми, алай каушама син. Каты да басма шул хәтле... Скрипка сызган күк кенә йөрт пычкыңны. Менә шулай. Ә төптән кисүне, Славин дәдәң әйтте, күрше кызларга кушам, диде.

Моны әйткәндә пычкыны Хәлим тарта иде, пычкы кинәт, комга кергән чана шикелле, туктап калды.

— Кирәкми, кирәкми, бабай,— дип пышылдады Хәлим.— Пычкы белән кисә алмасам, тешем белән чәйним мин аны, әмма ләкин кызлардан мәсхәрә иттермим инде.

Шәйхаттар бабай, кайчандыр Хәлим яшендә булган Шәйхаттар бабай, Хәлимне аңлады, сирәк тешләрен күрсәтеп көлемсерәде. Күзләре, ничектер, ялтырап китте.

— Һәй, мал-лай-й!..— дип сузды ул һәм пычкыны гадәттәгедән җитез итеп үзенә тартып алды.— Һәй-һәй, малай-й!..

Ә Мәннән абзый еккан агач киселеп бетеп, яңаны егарга, Хәлим белән егарга чират җиткәч, алай димәде. Җитдиләнеп китте ул, Хәлим өчен генә түгел, үзе өчен дә борчылды. Бая Мәннән абзый бөтен авырлыкны үзенә алып кискән иде, пычкыны үз ягына тартып алганда катырак баскан иде. Ә хәзер бөтен авырлык аның өстенә төшә...

Бабай төсле үк борчылган, тик борчылуын йөзенә чыгармаска тырышкан Хәлим:

— Без әнә тегене кисик, бабай,— дип, кызларга ераграк бер наратны күрсәтте.

Шәйхаттар бабай, «нишләп?» дип сорап тормады, эшнең нәрсәдә икәнен төшенгән иде ул. Ләкин бернәрсә дә төшенмәгәндәй итеп:

— Әйдә алайса,— дигән булды һәм Хәлим күрсәткән нарат төбендәге карны тапташтырды да ылыс җәеп тезләнде. Хәлим озын, төз наратка карап, тирән, салкын суга чумар алдыннан яр кырыенда басып торган кешедәй, калтыранып куйды, аннары ул да тезләнеп, пычкы сабына ябышты. Пычкы, бабай тартып алганда, әз генә эз сызса да, Хәлим тартканда, эздән чыгып, тешләре белән кызгылт кәрән кайрыны тырнап төште. Бабай, эндәшмичә генә, пычкыны беренче сызгаң эзенә кертеп, үзенә таба тартты. Хәлим тарта башлагач, пычкы тагы (бу юлы карга кадәр) кайрыны тырнап төште. Хәлимнең борын яфраклары, ике каш арасы тирләп чыкты. Пычкы өченче тапкыр да эздән чыгып, кайрыны тырнап төшкәндә, Хәлимнең калак сөякләре арасына кадәр тир бәреп чыккан иде.

Әгәр бу хәл урманда түгел, өйдә, лапас астында булса, әгәр аның пары Шәйхаттар бабай түгел, әтисе булса, ул, бәлки, булмый мининән, дип торып киткән дә булыр иде инде. Ә биредә җитмәсә тегеләрнең шырык-шырык көлә-көлә килеп җитүләре бар бит әле тагы...

Хәлимнең хыялында кызлар инде килеп тә җиттеләр... Әлеге кечкенәсе, Хәлимнән балтаны тартып алып ботак чабып күрсәткәнс, Зәйтүнә исемлесе, Хәлимне бер читкә төртеп җибәрде дә чаж-чыж итеп кисә дә башлады. «Һай, егет, буй гына бар икән синең!..»

Хәлим пычкыны эзенә куйды да, бер кулы белән сабыннан, икенчесе белән сыртыннан тотып, үзенә таба тартты. Бусында пычкы эздән чыкмады Кабат сызганда пычкы үзен эздә тотып тора иде инде. Авыр булды Хәлим өчен бу сызулар. Хәзер куркудан түгел, арудан, җайсызлыктан тирләп чыкты Хәлим. Ләкин бусы җылы тир иде, бу — артка чигенү түгел, алга таба бару иде. Алда торган ун мең, йөз мең адымның беренче адымнары иде бу. Инде Шәйхаттар бабай йөзендә дә җиңү өмете чагыла иде. Хәлим шинелен салып, бер ботакка элде. «Була бит, бабай!» — димәкче булды һәм шунда ук: «Юк, алай дияргә иртә әле»,— дип эндәшми калды.

Әйе, алай дияргә иртә иде әле. Бик тиз арыдылар алар. Тән җылысы Хәлим тезләнгән ылыс аша үтеп карны эретте. Тезе юешләнеп әчетте. Шулай да малай сер бирмәскә тырышты.

— Арыдыңмы, Хәлим?— дигәч,

— Бик ук түгел, бабай,— диде.

— Ял итик.

— Бераз кисик әле.

Һәм алар кистеләр. Сызган саен пычкы тирәнрәк батты, моны күреп Хәлимнәрнең күңелләре үсте, әледән-әле ишетелеп торган паровоз тавышлары аларга дәрт кертте:

— Ә иртәгә паровоз фронтка без кискән утынны ягып китә инде, әйе, бабай...

— Шулай итә...

— Ух, бабай...

Шул чак Хәлим Шәйхаттар бабайның шомлы сулышын ишетеп калды. Әйтерсең, бабайның үпкәләрен алганнар да, иске гармонь мехы куйганнар, әйтерсең, бабай, үпкәсе белән түгел, шул мех белән сулый иде.

Хәлим, сорап та тормыйча, пычкыны туктатты.

— Ял итик, бабай.

Бабай да сынатырга яратучылардан түгел. Ул да, Хәлим шикелле, кисик әле бераз дигән булды. Хәлим тыңламады. Тез асларындагы ылысны биегрәк өеп өстенә утырды.

Инде хәзер бармактагы яулыкны чишәргә дә була иде. Ләкин Хәлим чишмәде. «Шешкән бармак белән дә шулай эшли алган, дисеннәр әле!» — Ул яулыкны калынрак итеп бәйләп куйды. Һәм бая әйтергә теләгән: «Була бит, бабай!»ны тартынмыйча әйтте.

— Була болай булгач,— диде бабай.— Тырышкач, ташка кадак кагып та була ди бит. Дөрес, аны һәркем кага алмас. Ә син кагарсың. Кага торганга ошыйсың син,— диде Шәйхаттар бабай һәм тәмәке төрә башлады.

Кышкы көннәр кыска була, әбәттән соң бераз селкенгәләп алуга караңгы төшә дә башлады. Анда-санда тартылган тәмәке утлары тагын йолдызлар шикелле җемелдәшәләр иде. Кызлар тагы килеп җиттеләр. Алар бу юлы да көлешә-көлешә килделәр. Бу юлы да беренче сәламне бабайга бирделәр.

— Нихәл, бабай!

— Картларча гына.

— Картларчага бик охшамаган әле: туныйсыз гына,— диде кызларның берсе.

Икенчесе:

— Кайтыгыз инде, бабай, бүгенгә җитеп торыр,— диде.

Бабай, кисүеннән туктамыйча гына, әйтеп куйды:

— Һәй, бу вакыттан кайткач, эш була димени ул.

— Бәй, хайран күп эшләгәнсез ич. Мич башында ятасы бабай шулкадәр эшләгәч тагы...

— Мич башында?.. Аңа карасаң, сез үзегез дә егетләрнең өй түреннән гармонь сыздырып үткәннәрен тыңлый-тыңлый, чигү чигеп кенә утырасы кызлар да бит...; ак яулыкны арттан бәйләп, сагыз чәйнәп, утызлы лампа яктысында...

— Лампа яктысында булмаса, электр яктысында чигәбез без аны чигүне...

— Чигәрсез...— диде бабай,— ләкин хәзер түгел, сугыш беткәч, мин яңадан мич башына менеп киткәч...

— Юк, хәзер чигәбез, бабай. Ышанмасаң, кичке аштан соң безнең баракка кереп кара.

— Үзеңә янчык чигеп бирербез.

— Ә егетеңә — кулъяулык...

— Аның яулыгы ба-ар,— дип сузды кызларның иртә белән Хәлимне ботак чабарга өйрәткәне, Зәйтүнә исемлесе. Һәм, малайның бармагындагы яулыкка карап, әллә ничек серле итеп, көлеп куйды.

— «Нигә көлә ул? Әллә Хәлимнең хәйләсен сизенгәнме, югыйсә?.. Әйтеп салмасын тагы...»

Хәлим уңайсызланып бер читкә китте дә кослып калган чыбык-чабыкларны җыеп йөргән булды. «Ә бабайдан, кайчан шеште аның бармагы, дип сорасалар? Бабай, нишләп шешсен, шешмәде, дисә?..»

Хәлим, үзем шунда булсам, бабайны андый җавап бирүдән ничек тә тыеп калырмын дип, яңадан эш урыннарына килде.

Ләкин ул килгәндә сүз икенче темага күчкән, уенкөлкедән ераклашкан, Шәйхаттар бабай тәмам кызып җиткән иде.

— ...Ә немец сезгә генә дошманмыни? Миңа дошман түгелмени ул немец?! — диде Шәйхаттар бабай.

Бу сүзләрне ул кызларның: «Сиңа эшләмәсәң дә ярый инде, бабай» диюләренә җавап итеп әйтте. Һәм кызларга авыз ачарга да бирмичә, дәвам итте:

— Анда немец килә, ә Шәйхаттар мич башында кендеген җылытып ята... Ю-ук, сез, прәме, хәтерне калдыра торган сүз әйттегез әле... Әз генә җаны бар кеше тик ятмас бүген. Бүген тик яту — немец алдында кул күтәреп тору белән бер ул. Ә мин патша әрмиясендә дә немец алдында кул күтәреп тормадым. Хәзер күтәрәмме соң мин кулымны!..

— Ах алла... кызма әле, бабай...

— Тик тор! Сез генә күпне беләсез! «Мылтык тотар хәлең калмаса, тешең белән чәйнә немец бугазын», диләр иде безгә әфисәрләр...

— Кызма әле, бабай...

— Тик тор!.. Аннары, сез минем якка шуны да белегез: минем немецта үз чутым да бар.

Шәйхаттар бабай бияләйләрен салып атты да кулларын аска каратып кызларга таба сузды. Аның бер генә бармагында да тырнак әсәре юк иде.

— Пленда... сугыш серен әйтмәгән өчен... Ә мин сугыш серен әйтергә дур-ракмыни. Дөрес, ул вакытта патша заманы иде әле. Ә җир, барыбер безнеке, ата-баба җире... Келәшчә белән суырдылар. Сәгатькә карап кына суырган булалар, бетле тәреләр. Берьюлы суырып алмый бит ул аны. Берсен-берсен бер ел суыра дип белерсең... Шулай үттеләр алар минем үзәккә.

Шәйхаттар бабай тешләрен кысты. Чигә сөякләре юка яңак тиресен төртеп чыктылар. Кызларның берсе аның бияләйләрен җирдән алып киертте һәм, нидер әйтергә теләп, авызын ачты. Шәйхаттар бабай кызга бу юлы да сөйләргә бирмәде:

— Әйдә, улым, тот,— диде ул Хәлимгә. Үзе тезләнде дә пычкыны эзгә кертә башлады. Хәлим дә тезләнде. Кызлар китәргә дә, китмәскә дә килештермичә, тик басып тордылар. Пычкы бу юлы гадәттәгедән тиз йөрде. Менә ул кысыла башлады. Шәйхаттар бабай, авыр күтәрелеп, балтаны кулына алды.

— Шулай, кызлар, миңа мич башына менәргә никак ярамый.

Ул, инде тыныч сөйләнә-сөйләнә, агачның киселми калган ягына берничә тапкыр чабып куйды. Артык юан булмаса да, яхшы ук озын нарат, Шәйхаттар бабайның сүзләрен хуплаган төсле, тантаналы шаулап, ак кар өстенә ауды. Йомшак кар, буранлап, югары күтәрелде дә әкрен генә нарат өстенә яуды.

13 ХӘЛИМГӘ УҢАЙСЫЗ БУЛЫП КИТТЕ...

Баракта ут сүнде. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр саф һавада эшләп арыган кешеләр бик тиз йокыга талдылар. Шәйхаттар бабайны да йокы изрәтте. Ә Хәлим аңар йокларга бирмәде. Йоклап китәм дигәндә генә я бер, я бер сүз әйтеп куя иде. Алар, зур тәрәзәләрдән төшкән ай яктысында бер-берсен күреп, әкрен генә сөйләшеп яттылар.

Эш җиңел булмады. Әле мондый эшкә чыныкмаган Хәлим өчен дә, җегәре йомшаган Шәйхаттар бабай өчен дә авырга килде. Ашханәдә беренче кашыклар калтырап торды. Шулпа, авызга килеп җиткәнче чайпалып, түгелеп бетте. Хәлим дә арыган иде. Ләкин ул хәзер бу турыда уйламаска тырышты. Кызышкан учларын одея-

лы астыннан чыгарып салкынча сәкегә куйды да бабайның колагына пышылдады:

— Без, синең белән, Шәехтайга азык әзерләүчеләр генә түгел инде болай булгач, ә бабай.

— Төшенеп бетмәдем.

— Фронтка корал ташый торган поездларны йөртүчеләр дә булдык инде без болай булгач...

— Нәкъ шулай, улым...

— Директор, ун пулин булса да, дигән иде, ә безнең утыз биш булды.

— Һәйбәт булды, улым.

— Ух, баба-ай!.. Ә ул паровоз мичендә ничек сыя соң без кисә торган утыннар, бабай? Миче зурдыр шул, имә? Яраса, бер күреп чыгарбыз әле, яме, бабай?

Шәйхаттар бабай җавап бирмәгәч, Хәлим, башын күтәрә төшеп, аның битенә карады. Бабай инде күзләрен йомган, изелеп йоклый, ә йөзе әле һаман да елмая иде.

— Йоклап та киткән,— диде Хәлим һәм әкренләп үзе дә изри башлады. Изрәү аралаш аның күз алдына Шәехтай килеп басты.

«Шәехтай, Шәехтай! Нишлисең икән син хәзер,— диде Хәлим атны ни кыяфәттә күз алдына китерергә белмичә.— Башак ашыйсың микән? Җылы су эчәсең микән? Әллә инде эни түшәп биргән коры саламда йоклап ятасың микән?.. Ай, бик арык бит әле син, бахбай, бик арык... Бераз сабыр ит инде, менә он алып кайтырбыз, акча яхшы төшсә, солысы да булыр... Рәхәтләнеп ашарсың, малкай. Кайткан көнне алдыңнан калганчы ашатам әле мин сине. Ни төсле булырсың икән... Җәләйләргә рәхмәт инде, ничек башларына килгән. Авылда көн тик йөреп тә үтәр иде... Ә хәзер өйдә калган пионерлар нишли икән?

Урынында язып китәргә кирәк килмәгән: Хәлимнең тәрбиягә ат алуы көне-сәгате белән пионерлар арасына таралып өлгерде. Этиләре өйдә була торып тәрбиягә ат алмаганнарны, яки алырга теләмәгәннәрне әйткән дә юк, Хәлим кебек үзләре эти урынына калып, чамалары булмаганнар да уңайсызландылар. Көнләшүчеләр дә булды. Әлбәттә, көлүчеләр дә юк түгел иде. Андыйларга өеткы салучы Ибрай булды.

— «Үзең хәерче бул, үзең җырлап йөр», диләрме әле? —диде ул авызын колагына хәтле ерып.

— Хи-хи-хи...

— Җитмәсә, «малкай, малкай...» дигән була бит әле ул аны... Аяклы каза ич бу, дигән идем, абзардан куып чыгарды, марайрар...

— Ха-ха-ха...

Вожатый Фәрдәнә бу турыда тирән уйлады. Мәсьәләне шул ук кичне чираттан тыш сборга куйды. «Ашату гына димәгән...» Пионерлар колхоз абзарында калган урта көрлектәге атларны шефка алырга булдылар. Унбер баш атның һәркайсына зуррак яшьтәге бер-ике пионер беркетелде. Аларга Ленинградтан эвакуацияләнеп килгән өч пионер да кушылды. Дөрес, алар авыл балалары түгел иде, өчесенең дә эти-әниләре завод эшчеләре. Шулай да бу эшкә бер дә ялындырмый алындылар. Әйе, авыл балалары шикелле, атның сыйрагын култык астына кыстырып, тоягын чистарту түгел, кайсы-берсе йөгәненә кагылырга да өркеп торды. Ә торабара ияләнделәр тагы... Иң әһәмиятлесе: эшне җиренә җиткереп эшләделәр, эшчеләрчә дисциплиналы булып чыктылар һәм бу яклары белән авыл пионерларына үрнәк булдылар. Сбор карарында, иртән алтыдан җидегә, кич сигездән тугызга тикле атлар янында булырга, диелгән иде. Алар бер минут соңга калмыйча, килеп җиттеләр һәм, конюх күзәтүе астында, сбор карарында күрсәтелгән эшләрне башкардылар. Колхоз пионерлары абзарга килгәнче, алар инде шактый эшләрен бетереп куйдылар.

Ат абзарында иртә-кич эш кайнады. Башак өчен салам турадылар, су кайнаттылар. Су кайнату өчен утын бетә башласа, кечкенә чаналарын өстерәп, урманга йөгерделәр. Бара-тора атларга беркетелмәгән кечкенә балалар да, олы яшьтәге пионерлардан күрмәкче, абзарга йөри башладылар. Абзар чистарды. Атлар үзләренең нәни хуҗаларын күңелле пошкырып каршы ала торган булдылар.

— Менә бу чын-чынлап шефлык булды,— диде өлкән конюх.— Мактарга була сезне, оланнар.

Барак сәкесендә иптәшләре турында уйланып ята торгач, Хәлимнең башына шундый уй килде:

— Әгәр алар урынына кызлар калып торып, малайлар безнең белән килсә, ничек әйбәт буласы икән бит... Кара, нигә әйтмәдем?.. Ләкин алай Хәлим — Хәлим булыр идеме соң? Алай бүтәннәрдән нәрсәсе белән аерылып

торыр иде Хәлим?..— дип уйлады малай. Һәм бу бозык уе өчен шундук үзеннән-үзе оялып куйды.

— Үзем атакага барып, иптәшемнең йоклап калганына сөенгән кебек була түгелме соң бу?..

Хәлимнең йокысы качты. Аның вөҗданы газаплана иде. Әллә хәзер авылга йөгерсен микән? Ерак шул... Һәм ул, бер карарга килеп, урыныннан торды. Башын сәке астына тыгып, юл капчыгыннан куен дәфтәре белән карандашын алды да, ай яктысы төшкән тәрәзә төбенә тезләнеп, үзенең тәкъдиме турында иптәшләренә хат язды. Аннан-моннан гына киенде дә, хатны тотып, почтага чыгып йөгерде.

14

ГЫЙБРӘТЛЕ СҮЗ ӘЙТТЕҢ...

Урманда, берьюлы ике-өч җирдә, чаң суктылар. Хәлим чаңны ишетте. Ләкин йокысыннан айнып җитә алмады. Чаң Хәлимгә чишмә тавышы булып ишетелде... Яз икән... Хәлим, Шәехтайны җигеп, тирләп-пешеп сабан сөрә икән. Менә ул сабанын калдырды да, йөгереп килеп, чишмәдән учына җыеп су эчте. Аннары, эшләпәсенә тутырып алып, Шәехтайга эчерә башлаган иде, шул тирәдә генә чәчү чәчеп йөрүче Шәйхаттар бабай кычкырып салды: «Эчермә, эчермә!.. Малкай тирләгән, ә син аңар теш сындырырлык салкын су эчерәсең... Һәй, фәләнтөгән-фәсмәтән!.. Дөньяга бүген генә килдеңме әллә югыйсә?..»

Аннары чаң нечкә тавышлы кыңгырау булып ишетелде. Кыңгырау Шәехтай муенында икән, колхозда уңыш бәйрәме икән. Кызыл гаскәр Гитлер яуларын бөтереп тыккан, сугыш беткән, кырлар мул уңыш биргән икән. Хәлим кара лаклы зур тарантас кузласына утырган, ул уртага җигелгән Шәехтайны көчкә тыеп тора икән. Шәехтай ярсып таптана, башын чайкый һәм шул чакта кыңгырау нечкә генә шалтырап куя икән. Менә Хәлим тыеп кала алмады, Шәехтай элеп алып китте. «Хәлим, тот!..» Борылып караса, тарантаста, орденнарын ялтыратып, кулын әнисенең биленә салып, әтисе утыра икән... Шәехтай алдагы атларның барысын да узып чаптыра башлады. Юлны ташлап, уҗым өстеннән алып китте. Канауларны сикереп чыкты. «Хәлим, тот!» Хәлим аякларын терәде, дилбегәсен кулына чорнап тотты. Ат аның саен ярсый иде. «Хәлим, тот!..» Чаң чаңга әйләнде.

Хәлим күзләрен ачып җибәрде һәм кулы белән орыныр-орынмас уятып торган Шәйхаттар бабайны күрде. Ул, уятырга кызганып әкрен генә:

— Хәлим, тор! — дип сөйләнә иде.

Хәлим төшендә дилбегә итеп кысып тоткан шинель чабуларын җибәрде. Стенадан стенага сузылган киң сәке бушап калган, урманчылар кайсы юына, киенә, кайсы киенеп бетергән дә, иптәшен ашханәгә әйди, ә кайберләре инде ашап кайтканнар, пычкы һәм балталарын күтәреп, эшкә китеп бара иделәр.

— Әбәү, ник уятмадың, бабай?

— Мин үзем дә чаңга гына уяндым. Изелеп кенә киткәнмен, һи-һи... Нихәл, йокың туйдымы?

— Туйды.— Хәлим сәкедән сикереп төште дә күлмәген салып, кран астына кереп, юынырга тотынды. Юына-юына ул Шәйхаттар бабайга әле генә күргән төшен сөйләде.

— Өндә шулай булсын иде ул, ә, бабай!..

— Ә нигә булмас икән... Башкасын белмим, әмма ләкин, сабанны сөрәбез без аның белән.

Ул, моңа дәлилләр китерә-китерә, озак итеп сөйләргә керешкән иде, Хәлим ашыктырды. Ә Шәйхаттар бабай башлаган сүзен бетермичә туктамады. Аннары әйтте ул Хәлимгә:

— Ашыкма. Ашыгып эш булмый. Беләм мин сине, синең кешедән калышасың килми. Ә без, әйтергә мөмкин, кеше түгел, син әле кеше булып җитмәгән, ә мин инде...— Ул йөргән җирләре әллә кайда еракта калган кеше төсле итеп, кулын селкеп куйды.

Ашханәдә дә әкрен генә маташты ул. Алар эш урынына барып җиткәндә, күрше кызлар әллә кайчан килгән һәм, бер чыршыны егып, турап та бетергәннәр иде инде.

Шәйхаттар бабай кызларга ерактан елмаеп сәлам бирен килде.

Кызлар кисүләрен әкренәйттеләр.

— Нихәл, бабай! — диде аларның берсе,— нигә соңладыгыз, әллә егетең йокы чүлмәгеме?

— Түгел, нишләп алай булсын...

— Без егетеңне уята алмыйсыңдыр, дип торабыз тагы. Зәйтүнәне җибәрергә тора идек инде.

— Түгел...— дип сузды Шәйхаттар бабай.— Ул инде әллә кайчан...

— Шулаймыни?..

— Шулай... Әйдә, улым, эшне менә монысыннан башлап җибәрик әле,— диде бабай һәм ылыслары кечкенә чүмәләдәй булып күренгән нәзек-озын нарат төбенә тезләнде.

Пычкы, коры нарат кайрысын берникадәр кирлемырлы тырнап торды да, эз алып кисә башлады. Кызларның тавышлары тынды. Аларның бары пычкы һәм балта тавышлары гына ишетелеп тора иде. Кичә, берсе килеп, берсе китеп, туктаусыз йөреп торган кызлар, бүген ник бер килеп карасыннар... Хәлимнәр туктаганны күреп, берәр уен-көлке әйтеп алдылар да тагын кисәргә тотындылар.

Шәйхаттар бабай янчыгын чыгарды:

— Я, килегез әле, күршеләр, каршыгызга утырып бер көйрәтеп алыйм әле.

Ә күршеләр, кичә шундый сүз ишеткәндә мең белән җавап кайтарган кызлар, бу юлы шаяртып тормадылар. Бары Зәйтүнә исемлесе генә, кичә Хәлимне ботак чабарга өйрәткәне генә, пычкысын беразга әкренәйтә төшеп:

— Сагынсаң, үзең кил, бабай,— дип куйды һәм әүвәлгедән дә кызурак кисә башлады.

— Әбәү... Әллә кичәге өчен бабагызга үпкәләдегезме югыйсә?..

— Юк. Кичә бик гыйбрәтле сүз әйттең син, бабай...

— Кара, нинди сүз булды икән ул? — дигән булды бабай.

Зәйтүнә эндәшмәде. Әле генә киселеп чыккан юан томранны утыртып куйды да авыр балтасы белән китереп сукты. Тагы бер сугуга нарат икегә ярылып китте. Зәйтүнә берсе өстенә утырды да Хәлимгә карап елмаеп куйды.

Хәлим ах итте.

«Әллә балталарының берәр хикмәте бармы боларның?..»

Төшке ашка чаң сугылып, кызлар ашарга киткәч, Хәлим чыннан да шикләнеп аларның карга күмеп калдырган балталарын барып карады. Балтаның берниндидә хикмәте юк иде, әлбәттә. Ә менә эшләре хикмәтле иде... Тау-тау өелеп торган утын әрдәнәләре Хәлимнең башын әйләндереп җибәрде. Ә бабай янына килгәч, көнелсезләнеп, болай диде:

— Без дә эшләгән булып йөрибез икән, бабай...
— Нигә, улым?
— Син аларныкын барып күрсәң икән...
— Бик күпмени?
— Әнә ул әрдәнәләр икесе дә бүген турап өелгән.
— Ә-ә...
— Кешедән калу була бит бу, бабай.

Шәйхаттар бабай башта, без яртышар кеше генә, фәлән генә, дип акланып торды. Аннары уйга калды: «Малай дөрес әйтә. Әйе, кешедән калу була бу... Тукта әле, тукта...» диде ул эченнән генә. Аннары, үзенең көченә ышаныпмы, әллә Хәлимне юатыр өчен генәме, әйтеп куйды:

— Борчылма, Хәлим, калышмабыз без алардан.
— Калышмассың...
— Менә күр дә тор.

Икенче көнне иртә белән Хәлим уянганда (кешеләр бар да йоклыйлар иде әле) Шәйхаттар бабай баракта юк иде. Хәлим берникадәр вакыт, керер, тышка гына чыккандыр, дип көтеп ятты. Көтеп-көтеп кермәгәч, урманга чыгып эндәшеп карады. Бабай юк иде.

— Әллә инде эшкә киткән?..

Әйе, бабай шунда иде. Ул инде кичә ярылмый калган ике-өч агачны ярып куйган һәм бер нечкә наратны, төбен балта белән чабып егарга маташа иде. Хәлимне күргәч, ул, урлап урман кисүче шикелле, уңайсызланып туктап калды. Билен турайтты. Балта борынын тапталып тыгызланган карга чапты һәм, бик гади нәрсә турында сөйләгән кебек итеп, әйтеп куйды:

— Иләмсез кызу якканнар ла... йоклап булмады. Бераз сулу алыйм дип чыгуым иде...

Бабай, чыннан да шуның өчен генә чыккан кеше шикелле итеп, яңа ярылган нарат өстенә килеп утырды да, бер мизгел бүреген салып тезенә куеп торды.

Хәлим агач араларыннан үтеп кергән ай яктысында аның шома кырылган башыннан күтәрелгән җылы парны күрде, тәмәкесен төрә алмыйча калтыранып торган шыр сөяк кулларын күрде һәм аны шелтәләү өчен сүзләр эзләде. «Ник бу вакыттан килдең? Вакытлы эшләү дә бик җиткән сиңа», димәкче булды ул. Ләкин әле генә килеп туктаган көчле паровозның арыган тавышын ишетеп туктап калды. Паровоз гүя: «Утын бир, утын

бир, утын бир...» дип пошкыра иде. Шул чак әтисенең: «Снарядны тагы бер генә минут китерми торсалар, безнең үзебезне дә, тупларыбызны да немец танклары таптап китә иде» дип сөйләгәне исенә төште Хәлимнең. Ул Шәйхаттар бабайның күзләренә карады. Гүя, Шәйхаттар бабай да бу турыда ишеткән, күзләре гүя, менә мин дә син уйлаганнарны уйлыйм шул, дигән шикелле итеп карыйлар иде.

Хәлим дәшми калды. Һич алай итәрмен дип уйламаган иде, карга кадалып торган балтаны алды да Шәйхаттар бабай чапкан эзгә чаба башлады.

Бабай урыныннан күтәрелде:

— Син нәрсә, Хәлим?

Хәлим җавап бирмәде.

— Нишлисең, дим?

— Чабам ич.

— Чапма, бар кайтып йокла, бик иртә әле.

Бабай балтага үрелде, Хәлим бирмәде:

— Нигә, сиңа да иртә ич, Шәйхаттар бабай.

— Миңа — миңа инде ул.

— Миңа да — миңа шул менә, бабай...

Бу, Хәлимнең: син эшләгәндә мин ничек карап ятыйм, дию иде, Шәехтайга азык күбрәк булсын, дию иде, немец танкысы безнең тупны таптап китмәсен өчен, снарядлар фронтка бер минутка да соңга калмыйча барып җитсен, дию иде. Бу, ниһаять, Хәлимнең кызлардан калышмыйк, дию иде. Шәйхаттар бабай аны шулай аңлады да. Тик ул Хәлимне үлеп кызгана иде. Шуңа күрә һөҗүмгә күчеп карады.

— Әниеңә әйтәм мин сине... Фронттан кайткач, әтиеңә дә...

Хәлим дәшмәде. Ул чык-чык итеп нарат төбен чабуын дәвам итте. Шәйхаттар бабай төкереп куйды. Һәм картларча алпан-тилпән атлап китеп барды. Үпкәләде, кайтып китте, дип уйлады Хәлим, ләкин ялгышты. Дөрес, ул баракка кайтты кайтуын, ләкин бик тиз әйләнеп килде, бу юлы аның култык астында пычкы иде. Ул, дәшми-тынмый гына килеп, икесенең дә тез асларына калын итеп ылыс җәйде. Пычкыны кисү уңаена куйды. Хәлим дә, балтасын ташлап, дәшми-тынмый гына пычкы сабына ябышты.

— Болай кылана торган булсаң, директорга керәм мин, менә шул сиңа.

— Керерсең.

Пычкы, көн дә әйтелә торган: «Хәерле сәгатьтә»не көтеп тормыйча, чаж-чыж йөри башлады. Шәйхаттар бабай пычкысын кирәгеннән артык каты баса-баса әйтте:

— Бәй, әллә кермәс дип беләсеңме?

— Керерсең, дим ич.

— Керермен, и сине кайтартып җибәртермен...

— Шулай итәрсең, ләкин башта үзеңнең ярты төннән торып килгәнеңне әйтерсең, яме?

— Дөрес сөйләмисең, син килер алдыннан гына килгән идем мин.

— Ә боларны Тукай шүрәлеләре ярып куйды микәнни?

Бабай беравык сүз эзләп торды. Тапкыр сүз таба алмагач, төкереп башын чайкап куйды. Ә кисеп бетергәч, бер сүз дә әйтмичә, Хәлимне арык күкрәгенә кысып, сөеп торды.

Хәлим аның тир исен сизде, иске гармонь мехы шикелле гыжлап сулыш алуын ишетте. Бу минутта Шәйхаттар бабай Хәлимгә үз бабасы шикелле үк якын иде, үз иде.

Ул бу турыда Шәйхаттар бабайның үзенә дә әйтә язып калды. Һәм, аның кочагыннан чыгып, балтаны кулына алды да әле генә егып салынган наратның ботакларын чабарга кереште.

— Ә син тарта тор, бабакай. Төреп биримме?..

Үзләре шаулап йөрмәсәләр дә, Хәлимнәрнең бу эшләре тиз арада бөтен урманга таралып өлгерде. Аларның иртәнге ашка кадәр эшләп киткән эшләрен башта күрше кызлар килеп күрделәр. Күрше кызлар үзләренең күршеләренә, э кич кайткач, баракларындагы кызларга сөйләделәр. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатлангач, һәм, бу тулы бәяле булмаган ике кеше сугыш вакытының эш нормаларын җитмешәр процент итеп үтәгәч, ераграк участоклардан да килеп, эшләгәннәрен карап киттеләр.

Кичкырын директор да килде. Ул Хәлимнәрнең үзләренә күренмичә, бер читтән генә карап торды.

Хәлимнәр тигез генә, каушамыйча гына эшли иделәр. Хәлим тизләтә башласа, Шәйхаттар бабай туктата иде.

— Бер көйгә генә син, скрипка сызган шикелле генә... Озак эшлә син, ну бер көйгә эшлә. Бертуктамый алты чакрым йөгереп буламы? — Юк. Ә менә әкрен-әкрен алтмыш чакрымны да барып була. Шул-шул...

Ул Хәлимгә кырыкмаса-кырык әйтелгәннәрне кабатлады. Утын кисүнең бөтен нечкәлекләрен өйрәтте. Хәтта кискәндә, ярганда ничек суларга икәнен дә әйтте ул Хәлимгә:

— Син алай тәртипсез сулама. Менә ничек кирәк: пычкыны тартып алганда сулышыңны чыгар, ә мин тартканда сула. Шулай ит...

Ял иткән арада Шәйхаттар бабай пычкы тешләренең разводын карады. Берәр теше кысыла төшкән булса, хәзер игәү алып киңәйтте. Утын яру өчен, төрле калынлыкта, төрле киңлектә чөйләр ясады. Ул аларны утынына карап кулланды. Метр озынлыктагы, ярты метр юанлыктагы нарат тумрасын бастырып куйды да, көрәшкә чыккан батыр төсле, башта аңа карап торды. Аннары җайлырак ягыннан китереп сукты. Чөй какты. Анысы бераз кергәч, икенчесен какты. Агач, сыкрап, урталай ярылып китте. Хәлим, аларның егылганнарын да көтмичә, күтәреп алып әрдәнәгә өя барды. Нечкәрәк агачларны үзе ярып ташлады.

Эшне туктатырга чаң суккач та, Хәлимнәр бераз юандылар әле. Алар гына түгел, күрше кызлар да кайтып китмәделәр. Әйтергә кирәк, бөтен тирә-якта, көндезге шикелле үк булмаса да, пычкы чыжылдаулары ишетелгәләп куя иде.

Шәйхаттар бабай кешеләрнең чаң суккач та эштән туктамауларында үзләренең азмы-күпме катнашлары барлыкны аңлап, балаларча куанды. Бу турыда ул Хәлимгә дә әйтте.

— Шуңар микән, бабай?

— Шуңар шул, һе.

Хәлим тагын очынып китте.

— Яле, менә бусын да егып салыйк әле, бабай. Бер ялгызы моңаеп утырмасын...

Директор барысын да күрде, барысын да ишетеп торды. Ул, тиз генә китеп, бик тиз кемнедер ияртеп килде. Монысы бабай белән малайның бүгенге эшләренә күз йөртеп алды да башын чайкап куйды. Кул биреп күреште ул алар белән, сорашты һәм үзләрен рәсемгә төшереп

алып китте. Бүген кисеп өйгән әрдәнәләрен дә төшерде рәсемгә.

Икенче көнне бу рәсемнәр ашханә алдындагы ике янәшә каенга беркетелгән мактау тактасында иделәр. Рәсемнәрне зур ак кәгазьгә ябыштырганнар да кызыл лента белән урап алганнар. Ә асларына: «Болар леспромхозның мактаулы кешеләре», дип язылган иде. Әрдәнә рәсеме дә шунда. Пөхтәләп өелгән әрдәнә рәсемдә бигрәк матур булып чыккан. Рәсем астында Хәлим белән Шәйхаттар бабай турында кыска гына хәбәр дә бар; аны бер хатын кычкырып укып тора иде. Тыңлаучылар артканнан-арта бара; ашханәдән чыкканы берс шунда туктый иде.

Менә хатын яңа чыкканнар өчен хәбәрне яңа баштан укый башлады. Ә халык күбрәк җыйналгач, Хәлимнәрнең мактаулы эшләре шикелле үк, үзеннән-үзе митинг кебегрәк нәрсә башланып китте.

— ...Безнең бригада моңа кадәр дә начар эшләми иде,— диде беренче булып сөйләүче кеше.— Ә бабай белән пионер безнең күзне тагы да ача төштеләр. Безнең норма йөз дә биш тирәсендә йөри иде. Иртәгәдән башлап бригада иссменнән йөз унбишкә җиткерергә сүз бирәм.

— Йөз егерме...

— Әнә, минем тавариш йөз егерме, ди... йөз егермегә җиткерергә сүз бирәм...

Башкалар да шундыйрак итеп сөйләделәр. Моңар кадәр эленке-салынкырак эшләп килгәннәрнең кайберләре нормаларын үтәргә сүз бирделәр.

Хәлим, бу хәлнең төшендә түгел икәненә ышангач, Шәйхаттар бабайга пышылдап куйды:

— Рәсемнәрне күрәсеңме, бабай?

— Күрәм, күрәм...

— Ух, бабай!..

Хәлим бу сүзләрне кычкырып әйткәнен үзе дә сизми калды. Ишетеп калган берничә кеше борылып карады. Аларның берсе — беренче көндә Хәлимнәр бригадасында эшләгән Мәннән абзый иде. Ул Хәлимнәр белән кул кысышып күреште һәм Шәйхаттар бабайны эчкә, халык арасына, түгәрәккә өстерәп кертте:

— Шауламагыз әле, әй! Менә Шәйхаттар бабай үзе! Сөйләп җибәр әле үзләренә, картым.

— Сөйлә, бабай, сөйлә!

Шәйхаттар бабай кулын селтәп куйды:

— Сөйли белмим мин, таваришлар,— диде ул.— Йөрәк түзмәгәнгә бер кымшынып карау гына иде. Үзегез беләсез, хәзер тик ята торган чак түгел. Тик ятсаң, хәзер цвай, драй килеп житә. Ә ул тәрене китерергә никак ярамый. Ямап да эшәке жанвар ул,— дип артка чигенә башлады. Мәннән абзый аны тотып алып, югары күтәрде.

Менә биш-алты кеше килеп аны һавага чөеп жибәрде, шунда ук берничә урманчы эләктереп алып, көчле кул чабулар астында тагы да югарырак очыра башладылар.

Шәйхаттар бабай башта үзен нишләткәннәрен аңламый торды. Аңлап алгач, ялына башлады:

— Төшерегез, төшерегез, дим, юньсезләр, сөякне коясыз ич...

Кешеләр, әллә инде чыннан да Шәйхаттар бабайның таралып китүеннән куркып, әллә бик авыр булганга, тотып алып жиргә бастырдылар һәм, Хәлимне эләктереп алып, көлтә урынына чөеп йөртә башладылар. Хәлимнең йөрәге, упкынга сикергәндәге шикелле, кысылып килде. Аяк табаннарыннан алып чәч төпләренә кадәр кытыклана иде аның. Ул «Төшәм, төшерегез!» димәкче булды, ләкин сүзен әйтә алмыйча торды... Менә аның күзләре мактау тактасына төште. Тактада күрше кызларның да рәсемнәре бар иде. Алар нигә аста. Ә алар бит бүген дә Хәлимнәрдән күбрәк эшләделәр, нормаларын 100 гә житкерә яздылар. Әллә алар эше беләп Хәлимнәр эшен бутадылар микән?..

Хәлимгә чыннан да бу шулай булып тоелды. Арадан кемдер чыгып Хәлимнәрнең рәсемнәрен кызлардан аска күчереп куйды. Хәлимне чөючеләр як-якка таралдылар. Хәлим бозланып каралган жиргә егылып төште... Хәлим, шуны күз алдына китереп, чак кына кычкырып жибәрмәде. Ләкин икенче секундта ул чынбарлыкка кайтты:

— Төшерегез! — дип әйтә алды ул көч-хәл белән.

Төшерү кая!.. Кешеләр Хәлимне тагын да югарырак очырдылар.

— Төшермәгез, төшермә!

Хәлим, таныш тавыш ишетеп, аска карады һәм бөтен кешедән кечкенә, ә Шәйхаттар бабай янында бала гына булып басып торган Зәйтүнәне күрде. Ул төшеп килгән Хәлимне тагы да югарырак чөю өчен, аяк очларына

басып, бармакларын тырпайтып, кулларын югары күтәргән иде.

Хәлимне, директор сөйли башлагач кына төшереп, җиргә бастырдылар.

Директор озак сөйләмәде. Ул урманчыларны Хәлимнәрдән үрнәк алырга чакырды һәм аларны акча белән бүләкләве турында белдерде. Хәлим шунда ук бу акчага күпме он, күпме печән алып булачагын исәпләп чыгарды.

— Бер айга җитә, бабай, Шәехтайны бер ай ашатырга җитә!..

— Авызына бал да май, улым.

Хәлим чиксез шатланды.

Былтыр госпитальне немец бомбасыннан саклап калганда һәм әтисен үлемнән алып калганда ничек шатланган булса, нәкъ шулай шатланды. Ләкин шунысы кызганыч — аның бу эшен дә иптәшләре күрми. Менә шунда ичмасам Каюм гына карап торса да, ничек күңелле булыр иде... Кара, ә нигә килмәделәр икән соң алар?..

15 БЕЗ ДӘ ТИК ЯТМЫЙБЫЗ

Хәлим иптәшләреннән хәбәр юкка борчылып йөрде. Эшкә барганда-кайтканда почтага кереп, хат сорашты. Менә хәзер, митингтан кайтып, Мәннән абзый белән шашка уйнарга утыргач, аңа хат китереп бирделәр. Берне түгел, икене! Хәлим почтальон кызның: «Тилмерттем тилмертүен, аның каравы сразы ике!» — диюенә тумбочка артыннан атылып чыкты һәм ишек төбендә җилкәләрендәге карны каккалап торган почтальон кызның сумкасына килеп ябышты.

— Чынлапмы, апа җаным?..

Партнеры никадәр кыстаса да, Хәлим партияне уйнап бетермәде. Ул ишек төбендә үк хатларның әле берсен, әле икенчесен укырга тотынды һәм, нык карар кылып, Җәләй кулы белән язылганына тукталды.

Кат-кат сәламнән соң һәм Хәлимнең кыска язганына кайта-кайта үпкәләгәннән соң, Җәләй хатында болай диелгән иде: «...Хәтерендәме, директор начинкалы конфет ящигы, дигәндә күзлекле кешегә карап ничек елмайган иде? Ай-яй, без ясый торган ящикларга тутырылган конфетлар, белмәсәң бел, Берлинны тетрәтәчәк

икән... Димәк, без дә турыдан-туры сугыш өчен, җиңү өчен эшлибез булып чыга. Әлбәттә, биредә кирәкләр дә ясыйлар. Ләкин ящиклар белән чагыштырганда ул чүп тә түгел. Аларны нибары ике чуваш карты ясый. Син инде, кирәк дигәч, аны монда Мифтах бабай кебек юнып утыралар дип белә торгансың. Шулай булмый ни! Техника, туган! О-о, нинди генә корал юк монда! Менә без шул инструментлар белән ящик өчен такта ышкылыйбыз. Ә сугышка кадәр биредә йорт җиһазлары: өстәл, скамья, шкафлар, буфетлар ясаганнар. Клубларына баргач күрдек.

Үзең генә бел, Хәлим: җиденчене бетергәч, мин бернәрсәгә дә карамыйча, столярныйга китәм. Уфага. Чувашлар, кулларың алтын синең, без сине менә дигән столяр итәбез, Уфаның үзендә дә күргәннәре булмаган җиһазлар ясый башларсың, диләр. Әллә юри әйтәләр инде... Ничек кенә булмасын, мин бу эшне яраттым. Мине хәзер әллә ни белән дә бүтән эшкә кызыктыра алмыйсың. Ә менә Мотыйк яратмый, тиле. Читлеккә ябылган аю баласы кебек йөри. Күзләре гел «Никкүчтем» ягында. Монда әйткән монда калсын — бер тапкыр кача да башлаган иде, без тотып калдык. Авызында гел ике сүз: авыл да әни. «Сезнеңчә, «Никкүчтем» кайсы якта? Безнең «Никкүчтем» ничә метрлы баскычка менеп карасаң күренер икән?..» Хәзер инде китәсе көнне сәгатьләп саный, колагы гел радиода. «Бәлки, каникулны фәләнчә көнгә кыскара дип хәбәр итеп куярлар?..» Шуңар күрә эшенең бер дә рәте юк. Ирек белән мин ышкылаган такталар беләү шикелле, шоп-шома. Ә аныкын кулына тотсаң, учыңа шырпы кертми калмыйсың. Кичә үзен больницага алып барырга туры килде. Кадак урынына бармагына суккан... Ә, әйе, больницада безнең Нәҗипне караган сестраларны күрдек. Хәбәрсез югалганын ишеткәч, бик кайгырдылар. Аның сугышка китәргә ничек омтылып ятканын сөйләделәр. Бер тапкыр, мескен, сестраларча киенеп качмакчы булган. Ак халат кигән, башына кызыл тәреле ак яулык бәйләгән, хәтта түшенә күкрәк ясаган. И, нәкъ поезд килгән вакытны туры китереп, больницадан чыгып шылган. Әче җил-буран, кешенең өстендә тун, ә моның... Сразы игътибар иткәннәр, әлбәттә... Шулай йөргәндә, өзлегеп, янә бер ай авырып яткан. Ә терелеп чыккач, поездга утырып киткән. Кая? Беркемгә бер сүз әйтмәгән. Кызганыч,

туган. Төшеп кенә югалды бит. Әйбәт малай иде. Их, сугыш, сугыш!..

Без биредә бик күп кызыклар күрдек, әллә нәрсәләр ишетеп бетердек. Сезнең станциядә ничек итеп куян сатып йөргәннәрегезне дә сөйләделәр, тишек авызлар. Хе, хе, хе... Фәррах абзый инде... Мастерскойга килгән иде, кроликлары өчен оя ясатырга. Я тагын «Никкүчтем» аучылары килеп чыгар, дигән була...

Без бик күңелле итеп торабыз. Көн саен кино яки концерт булып тора. Китапханәдә китап бик күп. Тик укырга вакыт калмый. Эш, эш... Патроннарны, снарядларны фронтка итәккә салып алып бармаслар бит... Шуның өстенә әле буш вакытларыбызда Рига, Каунас шәһәрләреннән эвакуацияләнеп килгән кешеләргә ярдәм итәбез. Тырмалар, көрәкләр, китмәннәр ясап бирдек. Кичә, якын-тирә авылларга барып, алар өчен чәчүлек бәрәңге җыеп алып кайттык.

Бик кызгандык без аларны. Күбесе бирегә килешли бала-чагаларын, ата-аналарын югалтып бетергәннәр. Кайберләре өйләреннән чыгып киткәндә өсләренә бер кат кием, ашарларына бер сыпык ипи дә алырга өлгермәгәннәр. Ләкин алар еламыйлар. «Болар барысы да кешелек дөньясын Гитлердан бөтенләйгә коткару хакына», диләр алар; менә нәрсә диләр. Кайткач безгә бу турыда отрядта сөйләргә кирәк булыр. Шикәрсез чәй, итсез аш, сабантуйсыз язны өнәп бетермәүчеләргә бераз гыйбрәт булып куймасмы дим. Ник, шулай ич.

Я, ярый, барысын да язып бетереп булмас, калганын кайткач. Без уникесендә кич белән совхозга азык алырга бара торган машинага утырып кайтабыз.

Хуш, Хәлим. Шәйхаттар бабайга сәлам әйт.

Җәләй, 6 январь, 1943 ел».

Хәлим Җәләйнең хатын, әлбәттә, бер тапкыр гына укымады. Ул аны Шәйхаттар бабайга да укып күрсәтте. Ләкин соңыннан. Хәзер исә аны Фәрдәнә кул куйган хат көтә иде.

«...Малайлар сезнең янга бара алмады инде, Хәлим, үпкәләмә, яме,— диелгән иде бу хатта.— Чөнки кызларга уйламаган-көтмәгән эш килеп чыкты. Фронтовикларга тире бияләйләр тегәбез. Тирене безгә «Дуслык» артеленнән китереп бирәләр. Артельдән килгән бер апа белән

Рәхимә җиңги кисеп тора, без тегәбез. 300 пар тектек инде. Кайтып житсәң, үзең дә күрерсең әле, бик күңелле итеп эшлибез. Гармонь уйнап тора. Әүхәди абзый кайтты бит. Контужен булган. Шул уйный гармоньны. Укыгандагы шикелле кырык биш минут эшлибез дә ун минут ял итәбез.

Ярый, хуш, Хәлим. Бездә бүтән яңалыклар юк. Ә, әйе, шул бар икән: Ибрай ялгыз каз кебек урамда бер үзе каңгырып йөрде-йөрде дә, безнең белән бияләй тегәргә утырды. Ай-һай, ахырга кадәр түзәр микән. Бер дә булсынга йөргән кебек түгел. Әйдә ярар, шулай йөри-йөри арага кереп китмәсме әле. Тик берәр хәл генә китереп чыгара күрмәсен инде...

Берәр көн булса да алдан кайт, Хәлим. Каникулны күрми каласың ич.

Фәрдәнә, 6 январь, 1943 ел».

Читтә йөреп юлың уңса, шулай була: хәзер Хәлим күз алдына авыл тагын да матуррак булып килеп басты. Иптәшләре, укытучылары хәзер аңа бертуган булып күренделәр. Хәтта Черки Ибрайны да хәзер Хәлим ничектер, якын күрде. Ул аны Черки итеп түгел, Ибраһим итеп күз алдына китерде.

«Хәзер шуннан Ибраһим килеп керсә, мин аңар үзебезнең эшләгән җирләрне күрсәтеп йөрер идем. Ашханә алдындагы мактау тактасын күрсәтер идем. Аннары икәү бергә шушы урынга ятып йоклар идек...»

Хәлимнең авылга кайтасы килә башлады. Шулай кайтып керербез, болай кайтып керербез, дип хыялланды ул... Менә ул хыялында бабасы белән үрәчәле кечкенә чананы тартып кайтып та җитте. Авылга кергәч, шәбрәк атлау өчен, алар күпер төбендә туктап ял итеп алдылар. Мәктәп яныннан узып барганда, Хәлимнәрне фронтовикларга бияләйләр тегеп утыручы балалар күреп йөгереп чыгып, чананы актара башладылар. Ә чанада он, солы, ипи... Хәлим иптәшләрен ырып-ерып Шәехтай янына йөгерде... Ята-ята Хәлимнең хыяллануы төшкә әйләнә башлады. Ләкин аңар йокларга ярамый иде әле. Ул сискәнеп күзләрен ачты да Шәйхаттар бабайның ай яктысы төшкән якты йөзенә карап алды. Ай яктысы шундый якты иде, бабайның битендәге һәрбер җыерчык аермачык күренеп тора иде. Тигез генә

сулап, картларча тыныч гырылдап ята иде Шәйхаттар бабай. Хәлим тиз генә сәке астыннан үзенең капчыгын тартып чыгарды. Аяк очларына гына басып, тәрәзә төбенә килде дә кесәсеннән нәрсәләрдер алып капчыгына салды һәм аны учларында үлчәп торды. Аннан шикләнеп, капчыгын каушый-каушый чишә башлады.

Шәйхаттар бабай Хәлимнең кичә дә, кешеләр йоклап беткәч, капчыгына нәрсәдер салганын күреп калган иде. Бүген дә салмас микән дип, нәрсә икәнен күрә алмам микән дип, юри йоклаган булып ята иде. Хәлимнең тәрәзә төбенә килеп тезләнүенә ул башын күтәреп карады. Карады, һәм капчыкка ящерелгән әйберләрнең көн дә өч тапкыр ашханәдә бирелә торган ипи телемнәре икәнен күрде.

— Эһем, эһем...

Хәлим моны ишетсә дә, шикләнмәде, төшендәдер, дип эшен тыныч кына дәвам итте. Ул ипи кисәкләрен тәрәзә төбенә салып санап чыкты. Кимемәгәнлекләренә ышангач, рәхәт елмаеп куйды да яңадан капчыгына тутырды. Аннары капчык авызын әлләниләр кыландырып бәйләде һәм, сәке тиңентен түбән иелеп, сәке янына килде. Шәйхаттар бабай баягыча ук тыныч ята иде. Хәлим ялт иелеп, капчыгын ящерер өчен, сәке астына кереп китте. Ә чыкканда (каушап йөрсәң шулай була ул) терсәге пычкыга тиеп китте. Пычкы тын баракта озак чыңлап торды. Хәлим җыерылып килде. Пычкы тавышын басарга теләп тамагын кырып куйды. Сәке астыннан уктай тиз, күләгәдәй тын чыгып, урынына үрмәләде. Хәлимнең сул ягындагы күршесе шомланып башын күтәрде:

— Кем анда?

— Мин идем лә,— диде Хәлим.— Мин, Җамалый абзый. Ай-яй, суык тышта. Йолдызлар бик күп чыккан. Шәйхаттар бабай әйткән крещение суыклары җитә, күрәсең...

Шәйхаттар бабай күзләрен ярым ачкан хәлдә елмаеп куйды. Ул инде, әләктең бит, малай, дип пышылдарга да булган иде, эндәшми калды. Аның өчен мәсьәләнең бер ягы болай да ачык: Хәлим ипине, һичшиксез, Шәехтай өчен әзерли, ләкин икенче ягы төн төсле караңгы: кайдан ала ул аларны? Әллә урлыймы?

Шәйхаттар бабай икенче көнне ашханәгә баргач, ипинең серен белергә теләп, күзләренә төшеп торган аклы-сарылы кашлары астыннан гел Хәлимгә карап

утырды. Менә Хәлимнәргә, алар өстәлендәге тагы ике кешегә, тәлинкә белән дүрт кисәк ипи китерделәр. Хәлим ипинең үзенә ошаганрак кисәген алдына алып куйды. Аңар горчица сөртте, тоз сипте, бармак башы кадәр генәсен сындырып капты да мактап куйды:

— Бүген ипи бигрәк тәмле икән. Кичә бераз әчерәк иде,— дигән булды. Ул, ике йөз илле граммның яртысын берьюлы капкан кебек, авызында телен әйләндерерлек тә урын калмаган кебек кыланды. Күршеләр дә ипиләрен тәлинкәдән алып алларына куйдылар һәм сындырып кабып карадылар. Ул арада официант, тирән тәлинкәләр белән куе кайнар токмач китереп, өстәл читенә куйды. Итле, борычлы кайнар токмач исе борыннарны кытыклап, авызлардан сулар китерде. Кешеләр зур аппетит белән тәлинкәләргә үрелделәр. Хәлим дә бер тәлинкәгә сузылды. Ике куллап алды ул мөлдерәп тулган тәлинкәне һәм әкрен генә үз алдына китереп куйды. Шәйхаттар бабай, Хәлим тәлинкәне ипие өстенә куйды дип белде — аның ипие нәкъ шунда ята иде. Ләкин, бабай ни күзе белән күрсен, тәлинкә, башкаларныкы шикелле үк, тигез ак эскәтер өстендә утырып калды; тәлинкә астында бернинди дә ипи юк иде. Ә Хәлим булары бөркелеп торган тәлинкәсенә якын иелеп тәмле токмачны шопыра башлады.

«Ипиен кая куйды соң бу шайтан баласы?..»

Шәйхаттар бабай Хәлимнең ипиен ничек яшергәнен бары кичке аш вакытында гына сизеп алды. Менә Хәлим, нәкъ иртә белән гә шикелле итеп, тәлинкәгә үрелде. Һәм... ашны алдына китереп җиткергәч, чәнчә бармагы белән тәлинкә астындагы ипине алдына шудырып төшерде. Шәйхаттар бабай таң калды, һәм өстәл астыннан, ишкәк шикелле озын кулы белән үрелеп, Хәлимнең ипине кесәсенә шудырырга торган кулын тотып алды:

— Стоп, машина!..

— Нәрсә-ә?..

— Белмим нәрсәдер... кулыңда нәрсә соң?

— Бернәрсә дә юк.

Шәйхаттар бабай Хәлимнең ипиле кулын өстәл астыннан тартып чыгарды.

— Әйтәм ябыга... Һе! Кара син аны, ә... Аша хәзер үк!..

— Мин кич ятканда ашыйм аны, бабай.

— Ашыйсың... Күрдем мин синең кич яткандa ничек ашаганыңны...

Хәлим үзен акларга сүзләр эзләп маташты.

— Мин аш белән дә туям бит, Шәйхаттар бабай...— диде ул.

— Ялганлыйсың!.. Әниең сине миңа тапшырганда, кул гына куйдырмады. Кара аны, мин сине нишләтергә белермен!..

Шәйхаттар бабайның теле шулай диде, ә йөрәгендә бөтенләй башка төрле уйлар иде. Бу минутта аның Хәлимне алдына алып сөясе килде. Кулларын мөмкин кадәр йомшак йөртеп, чәчләреннән сыйпыйсы килде. Ләкин болай эшләсәң, Хәлим тагын да шуны ук кабатлар дип курыкты. Шәйхаттар бабай андый нечкә хисләрдән бары шуңа күрә генә тыелып калды.

16 ӘЙДӘ СОҢ...

Менә китәр көннәр дә килеп җитте.

Иртәгә китәсе дигән көнне Хәлимнәр иртүк базарга чыгып, эш хакларының һәм бүләк акчаларының бер өлешенә икесе тартып кайтырлык солы белән он сатып алдылар да, үрәчәле чанага салып, печән белән төреп бәйләп сәке астына кертеп куйдылар. Төшке аштан соң, соңгы тапкыр эшкә барырга торганда, аларны директор чакыртып алды.

— Бәй, нишләп шул гомер тик ятыйк без, иптәш директор? Үзең әйтмешли, ун пулин булса да...

Шәйхаттар бабай моны директорның: инде эшкә барып йөрмәссез, юлга чыгар алдыннан ял итәрсез, дигәненә җавап итеп әйтте. Директор Шәйхаттар бабайны, иңнәреннән тотып, йомшак диванга утыртты:

— Җитте, бабай. Бик рәхмәт. Ун түгел, мең булды. Барыннан да бигрәк, сезнең эш үрнәге эшләп чыгаруны күтәрүгә өндәү булды. Бик рәхмәт сезгә,— диде директор һәм, аларны үзенең өенә алып кайтып, хәзинәдә бары белән кунак итте, аннары, кичке ашка кадәр ятып торырга урын күрсәтеп, эшенә китте.

Бүлмә җылы иде, урын йомшак. Шәйхаттар бабай белән Хәлим берничә минут тыныч кына яттылар. Алган оннарын, солыларын һәм калган акчаларына алачак фуражны сабанга төшкәнче җитәрлек итеп күңелдән

бүлеп чыктылар. Әзрәк шикелле күренгәч, ике генә айга җитәрлек итеп бүлделәр.

— Ярый, кыш чыкканчы тагын бер килербез әле,— диде Шәйхаттар бабай.— Юк, син килмәссең, син укырсың, атны карарсың, ә мин килермен. Фәсхи кордашны алып киләм мин. Дөрес, ул миңа тормый, шулай да уң пулин булса да дигәндәй...

Берәр кеше читтән карап торса, аларны бик рәхәтләнеп ял итәләр дип уйлар иде. Ләкин тик ятарга өйрәнгән кешегә эшли башлавы никадәр читен булса, эшләп өйрәнгән кешегә тик яту шулкадәр үк кыен икән. Алар ята-ята алҗып беттеләр. Әле бер як белән яттылар алар, әле икенче якка әйләнделәр. Ә сәгать эчпошыргыч әкрен йөрде, вакыт бик әкрен үтте.

— Озын теленең караңгы төшкәнче генә дә өч тапкыр әйләнеп чыгасы бар икән әле, бабай.

— Бер, ике... кара, шулай икән шул... Әллә бер чыгып йөреп керәбезме? Бариннарча гына, кесәгә кулны тыгып, кеше эшләгәнне карап, ә?

— Әйдә соң.

Һәм алар, кесәләренә кулларын тыгып, кеше эшләгәнне карап йөрергә дип чыгып киттеләр.

Көн җылы иде. Тәңкә карлар ява иде урманда. Башлап алар күрше кызлар янына киттеләр. Килеп җитәрәк Хәлим кызларның утын әрдәнәләре өстендә кечкенә кызыл флаг күрде.

— Флаг, бабай,— дип пышылдады Хәлим.— Стахановчылар флагы.

— Ә-ә...

Шәйхаттар бабай аларга, башка вакыттагыча, еракта эндәшеп килергә дә каршыларына утырып берне төреп тартырга уйлады. Ләкин кызлар шулкадәр бирелеп эшли иделәр, эшләреннән бүләргә уңайсызланды. Юан нарат артында туктап, пычкыларының тигез, җиңел йөрүенә сокланып карап торды да пышылдап куйды:

— Кирәкмәс, улым, мишәйтләп йөрмик без аларга...

Шәйхаттар бабай белән Хәлим, кызларга күренмәс өчен, агачларга ышыклана-ышыклана кире киттеләр. Менә аларны су сибеп катырылган юлдан ат чанасы белән станциягә утын тартып килүчеләр куып җитте.

Хәлимнәр, читкә тайпылып, аларга юл бирделәр. Шәйхаттар бабай, бер төп башына утырып, янчыгын

чыгарды. «Хәзер үзләре белән гәпләшеп берне тартып алыйм әле»,— дип уйлады ул. Ләкин тегеләр туктап тормадылар. Шәйхаттар бабайны ихтирам белән сәламләделәр дә кызу-кызу узып киттеләр.

Шәйхаттар бабай аларга: «Яп итегез, якташлар, берәрне көйрәтеп алыйк»,— димәкче булды, ләкин кычкырта-кычкырта станциягә кереп килгән паровоз тавышын ишетеп, эндәшми калды.

Хәлимнәр, йөри торгач, эшелонга утын төяп торган кешеләр янына килеп чыктылар. Болары да, исәнлек-саулык сорашып алдылар да, эшләрен дәвам иттеләр. Аларның кулларында метрлы юан агачлар, уракчылар кулындагы көлтәләр шикелле, җиңел йөрде. Шәйхаттар бабай алар белән саубуллашты да Хәлимне бер читкә әйдәп алып китте:

— Әйдә, кайтып ятыйк без, улым, болай булмады әле бу...

— Булмады шул... Син шунда торып тор, бабай, мин хәзер киләм,— диде Хәлим. Үзе тиз генә директор өенә кереп, пычкы белән балта, кечкенә чана сорап алып чыкты.

— Лутчи бераз эшләп алыйк без, бабай.

— Ә?.. Бик дөрес, улым. Тик торганчы тиген эш дигәндәй...

Алар шактый юан бер коры имән сайлап алып ектылар да турап ярдылар.

— Ә хәзер болай итик без, бабай. Үз кулыбыз белән паровозга ягып җибәрик. Поездны үзебез тартып барган шикелле булсын. Ләкин фронтка бара торган паровозга, корал төялгәнгә ягыйк...

— Алай итсәк тә була, улым.

Алар утыннарын чанага төяп, кичке товар поезды килеп туктаячак урынга ташып куйдылар.

Караңгы төшеп бетүгә станциянең аргы башында кызыл семафор сүнеп, язгы чирәм төсле яшеле балкыды: — «Рәхим ит, корыч юртак!..» Ул да түгел, Хәлимнәр көтә торган паровозның көчле уты күренде. Ул, бик юан, бик озын көлтә булып, уйнаклап яуган яфрак карны яктыртып, тимер юл буенча сузылды. Ул көлтәсе шомарган рельсларны, стрелкаларны, аркылы шпалларны яктыртты. Озакламыйча, җир тетрәтеп, мәһабәт кычкыртып, корыч юртак үзе дә станциягә килеп керде.

Эшчеләр, эшелон туктап җитүгә, тендерга утын төяргә керештеләр.

Шәйхаттар бабай машинистка үзләренең кем булуларын һәм уйларын әйтте:

— ...Егетнең паровоз мичен дә бик күрәсе килеп йөри иде.

— Алай... Кисүен дә үзегез кистегезме?

— Үзебез.

— Әнә сез нәрсә уйлап чыгарган... Аңлыйм, аңлыйм. Бик рәхмәт. Рәхим итегез. Әй, Микита, булыш әле үзләренә!

— Юк, без үзебез.— Хәлим шинелен салып рельска ташлады һәм утыннарны ун минуттан кузгалачак паровоз миченә менгереп сала башлады. Корыч мич агарганчы кызган иде, коры имән агачларының кергәнен берен шунда ук көчле ялкын чолгап ала барды.

Хәлимнәр агачларның мичкә очмаганнарын паровозның тендерына менгереп, бер читкә әрдәнәләп өеп куйдылар.

Хәлим, бу хәлгә сокланып һәм горурланып карап торган машинист белән кочегарга бик мөһим, бик җитди итеп:

— Фронтка барып җитмичә тимәгез сез боларына,— диде.

— Нигә, егет?

— Фронтка җитәрәк кенә ягарсыз. Паровоз фронтка безнең утын белән барып керсен... Паровозны фронтка без этеп керткән төсле булсын,— диде Хәлим һәм утыннарны сыйпап куйды.

Паровоз Юдинодан соң кире борылачак, аннан эшелонны бүтән паровоз тагып китәчәк иде. Ләкин машинистның бу турыда әйтеп Хәлимнең кәефен җибәрәсе килмәде.

— Ах, әнә син ничек...— диде ул,— аңлыйм, аңлыйм. Ярый, шулай эшләрбез, туган.

Шәйхаттар бабай да шул турыда кайгырткан булды.

— Шулай эшлә. Кызганмыйча як. Күп итеп як,— диде ул һәм, Хәлимгә ишарәләп, машинистка күз кысып куйды.— Паровоз фронтка выж итеп барып керсен әле бер, ялкынын күрүгә, бетле җанвар — немец куркып качарлык булсын әле...

Артта, вокзалда ике тапкыр кыңгырау кактылар. Эшелон койрыгында свисток чырылдады.

Шәйхаттар бабай кадәр үк озын гәүдәле, аның яшь чагындагы кебек таза гәүдәле машинист Хәлимне, аннары Шәйхаттар бабайны паровоздан күтәреп төшерде.

— Рәхмәт. Хушыгыз, туганнар! Хуш, егет! Әлбәттә, син әйткәнчә эшләрбез,— диде ул һәм паровозның свисток рычагын тартты. Паровоз, һава ярып, калын тавыш белән кычкыртып куйды. Сугыш вакытында һәрнәрсә ашыга. Паровоз да, кычкыртып бетергәнче үк, вагоннарын бер-бер артлы шалдыр-шолдыр тартып алды һәм тиз-тиз китеп тә барды. Менә вагоннар да Хәлимнәр яныннан уза башладылар. Берсеннән-берсе кызурак узды вагоннар. Соңгы берничәсе шулкадәр кызу узды, алар артыннан инде күз иярми иде. Хәлим аларны санап чыгарга чак өлгерде.

— Алтмыш,— диде ул актык вагон узып киткәч,— алтмышны таккан, бабай.

— Алтмы-ыш...

— Әйе. Ул алтмышның барысын да безнең утын тартып бара бит әле, бабай, ә?

— Безнең утын шул, улым.

Эшелон станциядән чыгып бетте. Бик тиз ерагайды эшелон. Ерагайган саен, нindидер куәт белән кысылган шикелле, кечерәя барды. Ул хәзер алтмыш вагон, вагон саен әллә ничә мең снаряд төягән эшелон булып түгел, тоташ озын кара бер әрҗә шикелле генә күренә. Борылып-сырылып барды-барды да, урман эчендә күздән югалды. Ә Хәлимнәр яккан утыннан чыккан кызыл очкынлы ак төтеннәр озак, бик озак, кичке урман өстен әкияттәгечә матур яктыртып бардылар. Очкыннар нарат өсләренә эреле-ваклы йолдызлар шикелле сибелеп калдылар.

— Бигрәк күңелле булды, бабай!

— Шулай булды.

— Безнең имәннәрне чыннан да фронтка кергәндә генә ягарлар микән, бабай?

Шәйхаттар бабай, дөресен әйтеп, Хәлимне күңелсезләндерәсе килмәде. Ул бер дә шик калдырмый торган итеп:

— Нәкъ шулай итәрләр,— дип куйды.

Паровоз тагы бер кычкыртты. Гүя, ул Шәйхаттар бабайның Хәлимгә биргән җавабын раслады.

17

«ХӘЗЕР КҮҢЕЛЕМ БОЕК ЧАГЫ...»

— Әттәгенәм лә... менә кайда икән алар!.. Әйдә, кер, улым Хәлим!..

Хәлим ишек тоткасын тотуга, аның битенә җылы һава килеп бәрелде, тышка бик әкрен булып ишетелгән җыр, кинәт тегермән буасын җимереп чыккан ташкын шикелле, көчле яңгырап китте.

...Хәзер күңелем боек чагы...

Хәлим Шәйхаттар бабай артыннан бусаганы атлады. Өйалдындагы караңгыдан соң көчле электр яктысы аның күзләрен чагылдырып җибәрде. Хәлим бер карауда бөтен өй эчен күреп алды. Әллә ни җиһазлы булмаса да, ямьле иде өй эче. Пөхтә итеп җыелган кроватьларда авылда кич утыргандагыча спай киенгән урманчы кызлар бәйләү бәйләп, чигү чигеп утыралар. Өй уртасындагы озын өстәлнең бирге башында бердәнбер ир кеше — Мәннән абзый — бер генә бармагы белән басып гармонь уйный. Уйнавының рәте юк. Шулай да кызлар аның көенә генә, аның артыннан гына барып, кая алып кереп китсә дә зарланмыйча, шул ук вакытта, барып җитсен дигән шикелле көчле итеп җырлыйлар:

...Хәзер күңелем боек чагы,
Син кайткач чәчәк атар...

Шуңа күрә кызлар Шәйхаттар бабай белән Хәлим килеп кергәнне сизмәделәр. Шәйхаттар бабай, карлы итекләрен бер-берсенә бәргәләп, шаяртып куйды:

— Һәй, һәй, һәй... безнең ишене иш итмәскә ахры әле боларның исәпләре!..

Ишеккә якынрак утырган кызлар, җырларын бүлеп, башларын күтәрделәр. Берсе, үзенең нечкә тавышы белән җырны басып, кычкырып җибәрде:

— Әчәч, кызлар! Кунаклар бар икәнич!..

Җыр, киселгән шикелле, кинәт тукталды. Көтмәгәндә кунаклар килеп керүгә барысы да каушый калдылар. Аннары, сикереп торып, ыгы-зыгы килергә, бөрешкән кроватъ япмаларын, өс-башларын тәртипкә китерергә керештеләр.

— Әйдәгез, әйдә, Шәйхаттар бабай,— диде Зәйтүнә һәм ап-ак йон оегы белән токмач кунасы шикелле чиста

юылган идәнгә чеметеп-чеметеп кенә басып килеп, Шәйхаттар бабайны чишендерә башлады.

— Ә, юк,— диде Шәйхаттар бабай.— Чишенә-нитә тормыйбыз. Егет аптыратканга гына... Апайлар белән саубуллашып чыгыйк инде, ди. Әйдә, алайса, мәйтәм, «электр яктысында чигү чиккәннәрен» дә күреп китәрбез, дим.

— Бик әйбәт иткәнсез, күренмичә китсәгез, үпкәлисе идек әле. Әйдә, утыр, бабай.

— Кил, егет.

— Ярый... биредә дә...

— Ай, егетең бер дә үзеңә ошамаган, бабай.

— Шундыйрак шул... Кил, улым Хәлим... Уһу-у... мин беркөн сезне шаяртасыз дип торам, чынлап чигәсез икән ич... Әллә янчыклар да маташтырасыз инде...

— Барысын да эшлибез, бабай,— диде Зәйтүнә.— Менә, күршең Мәйсәрә генә сүзендә тормады...

— Әбәү, бик тиз китәләр ич, сизми дә калдым.

— Әй, күңелендә булмаган инде... Менә бүген кич белән үзем...

— Ә юк, азапланма, Зәйтүнә кызым, минем бар,— диде Шәйхаттар бабай һәм чалбар кесәсеннән янчык чыгарды. Сакланып кына чиште ул аны һәм тәмәке төрә башлады.

Бу янчыкның нинди материядән икәнен әйтүе кыен. Бөтенләй тузып беткән, берничә җире киндер җеп белән типчелгән, хәзер тагын ике-өч җиреннән самосад тәмәке бөртекләре карап тора иде. Авыз турысында ике хөрмә төше, бер көмеш тәңкә булып, алар да гомер узу белән шомарып беткәннәр иде.

— Тузыбрак киткән икән, бабай...— диде берсе шаяртып.

— Тузар да...— Шәйхаттар бабай янчыгын бәйләде дә кадерләп кенә чалбар кесәсенә тирән төшереп салып куйды.— Илле еллап була бугай инде аңар. Хупҗамал җиңгәгез, ярәшәсе елны, су буена төшкәч биргән иде. Менә шулай итеп, уң кулы белән кәшимер яулык читеннән чыгарып (Шәйхаттар бабай бу урында, яулык читеннән оялчан көлемсерәп карап торган кызлар шикелле, кыйланып куйды), мә, җанашым, дигән булып...

Кызлар көлеп җибәрделәр. Шәйхаттар бабай, тәмәкесен теле белән ябыштыра-ябыштыра, зур авызлы мичкә таба китте.

— Син, Зәйтүнә кызым, яңа янчык белән минем күңелне аздырып маташма, Хупҗамал җиңгән каберендә тыныч кына ятсын...

Кызлар тагы көлделәр.

Шәйхаттар бабай өстәп куйды:

— Аннары, мин бүген бар, иртәгә юк, дигәндәй... Син аны, янчыкны, кесәсендә озак еллар йөртерлеккә бирергә кара.

— Бәй, аның андыймы, түгелме икәнен кайдан беләсең, бабай?

— Белегез... Хупҗамал җиңгәгез белгән ич.

Туктап калган көлү тагы да көчәеп китте. Кызлар көлешә-көлешә урыннарына барып утырдылар да чигүләрен дәвам иттеләр. Шәйхаттар бабай, тәмәке кабызу өчен мичтән алган күмергә өрүеннән туктап, күзләре белән Мәйсәрәне эзләде:

— Кара әле, Мәйсәрә, син җырлый-җырлый чигәбез дигән идең түгелме соң?

— Тфү! Иблис төкергәндер, бабай, синең теленә.

— Шундый ул...

Мәйсәрә нидер сөйләнеп калды. Зәйтүнә җыр башлап җибәрде. Кызлар бертавыштан күтәреп алдылар:

Минем дустым армиядә...

— Уйна инде, Мәннән абзый!

— Хәзер, хәзер...

Мәннән абзый, ләүкәдән әле генә чабынып төшкән кешенеке шикелле пешеп чыккан йөзеннән борчак-борчак тирләрен сөртеп алды да куркып кына Хәлимгә ишарәләде:

— Мә әле, туган... Белсәң дә, белмәсәң дә шыгырдаткала шунда... Адрес яздырырга гына дип кергән идем. Тоттылар да куштылар... Биш былтыр инде. Кырык имән екканнан болайрак булды...

Мәннән абзый гармоньны көй әйтергә белми аптырап калган Хәлим куенына төртте — үзе, идән такталарын шыгырдатмас өчен сакланып кына чигенә-чигенә, ишеккә килде. Котылганына тәмам ышанып җиткәч, Хәлимгә күз кысты да ятьмәдән ычкынган балык шикелле, ялт борылып, ишектән чыгып шылды. Күреп калган берничә кыз, кроватьларыннан сикерешеп төшеп, чыр-чу килеп, аның артыннан йөгерделәр. Шунда ук кире борылып керделәр.

— Качты...

— Эх!..

— Аучыдан качкан аю шикелле, сикерә-сикерә чаба.

— Ха-ха-ха!

Зәйтүнә, кулларын биленә куеп, Хәлим каршына килеп басты:

— Әйдә, егет, сиңа калды...

— Белмим бит мин, Зәйтүнә апа.

— Белмәсәң дә уйна!

Хәлим, Мәннән абзый урынына утырып, аның шикелле бер генә бармак белән шыгырдата башлады. Аннары, онытылып китеп, гармоньга бөтен йөрәген кушып, сузып җибәрде:

Тәрәзә төбем исле гөл...

Кызлар ах иттеләр:

— Менә сиңа «белмим»...

— Аб-бау, җаным!..

— Тфү, тфү, күз тимәсен!..

Кызлар Хәлимне сырып алдылар. Зәйтүнә белән Мәйсәрә аны, җилтерәтеп, түргә алып килделәр. Хәлим, тартынып кына озын скамьяның урта бер җиренә, өстәлгә арты белән утырды да көйне баштан башлады:

Тәрәзә төбем исле гөл,
Иснә, дустым, исле ул.
Уртасында бер чәчәк бар,
Өземм, синең төсле ул.

Шәйхаттар бабай җыр арасында башын чайкап куйды:

— Һа-а... син, апайларыңа дигәч, өздерәсең генә икән.

— Ах, мондый икәнеңне элегрәк белгән булсак!..

Тәрәзә төбем исле гөл,
Мин яратам кынаны,
Кына гөлне, матур гөлне
Сиңа ошатам мин аны...

— Уйна, егет, уйна!

Хәлим уйнады. Кызлар чигә-чигә, бәйли-бәйли җырладылар.

Менә Зәйтүнә чигүен бетерде дә кәгазь-каләм алып, Хәлим янына, өстәлгә алды белән утырды. Ахры күңелендә бар да язылган булган, бер дә тераләп тормыйча,

ә алдагы сүз турында уйлаганда җырга кушылып, йөрәгендәге кәгазьгә сала башлады:

«Сөекле кызылармеец!..»

Хәлим, Зәйтүнәнең каләме яңа сүз кыштырдаткан саен, күз кырыен кәгазьгә төшереп-төшереп ала иде.

Зәйтүнә язды:

«...Кем син? Белмим. Бәлкем берничә бала атасыдырсың... Минем бу хатым сиңа шул балаларыңны сагынып, уйланып утырганда килер. Ә, бәлкем, минем шикелле бер ятимсең...— Хатым сиңа минем шикелле ялгызлыктан боегып утырганда килеп төшәр. Ничек булсаң да, мин сиңа син дип эндәшәм. Сине Совет Армиясенең 25 еллыгы белән котлыйм һәм дошманны җиңеп, исән-сау кайтуыңны ихлас күңелемнән теләп калам...

Мин үзем бер татар кызы. Исемем — Зәйтүнә. Яшем — уңжидедә. Урманда утын кисәм һәм яралы фронтовиклар өчен кан бирәм. 5 литр кан бирдем инде. Кем белә, бәлкем шуларның берсе сине дә үлемнән алып калгандыр...»

Бу вакытта Хәлим хатка таба шулкадәр сузылган иде, Зәйтүнә аның сулышын сизеп, сискәнеп, борылып карады һәм хатын күкрәгенә кысты:

— Ай, укыма! — диде Зәйтүнә, шаян елмаеп.

Хәлим уңайсызланып башын читкә борды һәм хат белән мавыгу аркасында сүнә башлаган гармонен тергезеп җибәрде:

Минем дустым армиядә,
Хатлар язган өзелеп...

Кызлар җырлап бетермәделәр, сырган пиджагын иңбашларына салган бер кыз кереп килгәнне күреп, барысы да урыннарыннан кузгалдылар.

— Булдымы, Мәймүнә?

— Көчкә!

Мәймүнә дигәннәре култык астыннан, шома гына юка тактадан эшләнгән ящик чыгарып, өстәлгә куйды. Хәлим ящик капкачындагы «Калинин фронты солдатларына» дигән сүзләрне укыды һәм кызлар кулындагы мамык перчаткаларның, хәтфә янчык, асыл яулыкларның, Зәйтүнә яза торган хатның серенә төшенде.

Кызлар ящикны сарып алдылар:

— Әй, әйбәт булган, кызлар!

— Бик матур булган!..

— Бик матур. Җиңел кулдан үзем башлыйм әле,— диде ящикны ясатып кайткан Мәймүнә һәм үзенең мендәре астыннан бер пар оекбаш, кулъяулык, бер шешә одеколон алып килеп ак кәгазьгә төрде дә тар кызыл тасма белән җыйнак кына итеп бантлап бәйләде һәм ящик төбенә салып куйды:

— Иң бәхетлесенә!

Кызлар бар да бер-бер артлы үзләренең әле генә хәзерләп бетергән бүләкләрен ак кәгазьгә төреп, шулай ук тасмалар белән бәйләп, ящикка сала бардылар:

— Иң бәхетлесенә!

— Ай, кемгә генә туры килер икән!..

Салганы бере, бүләкләрен алачак кызылармеецларны кырыкмаса-кырык кыяфәттә күз алларына китереп, ящикка карап тордылар. Шәйхаттар бабай да карады ящикка. Бу вакытта ул, карт солдат буларак, бүләкләр окопка барып кергәч кызылармеецларда туачак тиңсез шатлыкны күз алдына китерде һәм әйтеп куйды:

— Рәхмәт, кызлар. Нәрсә әйтергә, бик әйбәт нәрсә уйлап чыгаргансыз.

— Әйбәтме, бабай?

— Һәй, юл-лар...— диде Шәйхаттар бабай һәм бераз уйлап торды да кинәт карар кылып, ни бар тәмәкесен бер кызның янчыгына бушата башлады.

-- Мә, бергә барсын әле шунда...

Кыз янчыгын тартып алды:

— Ай, кирәк түгел, бабай...

— Син алай димә, кызым. Анда бер төреп тарту өчен дөньяларыңны бирергә җиткән чаклар була...

Зәйтүнә, язуыннан туктап, өстәл аша Шәйхаттар бабай кулындагы тәмәкегә үрелде:

— Китер, китер, бабай, хәзер үземнекенә салам.

— Мә, шулай ит әле, Зәйтүнә.

— Яшьләр, дөнья рәтен белми әле алар, бабай...

— Әй, Мәхбүзә карчык,— дип көлде берсе.

Икенчесе Зәйтүнәне ашыктырды:

— Әйдә инде, Зәйтүнә. Син генә калдың... Ә, Мәйсәрә бар икән әле тагын... Әйдәгез инде!..

— Ашыгыгыз, ашык. Кичке пассажирскийга өлгертик.

— Хәзер, хәзер...

Мәйсәрә, хатын язып бетерде дә, мендәре астыннан бүләкләрен алып килде. Һәрберсен иптәшләренә күрсәтеп

чыкты. Хатын укымады, бүләкләре арасындагы җылы перчатка эченә тыгып калдырды. Перчаткалар өстенә кровате турындагы стенадан үзенең фоторәсемен алып килеп куйды.

— Әбәү, карточка да җибәрә!

— Җибәрәм.

— Яле, яле...

Бу Мәйсәрәнең җәй көне яшь каеннар алдына басып төшкән рәсеме иде: башында ак берет, өстендә юка гына ал күлмәк, билендә ак каеш. Болай да чамадан тыш тулы Мәйсәрә рәсемдә тагы да тулырак булып чыккан, аның тәне юка күлмәгеннән хәзер ташып чыгар төсле күренә иде.

Бу рәсемгә күзләре төшкән саен елмаймый калмаган кызлар көлешеп куйдылар. Мәйсәрә, иптәшләренең ник көлгәннәрен аңлап, кровате астындагы чемоданнан икенче бер рәсем алып килде. Кызлар тагы көлделәр.

Бусы Мәйсәрәнең кышкы пальтодан төшкән рәсеме иде. Бу рәсемдә ул шундый авыр үлчәүле булып күренә, менә-менә идән тактасын җимереп төшеп китәр төсле басып тора иде. Әллә инде фотограф та шуңардан курыккан, ерган авызын йомып бетергәнен дә көтмичә төшереп алган иде.

Мәйсәрәгә рәсемнәрнең берсен дә җибәрмәскә киңәш бирделәр.

Мәйсәрә килешмәде.

— Ә мин аны менә болай итәм...— диде ул. Бераз чамалап торды да соңгысын күкрәк тиңентен кисеп алды. Ләкин тулган айдай тулы бит, гәүдәдән аерылгач, тагы да җәелебрәк киткән төсле булды. Кызлар, моны күреп, шаркылдап көлеп җибәрделәр. Мәйсәрә үпкәләмәде. Үзе дә көлде ул. Аннары зарланып куйды:

— Нигә болай чыккан соң бу? Үзем мондый ук түгел лә инде мин, кызлар!..

Берсе шаяртып әйтте:

— Шулай шул... Карточкаң урынына ящикка үзең генә кереп ят, Мәйсәрә...

— Кирәкми, кирәкми!.. Поезд үз көенә генә барсын әле. Болай да срогы кыска.

— Поездны әкренәйтер, дисеңмени?

— Көт тә тор!..

— Хи-хи-хи!..

Мәйсәрә моңа да җәберсенмәде:

— Әйдә ярар. Кем белә, үзе бәлки миннән дә болайрактыр әле...— диде һәм ал күлмәкле рәсемен хаты янына тыгып куйды да бүләкләрнең барысын бергә төреп бәйләп ящикка салды.

Кызлар җырлап җибәрделәр:

Төннәр утырып әзерләгән
Бүләгемне ал минем,
Җиңеп исән-сау кайтуың
Теләп калам мин синең.

Иң ахырдан ящик янына Зәйтүнә килде. Ул ак кәгазьгә бик матур яшел хәтфә янчык куйды. Янчык өстенә әле карасы да кипмәгән хатын салды. Үзе төсле чәчрәп торган рәсемен куйды. Һәм... Хәлимнең күзләре зур булып ачылдылар — Зәйтүнә, ак алъяпкыч күкрәкчәсеннән бер кулъяулыгы чыгарып, кечкенә матур борыны төбендә әдәпле генә йөртеп алды да, «шәпме?» дигән төсле итеп Хәлимгә күз кысып куйды, аннары читчитеннән чеметеп таратып җибәрде,— Хәлим, ачкан авызын да яба алмыйча, катып калды.

— Чү! Бу ни хәл тагын?! — диде ул бераз ис җыйгач.— Минем яулык ич!

Хәлим бу сүзләрне чак кына кычкырып әйтмәде. Чак кына Зәйтүнә кулындагы яулыкка үрелмәде. Ул серле яулык яткан күкрәк кесәсен капшап алды. Яулык төрелгән кәгазь кыштырдады. Хәлим, аның белән генә тынычланмыйча, кеше-кара күрмәгәндә аралыкка кереп, кәгазьне сүтеп карады — яулык шунда иде.

— Бу ни хәл тагын?! — дип кабатлады Хәлим. Ул, Зәйтүнәне серле яулык серенә катнаштырып, әллә ниләр уйлап бетерде. Ләкин боларның берсенә дә үзе ышанмады.— Ни булса ул, хәзер тотам да сораштырам,— диде Хәлим, һәм бер җаен китереп Зәйтүнә янына килде.

— Зәйтүнә апа...

— Нәрсә, акыллым?

Ләкин Хәлим сораштыра алмыйча калды. Ишектән бәреләсугыла кергән толыплы кеше, леспромхоз агитаторы, шат кычкыра-кычкыра килеп, Зәйтүнә каршысында туктады.

— Бас! Бас! — диде ул һәм, толыбын да салмыйча, кул чаба башлады.

— Тагы шәһәр?

— Түгел.

— Икенче фронт?

— Түге-ел,— дип сузды агитатор һәм кулын селкеп куйды.

— Нишләп ачмый инде ул аны, ә, икенче фронтны?

— Ачмый, димәк, аның өчен шулай әйбәтрәк,— диде Шәйхаттар бабай сүзгә кушылып һәм Зәйтүнәгә эндәште: — Ә син, Зәйтүнә, әйдә, бас... иптәш агитатор әйтә икән — бас!

— Ай, нәрсә генә икән инде?

— Я, көттермә инде, Зәйтүнә!

Зәйтүнә назлылардан түгел иде. Итәк читләрен чеметеп кенә тотты да, ак йон оеклары белән йомшак басып, оста биеп китте. Аннары кулларын як-якка матур җәйде дә, баш бармакларына күтәрелеп, тын күлдә йөзгән аккош шикелле тын йөзеп, Шәйхаттар бабайга таба килә башлады.

Шәйхаттар бабай артка чигенде:

— Ә, юк, кызым, мине кузгатма инде син...

Ул арада агитатор тиз генә чыгып, өйалдыннан озынча авыр ящик күтәреп керде һәм Зәйтүнә каршына китереп куйды. Кызлар, чыр-чу килеп, ящикны сарып алдылар.

— Алып киләм дидем, и тәки алып килдем,— диде агитатор, толыбын сала-сала.

— Радио! Радио!..

— Ой, нинди зур!

— Менә дигәне бу! Американы да тота.

— И-и...

— Рәхмәт инде, Җәмилев абый!

Агитатор, су кранына «җир» ялгап, бүлмәнең бер очыннан икенче очына антенна сузды.

— Американы да тота,— дип кабатлады агитатор эше беткәч, һәм приемникның стрелкасын Нью-Йоркта туктатты.

— Америка хөкүмәте, союздаш дуслар, сезне фронтлардагы җиңүләрегез белән тәбрик итә,— диде Нью-Йорк рус телендә.— Һәм бер вагон язгы-көзге пальто, бер вагон ботинка...

— Менә, менә, аларның икенче фронтлары хәзергә шушы әле.

— Хәзергә дә, соңыннан да шуннан узмас ахры, бабай.

— Ә-ә...

— Узмас...

Агитатор стрелканы Москвага таба боргаңда, Анкарадан узды. Анкара «немец... немец туганнар...» дип нидер мыгырдап калды.

— Кара, төрек ич бу?

— Төрек.

— Аның белән эшләр ничегрәк соң безнең?

— Әйбәт түгел, бабай.

— Нишләп? Безнең договор бар ич аның белән.

— Договор немец белән дә бар иде лә ул, бабай,— диде агитатор, гасабиләнеп, һәм приемник стрелкасын Мәскәүгә китереп туктатты.

Өйдәгеләр барысы да тынып калдылар.

Мәскәү телгә килде:

«Соңгы сәгатьтә.

Бүген, 11 нче январьда, Төньяк Кавказда, генерал-лейтенант Масленников командалыгындагы безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң Георгиевск шәһәрен һәм тимер юл узелын...

Тыңлаучылар Мәскәүнең «алдылар» дип әйтәчәген белеп, кул чабарга тотындылар, агитатор аларны туктатты. Мәскәү бик кечкенә паузадан соң дәвам итте:

«...Минеральные Воды шәһәрен һәм тимер юл узелын...»

— Тыңлаучылар тагын кул чабарга җыендылар, агитатор аларны тагын туктатты. Мәскәү дәвам итте:

«...Пятигорск шәһәрен һәм тимер юл станциясен, Кисловодск шәһәрен һәм тимер юл станциясен...»

Тыңлаучылар инде кул чабарга ашыкмадылар, яңа шәһәр ишеткән саен аларның йөзләре яктыра барды. Мәскәү дәвам итте:

«...Железноводск шәһәрен һәм тимер юл станциясен, Буденный шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук район үзәкләре: Ачикулакны, Александровскоены һәм Архангельскоены алдылар. Бик зур трофей...»

Тыңлаучыларның артык түземнәре калмады, барысы бер үк вакытта кул чабып, бер үк вакытта ура кычкырып җибәрделәр. Кызлар берсен-берсе кочып алдылар.

— Мәйсәрә!

— Мәйсәрә кайда?..

Кызыл Армия Сталинград районында, дошманның гаять зур көчләрен чолгап алып тар-мар иткәннән соң,

фашистларга башка фронтларда да сулу алырга бирмичә, өннәренә таба куа китте. Озакламый Үзәк фронтта да, Кавказда да Гитлер армиясе тәртәне кире борды. Хәзер, көн саен диярлек, совет радиосы фронтлардан шатлыклы хәбәр ташып тора. Кызлар бу хәбәрнең һәркайсын биеп-җырлап каршы ала иделәр. Соңгы тапкыр шундый тантана вакытында Мәйсәрә өйдә булмады, аны биетә алмый калдылар, һәм алдагысында аңардан башларга булдылар. Шуңар күрә Мәйсәрә үзенең исемен ишетүгә, ни өчен эндәшкәннәрен төшенеп, әз генә дә назландырып тормыйча, шундый авыр гәүдәсен гаҗәп җиңел йөртеп, биеп китте.

Шәйхаттар бабай, ризасызлык белдереп, башын чайкап куйды:

— Юк, юк,— диде ул,— шулкадәр шәһәргә бер Мәйсәрә белән генә котыла алмыйсыз. Бас, бас! Барың да бас! Ә син, улым, ныграк тарт колагын!

Кызлар берәм-берәм уртага чыга башладылар. Зәйтүнә дә чыкты. Ул, чыккан уңайга бер кыз белән бераз әйләнгәләде дә, күзләре белән чакырып, Шәйхаттар бабайга таба килә башлады. Шәйхаттар бабай бу юлы: «Юк, мине кузгатмагыз» дип тормады, Зәйтүнәнең чакыруын гына көтеп торган кебек, уртага килеп керде...

— Һиә, һиә!..

Кызларның биегәне дә, кул чабып торганы да Шәйхаттар бабайга борылып карадылар.

Аның өстендә шул ук сырган пиджак, сырган чалбар, ләкин чалбарының балак очларында сүсләр юк, билендә дә сүс бау түгел, кызыл пута иде. Сакал-мыегы монда килер алдыннан гына бик тә җиренә җиткереп төзәтелгән иде.

Ул уртага чыгып басуга, бер кулын биленә куеп, әле бер, әле икенче иңбашын сикертеп куйды да, янында кул чабып торган бер кызның бил каешына кыстырылган яулыгын тартып алды һәм, шуны изи-изи, аякларын бию көенә басарга тырышып, Зәйтүнәгә таба бара башлады.

— Һиә! Һиә!..

— Ну, бабай!..

— Ну, му-ут!

Агитаторны да өстерәп чыгардылар.

Менә кул чабып торучы кызлар да биеп киттеләр. Бию кызды. Идән такталары сыгылып-сыгылып килде.

Стеналар селкенде. Өстәл селкенде. Өстәлдәге стаканнар, графин, кара савыты бер-берсенә бәрелеп-чылтырап торды, гүя алар да, барсы да, өй үзе дә биюгә күчкән иде.

Кемдер, узып барышлый, Хәлимгә кагылып китте.

— Тибешрәк, Хәлим, тибешрәк!..

Хәлим, җиңү шатлыгын аңына сеңдереп, бөтен барлыгын, йөрәген гармоньга кушып уйный иде, башын күтәрде. Кагылып узучы Зәйтүнә иде. Ул, аяк очларына басып, кулларын дулкынлатып, Шәйхаттар бабай янына килде дә аның янында күбәләктәй әйләнеп йөри башлады. Хәлимнең уйлары тагы да серлеләнә төшкән кулъяулыкка барып ялганды.

«Әллә син шаярттыңмы, югыйсә?..» диде Хәлим, Зәйтүнәнең шаян уйнаган күзләре белән очрашкач, һәм, эпипәне уйный иде, үзе дә сизмәстән, әллә нинди башка бер көйгә кереп китте. Биючеләрнең кайберләре, аптырашып, туктап калдылар. Кайберләре, әле төшенеп житмичә, бии бирделәр. Нәкъ шул чакта станциягә кереп килгән паровозның көчле тавышы яңгырап китте.

— Әчәч, кызлар, пассажирский!

— Ай, соңга калдык, кызлар...

— Калмадык. Почта өлгертә. Поезд биредә 40 минут тора ич. Печать бастырабыз да почтовый вагонга үзебез кертеп бирәбез!

Кызлар барысы да бүләкләре янына ташландылар. Зәйтүнә һәм тагын берничә кыз, пиджакларын иннәренә салдылар да, ящикны алып чыгып йөгерделәр.

— Һәйбәт булды бу. Әйдә, улым, без кайтыйк инде.

— Кайту кайда әле... хәзер керә алар. Чәй өлгерле. Хәзер чәй эчәбез, бабай.

— Ә, юк. Рәхмәт, кызым. Чәйне — кайткач... Ярый, хушыгыз. Гаеп итеп калмагыз. Иртәгә таң белән сәфәр безнең.

Шәйхаттар бабай, бүреген басып киде дә биегәндәй иткәндә бушаткан путасын кысып бәйләде:

— Әйдә, улым.

— Хәзер... Бераз гына торыйк әле, бабай. Зәйтүнәападан бер сүз сорыйсы бар иде минем..,

Шәйхаттар бабай белән Хәлим авылга карангы төшеп житкәч кенә кайтып керделәр. Юлга соң чыктылар алар, урманчы кызлар янында озак юандылар. Шәйхаттар бабай, китик инде дип, Хәлим, көтик әле, дип тартышып торган арада, сугышчыларга бүләк салырга киткән кызлар кайтып килде. Кызлар Хәлимне, сугыш беткәнче мондый гармоньчы әллә очрый, әллә юк дип, бармаклары саташа башлаганчы уйнаттылар. Егылганчы биеделәр, жырладылар. Аннары кунакларны — кайсының балы, мае, кайсының күмәче, корты, каклаган каз ите бар икән — бик әйбәтләп сыйладылар.

Ә яулык турында?

Яулык турында Хәлим Зәйтүнәдән бары шуны гына белә алды: Зәйтүнә үз яулыгын чиккән жепне сугышка кадәр үк район ярминкәсендә бер «Никкүчтем» апае белән бүлешеп алган. Чегән хатыныннан. Чигү үрнәген дә шул чегән хатыны биреп калдырган. Ә кем ул — Зәйтүнә белән бу жепне бүлешеп алган «Никкүчтем» апае? Зәйтүнә аның исемен дә, кайсы урамда торганын да белми. Кызлары барын-югын да белми. Урта яшьле, урта буйлы, сагызны бик оста шартлатып чәйни торган таза гына бер хатын, ди. Ә «Никкүчтем»дә андый хатыннар азмыни!.. Шулай да, кем икән ул? Кем булса да булыр, ул хәзер Хәлимнең уен били алмады. Аның уенда, аның күз алдында хәзер әнисе белән Шәехтайдан башка зат юк иде.

Ул авылга керүгә, бабайны әйдәп, тагы да кызулый төште. Урманда хыялланганынча, иптәшләрен очратып, үз кул көчләре белән эшләп алып кайткан фуражкаларны күрсәтеп тору да хәзер аны мавыктырмады.

Тизрәк, тизрәк Шәехтай янына!.. Ләкин мәктәп турысыннан узып барганда, бер класста зур ызгыш ишетеп, Хәлим тукталмый түзмәде. Шәйхаттар бабайны кайтарып жибәрде дә мәктәпкә атылып керде.

Ызгыш менә нидән чыга. Биялэйләр тегелеп бетү уңае белән район газетасыннан репортер килә. Репортер үзенә кирәкле мәгълүматларны алгач, нәни патриотларны рәсемгә төшереп алырга жыена. Кайда-кайда, мондый чакта Ибрай авыз ачып калучылардан түгел, ул аппаратның күзенә үк кереп утыра. Аны кызлар эшеңнең дә рәте булмады, житмәсә, буең алап шае,

бөтенебезне каплыйсың дип, өстерәп чыгаралар. Әнә, бар, артка бас.

Шулай булмый ни!.. Ибрай кул астына туры килгән беренче кызны — игезәкләрнең берсен этеп җибәрә. Икенчесе чәчрәп чыгып, туганын яклый башлый. Ибрай — черкигә, Гөлчәһрәләр — идән асты сандугачларына әйләнәләр.

— Кит, саз черкие! — ди Гөлчәһрә.— Әнә бияләйләрең авызларын ачкан, ашарга сорыйлар.

Моңа бәлки әллә ни әһәмият бирмәгән дә булырлар иде.— Каракның бүреге яна диләрме әле? — бу сүзгә Ибрай кызарып китә.

Нигә кызара соң, Ибрай?

Эш болай була. Иртәгә укулар башланырга торганга, бик тыгызга килсә дә, эшне бүген бетереп кайтырга булалар. Инде эшкә күнә башлаган куллар кулга йокмый. Тик бер Ибрай пошынмый.Ә шулай да, нормасын тутырмады, дигәннәрен ишетергә теләми ул. Тәнәфес вакытында Гөлгенә эшләп тапшырган бияләйләр арасыннан кеше-кара күрмәгәндә өч парын тартып ала да алар урынына үзенең атлатып кына чыккан, бармаклары эләгеп кенә торган өч парын тыгып куя. Моны бер Гөлчәһрә генә күрә. Ләкин ул да, Гөлгенәгә ачу тотып йөргәнлектән, эндәшми кала.

Хәлим кергәндә бияләй тегүче балаларга җитәкчелек итүче Рәхимә апа белән Мәрфуга Ибрайны орышып торалар, Ибрай чөгендер кебек кызарган, эндәшми, башын иеп тик тора иде.

— Я, Ибраһим, төшендеңме инде гаебеннең никадәр тирән икәнен? Ә син, Гөлчәһрә?

Шуңарчы үзен герой күреп елмаеп утырган Гөлчәһрә, ударның үзенә күчкәнен сизеп, авызын йомды. Кашларын җыерып аска карады. Мәрфуга дәвам итте:

— Дөресен әйткәндә, синең гаебең тагы да зуррак, Гөлчәһрә. Талашып китмәгән булсагыз, син эндәшми калыр идең, брак бияләйләр шул килеш фронтка китеп барды, шулай түгелме?

Хәлимнән алда гына кереп бер читтән тыңлап торган Шаһгәрәй абзый аңар ялгап алып китте:

— Ә анда ул бияләйне берәр артиллеристка, яисә разведчикка бирәләр. Бүләк. Татарстан пионерларыннан. Рәхәтен күр... Разведчик аны киеп, шуыша-шуыша дошман тылына кереп китә. Яман суык, җил, буран...

Менә шул чакта бияләй сүтелеп эченә кар кереп тула... Күз алдыгызга китерегез әле шул картинаны... Разведчик әйтә инде шул чагында: «Мин биредә алар өчен җан-фәрман сугышып йөрим, ә алар анда шул бияләйне дә...»

Гөлчәһрәгә барып җитте, ул үксеп елап җибәрде. Гөлзәһрәсе дә елар, туганын кызганып елар, дип көткәннәр иде, һәрвакыт шулай була иде алар. Бу юлы андый хәл булмады. Ул кашларын җыерды һәм, әнигә әйтәм мин сине, менә вәт, дип, туганы яныннан китеп утырды.

Ибрайның брагын, җыелышып, яңадан тегә башладылар. Ләкин ялкаулыкның зарары өч парга гына тиеп калмаган иде. Эшләп тапшырылганнар арасыннан Рәхимә апа тагын шундый: «Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче» тегелгән өч-дүрт пар бияләй алып килеп өстәлгә атты.

— Әй, энем, энем, игелек күрмәссең болай булсаң,— диде ул.— Мә, теләсәң ничек башкарып чык!..

Ничек башкарсын инде ул аларны? Аның башкарганын кем көтеп торсын? Рәхимә апа бер парын үзе алып төзәтә башлады, калганын башкалар бүлешеп алып төзәтергә керештеләр. Ибрай кулындагын да ала башлаганнар иде дә, бирмәде. Ул иптәшләренә арты белән борылып утырды да күз яшьләрен, гомер күрсәтмәгән күз яшьләрен бияләенә тамызып, тегәргә тотынды.

Күңелсез, эчпошыргыч тынлык урнашты. Ләкин ул бик аз дәвам итте. Тиз арада Ибрайга, Гөлчәһрәгә бәйле шаян сүзләр ишетелә башлады. Үзенең көр тавышы белән Каюм җырлап җибәрде. Аңар сандугач тавышлы Фәрдәнә һәм башкалар кушылды.

Коллектив хезмәт шулай күңелле ул! Хәлим дә үзенең урманнан кайтып килеше икәне белән дә хисаплашмыйча, тегә белмәсә дә, иптәшләре арасына кереп утырды.

Эш бетүгә репортер балаларны тагын сафка тезәргә тотынды. Гөлчәһрә бу юлы алга тыкшынмады. Иң артка барып посты. Гөлзәһрәсе дә (туганы өчен аңар да уңайсыз иде) артка барып басты. Һәм туганын чеметеп алды да болай диде:

— У-у сине! Ярый инде, бер юлга әнигә әйтмим. Моннан болай шундый эш эшләсәң, мин синең белән сөйләшмим дә.

— Ә Ибрай кайда әле, Ибрай? — репортер күзләре белән Ибрайны эзләде.— Кил, менә биредә сиңа бик әйбәт урын бар...

Бу вакытта инде Ибрайдан җилләр искән, ул дошман тылына шуышып барганда кулына кар кергән разведчикны күз алдына китереп, гаебенең тирәнлеге турында уйлап, өенә кайтып бара иде.

19 ШӘЕХТАЙНЫҢ ЯШЕРЕН ДУСТЫ

Хәлим чәй янында озак юанмады, урман күчтәнәчләрен (яшереп җыйган ипи сыныкларын) култыгына кыстырып, абзарга китте һәм ишектән атылып килеп керүгә исеме белән дәшә-дәшә йөгереп барып, атны муеныннан кочып алды. Ул абзарга кергәндә, озаклап сөеп торырмын, иркә сүзләр әйтермен дип уйлаган иде, ләкин атны күрү белән, аптырап китте. Үзләре урманда чакта әнисенең атны тәрбияләячәгенә никадәр ышанса да, атның үлеп куюыннан, һич югында ябыгуыннан курыккан иде. Курыкканга куш дигәндәй, ул бу турыда уйлаганда Әхмәтҗан конюхның «Юк инде ул, барга санамыйм мин аны, шушы арада аяк сузар инде ул...» дигәнен исенә төшереп шомланган иде. Ә ат әнә нинди булып тазарган! Дөрес, аның кабыргалары әле дә беленеп тора. Ләкин хәзер инде элеккеге шикелле карарга куркыныч түгел. Күз төбендәге чокырлары да кечерәя төшкән. Янбаш сөякләре дә беркөнге шикелле тиренә ертып чыгарга тормыйлар. Тиресе фонарьның саргылт яктысында ялтыр-йолтыр килә иде.

Ат Хәлимне матур кешнәп каршы алды. Койрыгын селкеп куйды. Акыллы ат башын Хәлимнең иңбашына салып торды. Ләкин акыллы ат, болай тазаруының сәбәбен үзе белсә дә, әйтеп бирә белми иде.

Аның сәбәбен Шәйхаттар бабай да әйтеп бирә алмады. Ул, балаларча сөенеп, олыларча исе китеп, атның һәрбер төген диярлек күзеннән кичерде һәм абзардан әйләнеп кайтуга Шәмсия җиңгигә турыдан-туры:

— Әйт, килен, нәрсә ашаттың? — диде.

Бабай Шәмсия җиңгинең бернәрсә дә ашатмадым дигәнен тыңларга да теләмәде.

— Шалишь, килен! Алай булмый. Бу хәлгә китерү өчен байтак кирәк аңар, ашь нәмәрсә түгел бит ул,—

диде бабай һәм,— әйт, нәрсә ашаттың? — дип кабатлады.

Шәмсия җиңги җәберсенеп куйды:

— Кара, ник алай дисең әле син? Минем үземнең дә исем китте инде аның шулай булуына, күзгә күренеп тазара ул...

Шәйхаттар бабай, менә хәйран тамаша, менә әкәмәт, дип куйды, артык бер сүз дә әйтмәде.

Әлбәттә ул ышанмады. Хәлим дә ышанмады. Ул, ашап-эчеп йокларга яткач, Шәйхаттар бабай да йокыга киткәч, әнисе янына килеп, әллә ул барында гына әйтмәдеңме, берәр нәрсә ашаттыңмы, дип сорады. Тагы шул ук җавапны алгач, урынына ятып күзләрен йомды.

— Ябыкмаган ич, тазарган. Нигә хафаланам әле мин...

Ә шулай да беләсе килә иде малайның. Икенче көнне кич, урманда хыялланганынча, атны кинәндергәнче, алдыннан калганчы ашатырга баргач, бу турыда Низам конюхтан да сорашты. Ул да шулай ук белмим, диде. Ләкин белмим дигәндә ничектер сәер итеп, мыек астыннан гына көлеп куйды.

Хәлим шикләнми кала алмады. Ул:

— Әһә, беләсең, беләсең!..— дип, балаларча куанып, аңар килеп ябышты. Ә Низам абзый алай гына тугарылып китмәгәч, аңар ияреп конюхлар алачыгына керде.

Ул хәзер конюхны абзардагыча турыдан-туры атакаламады, башта тегене-моны сорашып утырган булды. Фронттагы энеләре турында сорашты, аңар ярарга тырышып, җаеннан гына торды, көлгә күмгән бәрәңгеләренең көйгән исе чыга башлагач, кисәү алып алгарак күчерде. Шул арада үзен кызыксындырган сорауны китереп кыстыра иде. Ә конюх һаман белмимнән башканы әйтми, белмимне дә инде ул абзардагы кебек мыек астыннан көлмичә, шиккә төшерми торган итеп әйтә иде.

Шулай утырганда Хәлимнең сак колаклары ат абзарының ишеге шыгырдап ябылганны ишетте. Хәлим, сикереп торып, тәрәзәгә килде. Ни күзе белән күрсен: анда кемдер ат абзарыннан чыгып, каралтыларга ышыклана-ышыклана капкага таба китеп бара иде.

Хәлим ике куллап тәрәзә кагарга тотынды:

— Әй, тукта!..

Кеше, туктамады гына түгел, Хәлимнең тавышын ишеткәч, йөгерергә үк тотынды.

Хәлим аны танымады. Бу — кечерәк кенә бер малай булып, кулында шактый зур чиләк иде. Хәлим шинелен иңнәренә салды да серле малай артыннан йөгереп чыкты. Ләкин Хәлим капкадан чыкканда, малай урамда юк иде инде.

Хәлим нишләргә белмичә, бер-ике өй буе уңга, бераз сулга йөгереп карады. Аннары абзарга керде. Анда керсә, ни күзе белән күрсен, ат алдында улак тулы хуш исле җылы башак иде.

Хәлим бу хәлне күреп шаккатты. Бик, бик шатланды да ул. Ләкин аны хәзер вакыйганың шатлыгыннан бигрәк, сере кызыксындыра иде. Яшерен дусның кем булуын, ни өчен үзен танытмаска тырышып йөрүен беләсе килә иде. Һәм болар барысы да икенче көнне, атны иртәгә яңа абзарга, элеккеге урынына кучерәсе дигән көнне ачылды.

Ул болай булды:

Хәлим, бүген дә атына кичке башакны биреп чыккач, конюх янына кереп утырды. Ул үзе сөйләште, үзе болай да кысып куелган сукыр лампаны кыса төшеп, маскировканың бер читен күтәреп, тәрәзәнең күкле-яшелле пыяласы аша ишек алдына карап утырды. Серле малай килмәсме дип көтте ул. Ялгызлыктан ямансулап утырган конюхның да Хәлимне тиз генә чыгарып җибәрәсе килми иде. Утыра-утыра байтак вакыт үтеп китте. Инде каланча сәгате унны сукты. Хәлим, кайтырга кирәк инде, килмәс, дип мич куышыннан аякчуларын алып чолгарга торганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына, ачылып китте.

Малай! Кичәге малай!..

Хәлим бу юлы малайга эндәшеп тормады, үзен-үзе онытып, өйалдына ташланды.

Кара, ул бит ялангач! Аягына киярга дә оныткан ич!..— Хәлим кереп итекләрен киде, шинелен иңнәренә салып, конюхка эндәшә-эндәшә, ишек алдына чыгып йөгерде:

— Низам абзый, тор! Теге малай керде. Күр, хәзер мин аны ничек каптырам!

Ләкин ул арада малай да абзарда йоклап ятмаган икән. Хәлим шинеленең бер җиңен киеп, каушавы белән икенче кулын җиңенә тыга алмыйча, өйалды ишегеннән килеп чыкканда, серле малай йөгерә-йөгерә капкага җитеп килә иде инде.

Хәлим, өч баскычны берьюлы сикерде дә, малай артыннан ташланды:

— Тукта, малай, минә тиле, тимим ич мин сиңа!..

Малай туктамады.

— Тукта, малай, атам!— дип тә карады Хәлим, ләкин малай барыбер туктамады. Ул бик шәп йөгерде. Йөгерде-йөгерде дә һич уйламаган ишек алдына, бер дә бала-чагасыз ишек алдына, әлеге Мүкләк Зарифларга кереп китте. Хәлим дә аның артыннан атылып килеп керде. Малай ишек алдын йөгереп үтте дә, арт койманың бер тактасын кыегайтып (әллә инде алдан әзерләп куйган!), бәрәңге бакчасына чыгып шылды. Хәлим, аның артыннан килеп җитеп, шул ук ярыкка тыгылды. Ләкин аның гәүдәсе малай сыйган ярыктан чыга алмады — күкрәк турысыннан кысылып калды. Хәлим, гәүдәсен көч-хәл белән тартып алып, тиз генә арт капкага килде. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, капка бикле иде.

— Тфү!

Хәлим, үзенең кайда икәнен дә онытып, шинелен салып атты да коймага менеп китте. Ул хәзер тәмам ярсыган, аның күзенә бернәрсә күренми, ат та юк иде хәзер аның уенда, шинель дә. Бары әнә шул яхшы күңелле, ләкин бу яхшылыгын, ни өчендер, кешеләрдән яшереп эшләүче серле малай гына бар иде. Һәм хәзер бу серне ачу юлында, әллә нинди бәлаләргә очрыйсың дисәләр дә, Хәлимнең туктаячагы юк иде.

Хәлим коймадан бәрәңге бакчасына сикереп төште. Һәм мунча сукмагы буйлап инде шактый ерак китеп өлгергән малай артыннан җан-фәрманга йөгерә башлады.

Хәлим әйбәт йөгерде. Ләкин малай да бирешмәде. Ике ара әйтерлек кыскармады. Малай бер дә каушамыйча, артына да борылып карамыйча, ахрысы үзен тоттырмаячагына ышанып, йөгерә иде.

— Тимим бит мин сиңа, малай, тукта!

Малай туктамады.

— Тукта дим, малай!

Малай туктамады. Ул инде бәрәңге бакчасын йөгереп үтте. Бәрәңге бакчалары бетеп, бераз баруга, текә яр башлана. Малай, кар күмгән җир баскыч буйлап, яр астына төшеп китте. Аста, як-якта, ярга терәп салынган кара мунчалар тезелеп киткән. Хәлим малайны шулар-

ның берәрсенә кереп посар дип уйлаган иде, ләкин малай моны эшләмәде. Ул ярдан төшүгә елгага таба йөгерде. Елга өстен дә йөгереп үтте ул. Әз генә баргач та, елга яры буйлап сузылган олы юл китә. Юлның ике ягында да канаулар. Малай бер канауны оста гына сикереп чыкты. Юлны аркылы үтеп, икенчесе аша сикерде. Аннан куаклык башлана. Анда кергәч ул Хәлимгә һич тә тоттырачак түгел... Малай канау аша шуны уйлап сикерде. Сикерде, ләкин бер аягы канау читенә җитми калды. Малай канау эченә мәтәлеп төште. Шунда ук торып йөгерергә омтылып караса да, булдыра алмады. Канауда кар бик тирән булып, малай бил тиңентен кереп баткан иде.

Инде тәмам ярсыган Хәлим, аның артыннан килеп җитеп, канауга сикерде. Һәм ул да бил тиңентен карга батты. Ул көчкә кузгалып малай өстенә килде. Аны тану өчен йөзе белән әйләндерә башлады, ләкин малай, йөзен яшерү өчен башы белән карга шулкадәр кереп киткән, кузгатырлык та түгел иде. Хәлим, малайны кардан көчләп тартып чыгару өчен, җилкәсеннән бик каты итеп эләктереп алды...

20

МЕНӘ КЕМ ИКӘН УЛ!..

— «Чү!.. Өнемме бу, төшемме? Чәч толымы!.. Кара, кыз бала икән ич!» — Хәлим кайда икәнен, нишләгәнен, нигә шулай эшләгәнен дә онытып, кызның башын кардан тартып чыгарды. Ләкин аның куллары битенә шулкадәр нык ябышканнар иде, Хәлим ансат кына куптарып ала алмыйча каерырга тотынды. Кыз бала алай да кулларын битеннән алмады, ләкин, авыртканына чыдаша алмыйча, чырылдап кычкырып җибәрде.

Инде карамаса да була иде. Хәлим аны тавышыннан ук таныды һәм, кызның кычкыруын ишеткәндә ни кыяфәттә булган булса, шул килеш катып калды. Бу... Хәлим өчен елдан артык сер булып йөргән дүрт кызның берсе — «Г» хәрефенә башланган кызларның берсе иде. Гөлгенә иде бу!

Гөлгенә башын тагы карга яшерде.

Гөлгенәләр Хәлимнәргә нигездәш күрше. Аларның ата-аналары элек-электән яхшы күршеләрчә тату яши-

ләр. Зур эшләрне бер-берсенә киңәшмичә эшләмиләр. Колхозга да бер көндә, бер сәгатьтә керәләр. Ә Гөлгенә тугач, аның арты Хәлим дөньяга килгәч, күршеләрнең дуслыклары тагы да ныгый төшә. Әниләре бер-берсенә ешрак кереп йөри башлыйлар. Хәлим белән Гөлгенә дә, шуышып йөри башлаганнан бирле бер-берсен күреп, бергә уйнап үсәләр. Балалар бакчасына да бергә йөри алар. Мәктәпкә дә житәкләшеп барып керәләр, икесе бер партага утыралар. Ә балалар төртеп күрсәтә башлагач, шаян малайлар коймаларга, мәктәп стеналарына икесенең исемнәре арасына + билгесе куеп яза башлагач, бер-берсеннән читләшәләр. Бу читләшү табигый да. Гөлгенә — кыз бала, кызлар белән курчак уйный, 9—10 яшьләргә житкәч бик бирелеп чигүгә өйрәнә. Ә Хәлимне, ир баланы, кузна уены, лапта, кәшәкә-таяк уеннары, балык тоту, төннәрен ат сакларга йөрүләр үз эчләренә алып кереп китәләр. Хәзер Хәлим белән Гөлгенә бер-берсен бары мәктәптә һәм балаларның гомуми уеннары булган чана шуу, чаңгыда йөрү, урманга жиләккә бару вакытларында гына күрәләр. Бара-тора стеналардагы + билгеләре бозыла, төртеп күрсәтүләр бетә. Ләкин Гөлгенәнең йөрәгендә Хәлимне сабый чактан килгән үз күрү бозылмый, бетми.

Ничек бозылсын! Ничек бетсен!

Азмы тапкырлар Хәлим Гөлгенәне күркә, яки ата каз талый башлагач коткарып калды, азмы аның кулындагы прәннек-конфетын чукый башлаган усал этәчне куып жибәрде, азмы Хәлим Гөлгенәнең чайкап торганда суга агып киткән курчак керләрен алып чыгып бирде, азмы тапкырлар Хәлим Гөлгенә өчен үзенең күлмәге яки штаны белән елга читеннән вак балыклар сөзеп йөрде!..

Ир бала андыйга хәтерсезрәк була. Бәлки Хәлим үзе боларны оныткандыр да инде, ләкин Гөлгенә берсен дә онытмады, һаман үз күрде, дус күрде ул Хәлимне. Хәлимгә берәр шатлык килсә, мәсәлән, дәрестә «5» алса, Гөлгенә аның өчен яшерен сөенеп куйды. Хәлим башына берәр кайгы төшсә, мәсәлән, укытучыга жавап бирә алмыйча, башын түбән иеп торса, аның өчен яшерен көенде. Хәлим өстенә берәр куркыныч килгәнне күрсә, малайларның аны кыйнарга жыенып йөргәннәрен сизенсә, бу турыда Хәлимгә белдерә иде. Тел белән әйтми, имзасыз язу язып, үзе күрмәгәндә сумкасына сала, яки, язу-

ны ташка төреп, койма аша ишек алларына ыргыта иде.

Гөлгенә үсте. Аңарда балачак дусты Хәлимне дус күрү, үз күрү дә үсте. Хәлимне дус күрү, үз күрү баратора житдирәк эшләрдә дә чагыла башлады. Хәзер килеп, Хәлим тәрбиягә ат алгач, ул бу эштә үзенең булышырга теләвен Хәлимгә әйтмәкче дә булган иде, ләкин, әлеге дә баягы, уңайсызланды. Ә ярдәм итәсе килә иде. «Ялгызына авырдыр аның...» — һәм ул бу ярдәмне Шәмсия җинги белән Низам абзыйга әйтеп, Хәлимнән яшерен эшләде. Хәлимнәр урман эшенә киткәч, һәр кичне, Шәехтай улагына бер чиләк җылы, күе башак алып кереп салды. Үзе карап торып ашатты. Ат тазарыр, Хәлим аптырар. Аның бу серне чишә алмый йөрүен күреп тору үзе никадәр кызык булачак!..

...Хәлим, бераз вакыт зиһенен җуярга җитеп аптырап торганнан соң, Гөлгенәнең кулларын җибәреп, артына чигенде. Аның белән шулай тупас эш итүе өчен уңайсызланды. Гөлгенәнең иңнәреннән йомшак кына тотып торгызырга, әкрен генә тотып кардан чыгарырга уйлады. Аңар рәхмәтләр, иркә сүзләр, мактау сүзләре әйтергә теләде.

«Ләкин болай эшләү — Гөлгенә яхшылыгы каршында чүп тә тормый бит! Юк, мин хәзер Гөлгенәнең яхшылыгын кайтару өчен, аның күңелен күрү өчен, бик зур эш эшләр идем. Үземнең тормышымны куркыныч астына куеп, берәр батырлык эшләр идем мин! Нәрсә генә эшләргә икән?..»

Табигый буларак, Хәлимнең бу уена шунда ук яулык сере килеп тоташты. «Тукта, тукта, болай булгач, яулык иясе дә Гөлгенә булу бик ихтимал ич!..»

Һәм ул шулай булды да: Гөлгенә өченче елны концерт вакытында, сәхнә артында, Хәлимнәрнең фронтка китү турындагы серләшүләрен тыңлап торды. Хәлимнәр ул чакта китүнең һәрбер детале турында сөйләштеләр. Үтерсәләр дә бу уйларыннан кайтмаячакларына ант иттеләр. Хәлим үзенең солдат капчыгы барлыгын, аны печәнлеккә менгереп куячагын, юлда кирәк булырдай әйберләрне, ашамлыкларны, әзләп-әзләп, шул капчыкка сала барачагын әйтте. Гөлгенә моны да ишетте. Ә көннәрдән беркөнне, малайларның китәр көннәрендә, табыкларын эзләгән булып, Хәлимнәр печәнлегенә менде. Менде һәм әлеге серле яулыкны, тәмле кипкән

чикләвекләрне инде ашамлык белән тула язган капчык төбенә салып төште...

Хәлимнең күз алдындагы томанлы пәрдә югары башлады. Сабый чак истәлекләре берсе артлы берсе, кинокадрлар шикелле, тезелеп үттеләр. «Ул! Ул!! Яулык иясе Гөлгенә!!! Ой, Гөлгенә!!! Ә мин аны былтыр, Гөлчәһрәләр алдында, әнә ничек мыскыл иттем... Йолдызларыңны нинди үлән суы белән... Эх!.. Шуның өчен генә дә, булышырга түгел, битемә төкерергә кирәк булган минем. Сиздем, йөрәге белән елады бит ул шул чакта... Хәзер дә шул турыда уйлый торгандыр әле... Тукта, гафу үтенимче үзеннән...»

Хәлим шул теләк белән Гөлгенәгә таба килә башлады.

— Гөлгенә!..

Бу матур сүзгә, әз генә каушау, әз генә сагыш белән саф күңелдән әйтелгән сүзгә, тагы нәрсә дә булса өстәүнең, мәсәлән, «гафу ит мине» диюнең кирәге юк иде. Шуңа күрә, Хәлим икенче сүзләр табып әйтә башлауга, Гөлгенә аны бүлде:

— Әйтмә, әйтмә, Хәлим...

— Юк, син, Гөлгенә...

— Кит, Хәлим! — Гөлгенә, башын әз генә борып, бармаклары арасыннан Хәлимгә карап алды да тирән кардан тырмашып чыгып юлга күтәрелде. Әллә тотылуына гарьләнеп елап җибәрде ул шул чакта, әллә көлде. Юлны үтеп, икенче канауны сикереп чыкты. Елганы йөгереп үтте. Зариф абзыйларның мунча ишеге төбендә ташлап калдырган чиләген алды да, кайда үрмәләп, кайда йөгереп, ярдан менеп китте һәм килгән юлыннан түгел, үз бәрәнге бакчаларына таба йөгерә башлады.

Хәлим аның артыннан йөгермәде. Ул каушамасын дип, үзенең әле һаман да канауда икәнен аңлатып, йөткереп куйды. Һәм, әле генә үз күзе белән күргән бу хәлгә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, Гөлгенә күздән югалганчы карап калды... Аннары, Зариф абзыйлар ишек алдында калган шинелен кереп алды да, Гөлгенәгә карата өченче елгы тупаслыгы өчен үзен-үзе тиргитиргн, өенә кайтты.

— Тоттыңмы, улым?

— Кем әйтте әле аны сиңа?

— Низам абыең...

— Тотты-ым...

— Соң?

Хәлим елмаеп куйды:

— Бер сөйләрмен әле, әни,— диде ул һәм, иртәгә Гөлгенәдән гафу үтенеп язачак хатына сүзләр сайлый-сайлый, йокларга ятты... Хәлим бу хатына уңай җавап алгач, яулык турында сорап язды.

«...Әйе, мин,— диде Гөлгенә үзенең җавабында.— Мин, Хәлим... Ачуланма һәм әллә нәрсәләр уйлый күрмә. Бергә уйнап үскән сабый чак истәлеге ул сиңа...»

Хәлим язуны яулыгы янына салып куйды. Аңар, ничектер, бик күңелле, бик рәхәт булып китте. Сабый чакларындагы шикелле үк дуслык, якынлык сизде ул үзендә Гөлгенәгә. Ә Гөлгенәнең Шәехтай өчен анны нинди кыенлыклар белән юнәткәнен белгәч, ни әйтергә белмичә, аптырап калды. Монысын Гөлгенә хат аша түгел, сбордан кайтканда үз теле белән сөйләп бирде:

— ...Мәктәптә солдатларга бияләйләр тегеп кайткач, көн саен Зариф абзыйларга керә идем. Анда без Җәмилә түти белән аның бирнәсенә әзерли торган сөлгеләрен, аякчуларын чигә идек. Шуның өчен Җәмилә түти миңа, әтисеннән яшереп, он биреп чыгара иде. Мин ул онны Шәехтайга ашата идем...

— Әниең сүз әйтми идеме соң?

— Әнием сүз әйтми иде. Үзе дә ике чиләк он бирде әле ул. Идарә белән сөйләшеп, берәр ат тәрбияләүчегә бир дигән иде. Мин анысын да Шәехтайга ашаттым...

— Эх, Гөлгенә, Гөлгенә!..

— Нигә, Хәлим?

— Мин синең бу яхшылыгыңны үлгәндә дә онытмам, Гөлгенә, күр дә тор...

Гөлгенә дәшмәде.

— Юк, мин моны сиңа чын күңелемнән әйтәм, Гөлгенә. Чын күңелемнән.

Гөлгенә уңайсызланып кына әйтеп куйды:

— Ачуланмасаң, моннан соң да мин синең атыңны тәрбияләшер идем, Хәлим. Бергә тәрбиялик без аны, яме, Хәлим?..

— Рәхмәт, бу кадәресенә дә бик рәхмәт, Гөлгенә. Аның азыгы болай да күп инде хәзер.

— Тагы да күбрәк булсын, Хәлим. Тәрбиялик инде, бергә тәрбиялик.

Гөлгенә шундый ягымлы итеп, шундый саф күңел белән әйтте, Хәлимгә тагы да рәхәтрәк булып китте. Хәлим Гөлгенәнең кулын кысты:

— Рәхмәт, Гөлгенә. Шулай итәрбез, Гөлгенә...

Хәлим бу сүзләрне үзенә хисап бирмичә әйтте. Чөнки ул хәзер бөтенләй башка нәрсә уйлый иде. Гөлгенә аны кайдан алуы турында сөйләгәч, урманга китәр алдыннан Шәйхаттар бабай белән әнисенең һәм Хәтирә әбинең Зариф абзый турында бәхәсләшеп утырганнары исенә төшкән иде аның.

Юк, син хаклы булмаган, ахрысы, Шәйхаттар бабай. Әни белән Хәтирә әби хаклы булган биредә, диде Хәлим үз-үзенә һәм, үзенең шиге турында әйтү өчен, өенә дә кереп тормыйча, колхоз председателе янына китте. Ләкин аның янына кергәч, икенче төрле уйлады.

Зариф абзыйлар Гөлгенәләргә чыбык очы туган тия. Җәмиләсе онны: «Зинһар, бер кешегә дә, әтигә дә әйтмә»,— дип биргән. «Кем белә, бәлки ул аны туганы итеп, кызганып, үз авызыннан өзеп биргәндер. Әйттем исә, колхоз председателе Зариф абзыйларны чакыртып сораштыра башлар, тагы тентү төшертүе бар. Ярый ла әйбер чыкса, ә тагы шулай чыкмаса? Бары Гөлгенә белән әнисе генә начар атлы булып калыр...» Шуңа күрә Хәлим бу турыда председательгә әйтмәскә булды. Башка бер йомыш йомышлаган булып чыгып китте. «Юк нәрсә артыннан йөрим бугай...» диде ул. Ләкин шул ук кичне булган җыелышта Зариф абзыйның кыланышын күреп, моның киресен уйлады.

Колхозның хәле һаман авыр иде әле. Аңардан, кеше рәтендә, язгы чәчүгә орлык, һич югында атларга ашату өчен он яки бәрәңге сорадылар. Ә ул, бөтен кеше, хәтта начаррак хәлле колхозчылар да әзме-күпме ярдәм итеп торганда, мескенгә салышып, умачлык та оным юк, иртәгә берәребезнең өс киемен базарга чыгарып сатмый булмый инде, дип утырды. Еламады гына ул шул җавапны биргәндә. Кем дә булса ышангандыр бәлки, ә Хәлим ышанмады. Хәлимнең ачуы килде:

«Ялганлыйсың. Умачлык та оның булмаса, Җәмиләң аякчулар чиктергән өчен он түләп ятмас иде әле»,— дип чак кына кычкырып салмады.— «Кычкырып ни файда? Алай дигәнгә карап бирәмени ул? Кыш көне кереп кар сорасаң, кар да бирмәс ул...»

Шул сәгатьтән башлап Хәлим Зариф абзыйны чын-чыннан дошман күреп йөрде. Шәйхаттар бабай әйткән «башкалар яраланган килеш һөҗүмгә барганда, сәламәт була торып чокырда качып ятучылар» рәтенә кертте ул аны һәм үзенең шиген комсомол секретарена әйтми булдыра алмады. Секретарь бу турыда хәзергә тавышланып йөрмәскә, күзәткәли торырга кушты. Хәлим иренмәде. Тормышлары турында Гөлгенәдән сорашты. Йомыш тапкан булып үзе дә өйләренә кереп чыкты. Көннәрдән беркөн авыл йоклагач, елга аръягына, Гөлгенәне куып тоткан канауга төшеп, Зариф абзыйлар йортына озаклап карап торды. Менә мунчалары, эно бәрәңге бакчалары, эно өйләре. Әгәр кеше сүзе дөрес икән, әгәр он сатып яталар икән, алучы шушыннан килергә тиеш.

Ләкин Зариф абзыйларга килүче-китүче булмады. Олы юлдан берән-сәрән атлылар, җәяүлеләр узып китте. Бер ят кеше аксак ат җитәкләп узды. Күрше авылның никтер соңга калган почтальоны йөгерә-туктый узып китте. Кунакка кайтучы булгандыр инде — кечкенә генә котомкалы бер фронтовик җилдәй узып китте. Канау буеннан алар узганда Хәлим карга тирән сеңеп, өстенә ак җәймә ябынып ятты.

Төн урталары җитеп килгәндә, юлда тагын берәү күренде. Хәлим аны тавышыннан таныды. Бу — Ибрай иде. Ибрайның күңеле күтәренке; әкрен генә «Шат күңелле яшьләр»не көйләп килә. Көйли-көйли дә сызгыргалап куя, кайбер сүзләрен, өйрәнеп өлгергәннәрен җырлап та җибәрә иде:

«Фч-фч-фч-фч-фч от песни фч-фч-фч
Она скучать фч-фч-фч никогда-а!..

— Әллә этисе кунакка кайткан микән моның? Әллә фронтта тагы берәр күңелле хәбәр бармы икән?

Хәлим, түземен җыеп, Ибрайның килеп җиткәнен көтә башлады. Ләкин Ибрай килеп җитмәде, кинәт борылып, елгага, үз мунчаларына таба төшеп китте.

— Тукта, тукта... Бу бит тагы кыек юлга баскан! — диде Хәлим үзенә-үзе.— Чанасында нәрсәдер бар...

Хәлим үзенең кайда икәнен, нишләп ятканын да онытып, җәймәсен дә салырга онытып, сикереп торды:

— Ибрай!

Ибрай туктады. Һәм, артына борылуына, әкиятләрдә сөйләнә торган өрәкне күргәч, а-а дип сузды да телсез-авызсыз калды. Хәлим, исенә төшеп, җәймәсен салды. Ибрай тынычлана төшкәч, күзләренә керердәй булып сорау бирде:

— Чананда нәрсә?

Ибрай гомер булмаганча шат иде, ул көлемсерәп, шаяртып куйды.

— Синеңчә, белмим, нәрсәдер. Минемчә, карама.

— Кайдан алдың?

— Елгадан тоттым дисәм, ышанмассың инде...

— Урладың?

Дөресен әйтергә дә, бетте-китте иде. Юк бит, Ибрай гел шаяртып маташты.

— Чанага үзләре менеп яттылар дисәм дә, ышанмыйсың инде син.

Шундый җинаять эшләгән, җитмәсә ачу китереп көлеп тора!.. Хәлим тәмам чыгырыннан чыкты:

— Эх син, пионер... Ә теге вакытта честный пионерский биргән булдың!..

Моны Хәлим менә нинди вакыйга исенә төшкәч әйтте.

Хәлим, беркөн өстәмә дәрестән кайтып килгәндә, Ибрайларның лапас асларында ут күреп, койма ярыкларыннан карады. Лапас астында, фонарь яктысында Ибрай салам турап тора, ә ишек алдында бер ят ат йөри иде. Менә Ибрайларның өйләреннән бер кеше, фатирга төшкән кеше, ат хуҗасы он алып чыкты. Алар Ибрай белән зур тагаракка салып башак болгаттылар. Кеше атны чакырып башакка кушты да өйгә кереп китте. Ә Ибрай, ул кереп китүгә, атны улак янына куып җибәреп, башакны ике чиләккә җыеп салды. Ат, Ибрайның күңеле дөреслектә түгел икәнне сизенде ахрысы, абына-сөртенә улак янына килде. Ибрай атның иреннәренә бер уч башак алып сылады да: «Аша, аша, малкай» дигән булып, чиләкләрен алып, урамга йөгереп чыкты. Ә капка төбендә Хәлимне күргәч, чиләкләрен чак кына төшереп җибәрмәде. Һәм, үзен бик тиз кулга алып, ялганларга тотынды. «Конюшняга барам ла... узгынчы атын кайгыртып йөреп, үзебезнең атка башак бирергә оныткан мын...»

— Күрдем мин синең узгынчы атын ничек кайгыртып йөргәнеңне!..

Ибрай дәшмәде.

— Кем аты ул?

— Милиция начальнигыныкы.

— Кемнеке, кемнеке?

— Милиция начальнигыныкы.

— Их син... Бар кире сал!..

Ибрай ул чакта еларга җитте. Зинһар, отрядка ишеттермә, моннан соң алай эшләмәм, диде. Ә хәзер әнә тагын...

Хәлим кулын изәде һәм бер читкә китә башлады:

— Юк инде, Керпе, синең бөкреңне төзәтсә дә, кабер генә төзәтер...

Ибрай кычкырып көлде.

— Ха-ха-ха... Ну тел синдә хәзер, әй. Миңа да берәр үлгән немецны күреп кайтмый булмас ахрысы.

Хәлим, әллә инде сугып җибәрү өчен, кинәт Ибрайга таба борылды. Шул чак тегесе, бүреген башыннан ике куллап алып, Хәлимгә сузды. Бүрек эчендә дүрткә бөкләнгән бер кәгазь ята иде.

— Наряд?

— Ә соң?

— Нигә аны башта ук әйтмәдең?

— Алай кызыгы булмый ич аның.

— Ә нишлисең ул карама белән?

— Берлек белән куплекне бутадың. Кара аны, егет, укытучы ишетеп, үзеңә казык утыртып куймасын...

— Ярый, ярый... Алайса, *нишлисез?*

Ибрай, сөйләнә-сөйләнә, Хәлимне үзләренең мунчаларына алып керде. Анда, сукыр лампа яктысында, Шәпи һәм тагын бер малай, кайсы карама бөгеп, кайсы юкәдән бау ишеп маташа иде. Ә идәндә ярыйсы гына итеп эшләнгән ике кечкенә чана тора иде.

Хәлим авызын ачты да, ни әйтергә белмичә, катып калды. Көнләште ул алардан. Мин бит моның бер бавын гына да ишә белмим, диде. Ә бераз вакыт аптырап карап торгач, әйтеп куйды:

— Менә бу — эш дисәң дә эш. Менә һөнәр бу... Кем өйрәтте, дуслар?

— Сабир абый, пожарный Сабир.

— Менә бу эш,— дип кабатлады Хәлим.— Табанын да үзегез бөктегезме?

— Ул нәрсә-ә! Әле боларын ясап саткач, йөк чанасы бөгәбез, зурны.

— Сез аларны сатасызмыни?

— Ә соң? Сатабыз да «Чалкаш»ка он алабыз.

Хәлим телен шапылдатып куйды. Көнләште ул, ләкин йөзенә чыгармады.

— Ә нигә дип аны яшерен эшлисез?

— Кем әйтте аны сиңа? Бөтенесе белә. Фәрдәнә дә, Шаһгәрәй абзый да... Беләсең килсә, Шаһгәрәй абзый безгә үзе әйтте. Сабир абзыйны да ул көндерде.

— Ә нигә миңа әйтмәдегез?..

Ибрай иңбашларын җыерып куйды:

— Бәйрәм ашы кара-каршы, иптәш.

Хәлим елмайган булды. Ә эченнән бик нык уңайсызланды. Ул үзенең кайдан, ни өчен кергәнен дә онытып, идәнгә тезләнде дә малайларның эшләгәннәрен сокланып күзәтә башлады. Ой, бик күңелле эш икән бу! Хәзер, бераз гына карап торсын да, үзе дә эшләп карар.

Шулай уйланып торганда, ишектә бер кочак мунчала күтәргән малай күренде. Бу Каюм иде. Килгәндә, күрәсең, кырыкмаса-кырык егылгандыр, өсте-башы кар гына... Ул бусаганы атлар-атламас мунчаласын идәнгә ташлады да, берсенә дә күтәрелеп карамыйча, өстен кагарга тотынды. Кар бөртекләре җылы идәнгә төшеп эри бардылар.

— Һа-а, Каюм!.. Нигә озак тордың, марай?

Каюм болай да ачулы иде, Ибрайны күргәч, тагы да усаллана төште.

— Куянны үзең кебек шыр тиле дип белгәнсең шул...— диде ул аңа.— Я инде, Колмәмәт чокырына капкын куйганны кайчан күргәнең бар?..

— Ха-ха-ха!.. Әллә минем капкынга эләктеңме, Каюм марай?

— Ермасана шул авызыңны, Черки төре,— диде Каюм һәм Шәпигә зарланып куйды:

— Тизрәк кайтып җитим дип шул чокыр аша гына киткән булган идем... Ташлап калдырырга җиттем.

— Әле дә ничек аягыңны имгәтмәгәнсең.

— Читкә тайпылып калдым. Ә анда көрт икән. Чыгалмыйча ярты сәгать азапланганмындыр...

Каюмны кызгансалар да бу юлы барысы да көлештеләр.

Шул чак, мунча түреннән, баскан саен ярма карны шыгырдатып, кемдер узып китте. Китә бирсен. Берсе дә аның белән кызыксынмады. Ә Хәлим кызыксынды. «Тукта, тукта. Тегендә таба китте бит бу...» Хәлим, кайтып ятарга кирәк диган булып, алгы якка чыкты. Анда, елга буйлап, кемдер кечкенә чана тартып бара иде. Кеше, барды-барды да, бик аз гына туктап торды һәм, кисәк борылып, менә сиңа кирәк булса, Зариф абзыйларга таба китте. Мунчалары турына җиткәч, чанасын калдырып, ярдан күтәрелде ул һәм бәрәңге бакчаларына менгәч, күренмәс булды. Хәлим, җаймасенә төренеп, аның артыннан мунчага кадәр килде. Ярдан күтәрелеп менде дә карга ятты. Кеше Зариф абзыйларның арт капкаларыннан кереп югалды. Ул да түгел, капкадан бер хатын-кыз чыгып, мунчага таба килә башлады.

Бу — Зариф абзый кызы Җәмилә иде.

Хәлим артка шуыша-шуыша елга өстенә кадәр төште дә тын гына күзәтеп ятты. Җәмилә, ярдан төшеп, мунчаларына керде. Шактый торып чыкты ул анда. Чыкты да ишек төбендәге чанага нидер салып бәйләде. Көрткәрәк этеп куйды ул чананы һәм ярдан менеп китте. Хәлим, аның аяк тавышлары ерагаюга, мәчедәй сак атлап, чана янына килде: чанада капчык, капчыкта әллә арпа, әллә бодай иде.

«Нишләргә? — Мәрфуга районда ниндидер җыелышта. Председательгә йөгерергә кала... Ә Хәлим әйләнеп килгәнче, Зариф абзыйларга кереп калган кеше чанасын алып китсә? Әллә Ибрайлар мунчасына кертеп торыргамы?

Хәлим бер карарга да килә алмый калды, Зариф абзыйларның арт капкасы шыгырдап ачылды. Капкада кеше шәүләсе күренде. Хәлим яңадан кар эченә кереп чумды. Бу — шул, баягы кеше иде. Ул китәр уңайда торган чанасын алды да елгага төште.

Хәлим, аның артыннан барырмын, кайсы авылга, кайсы йортка кергәнен күзәтермен, дип уйлаган иде. Ләкин моның кирәге калмады: кеше Хәлимгә якын гына үтеп китте. Хәлим аны таныды. Зариф абзыйның Ташлыярдагы кияве — чулак Миңсафа иде бу.

Миңсафа, юлга күтәрелеп менеп, әз генә баруга, төнге буран эчендә күздән югалды.

Мәсьәлә ачык. Хәлим колхоз председателен уятырга йөгерде һәм кылт туктап калды.— «Бәлки Миңсафа

базардан кайтышлый, үзенекен куеп торгандыр да, хәзер шуны килеп алгандыр?.. Башта мунчага кереп карап чыксын әле, анда тагы да ашлык була калса, барып уятыр...

Хәлим тиз генә мунча ишеге төбенә килде. Колагын бәрәңге бакчасы ягына сузып тыңлап торды да, мунча өйалдына кереп, ишеген ачып җибәрде. Эчтән бүген генә ягылган мунчаның җылы пары килеп бәрелде. Тәрәзәдә калын маскировка булганлыктан, мунча эче кабер шикелле караңгы иде. Хәлим Каюм бүләк иткән кесә фонарен кабызды. Фонарь яктысы белән мунчаның һәр җирен капшап чыкты: ләүкә өстен, ләүкә астын, мичне, почмакларны, су кисмәге артларын. Ләкин һичкайда, һичбер шикле нәрсә юк иде.

Хәлим, өстенә килеп керүләреннән куркып, мунчадан чыкты. Аяк тавышлары ишетмәгәч, тагын керде, чормасына менеп төште һәм, әз генә дә шикле нәрсә тапмыйча, өенә кайтып китте.

Ул ике кич мунча тирәсенә бармады. Зарифлар турында уйламаска тырышты. Ә өченче көн кич, ялга каршы кичтә, мунча янына тагы килде. Һәм, бер дә курыкмыйча эчкә кереп, аның һәрбер ноктасын актарырга тотынды. Бу юлы беркөнге шикелле каушамады ул. Чөнки өскә килеп чыгуларыннан курка торган түгел, иң якын ике иптәше — Каюм үз янында, ә Гөлгенә мунча ишеге төбендә сакта тора иде. Берәр кеше килгәнне күрсә яки арт капка ягыннан аяк тавышлары ишетсә, кыз тиз генә Хәлимнәргә хәбәр итәргә тиеш иде.

Кыз хәбәр итмәде.

Димәк, тышта тыныч.

Хәлимнәр тыныч кына эшләрендә булдылар. Алар инде мунчаның бөтен җирен карап чыктылар. Идәнгә кагылган кадакларга кадәр әһәмият бирделәр алар: яңа кагылганмы, әллә күптәнме? Су кисмәкләрен кузгатып карадылар: астында баз-мазар юкмы? Ләүкә астын карадылар: шунда күммәгәннәрме? Аптырагач, башка карар җир калмагач, мич өстендәге ташларны актарып бетерделәр. Мич өстенә, һәрбер кара мунчадагыча, гади таш өелгән, таш араларында сыпык кендек, ватык йозак, шомарып беткән игәү кебек тимер-томыр күп иде. Казына торгач, мич төбеннән әллә нинди бик зур ике бакыр акча да килеп чыкты.

Каюм акчаларны күрүгә дөньясын онытты. Күзләре янды аның. «Тарих кабинетына экспонат менә кайда ул! 1700 елда сугылган, Петр Первый заманында!..»

Каюм аларны кесәсенә шудыру өчен чалбарына ышкый башлады. Хәлим башын чайкады:

— Ярамый.

— Мин аның урынына ике сынык дага китерен салам..., юк, өчне...

— Куй урынына.

— Барыбер әрәм ята ич...

— Ята бирсен.

Каюм теләмичә генә акчаларны мич төбенә салды.

Малайлар ташларны, тимерләрне элеккегечә итеп мич өстенә тезделәр дә ләүкә астына керделәр.

Ләүкә астының идәне юк, нибары бер тактасы бар иде. Үзләреннән соң эз калдырмас өчен, малайлар шул тактага тезләнделәр. Еш кына юынтык су агып төшкәнлектән, ләүкә асты сазлыкка әйләнгән, анда-санда бакалар сикерешәләр... Әлбәттә биредә һичнинди ашлык булуы мөмкин түгел иде.

Тагын кайдан карасыннар инде малайлар, нидән шикләнсеннәр? Андый җир юк. Хәлим, мунчада ашлык юклыкка тәмам ышанып, фонарен сүндерде.

«Кара инде мин тилене! Иптәшләрне кузгатып йөрү нигә кирәк булган миңа, җә? Имеш, күрегез дә торыгыз, тапмый калмыйбыз. Таптык. Хәзер боларга нәрсә дияргә инде?.. Хурлык бит, билләһи...»

Каюм да иптәшенең уңайсызланганын сизә, мунчада бодай түгел, көрпәсе дә юк икәнен күреп тора, хәзер аңар бары: төкер, Хәлим, әйдә кайтыйк, Гөлгенә дә туңа торгандыр, диярге генә калган иде. Ләкин ул моны эшләмәде. Тактага тезләнгән хәлдә, мунчада күргән, тотып караган нәрсәләрен күз алдына китереп үтте. Шул әйберләр арасында әз генә булса да шикләнерлек деталь юкмы? Юк бит. Тукта, ә менә ләүкә астында ярык җамаяк белән кызыл балчык бар. Нигә анда ул?

— Хәлим, син ләүкә астында җамаяк белән кызыл балчык күрдеңме?

— Соң?

— Синеңчә, нигә ул?

Хәлим фонарь кабызды. Фонарь яктысы белән җамаякны капшап тапты:

— Мич ярыкларын сыларга, билгеле.

Әйе, мич кырыкмаса-кырык җирдән сыланып беткән, ләкин күптән сыланган, һәрбер сылау өстенә калын корым утырган иде.

Тукта, тукта... Хәлим яңадан ләүкә астына керде. Бу мунчаның ярга терәп салынган стенасы Никкүчтем мунчаларының һәрберсенеке кебек үк зур-зур ташлардан түшәлгән, аралары бик нөхтә итеп кызыл балчык белән сыланган иде. Хәлим шул балчыкларга җентекләп карап торды. Аларның да сылаулары, мичнеке кебек үк искереп, катып беткән иде. Шулай булгач, бу яңа изелгән кызыл балчык нигә биредә?

Хәлим стена ташларына сыланган кызыл балчык өстендә имән бармагын йөртә башлады. Һәм үзенең болай вакланууыннан, нигезсез төпченүеннән үзе дә уңайсызланып китте.

— Тот капчыгыңны, ярыкка бодай тутырганнар ди!.. Һәй, хыялый да инде мин,— диде ул һәм, иң кечкенә таш әйләнәсенә сыланган балчык буенча өстән аска төшеп килгән бармагын ачу белән басып куйды. Бармак... менә сиңа кирәк булса... балчыкка батты. Бүтән таш араларындагы балчыкка төртеп карады, бармак батмады. Хәлим бармагын яңадан кечкенә таш әйләнәсендәге ярыкка батырды. Һәм шул хәлдә таш әйләнәсендә йөртте. Балчык буе белән бармакка сыланып, кубып төште.

— Димәк, бу таш яңа гына сыланган, Каюм?

— Яңа гына.

— Ә нишләп яңа гына? — Хәлим ташны кузгатып карамакчы булды, таш тотынуга кубып төште. Аның артында дымлы гади җир — яр кырые күренеп тора иде.

Хәлим тагын эченнән генә, хыялый да син инде мин, дип куйды һәм:

— Шулай да ташны яңа гына сылау нигә кирәк булды икән, ә Каюм? — диде.

Каюм, дустының сүзләрен санга алмаган кебегрәк итеп, ачу китерә торганрак итеп, әйтеп куйды:

— Купкан, шуңа күрә сыларга кирәк булган. Әйдә, Хәлим, малай, урынына куйыйк та чыгыйк,— диде ул һәм куптарылган ташны урынына кертеп куйганда, аның артында сәер бер дөбердәү ишетеп әсәрләнә калды.

— Нәрсә бар, Каюм?

Каюм дәшмәде. Ул ташны идәнгә куеп, бармагын таш артындагы дымлы җиргә тыкты. Бармак яртылаш

батты һәм тактага терәлде.— Иһи-и... Хәлим, фонарьны болайгарак суз әле,— диде Каюм һәм каушый-каушый такта өстендәге балчыкны сыпырып төшерде.

— Нәрсәдер бар, Хәлим.

— Бар.

— Тактасы алына.

— Ал әле.

Каюм тактаны (ул нәкъ таш күләмендә иде) күтәрып алды. Аның артыннан, әкият диярсең, комбайн бункерыннан аккан шикелле, менә дигән эре бодай шыбырдап ага башлады. Малайлар бер секунд аңышмыйча, нишләргә белмичә тордылар. Аннары тактаны тишеккә томалап куйдылар да тышка йөгереп чыктылар.

Каушауларыннан фонарьны сүндерергә дә онытканнар иде алар. Хәлим, Гөлгенә әйткәч кенә сүндереп, кесәсенә тыкты. Һәм аптырашта калган кызны өченче көн үзе качып яткан җиргә яткырды да өстенә ак җәймәне япты.

— Килгән-киткәнне шуннан карап ят, Гөлгенә, без хәзер...

Каюм белән Хәлим җан-фәрманга каядыр йөгереп киттеләр. Унбиш минут үтүгә — Гөлгенә өчен бер төн булып тоелган унбиш минут үтүгә, үзләре белән колхоз председателен һәм участок милиционерын ияртеп килеп җиттеләр.

Участковый Зариф абзыйны һәм Җәмиләне уятып алып чыкты.

— Бу нишләвегез инде, беркемгә төшермәгән тентүне тотасыз да безгә төшерәсез, тотасыз да безгә төшерәсез! — дип сукранып торган булды Җәмилә. Ә этисе алай итмәде. Малайларның аякларына ияреп чыккан бодай бөртекләрен күрүгә, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алган иде ул, телсез-авызсыз калды.

Кешеләр ләүкә астына кереп, әлеге тишекне ачып җибәрделәр. Һәм, Җәмилә белән этисеннән башкалар, барысы да таң калдылар: мунча стенасыннан, сайлап салган шикелле, эре-эре бөртекле бодай ага башлады.

— Ә кайдан килгән, кайдан салганнар аны анда?

— Кайдан салдыгыз?

Гаеплеләр әйтмәделәр.

Бодай акты да акты. Ярты төн авышканчы акты бодай. 16 капчык. Колхоз амбарына алып кайтып үлчәделәр. 72 пот килде. Бодай чыккан урынны һәм аның

анда ничек салынганын белү өчен, мунчаның яр як стенасын сүтеп ташладылар.

Мунча стенасы артына, яр эченә кертеп, кечкенә генә такта бура ясалган, бодайны бурага агызу өчен, мунча чормасыннан арба кендегеннән әз генә юан труба сузылган иде.

Хәбәр таң атар-атмас бөтен авылга таралып өлгерде. Карты-яше җинаять ачылган урынга җыйналды.

Колхозчылар хәйран калдылар. Алар гына түгел, үз гомерендә әллә никадәр, әллә ни төрле җинаятьләр ачкан зур тәҗрибәле милиционер да шаккатып, гел башын чайкап торды. Җинаятьчеләргә әйтер сүз таба алмады.

— Вәт контрлар, вәт корткычлар,— диде ул һәм бертуктаусыз тәмәке төтене саргайткан ак мыегын чәйнәде.

Ә 72 потның, Зариф кияве Миңсафа аркылы инде сатылып өлгергән 24 потның, малларына ашатылган хисапсыз күп потларның бурага кайдан килеп кергәне ачылгач, халык җинаятьчеләрне өзгәләп ташларга җитеп ярсыды.

Бу бодай — былтыр чәчелергә тиешле чәчү орлыгы була. Аны колхозчылар кышның кыш буена күз карасыдай күреп, саклап чыгалар. Зур уңыш бирсен дип, бөртекләп чистарталар. Ә Зариф аның бик аз өлешен генә чәчә дә, күбесен яшереп калдыра һәм, кызы Җәмилә белән бергәләп, үз өйләренә ташый. Йөз поттан артык чәчү орлыгын, ягъни аз дигәндә мең пот булып үсәчәк бодайны ташыйлар алар өйләренә. Шуның аркасында колхозчылар хөкүмәт заданиесен көчкә генә үтәп чыгалар, башка колхозлар рәтендә Кызыл Армиягә икмәк бүләк итә алмыйлар. Чәчү орлыклары җитәр-җитмәс кала. Уңышны да бик әз бүләләр. Күп кенә семьялар алдагы елдан калган икмәкләре белән канәгатьләнеп яшәргә мәҗбүр булалар.

Сүтелгән мунча янында җинаять ачылу уңае белән җыелыш башланып китте. Гадәттәгечә авыл советы председателе яки колхоз председателе ачмады бу җыелышны. Җыелыш үзеннән-үзе ачылды.

— Менә сезгә мәчет карты, тәкъва кеше! Менә сезгә яхшы ата баласы! — диде башлап сөйләүче колхозчы.— Без бодайның бер бөртеген ничек ике итәргә белми йөрибез, ә ул!..

— Бал башына житүче дә үзе булган инде, алайса...

— Шул чакта ук әйттем мин сезгә: Зарифулла эше дидем.

— Сугыштан соң батыр күп була...

Участковый мәкаль белән җавап бирүчегә сораулы карады. Тегесе аңлатып бирде:

— Зарифулла кладовщик чакта колхоз амбарыннан бик күп бал югалган иде. Каравылчы карт өзгәләнә: төнлә бер дә килүче-китүче булмады, Зарифулла көндез үзе берәр хәл эшләткәндер, ди. Ну пломба купкан, йозак ватык. Суд каравылчыга: йоклап урлаткан дип, 10 ел чәпеде, Зарифны аклады. Колхоз да эшеннән чыгару белән чикләнде.

— Ипи алып ант итте бит.

— Ант... Антны итә инде ул андый...

— Колхозның явыз дошманы булып чыктың син, Зарифулла абзый,— диде колхоз председателе,— без бит сине, әйбәт чәчүче дигән булып, кадерләп тоттык. Сырхавыңа ярамый дигәч, болай да җитешмәгән чәчү бодаен тарттырып ашаттык. Балына, маена кадәр биреп тордык бит...

Рәхимә апага, узган көз, өченче кеше булып тәрбиягә ат сорап алган күп балалы тол хатынга, председательнең сүзләре артык төче тоелды. Ул, кешеләрне этә-төртә, җинаятьчеләр каршысына барып басты:

— Кеше үз авызыннан өзеп колхозга биргәндә, сез тиф бетләре шикелле, ил тәненә ябышып... тфү, кабахәтләр!..— диде ул, башта Зариф абзыйга омтылды, аннары, ахры олы кеше дип килештермәде, Җәмиләнең битенә лач итеп төкерде.

Зариф абзый бизгәк тоткан кеше шикелле калтыранды.

Әнә аның сугыш башланганда гына салынып беткән зур өе. Әнә йорты тулы мал-туар, өе тулы кием-салым, җиһазлар... Әлбәттә, конфисковать итәрләр...

Зариф шашынып кычкырып җибәрде:

— Кичерегез, кардәшләр! Шайтан вәсвәсәсе булган... Мин үземнең бу гөнаһымны юармын. Эшләрмен дип кенә әйтмим, колхозның идәнен чәчем белән себерермен...— диде ул һәм бу кара хәбәрне ишетеп үлем түшәгеннән торып килгән этисенең аягына егылды. Этисе булганга түгел, авылның иң игътибарлы кешесе булганга, зур мәсьәләләрне хәл иткәндә халык һәркайчан аның киңәше белән хисаплашканга, хөрмәт йөзеннән олысы-

кечсе аны Акбабай дип йөргәнгә егылды ул аның аягына. Һәм аның аякларының әле берсен, әле икенчесен кочып елый башлады:

— Кичер мине, эти!.. Сора минем өчен халыктан!..

Акбабайның сакалы төсле үк ак йөзенә, ап-ак кашлары астындагы тонык күзләренә карап, аның фикерен көтте халык. Акбабай кызганыч сыкранып:

— Кит, Зарифулла,— диде,— туксан яшемә житеп тузан кадәр кер кунмаган намусымны таптадың син минем. Бөтен нәсел-нәсәбем исеменә тап төшердең. Бөтен авыл йөзенә кара яктың, бәдбәхет!

Акбабай кулындагы таягы белән Зариф абзыйның ике каш арасына каты итеп төртте. Һәм, калтыранган аякларын көч-хәл белән кузгатып, бер читкә борылды. Бу вакытта аның гәүдәсе, һәрбер агзасы, хәтта һәрбер сакал бөртеге калтырана иде. Аны йомшак кына тотып, мунча стенасыннан сүтеп алынган таш өстенә утырттылар. Акбабай бераз хәл алды да дәвам итте:

— Әгәр бу хәлдән соң сезнең алда сүзләремә колак салдыра алырлык дәрәҗәм калган булса, шулай итегез: тугры судтан сорагыз, законы бар икән, асып үтерергә хөкем итсен бу бәдбәхетләрне...

Колхозчылар Акбабайның сүзләрен күтәреп алдылар:

— Асып үтерергә хөкем итсен!

Зариф белән Җәмиләне районга алып киткәч, колхоз җыелышында шушы турыда карар чыгарып, прокурорга илтеп бирделәр. Аннан соң колхозчылар бер-берсен уяу булырга чакырып, Хәлимгә һәм аның дусларына катькат рәхмәтләр әйтеп, өйләренә таралдылар.

Өченче кисәк

1

ЯЗ ҖИТӘ БИТ...

Табигатьтә яз билгеләре күренә башлады.

Ерактагы кара урман, ничектер, күгелҗемләнеп, яшәреп китте. Көн урталарында урман өстендә җиңел зәңгәр нур балкып торды. Өй түрендәге миләш ботаклары яшелрәк төскә керделәр. Түбәләрдә кыш буе ак мамык шикелле күпереп яткан карлар, тыгызланып басылып киттеләр. Түбә читләрендә карандаш очы тикле генә бозлар күренде. Аннан бик тиз зурайдылар бозлар, озынайдылар, штык кебек булып сузылдылар. Чана юллары беләүләнеп шомардылар, аннан каралдылар чана юллары. Менә яз хәбәрчеләре — кара каргалар килеп, су буендагы биек талларга, тирәк башларына оя кордылар.

Кояш хәзер җиргә турырак карады, ышык җирләрдә сизелерлек җылытты. Тереклек чыганагы — кояш табигатькә әнә шулай әкренләп җан кертте. Эшкә дәрт артты кешеләрдә, күңелләр күтәрелде. Һәр җирдә язгы ыгы-зыгы башланды. Тимерчелектә чек-чек чүкеч тавышлары иртә таңнан кара төнгә кадәр ишетелеп торды хәзер. Тәгәрмәч тырнакларына, тугым ярыкларына сырышкан карларын тузгытып беренче арбалар узды урамнан. Дөп-дөп сулап, эрүсәгән карда тирән эз калдырып, МТСтан трактор килеп җитте. Чәчү машиналары, сабан-тырмалар барланды, амбар ишекләре ачылды.

Пионерларга да җан кертте кояш. Бөтен мәктәп ниндидер бер җиңеллек белән селкенеп куйды. Балаларның үз ыгы-зыгылары башланды. Тиздән имтиханнар! Җиденчегә күчәбез! Җиденчегә! Ә күчәрбезме? Моны ал-

тынчы класста хәзер Ибрай белән укуы озак бүленеп торган Гаяз гына әйтте. Хәлимдә исә бу шик көннән-көн кими барды. Ул финишка җиткәндә бөтен көчен, бөтен сәләтен салып йөгергән чабышчы кебек тырышты. Ул хәзер гади генә күчү өчен түгел, мактау грамотасы белән күчү өчен тырыша иде.

Хәстәрен алдан күрергә өйрәнгән балалар инде яңа дәреслекләр турында, алдагы ел өчен карандаш-каләм турында кайгырттылар.

— Җиденчедә химия керә ди, малайлар.

— Нәрсә соң ул?

— Әллә белмисең? Фи-и... Зрә тәмле, Гөлчәһрә марай. Без алдык. Сельпога кайткан.

— Җыен тозсыз синең авызда.

— Миңа тозлы ярамый. Саруны кайната.

— Сару кайнаганга акбур шәп. Бар, юлда туйганчы ашарсың, «Илшат»ка барып акбур алып кайт. Менә язуы...— Кызлар Ибрайны мәктәптән этә-төртә чыгарып җибәрделәр.

Ибрай җәберсенмәде. Сүз нинди акбур турында барганын белә иде ул. Мәктәп сторожыннан капчык сорап алды да, этен ияртеп, Акбуага китте.

Эш шунда ки, кызлар классны имтиханга аеруча матур итеп бизәргә булдылар. Кояш туры карый башлау белән, парникка гөлләр, чәчәкләр утырттылар. Кем мич агарта, кем идәнен юа, кем кызыл денталар, бизәкле кәгазьләр таба, кем урманнан ылыс алып кайта,— үзара шуларны бүлешеп алдылар.

Эш җитәрлек иде.

Шулай да пионерлар кырга, басуга күз төшереп алырга да вакыт таба иделәр. Менә бүген дә алар басудагы күгелҗемләнеп килгән карга, кар астыннан чыгып килгән тирес өемнәренә карап, үзара сөйләшеп алдылар:

— Яз җитә бит!..

— Җитә...

Бу сөйләшүләрдә шатлык, рух күтәренкелеге һәм дәрт бар иде. Шул ук вакытта, бу сөйләшүләрдә борчылу да сизелә иде.

Ничек шатланмаска! Яз килә. Гади яз түгел, зур сынаулар язы. Бу язда пионерлар зур сынау үтәргә, шуның белән фронтка ярдәм итәргә, ил алдында мактауга ирешергә тиешләр.

Ә ничек борчылмаска! Бу сынау бик авыр булачак. Көчеңне кызганмыйча, ару-талуны белмичә көн-төн эшләргә туры киләчәк. Ләкин куркынычы ансы түгел әле. Шулай тырышып-тырышып та көлкегә калуың ихтимал, эшнең барып чыкмавы ихтимал — менә нәрсәсе куркыныч аның.

Ә нинди эш соң ул?

Җиһан корткыч Гитлер явы, Сталинград янында камалып тар-мар ителгәннән соң, чигенә башлады. Ләкин граница ерак иде әле. Дошман ил эченә бик тирән үтеп кергән иде. Ул бернникадәр чигенде дә туктап көч туплады. Тагын һөҗүмгә күчте. Тагын чигенде. Бер җирдә чигенде ул, икенче җирдә ярсып һөҗүм итте. Дошманны илдән куып чыгарырга кирәк иде. Оясына кереп, моннан болай беркайчан да баш күтәрә алмаслык итеп, кыйнап ташларга кирәк иде. Моның өчен халык үзенең улларын фронтка җибәрә торды. Корал җитешмәде, корал торган саен күбрәк кирәк булды, аны көн-төн завод эшләде. Икмәк җитешмәде, икмәк торган саен күбрәк кирәк булды, аны колхоз бирде. Ләкин аны үстерү елдан-ел кыенлашты, ахыр чиктә кыенлашты. Фронтка киткән трактор өчен дә, фронтка киткән ат өчен дә, фронтка киткән ир өчен дә — хатын-кызлар, яшүсмерләр, карт-корылар эшләргә тиеш булдылар. Колхоз кырларында һәр килограмм икмәк өчен авыр көрәш барды. Ә ул миллион, миллиард, әллә ничә миллиард пот кирәк иде.

Һәр башакны штыкка тиңләде хөкүмәт.

— Штыксыз җиңеп булмый, иписез дә шулай ук. Икмәк! Икмәк! — диде хөкүмәт.

Хөкүмәтнең бу авазын колхозчылар гына түгел, пионерлар да ишеттеләр. Һәм алар фронт өчен үз куллары белән икмәк үстереп бирергә булдылар.

— Яз җитә бит...

Моны әйтү белән пионерлар, кар китәр-китмәс калкып чыгачак умырзая чәчәкләрен түгел, сабанны, сабанга җигелгән арык атларны күз алдына китерделәр.

— Яз җитә бит!..

Моны әйтү белән пионерлар, хәтфәдәй яшел болыннарны, су буйларын, кармак таякларын түгел, сөреләчәк буразналарны күз алдына китерделәр.

Пионерлар кышкы каникулларыннан соңгы беренче

сборларында ук колхоздан ун гектар җир сорап алырга ла, баштанаяк үзләре эшкәртеп, шунда бер мең пот икмәк үстереп, Қызыл Армиягә бүләк итәргә, дигән карар чыгардылар. Қарарны педсовет та, колхозның комсомол оешмасы да хуп күрде, ә класс җитәкчесе Тәзкирә апа күтәреп кенә алды.

— Шул ук вакытта бу бит әле биология буенча практик эш тә булачак...

Тәзкирә апа пионерларның бу эшләренә җитәкчелек итүне педсоветтан үзе сорап алды. Ә менә колхоз идарәсендә исә шикләнебрәк карадылар.

— Әллә маташып йөрмисезме? Утарсыз, башак җыярсыз. Ә хәзергә әнә атларны карый торыгыз.

— Анысы качмас, анысы да безнең эш. Ә ун гектарны без баштанаяк үзебез эшкәртеп, орлыгын да үзебез юнәтеп чәчәргә телибез.

— Орлыгын да үзегез юнәтеп?

— Үзебез юнәтеп.

— Әллә Зарифулланың тагын берәр бурасын тузгыттыгызмы, югыйсә?

— Әзерләгән, ди.

— Бик эредән кубалар бит. Шуңа әйтүем.

— Бер дә эрәм түгел, абыйлар.

— Җире дә юк бит аның якын-тирәдә генә.

— Ерактан бирегез.

— Һм-м... Нишләргә соң сезнең белән?..

Қолхоз идарәсе пионерларга үзләре сораган кадәр — ун гектар җил үлчәп бирде. Бу җир авылдан әллә ни ерак булмаса да, әйбәттән түгел иде, тунга сөрелмәгән, бу елгы сабанга бөтенләй планлаштырылмаган, эрем баскан ташландык җир иде ул. Шулай да пионерлар аны шатланып кабул иттеләр һәм шул ук көнне һәр дүрт почмагына түгәрәк кызыл такталар кадап куйдылар: «Пионерлар участогы». Аннан тагы идарәгә килделәр:

— Сөрергә ат та бирегез инде.

— Ярар, бирербез. Сабанга ерак әле. Барыгыз, укый торыгыз.

— Юк, хәзердән билгеләп куегыз сез.

— Әйдә инде, күңелләре булсын...— Идарә членнары пионерларга Хәлимнәрнең Шәехтәен, Қаюмнар тәрбияли торган «Чалкашны», дүрт пионер кушылып тәрбияли

торган тагын бер атны билгеләделәр. Билгеләп кенә калмадылар, бертуктаусыз керә-керә аптыратып бетергәч, атларны пионерлар исеменә язып та куйдылар. Шул ук вакытта аларны шыпырт кына колхоз эшенә планлаштырдылар:

— Эшләре барып чыкмый аларның. Дөрес, Хәлим шикеллеләре сабанны бераз маташтырыр да инде, ә орлыкны кайдан алсыннар ди? Тиресне ничек чыгарсыннар? Әйдә инде, яз житкәнче мавыгып йөреп торсыннар. Бозлар киткәч, елгада кызыл канат белән чабак чиртә башлагач, үзләре үк онытырлар әле...— диделәр идарә кешеләре.

Ләкин пионерлар онытмадылар, уй-теләкләре житди иде аларның. Колхоз басуы бирә торганнан ике өлеш (һәр гектардан йөз пот) уңыш алуны үзләренең карарларына язып куйдылар һәм, шуны тормышка ашыру буенча, жиң сызганып эшкә керештеләр.

Һәр гектардан йөз пот!

Пионерлар бу теләккә ирешү өчен бөтенесен эшләделәр. Февраль бураннары башланганчы ук, кечкенә чаналар белән урманнан чыбык-чабык алып кайтып, үзләренең ун гектар жирләрендә кар тоттылар. Уку йортында, мәктәп китапханәсендә иген үстерүгә карата нинди китап, журнал бар — алып кайтып, мул уңышка ирешүнең серен эзләделәр.

Тәзкирә апалары — бу тәжрибәле биолог — балаларга эше һәм киңәшләре белән ярдәм итте. Пионерлар белән барып, ун гектарның төрле жиреннән туфрак алып кайтып, үзләреннән анализ ясатты.

— «Туфрагыгызда чүп үлән орлыгы күп... Ә, юк, утарга аннан соң да кала әле ул... Менә нәрсә, кар киткәч тә жирне агуларга туры киләчәк. Аннан жирегез кызыл балчыклы, тирес күп сорый торган... Болай итәргә туры килер...»

Балалар аның ярдәме, аның киңәшләре белән генә канәгать булмыйча, район агрономының колхозга килгәнен көтеп алып, мәктәпләренә алып керделәр дә, мул уңыш алуның серләрен сораштылар. Колхозлашу елларының пионеры, хәзер тәжрибәле агроном, бу турыда пионерларга рәхәтләнеп киңәшләр бирде. Ул пионерлар белән кара төнгә кадәр сөйләшеп утырды. Ә тирес турында Тәзкирә апа әйткәнне үк әйтте:

— ...Ни чәчсәң дә тиресләмичә ярамый, тиресләргә кирәк,— диде ул.— Уңыш алыйк дисәгез, һәр гектарына 30 тоннадан да ким чыгармагыз сез тиресне. Чыгаргач таратып ташламагыз, әйбәтләп өеп куегыз.

— Тирес... Һәр гектарга утыз тонна тирес... Ай-яй...

Пионерларның күбесе бу эштән баш тартты. Хәлим, Фәрдәнә, Гөлгенә, Каюм кебек актив пионерлар да, әллә инде тиресе булмаса да ярар микән, диештеләр.

«Эше кызыклы түгел, исе киемгә сеңеп бетә, үзе бик күп кирәк икән, җитмәсә. Әйдә, ансыз да ярар ла...» Пионерлар агрономны озаткач, шулай диделәр. Ләкин иртән мәктәпкә җыелып киңәшкәч, бу уйларыннан кайтып, тирес ташырга дигән фикергә килделәр.

— Тирес ташырга!..

Һәр гектардан йөз пот уңыш! Мең пот икмәк! Фронт өчен мең пот икмәк! Җиңү өчен мең пот икмәк! Кызыл Армия өчен, безнең тормышыбызны, безнең тыныч укуыбызны, безнең шат киләчәгебезне, без укыячак институтларны саклаучы Кызыл Армиягә мең пот икмәк! — Исе сеңсә сеңәр инде, авыр булса булыр инде, түзәргә кирәк, көчне кызганмаска кирәк.

Һәм пионерлар көчләрен кызганмадылар. Дәрестән кайтып ашап-эчкәч, барысы да түгел, активрак сигез пионер, кечкенә чаналарга салып, ат, сыер абзарларыннан басуларына тирес ташыдылар.

Көлүчеләр әз булмады:

— Һәй, булмый, малайлар. Ат белән ташып та житкереп булмый әле аны. Сезнең бу тирес җирнең ирененә сөртергә дә җитә торган түгел.

Әйе, сигез кечкенә чана белән сигез бала әллә ни кыра алмый икән шул. Өч көн ташыдылар инде алар кырга тиресне, ә ул, якын барып карамасаң, күренерлек тә түгел иде.

— Чынлап та, җирнең ирененә сөртерлек кенә булды бит әле бу!

Кайда-кайда, мондый чакта Ибрай тыгылмыйча каламы соң! Башта ул зур башын артка ташлап, зур авызын чабата тикле ерып, тыңлаучыларга күз йөртеп чыкты, аннан болай диде:

— Кырга чыккан идем әле, марайрар, абынып егылдым. Әллә инде Муллаәхмәт абзыйның теге вакытта

башыннан төшеп калган бүреге булды, әллә безнең Хәлимнәр ташыган тирес...

Бер, булыр дип, бер, булмас дип икеләнеп йөргән пионерларга, әлбәттә, тәэсир итте бу. Ә күпчелек пионерлар күңелләрен төшермәделәр. Көлүчеләрне тыңламадылар. Бүген аз икән, иртәгә күбрәк булыр. Берсекөнгә тагы да күбәер...

Дүртенче көнне пионерлар дәрескә кадәр дә берәр юл илтеп кайттылар. Элек дәрестән соң ике тапкыр баралар иде, бүген өч бардылар. Шулай итә торгач, атна дигәндә, пионерлар җире өстендәге тирес өемнәре авыл башыннан да күренерлек булып үстеләр.

Ибрай тагын кысылмый калмады:

— Кара, әле генә мин дә күргән кебек булган идем, кая китте соң, чәнчелгән... Ә, карга каплап тора икән,— дигән булды.

Ибрай моңысы өчен кирәген алды. Нәрсәгәдер бик ачуы килеп узып барган Закирҗан бабай башта таягы белән Ибрайның кабыргасына төртте, аннан болай диде:

— Ә, юк инде, хәзер карга түгел, син алап та томалый алмаслык булган. Их сине, сине!.. Сиңа да хәрәм булмас иде, югыйсә. Тфү, тәре баганасы, бу кадәр бабаң мәрхүмгә ошарсың икән...

Шуннан Ибраһим шып булды. Тирес турында сүз чыкканда, көлү түгел, авызын да ачмас булды малаең.

Ә якшәмбе көн пионерлар, укытучылар җитәкчелегендә, зур өмә оештырдылар. Башта алар берничә көн классларга кереп балаларны өндәп йөрделәр.

— «Мине әни җибәрми»,— пионерлар һәм укытучылар кичен андыйларның өйләренә кереп, әниләрен күндереп йөрделәр.— «Минем киез итегем тишек»,— Хәлим үз итекләрен салып бирде, ә үзе күн итек киде.— «Минем бияләй...» — «Чык кына, безнең этинекен киеп торырсың...»

Өмә таң беленүгә башланды. Шактый бала катнашты аңар. Ә көндезгә таба, өмәчеләрнең тар сукмак буйлап тезелешеп, тирес тартып, басуга барганнарына, шау-гөр килеп, бер-берсен тартышып кайтканнарына кызыгып, бөтен авыл баласы купты. Бик кечкенә балалар да, кызык күреп, бәләкәй чаналарына бер-ике көрәк булса да тирес салып, пионерлар артыннан киттеләр.

— Барып чыга бит бу, малайлар.

— Әптери белән Фәтхели тотынсын имеш тә, барын чыкмасын имеш...

— Мин дә ташыйм әле, Хәлим абый...

— Мин дә...

Хәлим андыйлардан махсус транспорт бригадасы төзеде. Начальниклары итеп Фәтхели белән Әптерине билгеләде.

Ил төкерсә, күл була, диләр бит. Ил белән тотынгач, 30 мең саны сәгать саен кечерәя барды. Дөрес, ул бик әкрен, бик авырлык белән кечерәйде. Олы пионерлар — Хәлим, Фәрдәнә, Гөлгенә, Каюм шикелләләр — ат урынына эшләделәр. Хәлим үзенең тырышлыгы белән балаларны, бөтен авылны шаккатырды. Ул чанасына барысыннан да күбрәк салды, басудан барысыннан да тизрәк әйләнде.

Чын-чынлап бер массовый күтәрелешкә әйләнде бу өмә! Аның җиле Ибрай әнисенә дә — Тәзкирә апа Тимур командасына өндәргә килгәч, Ибрайны качырып калган анага да килеп бәрелде. Башта әйтте генә ул Ибрайга: «Әллә син дә чыгасыңмы, улым? Күр, бөтен авыл баласы купкан...» диде. Ә Ибрай киреләнгәч, тиргәргә тотынды: «Бар инде, бар, йөрәгеңә йон чыкмаган булса!..»

Ибрайга шундый бер этәргеч кенә кирәк булган, күрәсең, аның намусы болай да кузгалган булган, кеч-кенә чанага шактый зур кәрзин беркетте дә абзарларыннан җылы тирес төяп килеп чыкты.

Каюм нидер әйтеп, көләргә дип авызын ачкан иде, Хәлим, ишарәләп, аны тыеп калды. Бернәрсә дә булмаган кебек итеп:

— Ә, әйдә, Ибраһим, кер минем алга,— диде.

Ибрай акланып куйды:

— Иртүк чыгармын дигән идем лә... Өй эшен үзең беләсең: сыеры, сарыгы, идәпе, миче дигәндәй... Әни чирләбрәк тора, парин,— дигән булды.

Өмә көткән нәтиҗәне бирде. Басуда тирес таулары өмә көнне ике өлеш үстеләр. Моны күреп пионерларның күңелләре үстс. Алар икенче көнне дә дәрестән соң тирес ташыдылар.

Мең пот икмәк!

Илдә һәр башак өчен көрәш барганда, мең пот икмәк!..

Бу изге максат эшнең авырлыгын оныттырды. Пионерлар, һәр башагы штыкка тиң мең пот икмәк тавын

күз алларына китереп, зур дәрт белән эшләделәр. Һәм, беркөн килеп, эшне учетка алып торучы пионер:

— Житте! — диде. Ниһаять, югары уңышка таба тагы бер зур һәм кыю адым атланды.

— Аннан соң, сез күбрәк тары чәчегез,— диде агроном пионерларга.— Хезмәтеңне кызганмасаң, уңышны башка культуралардан да күбрәк бирә ул. Ләкин, хәзер килеп, эш анда гына да түгел, эш менә нәрсәдә: башка культураның орлыгы (әйтик, бодайның, арпаның) гектарына тугыз-ун пот кирәк, ә тарының бер поты да артыгы белән житә. Ун пот табуга караганда, сезгә бер потны табуы ансатрак булыр...

Бер пот! Ун гектарга ун пот! Аны без хәзер...

2 ИНДЕ КАЙДАН АЛАБЫЗ!..

Пионерлар орлыкны, әнә шулай ансат кына табуга исәп тотканнар иде — барып чыкмады. Барып чыккан булыр иде дә, серләрен «Илшат» пионерларына чишеп ташлап, эшне боздылар.

«Илшат» — элек-электән бай колхоз. Өстәвенә узган ел тирә-яктагы алты-җиде колхозның арыш басуын сугып киткән боз моңар канат очы белән дә кагылмады. Шуңа күрә ул, хөкүмәткә тапшырганнан соң да, Совет Армиясе фондына күп кенә бүләк иткәннән соң да, колхозчыларына бераз икмәк бүлеп бирә алды. «Ватан» пионерлары орлыкны шулардан барып сорарга исәп иткән иделәр. «Илшат» пионерлары күршеләренең бу исәпләрен тыныч кына тыңлап торган булдылар да колхозларыннан шулай ук ун гектар җир сорап алдылар. Ә «Ватан»нар капчыкларын кыстырып, «Илшат»ка килеп кергәндә, алар инде соңгы өйдән орлык теләнеп чыгып килә иделәр.

«Ватан»нарның өметләре киселде, ләкин дәртләре сүнмәде. Киресенчә, бу вакыйгадан соң «Ватан»нар чәчү турында тагы да җитдирәк сөйләшә башладылар. Чәчми калудан дөнья җимерелүдән курыккан шикелле куркытылар, һәм яман көнләштеләр алар «Илшат» пионерларыннан. «Илшат»лар эшләгәнне эшләмә, имеш... Юк, болайга киткәч, баш тартырга һич тә ярамый. Ничек кенә булса да, ничек кенә булса да орлык юнәтергә кирәк.

Пионерлар бу турыда тәнәфес саен җыелып сөйләштеләр. Дәрестән соң калып та шул турыда уйлаштылар. Уйлаша-киңәшләшә торгач, бер юлын таптылар да:

— Концерт куярга!

Унынчы мартта колхоз төзелгәнгә унбиш ел тула. Шул көнгә багышлап концерт куябыз да концерттан җыйналган акчага орлык сатып алабыз.

— Ләкин ул концерт күпме генә орлык бирер икән соң?

— Күпме бирсә дә бирер.

Әңгәмәгә комсомол секретаре Мәрфуга да кушылды:

— Күпме бирсә дә түгел, күбрәк алырга тырышырга кирәк сезгә.

— Ничек итеп?

— Концертыгызны клубта үткәрегез. Концертка «Илшат» колхозчыларын да чакырыгыз. Аларның колхозлары да безнеке белән бер көнне төзелгән ич.

— Алайса, булды гына...

Пионерлар концертны клубта, һәр ике колхоз өчен куярга булдылар. Концертны яхшылабрак үткәрү, күбрәк табыш алу турында укытучылар да кайгырттылар. Концерт өчен оригиналь номерлар уйлап чыгардылар. «Җиңеп кайт, эти!» дигән әдәби монтаж төзеделәр, Тукайның «Шүрәле» һәм «Кәҗә белән сарык» исемле әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Кәҗә белән сарык тиреләре колхозда бар иде. Шулардан, кечкенә артистларга чаклап, костюмнар тектеләр. Район күчмә театрыннан бүре һәм шүрәле костюмнары сорап алып кайттылар. Шүрәленеке бигрәк охшаган, нәкъ Тукайдагыча: мөгезләренә, тоякларына, «кытыкларга яралган» бармакларына, «кәп-кәкре борын»ына кадәр бар иде. Шүрәле ролен башкаручы Хәлим, аларны киеп көзге каршысына басқач, үзеннән-үзе куркып китте.

Рәсем укытучысы зур кәгазьгә, зур хәрефләр белән бөтен иҗат көчен салып, олысын-кечесен кызыксындырырлык итеп, афиша язды.

Пионерлар шүрәле, бүре, кәҗә, сарык булып киенделәр дә, афишаны күтәреп авыл буенча йөртеп чыктылар, аннары фанер тактага ябыштырып, «Илшат» колхозына күтәреп киттеләр.

«Илшат» пионерлары бу хәлне күреп шаккаттылар. Ә ничек көнләштеләр алар! Аннан да битрәк эти-әниләреннән оялдылар. «Ватан»нар борыныгызга чиертмәсен, диярләр инде. Их, ичмаса, әни генә күрмәсен иде...

Ләкин әниләр берсе калмый күрделәр. Гомер булмаган бу күренеш «Илшат» колхозчыларының картын-яшен урамга тартып чыгарды. Колхоз председателе үзе дә чыкты бу тамашаны күреп, идарә кызлары да йөгерешеп килделәр. Менә, Кәҗә белән Сарык бертавыштан афишаны укып җибәрделәр. Менә, озын бармакларын Кырлай егетен кытыклагандагы шикелле селкетеп, Шүрәле (Хәлим) алга йөгереп чыкты, чыкты да бөгеләсыгыла сөйләп китте:

— Килми калмагыз, мин дә катнашам, кети-кети, мин дә катнашам-м!..

Ул иң алда авызларын ачып карап торган берничә бәләкәй малайга озын бармакларын тиереп алды. Малайлар чыр-чу килеп як-якка сибелделәр. Афиша артыннан Бүре (Каюм) атылып килеп чыкты. Ул, тавышына булдыра алган кадәр дәһшәт бирергә тырышып, улады:

— У-у!.. Бу мин бу-у! Мин дә катнашам-м!.. ам-м, ам-м!..

Колхозчылар кечкенә артистларны сырып алдылар. Башта җылы өйләреннән чыгарга иренеп, тәрәзә аша гына карап торган кешеләр дә килделәр артистлар янына:

— Билетлары кайда сатыла соң моның?

— Бәй, биредә генә сатып китегез!

— Билетлары ни хак була?

Билетларның бәяләре ике сумнан өч сумга кадәр, дип, афиша читенә кечкенә генә итеп язылып куелган иде. Һәм бу бәяләрне Хәлим үзе тәкъдим иткән иде. Ә хәзер, аңа бу бәяләр кечкенә күренде. Ул афишаның бер читен үз кулына алган булып, 2 ле һәм 3 ле цифрларны йөнтәс учы белән сиздермичә генә томалап куйды. Билетлары ни хак була? дигән сорауга, тавышын калынайта төшеп, җавап бирде:

— Биш сум, дуслар, биш сум! Алгы сафлар сигез сум! Колхоз житәкчеләре өчен почетлы урыннар хәзерләнә, анысы — ун сум! Акчагызны кызганмагыз, җыйнаулашып килегез, безгә табыш бирегез!..

3

Концерт, чыннан да, биш сумны да, сигез сумны да кызганмаслык булды. Ул зур уңыш белән барды. Халык шыгрым тулы иде. Кешеләр һәрбер номерны алкышлап каршы алдылар, алкышлап озаттылар. «Җиңеп кайт, эти!» инсценировкасын, тамашачылар соравы буенча, кабатларга туры килде. Ә «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» балаларны бөтенләй әкият дөньясына алып кереп китте. Урман, ярык бүрәнә, Кырлай егете, шүрәлеләр, зур шүрәле... Сугыш бетте балалар өчен. Гүя аларның этиләре инде сугышып йөрми, сугыш кырында кешеләр кырылмый, шәһәрләр җимерелми, ил чиге тыныч иде.

Билет сатып утырган Җәләй сәхнә артына авызын ерып керде.

— Бетте. Бер билет калмады. Тагы шуның хәтле булса да китә иде әле. Хәтирә әбигә хәтле килгән... Кара моны,— диде ул, ничек эләкте шулай тутырылган бер тартма акчаны күрсәтеп,— бар биредә хәлләр, малайлар!

Пионерларның шатлыклары эчләренә сыймады. Алар хыялларында шул акчаларга инде орлык сатып алып, мәктәп кладовоена бикләп тә куйдылар.

— Чәчәбез бит болай булгач, малайлар!

— Чәчәбез, чәчәбез!

Ләкин Хәлим шат түгел иде. Аның шатлыгын ниндидер борчу караңгылый иде. Башка вакыт булса, ул бу акчаларны тиененә кадәр санашыр, аларга күпме орлык алырга мөмкин икәнен исәпләп чыгарыр иде. Ә хәзер ул моны эшләмәде, иптәшләренең шат авазларын ишетмәде, уйнаучыларны, залдагы халыкны күрмәде. Ул әледән-әле урамга йөгереп чыкты һәм, бик боегып, кире борылып керде. Бер тапкыр, «Шүрәле» инсценировкасы алдыннан, Шүрәле киеме кигән килеш, авыл башындагы күпергә кадәр йөгереп барып, район үзәгенә таба озаклап карап торды.

Караңгы, буран, җил... Хәлим өметсезләнеп башын түбән иде...

Эш болай булды.

Колхоз почтальоны Гайнулла абзый, беренче бөтендөнья сугышында күпне күргән карт артиллерист,

көннәрдән беркөнне почтадан кайтып сумкасын салып атты да, аркасына котомка киде.— «Булмый, йөрәк әрни, кардәшләр, минем өчен артык тыныч хезмәт бу хәзерге көндә... Тупчы бит мин. Минем эш — туп ату,— диде ул,— башканы табыгыз. Ә мин...» — ул чамалап торды да кулын көнбатышка изәде:— «Мин китим әле...»

Пионерлар көне-сәгате белән Гайнулла абзый урынына бастылар. Ун пионер үзе теләп алынды бу эшкә. Ун пионер почтальонлык бурычын чиратлашып үтәде. Көн саен бер пионер, кич белән дәресләрен әзерләп куйгач, почта алып район үзәгенә китте. Аннан иртәнчәк, ул көннәрдә колхозчылар өчен һава белән су шикелле кирәк булган совет информбюросының яңа белдерүләрен, газета, журнал, фронт хатларын алып кайтты. Бүген бер пионер башкарды бу эшне, иртәгә икенчесе...

Ун пионерның һәркайсы район үзәгенә почта белән инде икешәр барып кайтты. Икешәр тапкыр халык рәхмәтен ишетте. Фронттагы улларыннан сәгать саен хат көтеп яткан күз яшьле аналарның рәхмәтләрен ишетте, әтиләреннән хат көтеп йөргән сабыйларны шатландырды. Бу җаваплы һәм чиксез мактаулы эшкә кичә өченче тапкыр Хәлим барырга тиеш иде. Ләкин Хәлимнең спектакль уйнарга хәзерләнәсе булганлыктан, аның урынына Гөлгенә китте. Әллә кайчан, иртә белән үк, әйләнеп кайтырга кирәк иде инде аңар, ә ул һаман юк... Менә нәрсәгә борчылды Хәлим. Менә ул нәрсә өчен авыл башына йөгереп килде.

Район газетасы чыгып җитмәде микән әллә, шуны көтеп ята микән? Булмас... Әллә буранга күрә кайтмый тора микән? Юк, аңар карыймы соң ул... Таш яуса да кайтам, концертны күрмичә калмыйм, диде ич. Ә соң нигә кайтмый икән?

Җитмәсә, нинди караңгы! Буран котырганнан-котыра бара. Ә җиле тагын! Мөгаен, берәр хәл булгандыр. Район үзәге белән ике арада нибары бер авыл. Юл таба алмыйча, кыр буйлап адашып йөри торгандыр, бичара... Әнә бит юлны буран ничек күмгән. Чана эзләре дә күренми...

Хәзер Гөлгенә Хәлимгә сабый вакытларындагы кебек, арыш арасында зәңгәр чәчәк җыеп йөргәндә адашып калгач, бер-берсен юата-юата елашкандагы кебек, якын булып тоелды. Бервакытта да булмаганча кызганыч тоелды хәзер Гөлгенә Хәлимгә.

Инде нишләсен икән Хәлим? Тукта, бәлкем ул шушы тирәдә генәдер?..

— Әй-й.. Гөлгенәү-ү!.. Гөлгенәү-ү!..

Алда, юл читендә, күпердән ике-өч йөз метрда, ялгыз ак каен булырга тиеш. Хәлим кычкыра-кычкыра шунда таба йөгерде. Анда житкәч, әче итеп сызгырды да, колагын алга сузып, Гөлгенәнең җавабын көтеп торды. Җил улады Хәлимгә җавап итеп, буран котырды, ә Гөлгенә җавап бирмәде. Хәлим, кесә фонарен кабызып, як-якка йөртеп карады. Фонарьдан сузылган ут көлтәсендә кыеклап яуган буран күренде, Гөлгенә күренмәде.

— Димәк, ул бик ерак...

Хәлим Гөлгенәне салкын буран эчендә тирән карга бата-чума юл эзләп йөргән кыяфәттә күз алдына китерде. Менә йөрде-йөрде дә, хәлдән таеп, карга тезләнде Гөлгенә. Аны кар күмә башлады. Күзләреннән чыккан кайнар яшькә кар бөртекләре төшеп эределәр, эределәр дә яшь белән бергә керфеккә бозланып каттылар. Гөлгенә нидер әйтергә теләде, ләкин аның иреннәре ачылмады...

— Хәлим абый, син уйнадыңмы әле?

— Хәлим абый, мине дә клубка алып кер әле.

...Хәлим сискәнеп китте. Ләкин, юк, моны Гөлгенә әйтмәде шул. Моны Хәлим артыннан ияреп килгән кечкенә малайлар әйтте.

Хәлим хыялыннан чынбарлыкка кайтты. Әйе, ул артист бит әле. Шүрәле киемендә. Кара, аңар сәхнәгә чыгарга вакыттыр ич инде... Хәлим, әз генә уйлап торды да, фонарен кабызган килеш район үзәгенә таба каратып, каен ботагына элеп калдырды һәм клубка йөгереп кайтты.

Әйе, сәхнәгә чыгар вакыт әллә кайчан җиткән иде инде Хәлимгә. Кырлай егете (Шәпи), укымый кала язган Шәпи, бу дәһшәттән Хәлимнәр коткарып алып калган Шәпи, сәхнәдә иде инде. Ул үзенең Шүрәле керер алдындагы сүзләрен сөйләп бетергән, Шүрәле кермәгәч, инсценировкада булмаган бер җыр да җырлап алган, ә хәзер нишләргә белмичә аптырап тора иде. Хәлим сәхнәгә нәкъ шул вакытта атылып килеп керде. Аның йөнтәс өстенә кар сырышкан һәм ул шуның белән әкияттәге Шүрәлегә тагын да күбрәк охшый төшкән иде.

Шүрәле күренүгә, залда чебен очканы ишетелерлек тынлык урнашты. Хәлим, Гөлгенәне исеннән чыгарып торырга тырышып, роленә кереп китте.

...Кил әле син дә бераз
Бармакларыңны селкет, и,
Яшь егет, килче икәү
Уйныйк бераз кети-кети...

Хәлим, инсценировка бетүгә, залны яңгыраткан кул чабулар астында, сәхнә артына йөгереп чыкты. Аны тамашачылар кул чабып сәхнәгә чакырдылар, ләкин ул чыкмады. Хәзер тагы Гөлгенә иде аның уенда. Ул, үзенең каушавын яшерә алмыйча, Фәрдәнәгә эндәште:

— Гөлгенә кайтмаган бит әле безнең, Фәрдәнә.

— Гөлгенә кайтмаган?

Фәрдәнә, концерт белән мавыгып, Гөлгенәне онытып җибәрүен, үзенең гамьсезлеген әйтеп, үзен үзе тирги башлады.

— Ай, нигә элегрәк исемә төшермәдең соң син бу турыда, Хәлим?

— Каршысына чыгыйк, Фәрдәнә.

— Әйе, әйе...

Фәрдәнә пионерларның зурракларын чакырып китерде дә хәзер үк өйләренә кайтып, чаңгыларын алып килергә кушты. Ул хәзер үзенең кызыл галстугы, ак яулыгы, алъяпкычы белән генә ошый иде вожатый Фәрдәнәгә. Ә хәрәкәте, тавышы белән солдатларын һөҗүмгә туплаучы командир иде инде.

— Бар, чаңгыңны ал да хәзер килеп җит! Биш минуттан биредә бул!

— Минем биисем бар бит әле, Фәрдәнә апа.

— Биемәссең.

— Бәй, мин...

— Бар, диләр сиңа! Минем чаңгыны да ала кил. Ә син, Гөлчәһрә, концертны алып бар. Без кайтып житмәсәк, кичәне япканда килүләре өчен халыкка рәхмәт әйт... Ә анысын әнә Мәрфуга апа белән киңәшерсез,— диде Фәрдәнә һәм сәхнә артыннан атылып чыгып китте.

Чаңгыга баскан пионерлар бик тиз җыйналып өлгерделәр. Авыл башына чыккач, юлның як-ягына киң сибелеп, Фәрдәнә командасы астында, җил-буранга каршы район үзәгенә таба шуып киттеләр.

Пионерлар өчен бу поход яңалык түгел иде. Военрук җитәкчелеге астында, аларның мондый походка, шушындый ук салкын буранлы кичләрдә, берничә тапкыр чыкканнары бар иде. Ләкин ул вакытта алар кырга алдан

чыгарып куелган карачкыны эзләп йөргәннәр иде. Ә хәзер чыннан да бәхетсезлеккә очраган иптәшләрен эзләргә чыктылар. Шуңар күрә аларның һәркайсы, кузгалып китүгә, үз тирә-ягындагы йөз метр араның һәр карышын җентекләп күзәтеп барды.

— Исән генә була күрсен, без аны тапмый калмабыз. Район үзәгенә җитәрбез, бөтен район басуын әйләнеп чыгарбыз...

Ләкин бөтен басуны әйләнеп чыгуның кирәге калмады. Бераз китүгә, Хәлимнең кесә фонаре белән яктыртылган ак каен күренде. Каеннан район үзәгенә таба көлтә булып сузылган ут яктысында, бер кулы белән почта сумкасын күкрәгенә кысып, икенчесе белән тирән кардан үрмәли-үрмәли, пионерка Гөлгенә кайтып килә иде.

Пионерлар, йөгереп килеп, Гөлгенәне күтәреп алдылар.

...Гөлгенә район үзәге белән ике арадагы авылны чыгып бераз киткәч тә, караңгы төшеп өлгерә. Юлны буран күмгән. Гөлгенә адашып йөри башлый. Тәмам хәлдән тайганчы, аяклары атламас хәлгә килгәнче йөри ул. Шулай йөри торгач, фонарьлы каеннан нибары бер километрдагы икенче бер каен янына килеп чыга. Һәм, артык атлый алмыйча, шуның төбенә килеп чүгәли. Берничә тапкыр йоклап китә башлый ул шунда. Ләкин Гөлгенә белә: мондый чакта йокларга ярамый, йокласаң өшеп үләсең. Гөлгенә аякларына калка. Аяклары тыңламагач, үрмәләргә тотына. Ә «Ватан»га таба үрмәли микән соң ул? Ә сулга китеп урманга барып чыкса?.. Гөлгенә шулай куркыныч уйланып, ләкин ахыр чиккә кадәр үлем белән көрәшергә карар кылып, үрмәли бирә. Үрмәли торгач алда әлеге фонарь яктысын күрә. Якты Гөлгенәнең өметенә дәрт куша. «Клуб тәрәзәсенең пәрдәсен күтәрделәр», дип уйлый Гөлгенә үзенчә. Һәм утка таба туры үрмәли башлый. Ут, буран пәрдәләп торганга гына шулай ерак булып күренгән икән, үрмәләгән саен ут та аңар каршы үзе йөгереп килгән шикелле якыная бара. Менә серле ут белән яктыртылган ак каенны күрә Гөлгенә...

(Гөлгенә бу турыда иртә белән, үзен коткаручы иптәшләре өенә хәлен белә килгәч, сөйләде. Берничә көн авырып ятты ул. Бик каты туңган, ике боты, кул бармаклары өши башлаган иде.)

Ә хәзер, иптәшләре килеп күтәреп алганда, бернәрсә дә сөйли алмады. Аның теше тешкә бәрелә, бөтен гәүдәсе дер-дер калтырый иде. Аны юлга алып чыгып, ике култыгыннан тоттылар да, кулларын, битләрен кар белән удылар, һәм, җылынсын өчен, кызу-кызу атлатып алып киттеләр. Авылга кереп, клуб янына килеп җиткәндә, Гөлгенәнең аяклары бераз языла башлаган, калтырануы да кимегән иде. Иптәшләре аны өенә кайтып ятарга кыстадылар, ләкин ул клубка керде.

Гөлгенә сәхнә артында почта сумкасын — Мәскәүдә иҗат ителгән газеталарны, өлкә, район газеталарын, «Ватан» солдатларының алдагы һөҗүмгә, бәлкем, нибары берничә генә минут калгач салкын окопта, салкын мылтык прикладларына куеп, газиз әнкәләренә, газиз балаларына, тормыш юлдашларына язган хатларын Хәлимгә бирде.

— Мә, үзең тарат инде, Хәлим,— диде ул. Үзе, сәхнәгә чыгып, концерт бетү турында әйтергә торган Гөлчәһрә янына килеп басты.

Гөлгенәнең кар сарган өстен, карлы маңгай чәчләрен, стенадагы кызыл комач шикелле кызыл йөзен, арыган гәүдәсен күреп, кешеләр тынып калдылар.

— Абыйлар, апалар, сезгә Сталиннан телеграмма!— диде Гөлгенә.

Кешеләр аңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә, аптырап карап тордылар. Гөлгенә, куеныннан бер кәгазь чыгарып, ашыкмыйча гына укып китте.

«Танклар колоннасы төзү өчен йөз илле бер мең сум акча җыеп биргән «Ватан» колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. В. Сталин».

Ура тавышлары яңгырады. Кул чабу тавышлары клубка сыймады.

Гөлгенә, шул тавышлар астында сәхнә артына чыгып, иптәшләре кулына ауды.

Концерт шулай тәмам булды.

4 БЕРЕНЧЕ БУРАЗНАЛАР

Җепшек канатларын җәеп, рәхимле елмаеп яз килде. Кояш күзләрне чагылдырырлык итеп туры карый башлады. Көн-төн эреде хәзер кырда кар. Уйсу җирләргә,

яшыгып-ашыгып, сулар жыелды; аннан су елгаларга агып төште. Тезелеп бозлар акты елгада. Сайрар кошлар, жылы яклардан кайтып, агач башларына, текә яр кырыйларына оя кордылар. Ак каеннар, юкәләр бөреләнде. Кар астыннан беренче умырзая чәчәкләре төртеп чыкты. Калку кырларда хәтфәдәй яшел уҗымнар күренде. Ике тәрәзә арасында кыш буе үлеп яткан чебеннәр терпәкләнә башлады. (Җаен тенкәгә тияр әле ул, ә хәзер күңелле.) Кояшлы бакчада төрле-төрле күбәләкләр канат җәйде.

Пионерлар да җәйделәр канатларын, алар, колхозчылардан күрмәкче, тирес өемнәренең кар астыннан чыкканын берен барып тараттылар. Әремкәрне йолкыдылар да өеп яндырдылар, җирләрнең туңы киткәнен, сабанга өлгергәнен күзәттеләр. Поезд килер дә китәр, утыра алмый калырбыз, дигән кеше төсле борчылып йөрделәр алар.

Ә нигә борчылырга? Моның өчен әнә пионерлар участогына беркетелгән Шәйхаттар бабай бар ич. Бар да бит, ул пионерлар эше өчен пионерлар кадәр яна микән соң? Юк, аның берәр көн онытып күзәтми калуы бар. Шунын аркасында эшне бер көнгә соңлатуың бар. Ә тары өчен җирне никадәр иртә сөрсәң, шулкадәр яхшы, ди бит әнә Тәзкирә апа... Тагы шуны да онытырга ярамый, «Илшат»лар бар бит әле... Ничек тә «Илшат»лардан алда чыгарга кирәк. Ничек тә яхшырак эшләргә, икмәкне фронтка күбрәк үстереп бирергә кирәк.

Һәм менә бүген Хәлимнәр шул ниятләрен тормышка ашыру юлында өченче адымны атладылар. Өч атны өч сабанга җигеп, сабантуендагы узышлар шикелле, бер сызыкка тезеп куйдылар. Ә тырмага сыер, колхоз сыерын җиктеләр. Сабан артларына Хәлим, Каюм, Ибрай — иң таза пионерлар басты. Аларның алмашчылары Шәпи, Җәләй, Мотыйк бер читкә китеп утырдылар. Кечкенә пионерлар, инде яланаяк йөреп аякларын чебиләтеп бетергән кечкенә балалар, атлар белән сабанчылар тирәсендә мыжлап йөри, һәркайсы аларның тизрәк кузгалып китүен көтә иделәр.

Менә, малайлар арасыннан кемдер:

— Килә-ә!..— дип сузды.

— Килә, килә!

Анда, авыл ягыннан, бер кулын биленә, икенчесен

каш өстенә куеп, мәгълүмегез Шәйхаттар бабай килә иде.

Узган кыш урманда артыграк тырышып ташлаган ахрысы, кайткач бер чак биленә зарланып, чирләп ятты ул, ышандырганынча, урманга Фәсхи кордашы белән кабат бара алмады. Ә терелеп чыккач, үзе әйтмешли, үлемне тагын бер кабат алдап-йолдап озаткач, һәркайчан шат күңелле бу бабайны Хәлим тәкъдиме, иптәшләренең соравы буенча, колхоз идарәсе пионерларның кыр бригадасына агротехник итеп беркетте.

Баш та, күз дә иде ул пионерларның кыр эшләрендә. Ул аларны чәчүгә әзерләүдә бик күп тырышты. Чәчүлек тары чүплерәк иде,— җилгәрттерде. Җилгәргеч аера алмаган чүп-чарларны кул белән чүпләтте.

Дөрес, бик вак, бик ялыктыргыч эш булды бу. Озын-озын ике төн китте бу эшкә. Кызык күреп кенә тотынган кечкенә балалар таралышып беттеләр. Олырак пионерларның да чүпләп утырган килеш башлары салынып төште. Ләкин Шәйхаттар бабайның мәзәк сүзләре аларга йоклап китәргә бирмәде. Колхоз төзү елларын сөйләде ул пионерларга, беренче бөтендөнья сугышында, гражданнар сугышында күргәннәрен сөйләде. Шуларны тыңлый-тыңлый пионерлар, ниһаять, тарыны чистартып бетерделәр.

Шәйхаттар бабай Шәехтайны гына түгел, сабанга билгеләнгән өч атның һәркайсын тәрбияләүдә тырышып йөрде. Аз дигәндә көнгә ике тапкыр абзарга килеп, атларны карап китте ул. Бик кечкенә, бик аз әһәмиятле җитешсезлек күрсә дә, пионерларга моның ярамаган нәрсә икәнен төшендерде. Ә бер тапкыр, әлеге дә баягы, Ибрай абзар буйлап узып барганда Шәехтайга чыбык белән сугып киткәч, Шәйхаттар бабай яман телләнде: «Син, энекәш, кулың бик кычытса...» Өстәвенә, Ибрайны пионерлар сборында тикшертте. Бу сборга үзе дә килде ул һәм сүз алып та, кеше сүзен бүлеп тә Ибрайны тиргә төшергәнче орышты.

Шәйхаттар бабай, агротехник итеп беркетелгәч, пионерлар сборында еш була иде. Бер тапкыр ул пионерларга шундый сәер сорау бирде:

— Кар кайда тизрәк эри?

— Калку җирдә.

— Анысын әйтмим. Шәһәрдәме, авылдамы?

— Шәһәрдә.

— Ә нишләп шәһәрдә?

— Анда кар корымлы була, чуплс була. Кара әйберга, физика законнары буенча, кояш нурлары күбрәк, тизрәк үтә.

— Закон-маконнарыгызны белмим, әмма ләкин сүзегез дөрес. Безгә дә менә болынга, сезнеңчә итеп әйтсәк, кояш нурларын күбрәк, тизрәк үткәрергә кирәк.

— Нишләп?

— Атларны яшел печән белән тизрәк сыйлый башлау өчен.

— Ничек инде?..

— Ә менә ничек...

Шәйхаттар бабай үзенең фикерен сөйләп бирде. Пионерларга ошады. Алар икенче көнне, өй буенча көреп йөреп, көл җыйдылар. Туфрак белән куштылар да болынның Шәйхаттар бабай сайлап куйган җирләренә илтеп сиптеләр. Тәҗрибә уңышлы чыкты. Көлле туфрак астындагы кар күзгә күренеп эреде. Нәтиҗәдә, пионерларга беркетелгән атларның авызлары яшел үләнгә, өч-дүрт кенә көн булса да, алдан тиде.

...Шәйхаттар бабай килеп җитүгә билен турайтты. Кулын каш өстенә куйган килеш, сугышка ташланачак солдатларын күзәткән командир шикелле, яшь сөрүчеләрне күзеннән кичерде. Атларның, тырмадагы сыерның җигелүләрен карап үтте ул. Һәрбер әйберне тотып караган саен, һәрнәрсәгә күз төшергән саен сабанчыларга нәрсә булса да әйтми калмады:

— Камытынны кыса төш... Башмак ярамый мондый җирдә, чабата әйбәт. Ә син нәрсә дип, кәбестә шикелле, кат-кат киендең? Һәй, тумас борын картайган!.. Кайдан таптың бу бишмәтне, бик тар, иркен кием кирәк мондый җирдә,— диде ул. Ә сүз әйтер урын тапмаса, шулай кирәк, молодчина, дип узып китте. Иң ахырдан ул Шәехтай янына килде. Аңар, булдыра алырсың микән, дигәндәй шикләнеп карап торды да такталанып каткан кулы белән ялын сыйпап, сөеп куйды:

— Сынатма, яме!..

Аннары ул читкәрәк китте дә сабанчыларга сүзсез карап торды. Бу вакытта аның язгы җил каралткан җыерчыклы йөзендә, кечерәеп калган күзләрендә һәркайчан була торган елмаю югалды. Тантаналы иде ул бу вакытта. Һәм ул, шушы тантанасын киметәсе килмәгән шикелле, озак вакыт эндәшмичә торды. Сабанчылар да

үзләрен сабантуенда көрәшүгә чыгарга торган батырлардай хис итәләр, ә читтән карап торган кечкенә малайлар: «Әх, безгә дә сөрергә» дип, көнләшеп куйдылар.

Шәйхаттар бабай кулын каш өстеннән алды:

— Хәерле юл, оланнар!

Пионерлар сабаннарын тирес астында парланып яткан, җылы кояш нурлары белән күперeп киткән туфракка батырдылар. Атлар авыр тартып алып киттеләр. Җирне, үткен сабан калагы кисеп алып, бер якка каерып сала башлады. Сабан артыннан кара беләү шикелле тигез, шома буразналар сызылып калды. Буразналарда анда-санда кызыл симез суалчаннар, кара башлы ак кортлар күренде. Юк иде, әллә кайдан зур-зур кара каргалар очып килде. Алар җиргә төштеләр дә, сабаннар артыннан тыйтак-тыйтак атлап, суалчаннарны, ак кортларны чүпләп йөри башладылар. Читтән карап торган кечкенә малайлар, чыр-чу килеп, сабанчылар артыннан йөгерделәр.

— Кем узар икән?

Анысы бар бит әле... Яшь сабанчылар бер-берсе белән узара ярышалар иде. Һәм өч звено — алты пионер — алар һәркайсы бу ярышта җиңеп чыгуларына ышаналар иде.

Беренче звенода Ибрай бар. Ул барысыннан да көчлерәк. Бу звенода аның көченә таяналар. Икенче звено башлыгы — Каюм. Ул Ибрай кадәр үк көчле түгел, ләкин аты җиллерәк. Өченче звенода Хәлим бар. Дөрес, аның көче Каюмныкыннан артык түгел, атына килгәндә ике аттан да картрак, ләкин шунысы билгеле: Хәлим аты күргән тәрбияне бу атларның берсе дә күрмәде. Ана үзенең сырхап киткән бердәнберен ничек караса, Хәлим белән Гөлгенә Шәехтайны шулай карады. Сабанга чыгарга бер атна калгач, һәр кичне алмаш-тилмәш яныннан китмәделәр. Барганда-кайтканда Хәлим яки Гөлгенәгә очраган һәрбер уч печән Шәехтай авызына керде. Шуның өстенә Хәлим белмәгәне, Гөлгенә үзе генә белеп калганы никадәр иде... Шулай да Хәлим шикләнде. Ат та, сабанны онытып бетергән ат та, әллә инде үзенең көченә ышанмады, башкалар китеп баргач та әле кузгалмыйча торды. Бу секундта Хәлимне беркайчан да булмаган курку чолгап алды.

«Хур гына итмәсәң ярар иде...» Ә секундның икенче өлешендә Хәлим үзендә сабанны гына түгел, атның үзен

дә этеп барырлык көч сизеп, аякларын терәп, сабанны алга этәрде. Һәм дулкынланганын сиздермәскә тырышып, Шәехтайга эндәште:

— Һа-а-а, малка-ай!..

Малкай кузгалды. Хәлим кулларын сабаннан алды. Ат башта каушап кына атлады, сөртенгәләде ул. Аннары, башкалар шикелле үк, тигез атлап бара башлады. Бара торгач, Шәехтайның пионерлар һәм Хәлим үзе дә исәпкә алмаган уңай ягы ачылды: Шәехтай зур гәүдәле булып, аяклары озын иде, ул әкрен басты — күп алды. Һәм, кырык-илле адым чамасы китүгә, башка атларны куып җитте.

Хәлимнәр бераз вакыт сөйләшеп бардылар. Китап-дәфтәрләрен күкрәкләренә кысып беренче көн мәктәпкә баручы яшь балалар шикелле дулкынлана иде алар. Сугышка кадәр олы кешеләр генә башкарып килгән эшне эшли алулары белән хаклы рәвештә горурлана иделәр.

— Булдырабыз бит, дуслар!..

— Булмый гына карасын...

Ләкин сөйләшүгә теләк бик тиз бетте. Башта Ибрай туктады сөйләшүдән. Ул инде сораганга җавап та бирмәс булды. Аякларын өстерәп атлады, әледән-әле үз сабаны каерып салган кантарга абынып китте. Инде Каюмда да бик тиз Ибрайдагы галәмәтләр күренә башлаган иде. Аның маңгаеннан кара, шома буразнага борчак-борчак тир тамып төште. Ләкин ул сынатмаска тырыша иде.

Хәлим генә бирешмәде хәзергә. Балалар бакчасына йөри башлаганнан бирле, башта аңсыз рәвештә, баратора аңлап, физкультура белән шөгыльләнү, көн дә иртән тәнен салкын сулы киндер сөлге белән ышку, кара көзгә кадәр бер көн калмый су коену, элек-электән физик эшне яратып үсүнең нәтиҗәсе иде бу. Хәлим һаман да әле ярыйсы ук батыр атлады. Ат туктый башласа, сабанны этеп куйды. Шәйхаттар бабай аның янына килгәндә «молодчина, Хәлим!» нән башка сүз әйтмәде.

Шулай да Хәлим туктарга булды. Шәйхаттар бабай икенче тапкыр, туктагыз инде, оланнар, дигәч, ул иптәшләренә:

— Ялга-а-а! — дип кычкырды.

Ибрай, тагы берәр атласа егылырга җитеп арыган Ибрай, буразнадан читкә чыгып, яңа яшәреп килгән

канау буена йөзтүбән ятты. Каюм да аның янына килеп тәгәрәде. Берникадәр тегене-моны сөйләшеп яткач, куеныннан кыш буе математика дәресләрен язып барган калын дәфтәрен алды:

— Башлыйбызмы, Ибрай?

— Әйдә соң,— Ибрай да шундый ук дәфтәр чыгарып, битләрен актара башлады.— Менә мин бу теореманы онытам. Күңелдә гел шуны сорар төсле тора, башта шуны кабатлыйк әле, Каюм...

Хәлимнәр туктауга сабан сапларына, тәкатьсезләнеп, звеноларның икенче номерлары ябышты. Хәлим Шәехтайның әле бер, әле икенче ягына төшеп, аның йөрешен күзәтте. Аннан Шәйхаттар бабайны көтеп алды:

— Малкай бара бит, ә бабай?..

— Һәй, ничек кенә әле... Ал бирмәс ул тегеләргә.

— Бирмәсме?

— Әйтте диярсең...

Хәлим тынычланып Ибрай белән Каюм янына барып ятты. Ул да, буш арадан файдаланып, иптәшләренә кушылып имтиханга хәзерләнә башлады.

Алар өчәүләшеп байтак кабатладылар. Ә аерым-аерым укырга керешкәч, Ибрай бик тиз туйды. Яткан урыны да, кигән киеме дә җайсыз кебек тоелды аңар. Әле чалкан ятты ул, әле йөзтүбән. Ат куган, шаулашкан тавышларны ишетмәс өчен, колакларын да томалап карады. Ләкин башына һичнәрсә кермәде. Менә ул, кинәт дәфтәрен ябып, торып утырды, үзенчә иптәшләре күтәреп алыр кебек күренгән фикерен әйтте:

— Беләсезме, мин нәрсә уйладым, дуслар. Сез бит инде, үзегезгә калса, моны (ул сөрелә башлаган җиргә ишарәләде) зур эш саныйсыз.

— Соң?

— Раз шулай икән, мәктәптә безнең дилбегәне бераз бушатсалар булмас микән дигән уй килде әле минем башка.

Хәлим белән Каюм, төшенмәгәнлекләрен белдереп, бер-берсенә карашып алдылар. Ибрай аңлатып бирде:

— Мәктәптә бераз скидка ясасалар, ничек булыр икән димәкче булам.

Каюм елмаеп нидер әйтергә җыенды. Хәлим, сөйләсен-сөйләсен, дигән мәгънәдә күз кысты. Ибрай дәвам итте:

— Нигә, һәр эштә бар нәрсә ул. Мәсәлән, яшь балалы хатыннар эштән иртәрәк кайта, фронтовик семьялары налогтан азат ителә. Мин күпне өмет итмим. Әйтик, шунда, имтиханда мәсьәләнең җиңелрәген биреп куйсалар, кайсын бирәселәрен алдан искәртсәләр, совет властена бер зыян да булмас иде, минемчә.

Хәлим тыңлап бетерергә булган иде дә, Каюм тәки түзмәде:

— Анысы факт, совет властена бер зыян да булмас, ләкин синең үзеңә...

Хәлим Каюмны төзәтергә ашыкты:

— Юк, егет, совет властена моның зыяны бик була,— диде ул һәм күзен, сабан артыннан баручылардан алмаган хәлдә, Ибрайга терсәге белән төртеп куйды да дәвам итте: — Син доктор булам дисең бит әле? Ну вот, әгәр син скидка белән укысаң, синең докторлыгың да скидкалы булачак. Син, беләсеңме, сырхау дәвалаучы түгел, кеше җәфалаучы булып чыгасың.

Ибрай Хәлимгә арты белән борылып ятты:

— Арттырырга сиңа бир инде. Белмим, кеше дәвалау өчен бака канының ни өчен салкын икәнен белү ни пычагыма кирәктер.

— Районда булырга туры килсә, райкомга кер син, секретарь янына. Ул сиңа нигә икәнен аңлатып бирер,— диде Хәлим.— Шулай ич, Каюм?

— Фа-акт.

Хәлим тезләнеп утырды да 1941 елның көзендә секретарьдан ишеткәннәре турында бик җитди итеп сөйләргә кереште. Бу юлы аны Каюм бүлде:

— Ә безнең Ибрай белә инде аны... Беләсеңме, нәрсә уйладым әле мин. Ибрай, әлбәттә, тора-бара аңлар, ул акылсыз егет түгел, аңар әле килеп кенә җитми. Озын бит ул. Безнең авыздан чыккан сүз аның гәүдәсе биеклеге күтәрелеп, колакларына барып кергәнче, байтак вакыт кирәк...

Хәлим рәхәтләнеп көлде. Ибрай да ачуланмады, иркен елмаеп куйды:

— Шөпшә угы бардыр синең телеңдә, Керпе тәре.

Каюм дәвам итте:

— Әйтеп бетермәдем. Мин менә нәрсә уйлыйм. Ибрайга, иске кушаматын алып, скидкалы доктор кушаматы бирергә кирәк булыр.

Бусына Хәлим шаркылдап көлеп җибәрде. Ә Ибрай көлмәде. Ул корт чаккан кебек торып утырды. Черки — ул әле балачак кушаматы. Аның ни өчен бирелгәнен бара-тора онытып та бетерерләр. Ә скидкалы доктор... О-о... бу гомереңә китә торган. Тартар теленнән табар ди шул. Юк, моны ничек тә оныттырырга кирәк... Ул Каюмның авызыннан чыккан, үзенә бирелергә торган кушаматны һавадан җыеп алып юк итәргә теләгәндәй, кулларын хәрәкәтләндереп алды һәм, ялына төшеп, үзен кызгандырырлык итеп әйтеп куйды:

— Бала булма, Каюм, кирәк түгел. Әбер-чебер ишетсә, хәзер таратып җиткерер...

Ә әбер-чебер ишетә инде андыйны. Ишетә генәме соң!.. Бераз алга китү була, шулай да хәзер әйтеп үтәргә кирәк. Икенче көнне яшь сабанчылар, шау-гөр килеп, басудан кайтып килгәндә, канау буенда өч «әбер-чебер» күрделәр. Сабанчылар килеп җиткәндә аларның берсе үлгән булып ята, икесе шуның баш очында елаган булып утыра иде. Берсе — янәсе, үлгән кешенең хатыны — башына яулык бәйләгән, икенчесе — янәсе, күрше хатын — ятимәнең кайгысын уртаклашырга килгән...

— Доктор чакырып өлгермәгәнсез икән,— диде ул күз яшьләрен җиңе белән сөрткәндәй итеп.

Ятимә җавап бирде:

— Чакырдык чакыруын, тиз дә килеп җитте үзе. Ләкин файдасы тия торган булмады шул, файдасы тия торган булмады, күрше генәм. Скидкалы доктор булып чыкты.

Сабанчылар шаркылдап көлделәр. Ибраһим ялкын уртасында калган бүре кебек җыерылып килде. Менә ул кәмитчеләргә ташлану өчен омтылды, куллары йодрыкланды, авыр итекләре кәмитчеләрне типкәләп ташлау өчен хәрәкәткә килде. Ләкин ни буласын алдан белеп торган «мәет», аның «ятимә хатыны» һәм «күрше хатын» бер куллары белән кәләпүшләрен, икенче куллары белән төшеп калу ихтималы булган штаннарын тотып, төрлесе-төрле якка сибелделәр.

— Ә тегесе нәрсә тагын?

Сабанчылар Ибрайлар капка төбенә йөгереп килделәр.

Капка баганасына, кул җитмәс җиргә, пыяла китеге астына шундый вывеска кадакланган иде:

Ибраһим духтр.

(Скидкалы)

Кабул итү сәгатьләре: үзе ничек тели, шулай.
Звонок бирмичә кермәскә; ишек алдында хуҗавың
үзеннән дә усал эте бар.

Басылып килгән көлү тагын көчәеп китте. Ибрай вывесканы бер селтәнүдә коеп төшерү өчен, читәннәреннән казык суыра башлады. Суырып чыгара алмагач, вывескага карап-карап торды да, башта бер төкерде, аннан үзе дә шаркылдап көлеп җибәрде.

Әле хәзергә бу хәлнең булачагыннан хәбәре булмаган Ибраһим колакларын яңадан томалады да күзләрс белән дәфтәренә кереп батты. Бу вакытта Шәйхаттар бабай икенче смена сөргән җирләрне күзәтә-күзәтә буразналар өстеннән атлый иде.

— Әй, малай, карга санап барма, авызыңа тамызып китмәсен,— дип кычкырды ул.— Күр, никадәр чи калган!.. Ә син, энем, бик кума, атны ардырырсың... Шәпи улым, борыл инде, борыл. Тегеләр күзе тимәсен...

Шәйхаттар бабайның тегеләре — «Илшат» пионерлары, «күзе тимәсен»е — сөргәнне күрмәсеннәр дигәне иде.

Эш шунда ки, Хәлимнәр «Илшат»ларга кадәр берәр көн алдан чыгып, җирләренең түбән очын шыпырт кына сукалый башларга булдылар. «Илшат»ларның атлары әйбәт, болай да безне узып китәрләр әле, диештеләр алар.— «Ә бит «Илшат»ларның да шулай ук шыпырт кына чыгып сукалый башлаулары бар». «Ватан»нар моны күзәтеп тору өчен үр башындагы таш артына Фәтхели белән Әптерине менгереп яткырдылар.— «Андыймондый хәл күрсәгез, килеп әйтегез, яме?» — Әптериләр озак көттермәделәр, Хәлимнәр икенче тапкыр сменага басуга, ерактан ук кулларын болгый-болгый, йөгереп килеп җиттеләр.

Алар «Илшат»лар авылы башындагы ялгыз каеннан ике кечкенә малай сикереп төшкәнне, төшкән уңайга атларына атланып (безнеңчә әйтсәк: себерке сапларын бот араларына кыстырып), авылларына йөгереп кереп киткәнне хәбәр иттеләр.

— Ах, шайтан икән!..— Хәлим, сабанын сменасына биреп, үргә йөгереп менде.

Менә «Илшат»лар авылы башында Фәтхелиләр әйткән «атлылар» күренде. Алар артыннан тагын икәү килеп чыкты. Малайлар, дошманны фаш иткән чик сакчыларыдай шатлана-шатлана, «атларын» җан-фәрманга чаптырып, әрле-бирле йөрделәр дә тагын авылга кереп киттеләр. Һәм берничә минут үтүгә, авылдан унбиш-егерме малай ияртеп килеп чыктылар. Малайлар, һөҗүм итеп баручы гаскәр шикелле, шау-гөр килеп, биек җирдә ялгыз басып торган Хәлимгә таба килә башладылар. Килделәр, килделәр дә кар сулары белән тулып аккан елга читенә җиткәч, туктап, гөжелдәргә тотындылар.

Фәтхелиләр әйткән ялгыз каен башыннан тагын бер малай кычкыра-кычкыра сикереп төште.

— Өч ат, өч сабан, бер тырма, бер сыер, өч ат, өч сабан, бер тырма, бер сыер! — дип кычкырды ул, иптәшләре янына йөгерә-йөгерә.— Чәчрәп китим менәтерә!.. Әле дә сөрәләр.

— Үзбәкләр елга ике уңыш ала ди бит, әллә инде безнең күршеләр дә...

Моңар каршы Хәлим кулларын авыз кырыйларына куеп:

«Атлар ябык бит, атларны сынап карарга гына булган идек», дип кычкырырга уйлаган иде, шул минутта «Илшат»ларның икенче бер малайлары яр читенә үк килеп басты да бер кычкырып көлде, аннары әйтте:

— Кәҗәләребез егылганчы бераз тырнап калыйк, дидегезмени, үзегезгә калса, ха-ха-ха!..

— Кәҗә?! — Хәлим кинәт үзгәреп китте, утлы күмер төсле булып кызарды ул. Ләкин бу юлы уңайсызланудан түгел, ачудан кызарды. Һәм, гәүдәсен турайтып, бер-ике адым алга атлады. Ләкин көлүче малайга ни дип тә каршы әйтә алмады. «Әйе, аларның атлары янында безнекеләр кәҗә генә шул...»

Хәлимнең авызы томаланганны күреп, көлгән малай өстәп куйды:

— Ләкин, карагыз аны, фил булырга йөргән бака көненә калмагыз, ха-ха-ха!..

Ә бит шулай булуы да бик мөмкин... Ләкин бу шикне Хәлим йөзенә чыгармады. Үзенең көченә нык ышанган кеше тавышы белән «Илшат»ларга кычкырды:

— Ярый, филләр! Ләкин алай бик ашыкмагыз әле... чебиләрне көз көне саныйлар безнең авылда!..

«Илшат»лар шаулаша калды, Хәлим борылып, үзләре жиренә таба китте.

— Ну, әйбәт капладың да соң, Хәлим.

— Тел белән...

— Эш белән дә капларбыз, Каюм,— диде Хәлим моңа каршы һәм, ярсып килеп, сабанны Шәпидән алды.

— На-а, малкай-әй!..— диде ул һәм,— эш белән дә капларбыз, уйлама да,— дип кабатлады, сабан төрәнен җиргә тирән батырып.

Шәйхаттар бабай, Хәлим сабаны сызган буразнага карап, башын чайкап куйды:

— Кирәкми, Хәлим, алай каты басма, кирәкми...

Хәлим, көчен кая куярга белмичә, сабанны этеп бара башлады. Бу вакытта ул, сабанчы малай булудан бигрәк, солдатларын ияртеп атакага баручы батыр командирга охшый иде.

Хәлимнең үзен шулай тотуы пионерларны тынычландырып җибәрде. Ләкин бу тынычлык озакка бармады. күпмедер вакыт үтүгә, авыллары башында «Илшат»лар тагы күренде. Бу юлы аларның алдыннан, өч сабанны өстерәп, зур-зур өч ат килә иде. Атлар «Ватан»нарга шундый зур, шундый көчле булып күренде, әйтерсең, алар сабанны гына түгел, ун гектарның үзен таксаң да өстерәрлек иде. «Ватан»нар сулып төштеләр. Хәлимнең ышанычлы сүзләре алар алдында көчләрен җуйдылар. Хәлим үзе дә уйга калды:

— Ну, атлары... Айя-ай.

Ибрай кулын каш өстенә куеп:

—Ерактан күрмим, әллә синең Шәехтайдан да җиллерәкме? — дигән булды.

Шундый чакта да бит!.. Хәлим, тәмам ярсып, Ибрайга әле генә үз төрәне каерып салган кантарны ыргытты. Ибрай чүгеп калды, кантар Шәпигә килеп тиде.

Мондый чакта көләләр. Ләкин хәзер берәү дә көлмәде. Ибрай үзе дә уңайсызланып китте. Ул Хәлим янына килеп, ихлас күңеленнән кайгыртучанлык күрсәтеп:

— Без дә колхоздан яхшырак атлар сорыйк соң,— диде.

— Яхшы атлар безнең ун гектарны түгел, колхозның мең гектарын сөрү өчен кирәк,— диде Хәлим.— Пионер икәнбез, шушылар белән җиңеп чыгыйк без.

Шәйхаттар бабай җөпләп куйды:

— Һай, авызыңа бал да май, улым!

Ибрай кулын селтәде:

— Булмаганны...

— Бер дә булмаганны түгел. Мин инде күреп кайттым... Бөтенләй атсыз сөргән колхозчыларны да күреп кайттым мин... Үзләре җигелеп...

Шулай башланган сүз, Фәрдәнә килү белән, җыелышка әйләнеп китте. Бер дәфтәр битенә карар язылды. Карарның башына: «Кадрлар барысын да хәл итә»,— дип язып куйдылар.

Аннары практик чараларны яздылар:

...Мәктәпкә барганчы да чыгып берәр сәгать сөрергә. Кич җидегә кадәр сөрергә. Якшәмбе көннәрдә иртән алтыдан кичке сигезгә кадәр эшләргә. Атларны авылга алып кайтып йөрмәскә. Аларны төнлә басуда саклар өчен, өч пионер билгеләргә. Сабанчылар звеносына тагы берәр пионер кушарга, диделәр һәм шушы карар нигезендә эшкә керештеләр.

5 ӘТИ СОРАП ЯЗГАН

Хәлим, беренче чаңны ишетүгә торып, урамга чыкты. Караңгы иде әле урамда. Көн салынкы. Авыр соры болытлар авыл өстенә бик түбән төшкәннәр. Яумый әле. Ләкин менә-менә сибәли башлар төсле — һавада җылы, рәхәт ләйсән яңгыр исе аңкый. Яңгыр теләп, яңгыр хәбәрчеләре — сыерчыклар оча кайдадыр. Су буендагы талларга кунып йоклаган каргалар, кар-кар кычкырып, берсен-берсе уяталар. Авыл уянып килгәнне белдереп морҗалардан ишелеп төтен күтәрелә. Төтен эчендә берән-сәрән кызыл очкыннар оча һавага. Калөм очы тикле кечкенә, кәгазь көле шикелле зәгыйфь бу очкыннар, күз ачып йомар арада, өсләренә диңгез акса да сүнмәслек сихри көч булып күренәләр дә кинәт сүнеп юк булалар...

Бик тын әле.

Әнә анда, шул тынлыкны бозып, бер капка ачылды, гүя аны да йокысыннан вакытсыз уяттылар, ачылганда, җәберсенгәндәй итеп, карлыккан тавыш белән шыгырдап куйды.

Капканы ачып чыгучы — колхоз председателе Сәлимҗан абзый иде. Ул, үз алдына «...Гектар... сабан... кеше...» дип сөйләнеп, ашык-пошык узып китте. Әнә мәктәп ягыннан берничә кыз бала килеп чыкты. Болар былтыр көз башланган эшне дәвам иттерүче тимурчылар — Фәрдәнә, Гөлгенә һәм тагын берничә пионерка иде. Пионеркалар

җанлы сөйләшә-көлешә узып киттеләр. Хәлим, я күреп туктарлар да, сөйләшә башларлар дип, капка баганасына ышыкланып калды. Алар узып киткәч, каршы якка чыгып, бер тәрәзәне шакыды:

— Хәдичә түтәй, Мотыйкны уят инде!.. Сабан беткәч йоклар, Хәдичә түтәй...

Аннан Хәлим Шәпиләргә килде. Өй түрендәге бакчаларына кереп, тәрәзәләрен чиертергә кулын күтәрде ул. Ләкин, никтер, чиертмәде, тавыш-тынсыз гына чыгып китте һәм икенче бер тәрәзә төбенә килеп туктады.

— Ләмига түтәй, сабанчыңны уят инде! — Җавап бирүче булмагач, Хәлим өйгә керде.— Исән-сау гына торасызмы, Ләмига түтәй

Ләмига түтәй Черки Ибрайның әнисе. Ул, учагын ташлап, Хәлимнең сәламен алды һәм аңар сәке кырыенда урын күрсәтте.

— Әй, Хәлим, нинди генә рәхмәтләр әйтим икән инде сиңа,— диде ул.

— Нәрсә өчен, Ләмига түтәй?

Ләмига түтәй сәкедә йоклап яткан Ибраһимга таба ишарәләде:

— Бәй, малайны тәмам кеше иткәнсең ич.

Хәлим борылып Ибрайга карады:

— Әллә өстен дә чишенми яткан инде...

— Чишенгән иде, торып яңадан киенде. «Иртәгә Хәлимнәр торганчы чыгып сөрә башлыйм, уятмый калма», дигән иде дә, кызгандым, күр, ничек каты йоклый.

Хәлим көлеп җибәрде, Ләмига түтәй дә көлемсерәде.

— Рәхмәт, бик рәхмәт сиңа,— дип дәвам итте ул. Хәлим аны бүлде:

— Миңа түгел, пионер отрядына әйт син рәхмәтеңне, Ләмига түтәй.

Ләмига түтәй кулын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә Хәлим янына килеп утырды:

— Әй, син лә, син. Башлап йөрүче син булгач, син дим инде мин. Күз алдында үзгәрде бит малай, әтисе кайткач, танымас та инде.

Ибрай чыннан да, танымаслык ук булмаса да, соңгы айларда шактый үзгәргән иде.

Ә элек нигә шундый була соң ул? Ибрайны әтисе баштанаяк укытучыларга тапшыра. Мәктәп барысын да эшләргә тиеш дип белә. Ул аның укуы белән кызыксынмый, дәфтәрләрен, табельләрен карамый, укытучылары

белән очрашып сөйләшү юк. Өстәвенә аның эше дә шундый. Тегүче була ул. Атналар, айлар буена өйгә кайтып керми. Аршины белән кайчысын, бер шакмак акбурын, инәсен-җебен, киндер алъяпкычына төреп, чана башына бәйли дә авылларга чыгып китә. «Һәйбәт өнәр», ди ул Ибрайга. «Өйрән. Мәңге бетми торган...» Ә Ләмига түтәй исә үзенең иркәсен, бердәнберен үз иркенә куя. Аның вак-төяк шаяруларына әһәмият бирми. Мәктәптән, улыгыз начар укый, дип килеп әйтсәләр, әйдә, түрә булмаса да ярар, колхозчының да дөньясы ярый торган хәзер, китап, гәзит укый белгәч, хат яза алгач, житмәгән тагын, ди. Алаймы? Бик яхшы. Ибраһим теләсә бара мәктәпкә, теләмәсә — юк. Нәтиҗәдә, бер ел классында утырып кала. Икенче елны да көч-хәл белән генә күчә.

Иркә бала, кагыйдә буларак, ялкау була.

Иркә — ялкау, шулай ук, кагыйдә буларак, усал була. Ибрай тәмам усалланып житә. Ул укытучыларын гына түгел, әнисен дә тынламый башлый. Теләсә кайсы малайны тотып кыйный, кызларга бәйләнә... Кешегә җәбер салудан да тартынмый башлый ул. Аның рогаткасы бер генә тәрәзәне коеп төшерми, бер генә тавык-чебине аксатмый... Ниһаять, әнисе дә үзенең ялгышын аңлап ала, ләкин инде бик соң була.

Нишләргә?

Берәүгә бер, берәүгә бер дару килешә. Пионер отряды һәм укытучылар, Ибрайның дәрәҗә яратканын сизеп алып, шуның белән дәвалап карарга булалар. Җыелышлардан бер жыелышта моны президиумга сайлыйлар. Әдәпле генә утыра Ибраһим президиумда. Ә икенче бер тапкыр, бөтен мәктәпне таң калдырып, жыелышның председателе итеп куялар. Көн тәртибендә соңгы мәсьәлә — ике малайның, авыз-борыннарын жимереп йөреп, укудан калулары турында була. Кәгазьдә көн тәртибен күргәч, Ибраһимның күзләре шарланып китә. Белгән булса, әлбәттә, сайлый башлауга чыгып шылган булыр иде ул. Ә инде өстәл артына, укытучылар арасына бер кереп утыргач, ничек шыласың!.. Ибрай, ни сөйлиләр — ишетми, кем сөйли — күрми. Ул бары көн тәртибендәге зур хәрефләр белән язылган соңгы мәсьәләне генә күрә. Тиздән шуңа чират житәсен белеп, газапланып утыра.— «Җир ярылсын иде дә жир тишегенә кереп китсәң иде...» — Ләкин жир ярылмый, чират соңгы мәсьәләгә житә. Председатель Ибраһим: «Соңгы мәсьәлә шундый,

хәзер шуңа күчәбез» дигәндә, әлбәттә, пырхылдап көлеп җибәргән булырлар иде дә, залга сибелеп утырган укытучылар балаларны алдан кисәтеп куялар. Зал көлми...

Сугышуның, дәрес калдыруның ярамавы турында укытучылар сөйлиләр, пионерлар сөйли. Ниһаять, президиум членнары, нишләтәбез инде бу сугыш чыкмарларын, дип Ибраһимнан киңәш сорыйлар, бу вакытта Ибрай сәхнәдән чак йөгереп чыгып китми. Ахырда укытучылар Ибраһимга малайлардан сугышмаска, дәрес калдырмаска сүз алырга кушалар.

Ибрай: «Моннан болай сугышмассызмы, дәрес калдырмассызмы?» дигәндә укытучылар никадәр тыеп утырсалар да, зал бер гөжләп ала. Ибрай ишетмәмешкә салыша... менә ул, фәлән белән фәләнгә, дәрестән калган, сугышып йөргән өчен, шундый-шундый җәза бирергә, дигән протоколны укып кул куя.

Әлбәттә, Ибрайга бу җыелыш берникадәр тәэсир итми калмый. Ул берничә көн яхшы гына йөри. Шул очрактан файдаланып, пионерлар, хулиганлык өчен инде кайчандыр бер тапкыр пионердан чыгарылган, яше дә үтеп барган Ибрайны пионерга керергә өндиләр. Ибрай керә. Анда да аңар мавыктырырлык эшләр кушалар; ничек эшләсә дә җаеннан торалар. Ибрайның сәхнә белән мавыкканын сизеп алып, драмтүгәрәккә тарталар. Ул баш рольне сорый һәм, ни булса ул дип, Ибрайга баш роль бирәләр. Әйбәт уйнамый Ибрай, шулай да аңар кул чабалар. Тагы икенче бер роль бирәләр... Шулай итә-итә Ибрай үзгәрә башлый. Ә укуга, физик эшкә килгәндә үзгәреш аз була. Атны да ахыргача тәрбияләп чыкмый — ике атна дигәндә туя. Тирес ташырга да, үзегезгә мәгълүм булганча, әнисе кугач кына чыга, икенче көнне аннан да «авырып кала». Сабанны да башта начар сөрә ул. Бу эшкә, файдалы эш итеп түгел, бер зәвык итеп кенә карый. Иптәшләре аны оялтып карарга булалар. Ялкаулыгы турында әче генә итеп стена газетасына язалар. Күрсәткеч тактасына зур карикатурасын ясап куялар: үзенең сөргән җиренә сыңар аягы белән генә басып тора. Чөнки бу җир шулкадәр кечкенә, икенче аягын куярлык түгел. Рәсем астында: «Тагы бер-ике көн сөрсәм, бу аягымны да куярга урын булыр иде инде...» — дип язылган. Ә аның янында кечерәк кенә бер малай үзе сөргән җирнең бер башына баскан да икенче

башын бинокль аша күзәтә... Ибрай тактаны кырдан кайтканда күрә, ләкин күрмәмешкә салышып узып китә. Ә кич белән, аны тибеп очырырга дип, урамга чыга. Аягын да күтәрә ул тибәргә дип, ләкин типми кала. Тибимме-юкмы дип икеләнеп торганда, аның иңбашыннан урам каравылчысы, әнисе ягыннан бабасы эләктереп ала:

— Әй, әй, әй-й... Алай булмый, улым, Ибраһим. Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә инде син...

Ибрай аягын төшерә.

— Ни генә әйтим инде мин сиңа, Ибраһим,— ди бабасы,— бөтен нәселнең битенә корым яктың бит син моның белән. Әбиең булып, әбиең борчыла. Әле менә этиең нәрсә әйтер. «Иткәнсең икән миңа ярдәмне, ишкәнсең икән!» дияр инде... Эх сине, сине... Ә кемнән җиңдергәнсең бит әле, ботың буе малайдан бит. Оял әзрәк,— ди бабасы. Ул, рәсемне тагын бер карар өчен, шырпы сыза башлый. Ибрай аның шырпылы кулына ике куллап ябыша.

— Кирәкми, бабай...— ди ул һәм, бер сүз дә әйтмичә, бераз уйланып тора.— Мин икенче болай булмыйм, бабай, бик каты тырышып эшлим,— ди ул елак тавыш белән.— Ләкин тактаны алсыннар иде, бабай...

— Дөньяда торыр исәбең булса, аң бул, бала: ничек өйрәнсәң — шуңа китә...

— Тактаны, бабай...

Тактаны алалар. Ибрай, чыннан да җелегенә үткән икән, яман хурланган икән, бик бирелеп, бик тырышып сөрә башлый.

Ләмига түтәй әнә шуларны хәтереннән кичерде дә, Ибрайны ята башлады. Хәлим Ләмига түтәй белән саубуллашып чыгып китте һәм яңадан бая шакымый киткән тәрәзәгә, Шәпиләргә килде. Бераз икеләнеп торды да, шакымыйча гына, өйләренә барып керде. Керүгә аны Шәпинең сеңелләре, былтыр әниләре авырганда, пионерлар алып килеп пешереп биргән тавык ботларын Хәлимнең тезләренә утырып ашаган кечкенә кызлар, кочып алдылар.

— Әниегез кайда, үскәнем?..

— Фермага китте, Хәлим абый.

— Абыйны уятыйкмы, Хәлим абый?

Хәлим зур сәкедә кечкенә генә булып йоклап яткан Шәпи янына килде. Шәпи, әйтерсең лә, бөтенләй тере

түгел, шулай каты йоклый иде. Сулаганы да сизелми иде малайның. Күрсәткеч тактасында, Ибрай янында, сөргән җирен бинокль аша карап торучы пионер шушы иде инде.

Хаклы рәвештә мактадылар аны. Шулкадәр бирелеп, шулкадәр көнләшеп эшләде ул, башкалар узып китә башлагач, елап җибәрә торган иде. Хәлим булып Хәлим таң калды аның бу хәленә:

— Бу нишләвең, Шәпи?

— Әти сорап язган: фронтка ничек ярдәм итәсең? дигән. Минем аны сөендерерлек җавап язасым килә; Ибрайдан күп итеп, синең хәтле итеп эшләгәнемне язасым килә минем,— диде Шәпи һәм шуңарга иреште дә. Кичә күрсәткеч тактасына Шәпинең нәкъ Хәлим кадәр сөргәнен язып куйдылар.

Хәлим, Шәпине уятырга кызганып, аз гына булса да йокласын әле дип, аның аяк очында утырып торды. Әкрен генә, сакланып кына кечкенә кулын тотты ул Шәпинең. Кулы кайнар, бармаклары сөялләнеп чыккан иде. Кыз баланыкы шикелле нәфис, ак бите язгы җил белән каралып киткән, иреннәре ярылып беткән иде.

Хәлим аның аяк очында, тагы бер генә, тагы бер генә суласын, дип утырды-утырды да, ниһаять, инде уятыйм дип, йомшак кына итеп иңеннән тотты. Шунда ук кулын кире алды, әкрен генә торды, бик әкрен генә итеп, кечкенә кызларга эндәште:

— Йокласын бераз. Без киткәндә генә уятырсыз. Кил, үскәнем, менә син шуннан без киткәнне карап тор,— диде һәм идәнне шыгырдатмас өчен йомшак кына атлап урамга чыгып китте.

6

ДӨРЕС ИНДЕ, ДӨРЕС...

Пионерлар авылдан чыгып сабан җирләренә килеп житкәндә, караңгы иде әле. Алар канау читләрендә төн буе яшь үлән ашап йөргән атларын эчерделәр, сөя-сөя җиктеләр дә сабаннарына керосин фонарьлары элеп кабыздылар. Шәйхаттар бабайның көн дә әйтелә торган: «Хәерле сәгатьтә, оланнар», дигәнен ишетү белән атлар әкрен генә кузгалып киттеләр. Тагын сабан төрәннәре җирне кисеп керде. Тагын бураналар сызыла башлады. Сыер да, әле бетмәдемени бу эшегез дигән күк беравык

зарланып мөгрәп торды да, тырманы ялкау гына өстерәп, китеп барды.

Шәйхаттар бабай хәзер, беренче көннәрдәге шикелле, сабаннар артыннан ыгы-зыгы килеп йөрмәде, пионерлар эшкә төшенеп житкәннәр иде инде. Ул, атлар кузгалып китүгә, көрәкләрен тотып, эшне кайдан башларга белми торган, әле бүген беренче тапкыр килгән пионерларны эшкә кушып чыкты:

— Фонарецны менә шунда куй да шушы җирне казы. Тирән казы. Бер батыруда җиткерә алмасаң, ике батыр. 20 сантидан ким булмасын. Сантиның никадәр икәнен күрсәттеләрме әле мәптегегездә?

— Мәптек түгел, бабай, мәктәп.

— Ну, мәктәп тек мәктәп... Мә, 20 сантидан ким итмә.

— Санти түгел, бабай, сантиметр.

— Һәй-й, миңа димәгәе... Әйдә, башла. Синең участок менә шуннан шунда чаклы.

Пионерлар, шау-гөр килеп, чи калган җирләрне казый башладылар. «Илшат»ларның «Ватан»нар шактый эшләгәч кенә торып чыккан кыр бригадирлары, бу хәлне күреп, хәйран калды һәм, йорттан йортка кереп, тартып-йолкып иптәшләрен уятып йөрде:

— «Ватан»нар чыкканнар да инде, фонарьлар кабызып чыкканнар!

— Нинди фонарь?

— Чәй белән эчә торган... Унбиш кенә түгел! Әллә бөтен мәктәпләре купкан инде...

— Кит лә!

— Ышанмасаң, ята бир инде алайса...

Шактый вакыт үткәч, «Ватан»нар инде берничә тапкыр алмашынып алгач, «Илшат»лар да үз җирләре өстендә күренделәр. Аларның да кулларында фонарь иде. Ләкин ул фонарьларның кирәге калмаган иде инде. Көнчыгыш алланып килә иде.

Эшкә усп күребрәк алынган «Илшат»лар да, «Ватан»нардан күрмәкче, ныграк җигелә төштеләр, күршеләреннән күреп, икенче көнне алар да аякларын иртәрәк киенделәр: ««Илшат» хәтле «Илшат» «Ватан» нан калышса, тавыклар көләр...» Ләкин «Илшат»лар бу турыда уйлаганда, симез атларын күздә тоттылар, әйе, алар да, мең пот өчен көрәшәбез, диделәр. Ләкин алар мең потны өч нульле бер таяк итеп кенә күрделәр. «Ватан»нар исә атларыннан бигрәк үзләренә ышандылар. Җан-фәрманга

тырышып эшләделәр алар. Хәлимнең бер тапкыр үкчәсе суелды. Ни кисә дә авыртты. Хәлим суелган җирен миндәр мамык куеп бәйләде дә, сабаны артыннан яланаяк тәпиләде. Бер тапкыр Каюмның аягына ат басты. Аяк йөзе күгәреп чыкты. Ләкин Каюм, иптәшләре әйтсә дә, кайтып китмәде, угалады, йөгереп йөргәләде, Шәйхаттар бабай рецепты буенча бака яфрагы ябыштырып бәйләде дә сабанына барып тотынды. Чөнки алар мең потны өч нульле таяк итеп түгел, 250 капчык ашлык итеп, 40 йөк икмәк итеп күз алларына китерделәр. Моның фәләнчә рота солдатны фәләнчә тапкыр ашатырга җитәчәген күз алларына китерделәр. «Ватан»нар моның политик эш икәне, эшләнми калырга ярамый торган эш икәне турында уйладылар. Шуңа күрә алар барлык мөмкинлекләрдән файдаландылар. Яз җитә башлагач, ай буена көн дә берәр сәгать артык укып килгәннәр иде, хәзер икешәр сәгать ким укыдылар. Башта һәр сабанга ике пионер куйганнар иде, авыр була башлагач, дүртәргә җиткерделәр. Арыган атларны төнлә авылга алып кайтып йөрмәделәр, канау буендагы сусыл яшел үләндә сакладылар. Ниһаять, «Ватан»нар агроном киңәше буенча колхозның өч сыерын җигәргә өйрәттеләр дә алмаш-тилмәш тырмага җиктеләр. «Илшат»лар башта бу хәлне күреп көлделәр. Янәсе: «Болайга киткәч безнең күршеләр тиздән тавыкларын да сава башларлар». Ә инде бу өч сыерның өч ат сөргән җирне тырмалап бетерә барганын күргәч, үзләре дә тырмага сыер җигәргә булдылар. Ләкин өйрәтелмәгән сыер алай тиз генә тәртәгә кермәде. «Суйсагыз да кермим мин анда», дигән шикелле, ачулы мөгрәп, җиргә сузылып яты. «Илшат»лар аны, кайсы койрыгыннан, кайсы мөгезеннән өстерәп, кайсы чыбыркылап, торгызырга маташтылар. Торгызырсың алай гына сыерны.

«Ватан»нарның ял вакытында булды бу хәл. Алар яңа гына елгада юынып менгәннәр һәм тары өйрәсе ашарга утырганнар иде. Сыер мәзәген күреп, барысы да яр читенә йөгерделәр.

— Ха-ха-ха!.. Нихәл, күршеләр... Ә сез сыерга тимәгез, мал иясенә охшамаса, харам була, ди бит ул. Хи-хи-хи...

«Илшат»ларның сүз әйтерлекләре калмады. Бик каты оялдылар алар. Нишләргә дә, сыерны нишләтергә дә белмәделәр.

— Үзегез дә шунда ятып торыгыз,— дип көлде кемдер Хәлимнәр ягыннан.

— Ә, алаймы? Ятып торыгызмы?

Берничә көннән «Илшат»лар тырмасын да, көне-төне өйрәтелгән, җиргә ятмый торган зур-зур сыерлар өстери башлады.

Күршенең тавыгы күркә булып күренә. «Ватан»нарның сөрелгән җирләре «Илшат»ларга чынбарлыктагыдан зуррак булып күренде. Башта «Ватан»нар белән үзләрен чагыштырганда, фил белән бака әкиятен искә төшереп көлгән «Илшат»лар хәзер икенче төрлерәк сөйләшә иделәр.

— Үзебез көлкегә калмыйк...

Мондый шик тугач, алар һәр көн «Ватан»нарның эш нәтиҗәләрен күзәтеп кайту өчен үзләренең разведчикларын җибәрә торган булдылар. Көндез килсә дә аны һичкем куып җибәрмәс иде, югыйсә. Разведчик «Ватан»нар басуына кара төн җиткәч кенә барды. Шулай күңелле, шулай рәхәт, шулай серле... Разведчик кечкенә көймәсендә елга аша тавышсыз гына ишеп чыкты да ат саклаучы пионерларга күренмәс өчен разведчикларча шуышып барды.

Ух, никадәр романтика!.. Анысы турында уйлый белде малай, ә менә эшенең сыйфаты турында җитәрлек уйламады. Ул «Ватан»нар җиренең «Илшат»ка карап торган башын үлчәде дә иңенә тапкырлады. Ә бит җирнең аргы башы аз булса да киңрәк булуы мөмкин... Разведчик бусын искә алмады. Әнә анда, түбәндә, гөлҗимеш куаклары артында күптән сөрелгән җир үзенең чәчүчеләрен көтеп ята. Разведчик анда кадәр барып җитмәде. Ул үзенең, эшне хәвеф-хәтәрсез, тавыш-тынсыз башкаруына сөенеп, килгәндәге шикелле әкрен шуышып, тын йөзеп кайтып китте. Дүрт күз белән көтеп торган иптәшләренә күзәтүенең нәтиҗәсен хәбәр итте:

— Фәлән хәтле генә...

— Ялгышмадыңмы?

— Юк, юк...

— Күрмәделәрме?

— Юк, юк...

Ә «Ватан»нар разведчикны күрделәр. Ә Каюм, кайчандыр фронтка китү, разведчик булу турында хыялланып йөргән Каюм, узган төндә «Илшат»лар эшен алар разведчигыннан чаярак итеп, елганы аңардан да тавыш-

сызрак кичеп, аңардан да әкренрәк шуышып йөреп, карап кайтты. Карап кына түгел, җир өстендә шуыша-шуыша, үлчәп тә чыкты ул. Өчпочмак белән төгәл итеп үлчәде.

— Җиде дә өч.

— Яхшы үлчәдеңме?

— Ике тапкыр.

— Ялгышмадыңмы?

— Һич.

Ә бу вакытта «Ватан»нарның сигез гектар да кырык биш сотый булган иде инде.

Менә ни өчен бүген алар: «Күрегез, белегез!» дигән шикелле тантаналы итеп, шау-гөр килеп, фонарьлар кабызып чыгудан да курыкмадылар.

Якшәмбе көн иде бу, уку көне түгел. Шуңа күрә бүген алар төнгә кадәр булса да эшләп, сабанны бетереп кайтырга уйладылар. Калган бер дә илле биш сотый атлаган саен кимеде. Анда-санда төртеп чыгарга өлгергән чүп үләннәр төпләре-тамырлары белән әйләнеп төштеләр, инде кибеп, соры төскә кергән җирләр карала бардылар. Аның саен күңел үсте. Эш дәртлерәк барды. Төшкә кадәр эшләп, төштән соң балыкка китәргә уйлаган «Илшат»лар да, «Ватан»нарның болай этләнеп ятканнарын күреп, эшләрен дәвам иттерделәр. Шулай да алар түзмәделәр, кояш баер алдыннан кайтып киттеләр. Ә «Ватан»нар юк. Кич булды, караңгы төште, «Ватан»нар әле һаман «этләнә» иделәр.

— Бетереп кайтабыз...

— Бетереп...

Ләкин йөгерүчеләр үзәкләренә үткәч әйткәннәрдер инде: «Беренче километрлар алай түгел, әмма актык метрларны үтү бик читен...» Биредә дә шулай булды. Малайлар арыдылар. Авырлык беренче номерларга (Хәлим, Каюм, Ибрайга) төште. Хәлим аяклары белән түгел, ә ниндидер авыр юан бүрәнәләр белән атлый шикелле иде. Шуның өстенә аның бер аягы, суелганы, һаман да сызлый иде әле, колаклары шаулый, башы авырта иде. Баш күп укыганда гына түгел, чамадан тыш эшләгәч тә авырта икән ул...

«Мин шулай, ә башкалар ни хәлдәдер?» — диде Хәлим һәм, иптәшләр бөтенләй арып егылмасын дип ялны ешайтты. Ул эш арасында Ибрайга карап-карап алды. Ибрай тешләрен кыскан да, сөйләшүгә дә, җырга да

кушылмыйча сөрә бирә. Ахры, чын-чыннан Хәлим белән ярышырга уйлаган. Элек сабан артыннан, арбасына ябышып барган юлаучы шикелле, өстерәлеп йөргән Ибрай әнә ничек тырышып атлый хәзер!

— Тукта, тукта, бу бит болай булса...

Хәлимнең шикләнүе урынлы иде. Менә сөрелгәнне үлчәп йөрүче пионер, Ибраһимның иртәдән бирле эшләгән эшен фонарь яктысына тезләнеп, кәгазьгә карап санап чыкты да кычкырып җибәрде:

— Үндүрт сотый! Ибраһим абыйның үндүрт сотый!

Хәлимнең бу вакытта унөч ярым гына иде әле. Ул, йөгереп килеп, үлчәүче малайның кулындагы цифрларны үзе санап чыкты.

— Дөрес...

— Дөрес инде, дөрес,— диде Ибрай көлеп,— сыңар аяк белән басып тору түгел, тәгәрәп йөрерлек монда минем хәзер, марайрар!

— Ах, шайтан!..

— Ә син борчылма... Мин сине, иске дусны, бер аягыңны күтәртеп тотмам. Минем арттан куып җиткәнче, тәпиеңне минем җиргә куеп торырсың...

— Ха-ха-ха!..

Хәлим дә көлде, ә йөрәге... Аңа, ничектер, күңелсез булып китте. Гүя ул кинәт кенә мәңге үземнеке булып калыр дип өмет итеп йөргән якын нәрсәсен җуйды. Иртәгә бөтен отряд шул турыда шаулар, ә аннары стена газетасы...

Ләкин бу хәлнең Хәлим өчен күңелсез ягыннан күңелле ягы зуррак иде. Узды — димәк, күңелен салып эшләде. Узды — димәк, ул инде бияләйләр тегеп яткандагы Ибрай түгел. Узды — димәк, ул башкаларны яхшырак итеп эшләргә канатландырды... Тагын шунысы бар бит әле, ул безнең казанда кайнап шул хәлгә килде ич... Хәлим, чын күңеленнән шатланып, Ибраһимның кулын кысты.

— Молодец, Ибраһим, тәбрик итәм, егет,— диде ул һәм сабанына килеп тотынды.— Әйдә әле, малкай! Чалкаш артыннан җиткәнче, шагом марш!

Балалар барысы да Хәлим ягында иде, җиңелүен ишеткәч, пошынганнар иде; хәзер аның бу эшкә аек каравын күргәч, җанланып киттеләр. Ә беркөн үлеп яткан «мәет» һәм аның баш очында елап утырган «хатын-кызлар» — өч әбер-чебер, авыл ягыннан тиз-тиз атлап килгән

Тәзкирә апа каршысына йөгерделәр:

— Ибрай абый Хәлим абыйны там-таллар арасында калдырды! Ибрай абый Хәлим абыйны там-таллар арасында калдырды!..

7 БЕТЕРЕП КАЙТАБЫЗ

«Илшат»лар кайтып китүгә байтак вакыт үтеп, караңгы төшеп җиткәч, «Ватан»нар тагы фонарьларын кабызып җибәрделәр. Фонарьлар кабынуга тирә-як тагы да караңгыланыбрак киткән төсле булды. Җир өсте ниндидер серле, тирән урман эченә җәелгән партизаннар лагерена ошап китте. Сабан артыннан бөкрәя төшеп барган пионерларның кечкенә гәүдәләреннән «Мең дә бер кичә»нең балыкчы әкиятендәге гыйфрит кадәр зур күләгәләр сузылды. Фонарьлар аз гына селкенеп киткәндә, бу күләгәләр гаҗәп зур тизлек белән басуның бер очыннан икенче очына күчтеләр. Бер читтә ял итеп яткан пионерлар, күләгәләргә төртеп күрсәтә-күрсәтә, шаулашып алдылар:

— Хәлим абыйны гына карагыз әле, малайлар! Телеграмм баганасы шае.

— Һа, Ибрай абыйны кара син!..

Малайлар берничәсе берьюлы җырлап җибәрделәр. Ләкин җыр бик тиз басылды, шау-шулар кимеде. Язгы салкынча һава арыган тәннәргә рәхәтлек биреп оета башлады. Ялга туктап хуш исле чирәмгә сузылып ятуга, күзләр ихтыярсыз йомылдылар. Ләкин Шәйхаттар бабайның әледән-әле: «Алмашка, егетләр!» — дип кычкырып торуы, уен сүзләр әйткәләп куюы аларга йоклап китәргә бирми иде.

Менә берничә пионерның әниләре килеп, өйгә кайтырга чакырдылар. Кайтамы соң!.. Ярты төн якынлашып килгәндә, берсенең әнисе улына кечкенә чүлмәк белән кайнар аш китереп китте.

— Йөрисез шунда юкка җык күреп,— диде ул малаена һәм, суынмасын өчен тастымаллар белән кат-кат төрелгән чүлмәкнең авызын чишә-чишә, дәвам итте: — Барып чыга торган булса, бер хәл иде... Чәчеп карадык инде без аны, тарыны. Үсми ул безнең җирдә...

Бу шомлы сүзне пионерларның беренче ишетүләре түгел иде. Хәтта колхоз председателе үзе дә тарыга карата шундыйрак караштa иде. Концерттан соң Тәзкирә

апа белән Хәлим киңәшкә килгәч: «Тары — тары инде ул,— диде председатель телен шапылдатып,— бодайга тырыша алсагыз икән сез менә...»

«Шулай итеп, бөтен кешелек тарихы тудырган китапларны өйрәнә-өйрәнә чәче-сакалы агарып беткән, гомере буена тәҗрибә кырыннан кайтмаган галимнәр безнең Сәлимҗан абый белгәнне дә белми микәнни?» — Хәлим ул чакта председательнең бу карашын иптәшләренә әйтмәде. Фәрданә белән генә сөйләште дә почта алырга баргач тагы бер тапкыр агроном янына кереп чыкты. Агроном аңа тарының өстенлекләре турында бик озак итеп сөйләде. Әллә ничә китаптан астына кызыл карандаш белән сызылган юлларны укып күрсәтте һәм Хәлим агроном яныннан, беркемнең дә тискәре сүзенә карамаска карар кылып, кайтып китте. Ә хәзер килеп, нинди дәртләнеп эшләп ятканда, эшнең иң кыены бетеп килгәндә, менә бу җиңги күңелгә шик салып утыра... Хәлим аның сүзләрен ишетмәс өчен, аның сүзләрен башка пионерларга ишеттермәс өчен гармонен тартып җибәрде. Күбрәк бала җырласын өчен ул җырның күңеллерәген сайлады.

Шул чакта учетчы пионер өчпочмагын атлата-атлата килде дә кычкырып салды:

— Утыз биш! Утыз биш сотый гына калды, малайлар!

— Һәй, яшә, малай, Мортаза!..

— Бетерәбез! Бетереп кайтабыз!..

Малайларның арулары бетеп киткән кебек булды. Ләкин кебек кенә булды. Пионерлар гына түгел, атлар да бик йончыганнар иде. Шәйхаттар бабай атларның атлаган саен авыррак пошкырганнарын ишетте, җылынган тиреләреннән чыккан парны күрде һәм «бетереп кайтабыз» диючеләргә каршы килде:

— Булмый, оланнар. Атларны эштән чыгарыр хәл юк,— диде ул. Һәм Шәехтайны тугара да башлады. Хәлимнәр никадәр ялынсалар да, ул үзенекен итте:

— Сорамагыз да, булмый да, оланнар.

— Алайса без кайтып председательдән сорыйбыз.

Бабай кырт кисеп:

— Олырагыннан сорасагыз да юк, — диде. Һәм, малайларның киреләнеп торганнарын күргәч, атларның калган икесен дә үзе тугарып, үләнгә илтеп куйды.

— Өч-дүрт сәгать,— диде ул.— Өч-дүрт сәгать ял итеп алсыннар, аннары карарбыз.

— Карарбыз димә инде ичмаса, җигәрбез, диген.

— Ну, җигәрбез... Барыгыз, кайтып йоклап килегез.

Кайтып йөрергә никадәр вакыт кирәк, җылы, йомшак урыннан торып килү — үзе читен булачак. Сабанчылар кайтып йөрмәскә булдылар. Алар гына түгел, чи калган җирләрне көрәк белән казып бетергән малайларның да авылга кайтасылары килмәде... Төн ничек тын, ничек серле, тирә-як дөм-караңгы. Әйтерсең лә куе калын соры болытлар, күк йөзен генә түгел, бөтен әйләнә-тирәне ярым түгәрәк гөмбәз булып томалап алганнар. Бик еракташы тракторларның атлар туктагач кына ишетелә башлаган тигезле-тигезсез дөпелдәүләре шул хыялый гөмбәзләргә нindидер серле таяк белән дөбердәтеп торган шикелле булып ишетелә. Елга читендәдерме, канауның елгага төшкән башындадырмы, янгыр теләп бакалар сайраша. Еракта, камышлы күлдә озак юллар очып килеп, бүген ач калган кыр үрдәге тынгысыз бакылдый. Тын һавада, караңгы күктә, әкрен генә ишек ачып япкандагы шикелле итеп, җиңел генә канат каккан тавышлар ишетелә. Соңга калган торналар, киек казлар шулай кайталар җылы яклардан...

Пионерларның берсенең дә сирәк кабатлана торган матур төнне ташлап китәселәре килмәде. Аларның бигрәк тә җир сөрелеп беткәнне күрәселәре, Шәйхаттар бабайның: «Ну, егетләр, тәки булдырдыгыз бит, рәхмәт төшкерләре!..» дигәнен ишетәселәре килә иде. Авылга сабанчы пионерлар белән бергә тантаналы итеп кайтып керәселәре килә иде.

Пионерлар ике җиргә учак яктылар да кайсы баш астына кантар куеп, кайсы җир өеп, кайсы беләген мендәр итеп йокларга яттылар. Яттылар һәм берәм-берәм йокыга да китә башладылар. Чи калган җирләрне казып йөргән малайлар сабанчылар кебек үк арымаганнар иде.— Безнең йокы килми,— дигән булып, учак әйләнәли тезелеп утырып, әкиятләр сөйләшергә керештеләр. Ләкин алар да, әкиятләрен ярты юлда калдырып, берәмберәм авып төштеләр.

Бары Хәлим генә йокламады. «Йоклап китсәм, уяна алмам, берсе дә уяна алмас», дип курыкты ул һәм тырма өстендә йокы белән көрәшеп утырды. Йокы каты һөҗүм итә башлагач, торып иптәшләрен карап йөрде. Якында

гына җимерек ындыр табагы бар, шуның муртайган түбә саламнарын алып килеп, өс-башлары юкарак иптәшләренең өсләренә ябып чыкты. Аннары, берсеннән берсенә күчеп, атларны карап йөргән Шәйхаттар бабай янына килде.

— Маллар ашыймы, бабай?

Шәйхаттар бабай җавап урынына Хәлимне битәрләп әйтте:

— Ә син атны алай чамадан тыш кума. Ул мескен болай да бик әрсез нәмәрсә, егылганчы эшләргә мөмкин. Ләкин аны беркайчан да ул чиккә китереп җиткерергә ярамый. Алай аяк сузуын көт тә тор. Син үзең дөнья күргән егет, ә үзең шуны белмисең.

— Белмим шул, бабай.

— Белмәсәң, бел менә.

— Ачуланма инде, Шәйхаттар бабай.

— Ачуланмыйм мин. Әйтүем шундый минем... Әнә ничек җан-фәрманга өстери бит ул, жаныкаем, сабанны...

— Һе!..

— Һе шул менә...— Шәйхаттар бабай бер тын сөйләшми ятты,— аннары хискә бирелеп, болай диде: — Һәйбәт смена үсә, шуңар сөенәм әле мин...

— Әйбәтме, бабай?

— Бинһая... Дөрес, эшне аны без дә эшли идек. Ну без бер яктан эти, икенче яктан нужа чыбыркылап торганга эшли идек. Ә сез аңлап, үзегез белеп... Менә хикмәт нәрсәдә... Әйдә, үзең дә ятып ял ит. Бик арыдың син бүген.

— Йоклый алмыйм мин, Шәйхаттар бабай.

— Йоклый алмасаң, ятып кына тор. Ул да әйбәт була,— диде Шәйхаттар бабай һәм, үзе дә ятып, беләген башы астына куйды, аякларын җыерып китереп, юрган астына тыккандагы шикелле хәрәкәтләндерде. Аннары, өстендә юрган юк икәнен аңышкач, туктады да авызын чапылдатып куйды.

Хәлим дә, Шәйхаттар бабай янына ятып, күзләрен йомды.

— Алай түгел, башта бер кавым йөзтүбән ят син. Аякларыңны тездән бөгеп, югары күтәр. Шулай әйбәт була. Элек солдат хезмәтендә безне шулай өйрәтәләр иде. Менә шулай...

Сүзен әйтеп бетерер-бетермәс, бабайның теле бәйләнә башлады. Ә бераздан ул инде картларча җиңел, йомшак гырылдый иде.

Хәлим дә, аның күңелле гырылдавы астында, изри башлады. Тын суда көймәдә чайкалган төсле рәхәтлек сизә башлады аның арыган гәүдәсе. Һәм ул, вакытында айнып, күзләрен ачты. Һөҗүм иткән йокыны качыру өчен, селкенгәләп куйды. Торды да тагын иптәшләре янына килде. Өсләрендәге саламнарны рәтләбрәк япты. Учакларга утын салды. Ашый-ашый шактый ерак киткән атлар янына килде. Инде ашап туйган атлар ятканнар, ә Шәехтай сусыл, йомшак, хуш исле үләнне әкрен генә керт-керт кимерә иде әле. Хәлим аның янына һәрвакыттагыча эндәшә-эндәшә килде. Һәрвакыттагыча назлап сөеп торды, иркә сүзләр әйтте аңар. Ат, гүя бу сүзләрне аңлады, ягымлы кешнәү белән җавап бирде.

— Ә син нигә ятмадың, Шәехтай, ә? Эх, Шәехтай, Шәехтай!..

Хәлим аның артык кыска калдырылган тышавын озынайтып бәйләде дә, гармонен алып, су буена төшеп китте.

8 «ТЕГЕЛӘР РАЗВЕДЧИГЫ...»

Су буе тып иде.

Су, әйтерсең, көнозын агып арыган да, хәзер ял итә — аның акканы күренми, тавышы юк, бары вакыт-вакыт борылыштагы ташларга бәрелеп, күңелле челтерәве генә ишетелгәләп китә иде.

Хәлим су читенә килде дә йокысын качыру өчен битен, беләкләрен юды, күкрәген чылатты,— «әйбәт...» — Аннары мүкләнгән бер таш өстенә утырып, гармонен зур дәрт белән тартып җибәрде:

По долинам, по взгорьям
Шла дивизия вперед...

Һәм кинәт туктап калды.

— Тиле дә инде мин. Иптәшләрне уятам ич...— диде ул, аннары бераз тынып торды да, су челтерәвенә охшатырга тырышып, гармоненың иң нечкә, иң хисле телләренә басарга керешге. Эзләнә торгач, гармоньда су челтерәве ишетелгән шикелле булды. Хәлим рухланып

китеп, шул ук вакытта көйне югалтудан куркып, бертуктаусыз кабатларга тотынды. Кабатлаган саен көй су челтерәвенә күбрәк ошый төште.

— Чыга бит...

— Чыга, Хәлим, чыга!..

Хәлим сискәнеп китте. Ялт борылып тавыш килгән якка, яр башына карады. Анда ярның нәкъ читендә, рәсемгә төшәр өчен тезелгән шикелле итеп, өч кыз басып тора иде. Хәлим борылып карауга кызлар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

— Нәрсә көләсез?..

— Бик матур көй чыгарасың ич... Нәкъ майламаган арба инде...

— Түгел, түгел, Хәлим, чыннан да бик матур. Чишмә тавышлары чыга, ихлас шулай.

— Шуңа якын, ләкин чишмә түгел. Суның ташларга бәрелеп челтерәве бу. Менә тынла...

Хәлим, аеруча дәрт белән, үзенең иҗатын берничә тапкыр кабатлап чыкты:

— Инде әнә суны тыңла...

Кызлар елганың түбән ягына, эретелгән корыч шикелле булып күренгән турысына карап, тыңлап тордылар.

— И-и, кызлар, шулай икән шул...

Хәлим, гармонен ике куллап тоткан килеш, кызлар янына күтәрелде:

— Ә майланмаган арба менә болай шыгырдый ул, Гөлгенә...

Хәлим, гармонен Гөлгенәнең колагына якын ук китереп, бакасына басып куйды.

— Ай-й! — Гөлгенә черелдәп башын артка тартып алды. Шул чакта аның кулындагы чиләк чайпалып, ак алъяпкычын чылатты. Фәрдәнә белән Гөлчәһрә көлеп җибәрделәр.

Хәлим чиләк янына килде.

— Оһо, сөт?

— Түгел, аш,— диде Фәрдәнә, көлүеннән туктап.— әйдә, урт солдатларыңны.

— Ә, юк, йокласыннар әле, яңарак кына яттылар.

— Бәй, суынып бетә ич ул.

— Суынсын, без аны...

Хәлим, сүзен бүлеп, каршы як ярга карады. Анда, тын караңгылык эчендә, елгага таба кемдер килә иде.

Хәлим, аның малай икәненә ышангач, рәхәт сулап куйды. Һәм эчке тавыш белән кызларга пышылдады:

— Килеп йөриләр дигән идемме мин сезгә! Шул инде бу — тегеләр разведчигы... Карап торыгыз, хәзер мин аны шундый итеп эләктереп алам...— диде Хәлим һәм буш кулын, кача-поса баручыны искәртмәстән тотып алгандагы шикелле, хозур кыландырып куйды.— Барыгыз, әнә шунда посып торыгыз...

Хәлимнең уйларын төшенеп житмәгән кызлар, чиләкләрен алдылар да, утыз-кырык адымдагы куаклык арасына кереп постылар. Хәлим үзе канауга сузылып ятты һәм күзәтүен дәвам итте. Ә теге малай ярдан сикерде дә су киму сәбәпле яртылаш комда утырып калган ике көймәнең берсен елгага этеп төшерде. Койрыгына кереп утырды да, сыңар ишкәк белән суны күңелле чапылдатып, Хәлимнәр ягына таба ишә башлады. Бу якка чыгып житкәч, әкрен генә төшеп, көймәне корыга тартып чыгарды. Һәм (кара әле син аны!) ишкәген суга батырды да авыр таш бастырып куйды. Хәлим көлеп жибәрде:

— Ну хәйләкәр дә, йөри-йөри шомарып беткән! — диде ул, янында кеше бар кебек сөйләнеп куйды.

Малай ярдан күтәрелеп менде. Кайтмый калган малын эзләргә чыккан кеше кебек, як-ягына каранып торды да, ахрысы сабанчыларның сүнеп бетмәгән учакларын күреп алды, эре-эре атлап шунда таба китеп барды.

— Бераз барсынмы, хәзер үк кычкырып котын алыргамы?

Хәлим шул турыда, бары шул турыда уйлап канаудан шуышып менде. Менгәндә аның күн итеге чыклы чирәмгә ышкылып шыгырдады. Әкрен генә шыгырдады итек, малай ахрысы шуны да ишетте, ялт итеп Хәлимгә таба борылды һәм эре-эре атлап килә башлады.

Хәлим курыкмады. Шулай да көтелмәгән бу хәлдән каушап калды. Тегеләр разведчигы дип уйлаган кешенең өстендә бер дә таушалмаган шинель, билендә шыгырдап торган өр-яңа каеш, башында йолдызлы солдат фуражкасы иде.

— Ялгыштым, бу разведчик булмады...— диде үзенә үзе Хәлим. Ул гармонен чирәмдә калдырып сикереп торды. Шинельле кеше, Хәлимнән ун адымда туктап, күңелле кычкырып жибәрде:

— Хәлим!

— Хəлим. Ə сез кем? — диде Хəлим, бераз аптырап карап торгач һəм шунда ук үзенə үзе җавап бирде: — Нəҗип ич!.. Честное слово, Нəҗип!.. Ой, Нəҗи-ип! — дип сузды ул һəм шат елмаеп, кулларын киң җəеп җибəрде. Нəҗип тə җəйде кулларын һəм, өч атлыйсын бер сикереп килеп, Хəлимне кочып алды.

— Ну, Хəлим!

— Ой, Нəҗи-ип!..

Нəҗип Хəлимне җибəрде, тагын кочып алды. Хəлим аны кочкан килеш шунда очраган төп башына утыртты. Үзе аның каршысына чүгəлəде.

— Малайлар: бетте ул, дилəр, ə мин əйтəм, бетмəс дим, бер килеп чыгар дим... И менə килеп тə чыктың...

— Чыктым, Хəлим.

— Кайларда булдың, Нəҗип, нигə бер дə хат язмадың?

— Язарлык булмады, егет, окружениедə идем.

— Тəки барып җиттең?

— Һи-и... ничек кенə əле!..

Хəлим уңайсызланып читкə карады.

— Ə мин җитə алмадым, Нəҗип.

— Синең җитмəсəң дə, җиткəннəн болай булган. Мин синең өчен бик шатландым, Хəлим.

Ул арада Хəлимнең «тегелəр разведчигын» ничек əлəктергəнен күреп торган кызлар, көлешə-көлешə, куаклыклар арасыннан килеп чыктылар.

Нəҗип, ялт сикереп торып, фуражкасын төзəтеп киде. Каешын рəтлəде. Төз басып, кулын козырегына күтəрде һəм үкчəлəрен бəреп алды. Кызлар моңа əһəмият бирмəгəч, тагы бəрде. Бусында шпоралар күңелле зеңелдəп куйдылар. Кызларның зеңелдəүне ишеткəннəренə ышангач, аларның шпораларга астан гына карап алуларын күргəч, Нəҗип рапорт бирде:

— ...нче гвардейский полкның тəрбиялəнүчесе Мустафин.

Ул бу сүзлəрне əйткəндə солдат иде əле, лəкин бик тиз тагы Нəҗип булып калды:

— Исəнме, кызлар, əллə танымадыгызмы? «Илшат» Нəҗибе ич, — диде ул уңайсыз елмаеп.

— Танымассың да, əллə нинди булып кайткансың ич.

Нəҗип тагын солдатка əйлəнде. Гəүдəсен турайтты. Прошу, дигəн булып, кызларга үзенең урынын тəкъдим

итте. Кызлар утырмагач, үзе утырды, терсәген тезенә куеп, баш һәм имән бармаклары белән ияген тотты. Нәҗип моны, арыганлыктан түгел, телләре фосфор белән яктыртылган сәгатен җиң эченнән чыгару өчен эшләде.

Хәлим кулын Нәҗипнең җилкәсенә салды:

— Фашисттан үчне алып кайттың алайса, туган?

— Эти өчен алдым, ә вообще юк әле. Ул фашист дигән аждаһадан үчне алай тиз генә алып бетерә торган түгел икән. Тереләренә өстәп, үлеп котылганнарын каберләреннән казып алып яңадан асып үтерсәң дә, алынып бетәсе юк икән безнең үчнең...

— И-и...

— Искә төшермәгез инде...— Нәҗип бу вакытта, өченче ел сәхнә артында көтүче малай турында укыгандагы кебек ярсу иде, усал иде.

— Газеталар Гитлерны кеше ашаучы дип язганда сәер тоела иде. Ну, күрдем, аннан да хуже икән...

Нәҗип бу вакытта тешләрен шулкадәр каты кысты, яңак сөякләре юка, шадра тиресен төртеп торды.

— Бер сөйләрмен әле,— диде ул бераз тынычлана төшеп,— яки укырмын. Күргәннәремнең барысын да яза бардым...

Нәҗип каптырмалы кыр сумкасыннан берничәсе бергә тегелгән дәфтәрләр алды һәм, актаргалап күрсәтте дә, яңадан сумкасына салып куйды:

— Я, үзегез нишләп ятасыз, дуслар?

— Безнең эш билгеле, Нәҗип. Үзең әйтмешли, шул ягу инде...

Нәҗип Хәлимнең күзләренә карады:

— Син, Хәлим дус, үпкәли күрмә тагын... Ятасыз, дип миң сүз уңае килгәнгә генә...

— Ярар, ярар... Син менә шуны сөйлә, ничек тереләп чыктың, ничек барып җиттең?..

Нәҗип бармак очлары белән чеметеп кенә фуражкасын салды. Фуражка астында басылып яткан табигый бөдрә чәч күпереп китте. Бер дә тотылмаган, күзне чагылдырырлык ак яулык чыгарып, маңгаена тидергәләп алуга, тирә-юньгә бик нәфис, бик тәмле хушбуй исе җәелде. Кызлар борыннарын әкрен генә тартып, бер-берсенә карашып алдылар. Нәҗип, үзенең бу көязлеге уңышлы чыгу белән канәгатьләнеп, сөйләп китте:

— ...Мине поездга алай кулдан тартып алучы бул-

мады. Вагон баскычларына эләгеп бардым. Куып төшерсәләр, тәпи-тәпи... Егерме бер көн дигәндә...

Нәҗип кыр сумкасыннан дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып, иптәшләре алдына җәеп салды да шырпы кабызды. Бу — күп тотылу, өсте-өстенә күп кенә шартлы билгеләр ясау аркасында танырлыгы калмаган, кайбер җирләре тишелеп чыккан карта иде. Нәҗип аның тирәсендә аеруча масаю, канәгатьләнү белән кайнашты һәм үзе генә укый алган билгеләрдән бер билгегә төртеп күрсәтте.

— ...Егерме бер көн дигәндә мин менә бирегә килеп чыктым. Можайский дип бәлки ишеткәнегез бардыр, шул шәһәр бу... Ну мине анда кертмәделәр, теге ягында бик каты сугышлар бара икән. Мин сулга китеп, менә шушы авылга барып кердем. Монда ыгы-зыгы ул кадәр түгел, зур юлдан читтә чөнки. Машиналар эрле-бирле чапмый. Сугыш кораллары ташымыйлар. Шулай да юл сабып бетерерлек түгел: колхоз мал-туарларын ерак тылга күчерә, кешеләр төялешеп чабалар... Эштән чыгып арыган идем, берәүгә кереп ятып йокладым. Иртән уянып китсәм, хуҗаның 3—4 яшьлек кызы, елый-елый, өстемә япкан пиджакны йолкып тора. Кич белән бу кыз мина үзенең курчакларын күрсәткән иде, ә мин аның дәфтәренә кызыл карандаш белән тавык-чебешләр ясап биргән идем. Ул шуңа бик сөенгән иде, эти-әнисенә күрсәтә-күрсәтә шатланып йөргән иде... Әллә ниләр әйтә-әйтә елый, күзләре шешенеп беткән. Мич башында идем, төштем. Өйдә беркем юк, өй тузгытылган, бушап калган... Ул якта халык, немец килә башласа, партизанга китә. Болар да шунда киткәндер дияр идем, кызны нишләп калдырып китсеннәр?.. Кыз мине өстерәп урамга алып чыкты. Һәм аның ник елаганын шунда белдем: кичә мине аркамнан сөя-сөя сөт һәм күмәч белән сыйлаган хуҗалар (кечкенә кызның эти-әнисе) юлның теге ягындагы имәндә асылынып торалар, әз генә читтә, эрүсәгән карда, кызның абыйсы — унбер-унике яшьлек малай хәрәкәтсез ята. Газетадан укыганда алай түгел, ә үз күзең белән күргәч, яман кызганыч була икән, елап җибәрә яздым... Эш болай булган: таң алдыннан авылга немецлар кергән. Халык партизанда. Ә кызның этиләре партизаннар белән элемтә тотар өчен авылда калганнар. Табылган бит шунда бер сволочь, бу турыда немецларга чишкән, боларны штабка чакырып алганнар да... Ә ма-

лай (әйбәт малай иде, нәкъ теге син сөйләгән Петя...) немецлар белән сугышып маташкан... Кыз, мескен, һаман өстери мине. Ул мине, әти-әниләрен имәннән алып төшәр, асылынып торганга гына сөйләшмиләр дип белде ахрысы, агачка төртеп күрсәтә, кулымны үбә. Учында зәңгәр чынаяк китеге, кулыма шул чынаяк китеген төртә. Янәсе, әти-әниләрен алып төшсәм,— ул аны миңа бирәчәк...

Нәжип туктап кулын селкеде. Сумкасын актарган булды, итек кунычларын тарткалап куйды, сәгатенә карап алды. Ул боларны инде көязлек белән түгел, нечкәргән хисләрен басу өчен, күзләренә килгән яшьне тарату өчен эшләде. Һәм, ахрысы, кабат хискә бирелүдән куркып, тасвирламыйча гына дәвам итте:

— Безне имәнгә якын җибәрмәделәр. Төш авышкач, кыз елый-елый минрәп йокыга киткәч, Тимка (кызның абыйсы) торып өйгә керде. Яланбаш. Чәче кан белән укмашып каткан, авыз-борыннарында кара кан. Мин аны, өстәлдәге әле суынып та житмәгән самовардан су алып, юындырдым. Тмика күгәреп чыккан битен, шешенгән иреннәрен, сызлавын басарга теләптер инде, салкын тәрәзә пыяласына куеп, бер сүз сөйләшмичә, әти-әнисенә карап утырды...

Кичен авылга немец килеп тулгач, безне өйдән куып чыгардылар. Без Тимкаларның мунчаларында тора башладык. Ә Тимка терелгәч, үзебезнекеләргә качу турында киңәштек. Кызны кечкенә чанага утырттык та, әбиләргә кунакка барабыз дигән булып, караңгы бер төндә авылдан чыгып та киттек. Коры елгадан түш белән шуышып бик озак баргач, әллә ничә авылны читләтеп үткәч, безне тотып алдылар. Үзебезнекеләр икән. Без Тимкалар авылында кайда ничә машина, ничә пушка, ничә танк барын, хәтта кайсы өйдә ничә немец торганны дәрес ятлаган күк ятлап алган идек — шуларны сөйләп бирдек. Ышанмый тордылар башта. Кечкенә генә бер авылда ул хәтле булмас, диделәр... Шуннан Тимкалар авылына бик күп кызылармеец җибәрделәр. Күбесе атлы. Шулар белән барып немецларны...

Нәжип хәзер гүя төп башында түгел, ә ат өстендә иде, гүя, кулында кылыч иде, ул гәүдәсен алга сузып, сизелер-сизелмәс сикеренгәләп, як-якка берничә кат кизәнеп алды.

— Сез дәме?

— Юк, без юк... Без атка атланып кына бардык... Авылга килеп керүгә, Тимка эти-әниләренә сарылды. Мин аңа булыштым. Имәннән чишеп алдык та... һәм шул чакта Тимкалар чарлагыннан атып... Тимканы...

— Үтерделәр?

Нәҗип тагын итекләрен тарткалап куйды. Сәгатен беләзегеннән салып боргалады да янәдән киде:

— ...Зур кабер казыдык та өчесен бергә, Тимканы урталарына салып, күмдек. Шуннан мине связной итеп алдылар. Кызны, командирлар кушуы буенча, бер кечкенә шәһәргә алып китеп, балалар бакчасына бирдем. Акылына бераз зарар килгән, төзәлсә кирәк диделәр. Юындырып, чиста күлмәкләр киерттеләр. Бу вакытта ул аеруча сөйкемле иде. Син минем тәтиләрем белән уйный тор, мин ботка ашыйм, аннары безнең өйгә кайтырбыз, яме ди. Әнием белән этием агачтан алма өзеп төшкәннәрдер инде, ди, мин сиңа да алма бирермен, яме, ди... Мин кызны күкрәгемә кыстым. Нәни кыз җылы куллары белән минем муеныма сарылды. «Ә син минем әнием шикелле коча белмисең, минем әнием мине болай, болай итеп коча иде, битләремнән мине болай, болай итеп...»

Нәҗип тагын итекләренә тотынды. Салмыйча гына сәгатен боргалап торды.

— Чиләгеңдә су түгелме, Гөлгенә?

Гөлгенә эндәшмәде. Ул кулын кашлары өстенә куйган да сулыгып-сулыгып елый иде. Аның өчен Гөлчәһрә җавап бирде:

— Юк, аш ул, Нәҗип абый,— диде һәм чиләккә элгән чүмечне алды да ярдан төшеп китте.

— Сугыш кына бетсен, авылга алып кайтам мин аны. Күр дә тор алып кайтам.

— Бәй, нишлисең аның белән?

— Беркемем дә юк бит минем. Үземә сеңел итәм. Ул мине болай да абыем дип йөри. Тәрбиячеләре дә шулай дип белә.

— Матурмы, Нәҗип абый?

— Бик. Күрсәң, үзеңнең дә исең китәр,— күзләре зәңгәр, чәче сары. Лентасы кызыл... Түлке бераз ябыкты әле. Ну ничево. Апкайткач мин аны...— диде Нәҗип һәм, Гөлчәһрә алып менгән суны комсызланып эчте дә урыныннан кузгалды.

— Ә сугышта күргәннәреңне сөйләмәдең!

Нәҗип медаленә кулын тидереп алды. Медаль җиз төймәгә бәрелеп, әз генә шалтырап куйды. Кызларның күзләре медальгә төште. Нәҗип канәгатьләнеп җавап бирде:

— Икенче вакытта, кызлар. Озак итеп, элеккегечә костер ягып, яме?

— Я... Килеп утыр, Нәҗип абый.

— Рәхмәт, рәхмәт.

— Безгә дә кил.

— Безгә дә.

— Рәхмәт, кызлар.

— Без китик, Хәлим. Чиләкне онытып калдырма...

Нәҗип тагын солдат кешегә әйләнде, китеп барган кызлар артыннан әйтеп калды:

— Үсәләр кызлар, Хәлим дус. Сугыш вакыты дип тормыйлар...

— Үсәләр.

— Әйдә, күрсәт әле, сез бик зур эшкә керешкәнсез ди бит.

— Ләкин әкрен генә. Уята күрмә. Йокласыннар.

— Кунып эшлисез?

— Бүген генә.

Нәҗип йоклап яткан пионерлар арасына килеп кергәч:

— Оһо, сез бөтенләй походтагыча...— дип куйды. Танырга тырышып, малайларның әле берсе, әле икенчесе өстенә иелде.

— ...Каюм, Шәпи, Ибрай... Кара, бу чыгым тай да тәртәгә кердемени инде?

Хәлим елмаеп куйды:

— Ничек кенә әле.

— Ә бу борчалар?..

— Кызык күреп йөриләр.— Хәлим Фәтхели белән Әптеринең өсләреннән төшкән саламнарын алып япты.— Кая, егет, онытканчы адресыңны калдыр әле.

Нәҗип рапорт биргән кебек чатнатып әйтте:

— Полевая почта № 2345. Гвардии воспитаннику Мустафину Назибу Гаряевичу.

— У-у, озын икән, онытырмын мин.

— Мә, язып ал.

Нәҗип блокнот белән чәнчә бармак кадәр генә калган шәмәхә карандашын бирде.

— Ай, бик басма, очын...

— Инде беткән карандашыңны...
— Бетсә дә бөтенгә алмаштырмыйм мин аны.
— Шулай бик яхшымыни?
— Яхшымы, начармы — бүләк.
— Кемнән?
— Үзем дә белмим.
— Ничек инде белмәгән кеше?..

Нәҗип Хәлимгә, шуны да аңламассың икән, дигән төсле карап алды: «Фронтовик түгел шул син...» Һәм, моның иптәшен кимсетү икәнен төшенеп, Хәлим сүз әйтеп өлгергәнче, иплəп кенә карандашның тарихын сөйләп китте:

— Окружениедә калгач булды бу хәл. Оборонада ятканда... Урман. Таң вакыты. Бер заман әллә кайдан гына самолет килеп чыкты. Үзебезнеке. Бераз түбәнәеп бер-ике әйләнде дә күтәрелеп китеп барды һәм шунда ук һавада парашют ачылып китте. Тагы берәү. Тагы... Бик күп парашют ачылды һавада. Ура кычкырырга тотындык. Солыдыр дибез... Атларга солы беткән иде безнең. Радио буенча солы сораткан идек... Парашютлар бер-бер артлы төшеп җиттеләр. Дөрес, солы. Ә бер ящикта, тышы киндер белән тышланган, өстенә «Татарстан кызларыннан Калинин фронты гаскәрләренә» дип язылган ящикта эреле-ваклы төргәкләр... Барысы да ак кәгазь белән төрелгән, барысы да бертөрле тар кызыл тасма белән матур итеп бәйләнгән... Миңа да өлеш чыкты. Таратып карасам — шушы карандаш, янчык, бик матур кульяулык, бер кыз рәсеме һәм хат... О-о, ниләр генә юк иде ул хатта! Әнисеннән башка туганы булмау турында да әйткән. Донор икән, күпме кан бирүе дә калмаган, хат яз дигән, беләсеңме, хат сораган. Ә мин яза алмадым... Тревога, һөҗүм... Адресын әллә кая илтеп тыккаимын шул чак... Мәнсез дигәндер инде...

Хәлим, кинәт нәрсәдер исенә төшеп, карандашның кырына киртләнгән З. Н. хәрефләренә карап торды да серле итеп пышылдады:

— Яулыгы белән янчыгы янында түгелме?
— Хаты белән бергә җуйдым... Менә бары шушы калды...

Нәҗип куен кесәсеннән, йөри-йөри таушалып беткән, ләкин матур күзләре, ягымлы иреннәре шул килеш калган яшь кенә бер кызның карточкасын чыгарды.

Хәлим сикереп үк торды:

— Зәйтүнә апа, честное слово, Зәйтүнә апа! — Хәлим онытылып шулкадәр каты кычкырды, шактый читтә йоклап яткан малайларның берничәсе башларын күтәреп карадылар.

Нәҗип Хәлимнең беләгеннән кысып алды. Каушады, нидер әйтергә теләде, әйтә алмады. Хәлим шыпырт тавышка күчеп өстәде:

— Безнең Зәйтүнә апа, алдынгы Зәйтүнә...

— Тукта, тукта... Син аны кайдан беләсең?

— Ник белмәскә... Урманда бергә утын кистек без алар белән.

— Син аны күрдең дәме?

— Менә инде... бергә эшләгәч, ничек күрмим ди мин аны!..

— Ул синең белән урманда утын кисте?

— Ә ник кисмәсен? Әле дә шунда ул.

Нәҗиптәге балаларча җиңел дулкынлану җитди уйчанлык белән алмашынды. Ул тирән караңгылыкка, урман ягына карап әйтте:

— Киткәнче бер барып кайтам әле мин аның янына. Рәхмәт әйтеп кайтам. Хатын укыгач шундый рәхәт булып китте. Чын күңеленнән язган бит. «...Сәламәтлек теләп, җиңеп кайтуыңны теләп калам», дигән.

— Кызык.

— Кызык шул... Ну, ярый, хуш. Кояш баеганда гына кайттым әле мин, госпитальдән соң ялга җибәргәннәр иде дә, ял юлга китеп бетте. Берсекөнгә сәфәр. Частьны куып җитәсе бар, үзең беләсең, һөҗүм итәбез.

Хәлим, иптәше авызындагы конфетка кызыккан сабый шикелле, тәкерәгән йотып куйды. Нәҗип, аның хискә бирелүеннән саклаңып, сүзне икенчегә борды:

— Күрүгә әйтермен дигән идем, истән чыккан, бик рәхмәт, Хәлим дус. Үлгәндә дә онытмам. Мылтыгыңны сатып алып биргәнсең бит син миңа теге вакытта алмаларны... Сестралар әйткәч, күзләремә яшь килде.

Хәлим кулын Нәҗипнең аркасына салды.

— Я, я... Син инде бигрәк.

— Бер дә бигрәк түгел. Әгәр шул чакта, моның өчен йөрәгеңне өзеп бир, дисәләр, мин һичшиксез...— Нәҗип дулкынланып Хәлимнең кулын ике куллап кысты, аннан йөрәгенә куеп торды.— Әгәр гомерем булса, мин синең бу яхшылыгыңны... Хуш, туган. Яттым, йокы керми. Үзең беләсең, юлда ашау да йоклау. Соң булса булыр дип,

сине күрергә барышым иде. Иртәгә кич миңа киләсең. Әни мәрхүмнән калган этәч йөри анда, ишек алдында, башын кая куярга белмичә...— Нәҗип кул йөзендә пычак кайраган шикелле итеп, кулын-кулга ышкып куйды.

Хәлим елмайды:

— Ярый, ярый...

— Килми калма, яме?

— Киләм, Нәҗип.

Нәҗип бармакларын шартлата-шартлата елгага таба китеп барды. Һәм кинәт туктап борылды да Хәлимгә таба килә башлады:

— Син ничек уйлыйсың, әгәр мин Зәйтүнә апа янына хәзер барсам? Ә?

— Юк, син ятып йоклап ал, Нәҗип.

— Ә беләсеңме, хәзер китим мин анда. Утыз чакрыммы әле моннан леспромхоз?

— Егерме ике.

— Ну, ул безнең халык өчен дүрт-биш сәгатьлек юл, китим мин хәзер...— диде Нәҗип һәм, зур-зур атлап, урман ягына таба китеп тә барды.

9 УҢЫШНЫ КЕШЕЛӘР ХӘЛ ИТӘ

Хәлим Нәҗипнең станциядә аерылышканнан бирле хәтсез үскән, аяк йөзләренә җиткереп тегелгән шинеле белән тагын да озынрак булып күренгән гәүдәсенә карап, шпораларның күңелле зеңелдәүләрен кызыгып тыңлап торды да йөгереп килеп таганга элгән казан астына ягып җибәрде. Һәм кызлар китереп киткән сөтле умачны җылытырга салды. Аннары Шәйхаттар бабай янына килде.

Өч-дүрт сәгатьтән диган иде, алай булгандыр инде... Шулай да Хәлим карт кешене вакытсыз уятып, ачуын китерүдән курыкты, үзем белмиммени мин, дию бар. Хәлим Шәйхаттар бабайның янына килеп ятты, аның уянганын көтәргә булды.

Еракта, Никкүчтемдә, беренче этәч, таң этәче кычкырды. Шунда ук икенчесе, өченчесе тавыш бирде. Аннары бик күп этәчләр бер-бер артлы җырлап җибәрделәр.

— Таң ата,— диде Хәлим,— э картның уяныр исәбе юк.

Хәлим Шәйхаттар бабайга таба борылды да йөткергәләп куйды. Имеш, ул төшендә җир сөрә: берничә тапкыр: «На, бахбай!» — дип кычкырды.— «Ялга! Аш пеште!»— дип тә карады. Шәйхаттар бабай мона да уянмагач, киерелеп кулларын җәеп җибәргән булды һәм бер кулын Шәйхаттар бабайның бөер турысына төшерде. Бабай әкрен генә «аә!» дип куйды һәм шунда ук кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Ну, шайтан баласы, ну, шельма! Бабаң мәрхүм дә шундый иде синең, шельма!.. Имеш, ул төш күреп ята, хи-хи-хи...— Шәйхаттар бабай салкын кулын Хәлимнең жылы жилкәсенә тыкты.

— Ай, Шәйхаттар бабай!

— Айдыр шул...

— Укырга барасы бар бит безнең, Шәйхаттар бабай.

— Беләм, беләм... Бар, уят инде, алайса.

Хәлим сикереп торды.

— Һәй-й! Сабанчылар, тырмачылар! Тор-тордан хәбәр килде!

Саф һавада аз булса да татлы йоклап, ял итеп алган пионерлар башларын күтәрделәр.

Тирә-якка җәелгән сөтле умач исенең кайсы яктан килгәнен борыннары белән эзләп таптылар да, чакырганны да көтмичә шул якка шуыштылар. Кайберләре тәлинкә-кашык, яки җамаякларын эзләп алып казан тирәли тезелә дә башладылар. Ә кайберләре, чиләктән кружка белән су алып, юынырга керештеләр.

Каюм, Әптеринең куш учына су сала-сала, чәнчеп куйды:

— Ибраһим абыена карама. Әптери энем, яхшылап юын,— диде.

Кинаяне аңлаган пионерлар көлештеләр.

Кемдер өстәп куйды:

— Дәшмә. Бәлки, Әптери дә доктор булырга исәп иткәндер.

— Алай булса, әйттем исә кайттым. Доктор кешегә юыну необязательно, конечно.

Пионерлар тагы көлделәр.

Ибрай, җиңел күтәрелеп, чиләк янына килде.

— Йөз проценты белән аңлашылды... Ну Керпе тәре, энәң...

— Ха-ха-ха...

— Әйдә сал, сал...

Сөттә пешкән арыш умачының әллә ни мактар җире булмый. Ә саф һавада йоклап карыннары ачкан пионерлар аны әллә ни күреп ашадылар.

— Эх, тагы булса!..

Тагы юк иде. Пионерлар, кашыкларының эчен-тышын ялап алдылар да, атларын, сыерларын алып килеп җиктеләр.

Тагы фонарьлар кабызылды, учак ягылды. Яхшы ук ял итеп алган атлар актык бураналарны сызарга керештеләр. Кичәдән бирле җыйналып килгән яңгыр, җилләмичә генә, тын гына явып үтте. Кибеп өлгергән туфрак җылы яңгырны йотып кына алды. Сөрелгән җир күпереп, йомшарып китте. Шәйхаттар бабай бер уч туфрак алып уа-уа сөйләпеп куйды:

— Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле? Иллә дә әйбәт була бу, оланнар. Тагы шулай бер явып китсә, 15—20 көннән чәчә башлыйбыз, болай булгач.

Еракта, бик еракта, тын караңгылыкны алтын кылыч белән ярып, яшен яшьнәде, ә күкрәве килеп җитмәде. Әз генә җилләп алды. Көнчыгышта күк чите ачылып, чөгендерле катык шикелле алланып китте. Әз-мәз яктыра башлады. Болытлар биегәйгән күк булдылар. Тирә-якта кара стена шикелле булып күренгән караңгылык ерагайды, сыегайды, аннары бөтенләй бетте.

Таң! Тәүлекнең иң хозур, иң ямьле чагы — таң!.. Үзе турында бик күп матур җырлар җырлаткан таң!.. Моңлы, нурлы, дәртле, серле, шигъри таң!.. Фонарь утлары, көнчыгышта җәелеп килгән таң яктысы астында, зәгыйфьләнә башладылар. Аларны сүндерергә вакыт иде инде. Ләкин пионерлар бу турыда оныттылар. Ә исләренә төшеп сүндерә башлагач, Хәлим сүндермәскә кушты. Киресенчә, иптәшләре ябынып йоклаган саламнарны җыеп алды да сөрелгән җирнең уртасына зур учак ягып җибәрде. Шуның белән «Илшат»ларны уятып чыгарасы килде аның. Шуның белән аларга үзләрендә тантана минутлары җитеп килгәнне аңлатасы килде.

Ул масая төшеп:

— Күршеләр белсеннәр эшнең нәрсәдә икәнен! Эшне симез атлар түгел, кешеләр хәл итә! — дип кычкырды.

Бу вакыт авыллары башында «Илшат»лар да күренде.

— Соңгарак калдыгыз, дуслар! — Хәлим, «Илшат»лар ишетсен дигән шикелле, каты кычкырып әйтте. Һәм,

дулкынланып килеп, сабанны Шәпидән алды да, бөтен көчен салып, этә башлады.— Әйдә әле, бахбай, тагы әз генә! На-на-на-а!..

Ат, сабан җинеләеп китүдән каушап, сөртенеп куйды да, тигез, җиңел һәм зур-зур атлап китеп барды. Бераз баргач, әкрен пошкырып куйды.

Менә, озын муеннарын сузып, югарыдан торналар очып үтте, унбер көн буена иләшеп беткән кара каргалар килеп җитте. Каргалар канатларын киң җәеп җиргә төштеләр дә, буразналар өстеннән тыйтак-тыйтак атлап, үзләренә иртәнге ашка суалчаннар эзли башладылар. Ләкин каргаларга бүген алай озак ризыкланырга калмаган иде шул инде. Яктырып бетәр-бетмәс, Шәехтайның аяклары пионерлар участогы янындагы каты сукага барып керде. Хәлим шактый артка калып килгән иптәшләрен ашыктырды:

— Әйдәгез, әйдә!..

Үзе чүгәләп бераз ял итеп алды да, йөгереп килеп, арыганрак бер иптәшенең кулыннан сабанны алды. Ул сабанны каты сукага китереп кертканче этеп барды. Аннары, маңгаена тибеп чыккан тирне кул аркасы белән сыпырып төшерде дә калкурак җиргә йөгереп чыкты, һәм «Илшат»лар ягына карап кычкырып җибәрде:

— Һәй-й!..

Ул бик каты кычкырды. «Илшат»ларның елгага якынраклары борылып карадылар. Ерактагылары да яр читенә йөгерешеп килделәр.

— Һәй-й!..— диде Хәлим тагы бер тапкыр.— Филләрнең нихәлләре бар, филләрнең? Чыктылармыни инде? Ярый, ярый, хәерле сәгатьтә! Ә без кайтабыз инде. Утау өстендә күрешкәнчегә кадәр хуш-сау булыгыз, күршеләр! — диде Хәлим көлемсерәп, аннары иптәшләренә таба борылып, арадан быргычы пионерны эзләде.— Әй, Сабирҗан, даешь сирена!..

— Ура!..

— Ха-ха-ха!

— Ура!..

«Илшат»лар, бигрәк тә разведчиклары, Хәлимгә ышанмады: «Кәмит уйныйлар...» Ә кайберләре, шул исәптән вожатыйлары, шикләнә калды. Ул иптәшләре белән сөйләшеп алды да, берничәсен ияртеп, өчпочмакларын алып, су читендәге көймәгә йөгерде.

Алар (пожарга баралар диярсең) шулай ашыгып иштеләр, көймәләре ярылып бата башлаган диярсең, шулай каушадылар.

«Ватан»нар аларны көлеп каршы алырга җыйналганнар иде, Каюм бер-ике чәнечкеле җыр да табып, иптәшләренә өйрәтергә керешкән иде, Хәлим туктатты.

«Илшат»лар, көймәдән төшкән уңайга, сөрелгән җирне өчпочмаклары белән үлчи-үлчи килделәр. Туктап тирәнлеген үлчәделәр. Үлчәделәр дә башларын чайкап куйдылар. Аптырагач: «Әллә сабаннарының берәр хикмәте бар микән»,— дип, аны басып торган килеш тә, егып та, әйләндереп тә карадылар. Ниһаять, арык карт атларга озак итеп карап тордылар һәм тагын башларын чайкап куйдылар. Вожатыйлары Мидхәт тә чайкады башын һәм ул чын күңеленнән булгандырмы, күнел өчен генәдерме, Хәлимнең бик җылы, яшенә карата бик зур кулын кысып тәбрик итте.

— Ничек булды бу, Хәлим, ә?

Хәлим, «Илшат»ларга уңышларының серен сөйләп бирде. Сүзенең азагында:

— Уңышны кешеләр хәл итә бит аны, күршеләр,— дип куйды.

Мидхәт күршеләрен уңышлары белән тәбрик итте. Аннары ул иптәшләрен үрнәк алырга чакырды. Бер үк вакытта эченнән генә, төнлә разведка ясаган булып йөргән, ул вакытта молодец булган, хәзер сукыр пәригә, тагын әллә нәрсәләргә әйләнгән иптәшен орыша иде.

Менә быргычы пионер Хәлим янына, калку җиргә килеп басты һәм, көнчыгышка карап, быргы уйнатып җибәрде. Җиз быргының зур авызында таң кызыллыгы чагылды. Пионерлар «ура» кычкырып, кепкаларын, бүрекләрен һавага чөйделәр. Бер-берсен кочып-кочып алдылар алар. Бу вакытта «Илшат»лар күршеләренә, аларның арыган гәүдәләренә, учак каршында йоклап, корымланып беткән йөзләренә, җиңүдән соң һәркемдә була торган горур елмаюларына сокланып карап тора иделәр. Аларның һәркайсы үз урынын «Ватан»нарның теләсә кайсы малаена бирергә дә, үзе аның урынына басарга әзер иде.

Пионерлар, шау-шу аркасында, туры айгыр җигелгән тарантасның үз яннарына җитеп килгәнен дә сизмәделәр. Ә күреп алуга, әйтерсең, команда булды, бар да

берьюлы тынып калдылар. Айгыр чабып килгән уңайга, пионерлар уртасына ярсып килеп керде. Тарантасның бер ягыннан колхоз комсомол секретаре, икенче ягыннан райком секретаре сикереп төште.

Никадәр үзгәреш! Ә бары ел ярым бит әле. Ничек ябыккан, картая да төшкән. Чигәләрендә кыра чәч инде берәм-сәрәм генә күренә. Әйтерсең әле генә бер тоташтан бик калын китап укып бетергән — күзләре алҗыган, кызарган, ә шулай да үзе һәрвакыттагыча җитез, хәрәкәтчән. Ул тарантастан төшкән уңайга, кул астына туры килгән Шәпине билләреннән тотып югары күтәрде. Аның маңгаена, йоклаганда, кайсыдыр шаярып язган корым йолдызга карап торды. Башка җирдә булса, секретарь малайны оялтыр иде. «Эх, син, трубочист», дияр иде, юк, бу юлы алай димәде, көлмәде дә. Ул хәзер бик житди иде, хәтта берникадәр каушый да иде кебек.

— Рәхмәт, рәхмәт, Ленин токымы! Партия рәхмәте бу сезгә. Уңышыгыз белән тәбрик итәм,— диде ул һәм барысы өчен дә Шәпине күкрәгенә кысып үпте. Аның оялган күзләренә карап, берничә мактау сүзе әйтте. Аннары Шәпине кулыннан төшерде дә Хәлимгә карады:

— Ләкин, дуслар, сез бик әһәмиятле бер нәрсәне оныткансыз бит. Ярышны, социалистик ярышны оныткансыз...— дип сөйләп китте.

Җәләй секретарьны бүлеп:

— Ә без ярыштык, договорыбыз да бар,— диде һәм битендәге корым йолдызны чыклы эрекмән яфрагы белән сөртеп торган Шәпигә төртеп куйды:

— Күрсәт, договор синдә бит.

Шәпи куен кесәсеннән бер кәгазь чыгарып секретарьга сузды:

Секретарь:

— Эһә, эһә,— дип кәгазьгә күз йөртеп чыкты да Шәпигә кире бирде.— Монысы яхшы булган... ләкин мин күршеләрегез белән ярышмавыгыз турында әйтәм.

— Ә без алар белән дә ярыштык. Хәлим, анысының договоры синдә ич. Күрсәт секретарь абыйга.

Секретарь монысын да алып карады һәм яратмыйча кире бирде:

— Ә нәтиҗә? Кайда нәтиҗә? Чын ярышларда була торган төп шарт кайда? Арттагыларга үзеңне куып житәргә ярдәм итү турындагы пунктны әйтәм. Социалистик

ярышның принцибы шунардан гыйбарәт бит, шулай итеп гомуми күтәрелешкә ирешүдән гыйбарәт.

— Без аны беләбез...

— Ә инде белә торып эшләмәү — бөтенләй начар. Плюшкинча килеп чыга бит. Байлык бар, ә кирәккә тотылмый, сандыкта череп ята... Кыскасы: начар булган сезнең үз кабыгыгызга бикләнеп ятуыгыз. Ул сезне менә нәрсәгә китергән: әйтик, сез кулга мылтык тотып, «Илшат»лар белән бергәләп, дошманга һөҗүм итә идегез. «Илшат»лар абынып егылды. Сез, аларны күтәреп торгызу урынына, үзегез белән әйдәп алып китү урынына, дәшми-тынмый гына читләтеп узып киттегез. Һәм, нәтиҗәдә, бергәләшеп дошманның авызын-борынын җимереп ташлау урынына, битен генә тырнап калдыгыз. Нәтиҗәсен үзегез ясарсыз дип беләм...

Хәлим, шулай ук аның иптәшләре дә, уңайсызланып аяк йөзләренә карадылар. «Илшат»лар башларын күтәрә төштеләр. Секретарь дәвам итте:

— Ә шулай да сез бик яхшы эшләдегез, бик яхшы эшләдегез, нәни патриотлар. Сокланырлык яхшы... Сезгә, «Илшат» пионерлары, күршеләрегездән үрнәк алу зыян итмәс...

Бу юлы «Илшат»лар түбән карадылар, «Ватан»нар башларын күтәрделәр.

Хәлимнәр авылга кайтып кергәндә, көнчыгышта кызарып чыгып килгән кояшның сырты күренде. Кояш, гүя аңар күтәрелеп менүе авыр иде, әкрен генә чыкты офыктан. Бик тә, бик тә зур, бик тә, бик тә кызыл иде кояш. Ул чыгып җиткән уңайга, күе зәңгәр, тигез офык буенча тәгәрәп китәр төсле күренде. Һәм шунда ук, офыктан әкрен генә аерылып, салмак кына өскә күтәрелә башлады.

Киң таш юлның һәр ике ягын бизәгән хәтфәдәй яшел чирәмдә вак-вак энҗе бөртекләре төсле чыклар җемелдәште. Авылның аргы башында, урам уртасында, озын чыбыркысын иңенә аскан көтүче Габделмән бабай күренде. Аның бик озын кара күләгәсе төнге яңгыр юып киткән таш юл буйлап сузылды. Көтүче бабай, кояшка арты белән басты да, быргысын уйнап җибәрде. Һәр көн ишетелә торган, һич туйдырмый торган борынгы быргы моңы урамнар, тыкрыклар буенча очты. Капкалардан,

ялкау атлап, ялкау мөгрәп, сыерлар чыга башлады. Урамда ак алъяпкычлы бригадир кызлар, кулларына камыт, йөгән, чыбыркы тоткан, Хәлимнәрдән әз генә калку сабанчылар, Шәйхаттар бабайдан әз генә яшь чәчүчеләр күренә башлады. Һәрбер хәрәкәте, һәрбер тавышы белән күңелгә яшәү дәрте сала торган язгы авыл шулай уянды.

Өс-башлары таушалып, бит-куллары каралып беткән, ниһаять, арыган, ләкин бик тыныч, бик шат пионерлар. бер-берсен дәрескә соңга калмаска өнди-өнди, өйләренә таралдылар.

10 «КЕЧЕ ИЛШАТ» КЕШЕЛӘРЕ

Хәлим дә өенә кереп китте. Ләкин ул бер дә шат түгел иде. Ул бары иптәшләренең күңелләрен төшермәс өчен генә юл буенча уйнап-көлеп кайткан булды. Аның йөрәгенә райком секретареның хак, ләкин бик ачы сүзләре тырнады.

«Бергәләшеп дошманның авыз-борынын җимереп ташлау урынына...» — секретарь бу сүзләрне әйткәндә гүя Хәлимгә: «Син дөнья күргән малай бит, ичмаса, сиңа белергә иде»,— дигән шикелле итеп карап куйды. «Абынып егылган иптәшеңне күтәреп торгызу урынына...» — райком секретаре бу сүзләрне бер дә бозылмый торган итеп, тирән уеп, Хәлимнең йөрәгенә язып калдырды.

Хәлим, дәрес беткәнне дә көтмәстән, бу турыда Фәрданәгә язып бирде. Ә тәнәфес вакытында тулы итеп сөйләп күрсәтте.

— Дөрес әйткән бит, Хәлим.

— Дөрес шул менә. Ә син аның шул дөресне ничек итеп әйткәнен күрсәң икән. Йөрәкне телеп-телеп алды бит ул бу сүзләрне әйткәндә. Мин аның шикелле итеп әйтеп бирә генә белмим.

— Ичмаса, ник беребезнең башына килсен!

— Төзәтергә кирәк безгә бу хатабызны, Фәрданә.

— Ничек итеп?

— Социалистик ярышка чыгыйк без «Илшат»лар белән... Андый түгел, чын ярышка.

— Туйдан соң думбыра...

— Мин дә шулай дигән идем. Тәзкирә апа, кирәк, ди. Башта аларның эшләрен барып карагыз, кирәк икән, булышырсыз да ди...

Дәресләр беткәч, Хәлим белән Фәрдәнә, комсомол секретарен күреп сөйләштеләр дә, «Илшат»лар басуына киттеләр. Юлда аларга Каюм, аннан Ибрай иярде. Шәйхаттар бабай, көрәк белән, сөрелгән җирнең «килмәгән урыннарын китереп» йөри иде, ул да барып килергә булды.

Кай арада дәресләре беткән дә, кай арада чыгып җиткәннәр, Хәлимнәр көймәдән төшеп ярга күтәрелеп менгәндә, «Илшат» лар күптән инде кырда иделәр. Җирнең аргы башында шул ук өч ат, бер сыер күренә иде. Малайларның алдагы көннәргә караганда күбрәк, ыгы-зыгыларының азрак булуына, хәрәкәтләрнең тизлегенә караганда, райком секретаре белән очрашуның нәтиҗәсе булганлыгы сизелеп тора иде.

Кыр буенча сибелгән «Илшат»лар, Хәлимнәрне күргә, бергә җыелып тиз генә нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Ул да түгел, өч кечкенә малай, иптәшләреннән аерылып, сызгыра-сызгыра, Хәлимнәргә таба йөгерә башладылар. Бот араларында «ат», аркаларында «карабин», билләрендә «кылыч» иде аларның. Өчесенең дә штан балаклары сызганылган, күлмәк изүләре чишелгән. «Атлылар», сөрелгән җирне чыкканчы, як-якка сибелеп җан-фәрманга йөгерделәр дә, өчесе бергә кушылып, Хәлимнәрнең юлларын кистеләр.

— Ярамый! Анда барырга ярамый! — диде малайларның берсе, Вәгыйзь исемлесе, өченче ел солдат-солдат уйнаганда «үлеп яткан килеш» Сәмине аягыннан тартып екканы.— Ярамый, председатель үзе югында чит кешеләрне кертеп йөртергә кушмады.

— Нинди председатель?

— Һе. Колхоз председателе.

— Нәрсә лыгырдыйсың соң син?

Хәлим, шулай дип, малайны читләтеп үтеп, алга уза башлады. «Атлылар» өчәүләшеп сызгырырга, кычкырырга, Хәлимне артка этәргә тотындылар. Аптырап калган Хәлим тартышып тормады, үзе үк артка чигенде:

— Председателегез кайда соң?

— Белмибез.

Хәлим еракта җыелып торган малайлар арасыннан күзләре белән «Илшат» председателе Солтангәрәй абзыйны эзләде, күренмәгәч, тагын «атлыларга» эндәште:

— Кайда дим председателегез?

— Белмибез.

— Күршеләр яман да ачуланган безгә,— диде Хәлим, иптәшләренә таба борылып. Һәм «атлылар» ишетсен өчен, юри кычкырып әйтте: — хәзер табып киләм мин председательләрен, идарәләрендәдер әле. Анысы да шулай карышса, тотам да райкомга шалтыратам. Без бит уйнарга килмәгән,— диде ул һәм, Фәрданәгә әкрен генә нидер әйтте дә, тиз-тиз Акбуага таба китеп барды.

Моны күреп, «атлыларның» берсе, Вәгыйзь исемлесе, «атының» башына таккан каешны муенына элде дә бер кулы белән үзенең артын кыйнап, икенчесе белән «кылычын» болгап, туктаусыз сызгыра-сызгыра, авылга таба йөгерде. Һәм, Хәлимне узып киткәч, кинәт сукмактан ялт сулга борылып, гөлҗимеш куаклары эченә кереп күздән югалды.

Хәлим бу малайның «юләрләнеп йөрүенә» әһәмият бирмичә генә узып китәргә булган иде дә, куаклыкның иң куе бер җирендә кечкенә генә кызыл флаг күреп, сызгыруның да шунда барып җиткәч кинәт өзелгәнен ишетеп туктап калды.

— Нәрсәдер бар анда...

Хәлим шунда сугылып китәргә булды һәм флагка карап тиз-тиз атлый башлады. Флаг тирә-якка ямь биреп, яфраклары шиңәргә дә өлгермәгән яшь каен тармакларыннан ясалган шалаш өстендә җилферди иде. Шалаш ишеге төбендә Вәгыйзьнең «аты» сөялеп тора, ә ишек өстендә «Кече Илшат идарәсе» дигән ак калай вывеска ялтырый иде.

Хәлим иңбашларын җыерып куйды:

— Нинди идарә? Нинди «Кече Илшат»?

Хәлим керергә дип шалаш авызына килде һәм, анда сөйләшкән тавышлар ишетеп, туктап калды.

— Әх, Вәгыйзь, Вәгыйзь! Сиңа, ичмаса, Хәлим авылга кереп киткәнче көтеп торырга иде.

— Минем монда килгәнне сизмәде ул, иптәш председатель.

— Сизмәс, немец шпионы эләктергән Хәлим диләр аны. Бар, чык, ишек төбендә тор. Күренсә-нитсә, тиз генә миңа хәбәр ит.

Вәгыйзь чыгарга өлгермәде, аңар боерык бирүченең берничнди дә колхоз председателе түгел, Солтангәрәй абзый түгел, ә «Илшат» пионеры Мидхәт икәнен тавышыннан таныган Хәлим шалашка атылып килеп керде.

Ләкин, бу ни тамаша? Анда Вәгыйзь дә, Мидхәт тә

юк иде, Хәлим анда, шалаш түрендә, ниндидер язулы икенче бер ак калай күрде. Унга карады — берни күрмәде, сулга карады — ике кыз күрде. Кызларның берсе, такталары ышкыланмаган, аяклары җиргә кертеп ясалган кечкенә өстәл артында, счет, кара савытлары, кенәгәләр, төрле кәгазьләр белән тулы өстәл артында, шалт-шолт нидер хисаплап утыра, ә икенчесе әле генә өзелгән каен себеркесе белән инде үләне корый башлаган җир идәнне себереп йөри иде.

Чыннан да, бу ни тамаша? Нинди шалаш бу? Ә Вәгыйзь белән Мидхәт кайда?.. Хәлим гаҗәпләнеп, хәтта шомлана калып, артка чигенде. «Әллә төш күрәмме, югыйсә?» — диде ул җитди үк икеләнеп. Аннары бер-ике адым алга атлап, түрдәге калайны укыды: — «Колхоз председателе».

Хәлим җентекләбрәк караган иде, кергән шәпкә шалашның түр стенасы булып күренгән каен тармаклары артында, аяклары каезланмыйча, өсте ышкыламыйча ясалган тәбәнәк өстәл күрде. Ә өстәл артында, шактый биек түшәгән чирәм өстендә авыр сызланып Мидхәт ята, Вәгыйзе аның баш очында сулы стакан тотып тора иде.

Хәлим барысын да аңлап алды. Мидхәтнең нәрсәдән, нишләп авырганын да аңлады һәм эчтән көлеп куйды, тыштан исә Мидхәтне кызганган булып:

— А-а... авырыйсыз икән ич...— диде.

— Авырый, бик каты авырый,— диде Вәгыйзь, кайгырган булып.

Авыру да күз агын әкрен генә Хәлимгә кайтарып салды:

— Кем бар? Ә-ә, Хәлим күрше икән. Нихәл, туган. Менә болай булып киттем бит әле...

— Әйе, синең хәл әйбәттән түгел. Ни булды, Мидхәт парин?

— Бизгәк, ахры, яман туңдыра.

— Кара син аны, ә! Сезнең эшне күрергә дип килгән идек тә, җибәрмәделәр. Председателегез бирегә түгел микән, дип керүем иде.

— Председатель бирегә биредәсен дә...

— Ничек биредә? Кайда?

— Ә соң мин?

— Син? Син «Илшат» колхозы председателе?

— Мин «Илшат» колхозы председателе. Зур «Ил-

шат»ныкы түгел, аныкы Солтангәрәй абзый. Ә «Кече Илшат»ныкы мин.

— Ни болгатасың син, Мидхәт? Нинди «Кече Илшат»?

— Ни... Пионерлар участогына шундый исем бирдек — «Кече Илшат». Ә мин аның председателе. Әнә теге — хисапчы, Мәрьям — сторожиха. Бригадирлар, идарә членнары бөтенесе кырда...

Авыру үзенең авыру икәнен онытып, сәламәт кешечә сөйләшүгә күчте. Һәм шунда ук исенә килде. Хәлимнең: әйдә, акрынлап барып, сөрелгән җиреגעזне карап кайтыйк әле, диячәген сизеп, тагын сыкрый башлады:

— Эһ, эһ... Өйгә кайтсам, әни берәр нәрсә эшләтер иде дә, кыймылдарлык та хәлем юк...

— О-о! Шул хәтле, ә?

— Яман инде. Кайда, Вәгыйзь, кунакка урын бир. Мәрьям, син чәй куеп җибәр.

Хәлим түзеп-түзеп торды да шаркылдап көлеп җибәрде, һәм Мидхәтнең якасыннан тотып өстерәде:

— Әйдә, тор, дускай! Күрдек, артист булырга ярыйсың икән.

Мидхәт, күзләрен киң ачып, Хәлимгә карады. Хәлим көлә-көлә дәвам итте:

— Ә мин ишетеп тордым, үзең әйтмешли, немец шпионын тоткан Хәлим ич мин.

Мидхәтнең битс чөгендер булып кызарды. Колакларына кадәр кызарып чыкты аның. Урлаганда тотылган карак шикелле, нишләргә белмичә каушап калды. Хурлыгыннан елап җибәрергә әзер иде ул бу минутта.

Ләкин малай үзен бик тиз кулга алды. Торып утырды да гамьсез генә итеп әйтеп куйды:

— Ник килдең?

— Эшегезне күрергә, Мидхәт.

— Көләргә?

— Юк, Мидхәт, күрергә, кирәк икән, ярдәм итәргә, райком секретаре әйткәнчә, үзебезнең хатаны төзәтергә килдек. Бәлкем әле, сездә дә безнең өчен файдалы яклар бардыр...

Мидхәт, соңгы сүзләрне, мыскыл итүнең башы дип аңлап, сикереп үк торды.

— Чыгып кит! — диде ул ишекне күрсәтеп.— Вон минем идарәдән!

— Ә син кычкырма. Мин бит, барыбер, курыкмыйм.

Хәлим «курыкмыйм»ны шундый тыныч, шундый батыр әйтте, Мидхәт кинәт йомшап төште һәм Вәгыйзь белән хисапчыны чыгарып җибәрде дә (сторожиха чыннан да чәй кайнатырга чыгып киткән иде), кулын Хәлимнең күкрәгенә куйды:

— Хәлим туган, тыңла, кереп йөрмә син безнең җиргә. Карадың ни дә, карамадың ни, рәт юк әле безнең анда. Өч көнсез дә башкарып чыгып булмас әле. Бөтен эшне кадрлар харап итте, туган.

— Ә без бит ничә көнлек эшегез барын белер өчен килмәдек, Мидхәт. Ихлас шулай: кулыбыздан килгән кадәр ярдәм итәргә дип килдек.

Мидхәт ышанмыйча Хәлимнең күзләренә карады.

— Честное пионерское, менә.

— Ничек инде ярдәм итәргә?

Хәлим ничек икәнен сөйләргә кереште. Шул чак ишектә бер малай күренде.

— Керергә рөхсәтме, иптәш председатель?

— Ни йомыш?

— Ат аксады. Санитар, мондый авыруны мин берни эшләтә алмыйм, ди. Агроном да шулай ди, ә зампред, минем функциягә керми, ди. Йөри-йөри ат алҗып бетте. Нишләргә боерасың?

Мидхәт, колхоз председателенә охшарга тырышып, зарланып алды:

— Менә бит ул ничек, күрше, үзеңнән башка бер эш тә эшләнми бездә.— Һәм, Хәлимне әйдәп, шалаштан чыкты.

Ат тирәсендә бер әйләнде, ике әйләнде. Атның авызын ачып караган булды. Аякларын тотып-тотып карады һәм эре генә итеп әйтеп куйды:

— Бар, Шамил, хәзер үк «Зур Илшат» санитарына илт,— диде ул.— Тукта, язу ал. Мөршидә, бар әле, «Зур Илшат» ка отношение яз. Ләкин волокитасыз гына...

Мөршидә кереп киткәч, Мидхәт тагы зарланып куйды:

— Читен, туган, болар белән эшләве, отношение язарга да үзең өйрәтергә калгач...— («председатель» кулын селкеп куйды.) — Инша кадәр итеп, дәфтәр битен тутырып язалар бит. Ни әйтәм, кыска языгыз дип, волокитасыз гына дип. Юк бит...

Хәлим шалашка бәйләп куелган атны йөгәненнән тотып бераз йөртеп карады да, аксаган аягын күтәреп, бер җирен дә калдырмыйча капшап чыкты — ат тыныч тор-

ды. Табаныи капшады — ат тагы тыныч торды. Ә тоягына чиертә башлагач, сискәнеп китте.

— Эше бәләкәй моның, иптәш председатель,— диде Хәлим үзендәге өстенлекне сиздереп.— Тояк астына шырпы кергән, шул гына...— диде дә, бармак битләрен тояк өстендә сукыр кеше үз әлифбасын укыган шикелле, әкрен генә йөртергә керешге. Ат кинәт тартылып китте. Хәлим бармакларын йөртүдән туктап, тояк астыннан каләм кадәр шырпы тартып чыгарды. Ат куркып кына җиргә басты һәм, бәладән котылганына ышангач, бер урында таптаныи, койрык очын селкеп куйды. Бар да, Мидхәт үзе дә, Хәлимгә карап сокландылар: «Кайдан белә бу Тальян Хәлим барысын да?» — диде Мидхәт һәм астан гына иптәшләренә карап алды. «Сүз чыккан саен әйтә инде болар хәзер: әллә кем булма, диләр инде. Тояк астыннан шырпы алырга син бит үзең дә безнең белән бер көнне өйрәндең, диярләр инде...» — Мидхәт шулай уйлады һәм, эчке борчылуын яшерә алмыйча, үзенең кул астындагыларга боерык бирде:

— Әйдә, барыгыз, эшегездә булыгыз. Марш!

Кызлар көлешә-көлешә шалашка кереп киттеләр. Сабанчы малай, атын әз генә җитәкләп барды да, атланып алып юрта башлады. Вәгыйзь дә, «атын» бот арасына кыстырып, артына шапылдата-шапылдата, аның артыннан йөгерде.

Хәлим, үзләренең усал ният белән килмәгәнлекләренә Мидхәтне ышандыра-ышандыра, җир башына килеп җиткәндә, үз вазифаларына турылыклы «атлылар» баягы урыннарында басып торалар иде әле. Фәрдәнә бер «Илшат» кызы белән сөйләшеп утыра, Каюм белән Ибрай, Хәлимнәрнең бирегә киткәннәрен күреп калып соңыннан килгән тагы берничә «Ватан» малае һәм Шәйхаттар бабай су буеннан менеп киләләр иде.

Шәйхаттар бабай, эш турында сүзгә керешкәнче бер тартып алырга, «Илшат» малайларыннан авыл яңалыкларын сораштырырга уйлаган иде дә, эчкәрәк кергән саен чи калган җирләргә ешрак сөртенә башлагач, идарәләре белән мактанып барган Мидхәтне бүлде:

— Идарә салуыгыз әйбәт булган. Яңгыр булдымы — авылга кайтып йөрмисең. Әйтергә кирәк, купальнигез дә әйбәт. Югыйсә, коеныр җиреңнән коенмый йөрисең безнең елгада. Төбе гел саз. Тужы самый әйбәт булган...

Әмма ләкин, эшегез эш түгел, күрше... Я, кай җирен эш дисең инде монын?

Шәйхаттар бабай чи калган җирдә туктап, сабан төрәне каерып салган кәзләрне аягы белән буразнага сыпырып төшерде: — Я, шул да булдымы инде эш?

Мидхәт башын түбән иде.

— Ә монысын кара... Монысы нәрсә тагын?..

Шәйхаттар бабай, җим эзләп йөргән әтәч кебек, әле бер, әле икенче җиргә барып төртелде. «Ватан»нар һәм эшләрен ташлап килгән «Илшат»лар аның артыннан тавыклар шикелле йөгерешеп йөрделәр.

— Эх сезне, сезне!.. Агротех нәмәстә карый соң сезнең?

— Безнең агротехник яшьрәк шул, Шәйхаттар бабай, барысын да белеп бетерми әле.— Мидхәт, борын асты ялтырап торган, аяклары чебиләп беткән тугыз-ун яшьлек малайны күрсәтте.

Шәйхаттар бабай көлми түзә алмады:

— Түгел, мондый түгел, чын агротехны, минем шикеллене әйтәм мин.

— Синең шикелле нигә безгә?

Шәйхаттар бабай җәберсенеп куйды:

— Нигәме? Менә минем егетләр әйтерләр әле сезгә минем шикелленең нигә икәнен,— диде ул һәм аз гына читтә атын чыбыркылап торган малайга кычкырды:

— Сукма, тимә хайванга, малай актыгы!..

— Йөрмәгәч, нишләтим мин аны?

— Йөрмәсә, берәр минут ял иттер, арыгандыр.

— Әйе, арыган сиңа... Чыкканнан бирле чыгымлый да чыгымлый. Госман әнә никадәр сөрде инде, ә минем чыгымлый.

— Чыгымлый, чыгымлый!..— дип үчекләп куйды Шәйхаттар бабай малайны.— Мин ат урынында булсам, чыгымлау түгел, куш аяклап ипи шүрлегенә менеп төшәр идем әле.

— Ни-ик?

— Син ни әйтер икән дип. Кара әз генә, атыңның аягы валюкка бәрелеп йөри ич. Озынайт постромканны. Һәй, ан-наң яламаган малай!.. Ул хәтле озын да итмә, авырга килә. Аягы валюкка тияр-тимәс кенә булсын... Менә шулай...

— Һна-а!

— Чыгымлыймы инде хәзер?

— Чыгымламый.
— Чыгымламас шул,— диде Шәйхаттар бабай, аннан Мидхәткә эндәште:
— Менә нәрсәгә ул агротех, иккүзем.
— Һе.
— Тагын, менә нәрсәгә... Хәлим энем, кил әле, сантиең белән үлчәп кара әле шушы төшне.
Хәлим итек балтырыннан киртле чыбык алып сөрелгән җиргә батырды.
— Унөч.
— Ә яшел тышлы китапта ничә санти булырга тиеш дигән әле?
— Егерме.
— Егерме ике булса ишшу да әйбәт димәгәнме?
— Дигән.
— Ишеттеңме, Мидхәт тованиш?
— Ишеттем.
— Ишетсәң, колагыңа киртләп так. Менә нәрсә өчен кирәк ул агротех. Агротех булса, разе ул сезгә болай итеп җир бозып йөрергә юл куя!
— Шулай, шулай, Шәйхаттар бабай, ныграк син аларны...
Шәйхаттар бабай артына борылып карады. Анда «Илшат» колхозы председателе Солтангәрәй абзый күбеккә баткан атыннан төшеп килә иде.
— Ныграк, дисең?.. Аларны, бәлки, бик нык кирәкмәс тә. Әмма ләкин, райком булсам, мин сине, фәлән-төгән нәмәрсәне, моның өчен салып суктырмый калмас идем. Я, күр инде, шул да булдымы сөрү!
Председатель җирне берничә төштән үлчәп карады:
— Да-а...
— Ә монысы нәрсә тагы?
Председатель эндәшмәде.
— Малайларны тәмам башка чыгарып җибәргәнсез икән, алай да... Тфү, фәлән-төгән!..
Шәйхаттар бабай шактый ярсу иде бу чакта. Ул якыннан гына узып барган тырманы туктатып әйләндерде дә, һаман председательне тирги-тирги, тырма тешләренә уралган әремнәрне чүпли башлады. Председатель уңайсыз хәлдә калды. Ул көрәк алды да тирән батырабатыра чи калган бер җирне казырга тотынды, бераз казыгач әйтте ул:

— Мидхәт, бар әле, көрәкләр белән берничә пионер алып кил.

— Безгә дә алып кил,— диде Хәлим.— Ул иптәшләрен санап чыкты да өстәп куйды:— Сигез көрәк алып кил безгә.

Мидхәт бер уңайсызланып, бер «Ватан»нарның ярдәм итәргә торганнарына шатланып авылга йөгерде. Солтангәрәй көрәген җиргә кадады да әйтеп куйды:

— Барысының да артыннан йөреп булмый шул, Шәйхаттар бабай.

— Ә, юк, йөрергә кирәк. Сез йөрмичә, кем йөрсен ди алар артыннан! Карлыгач балаларын очарга чәүкә килеп өйрәтми бит.

— Анысы шулай... Әнә анда миң гектар бар бит минем, мин...

— Булсын, ике миң булсын. Шул ук вакытта син анны да онытма. Әгәр һәрбер башак бер пуляга тора икән, әнә кая китә ул? Бирелдә ничәмә-ничә миллион башак үсәчәк?.. Аннары үзең йөрү әбәзәтельне түгел. Ниушты сездә минем шикелле берәр карт юк? Сибгатулла кордаш бу егетләргә нишләп агротех була алмас икән, ә, Солтангәрәй?..

Берничә минуттан «Илшат» пионерлары участогында кызу эш башланды. «Илшат» һәм «Ватан» пионерлары чи калган җирләрне казырга керештеләр.

Мидхәт Шәйхаттар бабай әйткән Сибгатулла бабайны үзләренә баш итеп чакыру өчен, өч пионерны илче итеп җибәрде. Сибгатулла бабай баш тарткан икән. Илчеләр икенче бер бабайның ризалыгын алып кайттылар.

«Идарә членнары» белән «агротехник» та, «санитар» да эшкә кушылды. «Атлылар» да «атларын» җиргә кадап куеп, «мылтык-кылычларын» салып ташлап, кулларына көрәк, тырма алдылар.

Хәлим үзләре эшләгән хатаның төзәтелә башлаганын күреп шатланды. Изүләрен чишеп, җиңнәрен сызганып эшләде ул. Үз җирләредәй күреп, әле тырышып-тырышып җир сөрде, әле көрәкне тирән-тирән батырып, чи калган урыннарны казыды. Эзе калсын дигән шикелле, җиренә житкереп эшләде Хәлим. «Илшат»ларның үз иткәннәрен, кырын карамаганнарын күргәч, уен-көлке сөйләп, аларны тырыш эшкә өндәп йөрде.

Хәзер Мидхәт тә «идарәдәге» Мидхәт түгел иде инде. Эш алга барган саен аның күңеле үсте. Аңарда яңа фи-

керләр туды. Йөгерә-йөгерә эшләп йөргән килеш, бүген кич үткәреләчәк сборда тәкъдим ителәчәк социалистик договорның проектын төзеде. Хуҗалык елын тәмамлауга кадәр эшләнәчәк эшләрнең зурысын, кечкенәсен кертте ул бу договорга.

Хәлим аңа:

— Безгә гектарыннан 100 пот яз, безнең җир ашланган, үзегезгә 80 не куй,— диде.

— Юк, алай булмый. Без сездән калышмыйбыз. Ничек тә йөз итәбез. Итәбез, Хәлим!..

Мидхәт шат иде. Ул хәзер чәчүлек тарының чүпле булуына гына борчылды. Тарыда лисохвостка дигән, тары төсле үк, аның авырлыгындагы ук, тик бик әз генәваграк чүп бар иде. Бу чүп җилгәргечтән төшми, эшем эш булсын дисәң, аны бермәмләп, кул белән чүпләргә туры киләчәк.

Ун пот тарыны бермәмләп!

Мидхәт, Хәлимнәр киңәше буенча, «идарәне» вакытлы рәвештә ябып куйды. «Бригадирларны», «хисапчыны», «дежурныйларны» тары чистартырга кушты. Идарәдә бер сторожиханы гына калдырды ул. Аңар да чистартып утырырга бер көшел тары җибәртте.

— Тагы кешең юкмы соң, Мидхәт?

— Ялгыз хуҗалыклар белән сөйләшеп карасак инде...

— Нинди ялгыз хуҗалыклар тагын?

— Һәй, бездә бик күп алар... Идрис, Азат, барыгыз, ялгызакларны җыеп килегез,— диде ул, тагы председательгә охшарга тырышып.

Малайларның берсе ярга таба китте, берсе авылга йөгерде. Озак та үтмәде, яр кырыенда әле пионер яшенә җитмәгән дүрт малай күренде.

Хәлим малайларны таныды: алар Хәлимнәр бу якка чыкканда, елга читендә быкырдап яталар һәм, кайсысы, биш кердек дип, кайсысы, алты дип, үзара бәхәсләшәләр иде. Ул вакытта ук инде аларның муен тиреләрендәге, колак яфракларындагы бала йоннары кабарып чыккан, тәннәре йолкынган каз муены төсле булып күгәргән, борын аслары ялтырап тора иде.

Хәлим көлеп куйды:

— Шулармы инде синең ялгызакларың?

— Шулар.

Ярда тагы ике малай күренде.

Болар икесе дә икешәр кармак таягы тоткан, икесендә дә зур-зур чиләкләр һәм чиләкләрнең берсендә чәнчә бармак кадәр генә бер кызыл канат күренә иде. Кызыл канат хуҗасы алгарак чыкты һәм, индс үлү генә түгел, тәңкәләре коелып беткән балыгын өскә чыгару өчен, чиләген чайпалтып куйды. Икенчесе Хәлимгә пышылдады:

— Үзе тотмады ул аны, өченче көн югартын агып килде. Минем дә бар иде, мин мәчегә бирдем.

Авыл башыннан тагы өч-дүрт «ялгызак» килеп чыкты. Кояш, аксыл болытлар итәгеннән чыгып, саф, зәңгәр, тирән күктә йөзә башлады. Җирдән күтәрелгән бик якты, пыяла төсле үтә күренмәле парның әкрен искән җил белән җиңел дулкынланып торганы күренде. Бу вакытта «Кече Илшат»ның сөрүгә катнашмаган «колхозчылары» «ялгызаклары» белән берлектә идарәгә җыелып «председатель»өстәлендә һәм «хисапчы» урынында шау-гөр килеп тары чистартып утыра иделәр.

11 БЕЗГӘ ЙӨЗ КИРӘК

«Илшат»ларга социалистик ярдәм, Хәлимчә итеп әйтсәк, «абынып егылганнарны күтәреп торгызу» шулай башланып китте.

«Ватан»нан «Кече Илшат»ка һәр көн берничә пионер килеп, булышып йөрде. Бүген берәүләре килде, иртәгә икенчеләре, аннан өченчеләре. Һәм бу эш Мидхәтләрнең җирләре сөрелеп беткәнче дәвам итте.

Тегеләр күрмәсен, тегеләр куып җитмәсен дип куркып йөргән «Ватан» пионерлары, хәзер киңәшләре белән дә, кул көчләре белән дә күршеләренә үзләре артыннан куып җитәргә булыштылар. Бу ике отряд пионерлары хәзер бер ата балалары кебек дус иделәр. Берсендә булган җитешсезлекне бергәләшеп бетерделәр. Уңышлы якны күршеләренә күчерергә ашыктылар. Мәсәлән, җир сөрелеп бетүгә район агрономы, үзенең кышкы вәгъдәсе буенча, «Ватан» пионерлары җиренә, үзе карап торып, культивация ясатырга килгән иде, «Ватан»га гына дип килгән иде ул, ә Хәлим аны, үзләреннән соң үтенә-үтенә, күршеләренә алып китте.

— Ярамый бит, хәзер безнең алар белән договор бар, чын-чынлап ярышабыз без, Дәүләтгәрәй абый.

Әлбәттә, «Кече Илшат»та да «Ватан»нар үрнәк алырлык яклар табылды. «Ватан» нар, алардан күреп, утау һәм урак вакытында кунып эшләү, яңгыр яуганда кереп ышыклану өчен, шалаш кордылар. Ә «Илшат»лар «Ватан»нарның шалашларын сөрелгән җирләре уртасына китереп корганнарын күреп, «идарә»ләрен участокларына якын җиргә күчерделәр. «Ватан»нар, «Илшат»лардан күреп, әйбәт кенә бер купальня ясадылар.

Бер очтан шуны да әйтеп үтик: «Кече Илшат», «идарә» сүзләре хәзер инде көлеп сөйләргә генә калган иде. «Идарә» орлык чистартканда вакытлыча ябылудан беркайчан да ачылмады. «Кече Илшат» сборлардан бер сборда таратылып, эш кәгазьләре костерлардан бер костерда көлгә әйләнде.

Бу ике отряд, хуҗалык эшендә генә түгел, пионер тормышында да бер-берсенә якынайды. Алар хәзер һәр ике якны кызыксындыра торган мәсьәләләр буенча берләшкән сборлар үткәрделәр. Хәтта бергәләшеп стена газетасы чыгардылар алар. «Киңәш» — бу газетага шундый исем бирделәр. Редакция составына район агрономы да кертелгән иде. Хуҗалык буенча алда торган бурычларга кагылган мәкаләләрне, телефон буенча булса да, аның белән киңәшеп яздылар. Газетаны ике данә эшләп, һәр ике колхозның идарәләре алдына элеп куйдылар.

Җир җылынды. Тары чәчәр вакыт килеп җитте.

Шәйхаттар бабайның чәчүгә үз куллары кычытып тора иде, ул инде әллә кайдан тишек-тошык бер тубал табып, Хәтирә әбидән яматып та алган иде, ләкин, кая ул, пионерлар якын да килмәделәр, агроном да рөхсәт итмәде. Ул киң рәтле чәчкеч белән беренче ярты гектарны үзе чәчеп күрсәтте. Калганын пионерлар чәчтеләр.

Аннары агроном «Ватан»нарның да, «Илшат»ларның да күргәннәре булмаган бер эш эшләде. Атка ике метрлы имән бүрәнә җиктереп, чәчелгән җир өстеннән тәгәрәттерде. Пионерлар өчен монысы сәер генә түгел, шикле дә булып күренде:

«Җирне йомшарту өчен сөрдек, тырмаладык, культивацияләдек, ә ул әнә килде дә...»

Агроном аңлатып бирде:

— Бер дә курыкмагыз сез аңардан. Тарыдан мул уңыш алыйм дисәң, шунсыз булмый. Дөрес, без хәзер

җирнең өске катын тыгызладык, ләкин шуның белән без җирдәге дымны саклап калдык. Җирне тыгызлау белән бер үк вакытта без аны тигезләдек тә. Хәзер сезнең орлыклар бертигез булып тишелер. Җир өстенә, команда белән чыгып тезелгән солдатлар шикелле, бер көндә, бер сәгатьтә төртеп чыгар. Бар да бертигез булып үсәр алар хәзер. Ә тигез үсү — үсемлек берсен-берсе каплап китмәсен өчен, берсе өлгереп, икенчесе өлгермн калмасын өчен кирәк.

Агрономның сүзләре раска килде. Уникe көн үтүгә җир өстендә тип-тигез яшел, йомшак үсемлек күренде. Ул торган саен калынайды, куе яшел төскә керде, озынайды. Ә бер кат утап чыккач, ул тагы да матурланып куерып китте.

Шәйхаттар бабай җилкәсен кашып куйды:

— О-о, биредә чыннан да иген була бит, Хәлим. Гектарыннан алтмыш-җитмеш потны җыеп алабыз бит без болай булгач...

— Алтмыш-җитмеш?

— Нигә?

— Безнең өчен алтмышы да, җитмеше дә аз шул, бабай. Безгә йөз кирәк.

— Йөз! Юк, йөз булмый. Монысына да бөтен кешенең исе китте инде. Әле бая синең тавариш, райком секретаре сугылган иде, Сәлимҗан белән. Беләсеңме нәрсә ди Сәлимҗанга? — Кара, ди, гыйбрәт ал,— ди... Теге тик тора, сабагын белмәгән малай шикелле аска карап. Ә киткән чакта көлә секретарь: «Инде тары чәчмәскә тагы нинди сылтау уйлап чыгарырсың икән?» — ди. Сәлимҗан бер сүз дә әйтмәде, мыегын чәйнн бит ул андый чакта. Шул, мыегын чәйнәде-чәйнәде дә секретарь артыннан әкрен генә китеп барды.

— Һе.

— Җитмеш әйбәт ул, Хәлим, син шуңар шөкер ит.

— Шөкер итә алмыйбыз, Шәйхаттар бабай. Безне мәктәптә арттагыларга тигезләнергә өйрәтмиләр, ә алдынгылар менә ничек эшлиләр: Казахстанның Курман колхозчылары быел һәр гектардан җитмеш пот та түгел, йөз дә түгел, 1200 пот тары урып алганнар.

— Күпме, күпме?

— 1200 пот.

— Кирәкмәс, энем. Алай ялган сөйләргә өйрәнмә.

— Ышанмыйсың?

— Бигайбә, энем. Тузга язмаганны дөрес булса да сөйләмә дигәндәй...

— Тузга язмаса, китапка язган, бабай. Әйе, әйе. Агроном укып күрсәтте. 1206 пот дигән әле...

— Хәйран тамаша!.. Бу кеше дигәнең әллә нинди могҗизалар эшли башлады.

— Ә безнең 10 гектардан да 1200 пот булмый. Гарьлек бит бу, бабай.

— Гарьлек дип инде... Белмим соң тагы...

Бу сөйләшү Хәлим соңгы имтиханын биреп кайтып керүгә булды. Нинди шат иде ул капкадан кергәндә, күңеле чиксез күтәренке иде. 2 ле бер дә юк, 3 ле бер генә, гел 4, бер 5 лесе дә бар әле!.. Өстәвенә, Шаһгәрәй абзый, тимурчылар турында сөйләгәндә, алдынгылар рәтеннән Хәлимне дә кат-кат мактап телгә алды:

— ...Фронтта да, авылда да бик авыр ел булды бу. Ә шулай да һичбер бала укуын ташламады. Элек ташлаган 9 бала берсе калмый мәктәпкә кайтып бетте. Нибары бер бала классында утырып калды. Мин монда Тимур командасының чиксез мактауга лаеклы хезмәтен күрәм. Рәхмәт сезгә, кадерлеләрем,— диде Шаһгәрәй абзый һәм тирән дулкынланып, Хәлимне президиумнан өстәл алдына тартып чыгарды, аның уң кулын ике куллап кысты: Син шушы эшең белән генә дә әтиеңнең, бүген син анда кирәклерәк, дигән сүзләрен акладың. Укытучылар исеменнән рәхмәт сиңа,— диде ул. Балалар, үзләренең бу рәхмәткә кушылуларын белдереп, кул чаптылар. Ә Шәпи («Ватан»да юк, кайдан алгандыр) Хәлимгә тугыз бала исеменнән, яңа өзелгән зур бәйләм канәфер чәчәкләре китереп бирде... Хәлим аны Фәрдәнәгә, Каюмга, бөтен тимурчыларга бүлеп чыкты. Бер тәлгәшен фуражка рeмененә кыстырды. Иң матурын, яңа ачылып килгәнен Шаһгәрәй абзыйның күкрәгенә китереп каклады һәм кочып алды. Зал, карт укытучыны хөрмәтләп, кул чапты. Хәлим күңеле нечкәреп киткән укытучысының күзләрендә яшь бөртекләре күрде. Аның күгәргән иреннәре: «Рәхмәт, рәхмәт, кадерлеләрем...» дия иде.

Әйе, капкадан кергәндә Хәлимнең күңеле күтәренке иде. Ул инде ашагач-эчкәч, иптәшләре белән болынга чыгарга, кар тотарга түгел, тирес түгәргә түгел, сыер тизәге жыярга түгел, ә чәчәкләр эчендә аунап күңел

ачарга уйлаган иде, Шәйхаттар бабай 60—70 дыюгә күңелсезләнеп китте. Ашап-эчеп алды да басуга чыгып китте. Тары Хәлимгә бу юлы, ничектер, сирәгрәк шикелле күренде һәм ул күңел ачуны, болынны онытты, өенә дә кереп тормады, туп-туры районга, агроном янына китеп барды.

— Сез, йөз пот була, дидегез. Йөз булмый бит безнең, Дәүләтгәрәй абый...

Хәлим бу сүзләрне әйткәндә шундый күңелсез, шундый кызганыч иде, агроном кемгәдер шалтырату өчен алган телефон трубкасын кире куеп, урыныннан торды һәм, өстәл артыннан чыгып, Хәлимнең башыннан сыйпады. Ул аның җаны-тәне белән тырышып йөрүен күреп сокланды. Һәм үзенең киңәшләре белән ничек тә ярдәм итәргә тырышты.

— Һ-м,— дип торды ул карандаш очын иренена куеп уйланган хәлдә,— утадыгызмы әле?

— Утады-ык...

— Тарыгыз кыяклангач, тагын бер утагыз. Басуыгызда энә очы кадәр дә чүп үләнн калмасын. Шулай эшләгәндә, йөз пот алуыгызга расписка биреп куярга да була,— диде агроном.

Ә берничә көн үтүгә Хәлим артыннан «Ватан»га үзе килеп житте. Ул килгәндә пионерлар елгада су керәләр, балык чирттерәләр иде, кармакларын ташлап, елгадагыларны киенергә дә онытып, агрономны сырып алдылар.

— Беләсезме, сез тагы менә нәрсә эшләгез... Ләкин монысы инде су кереп, балык тотып йөрү кебек булмый... Боргаламый-сыргаламый гына әйткәндә: монысы — бик пычрак эш...

— Булсын, булсын!..

— Булсын булса, болай итәсез...

Икенче көнне таң белән пионерлар яңа һөҗүмгә чыктылар. Бу эштә пионерларга, Шәйхаттар бабай түгел, агроном белән Тәзкирә апа житәкчелек итте һәм анда ир балалар гына түгел, кызлар да катнашты.

Тары янына бик зур бер кисмәк китереп куйдылар. Аңар унбишләп малай кечкенә арбалар, носилкалар белән сыер тизәге ташыды. Абзардан гына түгел, көтүлектән дә җыйдылар малайлар сыер тизәген. Ә кыз балалар елгадан су китереп торды. Хәлим белән Ибраһим бер өлеш сыер тизәгенә 5 өлеш су кушып изделәр. Ибраһим, киндер бияләйләр киеп, сыекчаны зур агач көрәк белән бол-

гата-болгата, борынын озак тартып иснәп тордытордны да:

— Ну, марайрар!.. Сыер ите шулпасында пешкән кәбестә ашыннан бер дә ким булмый бу. Кызрар, сез дә килеп, бераз иснәп китегез әле...— диде.

Үзара сөйләшә-сөйләшә көянтә-чиләк белән су алып менеп килгән кызлар борыннарын алъяпкыч читләре белән тоттылар. Берсе:

— Я бу доктор дигәннәрнең борын! Бигрәк нәзакәтле була икән,— дип куйды.

Барысы да көлеп җибәрделәр.

Ибраһим шып булды. «Ну, Гөлгенә, энәң...» Ул моны эченнән генә әйтте.

Сыекчаны әзерләп бетереп, ике көпчәкле арбага көйләнгән кисмәккә салгач, тимерче килеп, кисмәкне труба аша арба артындагы күп тишекле улакка тоташтырып бирде. Пионерлар сыекчаны һәр гектарга 20 центнер исәбеннән тарыга сибеп чыктылар. Кырыклап баланың тагын ике көне китте бу эшкә. Әйе, пычрандылар балалар, арыдылар, ләкин алар моның белән уңышны бик күп күтәрделәр.

«Ватан»нар моны, әлбәттә, «Кече Илшат»лардан яшереп эшләмәделәр. Киресенчә, Хәлим, агроном килеп төшү белән, «Илшат»ка чаптар җибәрде. Агрономның өйрәтүен «Илшат»лар да килеп тыңлап тордылар. Алар да төне буе хәзерлек эшләре алып бардылар һәм таң ату белән үк эшкә керештеләр.

— Инде хәзер йөз генә дә булмый,— диде агроном.— Ләкин утагыз, энә очы кадәр дә чүп үлән булмасын басуыгызда. Чүп үләннәрнең күренгәнен берсен, снайперлар фрицларны чүпләгән шикелле, чүпләп торыгыз.

— Бер керешкәнбез икән, иренмик инде без,— диде Хәлим агроном киткәч үзенең иптәшләренә,— ашасыннар әле әтиләр без үстергән ботканы рәхәтләнеп, авызларын тутырып.

— Тагы бер кат утыйбыз әле, малайлар.

— Утыйбыз, утыйбыз!

Һәм пионерлар утадылар. Утауда пионерлар гына түгел, бөтен мәктәп катнашты. Хәтта сигез-тугыз яшьлек балалар да читтә калмады. Алар да иртән үк торып утауга килделәр. Әйе, су буенда чапырдашып яту алар өчен рәхәтрәк булыр иде, балык каптырырлар иде су кереп

туйгач. Аннары җиләккә китәрләр иде... Юк шул. Пионер абыйлары әнә нәрсә диделәр: «Чүп үлән йолкып ташлау — фашистны йолкып ташлау ул. Ә фашистны йолкып ташлагач, сугыш бетә. Әтиләр, абыйлар өйгә кайта. Бүген җыймый калган җиләкне шул чакта җыярбыз, шул чакта суны бүгенге өчен дә керербез, балыкны бүгенге өчен дә тотарбыз» диделәр...

12 ИШКӘНСЕЗ ИКӘН...

Мактадык та мактадык, ләкин тарының көйсез яклары да бар бит: ул соң өлгерә. Әнә инде колхоз арыш урагына чыкты. Бодай белән арпасы да җитеп килә. Ә пионерларның тарылары әле өлгерергә уйламый да иде.

Пионерлар, икенче кабат утаганнан соң, бөтенләй бушап калдылар. Атлар тирәсендә дә эш калмады аларга. Хәзер колхозның бер аты да кырдан кайтмады: шунда ашады, шунда кунды. Пионерлар өстенә төшкәне — кояш баеганда атларны бер тапкыр су кертеп кайтудан гыйбарәт иде. Ә монысының эшлеге ни дәрәҗәдә икәнне ир балалар белә инде.

Эшсез тору эшкә өйрәнеп җиткән балаларга әллә ничек сәер тоелды. Бөтен колхоз эштә, колхоз бал кортлары оясы кебек гөҗләп тора, ә без...

Пионерлар, үзләрен окопта озак вакыт һөҗүм көтеп яткан солдатлардай, уңайсыз хис итә башладылар. Су керделәр алар озак-озак итеп, судан чыктылар да балык чирттерделәр, җиләккә дә барып кайттылар. Урманда җиләк күп иде, тәмле иде, никадәр ашасаң да туйдыра торган түгел. Ләкин сугыш вакытында, колхозда эшче көче җитмәгәндә болай йөрү әйбәт була микән соң? Юк, әйбәт булмый. Колхозда эшче көче җитмәгәндә, безнең болай йөрү әйбәт булмый, иптәшләр...

Хәлим, Каюм, Фәрдәнә, Гөлгенә һәм тагын берничә пионер җыелып сөйләштеләр, укытучылар белән киңәштеләр дә басуга чыгып киттеләр. Анда аларны — сөйләнеп кенә йөрмәгән, эшли дә белгән пионерларны — колхозчылар ихтирам белән каршы алдылар. Хәзер аларның газета укулары колхозчыларның колакларына ятышлырак булып ишетелде, сөйләгән сүзләре көчлерәк булып яңгырады. Ә көннәр каты кыздыра башлагач, игеннәр нык өлгереп, башаклар коелырга җиткәч, пио-

нерлар басуга күп булып, шау-гөр килеп, быргы уйнатып, барабаннар кагып чыктылар. Аларның кулларында киң кызыл комачка зур-зур хәрефләр белән язылган шундый лозунг иде:

Бүген җыеп алыр игеннәрне
Иртәгәге көнгә чигерү:
Бу — Гитлерга 50 километр
Җирне биреп, артка чигенү.

Лозунгны калку җиргә кадап куйдылар да, иңнәреннән уракларын алып, уракчылар янына килделәр. Кыр бригадиры аларны иң алдынгы уракчыларга беркетеп чыкты:

— Әйбәтләп, үзеңнән дә оста ура торган итеп өйрәт әле шушы егетне, Маһирә җиңги.

Пионерлар, уракчы хатыннар күрсәткәләп бирүгә, ә кайберләре күрсәткәнне дә көтеп тормыйча, арыш төбенә иелделәр.

Ул да түгел, авыл башында тагы бер төркем бала күренде. Укытучылар җитәкчелегендәге бу төркем кече яшьтәге пионерлардан һәм пионер яшенә җитмәгән балалардан тора иде. Бик күп иде алар. Аларның да кулларында озын кызыл комач булып, шундый сүзләр язылган иде:

Син җыймыйча җирдә калдырсаң,
Тик бер генә иген башагын —
Бер пуляны фашист йөрәгенә
Атмаенча җиргә ташладың.

Балалар, комачны ике чүмәлә өстенә беркетеп куйдылар да, киң фронт булып урып баручы уракчылар артына сибелделәр һәм коелып калган башакларны итәкләренә, кепкаларына, тырыс яки кечкенә кәрзиннәргә җыярга керештеләр.

Ә кич белән караңгы төшеп килгәндә, тын елгада кара-каршы йөзеп килгән ике көймә күренде. Көймәләрнең берсе «Илшат»ка, икенчесе «Ватан» ярына таба йөзә иде. Берсеннән-берсе ашыгып йөзгән бу көймәләрнең берсендә Хәлим, икенчесендә Мидхәт иде. Мидхәт, Хәлимне танып алуга, ишүеннән туктап эндәште:

— Әй, иске дус, борыл. Сезгә барам.

— Юк, син борыл. Мин сезгә барам.

— Нигә?

— Без договорга тагы бер пункт өстәргә булдык.

— Нинди?

— Тыңла! — Хәлим әле генә пионерларның ашыгыч җыйналган сборларында кабул ителгән сүзләрне күңеленнән укып чыкты:

— 1943 елда колхозның 200 гектар җирен урып-җыеп бирергә, 200 гектар җирдә башак җыярга.

Мидхәт, Хәлим көймәсенең читеннән тотып, аның күзләренә карады һәм үзендә ниндидер өстенлек булуны тавышы белән үк аңлатырга теләп, әйтте:

— Ишкәнсез икән, иске дус... Яндыр фонареңны! — диде ул, тантаналы итеп, һәм, куен кесәсеннән ярыш договорын чыгарып, фонарь яктысына иелде. Договор кәгазе, яңадан-яңа өстәмәләр кертелә-кертелә чуарланып, тузып беткән иде.

— Тыңла...

«Илшат»лар договорына өстәлгән пунктның да эчтәлеге «Ватан»нарныкы шикелле үк булып, йөкләмәләре берникадәр зуррак иде. Хәлим, Мидхәт укыганчы ук, цифрларны күреп алды һәм шунда ук үз договорын кесәсеннән чыгарып, «Илшат»ларныкы шикелле итеп, төзәтеп куйды: 22; 220...

— Әйдә инде сезнеңчә булсын.

— Аз, аз бу сезнең өчен.

— Ну, мә алайса! — Хәлим соңгы «2»леләрне «3»ле итеп төзәтте.

— Иһи-и... Син нәкъ базардагыча... Менә болай ит син...

Мидхәт үз договорын ишкәк сабына куйды да 22 не 25 итеп, 220 не 250 итеп төзәтте һәм аптырап карап торган Хәлимнең кулына карандаш төртте:

— Мә, мә, төзәт, иске дус!

Бу күп булачак иде, бу авырга киләчәк иде, шулай да Хәлим сынатмаска булды. Карандашны Мидхәт кулыннан дулкынланып тартып алды да цифрларны 27 һәм 270 итеп төзәтте һәм, үзенә күчкән өстенлекне көчәйтергә тырышып, өстәп әйтте:

— Ә без бер көн эшләп тә кайттык инде.

Мидхәт тагы елмайды:

— Ишкәнсез икән, иске дус!.. Белмәсәң бел инде алайса: без ике көн эшләдек һәм әле кайтканыбыз да юк. Урабыз әле без...

Хәлим моңа каршы әйтергә сүз тапмады. Башын чайкап куйды да, сөйләшкән арада шактый түбән аккан

көймәсен агымга каршы борып, үз якларына таба каерып-каерып ишә башлады.

13 ЗӘҢГӘР КОНВЕРТ

27; 270 — бу аз түгел. Тиздән инде тары да өлгерер. Укуга да ерак калмый. Башкарып чыга алсак ярый инде...

Пионерлар, шул ук вакытта, үз өсләренә алган ике мөһим эшне онытмадылар. Боларның берсе — тимурчылык иде. «Фронтовик семьясы аз гына мохтаҗлык, бик аз гына да ятимлек сизмәскә тиеш!» Тимурчыларның төп лозунглары хәзер шул булды, һәм алар моны намус белән үтәп килделәр. Ничектер бер тапкыр бер фронтовик анасының Акбуага барып, күпер салган җирдән йомычка җыеп йөргәне килеп ишетелде. Икенче берсенең урманнан чыбык-чабык күтәреп кайтканда егылып ятканын әйттеләр. Бу хәл бер генә тапкыр булды. Ә шулай да пионерлар, тузгытылган кырмыска оясыдай, нишләргә белмәделәр. Бу эштә гаепле пионер шелтәсез кала алмады. Шул ук көнне дүрт пионер кечкенә арбаларга урманнан коры ботаклар төяп кайтып, фронтовик аналарының лапас асларына кертеп өйделәр. «Беткәнен көтеп тормагыз, без хәзер, Гайшәбикә түтәй...»

Шуннан соң мондый хурлыклы хәлнең кабатлануына юл куелмады. «Кемнең нәрсәсе җитеш түгел, кем нәрсәгә мохтаҗ» — хәзер бу турыда Фәрдәнә үзе кайгыртып торды. Көн саен бер фронтовик семьясының өендә булмый калмый иде ул хәзер.

Пионерларның икенче мөһим эшләре — элеккечә почта ташу иде. Монысын алар хәзер аеруча яратып эшлиләр иде. Чөнки информбюро белдерүләре хәзер «Бүген безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң...» дип түгел, «Соңгы сәгатьтә» дип башлана, кешеләр почтаны дүрт күз белән көтеп алалар иде. Хат ташучы хәзер почтадан туры кырга кайта. Уракчылар ерактан күреп, эшләрен ташлап, каршы йөгермәсеннәр өчен, иген арасыннан посып кына килә дә, халыкның иң күп эшләгән җирендә туктап, кычкырып җибәрә: — «Һәй-й!.. абыйлар, апалар, бүген фәлән шәһәр!..» — әйтерсең, пионер ул шәһәрне үзе алган, кешеләр аны шундый ихтирам белән тыңлыйлар. Аннары пионер хатларны таратып чыга. «Әсмабикә әби, бие... түгел, Борһан абыйдан... Ә юк, бащта бие...

Белмәсәң дә бие... Кремльдә булган җыелышта Калинин бабай Борһан абыйның күкрәгенә үз кулы белән орден кадаган».

— Миңа тагын юкмыни әле, улым?

— Бар, бар, сиңа да бар, Зөлхәбирә җиңги. Икәү, ике хат...

Ай барысы да шундый гына булса!.. Шатлыклы хатлар арасында кайгылылар да була иде шул...

Шундый кайгылыны бүген үз чиратында почтага барган Хәлим алып кайтты. Җыйнак кына зәңгәр конверт эчендә иде бу хәбәр. Почта кызы конвертны башта Хәлимгә бирми торды. Аннары, ичмаса, авылына кайтканчы күрмәсен, дип башка конвертлар арасына тыкты да, аны-моны сөйләшкән булып, үз кулы белән Хәлимнең сумкасына салды. Ләкин Хәлим кемнән кемгә хат барын карап чыкмыйча түзәрме соң! Кайсы хат белән, кемне кайтып шатландырасын белмичә, түзәрме!.. Бусы Каюмнарга... Шәпиләргә, оһо, икәү... Хәтирә әбигә... Ну, сөенер инде...

Актара торгач, Хәлимнең күзләре матур гына зәңгәр конвертка туктады. Укый-укый гадәтләнеп беткән ТАССР сүзләрен йөгереп үтте ул. Район, авыл исемен дә күреп өлгермәс борын укып чыкты. Капка номеры... Хәлимнең күзләре кинәт борчулы кыяфәткә кереп, исем фамилиягә күчте.

«Шәмсия Арслановага...» Хәлим белеп бетергән: һәрбер яза белгән солдат адресны үзе яза. Авыр ятса да, кулы яраланса да үзе тырыша, уңы яраланса, сулы белән тырнаштыра. Ах, моның хат язарлык та рәте калмаган икән димәсеннәр өчен шулай эшли ул... Ә бу хатның адресы ят кул белән язылган иде һәм бусы инде авыр кайгы билгесе иде!.. Хәлимнең куллары, бөтен гәүдәсе калтыранды, Хафиз абыйсы Мәскәүдә хәрби мәктәптә, димәк, эти...

Шулай да Хәлим начарны уйламаска тырышты.— Бәлки, алай түгелдер,— диде ул үзен-үзе юатып.— Бәлки, аның ике кулы гына яралангандыр... Шуна күрә хатны иптәшләре язгандыр...

Хәлим шулай уйланып, үзен-үзе шуңа ышандырырга тырышып, урамга чыкты. Һәм, чынын никадәр беләсе килсә дә, хатны ачып карамады. Болай әйбәтрәк, болай аз гына, бик аз гына булса да өмете бар әле аның. Ачып укыса, үз күзе белән күрсә...

Хәлим әтисе турында бары яхшыны гына уйларга тырышты, аның кулларын да өзелгән итеп түгел, бармаклары гына яраланган итеп күз алдына китерде, бармакларын да инде төзәлеп киләләр итеп, хәзерге сәгатьтә каләмен шул бармаклары арасына кыстырып, икенче бер хат язып утыра итеп күз алдына китерде. Күз алдына китерде, ләкин моның үзен-үзе алдау икәнен уйлап, конвертның читен ертты һәм, хатка күз төшерүгә, әчке сыкрау белән «әти!..» дип кычкырып җибәрде.

Хәлим хатны яшь томаланган күзләренә якынрак китереп, янә: әти, әти!..— диде.— Әле өченче көн генә Таллинга һөҗүм хәзерләвегез турында үз кулың белән язган хатыңны укыган идек бит, әтием...

Хатны Зиннәт абзыйның фронт иптәшләре язган иде:

«...Таллинны алгач, дошманны ары куып барганда, минага эләгеп һәлак булды. Полк аны, шәһәрдән ерак түгел бер калку җиргә, ялгыз имән төбенә, чишмә янына җирләде...» диелгән иде хатта.

Аңар бик күп сугышчылар, командирлар кул куйган иде. Хат янында кабер рәсеме дә бар, аның астына: «Бирегә өлкән лейтенант Зиннәт Арсланов күмелде» дип язылган иде.

Хәлим хатны, кабер рәсемен йомшак кына итеп күкрәгенә кысты. Иренен авырттырганчы тешләде дә, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, кепка козырегын түбән төшереп, почта яныннан китеп барды.

Райбашкармага кечкенә чемоданнар күтәргән, төрле рюкзаклар аскан яки култык асларына бөктәр-мазар кыстырган кешеләр кереп бара иде.

Башка вакыт булса, шәһәрдән уракка килүче бу кешеләрне Хәлим санамый калмас иде, аларны райондагы колхозлар санына бүлеп чыгар иде — «Әһә, безгә фәләнчә кеше тия...» — Ә хәзер ул алар яныннан һичбер төрле әһәмият бирмичә, бәрелә-сугыла узып китте. Кайтып житкәнче берни күренмәде аның күзенә. Кайткач газеталарны, хатларны сүлпән генә йөреп, таратып чыкты. Үзләре укый белмәгән карт-карчыкларга башка вакыттагыча укып бирмәде. Күкрәк кесәсендәге хатын (иң авыр кайгыны) кулы белән кысып, өенә таба өстерәлде ул. Бераз баргач, туктап калды.

— Әнигә бүген үк әйтмим әле, тиз генә әйтмим, бер дә әйтмим...— диде ул, һәм, колхоз председателе Сәлимҗан абзыйның үзенә генә сөйләп эчен бушату өчен,

правлениегә килде. Председатель урып-җыюның барышы турында бригадирлар, ферма мөдирләре, агротехниклар белән киңәшмә үткәрә иде.

...Сабаны да, үч иткән шикелле, арыш белән бергә өлгерде бит быел. Арпа коелырга тора. Уракка кеше җитми... Бер кешене икегә ярасыңмыни.. Киңәшмә шул турыда баш вата иде... Рядовой колхозчылар гына түгел, авыл советы, колхоз правлениесе эшчеләре, укытучылар күптән инде урып-җыю эшенә тартылып беткән, эвакуация тәртибендә килгән өч семьяның да эшкә яраклы кешеләре басуда, эшче буларак, әллә кайчан онытылып беткән карт-корылар да ихтирам белән телгә алынган иде инде. Ә шулай да кеше җитми иде әле.

— Хәтирә әбине, Мәстүрә, Сәхибҗамал әбиләрне алып чыгыгыз.

— Басу ерак. Йөри алмыйлар.

— Ат белән илтеп куй. Идрис абзыйны, Сәмигулла, Хөснулла бабайларны да алып чыгарга кирәк.

— Күзләре начар күрә бит.

— Җилгәргечкә куй, әйләндерерләр бер көйгә. Ә Гайшәбикә әбине киленнәре белән уракка күчер,— диде председатель һәм, тагы да шундыйлар калмады микән дип, күзләрен тиз-тиз исемлектә йөртә башлады. Өстән аска төште ул тиз генә, бик тиз генә астан өскә менде. Күрәсең, эзләгәнен тапмады, карандашын исемлек өстенә ачу белән атып бәрде дә, кулларын артка куеп, тиз-тиз идән буйлап йөрергә тотынды һәм, каланча сәгате суга башлауга, кинәт туктап калды:

— Фәйрүзә!

— Мин.

— Пожарный Сабирны эскерткә куй. Каланчага хатыны менәр.

— Кулы ярамый бит, Сәлимҗан абый.

— Чиркәү кыңгыравы түгел, сыңар кулы белән кагар.

— Андый-мондый хәл булса?

— Сабирын ерак җибәрмә. Авыл башындагы бодайны эскертләр. Әмәгеннән Чәмәген аерма: Муллаәхмәтне дә эскерткә куш.

— Ә кучер?

— Вакытлыча кыскартырга.

— Атны кем җигәр?

— Кемгә кирәк шул.

— Вәкил-мазар килсә?
— Ул да үзе җигәр.
— Белмәсә?
— Белмәсә, колхозга кертмә! Җитте! Ниткән вәкил ди ул ат та җигә белмәгәч!.. Шулай ит... Акбабай ни-хәлдә?
— Аны да борчымыйк инде, кем, Сәлимҗан...
— Ичмаса, бодай чабучыларга күрсәткәләп тора алмас микән?..
Бригадир башын селкеде. Председатель, тешләрен кысып, исемлеккә иелде:
— Бер кешене икегә ярысыңмыни!..
Кулларына блокнот яки кәгазь тотып утырган бригадирларның берсе тамагын кырып куйды:
— Әҗем Зарифы белән Габдрахман абый госпитальдән соң ялга кайттылар.
Председатель башын күтәрде.
— Бар йөгер, риза булмаслармы икән. Хәлне әйбәтләп сөйләп бир. Зинһарлап сора.
— Сорадым инде мин, риза булдылар.
Председательнең йөзе яктырып китте.— Урак машинасына! — диде ул шатлыгын яшерә алмыйча.— Икесен дә урак машинасына, күз нурларымны!..
— Барабанга кеше юк бит әле...
Председательнең йөзен тагы болыт тартты. Тагы идән буйлап йөри башлады ул. Сукыр лампа корымы һәм тәмәке төтене белән саргаерга өлгермәгән яңа плакат янында туктап торды. Плакатта кызылармеец. Ул, колхоз кырларына карап, «Җиңү өчен икмәк кирәк!» дип кычкырып тора иде.
— Анысы факт, кирәк... Ләкин, күрәсең, урып өлгерә алмыйбыз...— диде председатель, чын кызылармеец белән сөйләшкән кук сөйләнеп куйды. Аннары борылып, Шаһгәрәй абзыйга эндәште:
— Хәтерләгез әле, башак җыючы балалар арасында уракка яраклылар юкмы?
— Юк бит. Иң зурысы унда.
— Һм-м... бар әле, Әүхәди, минем атны җик. Спирт заводы белән сөйләшеп карыйм. Ичмаса, ике-өч кенә кешеләрен булса да тынлап тормаслар микән.
...Я инде, шундый чакта ничек итеп председатель синең кайгыңны уртаклашып торсын?.. Хәлим идарәдән чыгып китте.

— Әхмәтша абыйга сөйлим...— дигән карарга килде Хәлим һәм авыл советына керде.

Анда Әхмәтша абзый — авыл советы председателе — укытучылар һәм авыл советы эшчеләре белән киңәшмә алып бара иде.

— ...Кызыл Армия алдында без һәмишә бурычлы әле, җәмәгать,— диде председатель,— без Кызыл Армиягә тагын 15 кыска тун, 60 пар җылы бияләй җыеп тапшырырга тиеш. Без тагын 15 мең сумлык лотерея билетлары таратырга тиеш. Барыгыз, халык белән иплəп кенә сөйләшегез,— диде ул һәм мич артына өелешеп, аның «бурычлы» урынына «борычлы» диюеннән елмаеп, тагы бер әйтсә, шаркылдап көлеп җибәрергә җитеп торган малайларга эндәште:

— Нәрсә кеткелдисез анда? Кайсыгыз җигә белә? Минем атны җигеп китерегез, райбашкармага китәм!

Малайлар берсе калмый: «мин» дә «мин» диешеп, чыгып йөгерделәр. Председатель райбашкармага алып барачак кәгазьләрен портфеленә тутыра башлады.

...Я инде, шундый чакта ничек итеп ул синең кайгыңны уртаклашып торсын?..

Хәлим башын иеп чыгып китте һәм, әкрен генә килеп, бабалары ишегең шакыды.

Шакыды һәм кермичә китте.

— Кирәкми. Бабай ерак ындырда хәзер. Ә әби чыдамас, шунда ук әни янына чыгып йөгерер. Бик ярата бит ул этине.

Хәлим Каюмнарга керде.

— Каюм тары саклый. Кара, үзең кушкансың ич...

Хәлим арыган аякларын өстерәп, кайгысының бөтен авырлыгын хис итеп, өенә кайтты. Ишек ачык иде, әнисе кызыл юллы ашъяулык җәелгән өстәл янында, дәрес хәзерләүче бала кебек сөйләнә-сөйләнә, нидер язып утыра иде. Хәлим, әнисенең сүзләрен ишетмәсә дә, этисенә хат язганын аңлады. Чөнки өстәлдә бары этисеннән килгән хатларны укыгандагы һәм аңарга хат язгандагы шикелле кадерле минутларда гына кабызыла торган унлы лампа балкый иде.

— Беләм инде, этинең өченче көнге хатына җавап яза, ордены белән тәбрикли...— диде Хәлим һәм «ялгышасың бит, әни!» — дип чак кына кычкырып салмады.

Шәмсия җинги, бусагадан атлар-атламас басып торган Хәлимнең сулаганын ишетеп, борылып карады. Бик

шат иде аның йөзе, карашы бик җылы иде. Улын күргәч, ул тагы да яктырып китте һәм, урыныннан җиңел күтәрелеп, Хәлимне кочып алды:

— И-и... Кайттыңмыни, улым. Әйдә, кер... Дөнья мәшәкате белән онытып торам икән, әбиең искә төшерде: этиеңнең туган көне ич бүген. 50 яшь тулды этиенә, ә безнең өйләнешкәнгә 30 ел. Бераз бәйрәм итеп алыйк дидем... Хәзер әбиең белән Гөлгенә әнисе дә...

Хәлим үзенең артык борчулы күзләре әнисенең артык шат карашы белән очрашудан куркып башын читкә борды.

Шунда гына ул өйнең сугыш башланганнан бирле булмаганча бизәлгән икәнен күрде: мич сөттән ак итеп агартылган, тәрәзәләрдәге эч пошыргыч маскировкаларны каплап, ак кисея пәрдәләр корылган. Тәрәзә араларында авыл өйләренең күрке — кызыл башлы сөлгеләр. Идәнгә нәфис сугылган киндер палас җәелгән. Гади, тәрәксез урындыкларда да ниндидер тантана бар кебек. Алар бер-берсеннән тигез ара калдырып, әз генә кыеклап, ничектер матур итеп тезелгәннәр. Мич алдында, кечкенә тишекләреннән утлы күмерләрен күрсәтеп, парларын бөркеп, кояштай сары самовар шаулап утыра. Ә түрдә, ике тәрәзә арасында, Зиннәт абыйның кызыл ефәк ленталарга уралган зур портреты карап тора иде.

— Кара, нишләп аптырап торасың? — диде Шәмсия җиңги Хәлимгә һәм, кочкан килеш, түргә алып килде.

— Утыр шунда. Анда түгел, менә бирегә, этиең урынына, этиең булып...— диде ул һәм, яшь киленнәр җитезлеге белән, самоварны өстәлгә китереп утыртты. Аннан зур таба белән хуш исле карабодай коймакларын мичтән алып китереп куйды.

Хәлим коймакларга түгел, өстәл читендәге язылып бетмәгән хатка карады.

Зиннәт абзый хатларының берсендә: «...хатыгызны кич белән окопта, һөҗүм көтеп ятканда китереп бирделәр, таң атканчы укый алмыйча тилмереп чыктым, югыйсә, әзрәк, ачыграк язылган булса, укый да алган булыр идем, ай яктысы бик шәп иде ул төнне...» дип язган иде. Ахры шуны исендә тотып, Шәмсия җиңги хатны эре хәрефләр белән, шәмәхә карандашын төкерекли-төкерекли язган иде. Хәлим хатка үрелде, ә әнисе аңар таба коймаклы табаны этәрде:

— Аша, үзе кунакка кайтып килмәсме, дип саклап тора идем, кайтмады ич. Яңа өлгергәч кайтыр, боерса... Кара, аша инде...

Хәлим, йөрәге белән сыкрап, йөзе белән елмаеп коймакка үрелде. Кулы калтырады аның, шундый калтырады, коймагы ашъяулыкка төшеп китте. Хәлим, тамагыннан үтмәячәген белеп, коймакны кире табага куйды һәм үрелеп гармонен алды да, ничектер, йөрәк өзгеч итеп сузып җибәрде:

Кара урман аша-лай
Кошлар сайраша, шул,
Башлар адаша...

— Абау-у, әлләниндине уйнама! Әтиең җырлый торганны, матурны уйна,— диде Шәмсия җиңги, чынаякларга чәй ясый-ясый.

Хәлим башын гармонь өстенә иде дә, эчке хисләрен җиңәргә тырышып, уйный башлады:

Камыр баскан кодагыйның
Кулы ябыша микән?

— Менә шулай,— диде Шәмсия җиңги...— Менә шулай...

Кодагыйның юачасы
Майсыз да пешә микән?..

Гармонь шулай диде. Ә йөрәк әрнеде. Йөрәк гармоньны үзенә буйсындырды:

Өзелде лә үзәк...

Хәлим гармоне өстенә тамган яшьләрен күрсәтмәс өчен, башын тагын да ия төште.

Өзелде лә үзәк, янды йөрәк,
Ишеткәч хәбәреңне...

— Эх әни!.. Ялгышасың бит, әни... Әтигә илле яшь тулмады һәм инде беркайчан да тулмас...— Хәлим шулай диярга уйлады. Әйтмәде — юк, кирәкми. Бүген кирәкми. Беркайчан да кирәкми. Белми торсын...— Хәлим үзен кулга алды. Ул кунаклар кергәч, ашаган, эчкән, уен-көлке сөйләшкән булып бераз гына утырды да, тарыны карап кайтыйм әле дигән булып, чыгып китте һәм, кайда барганын үзе дә белмичә, тын урам буйлап китеп барды. Болынга килеп чыкты ул бара-бара. Әнә ат саклаучы малайлар. Кostерлары ничек күңелле дөрләп яна!.. Хәлим бераз икеләнеп торды да туктамыйча китеп барды. Болынны үткәч, кечкенә генә бер тау бар, анда, әтисе

кабере янындагы шикелле, ялгыз имән үсә, тау итәгендә чишмә чылтырый. Хәлим шунда менде.

Соң иде инде. Шулай да караңгы түгел. Күк йөзен юка гына, җиңел генә ак болытлар томалап алган. Шул болытлар артында, кисея күлмәк аша күренгән алсу тән шикелле генә булып, тулы ай беленеп тора. Һава аеруча рәхәт — җылы да түгел, суык та. Тауга түшәлгән анда-санда чәчәкле яшел чирәм өстендә, бик юка болыт төсле булып, ак томан җәелеп ята. Мең, ә бәлки бик күп, бик күп мең еллар буена ташу уйган яр читендә гел бертөрле, ләкин бер дә туйдырмый торган тавыш чыгарып, күп сулы чишмә чылтырый. Бик тын. Ялгыз имән үзенең саргаер-саргаймас яфракларын әз генә дә селкетми.

— Әтием баш очындагы имән нишли икән хәзер? Ул да, көн буе яфракларын кыштырдатып сөйләшкәннән соң, әтигә тавыш булмасын дип, шушылай тын гына утыра микән? Андагы чишмә дә хәзер шушылай чылтырый микән? Әтием, әтием!.. Нәрсә дидең икән син үлгәндә? Берәр сүз әйттең микән? Өлгерә алдың микән әйтергә? Соңгы сулышыңны алганда, мин янында булсам, ни әйтер идең икән син, этекәчем? Беләм, «Үч ал, улым! Ку хәшәрәтне изге җиребездән!» дияр идең син... Тукта әле, нигә кайттым соң мин? Нигә фронтта түгел? Нигә монда басып торам соң әле мин?..

Хәлим нидер уйлап кинәт хәрәкәткә килде. Тезләнгән иде, аякларына басты. Көчле дулкын шикелле, ватардай җимерердәй итеп диңгез ярына килеп бәрелгән һәм шунда ук кире кайткан дулкын шикелле, хәлсезләнеп, яңадан чык**лы** чирәмгә тезләнде. Башын түбән иде. Белмим, күпме торыр иде ул шул хәлдә, белмим, нишләр иде, якында гына көянтә-чиләк тавышлары ишетеп, сискәнеп китте.

— Хәлим!

Хәлим башын күтәрде.

Анардан берничә генә адымда, көянтә-чиләкләрен асып, чишмәдән кайтып килүче Гөлгенә басып тора иде. Белгән иде ул Хәлимнең кайгысын. Кичә үз чиратында почтага баргач ук ул инде әлеге шомлы хатны күргән иде. Һәм, тапшырганда җаным әрнер дип, алмыйча кайткан иде. Хәзер күргәч тә читләтеп үтә башлаган иде ул Хәлим яныннан. Ләкин алай яхшы буламы соң? Намуссызлык булмыймы алай? Барыйм, кайгысын уртаклашыйм, диде ул үзенә-үзе һәм юату өчен хисле, матур сүзләр

сайлый-сайлый каршысына килеп басты, әкүзгә күз очрашкач, каушый калды. Бары:

— Елама, нәнәм...— дип кенә әйтә алды ул аңар.

«Елама, нәнәм!..» — Тукта, тукта... Хәлимнең бу сүзне кемнәндер, кайчандыр күп тапкырлар, ләкин бик тә, бик тә күптән ишеткәне бар иде ич. Күргән төш шикелле томанлы гына хәтерли хәзер Хәлим бу сүзне. Кем әйтә иде соң аңар шулай дип? Кара, Гөлгенә бит... Әйе, әйе, Гөлгенә!..

Берәр малай кыйнап кайтарса, яки әнисеннән нахакка эләксә, Хәлим ике йорт арасындагы коймага башын куя иде дә үксеп елый иде. Моны ишетеп, койманың үз ишек аллары ягына Гөлгенә килә иде. Ул, койма ярыгыннан кечкенә, бераз сипкелле кулын сузып, Хәлимнең җиңеннән тарткан хәлдә, әлеге «елама, нәнәм»не әйтә иде. Бик җиңел, хәтта рәхәт булып китә иде Хәлимгә шул чак.

Хәзер дә аңар бу сүзләр шифалы дару кебек тәэсир итте, ничектер, җиңелрәк булып китте аңар. Бер үк вакытта Гөлгенәнең бу сүзләре Хәлимнең тулган күңелен ташытты. Нервлары берьюлы йомшарып китте аның. Тәненә моңа кадәр хис иткәне булмаган рәхәт җылылык таралды. Хәлим дулкынланып Гөлгенәнең аяк йөзенә ауды һәм үксеп елап җибәрде. Гөлгенә тиз генә чиләк-көянтәләрен җиргә куеп, Хәлим янына тезләнде дә йомшак кына итеп аның чәчләрен сыйпады. Елама, димәде Гөлгенә хәзер Хәлимгә, бары чәчен генә сыйпап торды. Хәлим аның саен үзен ниндидер рәхимле көч кулында кебек хис итте. Бу көч бик тиз үсте, зурайды. Хәзер ул Хәлимнең һәр ягында, алдында да, артында да, хәтта үзе баш төрткән чирәмдә дә бар кебек иде, бөтен дөнья шул көч белән тулган кебек иде. Хәлим канының һәрбер тамчысында да бар кебек иде.

Бу көч, әле генә кире кайткан диңгез дулкыныдай, хәлсезләнеп чирәмгә тезләнгән Хәлимгә рухи көч бирде. Хәлим дулкынланып сикереп торды. Тешләрен кысты Хәлим, кулларын йодрыклады. Авыртканчы, тырнаклары учларына батып кергәнче йодрыклады ул кулларын. Гәүдәсен солдатларча төз тотып, имән төбендәге зур ташка күз текәде дә таш астында әтисенең каберен хис итеп, кычкырып әйтте:

— Мин синең өчен үч алырмын, әтием! Үч алырмын мин синең өчен! Тыныч йокла, әтием!..

Болытсыз күккә тау артыннан кояш күтәрелде.

Кояш күтәрелүгә тауда бер олау күренде. Аның артыннан тагы берсе килеп чыкты. Өченчесе, дүртенчесе... Заготзерно конторасының тәрәзәсеннән карап торучы хезмәткәр тау битендә кырык сигез олау санады. Олаулар бер-бер артлы тезелеп, шомарган көзге юл буйлап, элеваторга таба төшеп килә иделәр.

Тәҗрибәле хезмәткәр, олауларның һәркайсындагы ашлыкның үлчәвен чамалап, кырык сигезгә тапкырлады. Тагы да бераз килгәч, олаучыларын күреп, иптәшләренә эндәште:

— Килегез әле тизрәк. Кайчан да булса, сезнең шундый тамаша күргәнегез бармы?

Олаулар өстенә кызыл галстуклы пионерлар утырган, бары берсендә генә олы кеше булып, монысы мәгълүмегез Шәйхаттар бабай иде.

Дугаларның кайсында кызыл байрак, кайсына ике таяклы озынча кызыл комач беркетелгән атларның маңгайларында да кызыл тасмалар. Нәни олаучылар, берсе калмый, көчле җыр яңгырата иделәр:

...Канга кан, үлемгә үлем!
Күтәрел, иптәш, зур көрәш бүген!

Җыр бетәр-бетмәс, заготзерно каршысына беренче олау килеп туктады. Аның дугасында җиңел генә флаг, ә арбасы буенча сузылган кызыл комачка шундый сүзләр язылган иде:

Бөтенесе фронт өчен!
Бөтенесе җиңү өчен!

Бу олауның олаучысы — Хәлим, аты — Шәехтай иде.

Шәехтай аеруча матур бизәлгән. Ялына да, маңгай чәченә дә ленталар үрелгән аның. Симез булмаса да, ялтырап торган зур, яхшы ук таза гәүдәсе өстендәге сбруйның җиз төймәләрендә кояш нурлары уйный.

Шәехтай артыннан икенче олау килеп туктады. Монысының кызыл комачына: «Бу тарыны без фронтовиклар өчен үстердек»,— дип язылган иде. Менә аның олаучысы — ак күлмәкле, кызыл галстуклы, кыска чалбарлы кечкенә генә пионер, «Скидкалы доктор» мәзәгендә үлгән кеше булып кыланган малай, олаулар барысы да

таудан төшеп беткәч, капчыклар өстенә басты да, быргысын як-якка йөртә-йөртә, сирена уйнап җибәрде. Сирена туктауга җыр яңгырады. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән бу тамашаны күрергә төрле район колхозларыннан ашлык китерә килгән колхозчылар җыйналды. Ыгы-зыгы килеп йөрүче станция эшчеләре дә туктап калды. Хәрби эшелон вагоннарыннан аякларын салындырып, тәмәке тартып, семянка ярып, гармоньга кушылып җырлап утырган солдатлар да килде йөгерешеп. Һәр минуты эш өчен планлаштырылган заготзерно управляющие да, эшен ташлап, олаулар янына чыкты.

Пионерлар, танклары алдына стройга тезелгән танкистлар шикелле, тиз генә олаулары алдына чыгып бастылар һәм комачларның берсенә язылган лозунгны бертавыштан яңгыратып җибәрделәр:

Һич онытма, иптәш, онытма,
Колхоз кырларында торып та:
Син, барыбер, бүген җир тетрәткән
Бомба, туплар яуган фронтта!

— Дөрес,— диде управляющий дулкынланып,— дөрес! Транспорт бригадиры кем?

Хәлим бераз каушап, бераз дулкынланып сафтан алга чыгып басты:

— Мин. Әллә сез управляющий абыймы?
— Әйе, әйе. Кайсы колхоз, иптәш?
— «Ватан».
— Тары дип әйтимме?
— Юк, тары ярмасы.
— Соң бит без...
— Беләм. Бу колхозныкы түгел, «Ватан» пионерларының фронтка бүләкләре.

Управляющийның кашлары дугаланып өскә күтәрелде.

— Бүләк?
— Әйе, бүләк,— диде Хәлим, ул управляющийга райком секретареның шушы турыда язган запискасын бирде һәм 1200 пот тары ярмасының озын, мәшәкатьле, шул ук вакытта данлыклы тарихын сөйли башлады.
— Кычкырып сөйлә, егет, без дә ишетик!
— Арбана бас!

Хәлим йөк өстенә менеп басты. Һәм, әйбәт белгән дәресеннән имтихан биргәндәге шикелле, кыю итеп сөй-

ләргә кереште. Барысы да тын калып тыңлый-тыңлый, Хәлимгә, пионерларга сокланып карап тордылар. Хәлим сүзен бетергәч, үзара сөйләшеп алдылар:

— Ай-яй!..

— Кара әле син аларны, ә!..

— Чиерттеләр болар безнең борынга!

— Әче чиерттеләр. Яшь чыгара торган итеп...

Артиллерист погонлы урта яшьләрдәге бер солдат кулындагы гармонен иптәшенә бирде дә берничә адым алга чыкты. Һәм дулкынланудан күз ярыларына тула башлаган яшьләрен тыеп, быргычы пионерны йөк өстеннән күтәреп алды:

— Я, ничек сугышмыйсың инде шушы гүзәл бала хакына! Ничек итеп шушы газиз баланы кабахәт фашист итегеннән таптатасың?

Артиллерист быргычы пионерның болай да кызыл, ә оялудан тагын да кызара төшкән битеннән үпте дә йөге өстенә бастырды:

— Тыныч бул, бала, без сине фашист итегеннән таптатмабыз.

Управляющий Хәлимнең кулын кысты:

— Бик рәхмәт, иптәшләр, — диде ул һәм тагын берничә мактау сүзе әйтте дә янында торган кешегә эндәште:

— Ярмаларын складка бушатыгыз... Эшчеләр бушатыр, ә үзләрен ашханәгә алып кереп, бик әйбәтләп сыйлагыз.

Хәлим, әз генә каушап, управляющийның җиңеннән тартты.

— Ә ул складтан безнең ярма фронтка китәрме икән соң?

— Анысын белеп булмый әле.

Хәлим:

— Юк, сез аны фронтка җибәрегез... Без бит аны солдат боткасына дип үстердек,— диде.

— Яшә, егет, дөрес эшләгәнсез!..

Солдатлар елмаешып үзара сөйләшеп алдылар. Управляющий, кашларын җыерып, әз генә уйлап торды да әйтеп куйды:

— Мөмкин. Телисез икән, фронтка да җибәрергә мөмкин.

— Ленинград фронтына дамы?

— Ә нигә Ленинград фронтына?

— Шулай уйлаган идек инде... Отряд карары.

— Һм-м... тукта, хәзер...— диде управляющий. Ул күзләре белән үзенә кирәк кешене (ГКО вәкилен) эзләп табып, аның белән шушы турыда киңәште һәм Хәлимгә әйтте:

— Анысы да мөмкин, Хәлим иптәш. Әй, Семен Семенович, өченче путьтагы запас вагоннарга төятегез, ... нче эшелонга тагарсыз. Адресы: Ленинград шәһәр башкарма комитеты, Ленинград фронты...

Бер солдат көнләшеп куйды:

— Эх, мать честная! Нигә безнең Белоруссия фронтына түгел соң ул?

Каюм, солдат ишетеп тынычлансын өчен, кычкырып әйтте:

— Кара, Хәлим, ике көннән «Илшат»лар китерә ич. Әйтербез, Белоруссиягә җибәрерләр. Аларның да бит мең потка якын була.

— Менә-менә... Нәкъ безнең казанлык икән.

— Юк шул, алар Украина фронтына диделәр. Хат та язып куйдылар инде алар.

— Ә ш-шайтан икән, тагы булмады,— диде әлеге солдат. Һәм шунда ук, тавышын үзгәртеп, өстәп әйтте:

— Әйдә, ярар, күршеләргә була бирсен. Без, ботка исе чыккан саен, зур кашыкларыбызны күтәреп бүген берсенә, иртәгә икенчесенә кунакка йөрербез, шулай ич, Гаврила...

— Анысы үзеннән-үзе билгеле.

Барысы да елмаештылар.

— Хәзергә кунакка йөри торыгыз, ә киләсе елга без тарыны ике өлеш күбрәк итеп үстерербез. Әгәр фашистларны шулай әйбәт кенә кыйнап торсагыз, барысын да сезгә җибәрербез.

— Бусына да күнәргә була,— диде Белоруссия солдаты,— ләкин ике өлеш бик күп була бит ул. Ашап бетерә алмабыз. Сугыш бетеп калыр.

— Бик әйбәт. Калганын сугыштан соң, Берлин урамында учак ягып пешереп ашарсыз, солдат абый.

— Алай, алай!..

— Ха-ха-ха!..

— Бусына да күнәргә була,— диде Гаврила дигәннәре һәм, пионерлар белән озак итеп гәпләшергә уйлап, бер аягын арба тәгәрмәченә куйды да янчыгын чыгарып, иплэп кенә тәмәке төрә башлады.

Хәлим, моны күреп, управляющийга эндәште:

— Без ашыгабыз, управляющий абый. Сугудагы, колхоз ашлыгын ташудагы атлар болар. Тиз кайтып житәргә куштылар.

— Бик әйбәт. Әйдәгез.

Олауларны товар вагоннары турысына китереп туктаттылар. Заготзерно эшчеләре үлчәүләр алып килгән арада, элеваторда эшләүче хатын-кызлар вагоннарның идәннәрен, стеналарын себереп, юып чыктылар. Пионерлар ярманың үлчәнгән берен вагоннарга бушата бардылар. Госпитальдә ята-ята эшсезлектән туеп беткән, колхоз эшен тансыклаган кызылармеецлар, пионерларның «кирәкми, үзебез төйибез» диюләренә карамастан, эшкә тотындылар. Вагоннарның төрле почмакларына гәрәбәдәй сары ярма таучыклары өелә башлады. Таучыклар бик тиз үсә барып, бер-берсе белән кушылдылар һәм бик тиз зур бер тау булып үстеләр.

Ярма төялеп бетүгә, пионерлар, шау-гөр килеп, Ленинград фронты солдатларына хат яздылар. Алар һәрберсе, вагоннарга ярманы үз кулы белән күбрәк төяп калырга тырышкан кебек, хатка да күбрәк үз сүзләрен кертеп җибәрергә омтылдылар:

— Исәнмесез, Ленинград арсланнары! — дип куй хатның башына...

— Инде Хәлим белән Шәехтайны әйт.

— Шәйхаттар бабайны да...

— Кирәкми, кирәкми, мине кирәкми!

— Яз, яз... Син тик тор, бабай...

— Инде ничек эшләгәнне әйт...

— «Илшат»лар белән ярышканны да.

Гөлгенә боларның барысын да язды. Һәм шулай дип тәмамлады:

«...Сугышны тизрәк бетерегез инде, абыйлар, фашистларны катырак кыйнагыз. Фашист кыйнау сездән, ботка бездән. Туйганчы ашагыз, кыстатып утырмагыз. Бетсә тагын җибәрербез!.. Исәнлектә күрешик, әтиләр, абыйлар».

Кырык җиде имза һәм бер тамга бизәде бу хатны. Пионерлар имзаларының хәрефләрен уйнаткалап, шул ук вакытта таныклык итеп куярга тырышалар. Куллар куелып беткәч, пионерлар хатны ярма тавы өстенә менгереп, ишек ачуга күренерлек итеп, озын чыбыкка кадап

куйдылар. Үзенең матур язуы белән танылган Шәпи ярма төялгән вагоннарның капка чаклы ишекләренә сокланырлык матур итеп язып куйды:

«Ленинград шәһәр башкарма комитетына. Ленинград фронты гаскәрләренә тапшыру өчен. Татарстан республикасы, «Ватан» колхозы пионерларыннан».

Үз балалары да хәзер фронт өчен, җиңү өчен шушы пионерлар шикелле нәрсә дә булса эшләп йөрүләрен күз алдына китергән солдатларга бу күренеш күңелле генә түгел, тиңсез шатлык та иде. Алар, инде өлгергән, парлары чыгып торган иртәнге ашлары турында онытып, балаларның эшләгәннәрен, әкрен сөйләшеп, бераз елмаеп карап тордылар. Ә түбәндәге манзараны күргәч, иң тыйнаклары да көлмичә түзә алмады. Пионерлар тимер юл эшчесенең вагон ишекләрен җеп шикелле генә тимер чыбык белән пломбалап китеп барганын күргәч, бер-берсе белән пышылдашып алдылар:

— Ә төнлә, берәр станциядә туктап торганда, караклар урлап китсә?

— Әйе шул...

— Бу тимер чыбыкны безнең Фәтхелли дә өзә бит.

— Әйе шул.

— Курыкмагыз, оланнар, берни булмый.

— Юк, була...

Заготзерно хезмәткәре алып килеп биргән берсеннән-берсе зур йозаклар белән вагон ишекләрен бикләп алып ачкычларын главныйга биргәч кенә тынычландылар пионерлар.

Бу бөтенесе өчен көлке күренде. Бу хәлгә главный да көлде һәм шунда ук җитди төскә керде. Ул, ачкычларны бумажнигына салып, эчке кесәсенә тыгып куйды. Кул астына туры килгән берничә пионерның башларыннан сыйпап әйтте:

— Тыныч булыгыз, балалар. Бер бөртеге дә, бер бөртеге дә югалмас,— диде ул һәм, калын көмеш чылбырлы зур сәгатенә карап алды да, свисток бирде.

Шуны гына көтеп торган мәһабәт корыч айгырның көчле тавышы яңгырады.

Хәлим вагонга менеп барган главныйның итәгеннән тартты:

— Зинһар, главный абый, чыгып-чыгып караштырырга онытмагыз инде. Ярма бик кирәк була да бит ул фронтта. Әрәм-шәрәм булмасын...

Бу вакытта главный үзен бер үсмер алдында түгел, зур начальнигы каршында кебек хис итә иде.

— Әлбәттә, онытмам,— диде ул,— хуш, улым, хушыгыз, гүзәл балалар!

— Хушыгыз, абый! Барып җиткәч, солдат абыйларга сәлам әйтегез!

— Ярый! Әйтербез!

Паровоз тагы әкрен генә кычкыртып куйды да кузгалды һәм буферын шалтыратып, беренче вагонны тартып алды, икенчесен урыныннан кузгатты паровоз. Өченче платформаны (озын, юан кара чыршы кәүсәсе кадәр көпшәле, кеше кереп ятарлык киң авызлы пушка урнашкан платформаны) тартып алды. Аның янындагы тау чаклы танк урнашкан платформаны кузгатты. Зур самолетны көчкә сыйдыра алган ике платформаның тәгәрмәчләре берьюлы тәгәри башладылар. Алар артыннан ярма да — җиңү өчен, шул пушкалар, танк, самолетлар шикелле үк кирәк булган ярма да — кузгалды. Ярмалы вагонның кузгалып китүе пионерлар өчен башта әллә ничек ямансу тоелды. Ә бераздан пионерлар әйтеп бетергесез шат иделәр инде. Алар, шау-гәр килеп, ярма төялгән вагоннар артыннан йөгерделәр. Эшелон тулы ход алгач, туктап кул изәргә керештеләр.

Поезд борыла-сырыла барды-барды да урман эченә кереп күздән югалды. Хәзер инде яшел урман өстендә аның куе ак төтене генә күренә иде. Төтен дә бара-тора ерагайды, кечерәйде, сыегайды һәм бөтенләй югалды. Ә пионерлар, безнең гүзәл балалар, күзләрен урман өстеннән алмыйча, әле һаман кызыл галстукларын, ак яулыкларын изиләр һәм әкрен генә, бик әкрен генә бер җыр көйлиләр иде:

Без эштә дә, укуда да
Алдынгы яшьләр —
Алдынгы яшьләр.

Фашизмны юк итәргә
Булышыйк, иптәшләр,
Булышыйк, иптәшләр!

Укыйк отличнога гына,
Булышыйк колхозга —
Булышыйк колхозга.

Партиянең өндәмәсе
Шул, иптәш, безгә —
Шул, иптәш, безгә.

15 СОҢГЫ СҮЗ

Кадерле укучыларым! Бәхетле совет балалары! Гүзәл балалар! Сезнең гомер таңыгызда мәңге-мәңге истә калачак чиксез шатлыклы ике вакыйга булып үтте: беренче көнне мәктәпкә бару, аннары пионерга керү. Беренче тапкыр мәктәпкә барасы көнегездә газиз әнкәгезнең иркәләп уятуына күзегезне ачып җибәрүегезне исегезгә төшерегез әле! Әнкәгезнең яңа, яңа булмаса тырышып юылган, пөхтә үтүкләнгән киемнәрегезне тотып: «Тор, үскәнем, мәктәпкә барасың ич бүген...» — дип, ягымлы елмаеп каршыгызда басып торганын исегезгә төшерегез әле! Тагын мәктәптә күргән беренче хисләрегезне әнкәгезгә кайтып очына-очына сөйләгәнегезне, әнием, «әни» менә болай языла дип, бу сүзне үзегезгә бик матур, әниегезгә чиксез матур булып күренгән кыекмыек хәрефләр белән дәфтәр битенә язып күрсәткәнегезне исегезгә төшерегез! Инде пионер вожатыеның муеныгызга үзегез шикелле пакь, керсез, матур, нәфис кызыл галстук таккан чакта, никадәр сиздермәскә тырышсагыз да, шатлыктан күзләрегез, иреннәрегез көлемсерәгәнен, тәнегез буенча бик җылы, бик рәхәт дулкын үтеп киткәнен хәтерләгез!.. «Мин, Советлар Союзы пионеры, иптәшләрем алдында ант итәм...» Юк, кирәкми, калсын... Ул минутлар әле сезнең хәтерегездә болай да бүгенгедәй саклана. Аннары мин бу турыда сез хис иткәнчә матур итеп сөйләп бирә дә алмам. Миңа ул шатлыклы көннәр рәхәтен татырга, күреп белергә туры килмәде бит...

Кадерле укучыларым! Бәхетле совет балалары! Гүзәл балалар! Сезне өченче бер шатлыклы көн көтә — комсомолга керү. Монысының шатлыгын кайчандыр мин дә татыган идем. Чирек гасыр инде аңар. Һәм бу көн турында сөйләп бирү минем өчен алай читен булмаячак.

Җирдә тиңсез кайгы — бөек Ленин үлгән көннәр иде. Бу югалтуны өлешчә булса да тутыру өчен алдынгы эшчеләр, крестьяннар партиягә агылды. Ә без, яшүсмерләр... Хәер, хикәя безнең буын турында түгел бит әле... Минем турыда түгел, сезнең турыда, Хәлим турында.

Хәлим комсомол бюросында бүген үзен яшь ленинчылар сафына алу мәсьәләсе каралачагын кичә кичкырын гына ишетте. Ярый әле бу вакытта дәресләрен хәзерләп бетергән иде, югыйсә, башына һичнәрсә кермәс иде —

шулкадәр дулкынланды Хәлим. Дөрес, ул гариза язганда да дулкынланган иде. Ләкин ул чакта болай ук булмаган иде. Чөнки гариза язганда комсомолга керү реаль нәрсә булып күз алдына килмәгән иде әле аның. Ә хәзер ул аны реаль нәрсә итеп хис итте. Үзен нинди дер яңа дөнья алдында торгандай хис итте. Ишекне ачып керәсең дә, бөтенләй, бөтенләй яңа дөнья башлана!.. Комсомол! Бигрәк бөек исем бит бу! Ленин комсомолы! Ленинчы яшьләр отряды! — Павел Корчагин, Зоя Космодемьянская, Александр Матросов, Олег Кошевойлар отряды. Әнә нинди саф канлы яшьләр, нинди баһадир йөрәклләрдән тора бит ул комсомол! Әнә нинди сынаулар үткәннәр алар! Ә алар үткән сынауны үтәргә туры килсә, Хәлим нишләр? Аргамакка атланып, кылычын кыныннан тартып алып, ак банда өстенә ташланганда йөрәге йомарланып килмәсме? Дошман амбразурасын күкрәге белән капларга йөгергәндә тез буыннары калтырамасмы? Муенына палач элмәк элгәндә, күзенә яшь килмәсме? Ярлыкагыз, дип тезләнмәсме ул дошман алдына — шунлык көч бармы аңарда?

Хәлим бу сорауга байтак уйлаганнан соң гына җавап бирә алды: «Әйе, бар, бар миндә андый көч!»

Ул беләкләрен баш астына куйды да күзләрен йоммыйча ярты төнгә кадәр уйланып ятты. Йокысы килсә дә, йокламады ул. Шатлыгы зур булганга гына да түгел, ишекнең теге ягындагы дөньяның җаваплылыгы турында уйлаганга гына да түгел. Юк. Хәзер аның йөрәген сизәргә, күз алдына китерергә мөмкин булмаган сагыш шикеллерәк бернәрсә тырнады. Хәлим пионер галстугын салып, күкрәгенә ВЛКСМ значогы тагуны чиксез шатлыклы, бик бәхетле гамьсез бала чактан аерылу дип хис итте. Озынлы-кыскалы телләрен гөлҗимеш куаклары арасыннан сузып дөрләп янган костерлар, кызыл галстуклы, чиксез шат йөзле нәни пионерлар, көмеш авазлы быргылар, барабаннар — барысы да әкияттәге оча торган паласка төялеп, әкрен генә артка чигенгән төсле булды. Хәлим хәзер үзен биленә кызыл пута буган, мыек чыгып килгән, кыңгыр бүреге астыннан озын тузма чәче чыгып торган, кулына дилбегә тотып чана үрәчәсенә баскан колхоз егете итеп күз алдына китерде. Аннары өстенә комбинезон кигән, комбайн штурвалына баскан комбайнер итеп күз алдына китерде... Ул да түгел, калын дәфтәрләр, калын китаплар

тотып, Казан авыл хуҗалыгы институтының зур киң пыяла ишекләреннән килеп чыкты...

Йокыга киткәч тә, Хәлим шулар белән саташып ятты.

Ә уянганда, көн яктырган иде инде.

Ул йокламаса да бик зәңгәр, бик саф, бик нәфис күк йөзе фонындагы тал-тирәкләрнең алтын яфракларына, өй түрендәге миләшнең язын янә яфракланачак яшь бөреләренә карап, хыялга чумып, тагын бераз ятып торудан да баш тартмас иде, ләкин өстәл өстендә ниндидер бер хат күреп, әсәрләнде һәм ялт сикереп торды.

Хат Женядан иде.

Хәлим Женяның «Ленин сказал: учиться, учиться, учиться!» дигән сүзләре шикелле үк матур итеп язылган адреска күз йөртеп чыкты да хаты ертылмасын өчен сакланып кына конверт читен кайчы белән кисеп алды. Һәм кайсын укырга да белмәде: конвертта, Женя хатыннан башка, моннан бер ай элек Женяның үзенә җибәрелгән хат та бар иде. Бу хат, укытучыларча итеп кызыл кара белән төзәтелеп чыгылган һәм астына «см. Женя» дип куелган иде.

Хәлим имза астында Женяның көлеп торган курнос борынын, килешле елмайган зур авызын күргән төсле булды һәм, әйтерсең, Женя хатны әле генә үзе биреп чыгып китте,— Хәлим ишеккә карап сөйләнеп куйды:

— Ну, Женя! Ну, урыс малае! — диде ул һәм зур бер мавыгу белән дустының хатын укый башлады. Хат озын иде. Мин аның бары сезне кызыксындырырлык урыннарын гына күчереп үтәм.

«...Хатыңны күз йөртеп чыгу өчен үзеңә җибәрәм. Абзаң исән чакта өйрәнеп кал... эһем-эһем... Аннары киредән үземә җибәрерсең, яме? Ләкин үпкәли күрмә, Халимушка. Мин бит үз итеп...»

Хәлим, иптәшенең чын күңеленнән әйткән сүзләренә куанып, алдагы юлларга күчте һәм аларның кызыклыгы беренчеләрен томалап китте.

«...Мин синең турыда пьеса яздым. Синең шпионны тотуың турында... Бомбежка вакытында качып яткан идекме — шул подвалда куйдык. Мин — син булып уйнадым. Сина ошамадым ошавын, үзең беләсең: буй кечкенә, шулай да килештердем. «Кухня»ның чын пыяла тәрәзәсен сөзеп «ишек алдына» сикергәндә маңгай тырналып канады, борын кузна хәтле булып шешеп чыкты, күздән утлар күренде, малай. Ишек алды пәрдәсен дә

шул килеш, мангай канаган килеш, уйнап чыктым. Укытучы бәйлик дигән иде дә, мин бәйләтмәдем. Болай әйбәтрәк: нәкъ тормыштагыча чыкты... Бик яраттылар. Октябрь бәйрәмендә госпитальгә дә барып куябыз әле. Кышкы каникулда үзенә дә күчереп җибәрермен, яме? Хәзер бер дә вакыт юк. Эш, эш... Дәрестән соң шәһәрне төзекләндерергә йөрибез... Без бит быел мәктәп өчен бәрәңге утырттык, тары чәчтек. Тарыны урдык та инде. Ләкин аның белән конфузга калдык... сиңа, авыл кешесенә, бигрәк тә көлке тоелыр инде ул, биредә булып биредә бөтен шәһәр көлде. Завхоз яңа безнең хәзер. Гомерендә авыл күрмәгән кеше... Бу, көннәрдән бер көн бер авылга бара да, бөтен тарыны ярдырып кайта, ә иртәгесен моны шәһәр советына җыелышка чакыралар. Бу чыга да кеше рәтендә сөйли: без фәлән кадәр бәрәңге үстерәбез, фәлән кадәр тары. Тары бик уңды, киләсе елга да чәчәбез, чәчүгә дигән тарыны ярдырып, амбарга салып та куйдык инде...— ди.

Халык гөжли башлый. Янында утырган берәү моның итәген тарта. Ашарга дигәнен диген, ди. Ә бу, бер барган юлы чәчүгә дигәнен дә ярдырып кайттым инде мин, дип әйтеп сала. Завхозыбыз берничә көн урамга чыгарга оялып атты. Шәһәребездән китәм дип сөйләнеп йөргән иде дә, күнекте инде. Каяндыр авыл хуҗалыгы турында бик калын бер китап алып кайткан, хәзер шуның белән мәш килә. Шуның белән ята, шуның белән тора. Кызык... Безнең дә күзне ачырмыйлар, малай. Имеш: «Я, нихәл, чәчүгә дигән бәрәңгегезнең кабыгын әрчеп куймадыгызмы әле?» — Теләсәң ела, теләсәң көл...»

Хәлим өчен хатның һәр сүзе кызык булды. Ул аны кат-кат укыды, соңра кулына үзенең кызыл кара белән төзәтә-төзәтә чуарланып беткән хатын алды, аның һәрбер хатасын өйрәнде.

«Пруса» түгел — «просо» кирәк икән... «Мягкий» дигәндә мягкий знак кирәкми икән. Уһу-у... бер сүздә биш хата: «пятнатст». Дөресе — «пятнадцать» икән... Рәхмәт, рәхмәт, Женя... Ой, нинди әйбәт син, Женя! — диде Хәлим, аның имзасына карап.— Бик әйбәт бит син. Яратам мин сине, бик яратам, Женя җаным...

Хәлим дулкынланып дәфтәреннән бер бит ертып алды. Каләмен карага манды. Шунда ук кире куйды.

— Кайткач, комсомолга кереп кайткач язам мин сиңа, Женя,— диде ул һәм юынды да, гимнастеркасын

киеп, каеш булмыйча гына йортка чыкты. Ул хатны Гөлгенәгә яки Каюмга кереп укырга теләде. Аларга нинди шатлык алдында торганын әйтергә теләде һәм, Гөлгенәләр белән ике арадагы койма ярыгыннан карады. Гөлгенә ишек алларында бик бирелеп кер уа, әнисе прачка тирәсендә кайнаша иде. Хәлим Гөлгенәне эшеннән бүләргә уңайсызланды, Каюмнарга керергә булды. Ләкин аның пожарный Сабир белән урманга карамага киткәнен хәтерләп, ачкан капканы кире япты. Кулына көрәк алып сыер абзарының тиресен бәрәңге бакчасына чыгарып өйде. Аннары балта тотып, каралтылар тирәсендә хуҗаларча кайгыртып йөрде. Кайсын какты, кайсын турайтты. Зуррак көч сорый торганнары яныннан карап кына узып китте.

Түбәнең калаен буятырга вакыт икән, су трубасын алмаштырганда да яхшы булыр иде, череп беткән. Капканы да яздан калдырмый төзәтергә кирәк... Менә тиздән сугыш бетәр, Хафиз абый кайтыр... Әти урынына ул калды инде хәзер. Ул кайтканчы хуҗалыкны тәртипкә китерергә кирәк... Оһо-о, базның стенасы бөтенләй череп беткән икән ич...

Хәлим, үзенчә, йорт-җирне төзекләндерүнең сметасын төзеде. Ничә бүрәнә, кирпеч, такта, күпме кадак кирәк булачагын чамалады... Аннары кереп аш ашады да кулына балтасын тотып, тагын йортка чыкты. Хәтирә әби күргән саен сүз кузгата иде, кереп аның мал тагарагын ямап бирде.

Ләкин нәрсә генә эшләсә дә, Хәлимнең дулкынлануы басылмаган иде.

Бүген Мүкләк Зарифларның йорт-җирләренә, малтуарларына, җиһазларына торги буласы. Хәлим шунда барып карап торды.

Башта йортын саттылар. Юан-юан бүрәнәдән гомерлек итеп салынган нарат йортны каралтылары белән колхоз сатып алды һәм шушы көннәрдә генә Ватан сугышыннан кулын өздереп кайткан Сталинград героена, кайчандыр бу йортны үзе бураган балта остасына бүләк итте.

— Игелеген күр, Нәбиулла туган,— диде колхоз председателе,— правление карары шундый. Әлбәттә, бу синең кулың бәясе тормый. Алтын иде бит синең кулың, Нәбиулла. Исән булса, мондый йортларны берничә дистәне салган булыр иде әле синең ул кулың...

Аннары мал-туарларын, җиһазларын саттылар. Шәмсия җиңги дә кызыл агачтан бик нәфис итеп эшләнгән өстәлләренә кызыккан иде дә, Хәлим кулын гына селекте.

Комсомолга керү һәм Мүкләк өстәле... Бу — намусны мыскыл итә торган эш булыр иде...

Хәлим үзенә бик күп нәрсә, бик зур үзгәрешләр вәгъдә иткән яңа дөнья бусагасыннан атлаганда, намусында гына түгел, тәнендә дә кер калдырасы килмәде. Ул кайтып коедан мунчага су ташыды. (Шыпырт кына эшләде ул моны, чөнки әнисе күреп калса, Гөлгенәне кертеп җиткерәчәк, Гөлгенә чиләкләрне тартып алып, суны үзе ташый башлаячак...) Юынып чыккач, Хәлим чиста күлмәк киде, хәрби киемнәрен киеп, Ленин рәсеме каршына басып, болай диде:

— Мин Корчагиннар, Зоялар, Олеглар, Матросовлардан торган комсомол исеменә тап төшермәм. Комсомолның лаеклы члены булу өчен, кирәк икән, тормышымны да кызганмам...

Хәлим бу сүзләрне колхоз комсомол бюросы членнары алдында да кабатлады.

Утырышта бюро членнары гына түгел, колхоз яшьләре алдында торган бурычларны билгеләү өчен җыйналган берничә коммунист һәм колхоз җитәкчеләре, мәктәп директоры да бар иде. Алар Хәлимгә күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

Менә Шаһгәрәй абзый күзлеген маңгаена күтәрде, мәктәптәгечә, кулларын артына куеп, бер адым алга атлады:

— Тап төшермәм... лаеклы булырмын... Күркәм сүзләр. Ләкин моның өчен, беләсеңме, Хәлим, ленинизм белән *коралланырга* кирәк. Белергә димим, *коралланырга.* Аны йөрәгеңә, каныңа сеңдерергә кирәк. Югыйсә, шундый кешеләр дә очрый бездә: ленинизмның һәрбер хәрефен белә, йокыдан уятып сора син аңардан — әйтә; фәлән том, фәлән бит,— шунысына кадәр әйтә. Ә шуны тормышка ашырырга килгәндә... (укытучы, йөзен чытып, бер тын туктап торды)... Хикмәт тә шунда, дустым.

Гражданнар сугышында бөтен тәне аклар кылычы белән телгәләнеп беткән, үзе әйтмешли, «алла кодрәте белән генә» исән калган карт солдат, Хәлим әтисенең балачак дусты, авыл советы председателе Әхмәтша

абзый сүз алды. Хәлимнең, сугыш беткәч, тыныч тормыш башлангач, Казанга укырга китәм диюенә каршы шушы сүзләрне әйтте:

— ...Укырга да барырсың — уку яхшы нәрсә. Ләкин, егеткәем, укыйсыңмы син, эшлисеңме — бернәрсәне онытма: сугыш бетүне, тыныч тормышны дөрес аңла. Сугыш бетү — Советлар иле дошманнан арынды дигән сүз түгел әле ул. Сугыш бетәр, Гитлер бетәр, анысы факт. Ләкин, шәйлә, Гитлердан да болайрагы килеп чыкмасын... Әйе, әйе, бер дә гаҗәпләнмә... 1919 елда без дә шулай уйлаган идек: Колчагын турап, Врангелен диңгезгә батырып ташлагач, Махносын бәреп еккач, инде мылтык ауга йөрергә генә кирәк булыр, кылычтан чалгы ясарбыз дигән идек. Ә күрдең, нинди хәлләр килеп чыкты...

Хәлим сискәнеп китте. Үзенең төп мәсьәлә буенча ясаячак чыгышының тезисларын актаргалап утырган карт коммунист — башлангыч партия оешмасы секретаре аның тәэсирләнгәнен сизеп, сүз алмыйча гына, авыл советы председателенә өстәп әйтте:

— Черчилльнең иптәш Сталин янына утырып, авызын ерып карточкага төшкәненә карама, энем. Алар безнең тирәдә безне яратканга сырпаланмыйлар. Кичәге һәм иртәгәге дошманнар алар безнең. Ничарадан-бичара кайнаша алар безнең тирәдә. Пример, менә мондый хәл була: зур юл буйлап барганда котырган этләр камап ала сине, өрәләр, тешләрен ыржайталар. Сизгерлегеңне өз генә җуйдыңмы, хәзер өстеңә ташланачаклар. Менә бер заман урманнан бүреләр килеп чыга. Моны күреп этләр өрүдән туктыйлар, хәзер этләр сиңа сыеналар, тынычлыгыңны бозган өчен гафу үтенеп чинарга, койрыкларын бутарга тотыналар... Зинһар, коткара күр, янәсе... Син, кеше, бүреләрне кырып саласың. Шуннан ни була? Котырган этләр сиңа рәхмәт әйтеп үз юлларына китеп барамы? Юк, әлбәттә. Алар хәзер сиңа тагы да катырак өрә башлыйлар. Инде хәзер, рус әйтмешли, гляди в оба. Югыйсә, алар сиңа ташланмый калмыйлар, чөнки хәзер аларга һичкем комачауламый. Бүре дигәнең юк ич инде хәзер...

Хәлимне яңа хисләр күмеп китте. Хисләр, күзгә күренми торган авыр әйбер булып, Хәлимнең башын түбән иделәр.

Әнә ничек икән әле!.. Ә моның бик тиз булуы да

мөмкин бит. Кырык беренче елгы шикелле, сизми дә калуың мөмкин...

Хәлимнең башы төрле уйлар белән тулды. Ул Мәрфуганың:

— Сүз райкомол секретаре иптәш Идрисовага бирелә,— дигәнен ишетте. Һәм башын ялт күтәреп карады. Аның алдында кайчандыр Хәлимнәрне райком секретаре янына кертмәскә маташкан, теге алтын тешле хатынга су салып биргән, кечкенә алтын сәгатьле, зәңгәр беретлы яшь кыз басып тора иде.

Ул, уйлама, мин бит сине таныйм дигән шикелле, Хәлимгә карап елмаеп торды да берет читеннән чыгып торган сары калын чәчен төзәткәләп куйды. Кинәт җитди төскә керде ул һәм, телефон буенча колхозлардан мәгълүмат җыйгандагы шикелле итеп, каушамыйча, ашыкмыйча сөйләп китте.

Ул — комсомолның алдында торган бурычлар турында бер-ике сүз әйтте, сүз арасында 1941 елның көзен искә төшереп, Хәлимне бераз оялтып алды. Сүзенең ахырында болай диде:

— Мин, бирегә килер алдыннан, райком секретаре белән сөйләшеп утырдым. Ул миңа Хәлимне үз исеменнән яклап сөйләргә кушты. Хәлим һәм Хәлимнәрнең эшләренә югары бәя бирде ул. Чыннан да, иптәшләр, «Ватан»ның быелгы уңышлары турында сөйләгәндә, Хәлимнәрнең тырышлыклары турында да әйтмичә китеп булмый,— диде Идрисова, аннан Шаһгәрәй абыйга таба борылды: — «Ватан»да сокланырлык алмашчылар үстергәнсез, Шаһгәрәй абзый... Моның өчен без беренче чиратта сезгә бурычлы, сезгә, Шаһгәрәй абзый...

Укытучы, «бигрәк инде сез» дигән шикелле, ак башын әз генә селкетеп куйды. Идрисова дәвам итте:

— Чыгып сөйләүләргә карагаңда, Хәлимне комсомолга алуга каршы кеше булмас дип беләм... (Комсомолецлар арасында җанлы хәрәкәт булып алды.) Шулай ук гомуми җыелышта да каршы чыгучы булмас дип уйлыйм. (Бюро члениары тагы да җанлырак шаулашып алдылар.) Шуңа күрә, Хәлим, мин сине комсомол райкомы исеменнән Ленин яшьләре сафына басуың белән тәбрик итәм.

Комсомолецлар дәррәү кул чабып куйдылар. Шаһгәрәй абзый күзлеген ипләп кенә салды да ахыр чиктә киеренкеләнгән Хәлим алдына килеп иңнәреннән тотты:

— Без малай чакта синең бабаңның бабасы турында сөйлиләр иде. Ул, налог өчен актык кәҗәсен алып чыгып киткәндә дә, урядникка сүз әйтә алмаган. Ә бабаңның этисе алпавыт имениесенә ут салучы ирләрнең берсе булган. Ә бабаң, анысын инде без үзебез дә күрдек, илдән алпавытларны куды, партизан булып йөрде, кайтып Совет власте төзеде. Ә этиеңә килсәк, ул авыл хуҗалыгын бөлгенлеккә илтә торган юлдан дөрес юлга кертте. Колхоз оештыруда җиң сызганып эшләүчеләрнең берсе булды этиең. Һәм Иделгә килеп җиткән Гитлерны илдән куып чыгарды. Сине, Хәлим, кем белә, бәлки тагы да зуррак сынаулар көтә торгандыр. Шул сынауларга хәзер бул, Хәлим.

— Мин һәрвакыт...

— Сабыр ит... хәзер түгел әле син аңар. Аңар сине менә Мәрфуга апаңнар, комсомол хәзерләячәк — Ленин комсомолы. Тәбрик итәм, дустым.

Укытучының зәңгәр тамырлары беленеп торган хәлсез кулы Хәлимнең яшь, зур, алсу кулларында югалып калды. Аның иреннәре укытучының җыерчыклы маңгаена ябышты һәм ул, чыгарга мөмкин, дигәнне ишетеп, канатлы кош шикелле җиңел атылып клубтан чыкты. Чыгуына үзен көтеп торган Гөлгенә белән Каюмга килеп бәрелде.

— Булдымы, егет?

— Тәбрик итәм, Хәлим!

Бу вакытта Хәлим шулкадәр бәхетле, шулкадәр шат иде, бер үк вакытта шулкадәр дулкынланган иде, иптәшләренә ни дип тә әйтә алмады. Чыккан уңайга кулларын аларның иңнәренә салган хәлдә авылның киң ак таш юлы буйлап атлады.

Кич җитеп беткән иде инде. Кызыл, бик зур кояш офыкка төшеп җиткән һәм ул гүя Хәлимнең чыкканын гына көтеп тора иде — Хәлим күренүгә, гүя аны астан көчле куллар тартып алды, тиз генә таулар, урманнар артына кереп батты.

Бата бирсен! Иртәгә тагын да матуррак, тагы да яшьрәк, тагы да нурлырак булып чыгу өчен батты бит ул.

МАРАТНЫҢ ЯЗМЫШЫ



Беренче кисәк

1 ИЛӘМСЕЗ КАРА ТӨН ИДЕ

Гөлсем апа, гомеренә сугыш кырында булмаган, туп, мылтык тавышлары ишетмәгән Гөлсем апа, һич уйламаганда көчле шартлаулар астында калды. Өстә, куркыныч улап, самолетлар оча, алардан шәһәр өстенә бомба ява, аста биш-алты җирдә зениткалар ата — һавага көлтә-көлтә ут бөркелә иде. Урам бик еракта яшен яшьнәгәндәге кебек кенә яктырып китә дә шунда ук дөм-караңгылык эчендә кала иде. Бомбалар шулкадәр якын төшеп шартлый, Гөлсем апа килеп сыенган биек таш пулат стенасы гына түгел, тирә-як, бөтен өйләр дер селкенеп тора, анда-санда исән калган тәрәзә пыялалары чылтырап тротуарга коела иде.

Гөлсем апа, бераз вакыт онытылып, нишләргә белми торды. Аннары, юлга чыгу алдыннан үтелгән ПВХО занятиеләрендә өйрәтелгәнчә, тиз генә стена буена авып, колакларын томалады.

Ләкин саклануның кирәге калмаган иде инде. Самолетлар баш очында бераз әйләнгәләп йөрделәр дә, кара эшләрен тәмамлап, кара өермә кебек үтеп тә киттеләр.

Шартлау тавышлары ерагайды. Гөлсем апа каушавы белән кулыннан төшереп җибәргән кечкенә чемоданын капшана-капшана эзләп тапты да торып өстен кагынды.

Аңар әнә шул чатка борылырга диделәр бугай... Әйе, әйе, шул чатка... Гөлсем апа юл аша чыкты да,

күрәлмәгән тротуар буйлап, ашыга-йөгерә китеп барды һәм өч-дүрт өй буен үткә, кинәт туктап калды. Уңып беткән афишаларын җил өзгәләгән витрина төбендә, яңа яуган карда, яшь кенә бер хатын хәрәкәтсез ята иде. Читкә ташланган бер кулында икмәк кыерчыгы. Күрәсең, үзе өчен бик кадерледер — кысып тоткан; икенчесендә буш котелок булып, ашы түгелгән, кәбестә-кишерләре карга сеңгән иде. Янында бик кечкенә, күп дигәндә яңа дүрт тулып килгән сабый бала. Ул үзенчә нидер сөйләнә-сөйләнә бәләкәй, ябык куллары белән әнисен торгызмакчы булып маташа. Сабый, сабый!.. Ул әле әнисенә ни булганны белми. Гүя, әнисе түгел, уенчык аты гына егылган, әнисенең чигәсенә бәреп чыккан җылы кан да кан түгел аның өчен, ул аны атының су эчерткәндә юешләнгән танавын сөрткән кебек кенә сөртеп ала иде.

Гөлсем апа, бу бичара хатынның әле генә шәһәр өстенә үлем яудырып киткән самолетлар корбаны икәнен аңлап, тиз генә аның өстенә иелде:

— Гражданка!.. Гражданка!..

Хатын җавап бирмәгәч, куркытмас өчен җайлап кына баласына эндәште:

— Кайда торасыз, акыллым?

Бала курыкмады гына түгел, бер дә тартынмыйча, бу ят апага бераз сакаурак тел белән, р урынына л әйтеп, әллә нәрсәләр бытылдарга кереште. Кабат кайда торасыз дигәч, күзләре белән эзләп-эзләп торды да бер өйгә төртеп күрсәтте:

— Ә-әнә.

— Әтиең өйдәме?

Бала, монысына да туры җавап бирмичә, сугыш дип, Гитлер дип, үзенчә тагын әллә нәрсәләр бытылдарга кереште. Гөлсем апа, аның сүзе беткәнне көтмәстән, тиз генә барып, беренче парадный ишекнең әле бер, әле икенче ягындагы тәрәзәне дөбердәтте. Эчтән җавап булмагач, тирә-якка карана-карана кычкырырга, ярдәмгә кешеләр чакырырга тотынды. Ләкин караңгы, буш урамда монысын да ишетүче булмады...

Менә еракта гөрселдәгән зенитка утларының тонык-саргылт шәүләсе урамның аргы башын, җилдә сызылган шырпы кабынып сүнгәндәге кебек кенә итеп, берничә тапкыр яктыртып алды һәм шул шәүләләрнең берсе астына зур бер грузовик килеп керде. Гөлсем апа гру-

зовикка каршы йөгерде һәм фараларын сүндергән хәлдә шомлы ажгырып килгән машинаның каршысына килеп басты да кулларын киң җәеп кычкырырга тотынды.

Мондый чакта машина туктый. Ләкин бу бик ашыга иде, күрәсең, туктамады; әз генә әкренәя төшеп, Гөлсем апаны читләтеп үтә башлады. Гөлсем апа исә, кулларын җәйгән килеш,атылып килеп, аңар каршы төште. Машина бу юлы да туктамады, ләкин бик әкренәйде. Шофер тимер каскалы башын кабинадан чыгарып сорашырга өлгермәде, Гөлсем апа, машина яныннан абына-сөртенә атлаган хәлдә, үзе аңлатып бирде:

— ...Зинһар өчен... Үтенәм сездән...

Шофер янында кабинада килүче офицер яралыны кая булса да госпитальгә яки тиз ярдәм күрсәтү пунктына илтеп йөрүдән баш тартты. Моның өчен кире борылырга кирәк, ә алар передовойга ашыгалар... Шулай да, кабинадан тиз генә атылып чыгып, тротуарда кар өстендә хәрәкәтсез яткан хатын янына йөгереп килде.

Бу вакытта инде бала тыныч түгел, әллә әнисен торгыза алмаганга гарьләнеп, әллә бераз сизенеп, шыншый башлаган иде. Әле генә әнисе шикелле үк ягымлы итеп, акыллым дип эндәшеп торган апаны кабат күргәч, аңар зарланып, күз яшьләренә йотлыга-йотлыга:

— Әнием толмый-й...— диде.

Әйе, ана тормады, селкенеп тә карамады ул. Офицер белән кузовтан сикереп төшкән берничә кызылармеец аны, зур саклык белән күтәреп алып, өенә, җыештырылмаган кроватена кертеп салдылар һәм, ярасын бәйләргә индивидуаль пакет калдырып, исәнлек-саулык теләп, әз генә дә тукталып тормыйча, чыгып киттеләр.

Гөлсем апага ПВХО занятиеләре тагы бер тапкыр ярдәм итте. Ул, тавышка кергән күрше карчык ярдәме белән, хатынның ярасын санитарларча оста итеп бәйләде. Бәйләгән арада карчык зарланып алды:

— Әйттем мин аңа, төнлә йөрмә, бик караңгы, килми калмас, дидем. Юк бит, баламны ничек ач яткырыйм дип, чыгып китте. Их, их... Җитмәсә, авыру да бит әле ул. Саз бизгәге аңарда. Ач булуын әйтмим дә инде, без барыбыз да... Камап алганына дүрт ай була бит инде, каһәрнең...

— Ә сез?..

— Мин (карчык яралы хатынга ишарәләде) Мәрьям Зиннәтовнаның күршесе. Без аның белән бөтен йортка икәү калдык. Сабыен кушып исәпләсәк — өчәү. Бар да көнчыгышка эвакуацияләнеп бетте. Мин үзем... Кызым фронтта минем. Киявем дә. Мәрьям Зиннәтовнаның Искәндәреннән бер генә көн соң киткәннәр иде. Икесе дә исән-сау. Тик менә Искәндәр... Ой Искәндәр...

Карчык (гүя Гөлсем апа бу турыда болай да белергә тиеш иде) әйтеп бетермәде, авыр сулап, күзге өстәлендәге кара печатьле озынча кәгазьгә башы белән ымлады һәм, тагын «мин үзем...» дип башлады. Бу юлы да үзе турында әйтергә әллә онытып, әллә кинәт икенче бернәрсә исенә төшеп, ана үрдәк шикелле янтык атлыйатлый, ишектән чыгып китте:

— Бер таныш докторым бар минем. Әйбәт дигәндә дә әйбәт инде... Өендә туры китерә алсам...

Гөлсем апа... Ә кем соң ул Гөлсем апа?..

Революция бишеге — Ленинградның камалышта калуы бөтен совет халкын тирән хафага төшерде. Ленинградны бирү башкалага турыдан-туры куркыныч тудырачак иде. Шуна күрә Кызыл гаскәр аны, ана арслан үз баласын саклагандай, бөек бер фидакарьлек белән саклады. Шәһәр үзе дә (эшчеләр, хезмәткәрләр, укымышлылар, хатын-кызлар) изге көрәшкә күтәрелде. Корал тотар хәле булганы, нәрсә бар шуның белән коралланып, ополчение батальоннарында сугышты, сугышка ярамаганы окоп казыды, заграждениеләр корды, шәһәрне бирмәү юлында нәрсә эшләргә мөмкин — барысын эшләде. Үләрбез, ләкин Гитлерга кол булмабыз! Ничәмә-ничә буын бабаларыбыз акыл көчен салып, маңгай тирен түгеп төзегән ил күрке гүзәл Ленинградны Гитлер аяк астына ташлап качмабыз! — Ире-хатыны, олысы-кечесе бары тик шул турыда, бары тик шул турыда уйлады.

Ләкин хәл сәгать саен, минут саен кискенләшә барды. Гаскәр йончыды, сафлар сирәгәйде, корал, сугыш кирәк-яраклары җитешмәде. Шәһәрдә азык бетте, ягарга бетте. Икмәк, утын, ташкүмер карточкага калды. Икмәк кеше башына өч йөз, ике йөз, аннан йөз егерме биш граммга калды. Утынны пулинләп өләштеләр. Бара-тора бөтенләй бетте утын. Ут бетте шәһәрдә, водопровод туктады, коймалар, капка баганалары, каралтылар, агач өйләр сүтеп ягылды. Гитлер — җиһан корткыч

аның саен ярсуын арттырды. Аждаһалар аждаһасы үзенең кармавычлары белән блокаданы кысканнан-кыса барды. Шул рәвешчә Кызыл гаскәрне, беррәттән картлары, хатын-кыз, бала-чагаларны суык белән, ач үлем белән газаплап үтерергә исәп итте. Шәһәрнең тереклек шау-шуы тынды. Ленинград күген дәһшәтле үлем болыты каплап алды.

Ләкин совет халкы мондый аяныч хәлдә калган туганнарын, Кызыл гаскәрне ач үлемнән коткару өчен бөтенесен эшләде. Салкын кыш кереп сулар катуга Ладога күле аша Ленинградка юл салынды. Һәм боз өстеннән утыз километрга сузылган юл буйлап героик шәһәргә азык төялгән олаулар агылды. Бу юлны Ленинград кешеләре, зур өметләр баглап, «Яшәү сукмагы» дип атадылар.

Ләкин сукмак бик куркынычлы иде, бик тар иде ул. Як-ягында, нибары ун-унбиш километрда фронт, өстендә Гитлер козгыннары гәжләп очып йөри. Азык төяп килүче олауларның күбесе боз астына китеп һәлак булды. Ләкин тыл кешеләрендә Ленин шәһәрен саклаучыларны, аның героик халкын ач үлемнән йолып калу теләге чиксез көчле иде. Эшчеләр, хезмәткәрләр үзләренең паекларын бүлеп, колхозчылар хезмәт көннәренә тигән барлы-юклы граммнарыннан өлеш чыгарып, икенче олауларга, самолетларга төяп озаттылар. Халык вәкилләре, үз тормышларын куркыныч астына куеп, бу олауларны озата килделәр. Укытучы Гөлсем апа әнә шундый вәкилләрнең, Ленинградка Татарстан жиреннән килгән вәкилләрнең, берсе иде.

Ул, самолет Ленинградка килеп төшеп, азык-төлек тиешле кулларга тапшырылгач, өеннән алып килгән әзмәз күчтәнәчен кечкенә чемоданга салды да кайчандыр үзен шушы Ленинградта, педагогия техникумында укыткан профессорны эзләп китте. Профессорның квартирасы йозаклы иде. Тәрәзәдән тәрәзәгә, ишектән ишеккә йөри торгач, көчкә берсеннән җавап бирделәр һәм профессорның күптән инде семьясы белән Урал ягына эвакуацияләнгән булуын әйттеләр. Кинәт бомбежка астында калып, әлеге яралы хатын белән сабый балага килеп юлыкканда, аның шул профессорны күреп сөендерә алмавына күңелсезләнеп гостиницага кайтып барышы иде.

Карчык алып килгән, үзе дә үлек төсле ак чырайлы нәзек озын доктор яралы хатынны нәрсәләрдер иснәтеп аңына китерүгә, Гөлсем апа гостиницага ашыкты һәм, кайтып җитәрәк кылт исенә төшеп, үзен-үзе тиргәргә кереште. «Мәнсез дә инде мин... Ул бит ач та әле. Ә баласы тагын... Мәнсез дә инде мин...» — Ләкин бик соң иде инде. Әле дә озак йөрде. Иптәшләре борчылып тора торгандыр... Кире борылмады. Ә икенче көнне сугыштан яна чыккан берничә часть янында булып, аларга Татарстан хезмәт ияләренең бүләк һәм сәламнәрен тапшыргач, делегация башлыгыннан рөхсәт сорап, әлеге чемоданын алып, тагын килеп җитте.

Бу вакытта яралы хатын, доктор киңәшен тотып, кыл кыймылдатмыйча ята иде. Ул Гөлсем апаны тавышыннан ук таныды һәм башын борыр-бормас, иреннәрен чак хәрәкәтләндереп, ихтирам белән елмаеп куйды:

— Рәхмәт сезгә, ханым. Игелек күрегез.

Гөлсем апа, аның хәлен дә сорарга онытып, кичәге хатасын төзәтергә ашыкты. Чемоданын өстәл читенә куйды да кесәсеннән ачкыч эзли-эзли, сөйләнде:

— Мәнсез дә инде мин, каушавым белән кичә исемә килмәгән... Хәзер, хәзер... Сезгә насыйп икән...

Яралы юрган өстендә яткан кулын зәгыйфь кенә селкеп куйды:

— Юк, рәхмәт. Артык сыныгыгыз бар икән, әнә аңар...

Ул өстен дә чишенмичә, хәтта шарфын да чишмичә үз янында йоклап, яңа гына уянган, соңгы тапкыр ашаганда җәймәгә коелып калган икмәк валчыкларын чүпләп утырган баласына ишарәләде.

Гөлсем апа балага беренче тапкыр текәлеп карады һәм сокланмыйча кала алмады. Юк, алай әллә ни матур түгел иде ул. Әнисеннән аңа бик аз нәрсә күчкән: күзләре зәңгәр түгел, көрәнсу, чәчләре алтын-сары түгел, җирән; йөзендә дә әнисендәге нәфислекнең әсәре юк иде. Ә шулай да бу бала нәрсәсе беләндер сөйкемле, нәрсәсе беләндер сине үзенә тартып тора, караган саен карыйсың килә аңар, иреннәре ниндидер күңелле сүз әйтер өчен ачылгандай шаян елмаерга торалар, елмайды исә, курнос борыны да, бит уртасындагы чокырчык та елмаер, ак чырае алсуланып китәр кебек иде. Ә сөйләве!.. Ул үзенең бераз сакау теле белән шундый мәзәк, шул ук вакытта шундый җитди итеп бытылдый, нечкә

кашлары кыйгачланып өскә күтәрелә, маңгаена сизелер-сизелмәс җыерчыклар чыга, йөзе сагышлана һәм шул сагыш артында күңелле шаянлык төсмерләнә иде. Син аны, әгәр бала яратучан кеше булсаң, бер карауда үз күрә башлыйсың, шунда ук кулыңа алып сөю теләге туа торган иде. Ә өстендәге чын сәдәпле, ак челтәр иңсәле бархат бишмәте, песи бүреге, аякларындагы җылы йон оегы белән йомшак сары башмаклары аның сөйкемлелеген тулылап, бер үк вакытта әти-әнисе өчен үтә кадерле, үтә иркә бала икәнен әйтеп торалар иде. Тик шулай да айлар буена сузылган ачлык, эчкә төшкән салкыннар, әнисенең үз җылысын, үз сыныгын биреп саклап килүенә карамастан, аңар үзенең шаукымын тидереп өлгергән, яңа борнап килгән бу яшь үсенте түзәр-түзәр дә, иртә килгән салкын кыраудан шиңеп калган гөлчәчәктәй, бер көн дәррәү сулып төшәр кебек иде.

Сабый, валчыкларны чүпләп бетергәч, әнисенең киезләнеп каткан чәчләре белән уйнагандай итенде. Әйе, сабый өчен уен бик табигый ихтыяҗ, ләкин аңар караганда да ихтыяҗрагы — бәгырьне өзгәне — үзенекен итте. Бала тагын валчыклар эзләргә кереште. Ләкин җәймәдә бер валчык та калмаган иде инде. Шунысы гаҗәп: күрәсең, ул инде моның файдасыз эш икәнен төшенеп җиткән — әнисеннән ашарга сорамады.

Гөлсем апа камалышта калган Ленинградның дәһшәтле көннәр кичерүе турында ишетеп белсә дә (үз күзең белән күрмәсәң, шулай бит ул), болай ук дип уйламый иде әле. Камалыш дәһшәте кешеләргә, бала белән анага гына түгел, хәтта өйгә дә үзенең шаукымын салып өлгергән иде. Кыйммәтле рәсемнәр, төркмән паласлар, башы түшәмгә тиеп торган нәфис көзге, рояль, радиолар белән җиһазландырылган, кайчандыр җанга ял, күңелгә рәхәтлек биреп торган бүлмә озак вакыт җыештырылмау, атналар буена ягылмау сәбәпле аяныч төскә кергән, һәр җирдә тузан, стенасы дым тарткан, почмаклары бозланган, һавасы салкын һәм авыр.

Гөлсем апаның бөтен тәне чымырдап китте. Ул бик аз гына вакыт ни әйтергә, нәрсәгә барып тотынырга белми торды да, каушавы белән идәнгә төшереп җибәргән чемодан ачкычын эзләп табу өчен тиз генә килеп выключательне борды. Ут, әлбәттә, юк иде. Гөлсем апа

өстәлдәге күптән юылмый яткан савыт-саба арасында кайчандыр кыйммәтле одеколон белән тулып торган, хәзер исә этикеты корымланып беткән фигуралы шешә күрде. Шешәнең авызыннан чыгып торган күмерле тасмага карап, Гөлсем апа аның лампа урынына хезмәт иткәнен белде һәм шырпы сыза башлады. Яралы хатын иреннәрен генә кыймылдатып нидер әйтте һәм тәрәзәгә ишарәләде.

Әйе, әйе, ничек үзе абайламаган? Гөлсем апа муенына уралган мамык шәлен чишеп җибәрде дә кабаланып килеп маскировканы төшерде. Икенчесен төшергәндә, тәрәзә каршындагы йортның соры стенасына күмер белән зур итеп язылган. «Маскировка кормаган өчен трибунал» дигән сүзләрне күреп калды.

Кабызган шәпкә «лампа» өй эчен ярыйсы гына яктырткан кебек булган иде. Ләкин шунда ук аның шәүләсе бик тонык булып калды. Табак-савытлар арасыннан кроватька якынрак этәреп куйгач, яралының ярты як битенә ут шәүләсе төшеп, аны тагын да кызганычрак кыяфәткә кертте. Гөлсем апа термосыннан стаканга хуш исе аңкып торган, ләкин чемоданда ята-ята суынып беткән какао салып, яралының күгәргән иреннәренә китерде. Яралы исә башын стенага таба кыйшайтты:

— Рәхмәт, ханым. Мөмкин булса, әнә аңар...— диде ул, тагын сабыена ишарәләп. Шулай диде дә талган күзләрен йомды. Ләкин яшерә алмады, аның кара озын керфекләрендә энҗе бөртегедәй яшь җемелди иде.

Гөлсем апа чигенмәде. Бала яраланмаган, ач кына. Аның хәле бик үк начардан түгел, организмы да көрәшкә сәләтлерәк, ә әнисе ашыгыч ярдәмгә мохтаҗ... Гөлсем апа какаоны көчләп эчерә башлады. Ләкин ана тагын баш тартты.

— Аңар...

Сабый, иреннәренә какао тигәч, әнисенең имиләрен беренче тапкыр эзләп тапкан, әле күзләре дә ачылмаган песи баласы кебек кинәт очынып китеп, голкылдатырга тотынды. Йоткан саен тернәкләнә барды ул, ә эчеп бетергәч, канәгатьләнеп, үзенчә мыгырданып куйды.

— Тәмлеме, акыллым?

— Тәмле.

— Ни исемле әле син?

— Малат...

— Инде миңа киләсеңме, Марат?

Сабый энисе аша Гөлсем апага үрелде. Кулга килгәч, бер дә ятсынмыйча, аның колак алкалары, ак беретындагы фил брошкасы белән уйнап торды. Аннан нәни, ябык куллары белән Гөлсем апаның ягымлы елмайган ирен кырыйларын тотып, ашарга сорады:

— Тәти апа, мәми бил...

Гөлсем апа, чемоданында пәрәмәч, акмай, шоколад кебек күчтәнәчләре булса да, ач кешеләрнең берьюлы күп ашап ташлап үлгәннәрен ишеткәне булганга, берсен дә бирмәде. Бала кабат сорана, өстәлдәге термоска үрелә башлагач, кулында селки-селки көйләргә кереште:

— Бераздан, яме. Без шулай йөри торыйк, ә какао термоста пешә торсын...

Бердәнберенең ач үлем тырнагыннан котылу мөмкинлеген күргәч, яралы ананың күзләренә шатлык яшьләре бәреп чыкты. Гөлсем апа, аның өстенә иелеп, төз, матур борын төпләре буйлап тәгәрәгән яшь тамчыларын җәймә чите белән сөртә-сөртә, тынычландырырга тырышты:

— Кирәк түгел. Балагызга да, үзегезгә дә бернинди куркыныч янамый. Менә болар бар да сезгә... Аннары, ишеткәнсездер, соңгы көннәрдә фронтта хәлләр сизелерлек яхшырды бит. Озакламас, шәһәрегез камалыштан чыгар, кибетләрегез ризык белән тулар. Үзегез беләсез, юклыктан түгел...

Гөлсем апа, сөйләнә-сөйләнә чемоданын ачып, авыру анага берничә бүлем шоколад сындырып бирде, авыру ана күңел өчен генә бераз китеп алды да калганын баласына каптырды.

— Кыстамагыз, ханым, мин үз хәлемне үзем беләм...

Гөлсем апа ышанмады. Ничек инде... Бик тыныч ята бит... Шундый чакта була торган рухи төшенкелек кенәдер... Ул баланы, бик керләнгән, төбе сүтелеп киткән рейтузын алмаштырмакчы булып, чишендерә башлады. Ләкин салкын тиюе бар, башта мич ягарга уйлап, Мәрьям ападан утын сорады. Утын исә күптән юк, җиһазларның да күбесе ягылып беткән, шкаф, буфет кебек нәрсәләр дә калмаган иде.

— Вата алсагыз, әнә шуны,— диде хатын.— Балта шул тирәдә генә булса кирәк...

Әлбәттә, вата... Хәзер җиһаз дип тора торган чакмыни!.. Ул «лампа»ны, савыт-сабаларны тәрәзә төбенә алып куйды да өстәлне идәнгә егып салды, һәм... сугарга

дип кизәнелгән балтаны кире куйды. Бу — затлы агачтан матур сырлап, чын сәдәпләр белән бизәкләп эшләнгән бик нәфис язу өстәле иде. Кемдер инде аның аягына балта белән берничә мәртәбә чабып та караган, әллә чабучының егәре җитмәгән, әллә инде кызганып суккан, өстәл аягы бөтенләй диярлек зарарланмаган иде.

Аны ватып ягарга Гөлсем апаның да кулы бармады. Ул берәр нәрсә табу өмете белән залга керде, кухняга кереп чыкты, ләкин һичбер кайда янардай нәрсә таба алмады.

— Шул өстәлне генә...

— Юк, юк...

Гөлсем апа моңарчы, күрәсең, күз төшмәү сәбәпледер, ягылмыйча тәрәзә өсләрендә эленеп калган гардиннарны күрде. Хуҗа хатын каршы килмәде. Гөлсем апа һәр ике бүлмәдәге, кухнядагы гардиннарны җыеп алып вакълады да мич ягып җибәрде. Коры имән агачыннан мич капкачы кызарып чыкты, ә мич үзе бөтенләй диярлек җылынмады. Аңардан бүлмәгә дымлы авыр ис кенә аңкыды. Гөлсем апа, хуҗа хатын әйтүе буенча, почмакта өелеп яткан китапларның берничәсен, калын-калын ике альбомны, юкарып калган календарьны өстәп якса да, файдасы әллә ни булмады. Аның каравы, юеш ис күбрәк таралды, бүлмә һавасы тагын да тынчулана төште.

Шулай да Гөлсем апа, ачык мич авызына бик якын тотып, баланың рейтузын салдырды, әйләндерә-әйләндерә артын җылытты һәм, тиз генә коры рейтуз киертеп, әнисенең куенына китереп салды.

Яралы ана үзенең зәгыйфь, кызу кулы белән Гөлсем апаның беләгеннән тотты. Ләкин, үзен хискә бирелүдән тыеп калу өчендер инде, аның күзләренә туры карамады.

Хисләрен җиңде ана, бу юлы күз яшен чыгармады. Ә менә йөрәге... йөрәге елаганны яшерә алмады. Ул, гирән сыкрау аркасында сүзен сүзгә көч-хәл белән ялгап:

— Миңа бик авыр, ханым,— диде.

— Шулайдыр. Ярагыз шактый тирән бит, Мәрьям Зиннәтовна.

— Анысы әллә ни түгел, йөрәк әрни менә. Ой, әрни лә йөрәк!.. Иә, нишләр инде минем бу газизем, мин ул-

сәм?..— диде ана, иреннәрен сизелер-сизелмәс тибрәтеп.— Өстәвенә Гитлер басып керсә?.. Басып кереп, әтисен үтергән, яки мине яралап киткән солдатына минем сабыемны кол итеп бирсә?.. Күз алдыгызга китерегез әле, ханым...

Ул сүзләрен бер-берсенә көч-хәл белән ялгады. Берәр сүз әйтте дә туктап торды. Хәлем бетәр дә иң кирәген әйтә алмый калырмын дигән кебек, бик сакланып, ахыр чиктә әкрен итеп сөйләде:

— Ә күптәнме әле без нинди бәхетле идек! Күптәнме әле без чиксез бәхетлеләр чиксез бәхетлебезне йоклаттык та аның кровате янында утырып төн уздырдык... Юк, авырмады. Әтисе ятмый; ул ятмый дип мин ятмыйм... Бигрәк күңелле иде шул. Тышта ак төн. Күктә ай. Тәрәзәләр ачык. Бакчадан хуш ис бөркелә. Ә без шатлык исереклегендә татлы хыялларга чумабыз. «Менә тиздән бакчага йөри башлар... Бакчага мин аны үзем илтеп куярмын...» — «Юк, үзем...» — «Җәй көне мин аңа җиңсез ак күлмәк, кыска соры чалбар киертермен. Ә кыш көне... Синеңчә, чәчен алдырсак матур булырмы, Ильичның сабый чагындагы кебек итеп үстерсәкме?..»— «Ә кем булыр, Мәрьям, кем булыр безнең бу гүзәлебез? Беләсеңме, ул бит теләсә кем була ала. Кем булыр икән, Мәрьям җаным?..» — «Беркем дә булмасын әле, шул килеш кенә, кечкенә килеш кенә торсын әле минем күз нурым...»

Битенә кытай алмасы кадәр генә булып кояш нуры төшкәч, белдек: тышта таң аткан, кояш чыгып килә иде. Мин кояшны томалыйм. Борчып уятыр дип куркам. Ә әтисе минем кулны этәрә... «Тимә, тимә... күр, болай бигрәк матур», ди... «Әйдә, ятыйк инде...» — «Юк, мин ятмыйм әле...» — «Алайса мин дә... Иртәгә ял ич...» — «Бүген диген...» — «Ай, көлә, әтисе, әнә төшендә көлә...»

Бу безнең бергә уздырган актык көнебез, дөресрәге, актык сәгатебез булды. Радио. Сталин. Искәндәр... Бигрәк, бигрәк ярата иде шул ул нәниебезне!..— Кровате янына тезләнеп, әле генә кояш нуры сирпеп узган битен үпте дә... Һәм сәгате-минуты белән бөтенесенең асты-өскә килде. Ә нәкъ алты ай дигәндә... менә күрәсез...

Яралы ана инде үзен тыеп кала алмады, какао, пәрәмәч, акмайдан соң яхшы ук егәрләнеп киткән сабыен чакырып китерде дә, битен аның битенә куеп, тавышсыз

гына еларга кереште. Йөрәге белән елаган хәлдә тыңлап торган Гөлсем апа тагын аның өстенә иелде.

— Карагыз әле, кирәк түгел, кирәк түгел, Мәрьям Зиннәтовна... Ой, мин соң нишләп торам! Кара, мин нишләп торам әле? Аш пешереп җибәримче. Ярты тавыгым бар, бик яшь. Тиз пешәр,— диде ул һәм керосинканы кабызып эшкә кереште. Кранда су юк иде, чиләк белән урамнан кар алып кереп эретергә утыртты.

— Әй тын да соң тышта. Җылыткан. Бик матур булып кар ява. Шундый ак, урам яктырып киткән...

Яралы җавап бирмәгәч, Гөлсем апа, аны йоклаган дип белеп, кинәт тынып калды. Ярый әле кычкырып сөйләшмәдем, диде ул эченнән генә һәм сабыйның, энисе үзен йоклаткан чакта көйләгәнгә охшатырга тырышып, мәзәк бытылдаганын тыңлый-тыңлый, тавыгын юып салды, табак-савытны юды. Ә Марат энисен селки-селки көйләде дә көйләде:

Дәү үс, улым, үс, улым.
Дәү үс, минем күз нурым...

— Җитте, Марат, җитте. Бер йоклап киткәч, тирбәтмиләр инде аны.

Бала тынды. Энисенең юрганын әкрен генә аяк астына кадәр тартып китерде, чит-читен билләренә кыстыргандай итте. Энисе үзен йоклатканда нишләсә, барысын да кыланды бала. Кулын битләренә тидерер-тидермәс сөеп торды, чәчләрен сыйпады. Үзенчә бик җитди итеп: «Йокла, күз нурым, йокла»,— дигән булды. Маңгаеннан үпте энисен, аннан, әкрен генә төшеп, Гөлсем апа янына килде:

— Тәти апа, нәрсә пешерәсең?

— Тавык, акыллым. Син тавык яратасыңмы?

— Ялатам.

— Яратсаң, хәзер ашарсың... Юк, чи шул әле ул. Пешкәч, яме? Икәү пеширикме, Марат?

— Пешелик.

— Акыллым минем...— Гөлсем апа сабыйны кочып алды.— Тозыгыз бармы, акыллым?

— Бал.

— Бар, алып кил әле.

Марат, йөгереп барып, тоз алып килеп бирде дә, бер дә ятсынмыйча, Гөлсем апаның алдына кереп утырды.

һәм шунда ук шуышып төште дә, савыт-саба арасыннан актарып алып, пычак белән чәнечкә китереп бирде:

— Инде песә?..

— Иһи-и... болай булгач, пешми генә карасын!. Хәзер, акыллым, хәзер...

Сабый керосинканың икенче ягына чүгәләде дә, аның кастрюль төбенә төшкән кызгылт яктысына карап, инде быкырдый башлаган тавыкның тәмле исенә тәкатьсез булып, төкерекләрен йотып утырды, артык сабырсызлана башлагач, Гөлсем апа аңар чемоданыннан бер печенье алып бирде.

Бала тагын бу яхшы апаның алдына менеп сыенды, тагы идәнгә төште һәм иңенә аскан, бик вак энҗе белән бизәкләп эшләнгән яшел бархат сумкасын бушатып уйнарга кереште. Гөлсем апа башта әһәмият бирмәде, ә инде теге кара печатьле кәгазь өстенә ахак кашлы йөзек, бик кечкенә алтын сәгать, алтын чылбырлы медальон чыгарып тезгәч, игътибар итми кала алмады. «Мин чыгып торган арада, әнисе йокыга киткәч алгандыр. Берәр җиргә илтеп тыгар да әнисенең миннән шикләнүе ихтимал!..» — Гөлсем апа сабыйның кәефен бозмас өчен җайлап кына:

— Алай сорамыйча алырга ярамый, акыллым, бар, урынына илтеп куй, әниең орышыр,— диде һәм кыйммәтле әйберләрне баланың сумкасына тутыра башлады.

Бала аның кулларына ябышты:

— Әнием орышмый. Әнием үзе бирде...

Сабый башын да күтәрмичә уйный калды. Гөлсем апа, шомлана төшеп, тиз генә кровать янына килде. Ананың тәне әле баягыча ук җылы, ә йөрәге типми иде инде.

Күгәренеп китте Гөлсем апа, куллары калтыранды. Иреннәре ачылыр-ачылмас кыймылдап:

— Үлгән...— диде.

Марат, бу яхшы апаның, гел елмаеп торган, тәмле мәмиләр ашаткан, акыллым дип кенә эндәшкән апаның кинәт шундый куркыныч кыяфәткә керүеннән ниндидер күңелсезлек булганны аңласа да, «үлгән» сүзенең мәгънәсенә, аның үзе өчен дөньяда иң аянычлы сүз икәненә төшенмәде. Ул алдындагы «уенчыкларына» аш ташый башлагач кына:

— Тәти апа, тавык песте, тәти апа, тавык песте,—

дип кровать янына йөгереп килде һәм Гөлсем апаның итәгеннән өстерәргә тотынды:

— Тәти апа, тавык песте...

Гөлсем апа, сабыйны күтәреп алып әнисенең баш очына утыртты да үтеп барышлый керосинканың фитилен кыса төшеп, каушый-каушый ишектән чыгып китте:

— Шунда гына утыр, Марат. Ашка якын бара күрмә, пешәрсең.

Марат берчак түзеп утырды. Тагы бераз түзде. Юк шул, тик утыру күңелсез икән... Ул, чәчләреннән сөя-сөя, әнисен уятырга кереште:

— Әнием, тавык песте. Әнием, тол... Тол, әнием.

2 ТӘТИ АПА, ӨЙГӘ КАЙТЫЙК

Ниләр генә эшләтмәде бу сугыш кешене!.. Кемнең генә язмышын һич көтмәгәндә һич көтмәгәнчә үзгәртеп җибәрмәде!.. Берничә сәгать үтүгә, таң беленер-беленмәстә, Марат инде әнисеннән әллә кайда еракта, зур самолетта көнчыгышка таба очып бара иде. Пассажирлар, шул исәптән носилкалардагы яралылар да, аның, Гөлсем апа пешереп биргән тавык ботын тозга манып, әз-әз кабып, әдәп белән ашап утырганына сокланып карап торалар, летчик үзе дә, кулларын штурвалдан җибәрмичә генә, әледән-әле пыяла ишек аша пассажирлар ягына карап ала һәм сокланып башын чайкап куя иде.

...Эш болай булды. Гөлсем апа, сабыйны әнисе янында калдырып, коридорга атылып чыккач, берничә ишекне дөбердәтеп караса да, эндәшүче булмады. Баскычтан йөгереп төшеп барганда парадный ишектән, бер кочак яшь ылыс күтәреп, әлеге күрше карчык кайтып килә иде. Камалыштагы Ленинградта андый хәлләр еш булып торганга һәм кичә доктор эшнең шулай бетәчәген бер дә икеләнмичә әйтеп киткәнгә, күрше карчык Гөлсем апаның хәбәренә артык гаҗәпләнмәде. Ылысларын уң кочагыннан сулына күчерде дә, башын мәет яткан ишеккә таба ия-ия, ике-өч тапкыр чукынып алды һәм, йөрәге белән елап, болай диде:

— Керә алса, ниләр күрсәтер, ә хәзергә безне менә шулай кыра, бәдбәхет...

Гөлсем апа, кылт исенә төшеп, карчыкка сорау бирде:

— Ай, ә сабые нишләр инде хәзер, Лидия Андреевна?

Баланың ятим калачагын күреп торса да, кичә әле карчыкның башына, әнисе үлгәч бу бала ничек яшәр, дигән уй килмәгән иде. Гөлсем апа кинәт шундый сорау куйгач, ул ни дип тә әйтә алмады.

— Ерак туганнары да юкмыни, Лидия Андреевна?

— Бик якыны да бар. Искәндәр Зәбировичның бертуган абыйсы. Әле сугыш башланыр көннәрдә генә атна-ун көн торып киткән иде... Ләкин хатыны бер дә риза була торган түгел, үз балаларын да әле...— Карчык кулын селекте.— Тагын шунсы бар: сабыйны анда кадәр ничек илтәсең? Мәскәүдән ары, Ока суы буенда торалар, Касимов шәһәрендә. Әнә кайда.

— Ә соң нишләтәбез?

Карчык бу сорауны, сездә калып торса нишләр, дигән мәгънәдә аңлады һәм моның мөмкин түгеллеген сөйләп китте:

— Бераз керләремне юарга дип кенә кайткан идем. Мәет булырга торгач калдым. Югыйсә, атналар буена цехтан чыкмыйча эшлибез, кадерлем.

Гөлсем апа карчыкның мичтә пешкән алма кебек саргаеп җыерчыкланган битенә, нурын җуйган күзләренә кызганып карап торды да сорап куйды:

— Сез эшлисез?

— Ә нигә эшләмәскә?

— Гафу итегез. Соң сез нәрсә генә эшли аласыз?

Карчык бу сүзгә җәберсенде. Ул, тавышын яхшы ук күтәреп:

— Җиңү өчен снаряд кирәктер бит, һәм ул гөл бакчасында үсми торгандыр бит... Сез ничек уйлыйсыз, кадерлем? — диде.

— Әйе, әйе.

— Бездә бар да эшли бүген. Кулларын йөртә алмаса, аягы белән әйләндерә, күтәрә алмаса, өстери...— диде карчык һәм, күләгәләр шикелле тавыш-тынсыз гына узып барган унөч-ундүрт яшәр ике малайны күрсәтеп, алар өчен горурланып сөйләп китте:

— Әнә алар да эшли хәтта, кичке сменадан кайтып килешләре. Ә таң ату белән китап-дәфтәрләрен күтәреп, тиба алсалар берәр пулин утын кыстырып, мәктәпкә йөгерәчәкләр.

— Ничек, сездә мәктәпләр дә ябылмаган?

Карчык, җәберсенүен саклаган хәлдә:

— Бар да түгел, җилесе,— диде.— Ябылганнар иде, шәһәрдә калган укытучылар йөреп ачтырдылар. Укытучы, укытучы!.. Аларга да җиңел түгел шул. Шулай да була: кара такта янында мәсьәлә аңлатып торган килеш, аңы китеп, авып төшә. Тора да тагын дәресен дәвам итә...

Гөлсем апа Ленинград кешеләре өчен тирән горурланып, шул ук вакытта үзе өчен, бу нәрсәләр турында хәбәре булмавы өчен уңайсызланып:

— Әнә ничек...— дип башын түбән иде.

Карчык, Гөлсем апаның бу хәлен күреп, сүзне икенчегә борды:

— Ылыс алып кайттым әле менә. Урманнан. Паркта эсәре дә калмаган. Бөтен шәһәр шуңа ябырылды хәзер... Юк, кайнатып эчәбез без аны. Цынгадан искиткеч файдалы. Витамины да күп. Хәл кертеп җибәрә бераз...

Ни әйтергә белмәгән Гөлсем апа тагын:

— Әнә ничек...— диде һәм мәетне хәзерләүне карчыкка тапшырып, үзе, кайда икәнен сорашты да, күмү бюросына йөгерде. Ул әйләнеп кайтканда, бала, сүз тыңлап, урыныннан да кузгалмаган, ә түземе калмагач, әнисенең әле суынып бетмәгән муенын кочып утырган килеш йокыга талган иде.

Хәзер төнге уникe. Дурт сәгатьтән самолет һавага күтәрелә. Гөлсем апа әби белән киңәште дә, йоклап яткан Маратны әнисеннән аерып алып, башына әнисенең шәлен бәйләп эвакопунктка алып китте.

— Иң яхшысы шул,— диде аңа әби.— Аннан балаларны гел көнчыгышка озатып торалар...

Әби белеп әйткән икән, анда чыннан да кечкенә балаларны эвакуацияләүгә хәзерлек бара иде. Ләкин болай да нормадан үтеп китте дип, Маратны алудан баш тарттылар. Гөлсем апа баш врачның квартирасын эзләп табып, уятып керде. «...Зинһар өчен, беркеме дә юк...» Ләкин врач та мәсьәләне дәррәү хәл кылмады. Бер чыгып китеп, яңадан кереп, кат-кат ялынгач кына, ташлап калдырыйммыни инде мин аны дип, тиргәнә башлагач кына рецепт кәгазенә берничә сүз сызгалап бирде:

— Начальникка.

Берсеннән-берсенә йөгереп арыган, талган Гөлсем апа, начальник кабинетына килеп кергәндә, аягына чак

басып тора иде. Ләкин мәшәкать моның белән генә бетмәгән иде әле. Документлар (баланың метрикасы, әтисе турында извещение, әнисе турында врач белешмәсе) кирәк икән. Гөлсем апа, йокысыз вакытсыз бүленгәнгә борчылыпмы, күңеле нидер сизепме, көйсезләнә башлаган сабыйны начальник кабинетында, йомшак креслода утыртып калдырды да, йөгереп кайтып, тиешле документларны һәм үзенең чемоданын алып килде:

— Менә биредә бераз ризык һәм әнисенең кайбер кыйммәтле нәрсәләре. Зинһар ышанычлы кулга тапшыра күрегез инде.

— Уһу-у, син бик бай бирнәле кәләш икәнсең ич... Ни исемле әле син, туташ?

— Ир бала ул, иптәш начальник.

— Ах, шулаймыни? Бик шәп. Өйләнергә уйласа, кәләшенә бүләк әзер икән. Әйбәт, әйбәт... Әй, кайсыгыз бар анда?..

Минут үтүгә баланың милкенә акт төзергә керешелде. Начальник документларны кулына алды:

— 20 декабрь, 1937 нче ел. Их... их... Заманалар тыныч булса, иртәгә уянып китүенә кроватең тулы бүләк булыр иде, ә кичен кунаклар, елка, әйлән-бәйлән, уенкөлке, сый-хөрмәт... Мин беренче тостны... Их, их... Әйлә ярар. Без синең туган көнеңне бу юлы Ладога бозлары өстендә уздырып торырбыз... Аюлар шикелле.

Акт төзеп утырган өлкән яшьләрдәге сестра балага күз төшереп алды да өстәп куйды:

— Исән калса...

Гөлсем апа Маратның чәчен тарап бетереп, башына шәлен бәйләп тора иде, сискәнеп китте:

— Әле шундый куркыныч та бармыни?

Сестра җавап урынында кулын гына селтәп куйды.

— Нишләп, олауда балалар икәнен күрсәткән билге була торгандыр ич?..

— Ә ул аждаһа өчен барыбер. Тик кан түгелсен. Совет кешесе каны...

Гөлсем апа уйга калды. Начальник, урыныннан кылт сикереп торып, сестраны бүлде:

— Миңа бер идея килде. Беләсезме нәрсә, ханым. Алып китегез сез сабыйны үзегез белән. Мәскәүдә берәр балалар йортына бирерсез. Дөрес, хәзер һавада да яман тынычсыз чак, ә шулай да, боз өсте түгел инде...

«Кара, чыннан да... Бу бик мөмкин ич. Дөрес, самолет бик күп яралы солдат алачак. Ләкин бер сабый ничек тә сыяр әле, үтенеп сорармын...»

Начальник, Гөлсем апаның риза булганын ачылып киткән йөзеннән үк күреп, языла башлаган актны ерткалады да янып торган мичкә атты.— «Мандатам почтенья нету!..» — Аннары, баланың метрикасы белән кыйммәтле әйберләрен, өстәлдән учына сыпырып төшереп, Гөлсем апага бирде.

— Әй, Ефим агай!

— Яңа йоклап китте. Окоп казуда иде. Өч төн йоклаганы юк...

— Ул чакта, Марфа түтәй, үзеңә туры килә... Чуар бияне җигеп, тиз генә аэропортка илтеп куй үзләрен. Хәерле юл сезгә, хөрмәтле гражданка!

...Бик кечкенәдән яслегә йөреп, шаулап торган коллектив эчендә, тәрбиячеләр кулында үскән Марат самолеттагы пассажирларга тиз ияләшеп китте. Бу ИЛ-2 маркалы бик зур йөк самолеты булып, анда делегатлардан башка тагы күп кенә яралы солдатлар да бар, кайсыларының башлары, кайсыларының куллары бәйләнгән, берничәсе носилкаларда сыкранып ята, кыска тун өстеннән ак халат кигән, зур кызыл тәреле яшел сумка аскан яшь кенә бер сестра, аларның берсеннән-берсенә күчеп, хәлләрен сорашып, дәвалап йөри иде. Маратның күңелен тартканы да шул булды. Ул, тавык боты белән эшне бетергәч, сестрадан бинт белән мамык сорап алды һәм, аңардан күрмәкче, яралылар арасында йөри башлады:

— Хәлең нисек?..

Яралылар, житдилек сакларга тырышып, хәлләрен әйттеләр.

— Кай зилең авылта?

— Менә бу «зилем».

Марат, яралының беләген тотып, пульсын санагандай итенде. Бәйләде, су эчерде...

Пассажирлар рәхәтләнеп көлделәр. Носилкада ятучы бик авыр яралы кеше дә (монысы Гөлсем апаларның делегация башлыгы булып, окоптан окопка күчеп, солдатларга бүләк өләшеп йөргәндә яраланган иде) елмаймыйча кала алмады.

Марат исә гүя көлгәнне ишетмәде, елмайганны күр-

мәде, үзенчә сөйләнеп, сестра нишләсә, шуны кабатлап йөри бирде.

— Хәзел бәйлим, хәзел... Зә инде, йокла...

Шулай күңелле генә килгәндә, пассажирлар бар да, сүз куешкан кебек, кинәт тынып калдылар, сөйләшкән, көлешкән тавышлар берьюлы тынды. Кешеләрнең утырып барганнары артка янтаеп китте, басканнары, мәтәлә-абына, койрыкка килеп өелде. Тимер идәнгә тезеп куелган носилкалар да артка таба шуып киттеләр. Марат та бер солдатның «снаряд тигән» бармагын бәйләп торган җиренән носилка тоткасы аша мәтәлеп барып төште — самолет кинәт бик текә алып, югары күтәрелде.

— Ни булган? Аста «Тормыш сукмагы»ның як-ягында дошман зениткалары ата башлаган иде.

Гөлсем апа Маратны күтәреп алды да, әйтерсең аны һәлакәттән шулай саклап калу мөмкин иде, пальтосы эченә яшерде.

Самолет, ак болытларны тишеп өскә чыккач, тагын тыныч кына бара башлады. Гүя, болыт болыт түгел, ә очсыз-кырыйсыз сахрадагы эреле-ваклы кар көртләре, гүя, самолет киң чаңгыларын кигән дә шул көртләр өстеннән кар туздырып шуа иде.

Ян тәрәзәдән карап барган Маратка бусы да кызык тоелды. Аста «кар», күк йөзе язу карасы төсле куе зәңгәр, үзе тирән. Йолдыз! Йолдыз!.. Бик күп. Алтынмыни, бар да сап-сары. Ай да сары. Үзе тулы, үзе зур. Ә зенитка снарядлары озын, кызыл ут көлтәсе булып, астан «кар көртләрен» тишеп килеп чыгалар да, бераз менгәч, йомрыланып туктап калалар һәм шунда ук, яфракларын көчле җил тузгыткан гөлчәчәк кебек булып, ләкин бик тә әче сызгырышып, як-якка таралып сүнәләр.

Бер «көлтә» бигрәк якын чыелдап узды, ә менеп җиткәч, шундый көчле шартлады, самолет, тотып селкегән иске арба кебек, дерелдәп торды, пыялалары зыңгылдады самолетның. Пассажирлар күбесе күзләрен йомып, битләрен куллары белән томаладылар. Ә летчик, әйтерсең бу хәл тормышта түгел, кинода бара иде, әз генә дә каушамыйча, ләкин бик тә житди кыяфәткә кереп, рульне әле уңга, әле сулга борды һәм бертуктаусыз тирә-якны күзәтте.

Ләкин бу ни хәл? Самолет түшәмендәге люкта, пулемет янында, пулеметчы юк ич! Моны, башлап, Ленин-

град фронтының хәрби штабыннан Мәскәүгә командировкага баручы бер ромблы командир күрде. Ул летчик янына килеп:

— Ни өчен пулеметчы урынында түгел? — дип сорады.

Летчик, утырган килеш кенә кулын козырегына таба күтәреп төшерде дә, пулеметчының үз теләге белән фронтта, алгы сызыкта калганын әйтте.

Летчик шулай дию:гә, яралылар арасыннан Маратның мәзәкләренә күзен дә ачып карамыйча сызланып яткан бер сугышчы башын күтәрде һәм яны белән әйләнә башлады. Моны күреп, аның янына санитарка йөгереп килде:

— Нишлисез сез, иптәш сержант? Хәзер ятыгыз!

— Юк...— Сержант, сыкранмаска тырышып, носилкадан төште.

Башы бинт белән урап бәйләнгән иде аның. Ахрысы, яңарак кына яралангандыр, колак төбенә кан тибеп чыккан иде, бер аягы да яралы булып, сержант анысын өстерәп атлый иде. Ул урыныннан күтәрелүгә бер кулын санитарканың иненә салды, икенчесе белән буйдан-буйга сузылган тимер киштәгә тотына-сөялә люк янына килде:

— Пулеметчы мин, иптәш командир,— диде ул бер ромблыга.— Рөхсәт итегез.

— Сең бит сез...

— Зарар юк...

Кешеләр аңа пулемет янына менәргә ярдәм иттеләр. Сержант менүенә гашеткаларга ябышты.

Марат мәзәкләре онытылды хәзер. Барысы да сержантның аяк очына җыелдылар. Кайсы бу фидакарь сержантка пулемет лентасы сузды, кайсы ящиктагы дискларны барлады. Бер ромблы командир үзе дә сержант аяк очыннан китмичә, аңа файдалы кеше булырга теләп, шунда кайнаша иде.

Шул рәвешчә бераз баруга зениткалар тынды. Ут «чәчәкләре» сүнеп бетте. Хәзер инде тирән күккә, тулы айга, эреле-ваклы йолдызларга сокланып карап барасы гына калды. Ләкин, юк шул...«чәчәкләр» сүнүгә, дингез төбеннән упкын авызлы кит балыгы сикергән шикелле булды, болыт өстенә дошман истребителе Мессершмит-110 атылып килеп чыкты һәм җитез борылды да, ут төкерә-төкерә, безнең ИЛ-2 өстенә килә башлады. Коты

алынган Гөлсем апа Маратның битен пальто чабуы белән каплады. Ә Марат, йокы белән тартышып, күзләрен ачып җибәргәндә, безнең самолет болыт астыннан бара, летчик исә микрофонга нелә төшеп:

«Мин Акчарлак, мин Акчарлак... мине мессер атакалый, мине мессер атакалый...» — дип кабатлый иде.

Марат акчарлакны белә, узган җәй башында Нева буенда йөргәндә әтисеме, әнисеме күрсәткән иде. Ак каурыйлы, киң канат очларын суга тидерер-тидермәс бик матур кыйгачлап оча торган кош ул акчарлак. Ә бу — абый кеше. Нишләп ул «мин Акчарлак», ди икән?.. Марат шулай уйланып барганда «Акчарлак»ның йөзе кинәт ачылып китте. Ул, самолеттагыларга таба борылып, тыныч тавыш белән:

— Җир безне ишетте,— диде.— Шулай да әзер торыгыз, иптәшләр.

Хәрби кешеләр «әзер торыгыз»ны аңлап, калганнары алардан күрмәкче, бер-берсенә ярдәм итә-итә, парашютларын киделәр.

Ә чыннан да сикерергә туры килсә, Марат нишләр?.. Гөлсем апа, бер хәрби кешенең киңәше буенча, парашютны, пальтосын салып калдырып, фуфайкасы өстеннән киде дә Маратны шәленә төреп күтәрде. Зарар юк, хәзер инде аста үзебезнең җир...

Мессершмит ИЛ-2 не тыныч калдырмады. 15—20 секунд үтүгә үзенең корбаны артыннан койрыклы йолдыз тизлеге белән болыт астына атылып килеп төште һәм, бик тиз күреп алып, тагын ут төкерә-төкерә ажгырып килә башлады.

— Огонь! — Летчик шулай диюгә яралы пулеметчы гашеткаларны кысты.— Тек-тек, тек-тек, тек-тек!..

Ләкин мессер карчыга кебек җитез шул ул, оста маневрлар ясый ала. Безнең ИЛ-2 исә йөк төягән баржа кебек авыр борыла. Мессерга каршы тору аның өчен дуамал тәвәккәллек булыр иде. Ул, текә алып, өскә күтәрелде, ә мессерның борыны болыт астыннан килеп чыгуга тагын аска чумды.

Тагын өскә... тагын аска...

Бер тапкыр самолет аска төшмәде, өскә дә менмәде. Байтак вакыт болыт эченнән барды. Биредә болытның калынлыгы өч-дүрт километрга җитә иде, мессер эзләп табарлык түгел. Бар, болганчык судан чуртанны эзләп кара син!.. Ләкин, болытның мондый җире бик кечкенә

булып чыкты. Бераз баруга җәйге төндә уйсу җиргә җәелгән томан кебек юкарып калды болыт. Самолет аска чумды, тагын өскә калыкты...

Еласынмы хәзер Марат, әллә юкмы? Элек алар, шулай, әнисе белән автобуска утырып баралар-баралар иде дә, Марат көйсезләнә башласа, төшеп, икенче бер автобуска утырып, өйгә кайталар иде. Еласын әле, тәти апа белән өйгә кайтып китсеннәр әле. Әнисе дә торгандыр инде...

Ләкин монда күңеллерәк түгелме соң? Ай, йолдызлар. Ничек күп үзләре!.. Әнә теге самолеттан болайга таба әтисенең язу өстәлендәге кызыл карандашы шикелле озынча утлар оча, безнең самолеттан аңа таба да шундый «карандаш»лар очып тора. Өстәвенә тәти апаның чемоданында тәмле мәмиләр бик күп. Сорадың исә, ала да бирә, ала да бирә. Тагын ничек җылы монда!.. Өйдә әни, ни өчендер, гел ятып торырга куша. Аннары Марат ул кәбестә шулпасын бик үк өнәп тә бетерми. Җитмәсә үзен ерак барып алырга кирәк, чират торатора туңып бетәсең... Юк, еламасын әле, өйгә кайтмасыннар әле, монда күңеллерәк...

Шул рәвешчә бара торгач, көнчыгыштан, Зөһрә кызлы тулган айның як-ягыннан «Акчарлак» чакырткан совет истребительләре килеп чыкты. Истребительләр бомба ташларга чамалап ИЛ-2 өстенә үрмәләгән Мессершмитны куып алып киттеләр.

Кешеләр моны күреп шатланырга, берсен-берсе кочарга, оста маневрлар ясап, туктаусыз ут төкертеп үзләрен һәлакәттән алып калган летчик белән яралы пулеметчыга рәхмәтләр әйтергә тотындылар.

Инде куркыныч бетте. Шулай да кешеләр парашютларын салмадылар әле. Самолет болыт астына төшеп Мәскәүгә таба юл алгач, түгәрәкләнеп, табын булып утырдылар да кемдә нәрсә бар, бүлешеп, ашап-эчеп алдылар.

Ярый әле, «икенче автобуска утырып» өйгә кайтып китмәде, Маратка тагын күңелле булды. Ул табында иң кадерле кунак иде. Ярасын бәйләткәне, терелткән өчен дигән булып, ә бәйләтеп өлгермәгәне, снаряд тисә, минекен дә бәйләрсең дигән булып, Маратны кемдә нәрсә бар шуның белән сыйладылар. Юк, Маратның эшләре көйле монда!..

Шулай да, табын җыелып, кешеләрнең күбесе утыр-

ган килеш (бигрәк сәер инде: утырган килеш) йоклап киткәч, тәти апа да Маратны алдына алган килеш черем итә башлагач, хәтта санитарка да, башын сумкасына төртеп, күзләрен йомгач, йолдызлар белән ай болыт өстендә калгач, ут көлтәләре, кызыл «карандаш»лар очмый башлагач, Маратка кызык бетте. Тагын әнисе исенә төште аның.

Бер тапкыр Марат үзеннән әз генә калку бер кыз белән магазин витриналарындагы әйберләрне, уенчыкларны карап йөри-йөри әллә нинди ят урамга барып чыгып адашканнар иде. Бик озак адашып йөрделәр алар ул кыз белән... Кич булды, караңгы төште. Эзләп килеп тапканда, әнисенең елый-елый күзләре шешенеп беткән иде. Шул вакыйга исенә төшеп, Марат шыңшый башлады.

— Тәти апа, өйгә кайтыйк. Тәти апа, өйгә кайтыйк...— диде.

Һәм, әнисенә ошатырга тырышып, елаган булды.

— Әнием елый инде менә. Әй балам, балам, әйтә дә елый...

Малай шәл чите белән, әнисе шикелле итеп, күз төпләрен сөрткән булды, гүя ул — әнисе, ә Гөлсем апа — Марат, аны кочып үпкән булды.

Йокыга китәр-китмәс яткан пассажирлар, баланы кызгансалар да, башларын күтәреп елмаешып куйдылар. Пилот та, Маратның кыяфәтен кабинадагы көзгедә күреп, көлеп җибәрде. Гөлсем апа баланы беләгенә салып тирбәтә-тирбәтә юатырга кереште:

— Йокла, акыллым, йокла! Әниең еламый синең хәзер. Ул әле тормаган. Бик-бик озак йоклый ул бу юлы... Син дә йокла. Без әле синең белән озак, озак барабыз. Анда балалар бик күп, тәмле мәмиләр бик күп... уенчыклар бик күп...

— Әнигә мәми алып кайтабыз...

— Әйе, әниеңә мәми алып кайтабыз.

— Утын...

— Әйе, утын да алып кайтабыз.

— Әнием мич яга, әтием кайта...

Гөлсем апа артык түзеп тора алмады, башын бер якка борып, елап җибәрде.

Таң атты. Болытлар, Ленинград томаны артта калды. Көнчыгышта күк чите алланды. Нәкъ көнчыгышка

карап очкан самолет кабинасының тәрәзәсендә кояшның беренче нурлары уйнады. Аста кар урамлы, кар түбәле җиргә сеңгән авыллар, дилбегәдәй нечкә тимер юллар, Маратның уенчык паровозы хәтле генә кечкенә паровозлар, аңар тагылган кызыл тартма — вагоннар күренде, кар туздырып, буран уйнатып фронт ягына танклар, машиналар узды.

Менә безнең ИЛ-2 не һәлакәттән коткарып калган истребительләр килеп җитте. Алар әлеге Мессершмитны уртага кысканнар, ычкыныр әмәле юк иде.

Марат боларның берсен дә күрмәде. Тамак тук, җылы, рәхәт тирбәтә... Ул Гөлсем апаның алдында изелеп йоклый һәм бик күңелле төш күрә: әнисенең кровате янына тезләнгән дә апың итәгенә үз кесәсеннән берсеннән-берсе тәмле мәмиләр бушатып тора һәм, «ә мин ашадым инде, боларын сиңа алып кайттым» дип сөйләнә иде.

3 ӨЧЕНЧЕҢ БЕЛӘН КОТЛЫЙМ

Укучы хикәянең бу бүлегендә Маратны Мәскәүдәге берәр балалар йортында очратса, бик табигый булыр иде. Юк шул, язмыш дулкыннары аны бөтенләй икенче бер ярга кагып чыгарды. Әнисез калуына нибары бер тәүлек дигәндә, Марат инде Ленинградтан да, Мәскәүдән дә әллә кайда еракта, Казан шәһәрендә, Казанның Ягедни бистәсендә иде. Ә бер ай дигәндә тәмам ныгып житкән, йөзендә үлем шәүләсенең әсәре дә калмаган, рәхәтләнеп урамда уйнап йөри иде.

Әнә ул! Терәкле кечкенә чанасына кемдер зур эт җигеп биргән. Марат этне чыбык белән куа, ә эт тыңламый. Тыңлар да иде, җигеп өйрәтелгән эт ул, Маратның кулында эт күңелен аздыра торган әйбер бар — исе авыздан сулар китерә торган юан колбаса телеме... Менә эт, ялт борылып, Маратны чанасыннан төртеп төшереп карда ауната башлый. Үзе шаярып кына аунатa кебек, өрми, тешләми. Ә үзе гел колбасаны эләктереп алырга чамалый. Марат исә этнең күңелен аңламый, үзенчә нидер әйтә-әйтә шыңшып, колбасалы кулы белән дә, чыбыклысы белән дә, аяклары белән дә эткә каршы торып маташа.

— Посол, Аблек, посол!..

Эт, аның саен очыныбрак китеп, баланы тинтерәтә, ә читтән карап торган малайлар, аның саен хозур күреп, шарык-шарык көлешәләр.

...Әш шунда ки, Гөлсем апаның Мәскәүдә Маратны балалар йортына илтеп йөрергә вакыты булмады. Самолет, моторын да сүндереп тормастан, хәрби кешеләрне, яралы солдатларны төшереп калдырды да шунда ук Казанга очты. Бу инде Кызыл гаскәрнең Гитлер яуларын Мәскәү капкасы төбеннән куып җибәргән көннәре иде. Башкаланы дәһшәтле сугыш күкрәве дерелдәтми, канонадалар тынган, сугыш җәһәннәменең көйдергеч ялкыны башкала күгендәге соры болытларда чагылмый иде. Ләкин бу — дошманның шәһәрләр шәһәрен басып алудан гайрәте кайткан дигән сүз түгел иде әле. Киресенчә, котырган эт, бер сыйрагын бәреп сындыргач, тагын да ярсыбрак һөҗүм итте. Үз чиратында Мәскәү дә, уяулыгын киметмичә, киеренкелеген өз генә дә йомшартмыйча, дошманны һәр сәгать, һәр минут лаеклы каршыларга хәзер тора иде. Корыч броняга киенде Мәскәү! Шәһәр читләрендә, завод-фабрика ишек алларында озын көпшәләре күккә сузылган зениткалар урман булып үсте. Самолет тәрәзәсеннән карап барган Гөлсем апага төнлә Мәскәү өстен каплап алачак һава шарлары күренеп калды. Горький, Петровка урамнары буйлап шәһәрнең көнбатыш читенә таба төркем-төркем танклар узганы, соры шинельле, тимер каскалы, корыч автоматлы Кызыл гаскәрләр узганы; тротуар читләрендә ике яклап тезелеп киткән рельс загражденеиләрне саклап торучы часовойлар күренеп калды. Боерык булу белән бу заграждениеләр юлга аркылы борып куелачак, һәм... Ай, кая китте, кая китте синең тыныч, көнен-төнен күңелле шау-шулы чакларың, кышын-җәен матур чакларың, Мәскәү! Әллә бу син түгелме?.. Чыннан да, ул Гөлсем апа күреп белгән, кинофильмнар, рәсемнәр аша таныш булган, сугышка кадәрге Мәскәү түгел иде. Дөрес, болай барысы да үз урынында иде аның, бөтенесе үз: Кремле, Кызыл мәйданы, Союзлар йорты, Зур театры, вокзаллары, киң урамнары үз урынында. Ләкин алар барысы да ничектер моңлы, сагышлы кебек. Трамвай, троллейбуслар йөрми урам тутырып, машиналар, автобуслар бик сирәк. Бөтен тереклек җир астына, тирән метроларга күчкән. Көн-төн шау-гөр килеп торган магазин, ресторан, кинотеатрларның ишекләрендә аркы-

лы-торкылы такта, зур тәрәзәләрендә такта яки әрдәнәләп өелгән ком капчыклары. Түбәләрдә, урам чатларында курку белмәс ПВХО дружиначылары шәһәрне ут-күздән саклый... Бер борынгы Кремль генә үзенең горур мәһабәтлеген югалтмаган. Ахак йолдызларында, җиз гөмбәзләрендә иртәнге кояш нурлары уйный. Туппатша, Патша-кыңгырау, киртләч башлы кирпеч ихаталар, ихата читләрендәге манаралар... Ләкин, алар да сагышлы, моңлы бүген. Ил тәнендәге тирән ярадан алар да әрнешә кебек, Ленинын вакытлыча ерак тылга озаткан ятим Мавзолей әрни кебек, мәрмәр стеналарындагы ак бәс — аның бозланып каткан күз яше кебек...

Шуңа күрә Гөлсем апа Маратны Мәскәүдә балалар йортына илтеп тапшыра алмаганына бер дә үкенмәде. «Бигрәк яхшы. Балалар йорты Казанда бар ич. Анда балага тынычрак та, иркенрәк тә булыр. Бигрәк яхшы...»

Ул, самолет Казан аэропортына килеп төшүгә, Мәскәү белән Ленинград арасында йоклап киткәннән бирле селкенеп тә карамаган Маратны уятып җитәкләде дә ашыктыра-ашыктыра шәһәр буйлап алып китте.

Марат өчен исә Казаны да Ленинград иде. Әле бу сабыйга бөтен дөнья бер Ленинградтан, аның да үзе күргән өлешеннән гыйбарәт иде. Ул трамвайдан төшкәч тә, як-якка каранып, үз өйләрен эзләргә тотынды һәм Нариман урамына килеп керүгә, Гөлсем апаны матур гына тимер балконлы йортка таба өстерәде.

— Тәти апа, өйгә келик.

— Бу сезнең өй түгел ич, Марат.

— Безнеке. Ә-әнә безнең тәрәзә.— Марат пыялаларына аркылы-торкылы кәгазь ленталар ябыштырылган тәрәзәне күрсәтте һәм үз тәрәзәләренең бер бомбежка вакытында чылтырап коелганын, шуннан яңаны куйдыргач, әнисенең ана кәгазь ленталар ябыштырып чыкканын сөйләп бирде.

— Өйгә келик...

Сабый бу йорттан бик күп ФЗӨ балалары шаулашып килеп чыккач кына тынычланды. Ә бераз баргач, Гөлсем ападан ычкынды да тротуарның икенче ягыннан узып барган бер хатын артыннан йөгереп китте.

— Әнием, әнием!..

Сабый шунда ук әрле-бирле йөреп торган атлар, грузовиклар арасында калды. Гөлсем апа, ачы кычкырып,

бала артыннан ташланды — «чыр-рр...» — Милиционерның тревогалы итеп сыбызгы сызгыртуына хәрәкәт шып туктады. Ә Марат, берничә белән дә хисаплашмастан, «әнием, әнием!» дип, машиналар, атлар арасыннан йөгерә иде. Гөлсем апа, куып җитеп, Маратны тотып алды. Марат исә, ычкынырга тырышып, «әнисе»нә таба өстерәлде.

— Әниең түгел ул, ускәнем. Әйттем бит мин сиңа, әниең янына бик-бик озак йөргәч кенә кайтабыз, өегез җылынгач, мәмиләр пешкәч, әтиең сугыштан кайткач...

Марат аның саен катырак елады, Гөлсем ападан ычкынырга теләп тартылды. Гөлсем апа сабыйны үз иркенә куймый булдыра алмады. Сабый, йөгереп барып, «әнисенең» итәгенә ябышты:

— Әнием-м!..

Чыннан да хатын буе-сыны белән дә, кием-салымы белән дә Марат әнисенә охшаган иде. Ләкин, хатынның гаҗәпләнеп борылып каравына, Марат үзенең ялгышканын аңлап алды һәм, ят апаның итәгенә ябышкан килеш:

— Әнием кайда-а? — дип елап җибәрде.

Ят хатын өчен бу бер кызык кына иде, ә Гөлсем апаның күзләренә яшь килде. Ул ятимне юата-юата күтәреп алды да, авыр булса да кулыннан төшермичә, балалар йортына кадәр күтәреп барды.

Ләкин Маратны яше җитми дип, балалар йортына алмадылар. Гөлсем апа, күңелсезләнеп, «гел кире килеп тора...» дип көрсенеп куйды. Шулай да рухын төшермәде ул, шундагы хезмәткәрләрнең киңәше буенча, Маратны вокзалга күтәреп китте.

Юк, үзләреннән чыгарып җибәрер өчен генә әйтмәгәннәр икән: анда ятим калган кече яшьтәге балаларны тимер юл буйлап җыеп йөрүче күчмә балалар бакчасы килгән икән.

Гөлсем апа аны эрактан ук таныды. Биш-алты пассажир вагоныннан торган бу бакчаның тышы бәхетле балачак рәсемнәре, яңа өзелгән яшел чыршы ботаклары белән бизәлгән булып, хәзер кечерәк кенә бер паровоз аны урыннан урынга күчереп йөртә иде.

Гөлсем апа бакчаның туктаганын көтеп торды һәм, паровоз запас юлдагы озын гына бер эшелон койрыгына китереп туктаткач, шунда ашыкты.

Вагоннарның эче, заманына күрә, ярыйсы ук яхшы бизәлгән, утыргычлары алынып, ян яннарына, санпоездлардагы кебек, носилкалар беркетелгән, идәннәрендә кыйммәтле паласлар, стеналарда балаларның үз куллары белән үрелгән ылыс веноклар, тәрәзә төпләрендә хәтта кышкы гөлләргә кадәр бар; тик алар, 1941 нче елның рәхимсез суыгына түзә алмыйча, сулып төшкәннәр иде. Вагонның урта бер җирендә тимер мич. Ул ут булып кызган, әйләнә-тирәсенә сырышкан Марат яшендәге һәм аңардан чак калку балалар, тын калып, мич өстендәге кәбестә шулпасының исенә төкерекләрен йотып утыралар, корымлы кастрюльгә ашаган саен боткасы ишәя барган тылсымлы казанга караган кебек карап торалар иде.

Гөлсем апа тынычланып китте. «Юкка борчылганмын, баланың бәхете шушында икән...» дип сөйләнеп алды ул үз-үзенә. Ләкин дежурный сестра бер дә алай җанга җылы сүз әйтмәде.

— Андый булгач, сыйдырырга тырышырбыз инде,— диде сестра.— Ләкин бик тыгыз, ханым. Безнең урын 160 балалык, биредә инде 200 дән артып китте. Яшерен-батырын түгел: урын-җир житешми, күбесен ылыс җәеп идәндә яткырабыз, ашау-эчү ягы да, үзегез күреп торасыз...

«Алыгыз гына... Бала ылысына да, кәбестә шулпасына да риза булачак. Һәрхәлдә, Ленинград түгел инде...»— Гөлсем апа хәзер, берәр сәбәбе чыгып, баланы алмый калуларыннан курыкты. Шул ук вакытта, нигә икәнен үзе дә төшенмәстән, алмаска сәбәп табылуын, берәр тоткарлык килеп чыгуын теләде. Ә андый сәбәп килеп чыккач (ни булды соң сиңа, Гөлсем апа?), һәрвакыт тыныч, һәрвакыт сабыр табигатьле укытучы какшау нервлы бәйләнчек хатыннарча кызып китә иде. Ул, бакча мөдиреннән, «Ә санобработка язуы юкмыни?» диюенә каршы, «юк иде шул»,— дип кенә җавап кайтарасы урында, «һичбер эш волокитасыз гына булмый...» дип сукранып куйды.

Болай дигәч, мөдир дә үҗәтләнде:

— Әйе, булмый,— диде ул.— Әнә мәйдан аша гына чыгасы. Бевенче май урамы, йорт № 5.

— Соң бит сез биредә аңарчы тормассыз?

— Бүген китмибез әле.

Гөлсем апа тагы волокита турында әйтеп тиргәнде,

шул ук вакытта мөдирнең волокитасы нәрсәсе беләндер аны тынычландырып җибәрде. Ул, әз генә дә каршылык күрсәтмичә, Маратны мунчага, санобработкага алып керде. Санобработка дигәннәре яхшы ният белән башланган, ләкин тора-бара бик формаль нәрсәгә әйләнгән сугыш елларының бер бәласе иде. Баланың шактый керләнгән күлмәк якасына пиретрум сиптеләр дә санобработка үтте дигән әзер кәгазь кисәге тоттырдылар. Шуның өчен болай да эштән чыгып арыган Гөлсем апага никадәр җир килергә, ни гомер чират торырга кирәк булды!

Гөлсем апа тагын кызып китте. Ул, баланың муенындагы керне күргәч, килгән-килгән, чишендереп юыну бүлмәсенә алып керде. Колак артлары, арык муены шалкан чәчәрлек булып керләнгән иде сабыйның. Бот, беләзек буынтыкларында да укмаш-укмаш кер иде. Юа торгач, ләгәндәге су куе-көрән төскә керде, ә баланың арык тәне алсуланып, йөзе тагын да сөйкемләләнеп китте. Гөлсем апа аңа үзенең ак кофточкасын киертеп, шәленә төреп күтәрде дә тагын вокзалга, күчмә бакчага алып килде.

Инде бәйләнер нәрсәләре бетте бугай. Гөлсем апа бакча ишеге төбендәге пиндидер продукттан бушаган бер ящик өстенә килеп утырды. Ләкин мөдир, санобработка язуын алып, чукмар башлы инә белән Маратның документлары янына теркәп куйгач, «менә хәзер булды, секретарь керсен дә, оформить итәрбез» дигәч,— кыскасы, бала белән аерылышу реаль төс алгач,— Гөлсем апа бөтенләй алмашынып китте. Сагайды ул. Ә ак халатлы бер хатын кереп: «Я, Ленинград егете, хәзер инде син безнең Урал егете буласың», дигәч, «Нигә соң болар тагын берәр бәйләнерлек сәбәп тапмыйлар?» — дип уйлап алды.

Әйтмәсә дә күренеп тора, Гөлсем апаның Марат янында озаграк торасы, аңа озаклабрак карап каласы килә иде. «Әллә бүген үземә алып кайтып кундырыйм микән, берәр пар күлмәк-штан да әмәлләп алырмын, иртәгә иртүк китереп китәргә була ич...» дигән уй да килде аның башына.

Ә ак халатлы хатын ашыктырды. Ул:

— Әйдә, иркәм, аш пеште, хәзер аш ашыйбыз,— дип Маратка кулларын сузды.

Марат, ятсынып, Гөлсем апага сыенды, әле һаман

мунча җылысы чыгып бетмәгән арык куллары белән аның муенын кочып алды. Гөлсем апа сабыйны битләреннән сыйпап үпте дә, аерылышканда була торганча хискә бирелеп китүдән куркып, тиз генә ак халатлы хатынга бирде:

— Аерым алып тәрбияләгез, зинһар. Кешегә ни—аңар шул булыр. Шулай да әтисе хакына, әнисе хакына...

Нинди сөйкемле алсу йөзе дәррәү сулып китте Гөлсем апаның, иреннәреннән кан качты. Төз, кечкенә гәүдәсе тагы да кечерәебрәк киткән кебек булды.

— Беләсезме, аның әнисе... әтисе тагын...

Гөлсем апаның теле бәйләнде. Ак халатлы хатын дулкынланганын яшерергә тырышып әйтелгән бу сүзләрдән ана бала белән аерылышу читен икәнен аңлады. Шуңа күрә Маратны күрше вагонга тиз генә алып чыгып китмәде, кенәгәләр, кәгазьләр белән тулы өстәл өстенә утыртты да, үзенең баш тарагын алып, аның чәчләрен тарап торган булды. Гөлсем апа тыныч калсын өчендер инде, бала белән аеруча ягымлы мөгамәләдә булды. Аннары, Маратны җитәкләде дә: «Әйдә, инде әниең янына кайтыйк», дигән булып, икенче вагонга алып кереп китә башлады.

Марат, куркып, Гөлсем апага таба тартылды:

— Әем, мин тәти апа белән...

— Тәти апаң сезнең кайда торганны белми, мин беләм. Хәзер кайтып җитәбез...

Сабый тынычлана төште:

— Әниемә мәми алып кайтабыз.

— Әйе, әниеңә мәмиләр алып кайтабыз.

— Утын...

— Әйе, утын да алып кайтабыз.

— Хуш, тәти апа.

— Хуш, Марат, хуш, җаным. Акыллы бул, яме?

— Я.

— Бәхетле бул, матурым, дәү үс, ике күзем.

— Син дә дәү үс, тәти апа.

Ак халатлы хатын, ишекне ачарга торган җиреннән туктап, көлеп җибәрде, Гөлсем апа да елмайды. Ләкин ул, ак халатлы хатын шикелле, кызык булганга күрә генә елмаймады. Маратның соңгы сүзе Гөлсем апага мөлдерәмә стаканны ташыткан тамчыдай тәэсир итте. Бу сүз Гөлсем апада балага карата үзе дә сизмәстән өлгереп килгән мәхәббәтнең, алмагач чәчәге кебек ачы-

лып китүенә сәбәп булды. Бу сүз, шушы бер сүз, Маратның язмышын хәл итте. Ак халатлы хатын белән Марат артыннан ишек ябылуга, Гөлсем апага кинәт, вагон эче генә түгел, йөрәге дә бушап калган кебек булды. Чамасыз ямансу иде хәзер аңа. Ул (аныңча, бу бердәнбер дөрес карар иде, башкача булу һич мөмкин түгел иде) Марат артыннан йөгереп чыкты. Һәм, тамбурда ук куып җитеп, ак халатлы хатынның беләгеннән тотты:

— Гафу итегез, ханым, бала бүгенгә миндә кунсын әле. Иртә белән китереп китәрмен.

— Күрәм, сез нәрсәнедер әйтеп бетермисез?

Гөлсем апа баланы кулына алды:

— Беләсезме нәрсә, мин баланы үземдә калдырырга булдым.

— Бөтенләйгә.

— Мәңгегә.

Ак халатлы хатын, Гөлсем апаны ихтирам итеп, шул ук вакытта кызганып:

— Ах, балагыз юкмыни? — диде.

— Юк...— диде Гөлсем апа һәм Маратны күкрәгенә кысты.

— М-да-а. Ну что же. Беренчегез белән тәбрик итәм, ханым.

— Рәхмәт.

— Баланы үз тәрбиягезгә алып, аның урынын башка бер ятимгә калдыруыгыз өчен мең рәхмәт сезгә. Их, их... Мондыйлар илдә бик күп шул бүген... Рәхмәт, олы җан!

— Ну, что сез...

— Тыйнаклык — күркәм сыйфат, әлбәттә. Ләкин... яшерен-батырын түгел, үз баласыннан баш тартучылар да очрый әле бездә. Бик очрый.

— Беләсезме нәрсә, мин сезгә ялганладым: минем үземнекеләр дә икәү.

— Димәк, шаярттыгыз?

Гөлсем апа, әйтерсең, бик гади мәсьәләне хәл итә иде, шулай тыныч итеп, дөресрәге, тыныч күренергә тырышып болай диде:

— Юк, нишләп? Өч булсын.

Ак халатлы хатынның пенснэсе, борыныннан ычкынып, кара тасмасында асылынып калды. Ул аны яңадан борынына утыртып куйды да, ни әйтергә дә белмичә,

Гөлсем апага шикләнә төшеп карап куйды. «Әллә кырыкка бер тулмый микән моның?..» — диде ул. Ә инде Гөлсем апаның «өч булсын» дигәндә күзләре очкынланып киткәч, бөтен гәүдәсе, хәтта матур иреннәре, нәфис нечкә бармак очлары җиңелчә калтыранып куйгач, Гөлсем апага сокланып, аның өчен горурланып карап торды:

— Сез олы жан, олы жан сез, ханым...

Марат исә бу сүзләрнең, бу кичерешләрнең мәгънәсенә, үзенең кулдан кулга күчеп йөрүенең серенә төшенмәсә дә, Гөлсем апаның ниндидер яхшы нәрсә ниятләгәнен сизенеп, аның муенына сарылды. Гөлсем апа, өстәл хезмәтен үтәүче ящик өстенә иелеп, Маратны исемлеккә теркәп торган секретарьдан баланың документларын, кыйммәтле әйберләрен, дулкынлануы белән үзе дә сизмәстән, тулас итеп тартып алды да, вагондагылар белән саубуллашырга да онытып, кабаланып, ишектән чыгып китте. Һәм, әйтерсең, куып килеп, баланы алып калулары мөмкин иде, турыдан, вагон асларыннан үтеп чыгып, шпаллар, рельслар аша абына-сөртенә вокзалга таба атлады.

Шулай да, акыллы адым идеме соң бу? Әллә хис дигән нәрсәгә артык бирелеп китеп, акыл чыгып торган чакларда була торган бер кабынып китү генә идеме?

Гөлсем апаның үз хәленә күз салсаң, бары соңгысын уйларга мөмкин иде. Берсеннән-берсе кечкенә ике баласы булу өстенә, ире сугышның беренче көннәреннән бирле фронтта йөри, үзе исә бер башлангыч мәктәптә укыта һәм читтән торып педагогия институтында укый. Шуның өстенә квартирасы да шәптән түгел, Ягедидәге авылча кара-каршы салынган кыйшык-мыйшык бер өй кисәгенең ярты ягыннан гыйбарәт иде.

Гөлсем апа Маратны вагон-бакчадан кире алып чыгып киткәндә үзенең шушы хәле турында тирән уйламады, дөресрәге, уйламаска тырышты. Ул бу вакытта, авыр елларда, бик тыйнак шартларда яшәп тә, җиде бала алып үстергән изге хатын Пфлаумер ханым турында уйлады.

«...Ә шулай да, ирем риза булмаса?.. Юк, булыр... Ә менә булмаса? Үзебезнекеләргә дә тәрбия җитми ич дисә? Юк, әйтмәс... Юк, шулай да, әйтсә?..»

Гөлсем апа, шул ук көнне барысын да әйтеп, иренә хат язды. Белеп шикләнгән икән, Мостафа абый, нәр-

сәгәдер бик эче пошып, блиндаж авызында башын тотып утыра иде, укыды да: «Менә исәр, вәт исәр!..» — дип тиргәнеп куйды. Хатны башка вакытлардагы кебек котомкасындагы «Корыч ничек чыныкты» эченә салып тормады, саксыз гына койкасына ташлады, «менә исәр, вәт исәр!..» диде ул тагын бер һәм куен дәфтәрен тезенә куйды да үзенең риза түгеллеген әйтеп хат язды. Ләкин Гөлсем апа туктамады. Ул тормыштан бик күп мисаллар китереп, Пфлаумер ханым белән чагыштырганда монын «чүп тә тормый торган эш» икәнен әйтеп, ниһаять, үзенең балага иялэнеп беткәнен аңлатып язып салды. Ә монысына җавап озак килми торгач, шикләнә калды. Бу нәрсә? Әллә үпкәләттемме? Әллә үзенә берәр хәл булдымы? Юк, юк...

...Маратның эткә ингегеп кычкырганын ишеткәндә, Гөлсем апа яңа гына мәктәптән кайтып кергән һәм кырыкмаса-кырыгынчы тапкыр шул турыда борчылып, өстен чишенеп тора иде.

Ул, Марат тавышына сискәнеп, тиз генә тәрәзәгә килде. Ләкин Мараттан алда аның күзенә юл аша чыгып килгән карт почтальон күренде. Гөлсем апа, ачык форточкадан башын тышка сузып, эндәште:

— Мәхмүт агай, әллә бармы?

Почтальон карт елмаеп ияк кагуга тиз генә иңнәренә шәлен салып, каршысына йөгереп чыкты. Аны капка төбендә туктатып, калтыранган куллары белән өчпочмаклы хатны алды һәм, өенә дә кереп тормады, шунда ук сүтеп укый башлады. Юк, ул укымады, иренең исәнсау икәнен белгәч тә, аның тормыш-көнкүрешләренә тукталып тормастан, үзен борчыган сорауга җавап эзләде.

«...Сәер тоелды, әлбәттә, ай-яй...— дигән иде Гөлсем апаның Мостафасы.— Берәр җилбәзәк нәрсә булсаң, бу нишләвең инде тагын, дими калмас идем, әлбәттә. Ләкин син андый түгел, уйламыйча эшләмәгәнсең әле... Кыскасы, өченчең белән тәбрик итәм. Төкле аягы белән!.. Дөресен әйткәндә, без инде кичә аның исәнлегенә Ногман дус белән борын башына йөз иллешәрне төшереп тә алдык. Старшина да хәерлегә юрады әле: шул көнне, разведкага барып, ике «тел» алып кайттык. Берсе бик важный птица, малай, эсэсчы полковник...»

Гөлсем апа бу юлларны йөгереп үтте дә, шатлыгыннан нишләргә белмичә, бер өенә, бер урамга омтылды

һәм, хатны баш очында тотып селки-селки, капкадан атылып чыкты.

Ул башта этне куып җибәрде:

— Пошшол, пошол, Абрек!..

Аннан Марат каршысына чүгәләде дә аның учындагы инде эт өзгәләп бетергән колбасаны алып ташлады һәм, аның күгәрчен тәпиедәй булып кызарган нәни кулларын җылыта-җылыта, тирән дулкынланып:

— Улым, әйдә, кер, әтиеңнән хат килде ич,— диде.

Бу Гөлсем апаның Маратка беренче тапкыр улым дип эндәшүе иде.

4 АНСАТ БУЛМАС, АХРЫСЫ...

Гөлсем апа иреннән җавап хаты көткән арада, балалар йортына илтеп бирергә туры килсә дип, Маратны үз балаларына да, күршеләренә дә, сеңелем улы, Мәскәүдән алып кайттым, дип йөргән иде.— «Үзе заводта, кайтмый әшли. Калдырыр кешесе юк...»

Ә соңгы хат килгәч, кичен балалары җыелып, сөенеч чәйләре эчелгәч, дөресен әйтеп бирде. Һәм:

— Я, ни диярсез икән, Айтуган токымнары? Марат сезнең бертуган энегез булды бит инде...— диде.

Гөлсем апаның Саниясе (сокланырлык сабыр табигатьле кыз) бу хәбәрне ишеткәч тыелып кала алмады, кинәт җитез хәрәкәтләр ясап, селкенеп куйды. Курчагының итәк очын Мияубикә пычратканга кайгырып утыра иде, ыктырып китте. Дөрес, яңа алты тулып килгән кызчык семьядагы бу үзгәрешнең мәгънәсенә төшенеп бетми иде әле. Ул әнисе сүзләреннән Маратның моннан болай гел үзләрендә торасын гына аңлады. Хәер, аның өчен кирәге дә шул гына иде. Әнисе көнозын мәктәптә, Илдар абыйсы да бер өйдә тормый, укудан кайта да уйнарга чыгып чаба... Чаба бирсен! Инде хәзер Саниянең үз иптәше булды!.. Тик менә ул Сания белән уйнар микән соң?..

Кыз бала, уйга калып, әнисенә шундый сорау бирде. Ә уңай җавап алгач, кулларын чәбәкләп куйды:

— Әлләлеки, абыйга ялыныч бетте! Әлләлеки, абыйга ялыныч бетте!.. Әйдә, нәнәм, рәсем ясыйбыз.

— Әйдә.

— Әйдә, Сания апа, диген.

— Әйдә, Сания апа.

«Ә Сания исемле апалар буламы соң?..» Сания әнисенә беравык шикләнеп карап торды һәм, ипи кибетендәге апаның Сания исемле икәнен хәтерләп, тагын кулларын чәбәкләп куйды:

— Мин — апа, мин — апа!.. Син генә абый түгел, Илдар, мин дә апа, әлләлеки, мин — апа!..

Гөлсем апаның Илдары — әллә рәсем ясарга бер дә сәләте булмаганга, әллә сугыш чукмары буларак, маңгаенда шеш бетеп тормаганга, Шишкин кушаматы алган 9 яшьлек улы — яңалыкның мәгънәсенә тирәнрәк төшенде. Ул әтисенең ике «тел» эләктереп кайтуы турындагы юлларны тәмен бик белеп, кат-кат укып, иптәшләре арасында гына түгел, укытучысы алдында да дәрәҗәсенең үсеп китәчәге турында хыялланып утыра иде, кинәт житдиләнеп китте. Олыларча сагышланды ул. Башын олы кешеләрчә әкрен генә күтәрде. Күзләре әнисе күзләре белән очрашкач, гаепле вакытларындагы кебек уңайсызланып башын аска имәде, әнисенә хөкем итүчән кыяфәттә карап торды.

— Кара, ни булды сиңа, улым?

Инде малай күзгә-күз карап тора алмады, башын читкә борды.

— Әем, булмасын. Марат безнеке булмасын...

Марат, күзләрен Сания ясый башлаган рәсемнән алып, Гөлсем апага карады. Сания, ятимнең күңелсезләнгәнен күреп аны иңнәреннән кочып алды һәм, әллә инде әнисен Илдар ягына авар дип шикләнде, шыңшып куйды:

— Әйе менә... Булсын, әнием, булсын...

— Син кысылма яме, әбер-чебер!

— Әйе менә...

Илдар сикереп торды. Нидер әйтмәкче булып авызын ачты, әйтмәде. Сеңелесенә йодрык күрсәтте дә кире утырды.

— Сабыр, балалар. Илдар, тынычлан, акыллым.

— Нәкъ...— Сания, песи теле кебек кечкенә тел очын чыгарып, абыйсын үчекләп алды да иркәләнеп әнисенә сыенды. Әнисе, буш кулын җәеп, улын чакырды:

— Я, кил әле миңа, Илдар.

Илдар килмәде, турсайган авызын әз генә дә җыймыйча, табын яныннан торып ук китте.

Рәсем ясалып бетеп, әниләре «5» куйгач, Сания белән Марат йокларга яттылар. Илдар да ятты: уен белән

арып беткән малай бүтән көннәрдә мендәренә башын төртүгә изелеп кенә китә иде, бүген исә гел борчылып ятты. Гөлсем апа, иртәнге дәрескә әзерләнеп утырган җиреннән торып, аның янына килде:

— Йокла, улым, йокла, күз нурым. Юкка син...

— Әни...

Гөлсем апа улының кровать читенә утырды:

— Нәрсә, акыллым?

Илдар торды-торды да, әнисенең алдына капланып, үксеп елап җибәрде:

— Марат безнеке булмасы-ын...

Гөлсем апа, улының янына ятып, аның башын үз күкрәгенә күтәреп салды һәм маңгаенда гына калдырып машинка белән алынган чәчен сыйпый-сыйпый әйтте:

— Менә син болай ит әле: үзеңне Марат урынына куеп кара. Әтиең белән мин үлеп киттек, ди, ә Марат әнисе сине үзләренә ул итеп алып кайтты, ди...

— Әем, әем...

— Әлбәттә, әем. Ә шулай булса? Күз алдыңа китер әле: аның әти-әнисе исән, ә синекеләр...

Илдар, әнисен кочып алып, башын аның куенына тыкты.

— Әйтмә, әйтмә...

Марат хәзер Илдарга кызганыч булып китте. Ләкин ул әле әнисен, әнисенең мәхәббәтен Марат белән уртаклашырга һич тә риза түгел иде. Ул тагын шыңшып:

— Кирәкми, булмасы-ын,— диде.

Гөлсем апа улының тагын да нечкәрәк кылын тартып карарга булды. Ул, аның белән чыннан да килешкән кебек итеп:

— Ярый, алайса... Ләкин бүгенгә кунсын инде, таң аткач, чыгарып җибәрербез,— диде һәм Илдарның моннан берничә генә көн элек «Үги кыз» әкиятен укып утырганын хәтерләп,— яки үзең урманга илтеп адаштырырсың, дип өстәде.

Менә әйбәт була...

Әйе, шулай итсен әле. Малайлар белән ат-ат уйнаган булып, урманга алып барсын да чанасы белән чокырга вж!..— Илдар шулай уйлады һәм шундук бу уеннан кайтты:

— Әем, адаштырмыйк. Безнең урманда сихерче карчык юк.

— Ярар, чыгарып кына җибәрербез, алайса.

— Чыгармыйк.

Илдар бераз тынып торды. Әле генә, Марат уянсын, елап бетсен дип, юри каты кычкырып сөйләшкән малай, хәзер, киресенчә, аның йокысын бүлмәс өчен, пышылдап кына сөйләшә башлады. Авызын әнисенең колагына якын куеп:

— Түлке ул сине әни дип әйтмәсен, әем, әйтмәсен,— диде.

Ана, елмаеп, улының маңгай чәчен тузгытты.

— Я көнче дә соң син, Илдар!

— И син дә аны улым димә.

«Улым димә...» Гөлсем апа моңар каршы ни дип тә җавап бирмәде. Аның бу хакта үз уе, үз фикере бар иде, ләкин хәзергә бу турыда Илдарга бер сүз дә әйтмәде.

— Йокла, күз нурым, әйдә мин дә синең белән йоклыйм,— дип аның юрганы астына керде һәм кочып үбә-үбә:— Акыллым минем, курыкма, мин аңар сезнең авыздан өзеп алып бирмәм. Сезне кимсетә торган бернәрсә дә эшләмәм, тыныч бул, улым,— диде.

Илдар тынычлана төште. Әнисенең муенына сарылган хәлдә бик тиз йоклап та китте. Гөлсем апа үзе дә оеп китүдән ерак түгел иде инде, Илдарның төшендә, «ә касмакны мин барыбер аңар бирмим, үзем кырам», дигән сүзенә сискәнеп, күзләрен ачты.

— Илдар, Илдар!.. Бу кадәр көнчелек кайдан килде соң сиңа? — диде ул.— Аннары, бөрсеннән-берсенә күчеп балаларын карап чыкты. Өй шактый суык иде, юрганнары өстенә берәр иске-моски алып япты, мендәрләрен күпертеп салды. Аннары, эш өстәлендә өем-өем дәфтәр көтә иде, килеп утырды да кызыл карандашын кыйшык-мыйшык юллар өстендә йөртә башлады.

5 КҮРШЕНЕҢ НИНДИЕ ЮК

Иген кырларыбызда тыгыз башаклы алтын бодайлар арасында билчәннәр дә үсә әле. Элегрәк бик күп иде, хәзер алай ук түгел инде. Шик юк, тиздән бөтенләй бетәр. Ә менә кеше аңындагы билчән алай тиз генә бетмәс, ахрысы...

Гөлсем апаның асрамага бала алуын аек фикерле күршеләре мактап сөйләделәр. Карт-карчыклар, өенә кереп, рәхмәтләр әйтеп, һәркайсына бәхетле гомер теләп чыктылар.

— Ятимне сөендергәнең өчен игелек күр, бәбкәм.
— Шуның өчен сиңа миңе белән бирсен.
— Картаймыш көнеңдә ярдәмчең булсын.
— Мең яшә, кызым Гөлсем.

Күршеләр яхшы теләк белән генә калмадылар, ярдәм кулларын да суздылар. Берсе, Женечкабыз, әллә ничек, бик тиз үсеп китте, аягын кыса, дигән булып, өр-яңа итек кертеп бирде. Гөлсем апа никадәр баш тартса да, күрше хатын итекне кире алып чыкмады. Үзләре дә пенсия белән генә көн күрүче бер карт белән карчык, балалар китеп бетте, язга калса, үрә башлый дигән булып, бер чиләк бәрәңге күтәреп керделәр. Юк, юк... ни кыстасалар да, Гөлсем апа бәрәңгене алып калмады. Ләкин кичен мәктәптән кайтуына, бәрәңге камыш сумка белән аралыктагы агач чөйдә эленеп тора иде.

Әлбәттә, Гөлсем апаның бу фидакарь адымына обывательләрчә караучылар да аз булмады.

— Әллә тилергәнме ул хатын? Үзеңнекеләргә ничек житкерергә белми йөргән заманда...— дип башлады шундыйлардан берсе.

Моңа каршы икенчесе:

— Бер дә исең китмәсен, баланың әти-әнисеннән зур мөлкәт калгандыр әле, шуңа хуҗа булу өчен асрый торгандыр, тикмәгә түгелдер,— диде.

Бу гайбәтнең «дер»е бик тиз кисеп ташланды, аның урынына «Гөлсем малайның байлыгын Мәскәүдәге сеңелесенә калдырып торган икән, гомеренә дә бетәрлек түгел икән», дигән сүзләр өстәлде.

Капка аша гына торучы, сулга кәкрәеп каткан бер карчык, гайбәтченең дә гайбәтчесе булу өстенә, былтыр оныгын классында калдырган өчен Гөлсем апага ачу тотып йөри иде, гайбәткә тагы да кабахәтрәк төс бирде:

— Әйткәннәр иде лә аны, Мәскәүдәге бер тол кешегә чыгарга йөри икән, дигәннәр иде, бу шуның көчеге индс, алайса,— диде.

— Ә ире?

Андый кеше җавапка күршегә керми. Кәкре карчык:

— Әбәү, шуны да ишетмәдеңмени? Мостафасына әллә кайчан развод җибәрде ич инде,— дип куйды.

— Менә сиңа укытучы апа!..

— Оялмагач оялмас икән, җир бит.

Гайбәт куерганнан куера барып бөтен Ягеднигә таралып өлгерде. Ул, билгеле, Гөлсем апаның үзенә дә килеп ишетелде. Аны чыгаручының әлеге кәкре карчык икәнен дә белде ул. Ләкин гаебе булмагач, әллә ни исе китмәде. Карчык белән очрашканда берни булмаган кебек ягымлы исәнләшеп, түбәнчелек белән баш иеп уза торган булды. Бу хәл карчыкның ачуын кабартты. Ул Гөлсем апа артыннан:

— Юк, килеп җитмәгән әле чәнчелгәнгә, килеп җитмәгән...— дип мырылдап калды һәм изеп куйган камырына чүпрә өстәп җибәрде. Бер тапкыр, Илдарны урамда очратып:

— Кара, Гөлсем Илдары түгелме соң син? Абау, танырлыгың да калмаган, туп шикелле тәгәрәп йөри идең, чырага калгансың бит,— диде.— И аллам, әниегез бигрәк сансыз нәмәстә булып чыкты шул...

Икенче бер тапкыр, мичтән яңа гына чыккан бодай кабартмасы белән чәйләп утыра иде, малайның мәктәптән кайтып килгәнен күреп, тәрәзә шакып, өенә чакырып кертте. Башта ул:

«Әтиеңнән хат-хәбәр бармы? — дип сорашкан булды. Аннары өчаяктагы кайнар сары майга әйләндерә-әйләндерә манып, малайга бер кабартма сузды. Малай, бик тартынса да, түзмәде (ашыйсы бик килә иде шул), тәкатьсезләнеп, кабартмага үрелде.

Карчык:

— Аша, бәбкәм, аша, хәзер сезгә мондый ашлар бик үк эләкми дә торгандыр инде,— диде.

Илдар эндәшмәде.

Карчык дәвам итте:

— Ничек эләксен? Өчкә бүләсен дүрткә бүләсез шул хәзер, дүрткә...

Ә тагын бер тапкыр, инги чиратында торганда, Илдарны күрмәмешкә салышып, үзе кебек кәкрәеп килгән бер әбигә үзе чыгарган гайбәтне тагы да әшәкерәк төстә сөйләргә кереште...

— Әйтмә дә инде, Хөббелниса туганый,— диде тегесе.— Гыйфритти ирс, җәннәт кошлары кебек икс баласы була торып...

Илдар башын түбән иде.

...Әйе, ни әйтсәң дә күңелсезгә китте әле... Ничек кенә булмасын, аның өчен Марат бер терс хәсрәт кенә бит. Хөббелниса әби белеп әйтә: өчкә дигән бик озак

дүрткә бүленә (Маратка әллә ни гомер карточка бирми тордылар). Дөрес, эниләре, ул чак бер кашык артты дигән булып, чуенны тутырып пешерә иде. Ләкин, белмәс Илдар! Ул бит аны шул ук өч кешегә дигән әйбердән пешерә, ә куе күрсәтү өчен, өйрә булса, изелгәнче кайната, ботка булса сыек итә, әллә нәрсәләр салып күпертә иде... Дөрес, Илдарның да корсагы күперә, ләкин урамга чыгып берәр сәгать чаңгы шууга, Щукарь агай алашасы кебек, шиңеп кала иде... Хәзер Маратның карточкасы бар барын. Ләкин аның паегы күпме генә соң! Аннан энинең ул паекны алырга акчасы да булмый бит эле. Бурычка батып бетте инде эни. Теге матур шәлен дә бәйләми башлады, чыгарып сатмады микән әле...

Илдарның энисенә ачуы килде. Андый чакта шулай була бит ул, энисенең яхшы яклары онытылды, «начар»лары бер-бер артлы күз алдына килеп тезелделәр. Әллә кайчан әйткән иде бит инде, ул сатиннан сиңа җиңсез күлмәк белән трусик тегәрбез, дигән иде; ә үзе Маратка блузка тегеп киертте. Имеш, алмашына бернәрсәсе дә юк... Былтыр футбол тубы сорагач, киләсе язга алырбыз, дигән иде, яз җитеп бетте инде, ә туп күренми әле... Лагерьга путевка турында да телгә алмый. Элек кинога кергәч, ситросыз калдырмый иде; хәзер, ситро эчермәс өчен, фоэга юри икенче звонок булгач кына алып керә. Ә ситро акчасына Маратны... Ю-ук, Илдар өчен Марат бер тере хәсрәт кенә булды... Җитмәсә, син аның көен көйләп йөр... аңар тегене ясап бир, моны ясa... Кайда күргәндер, чанага эт җигеп, аны утыртып йөр тагын, чана шу аның белән кызлар шикелле... Ә Илдарның чаңгы шуасы килә... Сүзен дә аңлап булмый бит әле ул хәсрәтнең. «Нәрсә дисең?» — «Кал инде, кал...» — «Кайда калырга?..» Ә ул аның кар диюе икән...

Илдар күңеленнән Хөббелниса әби белән килеште. Энисенә бик, бик ачуы килде аның. Ә инде әби развод, Мәскәү кешесе... дия башлагач, гүя энисен урам буенча мыскыл итеп йөрергә алып чыктылар — кинәт үзгәреп китте.

Юк, энисен һаман элеккечә ярата икән, энисе бөтен эниләрдән әйбәт икән... Хәзер энисенә түгел, Хөббелниса әбигә ачуы килде. Аның беркөнге майлы кабартмалары бугазына кире килгән кебек булды. Һәм Илдар чират-

тан чыгып, башын беләгенә куйды да үксеп елап җибәрде:

— Түгел, минем әнием андый түгел...

Ә кәкре карчык тагын нидер ырылдый башлауга, Илдар үзен тотып тора алмыйча, аның каршысына йөгереп килде:

— Минем әнием андый түгел, түге-ел!..

Карчык, «тәүбә, тәүбә» диенеп, артка чигенде.

Ярсыган Илдар, күпме көткән чиратын ташлап, ипикүмәч алмыйча, өенә йөгерде, һәм кайтып керүенә, Сания белән бик дус, бик күңелле итеп курчак уйнап утырган Маратка ике-өч тапкыр сугып җибәрде:

— Э-е... Бар да синең аркада!..

Моңарчы кыйнау түгел, авыр сүз дә ишеткәне булмаган сабыйга беркайчан да булмаганча, күңелсез булып китте. Авыртмады, юк. Бераз гына авыртты да бетте. Ләкин Марат бу сугуның көчлеләрнең көчсезләрне җәберләү, өстеннәрнең түбәннәрне кимсетү икәнен инстинкт буенча төшенгән иде, Саниягә сыенып, елап җибәрде.

Сания, Маратны яклап, Илдарга ташланды. Кара әле син аны, гомер булмаган хәл бит! — Әле кизәнеп, әле этеп, әле чеметеп, абыйсын чигенергә мәҗбүр итте.

— Нигә тиясең син аңа, ә? Әнигә әйтим әле менә мин сине!..

Ләкин эш моның белән генә бетмәде. Гайбәтченең гайбәтенә илтифат итми йөрсәң, җене котыра. Кәкре карчык та икенче көнне, Илдар белән әнисенең бик тату сөйләшеп барганнарын күреп, нишләргә белмәде.

— Һаман җитмәгән икән әле чәнчелгәннәргә, җитмәгән икән...— дип калды ул алар артыннан. Һәм, үзе шикелле кара эчле бер кызы бар иде, шуңар кереп, Гөлсем апаның каенанасына хат яздыртты:

«...Теге вакыт киленебез бер придансыз килде дип йөргән идең. Алай хәттин ашып аһ орырлык булмаган икән ич... Күтәреп кайтып кергән иде, бөтен Ягедни шаккатты. Бер килеп күреп кит, хи-хи...»

Каенана кинаяне аңлады. Өненә таяк тыгып кышкы йокысыннан уятылган ана аю кебек тузгыды ул. Һәм шул ук көнне, бер барып дөньясының астын өскә китереп кайтырга дип, юлга чыкты. Әйе, ул, дөньяның

булмаса да, Ягеднинең астын өскә китермичә китми иде. Каенаналарның бик юашларыннан түгел иде ул. Ярый әле, бәхеткә каршы, станциядә үзләренең колхоз председательләре очрап, үзе белән кире алып кайтып китте. «Син тыгыла торган эш түгел, Гөлҗамал түти, ташла... Менә орлык бирделәр әле, шуңар сөен син. Чана юллары өзелгәнче ташып калырга кирәк булыр. Иртәгә башларсыз... Әйдә, бор тәртәңне...» Ләкин каенана чигенмәде, кайткач та, суганлап-борычлап, Мостафасына хат язды. «...Оялмаган да, күтәргән дә кайткан... Балаларыңа көн юк анда хәзер. Ябыгып беткәннәр, мескеннәрем. Өс-башлары тузып беткән... Мин тыгылмыйм, улым, үзең хөкем ит. Мина калса, олактыру яхшы булыр. Балаларны үзем карармын... Үз сөягем үземнән артмас».

Каенана Казанга баручы бер әшнәсе аркылы Илдар белән Саниягә дә әйтеп җибәрде: «Ә сез нәрсә карап торасыз? Елагыз, мәктәбегезгә барып әйтегез, әтиегезгә әйтеп языгыз. Көчегенә көн күрсәтмәгез юньсезнең...»

Эш болай зурга киткәч, Гөлсем апа уйга калды. Ул (күптән шулай кирәк булган икән) кәкре карчыкны райсоветка чакырттырды. Карчык райсоветка килүгә коелып төште һәм дөресен сөйләп бирде.

— Бар, кызыңны алып кил әле.

Карчык, укына-укына, кызын алып килде.

— Инде языгыз.

Карчык белән кызы райсовет председателе кабинетында Гөлсем апаның иренә һәм каенанасына, дөресен әйтеп, хат язып салырга мәҗбүр булдылар.

Ләкин гайбәт — сабын куыгы түгел, моның белән генә шартлап юкка чыкмады. Аннан карчык үзе дә тик ятмас әле... «Хөкем җирләренә йөртеп, болай мыскыл иттергән өчен берәр хәл эшләтми калмас...» — Хәзергә исә, койрыгы өзелгән елан кебек, куышына кереп посты.

6 ӘНИЕМНЕ САГЫНАМ

Марат, Гөлсем апага тиз ияләнсә дә, әнисен алай ансат оныта алмады. Дөрес, яңа бишкә чыккан сабый әнинең нәрсә икәнен белеп бетерми иде әле. Шулай да аның иң якын, иң кадерле кеше икәнен аңлый иде инде.

Ул, Ягедигә килеп тора башлагач, байтак вакытлар әнисен күрүне өмет итеп, гел тәрәзәдән карап утыр-

ды. Сания белән капка төбендә уйнап йөргәндә, берәр нәрсәсе белән әнисенә охшаган хатын-кыз узып барганны күрсә, әсәрләнә торган иде.

Бер тапкыр ул Сания белән автобус йөри торган урамга килеп чыкты. Бик шатланды Марат. Ничек шатланмасын! Аның әнисе өйдән гел автобуска утырып китә иде ич... Марат автобустан төшкән һәрбер хатын-кызны күзәтте. Бер апа төште автобустан, тагын бер. Берсе төште дә капка төпләренә кечкенә чана тартып чыккан кызчыгына эндәште. Кызчык, әнисен күреп, куана-куана йөгереп килде. «Ә мин тау шудым, Хәмит абый шуа торган җирдән... печтик тә курыкмадым, әнием...» Ана кызчыгын күтәреп алды.

Марат нәүмизләнде. Чаналы кызның әнисе килде, Маратның килмәде... Марат, бияләй очын тешләп, ана белән чаналы кыз артыннан карап калды. Ләкин өметен өзмәде.— «Әнә тагын бер автобус килә ич».

Әйе, бер, ике, өч, бик күп, бик күп автобус килде. Ләкин аларның берсе дә Маратның әнисен алып килмәде.

Сания Маратны өйгә алып кайта алмыйча алҗып бетте.

— Әни орышыр,— дип дә карады ул.— Бүген әни итле аш пешерә,— дип тә кызыктырып бакты, ахыр чиктә кулыннан тотып өстерәде.

— Хәзел, Сания апа, хәзел...

Сабый, бер белеп алгач, автобус остановкасына үзе генә дә килә торган булды. Ә бәлки аның әнисе монда төшми торгандыр, әнә тегендә-ә баргач төшәдер...

Бер килүендә ул артыннан эзләп килгән Саниянe үзе белән «әнә теге-е» остановкага барырга күндерде. Ләкин әнисе анысында да төшмәде.

Малай тагын үзен тынычландырды:

«Теге остановкада әнигә әз генә охшаган апа килде, монысында күп охшаган апа килде. Ә-әнә тегесендә бик-бик охшаган апа килә дә, аннан әнием килә...»

...Йөри торгач, кич булды, маскировкаланган Ягедни дөм-караңгылык эчендә калды. Балалар адаштылар. Ярый әле, бер белгән апа очрап өйләренә кайтарып куйды.

Әнисе өчен өзгәләнгәнен күреп, Гөлсем апа сабыйны үтә кызганды. Дөресен әйтеп бирсен микән әллә? — «Әниең үлде, син инде минем улым булдың...» — Юк,

юк... Гөлсем апа бу уен шунда ук башыннан чыгарып ташлады. Ул Маратны асрамага алган бер ятим бала итеп түгел, тумыштан үз баласы итеп үстерергә исәп итте бит. Гөлсем апа бу турыда Маратны вокзалдан алып кайтканда ук уйлап куйган иде инде. Мостафа абыйдан уңай җавап алгач, уен йөрәгенә беркетеп куйды. Бала үзенең үги икәнен белмичә үссен. Мине апа дип түгел, кызганганлыктан гына бала иткән *әни* дип түгел, *үз әнисе* дип белсен. Бары шулай гына, бары шулай гына мөмкин. Үсемлеккә кояш нурлары ничаклы кирәк булса, балага *үз анасының* мәхәббәте, *үз анасының* иркәләве шулчаклы ук кирәк. Шунсыз бала караңгы өйнең караңгы почмагында кояш нурларыннан мәхрүм үскән гөлчәчәк төсле боек булып үсәчәк. Туфрагын ничек кенә ашлама син аның, нинди генә матур банкаларга утыртма, боларның берсе дә кояшны алмаштыра алмый бит. Дөресен әйтсә (Гөлсем апа үзеннән белә), сабыйның рухы гомер-гомергә төшенке, күңеле китек булачак, гомер-гомергә ятимлеге турында уйлап әрнияччәк. Әйе, әйе, сабый өчен үз әнисен, үзенең ятим икәнен оныту күп мәртәбәләр хәерлерәк...

Гөлсем апа бу теләгенә ирешү өчен бөтенесен эшләде. Сания өчен борчылырга кирәк түгел иде, Илдарда ятимгә карата туганлык һәм мәхәббәт хисләре уятырга тырышты. Китапханәчегә әйтеп, Илдарга «Козета», «Золушка» кебек китаплар бирдертте. Үзе белән «Үги кыз» спектакленә алып барды. Пфлаумер ханым һәм аның асрамага алып үстергән жиде баласының ничек тату яшәүләре турында сөйләде. Гөлсем апа үз мисалында, әти-әнием юк, дип йөрүнең никадәр бәгырьне өзгәнен сөйләп бирде:

— ...Әни итегез, какмагыз сез аны... Уйламагыз да, мин сезне тагы да, тагы да күбрәк яратырмын...— диде ул.

Әнигә ышанмаска мөмкинме соң? Бигрәк тә Илдар белән Сания әнисенә?.. Ләкин менә бусын ничек аңларга? Ул елларда табында шикәр-мазар бик сирәк була иде. Чәйне күбесенчә «шулки» белән, ягъни бернәрсәсез эчәләр иде. Гөлсем апа, кайчандыр ун-унбиш конфет юнәтеп, үзенең мәктәптәге өстәл тартмасына бикләп куйды да, көн саен берәрне алып кайтып, Маратка биреп барды.— «Мә, апаңнар күрмәсен...» — Дөрес, ул моны яхшы ният белән эшләде: аңа баланың мәхәббә-

тел казанырга кирәк иде. Аннары бик бетәшкән бит, ни гомер татлы нәрсә күрмәгән, ә үзенекеләргә әледән-әле шикәр, конфет кереп торды... Бер тапкыр шулай Маратка конфет биреп торганда, Сания кайтып керде:

— Ә миңа?

Ана, ни тәҗрибәле укытучы, алты яшьлек баласы алдында каушап калды һәм, үзен тиз генә кулга алып, хатасын төзәтергә ашыкты:

— Сиңа иртәгә, ускәнем. Ә берсекөнгә абыеңа, яме? Буфетта бирәрне генә бирәләр.

Шулай микән соң?.. Элек бер ландрин алып кайтсаң да, урталай бүлеп бирә иден түгелме?.. Сабыр табигатьле Сания бу турыда бер сүз дә әйтмәде, ләкин бик күңелсезләнде ул һәм Гөлсем апа берничек тә аның күңелен таба алмады. Кызчык «я» диде, ә йөрәге алай димәде. Шул сәгатьтән аның көнчелек шәменә беренче тапкыр ут кабынды. Ни үз күреп йөргән Сания кинәт кенә Маратка салкынаеп китте. Бу салкынлык әниләре карточка алып кайткан ярты айлык конфетны бер утыруда өчесенә ашатып бетергәч тә бетмәде.

Сания хәзер Марат белән энисе кушканга гына уйнады. Ә кушу буенча уйнаган уен-уенмыни ул! Кыз хәзер урамга гел ялгыз шылу ягын карады. Ләкин шунсы ярады: ул конфет турында абыйсына әләкләмәде. Болай да көнләшеп йөргән Илдарны тынычландыру, әлбәттә, ансат булмас иде.

Ул да түгел, туры килеп торуын кара син, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, конфет вакыйгасыннан соң берничә көн үтүгә шундый хәл килеп чыкты. Ул елларда кешеләр эш сәгате, ял көне, отпуск кебек сүзләрне оныткан, тәмам арып егылганчы эшли иделәр. Гөлсем апа да, үзе һәм сугышка киткән тагын бер укытучы өчен укыту өстенә, бик күп җәмәгать эшләре алып бара, һәр шимбәдә госпитальгә китеп, дүшәмбе көн генә кайта, анда яралы солдатларга Совинформбюро сводкалары, китаплар укый, хатларын язып бирә, йомыш-юлларына йөри, авыр ятучылар янында төн чыга иде. Беркөн шулай, Гөлсем апа госпитальгә киткәч, Илдар белән Сания, Маратка бер дә әһәмият бирмичә, рәсемле лото уйнап утыралар, Марат исә бер почмакка поскан да, борынын мышнатып, аларга кызыгып карап тора иде, өйалдындагы чиләкләргә абына-сөртенә авылча киенгән бер хатын килеп керде һәм бусаганы атлауга, туктап:

— Я, Айтуган токымнары, менә мин килеп тә җиттем,— диде.

Илдар белән Сания бераз ятсынып карап тордылар да, танып алгач, йөгереп килеп, авыл хатынының муенына сарылдылар.

— Әби, әби!..

Әби (Гөлсем апаның бик ук юашлардан булмаган каенанасы шушы иде инде), өстен дә чишенмәстән, түшчегеннән ике күкәй алып, берсен Илдарга, берсен Саниягә бирде. Балалар шунда ук, Маратны кызыктырып, күкәйләрен әрчи башладылар.

Маратның мондый читләүне беркайчан да күргәне юк иде әле. Беркөн, паек алырга баргач, кибетче апа Илдар белән Маратка бер прәннекне дә урталай бүлеп бирде бит, Валерикны алырга кергән апа барысына да берәр ландрин өләшеп чыкты. Ә теге, әтиләре яныннан кайткан Ногман абый, көлдерә торган солдат, башта чикләвекне Илдар белән Саниягә генә биргән иде, Маратны күргәч: «Һа-а, Марат Мостафич онытылып кала язган ич...» — дигән булып, куш учлап бирде. Бәлки, бу апа да күрми торадыр, күргәч, ул да шулай итәр?.. Юк шул, бу апа алай итмәде. Ул төенен әйбәтләп төйнәде дә, аралыкка кертеп, чөйнең иң югарысына элеп куйды.

Шуңынчы өметен өзмичә, әбинең һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торган Марат бик кимсенде. Ә инде әби, күз кырыен гына төшереп алып, әкрен, ләкин усал тавыш белән:

— Теге нәмәрсәгез шушымыни инде? — дигәч, сабыйның авызы мәлшәйде, күзләренә яшь килде. Ул, Сания белән Илдар кулындагы күкәйләрне күрмәс өчен, башын түбән иде. Ләкин Саниянең күкәйле авызын чәпелдәткәне барыбер ишетелеп тора иде, тәмле итеп чәйнәгәне күз алдына килде. Әнә йотты да... Марат та төкереген йотып куйды һәм түзмәде, күлмәк итәген бармагына бер чорнап, бер сүтеп торган хәлдә, күзләреннән яшь мөлдерәп чыкты. Ә башын күтәреп караганда, Сания инде күкәен ашамый, әрчүдән туктап, баягы кебек ят күреп түгел vңайсызланып, Маратка карап тора иде.

7 ШУННАН СОҢ МЕНӘ НӘРСӘ БУЛДЫ

Марат күңелсез хисләр эчендә йокыга китеп бара иде инде; кемдер, шыпырт кына килеп, аның ябынып яткан тун чабуыннан тартты. Тәрәзәләрдә маскировка булганлыктан, өй эче дөм-караңгы, мич кырыендагы сукыр лампаның каләм очы кадәр генә калдырылган сүнәр-сүнмәс күгелҗем яктысы Марат яткан аралыкка килеп җитми иде. Марат чабудан тартучыны мышнавыннан таныды. Бу Сания иде. Сания, кулын тун астына тыгып, капшана-капшана Маратның кулын тапты һәм, кабыгы әрчелгән, очлы башы бераз гына тешләп алынган күчтәнәч күкәйне энесенең учына төртте дә әкрен, бик әкрен тавыш беләп:

— Аша, нәнәм...— дип пышылдады.

— Әйем.

Марат күкәйне кире бирү өчен Саниянең кулын эзләде. Ул арада Сания кулларын тун астыннан тартып алып артына яшергән иде.

— Аша, аша.

— Әйем...

— Әкрен. Әбине уятырсың... Аша инде, нәнәм.

Каты пешкән күкәй исе Маратның авыз суларын китерде. Малай бик тиз түземен җуеп, күкәй тешли башлады, һәм шунда ук, авызыннан алып, Саниягә сузды:

— Әем, үзең аша.

Сания Маратның өстенә иелде. Ул шундый якын иелде, җылы сулышы Маратның иреннәренә тиеп торды:

— Алайса, әйдә икәү ашыйк, нәнәм.

Марат дәшмәде. Сания, күкәйне икегә сындырып, зуррак кисәген энесенә бирде. Маратка рәхәт, бик рәхәт булып китте. Ул, барысын да онытып, авызын тәмле чапылдата-чапылдата, ашый башлады. Саниягә дә рәхәт иде хәзер. Ул үз өлешенең дә яртысын Маратның учына төртте һәм энесен ике куллап кочып алды:

— Мин үскәч, әни миңа чебиләр алып бирә. Чебиләр үсә дә күкәй сала. Мин сиңа ике күкәй бирәм... Юк, өчне...

— Ә мин үскәч...

— Әкрен.

— Мин үскәч солдатка китәм, сиңа чикләвек апкайтам... Теге солдат абый шикелле...

— Син мине яратасынмы, нәнәм?
— Ялатам. Әнине ялатам, Илдал абыйны...
— Илдар абый сине кыйнады ич. Курчак уйнаганда...

Сабый, кинәт исенә төшеп, уйга калды. Бераз торгач, Саниядән дә әкрен итеп:

— Илдал абый Аблекны җигеп билә, чана шудыла. Мин үскәч Маликны кыйныйм,— диде.
— Ник?
— Илдал абыйны кыйнады.
— Җирәкми. Сугышырга ярамый, нәнәм.
— Мин сугышмыйм. Маликны гына кыйныйм... Мин үскәч көчле булам...

Бу вакытта Илдар да уянган, башын мендәреннән күтәрә төшеп, тыңлап ята иде, көлеп куйды һәм ахрысы энесенең сүзләре тәэсир иткәндер, җитдиләнеп китте, уйчанланды. Ул да хәзер Маратны элеккеге кебек үк ят күрми иде инде. Аның да хәзер берәр нәрсә белән Маратның күңелен күрәсе килә иде. Бая, кызык булсын әле, иртә торгач итеген кия алмыйча җаны чыксын дип, Маратның бияләйләрен итек эчләренә тыгып куйган иде, хәзер әкрен генә торды да бияләйләрен алып мич уентыгына, җылыга китереп салды. Кичә, ачуы килеп, Маратның кылычын (тамчы бозын) сындырып ташлаган иде, иртән торгач та аның урынына икене, иң озыннарын куптарып алып бирергә уйлап куйды.

Шулай итеп, әбинең балаларны дошманлаштырырга теләп эшләгәне аларның дуслануларына бер сәбәп булды. Әби үзе алып килгән күчтәнәч оннан коймак изәргә дип урыныннан торганда, Сания белән Марат, песи балалары кебек, бер-берсенә елышып, рәхәт йоклап ята иделәр.

Әйтергә кирәк, бу — әбинең дә, элек уйлаганынча, дөньяның астын өскә китерергә дип килүе түгел иде инде (анар улы фронттан, каты булмаса да, зарларлык итеп язган иде). Шулай да ул Айтуганнар семьясында үз оныклары белән ят канның бертигез хокукта яшәвенә килешә алмады. Үлеп көнләште ул. Өсләреннән шуып төшкән туннарын алып ябарга дип килгән җиреннән тукталып, Санияне үз урынына күтәреп салды да Маратка таба әйләнеп:

— У-у, кара, ничек карап ята,— дип мыгырданды.

Марат тунны үзе төшеп алды. Һәм башын тун астына яшерде дә төймә тишегеннән әбине усал күзәтеп ятты. Ник шулай усал күзәтте ул аны? Үзен шулай кимсеткәнгә? Юк, аңа гына түгел. Аның өйдә хуҗаларча йөрүе, әниләре урынында йокларны сабыйны шикә төшергән иде. «Әллә безгә әни булырга килгәнме икән?» Шундый куркыныч уй туган иде Маратта.

Иртән уянып китүенә әбинең билендә әниләренен ак алъяпкычын, башында анын ак шәлен күргәч, сабыйнын бу шиге тагы да арта төште. Ул, шушы турыда Саниядән сорашмакчы булып, аның янына килде. Ә мич тирәсендә кайнашкан әби борылып карагач, куркып, эндәшми калды.

Табын янында исә сабыйны тагын бер күнелсезлек көтә иде. Әби: «Бусын аска салып калдырыгыз»,— дип балаларга икешәр бәрәңге куйды. Аны ялтыратуга коймак өләшеп чыкты. Дөрес, барысына да өчәрне бирде ул. Ләкин, юк шул, Сания белән Илдарның коймаклары зур һәм күпереп торалар, Маратның исә кечерәк тә, яньчек тә, ә берсенең асты күмерләнеп беткән иде.

Тагын кимсенде Марат, аңа тагын күңелсез булып китте. Коймак кайнар булмаса да, йотканда бугазын пешереп, әллә ничек тырнап, ят әйбер кергәндәге кебек күңелне болгатып төште.

Әбинең Маратны болай аерганын Сания дә күргән иде. Ул, уңайсызланып, бер әбисенә, бер Маратка карап утырды. Абый да күрсен дип, аягы белән Илдар аягына төртеп куйды. Ә Илдар болай да күргән иде инде. Ләкин ул Сания шикелле тойгыларын нечкәртеп тормады, өлешен һәрвакыттагыча башкалардан алда ялтыратып ташлады да (табада тагы бар иде әле) өстәмә көтә башлады.

Әби барысына да тагы берәр коймак өләшеп чыкты. Бу юлы Маратка да күмерләнмәгәнен, күпереп пешкәнен бирде. Бирде, ләкин коймак белән бергә сабый өчен иң кирәген, йөрәк җылысын бирмәде. Әби, Сания тәлинкәсенә салганда, «аша, балакаем, аша», диде һәм аркасыннан сөеп куйды, ә Маратны сөймәде, «аша, акыллым»ны да әйтмәде. Яны белән утырган килеш, ничектер салкын гына итеп салды ул коймакны анын тәлинкәсенә. Шуңа күрә бусы да көйгәне кебек үк тәмсез булды. Йоткач бугазда пиндидер әчкелт төер утырып калды.

Әби Маратка гел шулай кырын карады; табын янында аны гел аерды. Хәрәкәтләрен дә килештермәде ул аның: «Кара инде утыруын, аяк атлауларын әйтер идем бер, у-у көлүе, ябалакмени...» дип гел берәр гаебен табарга торды. «Алып бир шул себеркене! Я тиз бул. У-у, мәхәббәтсез!..» Күчереп утыртканнан соң шиңеп төшкән гөл тернәкләнә генә башлаган иде, яңадан шиңеп китте.

Бу хәл Санияне генә түгел, Илдарны да үзгәртеп җибәргән иде. Дөрес, ул һаман да көнләшә иде әле, ләкин хәзер аңарда Маратны кызгану хисләре туды. Кич белән әби, борчак шулпасы пешереп, Маратка сыеграгын салгач, Илдар, мин куены яратмыйм дигән булып, үз тәлинкәсен энесенеке белән алыштырып алды. Әби мыгырдана-мыгырдана тәлинкәләрне киредән алыштырып куйды. Илдар үз тәлинкәсен кабат Маратка таба этәрә башлагач, әби кашык белән аның кулына сукты:

— Яхшылыкның кадерен белмәсәң, мин сине!.. Аша!..

Илдар ашады. Ә әби сүнә башлаган самоварны аралыкка алып кереп, читеген салып өрдергән арада үз тәлинкәсеннән Марат ашына берничә кашык борчак алып салды. Абыйсы артыннан Сания дә шуны кабатлады.

— Аша, нәнәм.

Сабыйның бугазына килеп тыгылган төер эреп юк булды, йөзе яктырып китте аның. Ул Саниянең колагына үрелеп, болай дип пышылдады:

— Сания апа, әни кайчан кайта?

— Тагын бер йоклап торгач, нәнәм.

— Ә бу апа безнең әни булмыймы?

Сания белән Илдар көлеп җибәрделәр.

— Булмасын, әйе бит, Илдал абый?..

Әби озак тормады. Алып килгән май, күкәйләрен базарга чыгарып сатты, берничә әчмүхә чәй, шикәр алып, бушап калган төенчегенә төйнәп, култына кыстырды да «балаларыннан биздергән, әллә кайларда сөрлегеп йөргән» килененнән зарлана-зарлана, авылына кайтып китте.

Ул китүгә әниләре кайтып керде. Нурларын чәчәкләрнең алына да, гөлеңә дә бертигез сибүче кояш чык-

кан кебек булды. Балалар аны, ачкан ишеген дә ябарга бирмичә, кочып алдылар. Марат та кочты. Бу аның әнисен беренче тапкыр шулай сагынып көтүе иде. Балалар шунда ук, берсен-берсе бүлә-бүлә, әбинең Маратны ничек какканын сөйләп бирделәр.

Кечкенәдән үги апа кулында үскәнлектән, кимсетелеп яшәүнең нәрсә икәнен белә иде Гөлсем апа. Кайтып кергәндә күзләре йокысызлыктан кызарып чыккан булса да, иреннәреннән кан качкан булса да, бик шат иде әле, хәзер кинәт күңелсезләнеп китте. Илдар белән Сания моны сизеп, ә без шулай иттек, без болай иттек дип, әниләрен тынычландырырга керештеләр:

— Мин үземнең күкәйне...

— Мин ашның куесын...

Гөлсем апа елмаеп куйды. Балаларында Маратка карата дуслык, туганлык хисләре туып килгәнне күреп сөенде. Ә күчтәнәч мандариннарга башка вакыттагы кебек комсызланып ташланмаганнарын, Саниянең әйбәтрәк мандаринны Маратка таба этәргәнен күргәч, шатлыгыннан нишләргә белмәде.

Марат үзенә тигән мандаринны ашамады. Көн буе әле кулына тотып, әле кесәсенә салып йөрде. Кич белән генә ашады ул аны. Гөлсем апаның күчтәнәче бу юлы аңа шулкадәр кадерле иде.

Ләкин... ай, әни, әни!.. Сабый кичтән мандарин ашап ятты, иртән *үз әнисе* белән кәбестә шулпасын ашап утырганын төшендә күреп сөенеп уянды һәм күзен ачып карауга үксеп елап җибәрде.

Гөлсем апа алдына алып сөя-сөя юаткач, сабый бераз тынычланды, ә ул мәктәпкә киткәч, Илдарга килеп сарылды:

— Илдал абый, өйгә апкайт.

Кесәсендә Ленинградтан килгән, ни өчендер бик кадерле күргән матур бизәкле чынаяк тәтие йөри иде, шуны Илдарның кулына төртте. Алып кына кайт... Өендә аның паровозы белән Казбек исемле бахбае да бар әле. Аларны да бирер...

— Бахбаең менә ич...— диде Илдар һәм чоланнан кайчандыр үзе уйнап йөргән агач атны алып кереп, ишек төбеннән түргә таба тәгәрәтеп җибәрде. Марат атка каршы йөгереп килеп, кочып алды:

— Казбек, Казбек!..

Һәм шунда ук күңелсезләнде:

— Әем, бу Казбек түгел...
— Казбек инде, Марат, Казбек...
— Түгел. Чәче кыска.
— Алганнар...— Илдар үзенең маңгаенда гына калдырып алынган чәчен тотып күрсәтте.— Минә минекен дә алдылар.
— Аягы...
Әйе, Илдар атының арт аягы тубыктан сынган, бер тәгәрмәче төшкән иде. Илдар тагын хәйләгә кереште:
— Сугышта булган, теге кинодагы ат шикелле...
Марат, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, Илдарга карап торды:
— Әә синә...
— Әйе, әйе. Менә хәзер госпитальгә илтеп салабыз да аягы үсә...
— Үсми.
— Кая, госпитальгә илтеп кайтыйм әле...
Марат атны кочып алды.
— Әем, әем,— диде ул һәм атка менеп атланды.— Әнием янына кайтам.
— Әни бер генә була инде ул. Безнең әни әнә ич...
— Түгел. Минем үз әнием бал.
— Төшендә күргәнсең...
Илдар моны уйлап әйтмәде. Теленә килде дә әйтте. Шундый сүз бар бит: кеше сүзен юкка чыгарырга кирәк булганда әйтеп куясың. Ләкин бу сүз төшнең нәрсә икәнен белгән Маратны уйга калдырды.
Ул хәзер төшне гел күрә иде. Зур суда йөзеп йөри-йөри дә бата башлый; аннан балык канатына ябышып чыга. Яки Казбекка атланып һавада очып йөри. Йолдызлар кар кебек өскә сырышалар. Марат арада иң матурын, бик зурысын тотып алып Казбекнең маңгаена ябыштыра. Аннан Казбек белән икәү айны футбол тубы итеп тибеп йөртәләр. Бер Казбек тибә айга, бер Марат. Ә уянып киткәч, балык та юк, Казбек та, йолдызлар да, ай да... Аннан, күп вакыт үткәч, Марат икеләнеп *бу әнисеннән* сораша: ул Казбек белән чыннан да һавага менеп йөрдеме, әллә төшендә генә күрдеме?
Илдарның «төшендә күргәнсең» дигән Маратны әнә шуңа күрә уйга калдырды. Аңарда *үз әнисе* турында икеләнү түгел, иләсләнү башланды. Ә икенче бервакыт төшендә *бу әнисе* белән Невада көймәдә йөргәнен күр-

һәч, иләсләнү икеләнүгә әйләнде. Алар бит көймәдә *теге әнисе* белән дә йөргәннәр иде. Анда ике абый да бар иде әле. Ә-ә, берсе әтисе икән, берсе Касимовтан Маратка паровоз алып килгән абый. Анысы койрык тотты, әтисе иште, әнисе гитара уйнады, Марат, көймәнең әле бер як кырысна, әле икенчесенә ятып, кулын суга тыгып барды. Су салкынча, кулга бәрелеп чәчри, артта эз кала... Бүген дә төшендә шулай булды ич. Нәкъ шулай. Ләкин бүген ак күлмәкле, ак чалбарлы, тузма чәчле әти урынына әнә теге рәсемдәге солдат әти иште көймәне...

Марат, уянып күзләрен ачуына, төшен Саниягә сөйләде. Аннан *теге әнисе* белән өендә көймәдә йөргәннәрен сөйләп бирде. Сөйләгәндә, ул *теге әнисе* белән *бу әнисен,* өне белән төшен, төше белән өнен бутап бетерде.

Гөлсем апа сабыйның буталганын сизде һәм, эченә салып куйды. Тышта яз иде инде. Бу табигатьнең кышкы йокыдан уянып, хәрәкәткә килгән, кат-кат тунын салып бетереп, ашыга-ашыга өстенә яңа яшел киемен киеп торган көннәре иде. Көннәрдән беркөн мәктәптән дәресләре бетүгә үк кайтты да, бөтен семьясын алып, Аккош күленә китте. Маратлар Невада ничек йөргән булсалар, Гөлсем апа бөтенесен кабатларга тырышты. Көймәдә йөрделәр алар. Илдар иште, Сания койрык тотты. Гөлсем апа үзе гитара уйнады. Су суык булса да (Маратның *теге әтисе* коенган бит), Илдар су коенды. Аннары урман каравылчысыннан котелок сорап торып, Ленинградтагыча стерлядь ухасы түгел, бәрәңге пешереп ашадылар, селедка белән. Ә Ленинградтагы мороженое урынына урман каравылчысы яфрак чәй эчертте. Чәйдән соң Ленинградның гөлчәчәкләренә дә алмаш табылды: умырзая белән яңа ачылып килгән ландыш чәчәкләре. Боларын балалар чабыша-чабыша үзләре җыеп йөрделәр һәм монысы прогулканың иң күңелле җире булды.

Шул көннән соң Гөлсем апа баланың икеләнүе көчәйгәнне күрде. «Тизрәк, тизрәк онытсын иде инде... Бер тыныч йокламый, нервысы бозылып калуы бар... Тукта әле, тагын нәрсә эшләргә мөмкин соң?» Гөлсем апа, аэродромнан кайтышлый, Нариман урамында булган вакыйга исенә төшеп, мөмкин кадәр Марат әнисе кебегрәк киенеп йөрде. Бер тапкыр госпитальдән

кайтканда Марат энисенең медальонындагы рәсеме кебегрәк киенеп кайтты. Башына нәкъ анықы төсле, каен җиләкләре белән бизәлгән киң кырыйлы салам эшләпә дә алып киде. Марат, аны тәрәзәдән күреп, йөгереп чыкты һәм Гөлсем апага әйткәндәгечә итеп түгел, йөрәге белән:

— Энием, ай, энием!..— дип кочагына ташланды.

— Сагындыңмы ускәнем, бик сагындыңмы?

Гөлсем апа тавышын да Марат энисенеке кебегрәк итәргә тырышты. Ләкин, юк шул, артистның иң даһие да нәкъ син булып уйный алмый. Гөлсем апаны Марат бик тиз фаш итте.

— Минем энием ускәнем әйтми ие, акыллым әйтә ие.

Гөлсем апа баланы кочып үпте.

— Минем энием алай кочмый ие, менә болай-болай коча ие...

— Гел бертөрле кочмыйлар инде аны, Марат...

— Юк, кочалал...

Шулай да боларның һәрберсе Маратның икеләнүен көчәйтте. Ул торган саен энисен сирәгрәк хәтерләде. Ә җәйге каникуллар җитеп, Гөлсем апа күбрәк вакытын өйдә, балалары янында уздыра башлагач, теге эни күптән күргән бер тәмле төш кенә булып калды.

8

«МИН КИЛМЕСӘК»

Гөлсем апа ишек алдында, куе яфраклы карт юкә күләгәсендә имтиханнарга хәзерләнеп утыра, Илдар эт оясының купкан тактасын кагып маташа иде, авызына солы капчыгы киертелгән Казбегын тезгененнән җитәкләп, Марат кайтып керде.

Ул бик шат иде. Капка баганасына бәрелеп егылган атын да күтәреп торгызмыйча, Илдар янына йөгерде:

— Илдал абый, мин килмесәк, Илдал абый, мин килмесәк!..

Чүкеч тиеп авырттырган бармагын суырып торган Илдар, әллә ишетмәде, әллә ишетеп әһәмият бирмәде, энесенә күтәрелеп тә карамады. Балаларның дөрес әйтмәгән сүзләрен һәрвакыт төзәтеп әйттерергә гадәтләнгән Гөлсем апа дәфтәренә, механик рәвештә, килмешәк дип, дөресләп язып куйды. Һәм шунда ук, әсәрләнеп,

башын күтәрде. Марат, атын егылган килеш өстерәп, әнисенә таба йөгерде:

— Әнием, мин килмесәк. Мин килмесәк!

— Тсс...

Гөлсем апа, каләмен өстәлгә куеп, баланы алдына алды:

— Кем әйтте андый әшәке сүзне?

— Бел малай, бел малай...

— Зур малаймы?

Сабый, әле һаман әнисенең хафага төшкәнен аңламыйча, кулын чәбәкләп, көйли бирде:

— Зул, зул...

Гөлсем апа моны көтми иде әле. Бакчага йөри башламыйча, балалар арасына кереп китмичә, ишеттермәсләр дип уйлый иде. «Ул арада институтны тәмамлап чыгармын, кайда булса да берәр урта мәктәпкә күчерерләр, ә бәлки Казанның үзенә үк алып куярлар...» дип, үзен-үзе тынычландырып килә иде. Хәзер нишләргә соң? Институтны бетерергә тагын бер ел бар бит әле. Ул арада балага 5 яшь ярым була. Әлбәттә, аңынчы кырыкмаса кырык ишеттерерләр, аңлый башлар... Яңа төзәлеп килгән ярасы ачылыр... Кара, бу ягын исәпкә алмаганмын икән ич... Нишләргә соң инде?

Гөлсем апа, имтиханнарны биреп бетереп, 4 нче курска күчүгә, Наркомпроска китте. Ләкин анда укытучыны алай бик җылы каршы алмадылар.

— Кыскасы, сез, институтны тәмамлагач, Ягеднидән кайда булса да китәргә телисез? Мин сезне дөрес аңладыммы, иптәш Айтуганова?

— Әйе.

— Мәсәлән, Казанга.

— Алай диярг дә була.

— Ә юк, «диярг була» — укытучы сүзе түгел. Аныклыгы чамалы, конкрет түгел, ягъни.

— Ул чакта: әйе.

— Вот, вот. Ләкин мин сезне бу юлы шатландыра алмам. Хәзер без институт бетереп чыгучыларның бөтенесен а-выл-га, хөрмәтле ханым.

— Ә мин...

— Мин сезнең нәрсә әйтергә теләгәнегезне беләм. Ләкин әллә нинди сәбәпләрегез булса да, а-выл-га...— диде Наркомпрос кешесе һәм телефон трубкасын алды.

«Авылга... Тукта әле, нәрсәсе начар? Хәтта яхшырак була түгелме соң?.. Мостафа кайтканчы гына... Берәр якынрак авылга?..» — Гөлсем апа, артык уйлап тормастан:

— Ә мин авылга да каршы булмам төсле,— диде.

— Тагын аның түгел. «Төсле»сез генә булмыймы?

— Була.

Наркомпрос кешесе, шалтыратуыннан туктап, трубканы кире куйды:

— Ул чакта мең рәхмәт. Мин инде, бәрелеш була икән дип, сугыш кырына артиллерия чакырта башлаган идем. Рәхим итегез! Сез үзегез теләгән авылны хәзердән үк сайлап куя аласыз... Туктагыз әле, ә нигә моны сезгә киләсе елга калдырырга?

— Быел ук мөмкин?

— Нигә мөмкин булмасын, ди? Зинһар өчен. Ичмаса, бер бәладән коткарыгыз.

— Бәла?

— У-у, буылабыз, иптәш Айтуганова.

— Әнә ничек?

— Ирләрнең яшен, картын мәктәптә тотып булмый. Бер карыйсың — шарфын чорнаган, зур итеген кигән, бер кочак дәфтәрен, глобусын, тегесен-монысын күтәргән дә, салмак кына атлап, мәктәбенә кереп бара. Ну, бу тумыштан безнең бакча кошы, беркая да китмәс, дисең. Икенче карыйсың — укытучыдан җилләр искән... «Кая китте?» — «Фронтка»... Бәланең дә бәласе, иптәш. Мең укытучы җитешми, мең! Ә республиканың барлык пединститутлары, училищелары быел нибары өч йөз кеше бирде. Теләсәң ничек бул... Мең рәхмәт сезгә. Быелга башлангыч классларда укытып торырсыз. Ә киләсе елга...

Наркомпрос кешесе карта янына килде һәм кызыл түгәрәк белән әйләндереп алынган күп авылларның берсенә төртеп күрсәтте:

— Менә сезгә мәктәп. Быел гына салынып бетте. Торак йорты... Ах, анысы өлгереп җитмәгән икән әле... Зарар юк, өлгерер... Хәерле юл сезгә, иптәш Айтуганова.

— Туктагыз әле, ирем нәрсә әйтер бит, балаларым...

Гөлсем апа, өенә дә кайтып тормастан, иренә хат язды. Тизрәк җитсен өчен, аны, аэропортка алып ба-

рып, тиздән Мәскәүгә китәчәк самолетның пилотына тапшырды.

— Зинһар өчен, бик ашыгыч, Мәскәүдә сала күрегез...

Монысына Мостафа абыйдан җавап бик тиз килде:

«...Яздым, яздым да уйлап утырам әле,— дигән иде ул хатының азагында... «Что день грядущий мне готовит?» Нигә, шулай ич! Бу хат барып җиткәнче, синең тагын берәр мөгез чыгарып куюың бик мөмкин... Курыкма, курыкма, ачуланып әйтүем түгел. Дөресен генә әйткәндә, монысына ике кулымны да куям, авылга йөз белән, димәк? Әйдә, күчә бир, күчә бир... Ләкин шунсы читен булыр: авыл хуҗалыгын бер генә дә белмисең бит. Бераз китаплар укыштырып бар, ичмасам. Крестьян эшен белмәгән кешене авыл халкы өнәп бетерми. Аның авызын мөлаем ерып, елмаеп торганына карама, яратмавы ул аның... Ярый, хәерле юл. Бәрәңге тамырда үсә, сабагында үскәнен көтеп ятма, ач калырсың...»

9 ХУШ, ЯГЕДНИ!

Уенның иң кызып килгән чагы иде. Ишек алдында, арт койма буенда тузып беткән рессоралы арба әрҗәсе бар. (Аның хуҗасы — Хәйбуш исемле ломовой — чехларның беренче снаряды Ягедни өстендә шартлау белән арбасын тугарып ташлый да, атына атланып, биленә кылыч тагып, сугыш кырына китә һәм шул китүеннән илгә кайтмый... Ул көннән бирле йорт әллә ничә тапкыр хуҗадан хуҗага күчә, ләкин ломовойга хөрмәт йөзеннән, берсенең дә бу арба сәләмәсен ватып ягарга кулы бармый. Ул музей экспонаты кебек шунда тора бирә.) Балалар шул арбага чыпта җилкән корганнар, ящиклар өйгәннәр дә кораб итеп уйнап торалар иде. Матрослар бар да эштә: кайсы штурвалны (тырнаклары төшеп беткән тәгәрмәчне) әйләндерә, кайсы кыңгырау кага яки свисток кычкырта, кайсылары барлык туплардан (тишек-тошык самовар морҗаларыннан) дошманга (саплары белән җиргә кадап куелган себерке, көрәк шикелле нәрсәләргә) снаряд (вак таш) яудыра; арба астында Марат һәм тагын шундый бер кечкенә малай 20—30 кирпечтән өелгән «кораб миченә» уенчык көрәкләр белән күмер салып тора, ә Илдар

бинокль (төпләре төшкән ике түгәрәк пенал) аша дошманны күзәтә һәм идәннән аска үткәрелгән рупор (күгәргән су трубасы) аша машина бүлегенә команда бирә иде. «Полный вперед!» Кочегарлык өстенә механик хезмәтен дә үтәүче Марат рупор буенча үзенең колагына тамган капитан төкереген сөртеп ала да җавап кайтара:

— Есть, польный пелет.

— Лево руля!

— Есть, лево луля...

— Так держать!

— Есть, так делзать...

Шул чак ишек алдына, киң бортлары белән капка баганаларын сыдыра-сыдыра бер зур грузовик килеп керде. Грузовик борылып туктауга, капитан команда бирде:

— На шлюпки! На вражеского крейсера! За мной!..

— Урра!..

Илдар «кораб»тан сикереп төште һәм, машинаның биек резина тәгәрмәченә басып, борт такталарына ябышып, кузовка менеп китте. Аның артыннан барлык матрослар төрлесе төрле яктан кузовка үрмәләделәр, Марат та, үзенең кочегаркасыннан чыгып, грузовик янына килде. Ул тегеләй итеп карады, болай итеп карады, менә алмагач, аяк очларына күтәрелеп, кулларын сузды:

— Илдал абый, мин дә...

Ләкин, тукта әле... кылычы белән мылтыгы кайда киткән соң?.. Ә-ә, кичә солдат-солдат уйнаганда Валерикларда онытылып калгандыр әле... Ә һөҗүм вакытында аисыз булмый бит... Марат Валерикларга йөгерде. Ә ул кылычын тагып, мылтыгын асып кайтып кергәндә, һөҗүм сугышлары беткән, олы кешеләр грузовикка йорт җиһазлары төяп торалар, зуррак балалар аларга булышып йөри иделәр.

Монысы нинди уен икән тагын? Кызыклыдыр, ахрысы. Әнә әниләре самоварларын да алып чыгып грузовикка куйды.

Әниләре, ике кулына ике банка гөл күтәреп чыгып килешли, Маратка:

— Кайда йөрисең, улым, әйдә, авылга китәбез ич,— диде.

Марат әле авылның нәрсә икәнен белми, ә беркөн, Наркомзростан кайткач, әнисеннән: анда ипи, бәрәңге

үстерүчеләр тора... дип сөйләп утырганыннан бернәрсә дә аңламаган иде. Шулай да, хәзер сикергәләп, кулларын чәбәкләп куйды:

— Мин Казбекка атланып...

— Әйе, син Казбекка атланып барасың.

Марат, абзарга йөгереп кереп, атын җитәкләп чыкты. Ат күптән инде госпитальдән терелеп чыккан: ялы үскән, сынган аягы бер дә беленмәслек итеп кадакланган, яңа тәгәрмәч юнып киертелгән, гәүдәсе куе көрән төскә буялган, бәкәлләре ак, ялы кара, авызы кызыл, күзләре ут янып тора иде.

Билгеле инде, мондый ат тик тора алмый. Ат (ат урынына Марат үзе) ярсып кешнәде, чыгымлады. Марат аны көч-хәл белән тыеп, әле тезгене белән кизәнеп, әле башыннан сыйпап, грузовик алдына китереп бастырды:

— Тылл!..

Һәм тагын ярсый башлаганчы, тиз генә менеп атланды да кылычын кыныннан тартып чыгарды:

— Улла-а, улла-а!..

Шофер моторны кабызды. Машина, көчен кая куярга белмичә, гүелдәп дерелди башлады. Гөлсем апа озата керүче күрше-колан белән кул кысышып күрешеп чыкты да (Илдар әллә кайчан үзе менеп кунаклаган иде) Санияне күтәреп алып кузовка, бер йомшак төенчек өстенә утыртты, үзе кабинага шофер янына кереп утырды һәм кабина ишегеннән Маратка кулларын сузып:

— Кил инде, улым, кил, хәзер китәбез,— диде.

Кемдер Маратны әнисе алдына кертеп утырту өчен күтәреп ала башлады. Марат бөтен гәүдәсе белән атына ябышты:

— Әем, мин Казбекка атланып балам.

Озата керүчеләр һәм корабта үзе белән бергә хезмәт иткән «матрослар» рәхәтләнеп көлештеләр. Кешеләр Маратка моның «чын уен» түгел икәнен, авылга ат атланып барып булмаганын әйттеләр. Марат өчен уенның кызыгы бетте. Ул, күңелсезләнә төшеп, тынып калды. Шул чакта зур гына бер апа аны, ялан кылычы, карабины, аты-мазары белән күтәреп алып, кузовка менгезде.

— Хуш, Марат!

— Хуш, Ләхилә апа!

— Абау, безгә бер шигырь дә сөйләми китәсенмени инде, Марат?

Марат атын бер чемодан өстенә бастырып куеп менеп атланды да Габдулла Тукайның «Карлыгач» исемле шигырен сөйли башлады:

...Күп эшләде иленмичә; бала, бала,
Чыгалды ул матул-матул балалал да...

Ә машина кузгалып китүгә, Казбек — бер якка, декламатор-кавалерист икенче якка авып төште.

Тагын бар да көлештеләр.

Ләкин Марат югалып калмады. Ул үзләрен озата баручы ападан атын ике төеп арасына егылмаслык итеп куйдыртты да тагын менеп атланды.

Ачыксалал каллыгачның баллалы,
Чебен-челки тотып кайта аналалы...

Грузовик, капкадан чыгып, төнге яңгыр белән юылган ак таш юлга менде. Һәм еракта, зәңгәр күк гөмбәзе астында, юмарт кояш нурында тын гына черем итеп утырган ак Кремльгә таба юл алды.

Абрек исә, грузовиктан бер узып, бер артка калып, юл читеннән йөгерә иде.

Икенче кисәк

1 БЕР ДӘ КАЙТМЫЙК, ЯМЕ, ӘНИЕМ

Марат белән Илдар капкадан чыкканда, юл буйлап ике малай килә иде. Алдагысының — Илдар хәтлесенең өстендә майка да трусик, тәне бик ябык, гүя әле генә нефтькә манып алганнар, колакларына кадәр куе көрән төстә иде. Икенчесе бераз аграк. Монысы буйга безнең Марат чамасында булып, (менә кызык), алдагысының трусигына чабата киндерәсе белән тагылган иде. Су кереп кайтып килешләре булса кирәк һәм бик озаклап кергән булсалар кирәк, муеннарына каз итләре чыккан, бала йоннары кабарган, чәчләре суга манып алган мәче йоны кебек укмаш-укмаш кибеп каткан иде.

Ә нигә бер-берсенә киндерә белән тагылган соң алар? Һәм ни кыланалар?— Янәсе, «иген уралар». Алдагысы (Илдар хәтлесе) бер үк вакытта трактор да, тракторчы да. Ул бертуктаусыз дөп-дөп дөпелди, кулларын әле трактор рулен борып йөрткәндәге кебек итә, әле рычагны этеп куя да шунда ук үзенә таба тартып ала. Бәләкәе (зурысына киндерә белән тагылганы) комбайн һәм комбайнчы. Монысының эше тагы да катлаулырак. Ул кулларын комбайн канатлары кебек әйләндереп барырга, бер үк вакытта штурвалны борып йөртергә тиеш, өстәвенә ике атлаган саен шуып төшә башлаган трусигын күтәреп куярга кирәк була иде.

Трактор-малай, әллә эше бик тыгыз иде, әллә ваксынып торасы килмәде, Маратларга күз кырые белән генә карап алды да тавышын олыларча итәргә тырышып:

— Әй, әбер-чебер, тай юлдан, трактор сытып китмәсен,— дип кычкырды һәм үз эшендә булды.

«Әбер-чебер?..»— Илдарга авыл малаеның болай әллә кем булып сөйләшүе бер дә ошамады, ләкин уеннарын бик яратты ул аларның, шуңа күрә каршы сүз әйтмәде. Юл биреп калу өчен, Маратны житәкләп, бер читкә тайпылды. Трактор-малай исә, «ят кошлар» белән кызыксынмый кала алмады, яннарына җитүгә шып туктады.

Билгеле инде, ул үзенең трактор һәм тракторчы икәнен онытмады: башта аягы белән тормозны кысты, бер үк вакытта уң кулы белән рычагны тартып китерде һәм, үзенең шәрә түшенә учын тидереп карады да:

— Әй, водовоз-малай, кая олактың! Әллә күрмисеңме, радиатор кызган!— дип кычкырды.

Трактор белән комбайнны күрсәләр дә рәсемдә генә күргән шәһәр малайлары һичнәрсә төшенмәделәр. Ләкин нинди кызык! Зурысы шулай диюгә, бәләкәе кечкенә генә ыргак белән трусигына эләктергән киндерәне ычкындырды да, водовозлык бурычын да үз өстенә алып, юл читендәге сиртмәле коега йөгерде. Ә ул кое янындагы зур тагарактан кепка аламасы белән су чүмереп алып килгән арада, трактор-малай тракторын төзәтеп маташты: йодрыгын чүкеч итеп ботына сугып караган булды, тез башларына кагып-сугып торды, майкасын күтәреп бармак битләре белән кендеген боргалады, ә үзе күзләрен бер генә дә «ят кошлардан» алмады.

Илдарның өстендә, бик үк яңа булмаса да, әйбәтләп үтүкләнгән юка соры костюм иде. Чалбары тездән генә, балак очлары төймәле. Башында кечкенә козыреклы кепка булып, читеннән карга канаты кебек җете кара чәче чыгып тора, ә аягында сары ботинка иде. Ләкин башлары футбол тибә-тибә тишелеп беткән, бармаклары, бүген булмаса иртәгә, якты дөньяга чыгарга өмет итеп карап торалар. Маратны исә, кайчандыр әнисе хыял иткәнчә, Ленинның сабый чагындагы кебек итеп киендергәннәр: дулкынланып торган кызгылт чәчләре уңга ачылган, өстендә озынча ал сатин күлмәк, шундый ук штан, биленә тар гына кәмәр буылган, аякларында җиңелчә кызыл итекләр иде.

Трактор-малай, әлбәттә, Маратларның өс-башларына кызыкты, ләкин сер бирмәде. «Бик инде, мин моның ишене...»— диде аның мәлшәйгән иреннәре. Ул водовоз-малай китергән суны «радиаторы» күбенгәнче чүмерде-чүмерде дә:

— Фи, Лаеш малайлары булгач, мин әллә ниндиләр дип торам...— дигән булды.

— А-а, без Лаештан түгел дә әле.

— Ә каян?

— Казаннан.

— Әйе сиңа?

— Марат, күр әле, ышанмаган була...

Трактор-малай моңар каршы ни дисен? Башка җирдә, мәсәлән, берәр ят авылда яки урманда очраса, ә мин Мәскәүдән дияр иде дә бит, үз авылында ялган хәзер тотыла... Шулай да аның аста каласы килмәде, әкрен, ләкин горур тавыш белән:

— Ә минем әни агротехник,— диде.

Шәһәр малае өчен бусы да, радиатор, водовоз кебек үк яңа сүз иде. Ләкин ул, белмәгәнен йөзенә чыгармыйча, минем әни укытучы дияргә теләп авызын ачты. «Ә укытучы агротехникның тырнагына да тормас булса?..»— Илдар шулай икеләнеп торганда, трактор-малай үзенең өстенлеген ныгыту өчен, өстәп куйды:

— Былтыр 300 труддень эшләде.

«Монысы нәрсә икән тагын?.. Нәрсә булса да булыр, гел аста калмас ич инде»,— Илдар, күп уйлап тормастан:

— Ә минем әни 400,— диде.

— Һа-а, бик инде... Ә минем әти 500!.. Түлке хәзер сугышта әле... Бортмеханик. Ну, летчик инде... Врррр...

Малай, самолет булып, кулларын киң җәеп, әйләнеп йөрде-йөрде дә (янәсе, ул истребитель, таран ясый) башы белән Илдарның күкрәгенә китереп төртте:

— Врр-рх!

Илдарга малайның бу уены да ошады, төрткәненә сүз әйтмәде. Ә инде тагын бер тапкыр әйләнеп килеп, башы белән Маратны «таранить иткәч», Марат матур штаны белән лап итеп тузанга утыргач һәм авызын мәлшәйтеп елап җибәргәч, түзмәде, йодрыгы белән тегенең «радиаторына» шундый китереп төртте, «трактор-самолет» үзенең артындагы «комбайн» аша мәтәлеп барып төште. Ләкин ай-яй җитез малай икән, оста футболчыларча ялт сикереп торды да Илдарның якасыннан эләктереп тә алды:

— Измәңне изәм бит, бүдәнә!

— Җибәр якаңы! Я ипи шүрлегеңне җимереп ташлармын..,

— Җимергән кушмасыннар! Китереп торып кундырсам, читәннең анау ягына мәтәлеп барып төшәрсең.

— Төшкән иде ди!.. Китереп торып берне соссам, тамталлар арасына тәгәрәп китәрсең.

Икенче секундта алар инде, җим өчен тартышкан чыпчыклар кебек, юл тузанында әүмәкләшә иделәр.

Марат нишләсен икән хәзер? Ягедидә торганда, ул Саниягә тия башлаган бер малайны карабиныннан ата-ата куып җибәргән иде. Бу зур шул, карабиннан гына курыкмас... Марат, ярдәмгә әнисен чакыра-чакыра, капкага таба йөгерде.

Әлбәттә, Илдарга эләккән булыр иде. Көчләре бер чама булса да, «трактор-самолет» бик житез һәм чамасыз кыю иде. Шуның өстенә ул бит үз авылында! Ә үз йортында читәннәр дә булыша, ди... Ләкин шул чакта өсләренә җитеп килгән грузовикның кисәтеп кычкыртканын ишетеп, малайлар туктап калдылар. Грузовик та туктады. Аңа бик күп пионерлар төялгән: малае, кызы бер-берсенә тотынышып баскан, галстуклары җәйге кояшта ялкын телләредәй балкып җилферди, үзләре шундый матур, бик матур итеп бер җыр җырлый иделәр:

Эх, Иделнең буйлары,
Җәелеп аккан сулары...

Пионерлар тузанга батып әүмәкләшкән сугыш чукмарларын күргәч, җырларын әкренәйтә төшеп, бер-берсенә карашып-көлешеп алдылар, аннан, тагын да көчлерәк җырлап, кузгалып киттеләр.

Беркайчан да табалмассың
Аннан ямьле, аннан данлы елганы...

Трактор-малай, сикереп торган уңайга тузан болытына күмелеп, үзенең комбайнын әйди-әйди, грузовик артыннан йөгерде. Ә куып җитә алмагач, туктап, янәдән Илдарлар янына килде:

— Барыбер җитә иен мин аның артыннан. Дүртенче скоростька куеп өлгерде...

Сабый чак, сабый чак!.. Минут үтүгә малайлар инде якадан алышуларын, тузанда әүмәкләшүләрен онытканнар, татулык договорына кул куелган, бер-берсе белән танышып өлгергәннәр, хәзер хуҗалар кунакларга авыл күрсәтеп йөри иделәр.

Шәһәр малайларына күргәне бере күңелле булды. Алар хәтта коега, аның күккә «тиеп» торган озын сиртмәсенә, сиртмә очындагы агач чиләккә хәйран калып карап тордылар, Илдар чиләктән тамган бер тамчыны, әллә ни күреп, куш учына тотып алды.

— Телисеңме, су алып эчерәм,— диде аңар малайларның трактор булып уйнаганы, Фәрит исемлесе.

— А-а, ала алмыйсың да әле...

Фәрит күкрәгеп киерде.

— Минме? — Анкары үзенең комбайнына эндәште:— Шамил нәнәм, күр әле моны, ала алмыйсың, ди.

— Йә, ал.

Трактор-малай, кулларын алмаш-тилмәш йөртеп, чиләкне аска төшерә башлады.

Ничек кызык! Сиртмәнең җиргә тиеп торган башы, үзенә тагылган иске тәгәрмәч тугымын, борны китек балта, тимер кыршау, тагын әллә нәрсәләрне шалдыр-шолдыр өстерәп, югары күтәрелде, ә чиләк, күктән бик тиз төшеп җитеп, кое авызында күздән югалды һәм шунда ук аның кайдадыр тирәндә, суга бәрелеп, ишкәк ишкәндәге кебек күңелле чапылдаганы ишетелде. Озак та үтмәде, мөлдерәмә сулы чиләк кое авызыннан килеп тә чыкты.

— Мә, эч.— Трактор-малай Шамилнең әллә юыла-юыла, әллә чиләк урынында йөри-йөри уңып беткән кепка сәләмәсе белән су чүмереп алды да Илдарга сузды, ә Илдар суны иреннәренә китерүгә, кире алып улакка түкте:

— Әем, эчмә, чишмәдән эчәрсең. Чишмә суы зрә тәмле безнең. Моның бакасы бар...

— Бар сиңа...

— Күрәсең киләмс?

Илдар, трактор-малай артыннан кое бурасы читенә килеп, куркып кына аска карады. Ләкин аның ияләнмәгән күзләре кара су читендә, бураның бүселеп чыккан бүрәнәсе өстендә мүк кимереп яткан баканы күрмәде. Коеның муртайган юеш стеналарыннан Илдарның тирләгән битенә үтә дымлы салкын һава килеп бәрелде.

— Ай-яй.

— Нәрсә ай-яй?

— Тирән.

— Бу нәрсә-ә! Суы да чиләк күмелерлек кенә аның. Менә түбән очныкы ул...

— Фәрит абый чиләккә утырып төште.

— Төшәр инде?
— Фәрит абый, кара әле моны, ышанмаган була!
— Ике тапкыр төштем. Казылып беткәнче тулке.
— Ник?
— Бәхәстән.
— Я, тагын төш.
— Төш, ә, Фәрит абый?

Их, бер күрсәтсен әле Фәрит шушы шәһәр малайларына үзенең кем икәнен!..

Фәрит, ничек чыгу турында уйлап тормастан, аягын чиләккә тыга башлады. Шул чакта каршы капкада бик бетәшкән бер әби күренде. Әби капкадан чыгуына, кәкре таягы белән кизәнә-кизәнә:

— Көшегез, көш, юньсезләр, көш, кое яныннан,— дип кычкырды.

Илдар белән Марат, куркышып, читкә тайпылдылар. Ә авыл малайлары икесе дә тыныч иделәр. Шулай да Фәрит чиләк тагылган чылбырны җибәрде. Чиләк, очкыч шар төсле жиңел атылып, һавага менеп китте.

— Курыкмагыз, безнең әби ич ул,— диде Фәрит.— Аягы раматизлы аның. Ул килеп җиткәнче, мин, агаенем, бу коега җиде кат төшеп менәм... Ну, үзеннән шүрләгәнне бик ярата. Әйдәгез, куркып йөгергән булабыз.

Малайлар, берсен-берсе узып, тар тыкрыкка шылдылар.

Кемнәрне генә әсир итмисең син, әй җәйге авыл, үзеннең су буйларың, яшел болыннарың, бөдрә урманың, алтын кояшың белән!.. Ә гомерендә беренче тапкыр күргән Илдар өчен авыл — әкият дөньясы иде. Йөрүе, йөгерүе дә әкияттәге кебек җиңел тоелды аңар. Менә хәзер, гарәп әкиятендәге патша улы төсле, бер тилпенеп куяр да һавага очып менеп китәр кебек иде.

Бер тавыш юк. Тик әллә нигә бер, күңелле итеп, пароход кычкыртып куйганы гына ишетелеп китә. Илдар әсәрләнә. Фәрит, аның нигә әсәрләнгәнен төшенеп, аңлатып бирә:

— ...Идел якын ич безгә. Кама да. Салават батыр тавына менсәң, күренеп тора. Олы малайлар су керергә гел шунда йөриләр.
— Без дә бер барырбыз әле, ә, Фәрит?
— Барырбыз.

Пароход тавышы тынуга, кайдадыр чәчәкләрдән бал җыеп йөргән умарта кортларының безелдәшкәннәренә хәтле ишетелә башлый. Бигрәк тын шул. Өй түрләрендәге биек өянке, тирәк, карт юкәләр дә тын. Гүя алар да Илдарлар кебек авыл буйлап чабып йөри-йөри әлсерәп беткәннәр, хәзер тузма башларын түбән иеп, кыл кыймылдатмый рәхәт оеп утыралар. Кызыл, яшел түбәле өйләргә дә, анда-санда кысылып калган салам башлы каралтыларга да рәхәттер кебек. Гүя алар да чәчәк исле саф һавага, җылы кояш нурларына мәлҗерәп черем итәләр. Ә күге шундый матур, шундый зәңгәр, әйтерсең, Ягедниненең Зәңгәр Күлен алып килгәннәр дә, бик-бик югарыга менгезеп, йөзтүбән асып куйганнар...

Авыл Илдарның гына түгел, кечкенә Маратның да күңелен биләде. Әниләренең, ерак китмәгез, хәзер чәй куям, дигәнен Илдар белән бергә Марат та онытты. Өй түрендәге рәшәткәле бакчалар да, тал читәннәр дә, канау читендәге пәйгамбәр чәчәге, күкчәчәк, бака үләннәре дә — бар да, бар да аның сабый күңелен җәлеп итте. Башкалардан күрмәкче, Марат та үләнгә ятып аунады, тыраклап йөрде, сикерде. Тик хәзергә мәтәлчекне генә булдыра алмый иде әле. Башын җиргә кадап, аякларын күтәрә башлауга яны белән лап итеп авып төшә иде. Һәй, өйрәнер әле!... Хәзергә койма буйларында өелеп яткан бүрәнә өемнәренә менеп йөгереп йөрде. Йөрде-йөрде дә сикереп төште, тагын менеп китте.

Ә Фәрит? Үзенең коега төшкәнен күрсәтә алмый калган Фәрит ниләр генә кыланмады! Кулларын як-якка җәеп, читән башларына басып йөрде, егылып төште дә тагын менеп китте. Ишек алларындагы өянке башына менеп төште. Аякларын югары күтәреп, куллары белән атлап йөрергә омтылып караган иде дә, булдыра алмады. Бер егылды, ике егылды, өченчесендә ботыннан тотып торган Шамиле белән бергә әйләнеп барып төште. Билгеле инде, ул, син ектың дип, Шамилгә сылтады, ләкин бу номерны Шамилсез генә кабатламады, уңышсызлыкка очравын яңа мәзәк белән гомаларга теләп, сикереп торды:

— Төн качып яткан җирне күрсәтимме үзегезгә?

— Төн?

— Әһе. Төн качып яткан җирне?..

— Килә.

— Әйдәгез.

Фәрит, шәһәр малайларын ишек алларына җилтерәтеп алып кереп, кар базларының капкачын ачты.

— Тык башыңны!

Илдар карады да көлде. Марат бераз вакыт башын кар базына тыгып карап торды да:

— О-о, төн зул, бу кечкенә,— диде.

— Менә монда да бар.— Фәрит, кунакларны өйләренә алып кереп, бәрәңге базларын ачып күрсәтте.

— Ю-ук, төн зул...

Фәрит кунакларны маскировкасы корылган килеш калган мунчага алып керде:

— Менә тагын...

Беркатлы Марат ышана калды.

— Сания апама да күлсәтелбез әле, яме, Фәлит абый?

Кунаклар, бик тиз ияләшеп китеп, үзләрен Ягедниләрендәге кебек иркен тоттылар. Әллә нигә бер очрап куйган кеше үтеп киткәнче, яки капка төбенә кояшка сөякләрен йомшартырга чыгып утырган киез итекле, җитен сакаллы берәр бабай яныннан узганчы тынып тордылар да тагын теләсә нишләп йөрделәр. Бакча рәшәткәләрен чыбык белән сирпеп үттеләр — «трин, трин, трин...» — читәннәрне тотып-тотып карадылар. Илдар, хәтта, рәшәткәдән чыгып торган бер миләшне өзеп алырга батырчылык итте. Миләш пешмәгән иде әле, яңа кызарып килә, ә малай аны бик тәмле күреп кабып йотты.

— Илдал абый, миңа да...

Фәрит Маратка үз бакчаларыннан миләшне тәлгәше белән өзеп алып бирде.

— Ләхмәт, Фәлит абый. Ә нәлсә бу, Фәлит абый?

— Миләш.

— Милә-әш... Ай-я-ай...

Кунакларга һәр яңалык никадәр кызык тоелса, аларның белмәүләре хуҗаларга шулкадәр сәер күренә иде.

— Теге нәрсә?

— Әллә Казанда юк? Силос башнясы ич.

— Анда нишлиләр?

— Менә сиңа кирәк булса!.. Силос салалар.

— Нәрсә ул силос?

— Кара әле, Фәрит абый, шуны да белми!.. Мал азыгы. Аны, агаенем, безнең Вил дә белә.

— Ә мал нәрсә?

— Кит лә-ә!

Шамил җавап бирмәгәч, Илдар Фәриттән сорады:

— Фәрит, мал нәрсә?

Фәрит Илдарга ачулы итеп карады:

— Син юри-мырый сорыйсың. Укытучы апа шикелле. Укытучы апа да үзе белә, үзе сорый...

Хуҗалар кунакларның белмәгәннәренә ышангач, үзләрендәге өстенлек белән масаеп, берсен-берсе бүлеп, җавап бирә бардылар:

— Әллә Казанда юк? Пожар сарае ич.

— Кисмәкләре нәрсәгә?

— Менә тагы!.. Пожар сүндерергә,— диде Фәрит һәм пожарный Гайнетдинчә кайгыртып:

— Түлке атлары юк әле, задание ташырга алдылар. Үзең беләсең — сугыш. Тарту көче җитешми,— дигән булды.

Иөри-йөри ачыктылар шәһәр малайлары. Ләкин аларның берсенең дә өйгә кайтасы килми иде. Кайту кая!.. Артларыннан эзли чыккан Санияне дә, кызыктырып, үзләре белән ияртеп алып киттеләр.

— Әй, без бел төштә булдык, Сания апа...

— Алачыкта.

— Әйе, алачыкта. Йолдыз ясый торган җирдә.

Сания, икеләнеп, Илдарга карады. Илдар Саниягә күз кысып куйды.

— Белсе кызыл сакаллы, белсе кала сакаллы абый чүкеч белән кызган тимелгә сугып тола, йолдызлал һавага очып тола. Ә кич булгач, яналал... Чыгып калалбыз әле, әйе бит, Сания апа?

Балалар бары әниләре килеп чакыргач кына кайтырга булдылар. Алар барысы берьюлы әниләренә килеп сарылдылар һәм күргәнен берен тезеп киттеләр:

— ...Әнием, бер дә китмик авылдан, яме, әнием?

— Иртәгә дә, аннан иртәгә дә, яме әнием?

2 КАЗ БОТЫ

Гөлсем апага да ошады авыл. Ләкин ул авылның шул шигъри матурлыгы артында аның кырыс йөзен, авыр хәлен дә күрә белде. Әйе, ул да авылның табигый бизәгенә, шул бизәкләргә яраклаштырып, шуна пар китереп кеше өстәгән бизәкләргә сокланып карап торды. Сиртмәле

коесына, үзеннән зур көянтә-чиләкләр күтәреп суга баручы кыз балага, бар да бертөрле, шул ук вакытта һәркайсы үзенчә матур өйләргә, киртләч коймаларга, сырлы капкаларга карады. Карады да, боларның кайсының гына төбендә ир белән хатын, ана белән ул, егет белән кыз елашып аерылышмады икән дип, көрсенеп куйды. Сугыш җәһәннәменең ялкыны, бер ел дигәндә, авылны шәһәргә караганда да рәхимсезрәк итеп көйдерергә өлгергән, авыл өстенә җәелгән сугыш сөреме исен чәчәк исләре генә томалый алмаган иде.

Гөлсем апа самоварын куюга кибеткә керде. Кибеттә ипи заты, гомумән, булмый икән, Лаешның үзенә барып алырга кирәк икән, анда да әле һәр көн булып тормый икән. Күршедән әҗәткә берничә бәрәңге алып чыгып, яшел суган, бөтнек кебекләр белән алдаштыргалап, аш пешереп ашатты да карыннары кабат ачкапчы дип, балаларын тизрәк йоклату ягын карады. Иртәгесен озаграк йокласыннар өчен, сакланып кына атлап йөрде. Ә торуларына, «әни, урамга» дигәч, Ягеднидәге кебек, «чәй эчкәч» дип тормады, берәр ландрин тоттырды да сөя-сөя чыгарып җибәрде.

Илдар белән Марат чыкканда, Фәритләр инде күптән килеп житкәннәр, тик, укытучы апаларыннан уңайсызланып, дәшәргә кыймый торалар иде. Капкадан килеп чыгуларына, йөгереп килеп, сарып алдылар:

— Әйдә, Илдар, су керергә.

— Кая?

— Инешкә. Әнә генә. Басу капкасын чыккач та.

— Әем. Маратка әни кушмый.

— Куш-а,— дип сузды Фәрит,— Шамил белән купальняда керерләр. Зрә сай. Маратның түшеннән дә юк.

— Әйдә, алайса.

Юлда аларга тагын алты-жиде малай иярде. Фәрит белән Шамил ияргәне бере белән таныштыра барды:

— Рәшит. Быел беренчегә керә. Әтисе фронтта. Әнисе олаучы. Калача әйтсәк — ямьшек була инде.

— О-о, әни кеше ямьшек булмый да әле.

— Булмас, бар. Безнең, агаенем, сельсовет та әни кеше, Күчерт әнисе.

— Әнә, Күчерт үзе дә...

— Кит лә, андый исем булмый да әле.

— Исем түгел ул, кушамат.

— Ник?

— Гел кучерт тә кучерт,— дип утыргач... Бер тапкыр укытучы апага да әйтте.

— Ник?

— Укытучы апа, я, Җәмил, яздынмы дигән ие, башын күтәрде дә, кучерт, диде. Шуннан Кучерт Җәмил китте.

— И-и...

— Үзенә әйтмә түлке.

— Ник?

— Елый башлый...

— Фәрит абый, Харисны чакырыйммы?

— Чыгарыр аның әнисе!..

— Әнисе өйдә юк. Пристаньга, катык сатарга китте.

— Алайса, чакыр...

Шамил черелдәтеп сызгырып җибәрде. Озак та үтмәде, бай гына бер йортның капкасыннан Харис дигәннәре — нәзек-озын бер малай килеп чыкты. Аның бөтен киеме бер чалбардан гыйбарәт булып, ул да әтисеннән калган, үзенә бик зур, кендектән әллә никадәр күтәртеп кигән булуга карамастан, балагы җир себереп йөри иде, тез башларында һәм утыра торган җирләрендә кат-кат ямау. Башы да ямаулы кебек иде аның: сарык йоны ала торган кайчы белән тигезле-тигезсез китәрелгән чәче ерактан шулай булып күренә иде. Малай капка төпләреннән бер-ике адым гына атлады да, имән бармагын авызына капкан килеш, туктап калды.

— Әйдә, Харис!

Харис, бармагын авызыннан алмыйча, кыюсыз гына килеп, төркемгә иярде. Күреп күнеккәнгәдер инде, малайлар аны бик тиз оныттылар. Ә Илдар белән Марат аңардан күзләрен алмадылар.

Чалбары гына түгел, үзе дә әллә ничек сәер иде ул. Сүзгә кушылмады. Ниндидер оялчан бер елмаю белән елмайган йөзе балалар кызык сөйләсәләр дә, житди сүзгә күчсәләр дә, кыяфәтен үзгәртмәде, чалбарын, чәчен әйтеп мыскыл иткәндә дә, гел бертөрле елмая иде. Ләкин аның бу сәер елмаюы артында сагыш, ниндидер моң яшерелгән икәнен күрү читен түгел иде. Моны Илдар бер карауда сизде. Ул Фәритне арткарак алып калып:

— Нигә андый ул, ә?— дип сорады.

— Әнисе үги.

— Ә-ә...

— Зрә кага.

Илдар, Харисны кызганып, телен шартлатып куйды.

— Бик эшләтә дә. Маллар карата, су ташыта. Ә үз кызыннан ташытмый. Үз кызы чигү чигеп кенә утыра... Әнәтерә...

Тәрәзәдә, унбер-унике яшьләрендә генә булуына карамастан, кыланчыклык әлифбасын тәмам үзләштереп өлгергән: яулыгын арттан бәйләгән, бит алмаларына күп итеп иннек-кершән сөрткән бер кыз бала күренде. Фәрит аңар йодрык күрсәтте: «Ө-е!..» Кыз, телен чыгарып, Фәритне үчекләде дә тиз генә пәрдәсен төшерде. Фәрит кызга усал гына бер сүз әйтә башлаган иде, аңар Шамил килеп сыенды.

— Әкбәр...— диде ул, куркып.

Тәбәнәк кенә читән койма башында Илдарлардан шактый зур бер малай чүгәләп утыра иде. Малай, озын пиджак чабуларын канат итеп, күркә булып кагындыкагынды да, озын муенын сузып, ата күркә кебек гылдырдап җиргә очып төште.

Күңелле генә чыкты. Ләкин берәү дә көлмәде. Фәрит исә кашларын җыерды:

— Кушаматы да шундый аның: Ата күркә,— диде Фәрит.— Яман усал. Чукырга гына тора... икенчедә ике ел утырды инде.

Әкбәр сынык пәке белән тал чыбыгы юна-юна, малайларны көтеп алып, урталарына керде.

Голдыр-голдыр-голдыргу,
Әкбәр абзагыздыр бу...

Әкбәр бик мәзәк итеп такмаклады. Ләкин малайлар берсе дә көлмәде. Араларына килеп керүенә, тавыштынсыз гына як-якка тайпылдылар.

Әкбәр исә, ят кошларны бер кат күзеннән кичерде дә:

— Хай-хай-хай, кунаклар бар икән ич, күрми дә торам,— дигән булды. Аннары сирәк тешләре арасыннан челт итеп төкерде дә, Фәриткә ишарәләп,— ә каз боты белән сыйладыгызмы соң әле үзләрен?— диде.

Фәрит дәшмәде.

Әкбәр, ни өчендер, Маратның штанын тотып карады:

— Каз боты ашатмадылармыни әле сиңа, олан?

Беркатлы сабый:

— Миңа әнием канатын билде, аннан белаз ак итен,— диде.

— Юк, сиңа боты кирәк. Яле тешләрең тазамы?

Марат тешләрен күрсәтте. Моңысына малайлар көлештеләр. Ни җитди Илдар да елмаеп куйды.

— Самый каз боты кимерә торган икән,— диде Әкбәр.— Ярый, авызыңны яп инде. Син су кереп чыгуга, бик тәмле итеп пешереп куярбыз, алла теләсә...

Ни дияе соң бу Ата күркәнең?— Илдар, әлбәттә, Фәриттән сорашып белгән булыр иде, ул арада инешкә килеп җиттеләр, ә анда икенче бер кызык килеп чыгып, каз боты турында онытып җибәрделәр.

Төбе-тамыры белән авып, инеш аркылы күпер булып сузылып яткан, яшел яфраклары әз генә дә шиңмәгән өянкегә каяндыр бер соры куян йөгереп килеп керде. Чын куян, зоопарктагы шикелле. Каушап калган балалар исләренә килгәнче, куян, өянке ботаклары арасыннан сикерә-йөгерә үтеп, аргы як ярдагы гөлҗимеш куаклары арасына кереп югалды. Куян инеш аша чыгып җитәр-җитмәс, өянкегә куа-куа әлсерәп беткән зур гыйца бер эт, сары тимгелле кәкре койрык, атылып килеп керде. Эт өянке буйлап куян кебек оста чаба алмады. Җитмәсә, чыгып җиттем дигәндә генә, ботакка бәрелеп, шап итеп суга барып төште. Төште, ләкин каушап калмады, күз ачып йомганчы калкып чыкты да йөзеп китте. Малайлар, шау-гөр килеп, кайсы өянке буйлап, кайсы су аша йөгерә-йөзә куян белән эт артыннан йөгерделәр:

— Тизрәк, Сарбай, тизрәк!

— Каптыр, Сарбай, каптыр!..

Ләкин куян куян шул инде. Эт ярга чыгып, эзгә төшкәнче, китек колактан җилләр искән иде. Сарбай, куакларга бәреләсугыла урманга кадәр йөгерде дә туктады. Күрәсең, ерактан куып килгәндер, эт тәмам әлсерәгән иде, гарьлегеннән ярсып чиный иде. Малайлар аны юата-юата инешкә кадәр алып кайттылар да, чыр-чу килеп, өсте көзге кебек тигез, тын суга ташландылар.

Марат белән Шамил исә Фәрит әйткән купальняда — берничә генә озын такта белән корып алынган ярым түгәрәк эчендә — чыпырдаштылар.

— Синеңчә, куян кызганычмы, этме?

— Эт.

— Минемчә, куян.

— Ник?

— Эт, тота алса, куянны кабып кына йота ие.

— Алайса, минемчә дә куян.

Чыпырдап туйгач, Марат белән Шамил су читенә,

кояш җылысына чыккан маймычларны куып йөрделәр. Аннан «оек киделәр» (аякларын тез асларына кадәр ләмгә буядылар), «трусик киделәр», шул ук ләмнән берберсенә «галстук тактылар».

— Гел шулай йөрибез, яме?

Ә Илдар белән Фәрит кебегрәкләр, йөзеп туйгач, камышлыкка кереп, кача-кача уйнадылар.

Күргәне юк икән, уен Илдарга бик ошады. Малайлар, камыш төбенә чумып, авызларына куш эчле камыш кабып яталар. Берсе эзли. Кем дә кем үзен сиздерсә: камышы селкенсә яки камышы төбеннән кабырчыклар чыкса, аңар җәза бирелә: трусигы я штаны белән күзен бәйлиләр дә әлеге өянкегә менгезеп бастыралар. «Марш, аргы якка!» Ансат түгел. Ләкин, кара син аларны!.. Җәзага хөкем ителгән малайларның күбесе аргы якка шома гына чыгып җитеп, янәдән уенга кушылды. Тик кайберләре генә суга егылып төште. Илдар да ярты юлга житәр-житмәс суга шапылдады. Ул, мөгаен, чыгып та житкән булыр иде, бер дә сынатмаска тырышып, бер дә каушамыйча, бөтен уен өянкегә биреп атлый иде, энесенең кинәт кенә елап җибәргәнен ишетеп, каушап китте. Ә андый чакта каушадың — беттем диген инде...

Илдар йөзә-атлый судан чыкканда, Марат күз яшьләрен йодрыгы белән сөртеп елап тора, Шамиле юата-юата аның юешләп төйнәлгән штан балагын тешләре белән чишеп азаплана иде. Малайларның кайсылары Маратны, аның матур штанын кызганып сөйләнә, кайсылары, кызык күреп, эче катып көлә иде.

Менә Әкбәр, шаркылдап көлә-көлә, үзе посып торган таш артыннан килеп чыкты да штанны Шамилдән тартып алды.

— Нәрсә син кунаклар өлешенә керәсең? Үзләре кимерсен... Мә, олан, бик тәмле булып пешкән, хи-хи...

Илдар бая Әкбәр вәгъдә иткән каз ботының шушы икәнен аңлады. Һәм, штанны Мараттан алып, дәшмитынмый тешләре белән чишә башлады.

Бик каты иде «каз боты», җитмәсә, тозлы иде. Шулай да Илдар бер балагын чишеп бетерде. Икенчесенә тотынгач, Әкбәр:

— Кара, тәме йөгерде малайга, китер, энең дә бераз авыз итсен,— дип, штанны тартып алып Маратка атты.

Илдар (ахрысы, Әкбәр штанны авызыннан тартып алганда тешен кузгатты) авызын тотып бөгелеп килде. Лә-

кин түзде, еламады, һәм, шунда ук үзен-үзе онытып Әкбәргә терсәге белән бәреп җибәрде.

Юк, Әкбәр — Фәрит түгел инде, «комбайн аша» мәтәлеп барып төшмәде. Шулай да сугыш чукмары, эчен тотып, берничә адым артка чигенде. Ләкин ул авыртудан бигрәк үзен аклау өчен чигенде. «Башлап кем сукты?»

Әкбәрнең күркә дигәнгә беркайчан да ачуы килми. Киресенчә, мондый чакта очынып килә: чабуларын кабарта да, синең тирәңдә муенын сузып, ысылдап чабып йөри. Ә бу юлы алай итмәде, Фәритне бер читкә этеп җибәреп, Илдарның «измәсен изү» өчен алга омтылды. Ләкин шул чакта аның каршысына Кучерт Җәмил атылып чыкты. Харис та кия башлаган чалбарын салып куйды да («болай да алла кодрәте белән генә эләгеп тора, әүмәкләшергә туры килсә, бөтенләй таралып төшүе бар»), Җәмил янына чыгып басты.

Шунысы кызык: Харис әле дә сәер елмая иде, ләкин хәзер аның бу елмаюы артында сагыш та, мон да юк, ачу гына төсмерләнә иде инде.

— Тиеп кенә кара, менә монау таяк белән сосам, икмәк әгәр, сосам,— диде ул һәм су төбеннән табып алып чыккан нindидер агач тамыры белән кизәнде.

Илдар, үзен яклаучыларны күргәч, батыраеп китте. Ул, дулкынланып килеп, кукрәгеи Әкбәргә терәде. Ләкин Әкбәрнең буе озын, җитмәсә, калкурак җирдә басып тора иде. Илдар, аяк очларына күтәрелеп торуына карамастан, башы тегенең ияк астына туры килде. Мондый чакта тез белән ияккә кундырырга бик җайлы була... Ләкин, һәрбер хулиган кебек, Әкбәр дә куркак иде. Хәзер Илдар аның күзенә көчле булып күренде, ә каршысына малайлар да килеп баскач, кикриге тәмам шиңеп төште малайның. Ләкин ул, шүрләгәнен күрсәтмәс өчен, ызгышны уенга борып җибәргән булды.

— Ярый, бар, кайт инде,— диде ул Илдарга.— Әниеңне укытучы диден бит әле... Вәт әйт син әниеңә, мина «казык» утыртмасын... Никтер яратмый башладым әле мин аны, казыкны. Әйт, яме?

Малайлар әле генә бәрелешергә торганнарын онытып көлештеләр. Шул чакта тагын кичәге кебек булды: кичәге грузовик, кичәге пионерларны төяп, килеп житте. Тик бу юлы ул малайлар янында туктап тормады, машина астына килеп кермәсеннәр өчен, бераз экренәя төшеп, кисәтү гудогы бирә-бирә, күпер аша чыгып китте.

— Кая баралар алар?
— Башак җыярга.
Илдар, башакның нәрсә икәнен белмәсә дә:
— Әйдә, Фәрит, без дә барабыз,— диде.
— Әйдә соң.
Балалар, дәррәү кубып, грузовик артыннан йөгерделәр.

3 НИШЛӘТКӘЧ ОН БУЛА УЛ!

Малайлар йөгерешеп басуга килеп җиткәндә, хатын-кызлар кызып-кызып арыш ура иделәр. Яңа туган ай төсле ураклары бертуктаусыз керт-керт итә, көлтә баулары борып алганда шытырдап куялар, грузовик, пионерларны төшереп калдырган да, калтый-колтый сикергәләп, ары китеп бара иде. Пионерлар (малае, кызы) берничә гектар җирне буйдан-буйга урып барган уракчылар артына сибелеп, кайсы кепкасына, кайсы кечкенә кәрзингә, кайсы итәгенә «әллә нәрсә» җыеп йөри иде.
— Син аларны башак җыярга баралар, дидең ич,— диде Илдар.
Фәрит иптәшен көлкегә калдырасы килмәде, пышылдап кына:
— Башак шул ич инде, менә исәр,— диде.
— Ә ник җыялар?
— Иһи-и, си-ин... Ә соң он нәрсәдән була?
Илдар башакны, балалар җыя торган булгач, җиләк яки чикләвек шикеллерәк нәрсәдер дип уйлаган иде. Гайрәте кайтты. Шулай да пионерларның дәртләнеп җыеп йөргәннәрен күреп:
— Без дә җыйыйк, Фәрит, ә? — диде.
— Хәзер... Карлыгач апа, без дә җыйыйк әле.
Пионерлар арасыннан шәрә сыйраклы чандыр гына бер кыз бала күтәрелде. Ул Фәритләргә карап алды да күзләре белән тирә-яктан кемнедер эзли-эзли:
— Гыйззәт абый! — дип кычкырды.
Зур гына чүмәлә төбеннән берәү башын калкытты:
— Кем тия?
— Гыйззәт абый, комбайн участогын болар гына башкара алмас микәнни?
Малайлар, йөгереп килеп, Гыйззәт абыйны сырып алдылар.

Гыйззәт абый — шушы көннәрдә генә Ватан сугышыннан кулын өздереп кайткан кеше. Бригадир. Ул таң иртәдән авыл арасында, аннары басуда тыз-быз йөри-йөри арып, ачыгып беткән; әле яңа гына бераз капкалап алырга дип, чүмәлә күләгәсенә килеп утырган иде. Алдында, кызыл буйлы тастымал өстендә, әрчеми пешерелгән салкын бәрәңге, бер-ике кыяр, әрекмән яфрагы белән дым тарткан тоз, чалгы пәке. Ул, малайларны күргәч, иреннәренә китергән бәрәңгесен тастымалына куеп, ялт сикереп торды.

— Болармы? — Бригадир яктырып китте.— Ә нигә башкармасыннар икән?..

Гыйззәт абый кояш алган гимнастерка чабуларын төзәтте, каешын рәтләде.

— Построиться!—диде ул, җитдилек саклаган булып.

Солдатның хәрби киемнәренә кызыгып карап торган малайларны Карлыгач сафка тезеп чыкты.

— Һм-м, сыеграк икән шул,— диде бригадир, сафны күзеннән кичереп.— Ну, ничего. Елына күрә җылы шулпа... 1, 2, 3, 4, 5, 6 номерлар ике адым алга. Ә сез, кругом арш! Бераз үсә төшкәч килерсез, яме?

Марат белән Шамил бригадирның сүзенә төшенмәделәр, ә Фәрит аңлатып биргәч, күңелсезләнә калдылар.

Марат, еламсырап:

— Әем, без дә җыябыз,— диде.

Бригадир елмайды. Ул Маратны сыңар кулы белән күтәреп алып, күкрәгенә кысып торды да, җиргә бастырып, башыннан сыйпап куйды.

— Карлыгач, бар, үскәнем, комбайн кырына илтеп кил үзләрен,— диде ул. Үзе яңадан чүмәлә төбенә иелә башлаган иде дә, нәрсәдер исенә төшеп, сәгатенә карап кылт туктап калды һәм, тиз генә тезләнеп, сыңар куллыларга хас бер осталык белән табынын җыеп алды һәм, полевой сумкасына бөтереп тыгып, сикереп торды:

— Сорасалар, ындырда булам...

Карлыгач малайларны әле янарак кына комбайн урып киткән җиргә илтеп, бер-берсеннән ун-унбиш метр ара калдырып тезеп чыкты да, Фәриткә кайбер күрсәтмәләр биреп, үзе арыш кырына, иптәшләре янына йөгерде.

Өлгерде дигәндә генә боз сугып киткәнлектән, бодай егылгалаган, комбайн андыйларын ала алмаган, шуңар күрә җирдә башак хәтсез күп калган иде. Малайлар бик дәртләнеп эшкә керештеләр. Ә Илдар каушады. Ул бер

бөгелде, бер тезләнде. Эзли-эзли йөгереп барды, тагы тезләнде:

— Фәрит, мондыйларын да алыргамы?

— Алырга.

— Фәрит, нишләткәч ои була соң ул?..

— Менә тагы! Тарткач, билгеле.

Марат белән Шамил, абыйлары ни әйтсәләр дә, кайтып китмәделәр, Карлыгач күздән югалуга, чәчәк җыйгандагы кебек башын башка куеп кына, бик пөхтәләп кенә башак җыярга керештеләр.

— Ә мин монысын Сания апама апкайтам.

— Сания апаңа менә монысын алып кайт.— Фәрит Маратка кайдандыр килеп кергән кылчыклы бодай башагы ыргытты.

— Мыеклы!— диде Марат.— Мыек итеп уйныйм.— Марат башакны борын төбенә куйды һәм шунда ук кире алды:

— Әем. Кычыттыла...

Бар да көлештеләр. Фәрит Саниягә дигән башакның саламын алкалады да Маратның кепка төймәсенә эләктереп куйды.

Марат белән Шамил башак җыярга ни теләп керешкәннәр иде, бик тиз туйдылар. Алар каланча төбенә килделәр дә абыйларының ничек җыйганнарын карап тын гына утырдылар. Ләкин кеше эшләгәнне карап утыру бик тиз туйдыра икән. Тордылар да, җитәкләшеп, машинка белән алынган чәч шикелле төбе күренеп торган камыл буйлап әкрен генә китеп бардылар. Камыл төпләрендәге яңа үсеп чыккан яшь үләннәрне тотып-тотып карадылар. Марат берсен өзәргә омтылган иде дә, «я орышырлар»— дип куркып, кулын кире алды.

— Абау теге нәлсә, Шамил?

— Керпе ич. Курыкма, тими ул. Бармак белән төртимме хәзер үзенә?

Керпе, балалар килә башлагач, башын яшереп, инәләрен тырпайтты да саз түмгәге кебек хәрәкәтсез калды.

— Ник?

— Бездән курка.

— Ыллый, бездән кулка, ыллый!..— Марат кулларын чәбәкләп куйды.

— Китсәк, курыкмый.

— Әйдә, киткән булабыз.

Балалар каланча баганасы артына посуга, керпе, аякларын чыгарып, инәләрен яткырып, юлын дәвам итте. Артыннан йөгерә башлагач, тагын түмгәк булып катты.

Йөри торгач, балалар, бер-бер артлы тезелеп, үзләре салган тасма юлдан арлы-бирле йөреп торган бик күп кырмыска көтүенә очрадылар. Шамил чүгәләде дә, юлларына бармагын куеп, шаярта башлады. Шул арада берничә кырмыска Маратның аяк йөзенә үрмәләде, берсе ике бармак арасын тешләп тә алды. Марат кычкырып җибәрде. Шамил кырмыскаларны Маратның балтырыннан сыпырып төшерде дә үзендә өстенлек саклап:

— Курыкма,— диде.— Менә мин юри дә тешләтәм.— Авыл малае бер кырмысканы тотып алып учына салды Тешләү кая, кырмыска тизрәк учтан төшеп китү ягын карады. Шамил аны эләктереп алып башы белән учына терәде:

— Тешлә, йә, тешлә!..

Аңардан күрмәкче, Марат та, берсен тотып алып, башын уч төбенә терәп торды:

— Я, теслә!..— диде ул, һәм шунда ук, кытыкланып, кырмысканы учыннан өреп төшерде. Кырмыска, учтан мәтәлеп барып төшүгә, әз генә дә каушап тормастан, үзенең юлын эзләп табып, иптәшләре артыннан китеп барды.

— Нишлилэл?

— Ашарга апкайталар.

— Нәлсә?

Шамил, чүгәләп утырып, башын бик якын иеп кырмыскаларга карап торды да:

— Ашарга түгел икән. Өй салырга бүрәнә ташыйлар,— диде.

— Ээ сина?

— Әнә кара, үзең кара.

Марат иелеп караган иде, кырмыскаларның авызларында салам китекләре күрде.

— Бүләнә түгел дә эле.

— Аларча, бүрәнә.

— Ээ сиңа.

— Честное пионерское.

— О-о, син пионел түгел дә эле.

— Ә мин үскәч барыбер булам...

— Мин дә... Ә болалы бүләнә алылга балалал, әйе бит?

— Әйе, урманга.

— Ничек кызы-ык!..

Шамил чирәмнән бер бөҗәк алып кырмыска сукмагына ташлады. Бөҗәккә шунда ук әлеге кырмыска һөҗүм итте. Кырмыска кечкенә, бөҗәк зур... Бөҗәк сукмактан читкә тартылды. Ә кырмыска (кара син аны!) аякларын терәп, бөҗәкне үзенә таба тартты. Җибәрде дә этте, төрттe, тәгәрәтеп барырга итенде, яңа туган бала чәчедәй нечкә томшыгын дошманының тәненә батырды. Менә бөҗәккә тагын бер кырмыска килеп ябышты. Ләкин анысы икенче якка өстерәде, өченчесе килеп өченче якка өстерәде.

— Эх, төрле оянныкылар!— диде Шамил хафаланып.

Аннан тагын бер кырмыска килеп чыгып, беренчесе өстерәгән якка өстери башлады. Коллектив көч җинде. Алар икәүләшеп, бөҗәкне җилтерәтеп алып киттеләр, якякка өстерәп маташкан ике кырмыска бөҗәктән аерылып калды.

— Ай-яй ти-из...

— Ату кояш байый да, сакта торучы кырмыска ишекне бикләп куя.

Марат ышанмады. Ләкин, кызык ич, каршы әйтмичә, әкият күреп, тыңлап торды һәм үзеннән өстәп куйды:

— Бикләгәч, кылмыскалал тышта кала.

Аннан Шамил өстәде:

— Өсләренә яңгыр ява.

— Әә.

— Өйдә балалары куркып елыйлар.

Аннан Марат белән Шамил күбәләк куып йөрделәр. Куа-куа абыйлары янына барып чыктылар.

— Кайтыйк.

— Бераз уйнагыз әле, нәнәм.

— Әем, кайтыйк.

Фәрит, энеләрен мавыктыру өчен, икесен дә кладовщик итеп билгеләде. Бөтен балалар Маратларга, каланча төбенә, башак китереп биреп тордылар. Болары, Шамилнең тула эшләпәсе белән һәркайсыныкын аерымаерым үлчәп, аерым өемнәргә өя бардылар.

— Бер эшләпә, ике, өч, биш...

— Түгел, элек дүрт, аннары биш.

— Әә сиңа. Элек биш, аннары дүрт.

— Илдар абый, кайсы элек?

— Дүрт, нәнәм.

— Әйдә яңабаштан саныйбыз. Бер эшләпә, ике, өч, дүрт, биш, җиде, алты...

Грузовикта җырлап килгән пионерлар гына түгел, шофер үзе дә гаҗәпкә калды. Алда, инеш күперенә житәрәк, кичтән шәп-шәрә калган җирдә яшел ботаклардан әмәлләштерелгән шалаш кебегрәк ике-өч нәрсә күренә иде. Уртада учак, учак әйләнәсендә башларына әрекмән яфрагын эшләпә итеп кигән, кулларына сөнгеләр, ук-җәяләр тоткан туземецлар (Илдар, Марат, Фәрит, Шамил һәм башкалар) тезелеп утыра, ә юлга аркылы-торкылы берничә бүрәнә (таяк) салынган иде.

Туземецлар машина якынаюга дәррәү сикерешеп тордылар һәм, ура кычкырып, машинага һөҗүм иттеләр.

Шофер юлдагы бүрәнәләрне таптатып күпергә кереп китәргә уйлаган иде дә (әйдә инде, күңелләре булсын!), машинаны туктатып, тәшвишле сигнал биргән булды һәм кабинасыннан чыгып кулларын күтәрде.

Машинадагы пионерлар, шоферга карап, энеләренең тапкырлыкларына сокланып, көлешеп алдылар:

— Кара әле син аларны, нәрсә уйлап чыгарганнар бит!..

Сөнге очларын шоферга төбәп торган Марат белән Шамил шунда ук уеннарын онытып, берсен-берсе бүләбүлә, пионерларга эндәштеләр:

— Ә без бүген дә башак җыярга барабыз.

— Мин кладовщик булам.

— Мин дә...

— Бизмәнебез дә бар. Фәрит абый ясап бирде. Күрсәт инде, Марат.

Марат шалаштан бер башына йодрык хәтле таш (биш тонналы гер), икенче башына кечкенә генә тырыс (подаука) тагылган баулы таяк алып чыгып күрсәтте.

— Иһи, сез!..

— Бригадирыбыз да бар әле. Фәрит абый. Яшерен тавыш белән сайладык...

— Ничек, ничек?

— Яшерен тавыш белән...

Бар да көлде. Шофер, кабинасына керешли:

— Белеп сайлагансыз, достойный егет,—дигән булды.— Әйдә, кунаклагыз, алайса!..

Фәрит коралларын машинадагыларга төзәп торган иптәшләренә әмер бирде:

— Отбой! Коралларыгызны салыгыз!

Малайлар сөнгеләрен, ук-җәяләрен күпер астына төшереп куйдылар да, тәгәрмәчләргә, борт ярыкларына ябышып, кузовка үрмәләделәр. Ә берничә минут үтүгә, грузовик, Фәрит бригадасын комбайн участогында төшереп калдырып, пионерларны урманга таба алып китте.

Төнәген, кинәт яңгыр ява башлагач, Илдарлар үзләре җыйган башакны комбайн саламы белән күмеп калдырганнар иде. Хәзер, машинадан төшүгә, шунда йөгерделәр. (Беренче тапкыр килүчеләргә үзләренең кичә никадәр башак җыйганнарын күрсәтсеннәр әле!..) Ә башак өстендәге саламны алып ташлагач, аптырап киттеләр. Җиде өемчекнең нибары икесе бөтен булып, калганнары чәч тә баш тузгып ята иде.

Ә малайлар кичә аны шундый тырышып җыеп йөргәннәр иде бит, Марат белән Шамил һәркайсынныкын аерым-аерым ни матур итеп өеп куйганнар иде, бүген шул хәлендә, бик тантаналы итеп, Гыйззәт абыйга тапшырырга теләгәннәр иде... Балалар, күңелсезләнеп, бер тын сүзсез тордылар.— «Кем эше инде бу, ә?»

Быел яз көне мәктәптә шундый бер кызык булган иде: беренче класслар табигать почмагында ике әрҗәгә кабак утырталар. Нинди дер яңа сорт булырга тиеш. Орлыгын укытучы Заһит абый сугыштан яраланып кайтып килешли Белоруссия җирендәге бер колхоздан алып кайткан була. Бала саен бер орлык. Һәрбер бала үзе утырта. Инде үренте көткәндә генә (менә сиңа кирәк булса!), әрҗәләрне тутырып, кычыткан борнап чыга.

Билгеле инде, кемдер шаярткан. Бу әкәмәтне башлап укытучы күрә. Ул гаепләне фаш итү өчен хәйлә кора: класска керүенә, шиклерәк балаларны күзәткән хәлдә:

— Бүген табигать почмагына сугылмадыгызмы?— дип сорый.

— Юк.

— Юк...

— Ә мин әле генә шуннан төштем,— ди укытучы,— кабакларыгыз менә дигән булып тишелгән...

Бар да шатланалар. Әкбәр исә, моны укытучының балалардан көлүе дип белеп, башын артка ташлап, авызын ера.

«Әнә кем эше икән!..» — Ләкин укытучы, һичнәрсә сизмәгән булып, Әкбәргә табигать почмагыннан үрентеләрне алып төшәргә куша.

Әкбәр, ялт менеп, бер әрҗәне күтәреп тә төшә. Авызы колакларына житкән.— «Һе, һе, һе... кычыткан ич бу!..»

— Әйе, кычыткан,— ди укытучы.— Инде син безгә мондый уңышка ничек ирешүеңне сөйләп бир.

Әкбәр ык-мык. – «Нишләп мин булыйм?..» — Ә катырак кыса торгач, сөйләп бирергә мәҗбүр була.

— Ә кабак орлыгын кая куйдың?

— Ашадым...

Шул вакыйга исләренә төшкәч, башак җыярга килгән малайлар: «Әкбәр эше, аның эше!..»— дип шаулаша башладылар.

— Менә корткычны син аны!..

— Булмас ла-а, монда безнең башак барын Әкбәр каян белсен ди!

— А-а, кичә җыйганны күреп китте ич.

— Мыскыл итеп китте әле... Болай булгач, пристаньда тагын бер элеватор ачарлар инде, дип көлде.

Фәрит Карлыгачка әйтергә йөгерде. Ул Карлыгач белән укытучыны алып килүгә, малайлар тагын бер яңалык әйттеләр:

— Алган да әле ул. Рәшитнеке менә күпме генә калган.

— Ә минеке соң?..

— Сабыр, балалар.— Укытучы өемчекләргә җентекләп карап торды.— «Так, так...» — Аннан, иелеп, тирә-яктан, камыл төпләреннән нәрсәдер эзләде.— «Так, так...»— Һәм торып басты да болай диде:

— Әкбәрне каһәрләүдән туктагыз. Мәсьәлә ачык. Сезнең бодайга Әкбәрдән зарарлырак корткыч кул сузган. Һәм бер түгел, берничә, бик күп....

Укытучының сүзләренә Илдар белән Марат кына түгел, Фәритләр дә төшенмәде. Ә Карлыгач төшенде. Ул:

— Әкбәр алса, барысын да алыр иде, тычкан тигән, шулаймы, Заһит абый?— диде.

— О-о, тычкан монда хәтле килер инде!..

Билгеле, моны тычканны идән астында гына була дип белүче шәһәр малайларының берсе — Илдар әйтте. Һәм моның өчен аңар бик тә кызарырга туры килде. Кычкырып көлделәр авыл малайлары. Укытучы исә, Илдарны бу бәладән коткару өчен, тизрәк Карлыгачның сүзләрен дөресләргә ашыкты:

— Дөрес, Карлыгач, ләкин бер төзәтү кертик — тычкан түгел, әрлән

— Әрлән, әрлән!..

— Ләкин, Карлыгач, әрләнне гаеплеләр скамьясына утырту өчен синең бу дәлилең генә җитми. Я, кайсыгыз әйтер: ни өчен әрлән, ни өчен тычкан-мазар түгел?

Карлыгач, тезләнеп йөри-йөри, камыл төпләреннән нәрсәдер эзләнә башлады.

«Юк инде, гел Карлыгач та Карлыгач булмасын әле...» — Фәрит, аннан күреп бөтен бала, җиргә иелеп, эзләнергә тотынды. Ләкин алар нәрсә эзләргә кирәк икәнен белмәделәр. Берсе укытучыга шомарып беткән кеч-кенә таш алып килеп күрсәтте. Икенчесе укытучы янына, «таптым, таптым», дип кычкыра-кычкыра, коелып калган бодай бөртеге тотып йөгерде. Укытучы, елмаеп, башын гына селекте.

— Түгел...

— Менә Карлыгач ике салам очы белән җирдән бодай зурлыгы ике-өч соры бөртек эләктереп алды һәм, оялчан кызларга хас уңайсызлану белән уңайсызланып:

— Шушымы, Заһит абый?— диде.

— Мактыйм, Карлыгач. Килегез әле, балалар... бу нәрсә?..

— И-и, мин дә күргән идем аны...

— Тычканныкымы, әрләнныкеме.

— Әрләннеке, әрләннеке!..

— Дөрес.

— Инде әрләннең башакны ничек урлаганын күрәсегез киләме?

— Килә, Заһит абый, килә...

— Безнең дә килә.

— Сезнең дә?..— Укытучы Марат белән Шамилнең башларыннан сыйпады.— Килсә, бәлки хәзер күрә дә алырбыз... Әйдәгез әле...

Балалар башакларны, укытучы кушуы буенча, нәкъ кичәге кебек итеп, комбайн саламы белән күмеп куйдылар да каланчага менеп яттылар, кайсылары каланча баскычларына постылар.

— Хууш... Тирә-як әйбәт күренәме?

Балалар аска карадылар:

— Күренә, күренә.

— Су буе да күренә...— диде әллә Марат, әллә Шамил

— Алай су буе түгел, Казан да күренер. Кире якка карап яткансыз ич...

Укытучы аларны башак өеменә каратып яткырды. Һәм үзе дә, кулларын угалап, балалар арасына кереп ятты:

— Инде шауламагыз, кыл кыймылдыйсы булмагыз. Бик назлы кунак ул әрлән, борылыр да китәр...

Балалар, көләргә дип ачкан авызларын томалап, тынып калдылар.

Кайдадыр дөп-дөп трактор дөпелди икән, авылда чаңчың пожар каланчасы суга икән, тын калгач, бар да ишетелде. Ә күктә, нәкъ баш очында, бик дәртле итеп, тургай сайрый иде. Канатларын җәйгән дә бер ноктада һичбер селкенми тора. Аннан гаҗәп бер тизлек белән ялт икенче урынга күчә һәм яңа ел елкасына элеп куелган алтын кош кебек, хәрәкәтсез кала. Үзе гел сайрый, хәрәкәтсез торганда да, күчеп йөргәндә дә...

Тик балалар аңа күтәрелеп карамадылар. Хәзер алар үзләрен бик зур вакыйга алдында торган кебек хис итәләр иде. Хәтта укытучы үзе дә бу минутта, солдатлары белән окопта дошман һөҗүмен көтеп яткан командир кебек, җитди һәм сизгер иде.

Менә ул, һәр ике ягындагы балаларга терсәкләре белән төртеп, пышылдап кына:

— Гафил булмагыз, кунак килеп җитте,— диде.

Укытучы әйтүгә, балаларның күбесе башак өеменнән утыз-кырык адым читтә бер әрлән күреп, шаулаша башладылар. Йоны кызыл-көрән, мыегы да бар. Берничә генә бөртек, ләкин бик озын, ә аяклары кыска. Күзләре челтчелт итә. Мәзәк шундый, бер дә корткыч димәссең...

— Буксәсе дә бар аның, Илдар. Ике. Яңакларында. Шунда тутырып ташый.

— Әкрен, зинһар, әкрен.

Карлыгач, укытучыдан да әкрен итеп:

— Заһит абый, әнә, тагын берсе,— диде.

Әрләннәр икесе ике яктан килә иделәр. Бер-берсен күргәч, шып туктап тордылар. Аннан арт аякларына күтәрелделәр һәм каләм очы кадәр генә кара күзләре белән як-якка каранып алдылар да, коры саламны чак кыштырдатып, башак өеме астына кереп киттеләр.

Фәрит, әрләнгә ыргытырга дип, кепкасын кулына алды. Укытучы, Илдар аша үрелеп, аның беләген тотты:

— Сабыр. Кирәк түгел...

Корткычлар өем эчендә озак тормадылар. Буксәләренә тутырып, өстәвенә авызларына икешәрме, өчәрме башак кабып чыктылар да килгән юллары буйлап элдерт-

теләр. Һәм, әйтерсең жир йотты, күз ачып йомганчы юк булдылар.

— Я, ничек?

— Ай-я-ай.

— Алар икәү генә булмаган, әйе бит, Заһит абый?

— Ни өчен алай дисең?

— Ул хәтлене...

— Дөрес, Фәрит. Сезне кемендә биш-алты сукбай талаган. Әйе, әйе.

— Ә кая куйганнар?

— Анысын мин үзем сездән сорарга тора идем әле. Я, әйтегез, кая куйганнар?

— Мин беләм, мин беләм.

— Мин дә беләм. Оялрына ташыганнар.

— Дөрес.

— Ояларын эзликме, Заһит абый?

Укытучы сәгатенә, аннан шырпы тартмасы кадәр генә куен дәфтәренә карап алды:

— Булмый. Килегез, иртәгә эзләрбез,— диде.

— Ауларбыз дамы?

— Әйе, ауларбыз да. Үзегез белән көрәкләр алып килегез. Бер-ике чиләк тә...

Укытучы чамалап торды-торды да сугу машинасы тавышы ишетелгәләп куйган якка таба китеп барды. Бераз баргач, борылып:

— Шушы каланча төбенә җыелыгыз. Ләкин иртәрәк кирәк...— диде.

Малайлар, басуга сибелеп, башак җыярга керештеләр. Марат белән Шамил, бизмәннәрен каланча баганасына элеп куеп, корткычлардан калган бодайны үлчәргә тотындылар.

5 ОШАДЫ, ВАСИЛИЙ ДӘДӘ

Икенче көн иртән Илдар кыр буйлап укытучы әйткән каланчага карап йөгерә иде, шып туктап калды. Фәрит белән Шамил беркөн әнә нәрсә булып уйнаганнар икән! Трактор әнә нәрсә икән! Комбайн әнә нәрсә икән!

Илдар аларны күргәч тә таныды. Ничек танымасын! Алдагысы нәкъ Фәрит шикелле дөп-дөп дөпелдәп бара, кешесе рульне нәкъ Фәрит шикелле борып йөртә иде. Комбайн дигәненең киң канатлары бертуктаусыз нәкъ Шамил куллары кебек әйләнеп тора, кешесе дә нәкъ Ша-

мил кебек итеп штурвалны уңга-сулга бора иде. Ләкин беркөн Шамил барысын да эшләмәгән икән әле: бу кеше комбайнның тагын әллә нәрсәләрен кузгатып куя, нәрсәсенәдер аягы белән басып тора, тракторчыга әледән-әле кычкырып ала иде. Билгеле инде, такканы да чабата киндерәсе түгел, юан гына болтлы тимер иде.

Илдар тракторны Ягедни урамнарыннан кырыкмаса кырык үтеп киткән танкка охшатты һәм аңар әллә ни исе дә китмәде. Өстери дә бара. Танк кызыклырак та әле: пушкасы бар. Бух-бах... Ә менә комбайн!.. Ләкин нәрсә эшли соң ул? Комбайн башта Илдарга бодайны сыпырып ашап бара кебек күренде: нәрсәседер сыер күшәгән кебек, ләкин бик җәһәт керт-керт итә, ул узган җирдә бодайлар юкка чыга бара, артында тәбәнәк камыл гына утырып кала иде.

Илдар бодайны кызганып куйды. Их, нинди матур үсеп утыра иде... Тукта, әллә комбайн ялгыш эшли микән? Кешесенә әйтсен микән әллә Илдар?.. Ә инде керт-керт күшәп торган тешләренең бодайны ничек кыркып баруларын күргәч, канатларының ул бодайларны ничек кочып алып, су кебек агып торган яшел брезентка сала баруларын күргәч, аннары бодайларның молотилкага агып кереп, салам булып чыгуларын күргәч, фил борыны кебек озын юан трубасыннан тирән ящикка шыбырдап бодай ага башлагач, үзен-үзе онытып абына-сөртенә, комбайн артыннан йөгерде. Ачкан авызын да йоммады малай, артта, комбайнга тагылган зур арбада, молотилкадан чыккан саламнарны сәнәк белән җиргә этеп төшереп торучы ике үсмер кызның көлешкәннәрен дә ишетмәде.

Комбайн бер әйләнеп чыккач, балалар да җыела башлады. Башта Фәрит килде. Кызык: үзе трусиктан гына, ә башында артиллеристлар фуражкасы. Зур, күзләренә төшеп тора. Бер ягында күгәреп, тишелеп беткән фляга, бер ягында противогаз футляры. Аннары берсе көрәк, берсе чиләк тотып, Рәшит белән Күчерт Җәмил, тагын берничә малай килде. Алар да, комбайнны күтеп алып, Илдарга иярделәр.

— Нигә көрәк алып килмәдең, Илдар?

Шунда гына Илдар үзенең әрлән ауларга барышы икәнен исенә төшерде. Әрлән аулау да кызыктыр, әлбәттә. Ә үзе аулау түгел, кеше аулаганны да күргәне булмаган Илдар өчен, ул бик, бик кызык булыр. Ләкин комбайн

кадәр булмас инде!.. Шәһәр малае аның кай җиренә карарга белмәде. Иелде, үрелде, бер артына, бер алдына төште.

— Ну как, хлопец, игрушечка подходяща?

Илдар югарыга, штурвал күперчегенә күтәрелеп карады. Күперчектәге кеше, үзенең як-якка салынып төшкән озын кара мыегы, трубкасы, вак шадрасы, киң кырыйлы салам эшләпәсе, кысыграк күзләре белән анар кайсыдыр кинокартинадагы мәзәк артист булып күренде. Ләкин бу, әлбәттә, артист түгел, чын комбайнер иде.

Ленинград өлкәсенеке ул. Сугышның беренче җәендә, нәкъ менә хәзерге кебек матур гына урып барганда, кинәт әллә кайдан фашист козгыннары килеп чыгып, моның комбайнын бомбага тоталар. Шактый читкә төшкән бомба җиле комбайнерны бодай өстенә алып ата. Кул, аяк, өч кабырга... Кабырга ялгана, кул да төзәлә, ә бер аякны кистерергә туры килә. Госпитальдән чыккач, комбайнер шул хәлендә кыр корабын йөртергә өйрәнә...

Илдар үзе дә ничек итеп сүз кушарга белми килә иде, аның соравын ишеткәч, шаян елмайган күзләрен күргәч, бер дә тартынып тормыйча, җавап бирергә ашыкты:

— Подходяща.

— Я тоже так думаю. А чей ты, хлопец?

— Учительницын сын.

— Это новой-то?

— Новой.

Трактор туктады, комбайн да туктады. Тракторчы, кабинасыннан сикереп төшеп, ниндидер кораллар алды да чалкан ятып, гаҗәп бер осталык белән этелеп, трактор астына шуышып кереп китте. Малайларның кайсы чүгәләп, кайсы сузылып ятып, кыюраклары башын трактор астына тыгып, тракторчыны күзәтте: «Нәрсәсе ватылды икән?» Күбесе, комбайн янында калып, Илдарны сырып алды. Алар өчен комбайн түгел, Казан маласның шундый оста итеп русча сөйләшә белүе чиктән тыш вакыйга иде.

Ул арада комбайнер, күперчекнең такта идәненә агач аягы белән док-док басып, артка, баскыч төбенә килде дә:

— Так, забирайся сюда, учительницын сын,— диде.

— Можно да, дяденька?

— Ну разумеется.

Илдарны беркайчан да татыганы булмаган шатлык чолгап алды. Бөтен тәне, һәрбер чәч төбе рәхәт кытыклана иде аның. Ул ашык-пошык комбайнга үрмәләде.

Офык киңәеп китте. Бераз читтә кичәге уракчы хатын-кызлар, алар артында башак җыеп йөрүче пионерлар күренде. Урман авызыннан ялгыз мотоцикл атылып чыгып килә, олы юл буйлап, Иделгә таба ашлык төягән олаулар китеп бара, алар артыннан, сыңар кулын болгый-болгый, Гыйззәт абзый йөгерә иде. Сулда авыл. А-а, моңпан бигрәк матур булып күренә икән! Бөтен җире яшеллек эчендә: ишек алларына, капка төпләренә кадәр ямь-яшел. Әнә, әнә Илдарлар өе! Өй түрендә рәшәткәле бакча, чәчәкләр. Тәрәзә рамнары кызыл, капкачы да кызыл. Аны пионерлар, Казаннан укытучы апа килә дигәч, шулай бизәп куйганнар. Тик шунысы: түбәсе салам түгел. Әйдә, ярар, кичә килеп киткән абый, кышка мәктәп өе әлгерә, шунда күчәрсез, диде; бәлки аның түбәсе салам булыр әле...

Хәзер исә Илдарның бөтен барлыгын комбайн биләде. Илдарга комбайнның идән тактасы да әллә нәрсә булып күренде.

— Илдал абый, мин дә...

Илдар аска карады. Анда, малайлар арасында, еларга җитеп, Марат басып тора иде.

— Кара, ник килдең?

— Ә мин әнидән сорадым.

— А это что за плакса?

— Братишка мой.

— Так, давай его сюда.

Илдар Маратны җитәкләп күперчеккә менгерде.

— А их?

— Их я уже катал. Так что ли, орлы?

— Нәрсә ди ул?

Илдар тәрҗемә итте.

Малайлар Илдарның русчапы шулай оста белгәненә шаккаттылар. Укытучы апа улы булуы да җитеп беткән иде инде; Илдарның дәрәҗәсе тагын да үсеп китте.

Һәм малайлар, Илдарның үзеннән сорарга кыймастан, пышылдашып алдылар:

— Ничек белә ул, ә?

— Рус арасында торган...

— Торып кына белерсең, бар...

— Илдар, ничек өйрәндең, малай, ә?

— Ә аның нәрсәсе бар? Безнең Марат та белә аны.

— Белер инде?

— Чәчрәп китим, белә.

— Русча беләсенме, Марат?

— Беләм.

— Я, берәр сүз әйт.

— А что сказать тебе?

Фәрит шулкадәр сокланды, гүя Марат белән Илдарның авызларында исләре аңкып торган, үзе әкияттәге кебек ашаган саен зурая барган алма иде, төкерекләрен йотып куйды. Илдарның исә үз кызыгы кызык, ул, гипнозланган песи баласы кебек, комбайнердан күзен ала алмады. Юк, һаман түгел, комбайн белән әнә шунда кадәр генә урып бару өчен дә ул иң кадерле нәрсәләрен биреп бетерер иде: тар козыреклы кепкасын да, футбол тубын да... Чын комбайнер итсәләрме?.. У-у, ул чакта...

Комбайнер бөтен барлыгы белән малайның йөрәгенә кереп утырды. Ике якка асылынып торган җирән мыегы, киң кырыйлы салам эшләпәсе, вак шадрасы, хәтта агач аягы да килешле булып күренде аңар. Илдар аңында комбайнер нәкъ шундый булырга тиеш тә иде, әз генә башкача булса, килешсез булачак, алай гына да түгел, бөтенләй комбайнер була алмаячак иде. Ә менә хәзер Илдарга, комбайнер итәбез, син нәкъ шундый кыяфәткә керергә ризамы, дисәләр? — Әлбәттә риза! Ә «шундый мыек та чыга» дисәләр? «Чыга бирсен! Мәгез, битемә пәке белән шадралар да уегыз...»

Комбайн кузгалып китте. Молотилкасы, тузан күтәреп, бодай суга башлады. Комбайнга тагылган арбадагы кызлар, каеш кырыйлы күзлекләрен маңгайларыннан күзләренә төшерделәр, авыз-борыннарын тиз генә баш яулыклары белән уратып бәйләп алдылар. Һәм молотилка чәйнәп чыгарган саламнарны сәнәк белән эләктереп алып, өя бардылар, кибән чаклы булып өелгәч, арбадан төртеп төшереп калдырдылар.

Комбайн кузгалуга Василий дәдәнең йөзендәге көләчлек югалды. Хәзер ул бөтен игътибарын комбайнга туплаган иде. Күзләре генә түгел, гүя салынып төшкән мыегы, хәтта шадралары, бөтен гәүдәсе алдагы бодай дингезен күзәтә иде. Колаклары комбайндагы һәр частьның үзенә бертөрле тавыш чыгарып хәрәкәт иткәнен тыңлап бара, берәрсенең тавышында фальшь ишетелсә, яхшы дирижер кебек, хәзер сизеп алып, игътибарын шунда юнәлтә иде. Куллары әле штурвалны әйләндерә иде аның, әле рычагын тартып куя, шул ук вакытта я тракторчыга, я саламчы кызларга берәр боерык та биреп ала иде:

— Әз, әз. Өемегез монах бүрегә хәтле дә юк. Зуррак итегез!

Илдар аның турында, безне онытты, дип уйлады. Ә комбайнер онытмады. Алай гына да түгел, шәһәр малаеның хыялын укыган кебек:

— Димәк, сиңа машина ошады? — дип куйды.

— Ошады, Василий дәдә.

— Алайса, комбайнер буласың да килә торгандыр әле синең?

— «Килмимә соң! Үлеп килә...» — Ләкин Илдарның алай диярга теле бармады.— «Миннән буламы соң...» — диде ул үзенә үзе уңайсызланып, аска карады.

— Әллә килми?

— Килә дә...

— Яхшы һөнәр. Була бир.

— Әә, булырсың?..

— Ә нигә булмаска?

Илдар көрсенеп куйды:

— Ничек итеп булалар соң аны, абый?

— Укып, әлбәттә.

— Ю-ук...

— Нигә юк?

— Укып кына була торган булса...

— Ә нигә булмасын? Яхшы укысаң...

— Яхшы укысам, миннән дә буламы?

— Бик рәхәтләнеп.

— Ай, абый!..

— Нәрсә, ай, абый?

— Моны йөртү бик рәхәттер.

— Ничего. Мин яратам үзе.

— Штурвалын әйләндерү бигрәк тә рәхәттер, әйеме?

— Әһе.

— Ай, абый!..

— Нәрсә син, ай да ай?

— Юк, мин бер генә әйләндереп карарга ярамый микән димәкче идем.

— Әйләндерергә ярамый.

— Кулны куярга дамы?

— Ну, алай бик теләгәч, кулны куярга, бәлки, ярар да...

— Чынлапмы, абый?

— Я куй, куй...

Илдар кулын штурвалга куйды. Аның тәне буйлап рәхәт салкын йөгерде. Ул уңайсызланды, ләкин авызын ермый булдыра алмады. Чөнки аңар бик-бик рәхәт иде хәзер.

— Я, ничек, егет?

— Ух, ничек рәхәт!..

— Мин дә...

— Ах, син дә?..

Василий дәдә Маратны күтәреп алып штурвал төбенә бастырды.

Марат штурвалга үрелде, аяк очларына басып күтәрелеп тә карады ул. Юк шул, ичмаса бармагы гына да штурвалга тимәде.

— Ах, бераз үсәсең калган икән.

— Ә мин үскән...

— Буең җитми ич.

— Җитә, җитә...

Марат тагын аяк очларына басып үрелде, сикерде, тагын сикерде...

— Бернишләп булмый, үсә төшкәч килерсең инде...

— Әем, хәзел, хәзел...

Комбайнер аны күтәреп торды. Марат кулы штурвалга тиюгә, куанып көлеп җибәрде. Ә комбайнерныкы белән үз куллары да әйләнгәндә шатлыгы әйтеп кенә бетерерлек түгел иде. Ул:

— Илдал абый, менә мин әйләнделәм, Шамил, Абделхак, мин әйләнделәм!..— дип кычкырды.

Шул чак ящиклы арбага җигелгән пар ат килеп житеп комбайн белән янәшә бара башлады.

Нигә янәшә бара соң ул? Арба артына ирләрчә оста басып, дилбегә тотып килгән апа «фил борынын» ящик өстенә борып куйды, комбайнер бункерны ачты. Бункердан арбага шыбырдап бодай ага башлады.

— Я, бусы ничек, геройлар?

Марат белән Илдарга шулкадәр рәхәт иде, әйтергә сүз таба алмадылар.

Шулай куцелле генә килгәндә, трактор борылышта иләмсез үкереп куйды. Атлар өркеп читкә тайпылдылар. Арба «фил борыны» астыннан чыкты. Моны күреп, Василий дәдәнең шундый шат, шундый мөлаем йөзе кинәт караңгыланып китте. Хәзер ул чиктән тыш усал иде. Ул олаучы апа белән тракторчыны сүгә-сүгә бункерны япты.

Лəкин ул док-док басып килеп җиткəнче, байтак бодай җиргə агып өлгергəн иде.

«Ах, юк шул, инде хəзер ул безнең белəн маташмас...» Комбайн туктауга, Илдар, Маратны җитəклəп, аска төште һəм, малайлардан күрмəкче, тезлəнеп, җиргə коелган бодайны кепкасына җыя башлады.

Малайларның куллары җыйды, ə күзлəре дөньядагы иң-иң бəхетле Илдар белəн Маратта иде. Алар, берсен-берсе бүлдереп, теге яки бу сүзнең русчасын сораштылар.

— Ə трактор русча ничек була, Илдар?

— Комбайн ничек, Илдар, комбайн?

Шуңынчы барысын да əйтеп барган Илдар кинəт туктап калды. «Ул белми микəн?» — Илдар Маратка карады. Марат исə бу вакытта Шамил белəн Абделхакка рус балалары җыры «Чижик, чижик...»ны өйрəтеп маташа иде:

— Ю-ук, Чизек түгел, чизик.

«Чижик» Илдарны да коткарды. Авыл малайлары, трактор белəн комбайнны онытып, Маратның авызына карап каттылар.

6 КОРТКЫЧ ӨННƏРЕ

Балалар, урылган җир буенча сибелеп, нидер эзлəнə-эзлəнə баралар иде. Фəрит, чикерткə аулагандагы кебек йөгереп килеп, җиргə капланды һəм нəрсəнедер тиз генə учы белəн томалап алды:

— Таптым, малайлар, таптым!..

Фəрит, учын кыегайта төшеп, тапканын иптəшлəренə күрсəтте дə тагын шап итеп томалап куйды:

— Башлап үзем табам дидем, и тəки таптым...

— Яле, Фəрит энем, без дə күрик əле.— Укытучы Фəрит янына чүгəлəде. Фəрит кулын алды:

— Менə ич, менə!..

Фəритнең шатланганына карап, тапканы бер бик зур хəзинə дип уйларга мөмкин иде. Ул исə нибары чынаяк авызы хəтле бер тишек булып чыкты. Лəкин эзлəгəннəре дə шул икəн, укытучы канəгатьлəнеп карап торды да:

— Дөрес, Фəрит энем. Нəкъ үзе — əрлəн өне,— диде.— Лəкин, əйтергə кирəк, хəзер ул монда тормый, кайда булса да яңа өй җиткереп кергəн...

— Каян белдегез, Заһит абый?

Укытучы әйтә башлаган иде дә, кире уйлап:

— Ә мин үзем синнән сорарга тора идем әле,— диде.— Йә, Җәмил, әрләннең монда тормаганын каян беләбез?

Җәмил уңайсызланып аска карады һәм аягы белән аягын кашып алды. Әкбәр өн авызыннан әз генә читтә аунап яткан карандаш сыныгы кадәр бер талчыбыкны алды да шаяртып куйды:

— Шуннан беләбез: менә, күченгәндә кровать аягы сынып калган, һе-һе...

Балаларга кушылып укытучы да елмайды. Һәм шунда ук җитди тонга күчеп:

— Ә Карлыгач нәрсә әйтер икән? — диде.

— Белмим шул. Заһит абый.

— Алайса, тирә-юнен яхшылап тикшерегез әле, бәлки әйтә алырсыз.

Балалар кайсы тезләнеп, кайсы иелеп өн авызын, аның тирә-юнен тикшерергә керештеләр. Шул чак Марат белән Шамил, берсен-берсе бүлеп:

— Илдар абый да тапты, менә, менә. Ике оя!..— дип кычкырдылар.

— Әһә. Әйдәгез, шәһәр егетенекен күрик әле...

Балалар Илдар тапкан тишек әйләнәли җыелдылар.

— Ай-яй, сразы ике...

— Беренчедән, ике түгел, бер.

— Ә соң монысы?

— Анысы запас ишек кенә. Кинодагы кебек.

Әкбәр, пожар булса, шуннан чыгып шыла икән инде алайса, дип көлә башлаган иде, укытучы, аның сүзенә җитди төс биреп:

— Әйе, пожар я берәр хәвеф-хәтәр килеп чыкса!..— дип алып китте.— Аерма шунда: кинода запас ишеккә, кешегә күренеп торсын өчен, кызыл ут белән язып куялар... Ә бу, киресенчә, ишеген әнә ничек маскировать иткән.

Малайлар өн авызын томалап торган салам һәм кипкән үләннәрне тузгыта башладылар, ә Заһит абыйлары:

— Юк, тимәгез...— диде.— Хәзер мин сезгә шуны әйтим: бусында яшиләр. Я, әйтеп карагыз әле, моны каян беләбез?

— Тишекнең бер ягындагы чирәм тапталып беткән.

— Димәк?

— Әрләи кереп-чыгып йөргән.

— Ә Фәритнең?
— Тапталмаган.
— Димәк?..
— Кереп-чыгып йөрмәгән.
— Дөрес, сеңелем. Я, бер Карлыгач авызына гына карап тормагыз. Башкаларыгыз да әйтсен.

Балалар, өннәрнең берсеннән берсенә йөгереп, күргән бер аерманы әйтә бардылар.

— Моңысының таучыгы юк, тегесенең бар.
— Таучык турында соңыннан. Хәзер сез миңа шуны әйтегез, корткыч хәзер өнендәме, юкмы, моңысын ничек беләбез?
— О-о, аны кем белми!
— Белсәң, яле, Әкбәр энем.

Яшенә күрә шуклыкның чигенә чыккан бу малай мәзәккә дә бик сәләтле иде. Ул, әлеге «кровать аягын» алып, өн авызын шакыды да:

— Әй, әрлән әрләневич! Каршы ал, кунаклар килде,— дип көлде.

Малайлар да көлештеләр. Укытучы, елмаеп, Әкбәрнең башыннан сыйпап куйды.

— Ләкин алай белә алмыйсың шул, энем. Кунакчыллыгы бик чамалы аның. Каршы алмас ул безне. Ягез, дусларым. Кайсыгыз әйтә?
— Өнендә булса, су салуга йөгереп чыга.

Укытучы өстәп куйды:

— Запас ишектән.
— Әйе, запас ишектән.

Корткыч өнендә икән. Елгадан су алып килеп салулары булды, салам, үләннәрне мыеклы танавы белән сөзеп, запас ишектән ялт килеп чыкты.

Әрлән, күрәсең, өненә су агып төшүгә каушап калмаган, шунда ук чыгып йөгергән — арт саны гына чыланып өлгергән, ал саны бөтенләй коры иде. Ул килеп чыгуга көрәк, таяк, таш яки кантар тоткан балалар бераз каушап тордылар. Корткычка шул җитә калды. Чыккан уңаена бер дә туктап тормастан, аучыларның аяк араларыннан чыгып шылды һәм бик тиз күздән дә югалды.

Балалар, чыр-чу килеп, аның артыннан ташланганнар иде дә, укытучы туктатты:

— Булмый. Үзе шундый булса да, кеше тикле генә йөгерми ул... Без сезнең белән бер хата эшләдек. Я, кайсыгыз шуны әйтеп бирә?

Укытучы әйтеп тә бетермәде, Харис:

— Запас ишеген күмәргә кирәк булган,— диде.

— Дөрес. Инде хәзер әйдәгез, корткычның гүрнәчәсенә экскурсиягә төшеп меник... Сабыр. Алай сез бөтенләй җимереп бетерерсез. Ягез, кайсыгыз ватмыйча гына казый белер: Маратмы, Шамилме? Әллә икегез дәме?

Маратлар, уңайсызланып, абыйлары артына постылар.

— Карлыгач?

— Булдыра алмам шул, Заһит абый.

— Алайса, мин сезгә булышыйм. Өннең бер ишегеннән икенчесенә юл туп-туры салынган булырга тиеш.

Әкбәр, бик белдеклеләнеп, алга чыкты. Малайлар, әй, тагын... дип шаулаша башлаганнар иде, Әкбәр, бер дә исе китмичә, көрәк сабын тишектән тишеккә сузып салды да шуның буенча «кровать аягы» белән сызык сызасыза сөйләнеп куйды:

> Тыңлагыз, бу тик Карахмәтнең эше,
> Инде ул, мәгълүмегез, көчле кеше...

Тукайның «Кисекбаш»ын укыган яки ишеткәне булган балалар көлештеләр, укытучы да көлде һәм:

— Менә бусы өчен молодец, Әкбәр,— диде.

Әкбәр, канатланып китеп, көрәген туры батырып, җирне кисә башлады. Берничә минут үтүгә балалар алдында шундый картина ачылды; корткыч тишек авызыннан 15—20 градус сөзәк юл ясап, бер метр чамасы аска төшкән дә тубал хәтле оя казып куйган һәм, текә күтәрелеп, запас ишеккә юл ясап менгән иде. Ә оясы һәм юллары шундый чиста иде ки, балалар гына түгел, укытучы үзе дә гаҗәпләнми кала алмады.

— Үзе казыган микән ул моны, малайлар?

Моны ялкаулыгы өчен Ялкаветдин кушаматы алган Гайнетдин исемле малай, карандашына кадәр әйбер биреп кешедән очлаттыра торган малай, әйтте. Аңа каршы кайсыдыр:

— Нишләп үзе казып торсын, каләм биреп берәрсеннән казыткандыр шунда,— дип көлде.

— Ха-ха-ха, менә тик тормасаң!..

— Карагыз әле, малайлар, ничаклы башак ташыган!..

— Нинди эре диген син...

Әкбәр:

— 1 сорт, 2 номер, печәте генә юк,— дип көлкегә җибәрә башлаган иде, укытучы бүлдерде.

— Тагын кыек атып туры тигездең. Әрлән яхшы барында начарын алмас,— диде ул. Һәм бер кыз баланың юл буе җыеп килгән башак учмасы белән чагыштырып күрсәтте.

Әкбәр тагын көлде:

— Болай булгач, Гыйззәт абзыйга әйтергә кирәк әле. Югары уңыш участогының чәчү орлыгын әрләннәрдән генә сайлатсын.

— Ха-ха-ха...

Шул чак корткыч оясыннан чыккан башакларны санап торучы малай кычкырып җибәрде:

— 48! 48 башак!

— Бу нәрсә-ә... Узган көз дүртенчеләр туздырган бер оядан 15 000 башак чыккан.

— Чыгар инде?

— Әнә, Карлыгачападан сора. Әйе бит, Карлыгач апа?

Карлыгач малайның сүзен дөресләде һәм өстәп куйды:

— 15 кило да 500 грамм тартты.

— Ә инде хәзер энеләреңә исәпләп бир,— диде укытучы Карлыгачка.— Йөз, мең оядан җыйсаң, күпме тартыр иде икән?

Карлыгач чәч толымындагы кызыл лентаны сүтә-бәйли исәпләргә кереште. Марат белән Шамил бизмәннәрен каланча баганасына элеп куйдылар да корткыч өннәреннән чыккан башакларны үлчи башладылар.

Малайлар тагын берничә өн ачтылар. Берсе укытучыга:

— Кара, яз көне безнең дүртенчеләр аулап бетергән иде бит инде ул әрләннәрне, Заһит абый,— диде.

Укытучы аңлатып бирде:

— Күрәсең, бер-ике булса да калган. Бик үрчемле корткыч бит ул. Бер парыннан ел әйләнәсендә утыз-кырык әрлән үрчүе мөмкин.

Өннәрдән чыккан башакларны санап торучы Җәмил, канәгатьсезлек күрсәткән кебек итеп:

— Әбәү, монысында 12 генә,— диде.

— Ә ни өчен 12? Ни өчен, Карлыгач әйткәнчә, 15 000 түгел?— диде укытучы һәм үз соравына үзе үк җавап бирде.— Иртә әле. Бодайның чынлап торып өлгерүе кичәле-бүгенле генә бит. Ә корткычка иң өлгергәне, иң корысы кирәк. Туклыклы да була, үрми дә. Кыш буена бит ул аңар...

Шул чак Марат яңа гына ачып бетерелгән өнгә карап-карап торды да төбендәге башак өеменә ташланды һәм берсен, учларына салып, Шамил белән Абделхакка күрсәтә-күрсәтә шатланып кычкырды:

— Ай,минем башак! Сания апама дигән башак! Илдал абый, менә, менә, Сания апама дигән башак!..

Әйе бу — шул, кичә Карлыгач табып биргән «мыеклы бодай» булып, алкасына кадәр шул килеш сакланган иде. Марат аны абыйсына бирә башлады һәм шунда ук киредән учлары белән томалап, күкрәгенә кысты:

— Апкайтам, Сания апама апкайтам...

Укытучы шактый читтә яңа өн табып казырга торган Әкбәр белән Харисны туктатты:

— Кирәкмәс. Күрдегез, алар бар да бертөрле. Әйдә, утырышыгыз әле. Хәзер без сезнең белән корткычны аулау юлларын өйрәник,— диде ул һәм полевой сумкасыннан рәсемле китап чыгарды.

Юк, монысы кызык түгел. Рәсемнәрен генә күрсәтсә, бер хәер иде. Ә ул бер битен ачып куя да сөйли, сөйли... Маратның үзенең дә рәсемле китабы бар ла. Һәм ул аны теләгәнчә карый ала.

— Әйдә, Шамил, кайтабыз.

— Ник?

— Рәсемле китап карарга. Рәсемнәре бик күп. Ун, биш, мең, йөз...

— Йө-өз, ай-ай-й...

— Әйе. Төлкесе дә бар.

Марат Саниягә дигән «мыеклы бодайны» кепка инеченә кыстырды да трактор булып басты. Шамил аңар комбайн булып тагылды. Фәрит Илдарга күз кысты да чиләктән кепкасы белән су алып килеп «тракторның», аннан «комбайнның» «радиаторына» салды.

— Я, инде ура башлагыз.

Трактор, аның артыннан комбайн дөп-дөп дөпелдәп авылга таба юл алды.

— Кит, Илдар абый, тапталырсың!..

7 БЕЗНЕҢ ТҮБӘ КЫЗЫЛ

Гөлсем апа, балаларның бу мавыгулары озакка бармас, кара көзләр җитеп, табигать яшел киемен салгач, кырлар бушап калгач, шәһәрне сагына башларлар дип курыккан иде. Алай булмады. Балалар авылны элеккечә

ук яраттылар. Авылдагы һәрбер яңалык аларны үзе белән ияртеп алып китте, авыл табигатендәге һәрбер үзгәреш алар өчен матур китапның яңа бите кебек мавыктыргыч иде.

Башлап, кара көздән алда авылга алтыны килде. Барысы бердәй яшел булып утырган агачларны табигать нинди генә төсләргә бизәмәде! Бер ишеләрен сары, аксылсары, лимон-сары төсләргә манды; чия белән шомырт яфраклары күз алдында кызгылт-көрән төскә манып чыкты. Миләш, карга миләше әфлисун эче кебек кызгылтсары төскә керде; канәфер, зирек куаклары һаман ямьяшел иде әле; мәңге яшел чыршының ылыслары тагы да нәфисләнеп, югарып китте. Усак катнаш каен урманын күрегез әле! Көзен генә була торган саф зәңгәр күк фонында нинди нәфис ул! Бигрәк тә кояш чыкканда, тагын кояш баеганда! Нинди генә буяулар бөркемәгән анар юмарт табигать!

Дөрес, сайрар кошлар китте инде бакчадан. Кыйгач сафларга тезелеп, киек казлар очты югартын. Әнә кара каргага хәтле җылы якларга җыена. Аның каравы урманнан бер, ике, әллә ничә төрле песнәк килде. Әнә «зур» дигәне: аркасы яшел, түше сары, муены кара, яаклары җете ак. Ул да түгел, тук-тук тукран килеп җитте. Күкшәкош, кызылтүш, миләш чыпчыгы бик еш килеп йөрде хәзер урманнан.

Авылда тереклек шау-шуы, хезмәт музыкасы сүнмәде генә түгел, көчәйде, төрләнде. Басудан уракчылар китеп өлгермәде, сөрүчеләр килеп җитте; көлтә, комбайн бодае ташып йөргән атлар сабанга җигелде. Басуда көнтөн трактор гөрелдәде. Сугыш вакыты, атлар җитешми иде; кешеләр кырга тиресне кечкенә арбаларга җигелеп чыгардылар. Ындырдагы атлы молотилкага ярдәмгә комбайн кайтты. Көлтәңне биреп кенә өлгер!.. Беләү төсле шомарган олы юл буйлап пристаньга кызыл обозлар агылып торды: «Таң йолдызы»ннан, «Ленин»нан, «Идел»дән...

Киләсе елга мул уңыш вәгъдә итеп, басуларда куе, яшел уҗым келәме җәелде. Кичләрен киң болында костерлар кабынды. Әйләнә-тирәсендә әкиятләр сөйләшеп, көлдә бәрәңге пешереп утырган ат саклаучы малайларның көр тавышлары ишетелеп торды.

Илдә дәһшәтле сугыш бара иде. Ленинград һаман камалышта иде әле. Ялкын эчендә калган Сталинградта һәр урам, һәр йорт өчен сугыш бара иде. Гитлер явы тук-

татылмаган, аның яман шеш тармаклары кебек агулы кармавычлары Кавказ тауларына хәтле үтеп кергән иде инде. Мондый чакта иң зарурын гына эшләргә кирәк иде кебек. Ләкин җиңүгә тәмам ышанган халык икенче чираттагыларын да онытмады. Игеннәр җыелып бетү белән клуб, мәктәп буралары өстендә яңадан балта, пычкы тавышлары ишетелә башлады. Инеш ярларыннан колхозчылар таш чыгардылар. Хәзергә ул шунда әрдәнәләргә өелә барылды. Сугышлар бетеп, ир-ат кайткач, транспорт яклары рәтләнгәч, инешнең югары очына ташылыр. Сугыш сәбәпле бүленеп калган электростанция өчен ул таш.

Балалар шуларның барысын да күреп, барысы белән дә мавыгып йөрделәр. Илдар дәресләреннән бушануга, өчәүләшеп урамга йөгерделәр. Силос базына, фермага. Аннары, авыл балаларына ияреп урманга... Ерактан шулай матур күренгән урман, эченә килеп керсәң, бөтен бер әкият дөньясы иде хәзер.

Бик тын. Анда-санда яфраклар коелган да инде. Шундый матурлар — таптарга ятыргарсың... Өйдә утын яклары кысан булганлыктан, балалар башта чыбык-чабык җыеп куялар; алардан күрмәкче, Марат белән Илдар да җыя. Аннары барысы да җирне бизәп яткан яфракларга ташланалар.

— Монысы каен, менә имән.

— Өрәңге, өрәңге таптым, малайлар!..

Харис җыймый. Аны әнисе утын өчен генә җибәргән.— «Ишетсен колагың, кешедән ким күтәреп кайтсаң, тиреңне тунармын, тиреңне!..»

Харис, үги ана каһәреннән куркып, утынны кешедән күбрәк җыя, иң корыларын сайлый.— «Болай да әле берәр гаеп тапмый калмас...» Харис бу турыда әз генә дә онытмый. Ләкин, бала бит, ахрысы, гомуми гөрелтегә килеп кушыла. Ул, Маратның итәгенә абрикос кабыгы төсле йөнтәс сары, үтә күренмәле юка яфраклар табып алып сала да, балаларча гамьсез, шул ук вакытта ятимнәргә хас нечкә бер хисселек белән әйтеп куя:

— Яшел килеш коелса, матур да булмас ие, әәме, малайлар?

Малайлар яшел үлән өстендә яшел яфраклар коелып ятуны күз алларына китерәләр дә Харисның бу ачышы белән килешәләр. Харис җирдән куш учлап яфрак алып исни, аннан Илдарга иснәтә. Илдарның йөзендә канәгатьләнү күргәч:

— И исе дә мондый хуш булмас ие, әәме?— ди.

Илдар аның шундый нечкә хислелегенә соклана. Аны бөтенләй үз күрә башлый.

— Малайлар, әнә тиен!— ди берсе.

— Куян, малайлар!

— Төлке, ипидер, төлке!..

Малайлар моны күреп түгел, Казан малайларына күрсәтәселәре килеп әйтәләр. Ул җәнлекләрне күреп булмый хәзер. Алар инде бик тырышып кышка хәзерләнә. Ә менә көртлекне күреп була. Әнә ул. Ул инде җәйнең җәй буена ашап симергән, иртәгәге көн өчен ишәк кайгырган дигәндәй, имән башында бер гамьсез черем итә. Шундый симез, кунаклаган ботагы сыгылып төшкән. Көртлек, балалар килә башлагач, сагая. Тагы да якынрак килгәч, авыр күтәрелеп очып китә.

— Их, мылтык булса!..

— Ә миңа әни алып бирә... Үскәч түлке...

— Минем әти сугыштан алып кайта. Трофейныйны. Сиңа да аттырып карармын, яме, Фәрит?

— О-о, әллә минем үз әтием алып кайтмас дисеңме?

Бераз баргач, миләшлек очрый. Тәм кермәгән, бик әче әле ул. Берәрне өзеп кабуга күңелләре була. Сазлы аланда мүк җиләге күп. Ул да әле яңа пешеп килә. Балалар кабыгына сыеша алмыйча үскән соңгы чикләвекләргә ябырылалар. Чикләвек күп түгел инде. Бәлки шуңадыр: бик тәмле.

Әкбәр дә, үз эшләрен ташлап, кечкенәләр белән килгән. Ул монда да берәр мәзәк уйлап чыгармый калмый. Марат белән Шамилнең арткарак калганын көтеп йөри дә, йөгереп барып бер куак төбенә чүгәли һәм, авызына тиз-тиз җиләк тутырган кебек итеп, кулларын авызы белән куак арасында йөртә башлый.

— Марат, Шамил, килегез. Шыпырт түлке. Ату, хәзер теге йолкышлар килеп ябырылыр...

Сабыйлар карлыган шикелле кара җиләкләрне комсызланып өзеп кабалар һәм шунда ук йөзләре чытыла.

— Ха-ха-ха...

— Фәрит, Ата күркәне күр әле, Шамилләргә эт җиләге ашата!

Фәрит ишетми. Ул кошлар белән мәшгуль. Очраган бер кошны Илдарга күрсәтеп, үзенчәлекләрен сөйли. Илдар отып калу өчен бик җентекләп карап, әченнән исемнәрен кабатлап бара. Ә кайткач, язып куя. Рәсемнәрен

дә ясый. Тик шунсы: кошлар анын рәсемендә бар да бертәрле булып чыга. Икенче, өченче тапкыр күреп яса гач, рәсемнәр бераз ярыйсылана төшә. Ә Әкбәр һаман шаярта:

— Илдар, малай, бу көртлек дигәнеңме, Хөрәсән Шаһи балтасымы? Һе, һе...

Көлә бирсен. Үзе болай да ясый белми әле...

Кышы да балаларны биздерерлек булмады. Кыш авылга үз бизәген, үз ямен алып килде. Күз яуларын алырдай «мәңге» ак кар; күгелҗем-ак бүрек кигән, ак җилән бөркәнгән таулар; сызылып кына үткән беренче чана эзләре; үрләрне, үзәннәрне, кырларны, болыннарны кисеп үткән чаңгы юллары; кар чәчәгенә төренгән юкә, каеннар, чыршы, наратлар...

Хәзер Илдарны иң мавыктырган нәрсә җәнлекләр булды. Ул инде җәнлекләрне эзләренә карап та аера белә иде. Мәктәп бакчасы зур, аннан, бик куе. Чөнки бу авылда гадәт шундый: укырга керүче һәрбер бала бакчага үзе белән бер төп агач алып килә һәм мәктәпне тәмамлап чыкканчы үзе карап үстерә. Шундый куе булганга күрә, авылга килгән җәнлек бу бакчага сугылмый китми. Төнлә кар яуган булса, Илдар йокыдан торуына, энесе белән сеңелесен ияртеп, шунда йөгерә:

— Төлке килгән! Менә эзе. Зу-ур...

Илдар эз артыннан, Марат белән Сания абыйлары артыннан йөгерәләр. Маратның итегенә кар тула. Ләкин ул дәшми. Дәшсә, Сания апасы өйгә алып кереп китәр...

— И-и, Илдар абый, менә тагын бер эз,— ди ул.

— Шул ич инде ул. Әнә Гөлҗамал түтинең тавык кетәгенә тикле барган, аннан Хисам бабай ишек алдыннан урап килгән... Юк ла-а, анысы безнең Абрек эзе ич...— Илдар тезләнеп, күзләрен эзгә якын китереп карап торатора да телен шартлатып куя:

— Ах, төлке Абрек киткәч килгән... югыйсә ул аның!..

Марат белән Сания эз янына тезләнәләр:

— Каян белдең, абыем?

Илдар торып карлы тез башын кага. Ул масаймый, шулай да өстенлеген сиздереп әйтә:

— Ә соң кар? Абрек эзен кар күмә язган...— Малай аучы Җаббарның сүзләре хәтеренә килгәнгә шатланып, өстәп куя: — Төлкенеке әле генә баскан печать шикелле.

Балалар абыйларының шулай күп белгәненә шатланалар. Аларга рәхәт.

— Ә менә монысы куян,— ди Илдар.

— Куя-ян. Ай-яй.

— Җаббар бабай, капкын ясап бирәм, диде. Бакчага куябыз да куян эләгә.

— Ничәү?

— Берәү.— Илдар, энесенең бергә канәгать түгеллеген күреп, җавабына төзәтү кертә: — Аннары тагы берәү...

— Аннары тагы.

— Әйе, аннары тагы...

— Аннары асрыйбыз.

— Юк, бу андый түгел, йортныкын гына асрыйлар.

— Моны суеп ашыйлар, әэме, абыем?

Сания шулай дигәч, Марат, кулын чәбәкләп, сикеренергә тотынды:

— Әти кайткач суябыз. Әти кайткач суябыз!..

— Кунакка кайткач.

Илдар көлеп, «әй, тумаган тайның билен...» ди башлаган иде, кинәт уйга калды. Чыннан да, бик мөмкин. Әнә Фәрит этисе кайтты ич.

Илдар шунда ук, капкынны тизләтү теләге белән, Җаббар бабайга йөгерде.

Фәритнең этисе, самолеты яна башлагач парашют белән сикереп, кулын сындырган. Шуңар кайтты... Юк, Илдарлар этисе алай кайтмасын. Илдар үз этиләренең кулы да, бер җире дә имгәнми кайтуын теләде. Марат исә барысына да риза булачагын әйтте. Әнә Фәритләр этисе сыңар кул белән дә ничек ярата, үзе белән җитәкләп йөри. Ясалма кул куйгач сизелми дә эле ул...

Сания энесе белән килешми:

— Юк, сынмасын, сынмасын,— ди ул, еларга җитеп.

— Ярый, алайса, сынмасын...

Марат өйгә кергәч әнисенә сарыла:

— Әнием, безнең авылда торганны этигә яздыңмы?

— Яздым, улым.

— Кырыйдан ничәнче йорт икәнен дәме?

— Аныcын да яздым.

— Түбәнең кызыл икәнен дә яз.

— Ник?

— Әти күрер.

— Хәзер кызылы күренми ич аның. Кар яуган.

— Илдар абый күрн. Мин дә күрим. Әйе бит, Илдар абый?

Сабый өзелеп әтисен көтте. Аркасына котомка асып өй түреннән узып барган берәр шинельле кеше күрсә, артыннан йөгерде. «Әтидер, безнең өйне эзләп йөри торгандыр...»

Бер тапкыр әнисе янына ниндидер йомыш белән Осоавиахим кешесе кергән иде. Шинельле. Җитмәсә, фуражкасын да салмый утырды. Марат аны ничек чыгарып җибәрергә белмәде. Сүзләрен бүлдерде, көйсезләнде.

Гөлсем апа аптырый калды. Көнләшә? Әйе, шулай дип тә уйларга мөмкин иде. Марат әнисен очраган бер кешедән көнли иде. Бер тапкыр әнисе авырып ятканда, доктор аның кровате читенә утырып беләзеген тотып, сәгатенә карап торган иде, малай нишләрен белмәде:

«Төш, әниемнең аягын авырттырырсың».

Доктор эшнең нәрсәдә икәнен сизенеп көлә башлагач, Марат аны кулыннан тотып өстерәде. Ә мәктәп директоры хәл белергә кергәч, кит, доктор апа әниемә сөйләшергә кушмады, дип тегене кровать яныннан этәрде.

Хәзер исә Маратның көйсезләнүе аңар түгел иде. Ул, Осоавиахим кешесе өйалдына тәмәке тартырга чыгып киткәч:

— Кертмим мин аны,— дип ишекнең келәсенә үрелә башлады.

— Кара, нишлисең син?

— Ээ менә. Әти кайтыр да тәрәзәдән күрер...

— Күрә бирсен.

— Безне күрмәс, аны күрер.

— Менә тагын. Күрсен.

— Безнең өй түгел икән дияр дә үтеп китәр...— Марат елап ук җибәрде. Һәм Илдар, түбәне көрәп төшеп, әтиләренә, безнең түбә кызыл дип, хат язып салмыйча тынычланмады.

8 ТИР БЕЛӘН ТАПСЫН АШАРЫН

Марат, әнисеннән күрмәкче, гел укытучы булып уйный иде. Ул, көн саен мәктәпкә барып, ишек ярыгыннан, йозак тишегеннән әнисенең укытканын карап тора. Ә кич белән әнисен, абыйсын, Сания апасын, аның курчакларын, үзенең бахбаен тезеп утырта да дәрес бирә. Мәк-

тәптә әнисе нишләсә, шуларның берсен калдырмый кылана Марат.

Әнә ул. Күзлек (ике кыршаулы, ике саплы тимер чыбык) кигән. Башында әнисенең яшел береты. Берет астыннан юан-юан ике үрем тегәрҗеп чыгып тора (монысы — чәч толымнары); аягында әнисенең биек үкчәле туфлие. Йөри алмый, абына да сөртенә. Үзе искиткеч җитди; бар да шаркылдап көләләр, ә моның үзенең исендә дә юк.

— Җә-ә, инде язабыз...— ди ул.— Урамда буран, мин өйдә утырам... Яздыгызмы? Хәзер карыйм... Бер хәрефе төшеп калган. Әйтмим, үзең бел. Илдар, казыма борыныңны, бармагың сынар... Сания, акыллым, йолдызлар санап утырма... Син, Гөлсем, башың авыртса, бар, кайтып кит...

Әнисенә шул гына кирәк тә. Иртәнге дәрескә хәзерләнәсе бар. Әтиләренә хат язып салырга да вакыт... Ул бераз ял итеп алу өчен урынына китеп ята. Ә Марат, дәресләр беткәч, доктор кыяфәтенә кереп, «авыру бала» янына килеп җитә...

— Сула әле, инде теленне күрсәт. Салкын тигән. Укуың кала инде менә. Ах бала, бала...— ди ул һәм шунда ук, уенны онытып, башын әнисенең куенына төртә:

— Син мине яратасынмы?

— Яратам.

— Нихәтле?

— Менә моны-ың хәтле.

— Ә мин сине моның-моның хәтле,— ди Марат. Аннан «моның-моның хәтле» үзенә аз кебек күренә дә, «ы» авазын тыны беткәнче сузып өстәп куя:— Тагын менә моны-ы-ы-ң хәтле.

Чыннан да бик ярата ул әнисен. Ул инде әнисе өчен сөенә белә, аның өчен чын күңеленнән көенә белә. Тәрәзәдән карап утырганда Фәрит узып китсә, аңа карап шат елмая, Хариска да елмая, ә Күчерт Җәмилгә йодрык күрсәтеп кала. Күрсәтми ни! Сабагын белсен. Мәктәптә күгәрчен очырып утырмасын, әнине кычкыртмасын... Әкбәргә дә күрсәтә ул йодрыгын. Ләкин («я кереп кыйнар»...) башта ишекне бикләп килә. Тик ул арада инде Әкбәр өй түреннән үтеп киткән була. Шулай да күрсәтә ул аңа йодрыгын. Форточканы ачып. Үскәч, тотып кыйнар да әле. Кыйнамый ни! Укырга йөрми ич. Әнисе ул Ата күркә артыннан өйләренә бара бара «жык булды

инде». Беркөн этен чылбырдан ычкындырып калдырган. Әнисен тешләп кайтарды. Юри калдыргандыр әле, әни кермәсен дип... Кайткач елады әнисе... Икенче вакыт Марат үзе дә әнисе белән барыр инде. Абрекны нәртеп. Абрекны күрсә, аның Сарбае оясыннан танавын чыгарып карарга да курка...

Әнисен бик кызгана шул ул Марат. Зур үскәч, аның өчен үзе генә укытыр әле менә. Ул инде хәзер дә әллә нихәтле хәреф таный. Илдар әйтә, тагын шуның хәтле, аннан тагын шуның хәтле беләсең дә бетә, ди.

— Аннары укытучы булам.

— Әйе, аннары укытучы буласың.

Бер тапкыр ул Саниягә:

— Әйдә, әнигә булышыйк,— диде.

— Ничек?

— Дәфтәр төзәтик.

Саниягә Маратның тәкъдиме ошады. Әниләре эшләп утырган җиреннән арып йоклап киткән иде. Бер өем дәфтәрнең берсен калдырмый кызыл карандаш белән «төзәтеп» чыктылар: сыздылар, боздылар, яңаны язган булдылар. Әйтергә кирәк, алар моны ничек әләкте шулай эшләмәделәр. Әниләре эшләп куйган икенче бер өемдәге дәфтәрләрдәгечә итәргә тырыштылар, әниләре фәләненче бит, фәләненче юл, фәләненче хәрефне сызып, яңаны язып куйган икән, болар да аңысын сызып яңаны яздылар; фәләненче юл, фәләненче хәрефнең астына ике кызыл сызык сызылган икән, болар да сыздылар. Әниләре башта бик орышты. Ә моның ни өчен эшләнгәнен белгәч, орышмады. Әйтте генә ул аларга:

— Икенче алай эшләмәгез.

Саниянең дә хәзер үз мавыгулары бар иде. Бу кыз бала, өйдән бушандымы, иптәш кызлары белән фермага йөгерде. Анда ул күн итек, телогрейка, колакчын бүрек кигән апаларның малларны ашатып йөргәннәрен карап торды. Бар да кызык иде аның өчен: ак халатлы апаларның чүгәләп утырып без-без сөт савулары да, мә, түгә, мә, түгә, дип эндәшүләре дә бозауларның башларын борып, муеннарын сузып мөгрәп куюлары да, олы кызларның сыер караучы апаларга булышып йөрүләре дә...

Сания үзе дә, олы кызлардан күрмәкче, шефка бер бозау сораган иде, бирмәделәр. Шулай да, ул Карлыгач

хәтле булгач, шефка алырга дип, үзенә «Кызым» исемле бер башмак тана билгеләп куйды. Сания Карлыгач хәтле булганда, башмак тана карт сыер була ич! Анысын уйлап тормады. Аңар өеннән сынык-саньк алып килеп каптырды. Ләкин өйдә ашау-эчү ягы һаман да бик кысан иде әле, ипи-күмәч сирәк була, күбесенчә, иртә-кич буш аш белән генә калалар, аны да әниләре бүлеп кенә бирә иде.

Ә Илдар? Ул комбайнга тәмам гашыйк булып беткән иде инде. Ындырда ашлыклар сугылып беткәч, Василий дәдә комбайнны МТСка алып китте. Күлер чыгып тау гына төшәсе. Илдар хәзер гел шунда барып йөрде. Василий дәдә, малайның мавыгулары вакытлы гына булмаганны күреп, аңар җитдирәк карый башлады:

— А-а, моё вам, Илдар Мостафич. Килеп җиттекме? Яхшы, яхшы. Дәресне әзерләп куйдыкмы соң әле? Алай, әйбәт булган. Я кил, кил, нәрсә син анда кулга ияләшмәгән җәнлек шикелле читтә посып торасың?

Василий дәдә комбайнны иңе белән бик каты төртеп карый да, эчендә нәрсәләренендер шолдырдаганын тыңлап тора һәм нинди дер винтигын бора-бора кичә башлаган сүзен дәвам итә:

— ...Кыр патшасы инде. Ансыз безнең заманда ни ту, ни ну. Дәртең бар икән, ике куллап ябыш. Нәрсә әйтергә, әйбәт арба. Хәзинә. Черетеп баета торган. Телең белсәң, әлбәттә, серенә тәмам төшенеп эш итсәң, тагын иркәләп торсаң. Шулай булмаганда — муртайган бүкән, буш тартма, җан көеге. Валла шулай...

Илдар кул сөртә-сөртә майланып беткән житен чүбеген алып, башта үзенең чип-чиста кулларын сөртеп торган булды, аннары бик тырышып комбайн тузанын сөртте, тәгәрмәченә сыланып каткан балчыгын чүкеч белән каккалап төшерде, һәм Василий дәдә артыннан комбайн астына кереп китте. Комбайнер башын чайкап куйса, күңелсезләнде, ачылып китсә (димәк, эш көйле бара), бу да шатланды.

Бер тапкыр Илдар комбайн астында шулкадәр аунады, өйгә кайтып кергәндә бердәнбер пиджагы, тәмам эштән чыгып, автолга буялып беткән иде.

Гөлсем апа бик каты әйтте, җелегенә үтәрлек итеп. Ләкин тиргәмәде:

— ...Инде бар, чистарт. Әнә бензин, чүпрәк,— диде ул.

Малай чистартты.

— Инде үтүк кыздыр, юк, бүген үтүклисең. Күмер чоланда... Ярамый әле, элек яхшырак үтүкләнгән иде... Менә хәзер ярый.

— Мин иртәгә дә барам. Иртәгә Василий дәдә хедерны сүтә.

— Ышанам, моннан болай буялып кайтмассың.

— Ю-ук. Барам, әнием, яме?

— Барырсың.

Гөлсем апа юл кую кебек кенә итеп әйтте. Ә эченнән шатланды, балаларының шулай хезмәт эчендә кайнап үсүләренә шатланды ул. Чөнки ул хезмәткә, мохтаҗлыктан гына эшләнә торган эш итеп түгел, кешене чын кеше итү өчен иң зарур нәрсә итеп карый иде. «...Тир белән тапсын ашарын, итсен әлбәт иҗтиһат»ның мәгънәсен тирән аңлый иде ул. Чөнки аның үзен дә хезмәт кеше иткән, алай гына да түгел, хезмәт аны һәлакәттән алып калган иде...

Эш шунда ки, Гөлсем апа әти-әнисеннән бик яшьли калды. Тормыш алып бару яшь-яшьтән аның үз өстендә булды. Сугыш еллары, революция, тагын революция, аннан аяусыз ачлык... Кечкенә Гөлсемгә, үзенең сеңелесен ияртеп, шушы авыр еллар аша үтеп чыгарга туры килде. Бик авыр булды аңа, укый алмады, иртәдән кичкә кадәр кешегә су китерде, ул кер, идән юды; кайтты да өй эшләрен карады. Гражданнар сугышы бетеп илгә тынычлык урнашкач, әтисе өчен пенсия чыккач кына эләкте уку. Бу вакытта Гөлсемгә инде 13 яшь иде. Ул үзенең 8 яшьлек сеңелесе белән бер партага кереп утырды. Ә кайткач, тагы кеше хезмәте, өй эшләре... Ләкин, шулай авырлыклар белән яулап алынганга күрәме, яшәү бик тәмле, уку аеруча тәмле иде. Гөлсем тормышка, укуга теше-тырнагы белән ябышты. Ә бит әти-әнисе куеныннан чыкмыйча яшәгән, бер дә «Лаеш шулпасы» эчмичә, эшләмичә үскән яшьтәшләренең никадәресе укуын ташлады, кайберсе тормыш арбасыннан бөтенләй төшеп калды, арада бозык юлга кереп китүчеләр дә аз булмады. Гөлсем исә, авыр булган саен тормышка, укуга ныклабрак ябышты һәм, беренче бала анасы булганчы ук, шундый хакыйкатьне нык үзләштерде: тормыш көрәштән гыйбарәт һәм бу көрәшкә бала чактан әзерләнергә кирәк; әзергә хәзер үсү баланы булдыксыз, ялкау итә; бала көн күрүне авыз ачып һава сулау кебек ансат

күреп үссә, тормыш үз башына калгач та шуңар исәп итә торган була...

Менә шуңа күрә Гөлсем апа балаларын яшь-яшьтән эшкә күнектерде. Сугыш алды елларында аның асрау белән торыр мөмкинлеге дә бар иде, һәм Мостафасы бу турыда берничә тапкыр сүз дә кузгатып караган иде, Гөлсем апа кире какты.

«Әйдә, барчук булып үсмәсеннәр әле...» — Һәм балалар андый булып үсмәделәр. Ягеднидә торганда ук инде аның балалары әниләрен көн саен табын җәеп, көн буена үзләре тузгытып бетергән өйне җыештырып, хәтта идәнен юып көтә торган булдылар. Алар моңар шулкадәр күнектеләр, кемдер мәҗбүр иткәнгә түгел, мавыгып, шул ук вакытта нәкъ үзләре эшләргә тиеш эш күреп эшләделәр, йокыдан торгач юынуны, ашау-эчүне никадәр кирәк дип белсәләр, моны да шулкадәр кирәк күрә иделәр. Табын җәю генә түгел, Гөлсем апа өйдәге байтак эшне балаларына тапшырып бетергән иде инде. Утын кертү, бәрәңге әрчү, су китерү, ипи-күмәч алып кайту күптәннән Илдар белән Сания эше иде. Марат килгәч, аңар да өлеш чыкты. Аны, әлбәттә, һичкем мәҗбүр итмәде, ул абыйсы белән апасыннан күреп эшләде. Саниядән күрмәкче, чүпрәк алып тузан сөртте, гөлләргә су сипте, урынын җәйде, торгач җыйды. Әлбәттә, хәзергә ул боларның берсен дә җиренә җиткереп эшләми иде, самолетта солдатларның снаряд тиеп яраланган бармакларын бәйләгән кебек яки дәрестән авырып кайтып киткән әнисен дәвалагандагы кебек уен күреп эшләде. Эшен, күбесенчә, ярты юлда калдырып китте. Ләкин ул башлаганны берәү дә дәвам итмәде, бала кайчан да бер яңадан килеп, үзе эшләп бетерә торган иде. Ничек бетермәсен! «Илдар белән Саниянең әнә ничек матур, ә минем матур түгел...»

Бу мәсьәләдә Гөлсем апа үзе куйган тәртиптән чирек карыш та чигенми иде. Бер тапкыр Марат урамнан бик туңып кайтып кергәч, Сания, кызганып, башмакларын салдыра башлаган иде, Гөлсем апа анда да туктатты:

— Юк, юк, үзе...

— Чишә алмый ич, кулы туңган.

— Зарар юк, җылынгач чишәр... Угала, үскәнем, кулларыңны. Менә шулай. Тагын, тагын... Җылынса, башмагыңны сал инде. Утырып, утырып...

Моны күреп, Илдар булып Илдар ризасызлык белдерде:

— Үзең бер-береңә ярдәм итешегез дисең.

— Әйе. Кеше үзе эшли алмаса, яки ялгызына кыенга килсә... Я-ә инде, бар, үскәнем, кулыңны юып кил. Хәзер икәүләп әтиеңә хат язабыз...

Башак. Әрлән өннәре. Башмак тана. Комбайн. Гөлсем апа боларның вакытлы мавыгу гына түгел, коллектив хезмәткә мәхәббәтнең әлифбасы икәнен күреп ислэтә шатланды.

Әйтергә кирәк, авыл аның үзе өчен дә укылмаган бер китап иде. Калын иде, бик мавыктыргыч иде бу китап. Беренче битләрсенә күз йөртеп чыгу белән, эченә алып кереп китте. Дөрес, Гөлсем апаның, балалар кебек, теләсә кая барып, теләсә күпме чабып йөрергә вакыты булмады. Эш, җәмәгать эшләре муеннан, шуның өстенә бар да яңа һәм бик авырлар иде. Анысы анысы, утырткан бәрәңгесе, савар кәҗәсе дә булмаган өч бала анасына тормыш алып бару яман кыен иде. Марат әйткән матур шәл артыннан бик күп әйбер азык-төлеккә алыштырылган, сандык төбе тәмам коргаксыган, әш Марат әнисеннән калган алтын-көмешләргә килеп терәлгән, тик аларына Гөлсем апаның күңеле бармый тора иде.

Авыр, бик авыр иде Гөлсем апага. Ә шулай да ул «калын китап»ны актаргалап карарга вакыт тапты. Җае чыккан саен күргән-белгәннән сорашты. Мәктәпкә барганда-кайтканда үзен сарып алган балалардан да тартынмады ул. Мәктәп конюхы Закирҗан бабай, аның уйларын аңлап, очраган саен берәр нәрсә сөйләми калмады. Һәм сүзен һәр очракта берәр кызыктан башлап китә иде:

— «Җил тегермәне икәнен беләм, суы кайдан килә соң аның?» — дип әйтеп әйткән ди бер бәндә... хи-хи-хи... Әйдә, утыр әле, кем, озак итеп сөйлим мин сиңа хәзер...

Алай әйләнеч булса да, Гөлсем апа мәктәпкә күбесенчә тимерчелек, ферма, силос башнялары яныннан үтеп йөрде. Ындырчылар белән әңгәмә үткәрергә килгәч, җилгәргечне әллә ни күреп карап торды. Молотилканы китап буенча гына күз алдына китерә иде. Хәзер аның бертуктаусыз жу-жу итеп көлтә чәйнәп чыгарганын балаларча мавыгып карап торды. Ә кайчак, очынып китеп,

барабанга көлтә бирергә керешә, яки җилгәргечкә барып тотына, аны очынып-очынып әйләндерә иде. Тегермәнчеләргә Совинформбюро хәбәрләрен укырга баргач, тегермән ташларын тотып-тотып карый, озаклап буага карап тора иде. «Бар да нинди гади, шул ук вакытта никадәр акыллы эшләнгән!» Ул да, балалары кебек, барысын да сораша, аның сораулары арасында авыл балаларының хәтта Шамил кебекләре өчен дә көлкеләре була иде.

Бер тапкыр мәктәп түтәлләрендә кишер сирәкләп йөргән балаларны күреп, тәрәзә ачып кычкырды:

— Китегез, тимәгез кишергә!

— Кара, без утыйбыз ич, апа.

— Күрәм мин ничек утаганыгызны, алдыгыз тулы кишер...

Хәбәр өйгә үзеннән алда кайтып ишетелде. Балалар әниләрен көлеп каршы алдылар. Ә Илдар көлмәде. Ул, үкенечле итеп, телен шартлатып куйды:

— Ах, үземнән сораган булсаң... Малайлар тагын күзне ачырмый икән инде...

Гөлсем апа, шатланып, улын кочып алды:

— Ә син белә идеңме?

— Минме? Мин...— Малай үзенең белгәннәрен тезеп китте.

— Иһи-и... болай булгач, бу баруда директор малайларыныкы іше пароходны алып кайтмый булмас ахрысы...

— Узган юлы да шулай дидең син.

— Юк, монысында берсүзсез...

Сүзендә торды Гөлсем апа. Казанга килеп, йомыш-юлларына йөреп чыккач та, уенчык магазинына керде. Ләкин сугыш вакыты бит; магазинның вывескасы гына калган, анда хәзер электр әйберләренә ремонт ясыйлар иде. Бәлки сорочийда булыр? Гөлсем апа шунда китте һәм ярты юлдан борылып кайтты. Кинәт башына бик акыллы бер уй килде аның. «Бигрәк әйбәт, шулай итим әле...» Ул авыл башындагы күпергә кадәр килеп көтеп алган балаларына:

— Мин сезгә тагын пароход алып кайтмадым бит әле,— диде. Җитмәсә, көлеп әйтте.

Илдарны әйтәсе дә юк, Марат белән ни сабыр Саниягә кадәр авызларын турсайттылар. Алар бит инде авыл малайларына мактанып та куйганнар иде: «Үзе ак була, трубасы зәңгәрле-аклы, түбә кызыл. Маяклары-

ның да берсе кызыл, берсе сары. Ә буксиры көрән, төтене чыгып тора, тәгәрмәчләре комбайн канаты кебек чыж, чыж...— «Кычкырта дамы?..» — «Бәлки кычкыртыр да әле...» — Илдар белеп тора, малайлар күрсәт тә күрсәт дип хәзер килеп житә инде... Ну шушы әнине!..

Ә инде әниләре сумкасын чишеп, урындыкка кечкенә балта, чүкеч, кадак, ышкы кебек нәрсәләр чыгарып тезгәч, Илдар да, Марат белән Сания дә ачылып киттеләр.

— Менә нәрсә, Айтуган токымы, пароходны үзегез ясап карагыз әле...

Кече як бик тиз агач мастерское төсенә керде. Аннан бер-бер артлы «артык-портык» нәрсәләр чыгарыла барды. Алар урынын эш кораллары, такта, клей кебек нәрсәләр алды. Идән йомычка, струк йомычкасы белән тулды, өйдә нарат сагызы исе аңкыды.

Фәритләрнең этиләре балта эшен белә икән, кораллар белән ничек эш итәргә өйрәтеп торды. Марат белән Шамилгә дә эш табылды. Берсен, тәҗрибәсе дә бар дигән булып, завхоз иттеләр, икенчесен директор итеп куйдылар.

Билгеле, шактый агач башына җиттеләр малайлар. Һәр ике ишек алдында һичбер «артык-портык» такта калмады. Илдар, әни хәзер анда бернәрсә дә куймый, дигән булып, чолан шүрлеген дә куптарып алып керде, мунча чормасында да «тик яткан» бер такта табылды, әмма шулхәтле агачтан пароход түгел, бер ярык көймә дә чыкмады. Ләкин малайлар бик һәвәсләнгән иделәр, эшләрен туктатмадылар. Ә күңелсезләнә башласалар, Фәритнең этисе:

— Әйдә, ку, ку! Мәскәүне дә бер төндә генә салмаганнар,— дип дәртләндерә иде.

— Ә такта кайдан алабыз?

Илдар белән Фәрит ике йорт арасындагы койма такталарына тотынганнар иде дә, Гөлсем апа туктатты. Малайлар күпер салган җиргә барып калдык-постык йомычкалар җыеп кайттылар. Шунсы кызык: малайлар тактага караганда, йомычка белән саграк эш иттеләр.

Шулай тырыша торгач, көймә, ишкәкләр, маяк, аннан пароход та эшләнеп бетте. Әлбәттә, директор малаеныкының янына да куярлык түгел иде алар. Базар көнне җыенысына өч тиен бер акча бирмәсләр иде. Ә шулай да яшь балта осталары аларны кулларыннан төшермәделәр. Марат, завхоз буларак, аларны, навигация ябы-

лып торган чакларда (төнлә белән), гел шкаф тартмасында саклады. Әкбәр, син йоклагач кереп урлыйм дип куркыткач, кровате астына яшереп, кулына карабинын тотып ята торган булды.

— Кереп кенә карасын. Бах, бах мин аңар...

Малайлар пароходларны башта ләгәндә йөртеп карадылар. Мәңгегә килгән кебек бөтен дөньяга җәелеп яткан кыш бабай ак тышлы кат-кат тунын салып, биленә пута итеп бәйләгән капчыгына бөтереп тыгып, таулар, урманнар артына, үзенең туган иле — Төньякка китеп баргач, ягъни язлар җитеп, гөрләвекләр ага башлагач, пароходларны урамга күтәреп чыктылар. Ә боз китеп бетүгә, инешкә коя торган тар ермакка алып төштеләр.

Карарга килгән балалар флотилиядән күзләрен ала алмадылар. Алар (кайсы рәсемдә күргән, кайсы пристаньнан күреп кайткан, кайсы «үзе белә») пароходларны камилләштерүгә төрле киңәшләр бирделәр. Ак буяу юк иде, известь белән буядылар, кызыл буяу урынына Гөлсем ападан кызыл кара сорап алдылар, күрән буяу урынына суган кабыгы суы ярап торды. Ә яр читенә кипкән камыштан маякчы йорты да ясалып куелгач, як-яклап ак, кызыл маяклар да тезелеп китүкәч, өстәвенә Заһит абый пароход һәм буксирларга механизм (кәтүк белән резинка) куеп, үзләре йөри торган иткәч, уенга катнашырга теләүче балаларның иге-чиге булмады.

Флотилияне хәтта узган-барган олы кешеләр дә туктап карап тордылар. Гөлсем апа да килде.

— Әни, бүген мин — капитан.

— Мин төнәген булдым. Ә бүген мин — вахтенный матрос...

Үскәнем минем...— Гөлсем апа уйларының барып чыгуына, барыннан да бигрәк, Маратның җаны тынычланганга шатланды. Әнисе үлгәнгә ел ярым дигәндә, Марат аңар бәйле хатирәләрне тәмам онытып бетереп, бөтен барлыгы белән Гөлсем апага бирелгән иде инде. Бер очтан анысын да әйтеп китик, каенана да язмыш белән килешкән, хәзер сабыйны, үз күрмәсә дә, дошман күреп йөрми иде. Соңгы килүендә кучтәнәч итеп алып килгән балан бәлешен дә бик гадел итеп балаларның өчесенә дә бүлеп бирде. Ә күрше карчыкның: «Гөлсемегез кайсы авылга олакты соң?..» дигән хатына, җавабында: «Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле улып торгучы...»

ларны, «чуктыйн-чук, күптин-күп сәламнәр»не дә әйтеп тормастан, «Абау, Хөббелниса туганый, ...ашаудан туктамагач та туктамассың икән, тфү, җир бит!..» дип язып салды.

9 АЧЫКСАЛАР КАРЛЫГАЧНЫҢ БАЛАЛАРЫ...

Эңгер-меңгер чак иде. Авыл рәсемдәге кебек тын. Шул тынлыкны бозасы килмәгән кебек, әкрен генә янгыр сибәли башлады. Балалар, эшләрен ташлап, тәрәзәгә килеп өелделәр. Күптән яуганы юк иде, Гөлсем апа да тансыклаган икән, эш арасында урамга карап-карап алды. Сирәк, ләкин бик эре тамчылар басылып яткан юл тузаннарын кузгаттылар. Гүя кемдер күзгә күренми торган тылсымлы чыбык белән төртеп-төртеп ала — үләннәр берән-сәрән селкенешеп куя иделәр. Көнозын кояш астында көеп яткан түбә калае күңелле шыбырдый иде. Ә җилләп ява башлагач, урам караңгыланып киткәч, шыбырдау тоташ гөрелдәүгә әйләнгәч, тәрәзәләрне ябып куеп, тагын бар да үз эшләренә керештеләр. Гөлсем апа Мостафа абыйга җибәрергә җылы бияләй бәйләде, Сания кисәк-косаклардан курчагына күлмәк текте, Марат Мияубикәсен ашатты. Илдар, әнисенә уклау таягы юнып утырган хәлдә, малайлар белән ат сакларга баргач күргәннәрен сөйләргә керешә.

Ул әле тасвирлап сөйли белми, ләкин аның сүзләреннән шундый күренеш күз алдына килә: Төн. Бөркү болынга сизелерлек булып салкын төшә. Малайлар учак әйләнәле тезелешеп утырганнар. Көлгә күмеп пешерелгән бәрәңгеләр ашалып беткән инде; куырылган борчакның да исе генә калган; әкият сөйләшәләр.— «Борынборын заманда...» — Табигать үзе дә әкият дөньясы кебек: болын өстендә сыек томан; үзе бил тиңентен генә. Чалкан яттың исә, йолдызлар (гүя аларны лимон төргән кебек юка кәгазьләргә төреп чыкканнар) беленер-беленмәс кенә күренәләр; торып бастың исә, тимерче мичендә кыздырылган корыч кебек ялтырап яналар. Ай шундый якты, Зөһрәсе, Зөһрә кызның көянтә-чиләкләре аермачык күренә. Ә күк зәп-зәңгәр, куе-зәңгәр, үзе тәбәнәк. Шундый тын, ихлас белән тыңласаң, пароходның дөпдөп дөпелдәп баруына хәтле ишетелә, гүя ул Иделдән түгел, әнә шуннан гына, инеш буйлап кына узып бара.

Илдар хәзер ат сакларга бик еш йөри. Элегрәк атлану кая, ат атланган малайлар артыннан җәяү генә йөгерә иде һәм шуңар да риза иде; быел элдертә генә!.. Дөрес, ат өстендә Харис яки Күчерт Җәмил кебек күкрәген киереп, аякларын як-якка тырпайтып утыра алмый әле ул, атының муенына кадәр иелеп төшә, ялларына тотына, аяклары ат биленә кыскыч кебек чытырдап ябыша. Аңардан авыл кешеләре генә түгел, Гөлсем апага кадәр көлеп кала. Ә Марат көлми. Ул абыйсы артыннан авыл чыкканчы өметләнеп йөгерә дә күңелсезләнеп кире борылып кайта. Ну, бу әнине!.. Өйдә калырга булса, үскәнем, ди, ат сакларга дисәң, син кечкенә әле, ди...

Илдар бармагына кергән шырпыны әнисеннән алдырта да сүзен дәвам итә:

— Мин теге алашаны ташладым бит, әни. Ялкау. «Койрыклы йолдызны» бирделәр хәзер миңа, оча гына!..

Ул, яңа биясенең, ят тавыш ишеткәч, колакларын торгызып, шомлы кешнәве турында, еракта бер гамьсез уйнаклап йөргән колынның, матур мекердәп, әнисе янына йөгереп килүе турында сөйли.

— ...Кызы-ык. Башы, яллары күренеп бара, сырты да күренеп-күренеп китә, гәүдәсе күренми...

— Ник?

— Томан.

Илдар, әллә инде сөйләгән икәнен онытып, әллә аеруча яратып, бу җирен кат-кат сөйли. Сөйли бирсен! Күңелле ич. Марат дәшми. Ул абыйсының кабатлаганда төшереп калдырган сүзләрен өстәп куя:

— Колын сөт эчендә йөзеп килгән кебек күренә...

— Әйе, сөт эчендә йөзеп килгән кебек,— ди Илдар һәм ялгап китә: — Әнисе дә аңар каршы йөгермәкче була, йөгерә алмый, аягында тышау...

Илдар туктый. Бар да канәгать. Ә Марат туймаган әле:

— Тагын, Илдар абый.

— Бетте инде.

— Бетмәде. Ашыгыздан бака боты чыкканны сөйләмәдең.

Сания көлә, әниләре дә елмая, ә Илдар, күңеле болганып укшый башлый:

— Икенче кат искә төшерсәң, бернәрсә сөйләмим мин сиңа.

Маратка күңелсез булып китә. Ләкин ул хәзер, элекке кебек, бу семьяда үзен ят күреп йөргәндәге кебек итеп күңелсезләнми. Абыйсының ачуланганын шунда ук онытып, тагын ялына башлый:

— Алайса Әкбәрнең авырып ятканын сөйлә.

Барысы да көлешәләр. Илдар да, энесенең әле генә ачу китереп торганын онытып, елмая. Ләкин сөйләми.

— Я, сөйлә инде, без дә ишетик.

Әнисе шулай дигәч, Илдар сөйләп бирә. Ул аны мәктәп кичәсендә сөйләргә әзерләгән, ярыйсы гына килештереп сөйли:

— ...Барып керсәк, ята бу.— «Укырга ник килмәдең?» — «Авырыйм».— «Әйдә алайса, бүген үткәннәрне күрсәтәбез». — «Кирәкми, авырыйм».— Әнисе градусник куйды. Ашарына китереп бирде. Майлы ботка. Әй иркәләнеп кенә ята бу ашап... Бер заман әллә нәрсә шарт итте. Борылып карасак, градусник икән. 36 дан күтәрелмәгәч, боткага тыккан булган, наян! Ә градусник 42 гә житкән дә — шарт!.. Әй ярды үзен дә әнисе! Штанын төшереп...

Гөлсем апа да шаркылдап көлә. Марат, Әкбәр булып кылану өчен, әнисеннән градусник сорый. Әнисе бирмәгәч, баядан бирле аяк астында мыраулап йөргән Мияубикәсен үйната башлый. Мияубикәгә исә уен түгел, сөт кирәк. Ә сөт үзләренә дә юграк шул... Марат урынын җәеп куя. Юк, Илдар белән Саниянеке ише булмады әле. Аларныкына карап төзәтеп җәя. Аннары барып юына. Ләкин ятарга иртә әле. Ә соң нишләсен икән? Ул бераз әнисе янында басып торды, Сания янына килде. Илдар янына барып тезләнде. Ләкин кеше эшләгәнне карап тору эшмени ул! Марат Тукайның «Карлыгач»ын сөйләргә кереште. Ул урындыкка басып, кулларын әнисе өйрәткәнчә селкеп, бик бирелеп сөйләде. Өйдәгеләр аның инде бик аз калган сакаулыгын да яшерергә тырышып әйтелгән сүзләрен эш аралаш көлешә-көлешә тыңлап тордылар.

Менә декламатор:

«Ачыксалар карлыгачның балалары...» —

диде дә, кинәт эсәрләнеп, туктап калды. Сания, оныткан дип белеп, энесенең исенә төшерде:

Ә Марат, авызын бөрештереп:

— Кайтмый, кайтмый. Әниләре юк, оялары да юк...— диде һәм,— чыланалар инде алар менә-ә,— дип елап ук җибәрде.

«Ни булды бу балага?» — Гөлсем апа Илдар белән Саниягә сораулы карады.— «Әллә берәрсегез кыерсыттымы, югыйсә?»

Юк, кыерсытмадылар, эш болай булды. Фәритләр ишек алдында кош оясы бар. Яз көне кош сөюче балалар ясап куя торган ише түгел. Ана кош аны печән, мамык кебек нәрсәләр ташып карт акация башына үзе ясаган. Кош дигәч тә, сез аны сандугач яки карлыгач икән дип уйламагыз. Ишек алдыгызда нәзек озын гәүдәле, төскә көл төсле, сыек шәмәхә койрыклы бернәрсәнең түбәнтен генә очып, чебен-черки аулап йөргәнен күргәнегез бармы? Кош дигәнем шул инде. Әйтергә кирәк, аның бөтен эше дә шул чебен-черки аулаудан гыйбарәт, һәм ул бу эшнең зур остасы. Кайдан күреп ала, кай арада килеп җитә — и һоп тегене! Кешеләр аңар, бик белеп, чебенче дигән исем биргәннәр, ә табигать галимнәре, санитарка дип йөриләр. Монысы да бик тапкыр исем. Бу кош күп оялаган ишек алдында чебеннең заты да булмый. Ә чебен, үзегез беләсез, заразаны иң күп ташучылардан.

Кичә Маратлар кергәндә, ике чебенче читәннән чебен-черки аулап йөриләр иде. Әллә каян зур гына бер тилгән атылып килеп төште дә, күз ачып йомганчы, боларның берсен эләктереп алып менеп тә китте. Ә Фәритнең кече абыйсы — Госман берданка алып чыккан арада әллә шул ук, әллә икенче бер тилгән һавадан койрыклы йолдыздай атылып килеп төште дә, беренчесенең коелып калган каурыйлары тирәсендә чырылдап йөргән икенче кошны да эләктереп менеп китте. Фәрит белән Илдар акациягә менеп караганда, ояда әлеге чебенче кошларның балалары, әти-әниләренең ашарга алып кайтканнарын көтеп, чыелдаша иделәр.

Марат хәзер елый-елый әнисенә шул турыда сөйләп бирде. Бу вакытта яңгыр дөньяларны шаулатып ява иде, әледән-әле күк күкри, якында гына яшен яшьни, яңгыр тамчылары тәрәзә пыяласын юып төшәләр, пыяла үзе дә яңгыр белән эреп ага кебек иде.

Гөлсем апа Маратны алдына алып юатып карады.

— Йоннары калын аларның, улым, тәннәренә үтә торган түгел.

— Юк, үтә торган.

— Алар йоклаган инде. Тукай абый әнә ничек ди бит:

> «Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр килсен яшен...
> Уянмый ул, селкетми дә борын очын».

«Әэ сиңа. Өсләренә шундый яңгыр явып торганда ничек йокласыннар инде алар!..» — Юк, Марат монысына да ышанмады. Ул, әнисе алдыннан шуышып төште дә, ян тәрәзәгә килеп сыланып, Фәритләр ишек алдындагы карт акацияне эзләде; күрә алмагач, үз өй түрләрендәге яшь каен башына күтәрелеп карады да яңгыр астында бөрешеп утырган ятим кошчыкларны күз алдына китерде. Ә каеннан бер яфрак өзелеп төшеп яңгыр суына агып киткәч, «кош оясы да шулай агып китә инде менә», дип, тагы да катырак елый башлады.

Сания дә кызганды кош балаларын. Илдар, үз күзе белән күреп төшкәнгәдер инде, бигрәк кызганды. Ул, башта игътибар итмәгән кебек, уклавы белән кайнашкан булды; ә күк күкрәве кимеп, яшеннәр бик еракта яшьни башлагач, яңгыр туктап беткәнне көтмәстән, Фәритләргә китте.

Бу вакыт тышта караңгы төшеп беткән, Фәрит тә печәнлеккә менеп, әтисенең гражданнар сугышыннан киеп кайткан шинель сәләмәсенә төренеп йокларга яткан иде инде. Ишек алдында Илдар тавышын ишетүгә, трусик кына кигән килеш атылып чыгып, лапас баганасы буенча шуышып төште.

— ...Малай елый,— дигән булды Илдар.— Алып төшеп бирик микән әллә? Үзе теләсә нишләтсен.

— Әйдә соң.

Илдар яны белән акация кәүсәсенә сөялде. Тегесе, аның иңбашларына басып, ботакларга ябыша-тотына өскә үрмәләде һәм, менеп житкәч, телен шартлатып куйды.

— Нәрсә, Фәрит?

— Үлгәннәр.

— Барысы дамы?

Фәрит кошчыкларны бармак битләре белән кузгаткалап карады:

— Барысы да.

Илдар тагын:

— Ах, безнең малай үкерә икән инде алайса,— дигән булды.

— Очып киткәннәр, диярбез.

— Ышандырырсың аны, бар...— Илдар лапас астындагы буш кисмәкне акация төбенә тәгәрәтеп китерде дә, шуңар басып ботактан ботакка күчә-күчә, дусты янына үрмәләде.

Ятимәләрнең эти-әниләре урынны сайлый белгән, оя ипле генә өч тармак төбенә түшәлгән икән. Ләкин, алар аны ел да керә торган ояларына чыпчык кереп утырганга күрә генә, күкәй салыр вакыт җиткәнгә генә, ничарадан-бичара гына әмәлләштереп кергәннәр, күрәсең, оя әйбәтләрдән түгел иде. Үзе кәләпүш хәтле генә, печәне юка, яхшылап ныгытылмаган, мамыгы да бик аз иде. Кош балалары, кичә Илдарлар күреп төшкәндәге кебек, авызларын зур ачып, шәрә, алсу муеннарын бар да бер якка борып, күңелле чыелдашмыйлар, манма сулы оялары төбендә хәрәкәтсез яталар, укмашып беткән йон араларыннан күгелҗем салкын тәннәре күренеп тора иде.

— Ах, алданрак уйлаган булсак.

— Инде нишләтәбез?

— Әйдә, алып төшеп күмәбез.

— Әйдә соң...

Инде яңгыр басылган, күк ерак күпердән дөбердәп барган тимерсез арба кебек кенә күкрәп ала; болытлар авылдан авылга йөреп ява-ява гүя бик арыганнар, салкынча җил иркенә буйсынып, әкрен генә урманга таба китеп баралар иде. Аларның давылда өзгәләнгән җилкән кебек сәләмә читләреннән Илдар белән Фәритнең шәрә тәннәренә соңгы тамчылар тамып кала иде. Малайлар кошчыкларны кепкаларына салып, чит-читләрен бөреп авызларына каптылар да, Марат килеп җиткәнче күмеп ташлар өчен, ботактан ботакка тиеп төсле оста күчеп, аска төшеп киттеләр...

10 ЯТИМ КОШЛАРГА МЕНӘ НИ БУЛДЫ

Бер көтү бала болыннан җуа җыеп кайтып килә иде. Фәритләр турысыннан узып барганда, кинәт бер сәер тавыш ишетелде — берничә калай банка, бер-берсенә бәрелеп, шалтырый иде. Башкача түгел, Фәритнең Госман абыйсы тагын берәр әкәмәт уйлап чыгаргандыр әле!.. Шундый ул; аларның бөтен ишек аллары әкәмәт белән

тулы. Вакытлы-вакытсыз кече капкаларын ачып керденме,— мангаена имән чүкеч шалт! Мал абзарларының ишегенә килеп кагылдыңмы,— чиркәүмени — тиңгел-тиңгел кыңгырау шалтырарга тотына. Алма бакчаларындагы капкынга куян-мазар эләксә дә, кыңгырау шалтырый. Тик куян дигәнең бик сирәк эләгә, аның каравы шаян малайлар ялган тревоганы гел ясап торалар: кыңгырау шалтырый, Фәритнең абыйсы куян эләкте дип белеп йөгереп чыга, ә анда, капкында, саберке сабы яки мәче үләксәсе. Җитмәсә, койрыгында шундый язу:

«Куян үзе килмәде,
Мине генә җибәрде».

Госман да шаян малайлар алдында бурычлы булып калмый... Бер тапкыр кыңгырау тавышына йөгереп чыкса, капкында Күркә Әкбәр. Кулында күсе үләксәсе, үзе Тукай шүрәлесемени, разбой салып кычкыра. Ә Госман аны капкыннан ычкындырырга уйламый да. Ул, балалар күбрәк җыелсын өчен, мал абзарларының кыңгыравын ике куллап кага. Менә Фәрит алдан язылып куелган кәгазьне алып чыгып Әкбәрнең аркасына ябыштыра:

«Шүрәле фәрьят итәдер, аудан ычкынмак була,
Һәм дә ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була...»

Җуачы балалар, бусы да шундый мәзәктер әле дип, шау-гөр килеп, Фәритләр коймасына ябырылдылар, кечерәкләре башларын капка астыннан тыктылар. Һәм, мәзәкне күрмәс борын ук, шарык-шорык көлешә башладылар. Ә Илдар көлмәде, Марат белән Сания дә көлмәде. Алар белде: бусы Госман мәзәге түгел, Фәритнең житди тревогасы булырга тиеш иде.

Эш шунда ки, беркөн алар кош балаларын күммәделәр. Күмәргә дип, өянке төбенә чокыр казып торганда гына Фәритнең әбисе килеп чыкты.

— Нишлисез анда?

— Күмәбез. Кош балалары үлгән.

— Ай, мескеннәр...

Гайшәбикә әби кошчыкларның берсен кулына алып карады да учларында кысып җылы сулышын өрергә тотынды. Озаклап өрде ул. Аннан, хәйләкәр елмаеп, Фәриткә бирде. Фәрит кулына алуга шатлыгыннан кычкырып җибәрде: кошчык үзенең томшыгы белән малайның

уч төбен рәхәт кытыклый — яңа чыгып килгән мамык канатлары кыймылдый иде.

Шулай җылыта торгач, кошчыклар берәм-берәм бар да терелеп беттеләр. Шатлыкның чиге булмады. Балалар ятим кошчыкларны учларына алып сөйделәр, авызларын авызга куеп төкерекләрен эчерделәр. Ә иртәгесен иртүк килеп чебен тотып ашаттылар. Үзләре кечкенә, авызлары зур. Чебен, копилкага салган көмеш акча кебек, төшә дә китә...

Аннан кошчыкларны бүлешеп алдылар. Бала саен бер кошчык. Ләкин болай читен иде. Һәркайсына үзенекен, яныннан китмичә, саклап утырырга туры килә иде. Өстәвенә кошчыкларга да ялгыз-ялгыз күңелсез иде.

— Әйдәгез, күмәкләштерәбез,— диде Фәрит.

— Ничек?

— Фермадагы кебек.

Сания, фермадагы чебиләрне исенә төшереп, кулларын чәбәкләп куйды:

— Күмәкләштерәбез, күмәкләштерәбез!..

Кошчыкларны Гайшәбикә әбинең күкәй җыя торган бүрегенә тезеп яткырдылар да, печәнлеккә менгереп, эрҗә белән каплап куйдылар. Бергә җыелгач, кошчыклар күңелле чырылдаша башладылар. Алар бара-тора үзләренең шефларына бөтенләй ияләшеп беттеләр: шефлар яннарына менгәндә, барысы да башларын шул якка таба борып, зур авызларын ачып, чи-чи килделәр. Күңелле!..

Ләкин беркөнне Илдар белән Фәрит ашатырга дип менгәндә, кошчыклар боегып калганнар, ә берсе бүрек төбендә теге яңгырлы көндәге кебек, хәрәкәтсез ята иде.

Малайлар учларына салып, сулыш өреп карадылар, Гайшәбикә әби кебек итеп томшыгын авызларына да тыгып тордылар. Юк, кошчык терелмәде.

Илдар, чын күңеленнән әрнеп:

— Җитмәсә, безнең малайныкы бит,— диде.— Тагын елый икән инде.

— Без аны болай итик...

Үлгән кошчыкның муенында тар гына кызыл бантик бар иде, Фәрит аны чишеп алды да үзенекенә такты:

— Минеке үлгән диярбез.

Илдар Фәритне болай да үз күреп йөри иде, тагы да якынаеп китте. Тик ул бу уй башта үз башына килмәгәнгә генә уңайсызлана иде.

— Әби, ник үлде икән?
— Ашатмагансыз.
— Әә, ашатмас, биш тапкыр...
— Биш... Ә аларны әниләре көненә иллешәр, алтмышар тапкыр ашаткан. Аннан, чебен кирәк аларга, ак корт...
Әби өйрәткәнчә ашаткач, кошчыклар бик тиз үсеп киттеләр. Канатлары күзгә күренеп зурайды. Ава-түнә бүрек төбендә йөренделәр, очып чыгарга итенделәр...
Ләкин тагын нәрсә булган соң аларга? Фәрит нигә тревога күтәргән?
Илдар белән Марат һәм Сания жуаларын кочкан хәлдә Фәритләр ишек алдына йөгереп килеп керүгә, тынычланып киттеләр. Фәрит беркөн кошчык үлгәндәге кебек күңелсез итеп түгел, кыңгырауларын бии-бии шалтырата иде. Ул, Илдарларны күргәч, тагы да дәртлерәк шалтыратып:
— Очалар, очарга итенәләр!.. Минеке, әй, Маратныкы анау әрдәнәдән очып төште,— диде.
— Я тагын очыр...
Фәрит, бантиклы кошчыкны кисмәк читенә бастырып куеп, артыннан әкрен генә салам очы белән этәрде; кошчык аякларын терәп, артка этелде, Фәрит катырак төрткән иде, канатларын җәеп, чи-чи килеп, инде бик күп булып җыелган балаларның аяк астына очып төште.
— А-а, бик инде. Эткәч, песи дә сикереп төшә. Югары очсын ул менә,— диде Күчерт Җәмил.
Әкбәр монда да кысылмый калмады.
— Безнең Фәрит үзе дә гел аска сикерә ич. Яшел тышлы китапта, мал иясенә охшар, диелгән, һе-һе.
Бу көләрлек иде. Әллә айгыры шундый туры килә — ат сакларга барганда Фәрит еш кына атыннан егылып төшеп кала иде. Ләкин балалар ятим кошчыклар белән шулкадәр мавыктылар, Әкбәрнең сүзенә әһәмият бирмәделәр. Алар ничек булса да кошчыкларга ярдәм итәргә теләделәр. Кайсы берәр валчык эзләп алып каптырды, кайсы чебен тотып алып килде.
Ә Фәрит күңелсезләнде:
— Әби, нигә югары очмыйлар икән?
Балалар тавышына уянып, мендәрен күтәреп, келәттән өйгә кереп барган әби, тукталып та тормастан:
— Хәзер әби кирәк, бая мунчага су ташырга дигәч, ишетмәмешкә салыштың...— диде.

— Икенче вакыт ишетер идем, әбекәчем.
— Анда да, тыңлар ием, дими бит әле, сансыз... Болай итегез...
Әбинең киңәше файдалы гына түгел, бик мавыктыргыч та иде. Балалар, кошчыкларны алып, берсе калмый мәктәп бакчасына йөгерделәр.
Бакча төрле кошлар тавышы белән гөжләп тора иде. Агач саен диярлек матур-матур сыерчык оясы. Кайберләренә сыерчыклар килгәнче өлгер чыпчыклар оялап алган. Илдар, шундыйларның берсеннән ана чыпчык очып чыгып китүгә, үз кошчыгын кепкасына салып авызына капты да, агач башына үрмәләде. Һәм, кошчыгын оя авызыннан төшереп җибәрде дә, баз баскан карак малай кебек куркынып, ботактан ботакка төшеп җиргә сикерде.
«Инде ни генә булыр икән?» — Балалар, түземсезләнеп, ана чыпчыкның кайтканын көтә башладылар.
Чыпчык озак көттермәде. Авызына нәрсәдер кабып кайтты да, томшыгын оя авызыннан эчкә сузып торды һәм тиз генә очып та китте. Тагын кайтты, тагын китте.
Балалар иркен сулыш алдылар.
— Ят күрми, ашата...
— Каян беләсең?
— Ят күрсә, ул аны чыгарып ташлар ие.
— Әйе сиңа...
— Бер дә «әйе» түгел. Бар, оясына берәр карлыгач баласын кертеп кара әле...
Шулай бәхәсләшеп торганда, чыпчык тагын кайтып килде. Бу юлы аның авызында бер чеметем печән һәм мамык бөртекләре иде.
Балалар, моны күреп, бердәй шатланыштылар. Ә Марат белән Сания өчен бу әле табышмак иде:
— Илдар абый, нишли ул?
— Минем кошчыкка урын хәзерли.
— И-и...— Сания белән Марат кулларын чәбәкләп алдылар.
Балалар икенче кошчыкны да шунда менгереп куярга булганнар иде, тәҗрибә участогында эшләп йөргән пионерлар күреп туктаттылар:
— Чыпчык сезнең кошчыкларны, әлбәттә, чыгарып ташламас. Ләкин аңар бик авырга киләчәк. Бүтән ояларга менгерегез,— диделәр.
Марат белән Сания тагын кулларын чәбәкләделәр. Ә инде үзләренекен менгерергә чират җиткәч, сагайды-

лар, йөзләре сагышланып китте. Кошчыкларын, бүректән алып, күкрәкләренә кыстылар.

— Качыйк, тәти апам, бирмик,— дип пышылдады Марат Саниянең колагына һәм тәркемнән артка чигенә башлады. Ул пионерлар белән бергә яшелчәләргә су сибеп йөргән Гөлсем апа килеп аңлаткач кына тынычланды. Ә Илдар кошчыкның бантигын чишә башлагач, тагын борчылып, аның кулларына ябышты:

— Әйем, чишмә.

— Ник, нәнәм ?

— Очканда таныйм.

Балалар көлештеләр. Сания көлмәде. Ул үз кошчыгына да бантик ясап такты:

— Киләсе елда килгәч таныйбыз, әйеме, нәнәм? Ул чакта алар үзләре әни булалар.

Балалар кошчыкларын, чыпчыкларга «асрамага биргәч»тә онытмадылар. Аналары азык юнәтергә чыгып киткәнне саклап торып, әллә ничә тапкыр ашарларына биреп төштеләр.

Гөлсем апа барысын да күреп торды; кошлар очып киткәч, балаларга ямансу булачак иде; шуңа күрә ул Марат белән Илдарга алдан ук бер пар йорт куяны, Саниягә чебиләр алып кайтып бирде.

Атна дигәндә Фәритнең кыңгыраулары тагын телгә килде. Бу юлы кыңгырау мәктәп бакчасында, кош ояларына якын гына бер агач башында иде. Балалар йөгерешеп килгәндә, бакчаның ком сибелгән юлларында, юл читендәге чирәм араларында чыпчык балалары чыелдаша — чыпчыклар бала очыра иделәр.

Балалар, эзли торгач, Марат белән Саниянең кошчыкларын таныдылар. Алар икесе бергә яшь кенә бер юкә ботагында утыралар иде.

— Әнә минеке.

— Юк, анысы минеке, нәнәм.

— Минеке инде тәти апа.

— Ну ярый, синеке. Тегесе минеке...

11 ИДЕЛ БУЕНДА

Сугыш, сугыш! Нәрсәне генә үз каһәреңә буйсындырмадың син? Ил күрке — ямьле Иделне дә үзеңнең кара җәймәңә төрдең бит инде. Әнә пароход. Аның аккош ке-

бек ак булуы кояшның алтын төсле булуы шикелле үк табигый иде. Син аны да үзеңнең күңел кайтаргыч кара көрән төсеңә буядың. Иделнең нурлы күзләрен — ике яклап тезелеп киткән маякларны өреп сүндердең син. Маякчы тәрәзәсенә, пароход тәрәзәләренә маскировка кордың. Тавышы килә, кычкырта, дөпелди дә, ә үзе күренми; килеп җитәрәк кенә күз алдында ниндидер шыксыз нәрсә пәйда була һәм үзе шикелле үк иләмсез, дөмкараңгы пристаньга килеп туктый... Шулай да Иделнең үзен, аның табигый матурлыгын үз төсеңә буяу синең кулыңнан килмәде, сугыш! Син дип тормады: һәр язда бозлар тезелеп акты Иделдә. Бөек елга үзенең ярларыннан ташып чыкты; агачлар яфрак ярды, Идел урманнары, яр буйлары яшәрде; суы, кояш нурлары астында, ана баласына елмайган кебек җемелдәп акты. Аяз кичләрдә Иделнең очсыз-кырыйсыз күгендә ай калка иде. Урактай кәкре, аннан ярты, аннан тулы; Зөһрәле. Зөһрәсе көянтә-чиләкле... Ярында көймәләр чайкала, һавасында дары сөреме түгел, кыр чәчәкләре исе аңкый иде.

Шундый кичләрдән бер кичтә, Иделнең болын як ярында, маякчы өеннән әз генә читтә ике малай күренде. Салкынча булгангамы, әллә бераз курыккангамы, берберсенә елышып утырганнар. Учак ягып җибәрсәләр дә, яхшы булыр иде, әлеге дә баягы, ярамый, Идел сугыш режимына буйсындырылган. Маякчы апа ике чыгуында да кисәтеп куйды: «Карагыз аны, колагыгызны борырмын!..» Шулай да малайларның алларында коры чыбыкчабык, кулларында шырпы. Янәсе, урман әнә генә; бүремазар килеп чыкса, маякчы апа дип торып булмас...

Кичке шәфәкътән бирле утыра инде алар. Әниләрен көтәләр. Ул аргы якта пароходтан төшәргә дә, көймәгә утырып, бу якка чыгарга тиеш. Караңгы төшеп бетә; ярдан ярга кеше ташып йөргән ишкәкче бабай, көймәсен казыкка бәйләп, авылына кайтып китә; аргы якта, пристаньда, крушникларның: «Идет-идет, сама пойдет...»лары да ишетелми башлый, Идел йокыга тала, ә әни һаман юк та юк.

Малайларның зурысы: «Әйдә, өйгә кайтыйк, иртә белән килербез», — ди (монысы Илдар), кечкенәсе: — «кайтмыйк»,— ди (монысы Марат). Кайтмыйк, ди, ә үзенең күзләре йомылып-йомылып китә, башы абыйсының алдына салынып төшә.

— Йоклыйсың бит, нәнәм, әйдә инде...

— Ю-ук. Әнинең төенчеген күтәреп кайтам,— ди Марат һәм, жинел калтыранып, яны белән абыйсының жылы куенына сыена. Ул, тынгысыз акчарлакның яр читендәме, маяк өстендәме пи-пи, пи-пи дип сызгырынганын тыңлап тора да:

— Абыем, ник пи-пи итә ул? — дип сорый.

Илдар бүген аның «ник»ләреннән туеп бетте инде. Теләмичә генә:

— Сайравы шундый яки сөйләшүе,— дип җавап бирә.

— Ә ни дигән сүз ул: «Пи-пи»?

— Мин акчарлык түгел лә. Бар, үзеннән сора,— диде Илдар ачуланып һәм Мараттан читкә тартылды. Марат авып китте. Ул, элекке чак булса, күңелсезләнер иде, ә хәзер үз әти-әнисен бөтенләй оныткан, үзен тумыштан Айтугановлар семьясыныкы дип белә иде, шуңар күрә Илдарның бу тупаслыгына туган белән туган арасындагы бер кечкенә бәрелеш кенә дип карады, яңадан аңар килеп сыенды да, бер дә исе китмичә, сорашуын дәвам итте. Илдар исә бара-тора бөтенләй җавап бирмәс булды. Ләкин Марат, болай сөйләшми утырса, йоклап китәр иң. Еракта дөпелдәгән пароход тавышын тыңлап торды да:

— Ә пароход сөйләшәме? — дип сорады.

— Сөйләшә инде, сөйләшә.

— «Дөп-дөп-дөп, дөп-дөп-дөп» ни дию аның?

— «Кайтыгыз инде, кайтыгыз инде»,— дию.

Марат, чынга алып, пароход дөпелдәгән көйгә «кайтыгыз инде, кайтыгыз инде...» дигән сүзләрне әйтеп карады:

— И-и шулай икән шул. Каян белдең, абыем?

— Минем хәтле булгач, син дә белерсең әле... Әйдә, киттек.

— Әем. — Марат пароход дөпелдәгән якка карады да зарланып куйды.— Ул безнең әнине көтеп утырганны белми; белсә, алай әйтмәс иде, әйе бит, абыем?

— Барсана!.. Син теләсәң нишлә, мин кайтам...— диде Илдар һәм чыннан да торып китә башлады. Марат аңар чытырдап ябышты:

— Әз генә, бик, бик әз генә, абыем...

Белмим, Илдар тыңлар иде микән, шул чак аргы як ярдан «көймә-ә!..» дип сузган тавыш ишетелде. Марат, әнием, әнием, дип кычкыра-кычкыра күзләрен тавыш килгән якка юнәлтте, ләкин һичкемне күрә алмады. Ил-

дарга калса, эндәшүче — әнисе дә, түгел дә кебек иде. Шулай да эндәшү кабатлангач, кулларын авыз кырыена куеп, Маратка кушылды:

— Ә-ни-е-емм!

— Көй-мә-ә!..

Ярда өч көймә бар. Берсе ишкәкче картныкы, икесе маякчыныкы. Ишкәкче үзе киткәндә ишкәкләрен әллә кая илтеп яшерде; маякчы апа лапасына кертеп куйды. Сорасаң, орышыр инде... Орышса орышыр... Илдар, кыюсыз гына килеп, маякчы тәрәзәсен чиертте.

— Кем бар?

— Апа, әни көймә сорый. Теге якта.

Илдарның апа дигәне үзеннән әз калку бер кыз булып чыкты. Ләкин тавышы, үзен тотулары белән бу кыз чын апа иде. Ул аргы яктан кабат «көймә!» дигән тавышка кулларын авыз кырыена куеп, аһа-һа-һа-а!.. дип эндәште дә күзләре белән Илдарны үлчәп чыкты, һәм ни өчендер, үзендә өстенлек күреп:

— Ишә беләсеңме? — дип сорады.

Әлбәттә, моңар Илдарның ачуы килде. Ләкин кызга сиздермәде. Я кәҗәләнеп кереп китәр, ишкәген талап алып булмый бит, дип уйлады ул һәм, тавышын бер дә күтәрмичә:

— Беләм,— диде.

— Иделдә дәме?

— Иде-ел... Әллә безнең Аккош синең Иделең хәтле генәме?

Кыз ышанды. Ул тынычланып өенә кереп китә башлады: «Ишкәк әнә утынлыкта...» — Һәм кинәт туктап, еракта кычкырткан пароход тавышын тыңлап-тыңлап торды да утынлыкка таба үзе юнәлде. Илдар аның ниятен аңлап:

— Үзе-ем...— диде.

Кыз кимсетүле итеп:

— Әллә ишетмисеңме, скорый ич; җиле белән дә капландыра ул сине,— диде һәм ачу китереп, өстәп куйды: — Ә мин монда синең өчен җавап бир...

Илдарның муен тамырлары бүртеп чыкты. Көймәнең үзе өчен нигә кирәген дә онытты ул хәзер. Кызга, телең булмаса, карга күтәреп китәр иде инде сине... димәкче булды. Ләкин кызның көймә белән сокланырлык оста эш иткәнен күреп, ачкан авызын япты: кыз сикереп кергәндә, көймә әз генә дә чайкалмады. Ул көймәне бору

өчен ишкәкләрнең берсен алга, берсен артка шундый оста иште, көймә зыр әйләнеп, борыны белән сыек томанны икегә ярып китеп тә барды һәм бик тиз күздән югалды.

— Көймә сораучы булса, әйтерсез, хәзер кайтам,— диде ул томан эченнән.— Тунсагыз, әнә безгә кереп торыгыз... Юк, кермәгез, я песи балаларын таптарсыз...

Көймә кире әйләнеп килгәндә, Илдар чалбарын сызганып, бот төбентен суда басып тора, Марат маякчының икенче кызы — үзе хәтле генә кечкенә кыз белән чирәмдә уйнап утыра һәм әледән-әле Идел өстенә карап ала иде. Ул, көймәне күрүенә, күнелсезләнеп:

— Әни түгел-ел,— дип сузды.

Илдар исә монар бер дә күңелсезләнмәде. Көймәдә почта Зөбәйдә иде. «Бәлки әтидән хат бардыр?..» Ул, Зөбәйдә игътибар итсен өчен, көймәнең төбе комга тиюгә, чылбырыннан тартып ярга өстерәгән булды, энесе белән кычкырып сөйләште.

Ә маякчы кызы, аргы яктан почта кызын алып чыкканы, Илдардан:

— Әни дигән булдың... Их син, кола-ак...— дип көлде.

Көлсә көлер инде, әнә Зөбәйдә борылып карады. Ләкин карады гына шул, бер сүз дә әйтмичә, ярдан менеп китте.

— Тагын юкмыни, Зөбәйдә апа?

Почта кызы иңбашы аша борылып карады.

— Кем соң син?

— Илдар ич. Чулпанныкы. Укытучы Гөлсем улы.

Зөбәйдә сумкасыннан бер бәйләм конверт алды, күзләренә якын китереп, актаргалады да берсен Илдарга алып бирде.

— Ай рәхмәт, Зөбәйдә апа!

Илдар, хатны айга каршы тотып, көч-хәл белән сүзне сүзгә ялгый башлады һәм шунда ук күңелсезләнеп китте.

— Иске. Майда килгән хатыннан алда язганы. Сумкасында югалып яткандыр инде...— Илдар почта кызы киткән якка ачулы карап торды.

Шул чак аръяктан тагын «көймә-ә!» дигән тавыш килде.

— Менә бусы әни!..

— Әни, әни!..

— Көймә-ә!.. Әй-й!

— Аһа-һа-һа-һа!..— диде бу юлы да маякчы кызы. Ул, колакларын киеренкеләндереп, тыңлап-тыңлап торды

да инде узып киткән, бик еракта дөпелдәгән скорыйдан башка тавыш ишетмәгәч, Илдарга:

— Менә инде бара бир,— тик әнә шул кругны ал... Ә, юк, ансыз көймәгә аягыңны да атлатмыйм.

Илдар хәтле Илдар көймәдә круг белән йөрсен әле!.. Ләкин, берни эшләр хәл юк, риза булды. Ул, көймә борынын тавыш килгән якка таба куеп, дулкынланып, тиз-тиз иште. Менә хәзер аргы як ярга җитеп сикереп төшәм, әни шакката...

Ләкин тагын Илдар көткәнчә булмады. Аргы якта әни түгел, ак халатлы яшь кенә бер апа һәм кулын ак белән бәйләп муенына аскан, кара сакаллы, кара мыеклы солдат басып тора иде.

Илдар, күңелсезләнеп, кире борыла башлады, һәм шунда ук үзенең эгоистлыгы өчен уңайсызланып, көймә борынын киредән ярга таба турылады.

Нинди юньсез көн булды соң әле бу! Әнисе кайтмады. Зөбәйдә апа искереп беткән хат биреп китте. Иртәгә таң белән пионерлар инеш буйлап поход чыга, менә аннан да колак кага инде... Җитмәсә, бая яр читеннән бөрлегән җыеп йөргәндә күлмәк изүен буяды. Өр-яңа күлмәк бит...

Үз кайгысы белән мәшгуль Илдар ят апа белән солдатка бер күз төшереп алды да бүтән күтәрелеп тә карамады. Кепка козырегын борын очына хәтле төшергән хәлдә тик аска карап утырды. Тегеләрнең дә үз хәлләре хәл иде, ишкәкче малайда эшләре булмады. Ак халатлы апа солдатны беләгеннән саклык белән генә тотып көймәгә кертеп утыртты, яшел капчыгын кертеп куйды, шинелен беләгеннән алып, солдатның иңнәренә салды һәм, колагына шактый каты кычкырып:

— Ашыйсыгыз килмиме? — диде.

Солдат башын чайкады.

— Су...

Сестра, фляганы ачып, солдатка су эчертте һәм Илдардан:

— «Чулпан» моннан еракмы? — дип сорады.

«Берәр малайның әтисе инде бу алайса. Ә бусы кем икән?» — дип уйлады Илдар һәм җавап бирде:

— 3 километр.

— Шулай гына? — Ак халатлы ачылып китте. Ул авызын солдатның колагына якын куеп шактый кычкырып әйтте:

— Егет «Чулпанга» 3 километр, ди.

Солдат, җавап урынында, ишкәкче малайга таба борылып карамыйча гына:

— Белми ул, 8,— диде.

Солдатның колакка каты икәнен төшенгән Илдар, шактый кычкырып:

— 3 инде, солдат абый. Үз авылымны белмәскә мин,— диде.

Солдат, малайның тавышына бик эсәрләнеп, әкрен генә борылып карады. Һәм кинәт алмашынып китте, чиксез дулкынланып, Илдарга таба омтылды. Аннан, тыныч күренергә тырышып:

— Алай булгач, син укытучы Гөлсем улысыңдыр әле...— диде.

— Ә сез кайдан белдегез?

Солдат яр читендә житәкләшеп торган балаларга борылып карады:

— Тегесе Мараттыр.

— Марат шул.

— Тәти кызны Сания дияр идем инде, кечерәк, ә маякчы өеннән чыгып килгәне бик зур...

— Кара, каян беләсез соң сез, абый?

— Анысы гаҗәп түгел. Менә син «Чулпан»ны нигә 3 дисең? Шунсы гаҗәп.

— 3 булгач.

— Алайса, хатында ни өчен 8 дип яздың?

— Нишләп хат языйм ди мин сезгә?

— Оһо! Разия туташ, чишегез әле шул капчыкны. Астарак хатлар төргәге булырга тиеш. Анысы түгел, анысы да түгел. Әнә шунсын бирегез әле. Рәхмәт. Шырпыңны сызчы, Илдар Мостафич! Бу нәрсә, ә? Хәтерем алдамаса, мәктәптә безгә моны 8 ле дип укытканнар иде...

Илдар шаккатты дисәк аз булыр, ачкан авызын да япмастан катып калды. Бу аның цифры иде. Ул 3 лене гел шулай яза: түгәрәкләнеп килгән һәр ике ыргагы кушылыр-кушылмас кына кала да 8 легә охшап куя. Анысы вак мәсьәлә. Ләкин цифры Илдарныкы икән, хаты да аныкы була ич инде! Малай үз язганын бер күз төшерү белән укып чыкты: «...Маякчы өеннән сулга бер сукмак булыр; шул «Чулпан»га алып бара да чыга. Дөрес булсын дип, юри әллә ничә кешедән сорадым: яр читеннән «Чулпан»га 8 километр...» — Илдар, күзләрен хаттан алып, солдатка текәлеп карады һәм шатлыгыннан елап җибәрде.

— Ә-әти-и!..— диде ул, тотлыгып. Һәм, ак халатлы апаны ега язып, көймәне чайкалдыра-чайкалдыра, әтисенең кочагына ташланды. Кавышу хисләре басыла төшкәч, үкенечле һәм бераз үпкәләгән кебегрәк итеп:

— Ә сакалың булмаса, барыбер элек сине мин таный идем,— диде.

Көймә очлы күкрәге белән вак ташлы комны кыштырдатып килеп ярга бәрелүгә Марат та, Илдар кебек үк куанып, әтисенә сарылды. Мостафа абый, улларын тотып тора алмыйча, сыгыла башлаган иде, Илдар, сизенеп, кулларын аның муеныннан алды. Әтиләре исә, тезләнде дә һәр икесен сыңар кочагына кысып торды. Җибәрде дә тагы кочып алды. Үпте, сөйде. Аннан торып сәламәт кулын Маратның җилкәсенә салды:

— Синмени инде ул Марат — бакыр чәч?

— Әнием алтын чәч ди.

— Кара син аны!

— Сания апа да. Ачуланса, әйтми түлке. Чебиенең тәпиенә баскач, сукыр керпе, диде.

Мостафа абый, Маратның йомшак кызыл чәчләрен калтыранган бармаклары белән тарый-тарый:

— Юк, керпе килми сиңа, алтын чәч әйбәт,— диде һәм кинәт туктап малайларның әле берсенә, әле икенчесенә карап торды да: — Постой, постой. Нәрсә сез лунатиклар кебек, төн ката Идел буенда кайнаша идегез әле?

— Әнине каршы алырга килгән иек.

— Ул безгә тиски алып кайта.

— Аннан конструктор.

Мостафа абый моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, ә маякчы өенә кереп, юлда керләнгән ак якасын, яралы кулы асылган киң бинтны алыштырткач, сестрага мөрәҗәгать итте:

— Шул котомканы чишегез әле, Разия туташ.

Малайлар, сестра кузгалганчы йөгереп килеп, ашыгакаушый яшел капчыкны чишеп җибәрделәр. Аннан Шишкинның «Иртән нарат урманында» исемле атаклы рәсеме төшерелгән бик матур шкатулка килеп чыкты. Шкатулка ак, кызыл, зәңгәр, сары кәгазьләргә төреп бәйләнгән кечкенә-кечкенә төргәкләр белән тулы иде.

— Бусы алма, бусы хөрмә...— диде Мостафа абый төргәкләрне берәм-берәм алып балаларына күрсәткәндә.— Ә менә монысы Бессарабия чиясе, монысы Херсон винограды...

Марат бернәрсә дә төшенмәде. Илдар исә, елмаеп:

— Ә-ә, белдем инде, бакча белән ишек алдының зурлыгын шуңар сорап язгансың икән,— диде.

Әтиләре, бусагага утырып, балаларын сыңар кулы белән кочты да, кайчандыр, бала чагында мәктәп сәхнәсендә көйләгәнчә көйләп җибәрде:

«Булса калдырмак бераү ошбу җиһанда изге ат...»

Декламациягә, кулларын әнисе өйрәткән кебек болгый-болгый, Марат та кушылды:

«...Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһат».

Солдат Маратка сокланып карап торды. Бу вакытта аның күзләре «Гөлсем сине юкка гына яратмаган икән, мин дә яраттым сине, яраттым, сөеклем...» дия иделәр.

12 СОЛДАТ БАЛАЛАРЫ

Әти кайту зур бәйрәм булды. Кай арада ишетеп өлгергәннәрдер, туганнар, чыбык очы туганнар килеп җитте, күрше-колан кереп тулды. Гөлсем апа авыл тормышы белән торырга өйрәнеп килә иде инде («артык-портыкларын» сатып кәҗә алган, бәрәңге утырткан, Саниянең чебиләре әллә кайчан тавык булып җиткән, үкертеп күкәй салалар иде), хәзинәдә бары белән бөтенесен кунак итте. Ә Марат белән Илдар (кара, тәки теләкләренә ирештеләр бит!) иң симез куяннарын суеп әниләренә кертеп бирделәр.

— Пешер, әни. Бөтен килеш түлке... Ю-ук. Сыя, әни, сыя. Без инде аны салып карадык... И табынга да бөтен килеш куй, әти алдына, теге озын тәлинкә белән.

Балалар әйтеп бетергесез шат иделәр.

Кайтуы үзе бер шатлык. Ә орденнары, киеме тагы!.. Әтиләренең солдат фуражкасы Марат белән Илдарның башларыннан төшмәде. Чиратлашып киделәр алар фуражканы. Төшкә кадәр берсе, төштән соң икенчесе. Әтиләренә тик военкоматка-мазарга барганда гына биреп тордылар. Бигрәк матур шул: өсте яшел, әйләнәсе кызыл, козырегы елтыр кара. Ә ремешогы, төймәләре!.. Тик шунсы — бераз зуррак. Әз генә селкенүгә төшеп күзне каплый. Ләкин малайлар аңысына әмәл таптылар: кырыена чүпрәк тыгып кия торган булдылар.

Әти авыл һавасында, хатын, бала-чагалары арасында, колхозчыларның солдатка булган ихтирамы эчендә

тиз тернәкләнде. Берәр атна үтүгә үзе белән алып кайткан җиләк-җимеш орлыкларын шыттырды да, карап торып, балаларыннан түтәлләргә утырттырды. Берәр ел үссеннәр дә күчереп утыртырбыз, бәрәңге бакчасына...

Мостафа абый бер ай дигәндә яхшы ук савыгып, тимерчелектә тимерче картка булышып йөри башлады:

— Ә бераздан МТС ка, Айтуган токымы!.. бер дә «о-о!» түгел. Менә күрегез дә торыгыз...

Мостафа абыйның шат йөзенә, дәртләнеп эшләп йөрүенә карап, инде моның дөньяда бер моңы да калмаган икән дияргә була иде. Ләкин, юк шул, Совинформбюро фронтта эшләр яхшырганны, Гитлер илбасарларыннан яңа шәһәр, яңа авыллар азат ителгәнне хәбәр иткән саен, аның йөзенә шатлык белән бер үк вакытта ниндидер сагыш җәелә иде:

— Оһо, ике шәһәр, нихәтле авыл!.. Ә беләсеңме, Гөлсем, алар өчен ничә мең кеше кан койган, ничәме-ничә мең кеше корбан булган?..

Ул репродукторга карый иде дә, «ике шәһәр, нихәтле авыл» өчен үзләрен корбан иткән солдатларны күз алдына китерергә тырышып, мәңгелек дан сезгә, фидакарь дуслар, мәңгелек дан, дия иде. Аннан бу турыда онытткан кебек итеп, башын ялт күтәрә иде дә, я, ярый, әйдә, булмаса, чәйләп алыйк, дип сүзне икенчегә бора иде. Бүген кемгә чалгы тапаган, кемнең урагын тешәгән, чиләген төпләп биргән, чәй янында шул турыда сөйли иде:

— Фатыйма әбинең өйалды түбәсеннән яңгыр үтә икән, иртәгә иртүк шуңа барам. Илдар, син дә әллә кая китмә әле, ямаштырып бирик инде...

Ул моны үзен тынычландыру, һәлак булган, ут эчендә йөргән фронтовиклар каршында аклану өчен сөйли. Янәсе мин дә тик ятмыйм... Ләкин тынычлана алмый. «Юк, болай ярамый, ди ул, урманнан бер кочак утын алып кайту өчен өйдә дөя асрап яткыру эше була бит бу...»

Бара-тора ул урамда күренергә дә уңайсызлана башлады. Аның артыннан, мөгаен, бөтенләй башка уй белән карап кала торганнардыр, ә ул, гаеп итеп карыйлар, дип уйлады. Көннәрдән беркөн газетада дусты Ногманның зур гына батырлыгы турында укыгач, уңайсызлануыннан кызарып китте.— «Миннән госпитальдә калган иде бит әле. Ни арада барып, әнә ниләр эшләп өлгергән!.. Юк, булмады бу...» — Мостафа абый балаларына җиләк-җимеш үрентеләрен ничек каргарга икәнен күрсәтте, озаграк

торылса, кайсын кая күчереп утыртырга икәнен әйтте дә Гөлсем апага котомкасын әзерләргә кушты.

— Китәм, Айтуган токымы!..

Бу сүз балаларны аяз көнне күк күкрәвс кебек куркытып җибәрде.— «4 айдан диден бит, әле 2 ай гына булды».— Өчесе дә кинәт боегып киттеләр. Гөлсем апа да Мостафасының бу уен күтәреп алмады:

— Сәламәтлеген дә бик чамалы бит әле синең, Мостафа. Әллә торып торасыңмы?..

— «Синнән башка да җиңәрләр әле, пристаньда чәчәк тотып каршы алырсың үзләрен»,— димәкче буласың, әйе? Юк, Гөлсем. Гомерем буе газаплаячак бу мине.

— Комиссия азат итте ич.

— Намусым азат итми, Гөлсем. Тотма әле син мине...

Ләкин район комиссиясе аны «хәзергә яраксыз» тапты. Мостафа абый «бернәрсә белмәгән тыл бюрократларын» сүкте-сүкте дә икенче көн иртүк торып котомкасын иңнәренә киеп, Казанга китте. Һәм шул китүдән кайтмады.— «Ура! Сугышабыз, Гөлсем. Балаларга әйт, бик нитмәсеннәр. Бу юлы әллә ни күп торылмас...» — дип язды ул үзенең Казаннан салган хатында. Ә фронттан язганында: «Разведкага ярамадым. Колак сынатты. Тупчы иттеләр,— диелгән иде.— Әйдә, ярар инде. Тик торганчы тиген эш диләрме әле?.. Герман җирене атабыз хәзер. Дер селкенеп тора, малай. Күзәтү пунктына менеп карасаң, ап-ачык күренә...»

Мостафа абый бик еш язды. Хаты ике-өч көн саен килеп торды. Шуңар ияләнеп беткән Илдар белән Марат, почта кызы авыл башында күренүгә, каршы йөгерә торган булдылар. Сүз куешу буенча, кем алдан барып житсә, хатны шул ачып укырга тиеш иде. Бәлки бигрәк шуның өчендер, Марат мәктәпкә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнде. Ләкин әле 7 гә яңа чыккан Марат, инде 11 тулып килгән Илдарны бер тапкыр да уза алмады, бер генә тапкыр да хатны алдан ачып уку бәхетенә ирешә алмады.

Шулай көннәрдән беркөн, почтальонга каршы йөгергәндә, Илдар, энесенең күңелен табарга теләп, юри артка калды. Җыелып торган кар суын әйләнеп үтте ул, абынып егылган булды. Ул килеп җиткәндә, Марат инде хатны почтальоннан алып ачкан, хат эчендәге кара печатьле озынча кәгазьгә: «Илдар абый, күр әле, нәрсәсе бар!» — дип гаҗәпләнеп карап тора иде.

Илдар бер карау белән эшнең нәрсәдә икәнен сизей, йөрәк өзгеч тавыш белән елап җибәрде һәм, Марат аңышканчы исенә килеп, хатны аңардан тартып алды.— «Әни белмәскә тиеш, берсе дә белмәскә тиеш... Ләкин ничек?» — Ул хәйләгә керепте: конвертны укып торган булды.— «Әй, ялгыш биргән лә, безгә түгел бу...».— дигән булып, почтальон артыннан Харисларга йөгереп кереп китте. Почта кызына: «Зөбәйдә апа, бу безгә түгел, Зөбәйдә апа, бу безгә түгел!..» — дип кычкырган булды. Ләкин Зөбәйдә ишетмәсен өчен, юри әкрен кычкырды.

Илдар ничек кенә яшерергә тырышса да, Марат этиләренә нәрсәдер булганны сизенде. Абыйсы Харислардан чыгып: «Бирдем, Татлы Чишмә Гөлсеменә икән...» — дигәч тә: «Бирмәдең, бирмәдең, укыйк...» — дип көйсезләнә башлады.

— Бирдем инде. Зөбәйдә апага...

— Бирмәдең, бирмәдең, укыйк.

Илдар Маратны бер читкә этеп җибәрде дә (ахрысы, туйганчы бер елап кайтырга уйлагандыр) кырга таба китеп барды. Ләкин анда кечкенә чаналар белән басуга соңгы тиресләрне чыгарып йөрүче пионерлар кайтып килә иде; Илдар авыл читендәге ындырга таба борылды. Марат исә абыйсының артыннан калмыйча, бертуктаусыз: «Илдар абый, укыйк, Илдар абый, укыйк»,— дип шыңшып бара бирде.

— Кит, кыйнап ташлыйм бит!

— Ташла... Түлке укыйк, Илдар абый.

Илдар энесен кочып алды. Һәм, артык түзеп тора алмады, күзләреннән ихтыярсыз яшь бәреп чыкты:

— Кара аны, әнигә әйтмәсәң генә...

— Әйтмим, Илдар абый, әйтмим.

Маратта сүз йөртү гадәте юк иде. Илдар аңа бу юлы да ышанды. Ләкин шунда ук, «ай, түзмәс, әйтеп салыр», дип куркып, «үлде» урынына «аягы яраланды» сүзләре әйтеп укыды. Укыды, ә башка вакыттагы кебек Маратка күрсәтә-күрсәтә укымады. Бу сабыйны тагы шиккә төшерде. Ул юл буе: «үзем укыйм, тотып кына карыйм...» — дип бәйләнеп кайтты.

Илдар исә:

— Иртәгә, нәнәм, хәзер караңгы инде,— дигән булды. Ә үзе, я Марат әйтеп салыр, дип, хатны әнисе йокыдан торуга үзенчә итеп язып кую турында хыялланды.

Ләкин Марат бу юлы абыйсыннан чаярак булып чык-

ты. Абыйсы йокыга китүгә, хатны аның чалбар кесәсеннән алып, коридордан төшкән ут яктысына тотып укый башлады.

«Гөлсем ханым! Илдар, Сания, Марат! Сезнең газиз ирегез, сөйгән әтиегез, бүген, 25 февральдә, Одер елгасын кичкән чакта...» — Марат, йөрәге әрнеп, «әнием!» дип кычкырып җибәрде. Ләкин тавышы, бастырылган кешенеке кебек, бугазында кысылып калды. Зал якта укытучылар белән нәрсә турындадыр сөйләшеп утырган Гөлсем апа, ишетсә дә, төшендәдер дип, игътибар итми калды. Ә кычкырган тавышка уянып киткән Илдар ишектән чыгып барган энесен тотып алды:

— Чү, кирәкми, нәнәм!

— Ә-әтием үлгә-н...

— Кирәк түгел, нәнәм, син акыллы бит...

— Түгел, түгел...

Илдар, энесен үз янына яткырып, үгетләргә кереште:

— Зинһар инде... әйтмик, нәнәм. Әйтсәк, әни бик каты елый. Җәмилнең әтисе үлгәч, Маһирә апа ничек елады, безнең әни дә шулай елый. Аннан быел да авырып имтиханын бирә алмый кала... Әйтмик, яме, нәнәм?

Марат әнисен, Маһирә апа чаклы түгел, әз генә дә елатасы килмәде. Аның имтихан бирә алмый калуын, шуның өчен борчылып йөрүен теләмәде.

— Я, Илдар абый.

Ике туган бер җан, бер тән булып кочаклаштылар да, әниләре ишетмәсен өчен, әкрен генә елый-елый, берсенберсе юата-юата йокыга талдылар.

Иртә белән (бу якшәмбе көн иде) балалар йокыдан торганда, бәхеткә каршы әниләре дә, Сания дә өйдә юк иде: Гөлсем апаны районга җыелышка чакырганнар, Санияне күрше авылдан йөреп укучы иптәшләре килеп алып киткән иде. Өйдә балаларның елый-елый шешенеп беткән күзләрен, борчулы йөзләрен күрер кеше булмады. Илдар серне мәңге саклау турында әйтеп, дәфтәр битенә ант язды һәм кул куйды:

— Инде син куй, нәнәм.

Барыннан да бигрәк, сабыйны моның романтик ягы мавыктырды. Аның йөзе хәтта бераз яктырып китте. Ул антның астына исемен сызгалады. Илдар антны лампага якын тотып киптерде дә портфель инеченә тегеп куйды.

Ә хат белән извещениене кая гына яшереп карамады ул! Кая яшерсә дә табарлар кебек иде. Берничә көн ре-

продуктор эчендә тотты. Ботинка кунычына да тыгып йөреп карады. Аннан мунча өйалларының сайгагы астына күмде. «Юк, черер». Алды да, ислемай шешәсенә салып, бер түтәл төбенә күмеп куйды.

Бара-тора беренче әрнүләр басылды. Балалар тынычлана төштеләр. Шулай да Илдар Маратны әнисе яки Сания янында ялгыз калдырырга курыкты: аны гел үзе белән алып йөрде. Кичләрен клубка кинога алып барды. Пионерлар колхозның чәчүлек бодаен чистарталар иде, анда барганда да, класслары белән көл җыярга чыкканда да үзеннән калдырмады.

Әнисе шиккә төшмәсен өчен, Маратны ияртеп, элеккечә почта кызына каршы йөгергән булды. Ә әни, нишләп хат килми икән дисә?..— Илдар үзе әтисе булып язды. «Юк, таныр...» Хатны Фәриттән яздырып карады. «Барыбер таныр...» Ә башына: «Әни почтальоннан сорашса?» дигән уй килгәч, почтальон уза торган сәгатьләрдә әнисен капкадан чыгармаска, тәрәзәгә якын китермәскә тырышып йөрде.

Ләкин хәйлә ачылды. Ике ай дигәндә Илдар, мәктәп атын җигеп, әнисен станциягә озата китте. Бу — Гөлсем апаның Казанга, былтыр авырып китү сәбәпле бирә алмый калган соңгы ике имтиханын бирергә барышы иде. Көчле буран чыгып, чана юлы күмелә язганлыктан, ат бик әкрен барды. Гөлсем апа туңа башлаган Илдарны толыбы эченә алып, атны үзе тотты.

Урманга керделәр. Әнә алан. Аланда күл. Кышын да матур ул. Кечкенә генә, түгәрәк кенә. Кыш бабай боз белән томалап, өстенә кат-кат юрган ябып киткән. Юрганы ак, бик калын, йомшак. Читендә ялгыз ак каен. Каен биек, кәүсәсе юан, ботакларына, нечкә тармакларына кар сырышкан. Гүя каен биредә тикмәгә утырмый, күлне усал күзләрдән саклый... Ә язын, кыш бабай күл өстеннән юрганнарын җыеп алгач, гөрләвекләр агып төшеп, суы ярларыннан ташып чыккач, яңгырдан соң чистарып калган күк йөзе төсле зәңгәр күл өстенә төнбоеклар төртеп чыккач, ул да җәйге киемен кияр. Башын тагын да ия төшеп, нәфис толымнарын күл өстенә салындырыр; түбәнрәк, тагын да түбәнрәк... Җил исеп киткәндә йомшак яфраклары белән инде чалмаланган төнбоекларны сирпеп-сирпеп алыр...

Илдар әтисен станциягә озата барганда әнә шулай төнбоекларны иркәләп тора иде ул каен. Тик инде «чигә-

сенә чал керә» башлаган иде. Һәм бу «чал» аны тагы да матурлап, тагы да нурландырып җибәргән иде. Илдар әтисе белән шуның төбендә утырып ял иттеләр. Әтисе Илдарга юлга дип пешерелгән кактөшне ашатты, калганын Сания белән Маратка бирерсең дип, Илдарның куенына төреп тыкты. Үзе төнбоекларны як-якка аерып кулдән куш учлап су эчте һәм имән төбенә, аның алтынланып килгән яфракларына карап сузылып ятты да җырлады. Сагышлыларын да, шаяннарын да.

Әтисе шуның белән генә калса, Илдар хәзер әнисе белән ялгыз каен янышнан бәлки тынычрак узып китәр иде. Ләкин әтисе ахырдан Илдарны күкрәгенә атландырып утыртты да, чәченнән сөя-сөя, болай дип җырлады:

«Илем өчен утка кердем, җан алмам,
Яимый чыктым мин янар таулардан.
Җаным, бәгърем, синең өчен,
Сине үстергән Илем өчен
Мин утларга керәм янадан...»

Монысы исенә төшкәч, Илдар түзмәде, башын әнисенең куенына тыгып үксеп елап җибәрде. Һәм барысын да сөйләп бирде:

— ...Әнием, ачуланма инде, әнием, без, син имтихан биреп кайткач, барыбер әйтә идек...

Гөлсем апа бер сүз дә эндәшмәде. Толыбын салып улына киертте дә, дилбегәне алып, аягүрә торып басты һәм, әллә хәсрәтен шуның белән басарга теләде, әллә поездан калырмын дип курыкты, атны җан-фәрманга куа башлады. Мәктәп конюхы сугышка киткәннән бирле мондыйны күрмәгән туры айгыр, дулый-дулый, элеп алып китте.

Аның саен куды Гөлсем апа. Болай да әйбәт барган атка кизәнде, кычкырды. Аннан Илдары янына ауды да елап җибәрде:

— Ә мин белгән идем, улым. Сезнең ант итешкәнегезне дә тыңлап тордым мин. Хатны кабат күмгәнегезне Мәһирә апаң күргән, казып алып укыдым. Аннан, йөзегезгә чыккан иде бит... Тик сезгә сиздерәсем килмәде. Сезнең миңа белдермәскә тырышып, шуның белән миңа яхшылык эшлим дип белеп юанып йөрүегезне туктатасым килмәде.

Әнә нигә күңелсезләнеп йөргән икән әни соңгы көннәрдә! Әнә нигә күз төпләре күгәреп чыккан икән! Казаннан килгән артистка концертта:

«Исән йөреп, исән кайт,
Фашистларны җиңеп кайт...»

дип җырлаганда, әнә ни өчен иреннәрен тешләп, аска карап утырган икән!..— Илдар салкын уч төбе белән энисенең борыны буйлап аккан кайнар күз яшьләрен сөртергә, юатырга керешә.

13 ШУННАН СОҢ МЕНӘ НИ БУЛДЫ

Кайгылы хәбәр килгән көнне үк Илдарда этисе өчен үч алу теләге туган иде. Энисенең күз яшьләреннән соң һәм хәбәрне иптәш кызларыннан ишеткән Сания дәрес вакытында энисе классына атылып кереп, алдына капланып елаганнан соң, Илдарда бу теләк тагы да көчәйде.— «Юк, үскәнче көтмим, быел ук китәм. Хәзер үк...» — дип хыялланды ул. Узган көз солдат-солдат уйнап йөргәндә, малайлар ферма тиреслегеннән бер берданка көпшәсе тапканнар иде. Башта малайлар миңа да миңа дип талаштылар, э яхшылабрак карагач, берсе дә алмады: күгәрә-күгәрә көпшәсе чокырлы-чакырлы булып беткән, эченә әллә нинди кортлар оялаган иде. Илдар энисен станциягә озатып куюга шул көпшәне казып алып кайтып юды, керосин белән чистартты, приклад эмәлләп куйды. Чакмасы сынган иде, анысын Василий дәдә ясап бирде. Хәтта көпшә очын тигезләп мушка да эретеп куйды:

— Ләкин кара аны, атма, атарга ярый торган түгел, ярыла.

— Юк-юк. Солдат-солдат уйнарга кирәк ул безгә...— дип ялганлады Илдар.

Шул көнне Фәрит этисенең бер патронын урлап алып чыкты. Ярый әле күзгә-башка тимәде, берданка атуга ярылып китеп, Илдарның уч төбен чәрдәкләде, Фәритнең өске иренендә мәңгелек җөй ясап калдырды.

— Ә мин барыбер китәм...

Илдар моны кешеләр үзен күтәреп алып арбага салганда әйтте. Ай буена больницада ятканнан соң, инде ике атнадан гипсыңны алабыз дигән хирургка да шулай диде Илдар.

— Аныси үзеннән-үзе билгеле,— дип көлде хирург.— Ләкин шундый сорау туа. Кая һәм кайчан?

— Әти сугышкан җиргә, билгеле, Германиягә. Кулым тезәлгәч тә.

Хирург тагын көлде:

— Алайса, без синең белән соңга калдык, дустым. Хәзер газета кертерләр, укырсың. Сугыш Берлин бистәләрендә бара бүген. Так что, иртәгә, берсекөнгә Гитлер җәһәннәм поход пошел!

Хирургның сүзләре раска килде. Илдар больницадан чыгып авылга кайтып кергәндә, олысы-кечесе Гитлер яуларын җиңеп кайтучыларны каршыларга чыккан, кулларында чәчәкләр, күзләрендә шатлык яшьләре иде.

Менә солдатлар арасыннан бер солдат аерылып чыкты да читән буеннан боегып карап торган Илдарлар янына таба килә башлады. Башы ак белән бәйләнгән иде аның; кояш яхшы ук кыздыруга карамастан, чырае көл кебек, йөзендә әз генә дә кан әсәре сизелми; шулай да күмер-кара күзләре шат елмая иде. Ул килеп җитәр-җитмәс туктады да:

— Я, Айтуган токымы, әллә Ногман солдатны танымадыгызмы? Иһи-и, се-ез...— дип сүзды.

Кара, бу шул ич! Ягедпидә торганда килеп киткән, күчтәнәчкә чикләвек алып килгән солдат ич, әтиләренең фронтташ дусты ич!.. Балаларга бераз күңелле булып китте. Алар, Ногман абыйны үз күреп, хәзер сырып алдылар һәм, әйберләрен күтәрешеп, өйгә алып кайттылар.

Әтиләре үлгәндә ул шунда булган икән; әтиләре аңар, исән-сау кайтсаң, безнекеләрне күр, соңгы сәламемне тапшыр, дигән икән. Ногман абый хәзер өенә кайтып барган җиреннән шуның өчен пароходтан төшеп калган икән... Солдат бу турыда өстен чишенеп, юл тузаннарын юып, болдыр баскычына килеп утырып, Марат белән Саниягә тезләренә алгач сөйләде. Балалар ул сөйләгәндә күчтәнәч конфетларын учларында кысып, тын гына утырдылар. Илдар исә, яңа гына гипстан чыккан кулын сәламәт кулы белән тоткан хәлдә, олыларча җитди күзләре белән Ногман абыйга карап, каршында басып торды.

Солдат ахырда болай диде:

— Нәрсә әйтергә, күңелле булмады, гүзәлләрем... Үз кулым белән күмеп калдырдым, немец җирендә... Лә-

кин, сез бу кайгы турында уйлаганда менә нәрсәне онытмагыз: сезнең әтиегез сугыш кырында, изге көрәш юлында үлде. Сезнең һәм сезнең кебек миллион-миллион Марат, Сания, Илдарларның якты көннәрен караңгы төн итәргә килгән Гитлер яуларын тар-мар итеп үлде әтиегез. Шуңа күрә әтиегезнең — фидакарь совет солдатының — исеме олысының-кечесенең йөрәгенә тирән кереп урнашты, бу исем буыннан буынга, телдән телгә күчеп мәңге-мәңге яшәр. Шуны хис итү сезнең авыр кайгыгызны җиңеләйтсен, гүзәлләрем.

Солдат балаларның өчесен дә бер-бер артлы күтәреп үпте дә, бик арыган иде ахрысы, яңадан баскычка утырды.

— Ватанга турылыклы булып үсегез, дусларым, яхшы укыгыз. Бу сезнең сөйгән әтиегез өчен иң, иң зур һәйкәл булыр.

Өченче кисәк

1

ГАДӘТТӘН ТЫШ ВАКЫЙГА

Үзенең ыгы-зыгысы, мәшәкатьләре белән сигез ел гомер үтеп китте. Кайгы-хәсрәтләрне шатлык алмаштырды. Маратны кайчандыр агач атка атланып авылга барырга чыккан Марат димәссең хәзер; тәмам буйга җитеп бетте. 16 яше тулып килә. Икенче ел инде, электроэнергия техникумында укый. Ә Илдарны әйтәсе дә юк — егетнең егете! Комбайнчылар курсын бетереп чыкты; быел җәен үзйөрешле комбайн штурвалына басарга тиеш. Сания дә теләгенә иреште: фермада эшли. Мөдир итәрләр ахрысы, эшен бик яраталар. Гөлсем апа балалары өчен сөенеп туя алмый. Ләкин күтәргесез авыр кайгы басты аны, ә шулай да җиңә алмады. Шомырт кара толымнары әүвәлгечә бер чалсыз калды, күзләре әүвәлгечә яшь калды. Тик менә аяк басуларында гына элекке дәрт юк. Ерак-ерак юлдан авылына кайтып килгән юлчы кебегрәк атлый.

Семья эчендә туганлык ягына, бер-берсенә мәхәббәт мәсьәләсенә килгәндә, ул кадәресе әтиләре үлгәннән бирле тагы да көчәйде. Марат хәзер дә семьяда иң сөекле бала. Төпчек дип, гел иркәләп кенә торалар үзен. Әле берсе, әле икенчесе Казанга барып хәлен белеп кайта. Каникул җиттеме, көне-сәгате белән үзе кайтып килә:

— Сагындым, әнием, бик сагындым,— ди ул, әнисен үбә-үбә.

— Ә мин сагынмадым, бер дә...— ди Гөлсем апа, шаяртып һәм кочып ала да елый, елый... Көзләр җитеп, пристаньга озатып куйганда да елый Гөлсем апа. Кайгыдан түгел, әлбәттә, шатлыктан. Улының, улларының

киләчәкләрен, гомер юлларын күреп шатлануы бу аның. Ә гомер юллары якты, киң, иркен, моңар кадәр беркем дә яшәмәгәнчә күңелле... Мина шуларны әйтергә дә пәрдәне төшерергә иде. Һәм, әгәр 1953 елның язында гадәттән тыш бер вакыйга килеп чыкмаган булса, мин шулай иткән дә булыр идем.

Бу вакыйга Казан шәһәренең Максим Горький исемендәге культура-ял паркында башланды. Ул елны анда техника мәктәпләрендә укучы һәвәскәр художникларның иҗатларыннан зур гына күргәзмә оештырылган иде.

Соң иде инде. Караңгы төшеп килә. Җитмәсә, җил чыкты, янгыр сибәләргә тора. Яшь художниклар стендлардагы рәсемнәрне җыярга керештеләр. Шул чак күргәзмә янына бер кеше килеп туктады. Әллә кыяфәте шундый тәэсир итә торган булды (кара эшләпәсе читеннән ак чәчләре күренеп тора, мыегы да ап-ак, ә үзе бер дә картлар кебек түгел: гәүдәсе гаскәриләрчә төз, йөреше җиңел, өсте-башы бик пөхтә иде), әллә исәнләшүе тәэсир итте («исәнмесез, яшь бөркетләр!» — диде дә кулын йодрыклап югары күтәрде), балалар рәсемнәрне җыюдан туктап калдылар. Аның: «Җыегыз, җый, мин хәзер китәм»,— диюенә каршы: «Юк, карагыз, абый, рәхәтләнеп карагыз...» — диештеләр.

Ләкин кеше, балаларның ашыкканнарын күреп, бер рәсем янында да тукталып тормады, нәрсәдер эзләгән кебек, күзләрен йөгертеп кенә үтте: «Әйбәт. Яхшы. Оһо! Ярый торган...» — Иң кырый рәсем яныннан да шулай бер сүз белән генә үтеп китте ул. Ләкин, кинәт нәрсәдер исенә төшеп, бу рәсем янына кире борылып килде һәм торган саен әсәрләнә барды.

Бу кешене әсәрләндергән рәсем — рәсем буларак, бер дә искитәрлек түгел иде: көймә, бер кеше ишкәк ишә, күк ленталы бер кызчык койрык тота, яшь кенә хатын-кыз гитара уйный, ә кечкенә генә ир бала, түше белән көймә кырыена ятып, кулын суга тыгып бара. Бик гади картина. Шул ук вакытта ясалышының да шаккатар урыны юк. Һәрхәлдә, аның авторы турында: «Сәләтле күренә, художник булыр бу»,— диярлек түгел иде. Шуңардыр инде, бу рәсем иң кырый стендның иң кырый бер җиренә урнаштырылган иде.

Ә нигә шулай исе китте соң эшләпәле кешенең бу рәсемгә? Ни дип шаккатты? Ул көймәдәгеләргә шундый

итеп карый, әйтерсең, аларның барысын берьюлы кочып алырга җыена иде.

Кеше карады-карады да яхшы ук дулкынланып әйтеп куйды:

— Ә бит чыннан да охшаган!..

Һәм, аптырый калган балалардан уңайсызланып, үз-үзенә сөйләнде:

«Дөрес, кыяфәтләребезне охшаткан дип әйтеп булмый. Шулай да... Моны Мәрьям диярга була. Хәтерлим, аның да башында салам эшләпә иде, ул да чәч толымнарын шулай түшенә салган иде. Кара, хәтта гитарасы да бар ич! Ә менә монысы абый булырга тиеш иде, э биредә ниндидер кыз бала. Мине дә охшата алмаган. Аның каравы кепка минеке! Галстук та... Ә Марат! Марат нәкъ-нәкъ үзе инде! Ул да көймә кырыена күкрәге белән нәкъ шулай ятып, кулын суга тыгып барган иде бит...»

Кеше трубка кабызырга дип сызган шырпысын, рәсемгә якын тотып, имзага бераз карап торгач, тагы да әсәрләнә төште. Имза «М» хәрефе, тагын «А» га башланган ниндидер фамилиядән гыйбарәт булып, танырлык түгел, бик боргалап язылган иде. Кеше, дулкынланганын яшерә алмыйча, калтыранган кулындагы трубка сабын фамилиягә төртеп:

— Моны ни дип укырга? — дип сорады.

— Айтуганов.

— Һем-м... Кеше кинәт күңелсезләнеп китте. Ә бераздан, инде бик үк исе китмичә генә, трубка сабын «М» хәрефенә төртте:

— Ә моны?

— Марат.

— Марат?

Кеше, кыргый бер шатлану белән шатланып, шул ук вакытта күзләрен сәер йөртеп, арадан Маратны төсмерләргә тырышкан кебек итеп:

— Ә кайсыгыз ул Марат? — диде.

Аны, тавышына карап, яхшы ният белән сораша дип әйтерлек түгел иде. Ул «әйтегез, юньсезләр, бумажнигымны кайсыгыз чәлде?!» дигән кебек шомлы итеп сорады. Балалар шикләнә калдылар. Һәм шунда ук, бу сәер кешенең йөзе яктыра барганны күреп, тынычлана төштеләр:

— Без түгел. Тулай торакта ул. Электроэнергия техникумының тулай торагында.

Бер сәгатьтән кеше тулай торакта иде инде. Өч кроватьлы кечерәк кенә бүлмәдә ялгызы йоклап яткан үсмернең уянганын көтеп, шул ук вакытта аны танырга тырышып карап тора иде. Үсмер уяныр күзләрен ачуга, кеше үзе дә сизмәстән идәнгә тезләнеп:

— Син кем, Маратмы? — дип сорады.

Авыру бала янына кем килсен? Врачтыр... Үсмер, бик гади генә итеп:

— Марат,— диде.

Кеше өчен Маратның бердәнбер күнелле җавабы да шул булды. Нинди генә сораулар биреп караса да, ничек кенә итеп төпченсә дә, шуннан башка җанга җылы сүз ишетә алмады.

— Түгел, элек Казанда тордык, Ягеднидә. Юк, гел, гел Ягеднидә... Әни, кишләп үлсен, исән. Укытучы... Менә инде, үз этиемне хәтерләмәскә!.. Яраланып кайтканын да, яңадан киткәнен дә хәтерлим... Әни белән пристаньга хәтле озатып куйдык...

Кеше, Маратны калдырып, техникум канцеляриясенә менде. Сорашты, документларын алып карады. Әлбәттә, һичберсеннән үзе теләгән җавапны таба алмады. Һәм, тәмам өметеп өзеп, төшеп китте. «СССРда Марат исемле малай бер генә булырга тиеш димәгән ич...» — диде ул үзенә үзе. Һәм шунда ук: «Ә шулай да рәсем, күргәзмәдәге рәсем..» — дип баскычта туктап калды. Уйлап-уйлап торды да яңадан Марат янына керде:

— Әйт әле, сөеклем,— диде ул.— Нәкъ шундый рәсем ясау синең башыңа каян килде? Нигә син, мәсәлән, авылыгызның берәр матур күренешен ясамадың?

— «Нәрсә кирәк икән соң бу сәер кешегә миннән? Ни дип шулай төпченә ул?» — диде Марат, ачуы килеп. Ләкин кешегә бу турыда әз генә дә сиздермичә, гади генә итеп:

— Нигә, бу да матур ич, абый,— диде һәм, кешенең җаваптан канәгать түгел икәнен күреп, өстәп куйды: — Бу минем сабый чак истәлегем...

— Ничек, ничек?

Марат кабатлады һәм үзенең тумбочкасы өстендәге альбомнан күргәзмәдәге рәсемнең копиясен алып күрсәтте:

— Менә монысы әнием, монысы Сания апа, менә мин... Дүртенчебезне үзем дә белмим. Вакыты буенча, Илдар абый булырга тиеш, ә исемдә этием кебек калган. Шуңар күрә мин аны берсенә дә охшатмыйча ясадым.

— Ә бу кай җир соң, Марат?

— Аккош күле.

— Ленинград, Нева буе түгелме?

— А-а, безнең анда барганыбыз да юк әле.

— Кызык. Әйт әле, сөеклем, көймәдә йөрдегез, йөрдегез дә, аннары нишләдегез? Хәтереңдә калмаганмы?

— Калган. Илдар абый (әллә эти булды инде) су коенды.

— Я, я шуннан?

— Кырда йөрдек. Ә яңгыр яуганда, урман каравылчысы өенә кереп тордык.

Кеше хәзер ахыр чиктә дулкынланып, Маратны кочып алыр дәрәҗәгә килде:

— Сез анда уха пешереп ашадыгыз, аннары мороженое, шулай бит?

— Юк. Бәрәңге белән селедка. Илдар абый (әллә эти булды инде), селедканы ипи белән ашыйлар инде аны, дигән иде, әнием, көңелсезләнеп, әй, балалар, балалар, диде. Безнең ипиебез юк иде. Аннары каравылчы бабай безгә чәй эчерде.

— Һем-м... Ә каравылчы өennән чыккач, чәчәкләр җыеп йөрмәдегезме?

— Йөрдек.

— Ә яңгыр туктамагач, пароходка утырып, көймәгезне койрыкка тагып кайттыгыз, шулай бит?

— А-а, Аккош күлендә пароход йөрми дә әле.

«Һичнәрсә аңламыйм, һичнәрсә!»— Кеше трубкасын төя-төя тәмәке тутырды да ачык форточка янына килеп кабызды.

Шул чакта бер студент, йөгереп кереп, Марат янына киндер белән тышланган кечкенә генә ящик китереп куйды.

— Көчкә, малай. Бирми генә бит... Ярый, мин киттем. Теләктә тор. Җиңеп кайтсам, кичке чәйгә миннән йөз грамм хәлвә! — диде студент.

Ул ят кешене ишектән чыгып барганда гына күреп алды, һәм уңайсызлана калып, исәнмесез, диде дә аның җавабын да көтмәстән, кергәндәге кебек үк кабаланып чыгып китте:

— Дежурныйга әйттем, ужиныңны Агаҗан кертеп бирер.— Бу сүзләрне әйткәндә инде студент пиджак җиңен кия-кия коридор буйлап йөгерә иде.

— Минем урынга вратарь булып бара,— диде Марат, үкенечле итеп.— Тренировка вакытында аякны биртәйттем... Ә бу — посылка. Әнигә. Кара җимеш белән бераз өрек. Туган көненә дип җибәрүем иде дә, кире алдырдым әле. Эченә карточкамны салган идем, бик ябык чыккан. Я авырганны сизәр. Сизсә, елый башлый ул, и берәрсен хәл белергә җибәрми калмый, я үзе килеп житә...— диде Марат һәм урыныннан торырга омтылып терсәкләренә таяна башлады, кеше аны шунда ук туктатты:

— Ят, ят. Сиңа ярамый. Хәзер үзем алып бирәм.

Ул Маратка графиннан су салып эчерде һәм, тәмәке төтенен ике куллап куа-куа, тагын форточка янына килде.

Җәйге жылы яңгырдан соң чистарып калган күк йөзендә бер-бер артлы алтын йолдызлар калка; күктә айның тулысы, бик яктысы иде. Ят кеше форточкадан кулын сузып карады да тәрәзәне төбенә тикле ачып куйды. Бүлмәгә бераз дымлы саф һава, өй түрендәге карт юкәнең хуш исе бәреп керде. Бер үк вакытта төн күбәләкләре кереп түшәмдәге зур, бик якты лампочка әйләнәли очып йөри башладылар. Кеше лампочканы сүндерде дә яшел абажурлы өстәл лампасын кабызды. Марат, терсәгенә таянып, урамга, юылган асфальтка, инде зонтикларын җыеп култыкларына кыстырган хәлдә узып барган кешеләргә карады. Кеше бу юлы Маратны ятарга кыстамады, мендәрен кровать рәшәткәсенә иплән куйды да шуңа сөяп утыртты, һәм Мараттан күзен алмыйча, пыш-пыш трубкасын тарта башлады.

— Һичнәрсә аңламыйм,— дип кабатлады ул.— Һичнәрсә аңламыйм...

Укучым төшенгәндер, Марат ике вакыйганы: әтиәниләре белән Ленинградта, Нева суында көймәдә йөргәнен һәм Илдарлар белән Аккош күлендә йөргәнен бутый, күргәзмәгә куйган рәсеме дә шуңа күрә бутап эшләнгән иде. Кеше исә, Маратны, нәкъ без белгән Маратны эзли иде. Ә Маратны кемнең эзләве мөмкин? Аккош күлендә түгел, Нева суында көймәдә йөргән Маратны кемнең эзләве мөмкин? Билгеле инде: яки әтисе, яки әтисенең Касимоводагы абыйсы. Алайса, бу

соңгысы булып чыктымыни инде? Энесенең ятим калган улын үзенә ул итәргә исәп итте микәнни? Бик мөмкин. Туганлык хисе шулай бер булмаса, бер ташып чыга бит ул. Ләкин, бу ул түгел, этисенең абыйсы түгел, бу Маратның үз этисе иде.

Кара, ул сугышта үлгән ич. Юк шул, үлмәгән икән. Ә теге кара печатьле озынча кәгазь?..

2 МАРАТНЫҢ ӘТИСЕ

Маратның әтисе — Искәндәр Зәбирович Алпаров сугышта да инженер булып хезмәт итте. Дзотлар, дотлар төзеде, кирәк икән — җимерде, тагын төзеде. Эшен яраталар, барысы да әйбәт кенә бара иде, берничә тапкыр мина давылы, көчле артиллерия уты астына туры килсә дә, исән калган иде ул. Көннәрдән беркөн менә нинди зур бәхетсезлеккә дучар булды.

Өч иптәше белән урман аша кайтып килә иде. Төн. Караңгы. Күктә ай юк. Йолдызлар һәм яңа яуган кар гына бераз яктылык бирә. Менә каршыда өч кеше күренде. Әллә каян күренеп тора — немецлар. Разведчик булсалар кирәк. Искәндәр һәм аның иптәшләре, искәрмәстән килеп чыгып, тегеләрне плен алу нияте белән, агач артларына постылар. Ләкин баштагы өч — тозак булган икән! Искәндәрләр һөҗүм итүгә, куак төпләреннән тагын унлап немец килеп чыкты:

— Бирел, рус!

Дүрт совет солдаты дистәдән артык фашист белән сугышка керде. Бер, тагын бер иптәш һәлак булды. Искәндәр үзе дә авыр яраланып егылды... Күпме вакыт үткәндер, һушына килеп, күзләрен ачып җибәргәндә ул инде керосин лампасы белән яктыртылган тәбәнәк, тынчу бер бүлмәдә ята, ярасы бәйләнгән иде.

Менә кемдер русча, саф рус телендә:

— О-о, хәерле иртә, коллега!..— дип эндәште.

«Үзебезнең җир икән ич!..» — Искәндәр, тирән шатланып, яралы башын тавыш килгән якка борып карады. Ләкин анда рус кешесе түгел, башын учына салып, авыз читен мәсхәрәле кыйшайтып, ялтырап торган җирән чәчле бер немец офицеры утыра иде.

Искәндәр карады да катты. Таныш кеше. Ә кем? — Искәндәр ни караса да исенә төшерә алмады. Ә немец башын күтәрә төшеп:

— Хәтерегез бик кыска икән, ничек тиз оныткансыз...— дип сөйләнә башлагач, Искәндәр кабат һушыннан язарга житте һәм, дулкынланганын яшерергә теләп, күзләрен йомды.

«Плен төшүем генә житмәгән, әнә кем кулына килеп эләккәнмен бит!..» — диде ул үзенә үзе һәм, күз ачып йомганчы, үзенең үкенечле ялгышын хәтереннән кичерде. 1941 нче ел иде. Май бәйрәме .Искәндәрләрдә кунак. Тагын бер генә пар киләсе калган: Шабалин һәм хатыны. Менә алар да капка төбендә машинадан төшә. Яннарында бер ят кеше дә бар.

— Таныш булыгыз. Инженер Дипит Драйпе Каунастан. Бездә командировкада. Минем кунагым. Хужаларның күнелләре киң икәнне яхшы белгәнгә...

— Узыгыз, уз... Менә тагын, сүз түгел... Яшь совет иленнән килгән кунакка бездә урын иң түрдән.

Инженер белән инженер беренче рюмкадан соң ук уртак тел табалар. Кунак безнең әдәбият, сәнгать, бигрәк тә фән һәм техника яналыклары белән кызыксына. Табигый кызыксыну! Ләкин, соңыннан билгеле булганча, ана, сугыш башланыр алдыннан безнен илгә Германиядән жибәрелгән шпионга, гомумән безнен фән һәм техника түгел, Искәндәр эшли торган яңа хәрби завод кына кирәк була: кайда ул, нәрсә эшли, күпме эшли? Билгеле, ул Искәндәргә турыдан-туры шундый сорау бирми, үзе юкта килеп, хатыныннан яки күршекоданнан да сорашып йөрми, артыннан күзәтеп заводына да бармый. Кыскасы, шиккә төшерерлек бер адым да атламый ул. Киресенчә, гел сизгерлек турында сөйләнә һәм моны ул үз биографиясенә бәйләп сөйли — «Әти зур стажлы революционер иде. Очраклы бер кеше алдында чишелеп китүе аркасында харап булды. Аттылар...» — ди.

Бик мөмкин. Ләкин нишләп һәр кич миндә ул? Нигә, мәсәлән, шул ук Шабалинда түгел? — Үзендә шундый шик тугач, Искәндәр Драйпены сынап карарга була. Якшәмбегә каршы төндә, янгырга сылтау итеп, кунак Искәндәрдә кунарга кала. Искәндәр аны яткыра да үзе төн буе чертежларга күмелеп эшләп утыра. Күрше бүлмәдә Марат уянып көйсезләнә башлагач кына торып чыга ул. Шул арада Драйпе, «йоклап» яткан жиреннән ялт торып, Искәндәрнең күрше бүлмәдә Маратны юатканына колак салган хәлдә, чертежларны бер-бер артлы

фотога төшереп ала, ә Искәндәр кергәндә ул инде, әйтерсең, кузгалып та бакмаган, әүвәлгечә изелеп «йоклый». Искәндәр, Маратны көйләп кергәч, янәдән эшенә чума. Юк, чуммый, ул бая да юри генә эшләгән булып утырды,— чертежларын күзәтә: кузгалганмы, юкмы? Итәк-җиңең җыеп йөрергә өйрәнгән шпион шулкадәр сак эш иткән була, әйтерсең, ул аларга орынмаган да; фотога төшереп алгач, барысын да элеккечә тезеп куя. Бер генә урында бу төгәллеккә саклый алмый кала ул: линейканың очын менә бу сызыкка тидереп куя. Ә Искәндәр аны тидерер-тидермәс калдырган иде. Хәзер мәсьәлә ачык: кунак торган, чертежлар янында булган. Ә бәлки фотога төшереп алырга өлгермәгәндер? Ул кадәресе барыбер: төшерде ни дә, төшермәде ни. Чертежлар бөтен дөньяга билгеле бер хәрби заводныкы. Искәндәрнең аларны калдырып чыгуы да «кунак»ны сынау өчен бер хәйлә генә була.

Сынау шома уза. Ләкин Искәндәр бер урында бик нык ялгыша: иртә белән «кунагын» чәй эчереп озаткач та НКВДга йөгерәсе урында, заводка, директорына әйтергә китә. Ә директор киңәше белән НКВДга хәбәр итеп, аннан гостиницага, шпионның номерына агентлар килгәндә, соң була инде. Шпион ачык авызлардан булмый. Ул, номерына кайтып фотолентасын проявить итеп укып каравына, үзенең тозак эчендә икәнен аңлап алып, минут тормый, юкка чыга.

— Ә сез Драйпе белән ничек таныш? — дип сорыйлар аны Май бәйрәмендә Искәндәрләргә кунакка алып килгән кешедән, Шабалиннан.

— Ул безнең фабрикада командировкада иде. Стахановчылык хәрәкәте белән танышып йөрде.

...Тәне марля белән уралып беткән Искәндәр каршында хәзер әнә шул кеше, Ленинградта Драйпе фамилиясе белән йөргән немец шпионы утыра иде. Ул башын учыннан алды да:

— Ә беләсезме, сез үзегезнең сизгерлегегез белән минем эшне нәкъ ярты елга кичектердегез,— диде.— Мин сезне сугышның беренче көннәреннән бирле эзләдем. «Патриот. Әлбәттә, тылда ятмас...» Һәм ялгышмадым. Разведка бер ай дигәндә сезнең кайсы частьта, нинди эштә икәнлегегезне хәбәр итте. Берничә тапкыр ятьмә салып карадым — эләкмәдегез. Ниһаять, менә бүген... Бер сүз белән әйткәндә: выкладывайте! Электрич-

ка белән 4 сәгать баргач, Пирей станциясендә төшәсең дә урманга борылып керәсең. Бу кадәресе безгә билгеле. Аннан өч юлның кайсы белән китәргә, күпме китәргә?.. Кыскасы, сез безгә заводыгызның төгәл координатын эшләп бирегез. Бүген кич үк безнең егетләр барып бомбага тотарлар. Ә сәламәтләнә төшкәч, заводыгыз эшләп чыгара торган продукциянең чертежын... ләкин, карагыз аны, алдашмыйча гына...

Офицер, сүнгән сигарасын кабызды да, сүзен дәвам итте:

— Мин аңлыйм, сез совет командованиесеннән куркасыз. Ләкин юкка. Сез үлгән саналасыз...

— Ничек үлгән?

— Шулай. Минем егетләр гранатадан өзгәләнгән бер солдатны, сезнең киемнәргә киендереп, шәхси әйберләрегезне, документларыгызны кесәсенә салып, урманга, үлеп яткан өч иптәшегез янына илтеп ташладылар. Миңа мәгълүм булганча, совет санитарлары «сезнең» гәүдәне өч иптәшегез белән бергә алып кайтып күмделәр дә инде, ә частегыз кызыл кара белән сезне исемлектән сызып ташлады...

Немец үлеп яткан «Искәндәрнең» фоторәсемен өстәл тартмасыннан алып күрсәтте.

— Я әйтегез, моның кай жире сез түгел? Бер сүз белән әйткәндә, иблис үзе дә шикләнмәс иде, ха-ха-ха...

...Маратның этисе әнә шулай «үлә».

Ул немецка бер сүз дә әйтми. «Шул урманда дөрестән дә үлеп калган булсам, яхшырак буласы икән,— ди ул үзенә үзе,— инде бу елан мине кабергә кергәнче газаплаячак...»

Һәм офицер Искәндәрне газаплый... Башта ул аны кызыктырып бага. Өстәл тартмасыннан Франц Мюллер исеменә язылган немец паспорты чыгарып сала да:

— Фотокарточкагызны гына ябыштырасы калган. Борчылмагыз, аңысы иртәгә эшләнер...— ди.— Ә Ленинград бирелгәч тә, хатыныгыз белән балагызны алып килербез. Аларга да паспорт һәм яңа исемнәр табылыр... Фрау Зитте. Әйбәт бит? Ә малаегызга — Фриц, ә! Ха-ха-ха...

Искәндәр үз уйлары белән мәшгуль. Ул үзен сүгә: «Нигә мин иртүк НКВДга йөгермәдем? Тиле мин, тиле...» — ди.

Искәндәр дәшми торгач, риза булды дип уйлап, офицер шул ук өстәл тартмасыннан аның алдына бик матур бер имение рәсеме чыгарып сала:

— Ә монысы сезгә билгеләнгән бүләк. Фрау Зитте килгәч, барып карарсыз, ошамаса, башканы да күрсәтергә була,— ди.

Искәндәр, әлбәттә, баш тарта. Һәм шул сәгатьтән күз күрмәгән, колак ишетмәгән газаплауларга дучар була.

— Мине үтергәнче газапларга мөмкин...— ди Искәндәр,— ләкин шуның белән буйсындырырга, совет кешесен буйсындырырга уйлыйсыз икән, ялгышасыз. Зоя Космодемьянскаяны, Лиза Чайкиналарны хәтерләгез. Без барыбыз да әнә шундый...

— Ах, шундыймыни? — ди немец, көлеп.— Ул чакта без җәзаның икенче төрләрен дә беләбез, хәтта иблиснең үзен дә буйсындырырлыгын... Бүген иртән сәгать нәкъ 6 да Ленинград бирелде. Иртәгә Зитте ханым минем сөяркәм булачак, улыгыз минем дуңгызларымны көтәчәк. Ә үзегез мәңгелек каторга хезмәтенә хөкем ителәчәксез...

Шул чакта офицерның денщигы бүлмәгә кечерәк кенә форматлы бер газет кертеп чыга. Офицер газетның беренче битенә тиз-тиз генә күз йөртеп ала да Искәндәргә бирә. Искәндәр газетны кулына алуга таный. Ленинград фронты армиясенең политуправление органы. Анда чыннан да бүген иртән сәгать 6 да Гитлер гаскәренең Ленинград шәһәренә басып керүе турында хәбәр ителгән.

Шунысы аяныч, Искәндәр моның немец типографиясендә басылган бер уйдырма икәненә төшенми. Укып бетерер-бетермәстән, үзен-үзе тотып тора алмыйча диванга ава.

— Я, инде ни әйтерсең, совет кешесе?

Искәндәр, сөйгән Ленинградын, Мәрьяме белән Маратын Гитлер итек астында күз алдына китереп, йөрәге әрнүенә түзә алмыйча, күзләрен йома.

— Я, совет кешесе...

— Бөтен дөньяны басып алсагыз да, минем сезгә хезмәт итәсем юк.

Искәндәрне, канга батырганчы кыйнап, концентрация лагерена, үзе шикелле «кире беткән» бернчә

совет солдаты янына илтеп ташлыйлар. Аякка баекач, каторга хезмәте, газаплау, ачлы-туклы тотулар...

Шул рәвешчә, бер, ике, өч ел үтеп китә. 29 яшьлек ирнең чәче, сакал-мыегы агара, күзләре эчкә бата, битен җыерчык баса. Ләкин ул өметен өзми.— «Юк, болай бетмәскә тиеш»,— ди ул иптәшләренә. Һәм чыннан да, иртәләрдән бер иртәдә аны сугыш гөрелтесе уята. Ул да түгел, урамда башларына карт хатыннар киеп йөри торган кара берет кигән инглиз солдатлары күренә башлый.

— Яшәсен союздаш дуслар! — дип кычкыра Искәндәр төрмә тәрәзәсе аша.— Ура-а!..

Гаскәр керә дә керә. Ә нигә төрмә ишекләрен ватмыйлар инде? Нигә иреккә чыгармыйлар?..

Төнгә каршы ишек алдына бөркәүле кара машиналар кереп тула. Искәндәрләрне, менә сиңа кирәк булса, шул машиналарга төяп, Бонн шәһәренә күчерәләр.

Дөрес, анда Берлиндагы кебек газапламыйлар. Яхшы ашаталар, төрмәсе дә чиста, урын-җире дә әйбәт кенә була. Бераз ял итеп алгач та, Искәндәрне инглиз чиновнигы кабинетына чакырып кертәләр.

— О'Кей! Җиңү белән тәбрик итәм, дустым!

— Сезне дә шулай ук, хөрмәтле капитан.

Капитанның денщигы шунда ук поднос белән эчемлек һәм закускалар кертеп чыга. Җиңү хөрмәтенә Искәндәр баш тартмый. Ахыр чиктә йончыган, бик ябыккан була ул бу вакытта, бер рюмка эчүгә исерә кала. Шул чак чиновник аның алдына кечерәк кенә бер карта җәеп сала:

— Инде сайлагыз, дустым? Сезне кайсы ил үзенә күбрәк тарта?

Искәндәр сорауны аңламый.

— Ягъни кайсы яктан?

Чиновник ачыклап бирә:

— Кайсы илгә китеп урнашырга теләр идегез?

— Үз илемә, билгеле.

— Ялгышмасам, бу картада сезнең ил юк.

— Картада булмаса, җир йөзендә бардыр ич, хөрмәтле капитан?

— О-о, әйе, әйе, җир йөзендә...— дип мыгырдана чиновник.— Ләкин, шунысын яхшы аңлагыз, коллега, сезнең өчен артка юл юк. Бетте, киселде. Мәңгегә...

Чиновник моны, тупас булмаса да, шундый кискен итеп әйтә, Искәндәр бәхәсләшеп торырга урын калмаганны төшенә.

Ләкин бирәдә ниндидер аңлашылмау булырга тиеш. Ничек инде союздаш ил вәкиле совет солдатына шундый вәхшилек эшләсен! Әлбәттә шулай: инглиз түгел, немец бу. Союздаш армияләр килеп җитмәгән әле. Бу— фашистларның чираттагы бер шантажы!..

Кинәт айнып киткән Искәндәр сикереп торып:

— Сез инглизләр түгел. Сез моның белән инглизләрне, безнең союздаш дусларыбызны хурлыйсыз. Мин протест белдерәм! — дип кычкыра.

— О-о, әйе, протест... протест...— Чиновник, үткән көннәрнең мәгънәсез һәм үкенечле бер вакыйгасы исенә төшкәндәге кебек итеп, авызын кыйшайтып елмая да, кинәт җитдиләнеп, хәрбиләрчә атлап килеп тәрәзә шторасын күтәрә. Анда, урам тутырып, инглиз гаскәрләре узып бара, ачык машиналарда арлы-бирле олы чиновниклар йөреп тора.

— О'Кей, бәлки болар да инглиз түгелдер?

Искәндәрнең кулындагы колбасалы чәнечке идәнгә төшеп китә. Күз аллары караңгылана аның, тыны кысыла.

— Ул чакта сезгә мең нәләт! Ләкин белегез, мин үлгәнче илемә кайту өчен көрәшәчәкмен.

— О-о, әйе, әйе. Рус характеры... Ләкин хакыйкать шундый: корыч та сына, дустым.

Әйе, корыч сына, ләкин Искәндәрне сындыра алмыйлар. Немецтагы кыйнау, куркытулар бирәдә дә кабатлана. Иң кыены шул — башка тоткыннардан аерып, ялгызлык белән газаплыйлар. Прогулкага чыгармыйлар, ашарына да ишектән кул сузып кына бирәләр. Искәндәр хәзер көннәрнең исәбен ашау буенча гына чамалый. Аныңча бер атна дигәндә, аны тагын шул ук чиновник чакыртып ала. Бу юлы кабинетта америкалы, француз һәм инглизләрдән берничә журналист һәм фоторепортер да була. Барысы да Искәндәрне баш иеп, елмаеп каршы алалар:

— Рәхим итегез, коллега.

Искәндәр йомшак креслога килеп утыра. Чиновник аның алдына, түгәрәк өстәлгә, машинкада басылган бер бит кәгазь чыгарып сала.

— Башта укыгыз.

Искәндәр шунда гына белә: күзләре начарланган икән. Аңар берсе күзлеген салып бирә, ярдәм итми, өченчесенекен киеп карагач кына, Искәндәр кәгазьне укып чыга.

«...Мин моны Советларга хезмәт итмәс өчен эшләдем. Хәйләм уңышлы чыкты. Сез мине үлгән исәпләдегез. Ләкин мин исән һәм иректә! Мин, бер дә икеләнмичә, СССРга кайтудан баш тартам, бүген кичке поездда яңа дусларым белән ирекле Англиягә китәм...» — Хәзер Искәндәрнең күзләре күзлек белән дә күрми. Ул шулкадәр гасабиләнә, гәүдәсен туры тоту өчен ике куллап өстәл кырыена ябыша. Кара күзлекле, кызыл иренле репортерша, Искәндәр утырган кресло тоткасына утырып, ал маникюрлы озын тырнаклары белән аның әле ул чакта агарып бетмәгән чәчләрен тарый:

— Сездән бер генә нәрсә сорала, дустым: шуны күчереп язып, кул куегыз. Без аны сезнең Берлиндагы Верховный комиссарыгызга җибәрербез... Аннан, бүген кич шул ук текстны Бибиси радиосы аша укырсыз...

Искәндәр дәшмәгәч, чиновник денщик тотып торган подностан ике рюмка алып берсен Искәндәргә суза.

— О'Кей, әлбәттә, без кешене бушка эшләтмибез. Хезмәтегез өчен сезгә особняк һәм үзегез теләгән заводта эш тәэмин ителгән.

Искәндәр, чиновникның рюмкалы кулын этәреп, креслодан тора. Һәм, бу юлы үзен мөмкин кадәр тыныч тотып:

— Без фашистларга гаҗәпләнгән идек, кабахәтлекнең менә нинди дә була икән аның,— ди.

Чиновник, бер сүз дә әйтмичә, Искәндәргә дигән аракыны аның битенә чайпалта. Үзенекен эчә дә болай ди:

— Мин сезне кисәтеп куярга тиешмен. Бездә өченче вариант юк. Я безнең тәкъдимне кабул итәсез, яки, чиусак кебек, төрмәдә пыскыйсыз...

Искәндәр, әлбәттә, соңгысын сайлый. Аны үзе кебек «кире беткән» руслар белән бергә җир казырга йөртә башлыйлар. Ә көрәк тотар хәлләре калмагач, иртәләрдән бер иртәдә гитлерчылардан мирас булып калган бөркәүле кара машиналарга төяп каядыр алып китәләр.

Машинада руслар гына түгел, немецлар да, болгарлар да була. Күбәү була алар. Ә язмышлары барысының да бер. Әнә Берлин университетының карт профессоры. Ул, машинада бөркү булуга карамастан,

эшләпәсен басып киҥән, кулларын җиң очларына тыккан. Аны Боннга Демократик Берлиннан урлап киләләр һәм аңар да Искәндәргә куйган шартларны куялар.

— Дөньяда яшисегез килсә, мәйданга җыелган халык алдына чыгасыз да: «Көнбатыш Германиягә коммунистлардан качып чыктым», дип мөрәҗәгать итәсез. Шул чакта без сезне кинога төшереп алабыз һәм бөтен илләргә, шул исәптән Берлиныгызга җибәрәбез...

Намуслы кеше өчен үлем түгел, тарихка начар исем белән кереп калу куркыныч. Профессор кул гына селти һәм ул да Искәндәр көненә кала.

Кара машиналардагылар барысы да шундый. Мәсәлән, әнә теге кечкенә, чандыр немец. Анысы телен тик тота белмәве аркасында килеп эләгә. Көннәрдән беркөн, йөри торгач, Черчилльләр Берлинына килеп чыга бу. Пальтосы кыршылып беткән. Эшләпә кырыйлары шиңгән әрекмән төсле салынып төшкән, авызында арзанлы сигара.

«Бу карачкыны, әлбәттә, аударып булыр...» — ди эре генә бер инглиз офицеры. Ул аны каршыдагы кибеткә алып керә дә ике пакет он алып бирә:

— О'Кей, аша! Черчилль җәнапларыннан бүләк бу сиңа!..

«Карачкы» инглизнең карсак буена, зур корсагына, сакалсыз симез битенә, калын пенснесы артындагы чиләнебрәк торган кечкенә күзләренә, күнел кайтаргыч елмайган майлы иреннәренә карап-карап тора да, онны асфальтта җыелып калган яңгыр суына бушатып (менә кызык!), камыр баса башлый. Ә камыр тәмам тыгызланып житкәч, баш хәтле кукиш ясап, инглиз офицерына тоттыра:

— Мә, Черчилленә алып кайтып бир. Пекарь Ганс сәлам әйтте һәм озын гомер теләп калды, диген... Әйе, әйе, озын гомер... Өзгәләнгән Германиянең яңадан кушылып бөек дәүләт булып үскәнен күрми калмасын дим... Хайль, Черчилль!

Пекарь шунын өчен эләгә һәм Искәндәрләргә иш була...

Ул, машина төрмә капкасыннан чыгып сулга борылуга, Искәндәргә терсәге белән төртә дә:

— Соңгы юл....— ди.— Җырлыйк, иптәш.

Искәндәр зәгыйфь, ләкин гаҗәп күтәренке тавыш

белән Интернационал җырлап җибәрә. Машинадагылар Интернационалны һәркайсы үз телендә күтәреп ала. Кабинадагы полицейский, җырны басу теләге белән, бертуктаусыз сирена кычкырта башлый. Шул чакта уч төбе тикле генә тишек аша соңгы тапкыр якты дөньяга карап барган бер тоткын:

— Руслар! Руслар! — дип кычкырып җибәрә.

Әйе, рус кешеләре. Юл аша чыгып киләләр. Җидеме, сигезме... Андый чакта акыл яшен тизлеге белән эшли. Тоткыннарның хәллерәкләре (шул җөмләдән Искәндәр дә) ишек авызындагы полицейскийны егып, тулы ходка ыргылган машинадан асфальт юлга ташланалар:

— Коткарыгыз! Коткарыгыз! Коткарыгыз!..

Рус телендә ялварып кычкырганны ишеткән совет кешеләре имгәнеп тора алмый яткан тоткыннар янына йөгереп киләләр. МВД кешеләре икән; сугыш вакытында Гитлер кол итеп алып киткән, Гитлердан Черчилльгә мирас булып калган совет балаларын эзләп йөрүчеләр. Әлбәттә, инглиз командованиесе Искәндәрләрне безнең МВД кешеләренә бирми, башта уйлаганынча атарга да алып китми (җәнҗалдан курка); машинага төяп яңадан төрмәгә, төрмә больницасына алып кайта.

МВД кешеләре бу турыда Берлинга, безнең андагы Верховный комиссарга җиткерәләр. Нәтиҗәдә, айлар буена сузылган тарткалашлардан соң, инглизләр Искәндәрләрне азат итәргә мәҗбүр булалар.

Ләкин госпитальдә дәваланудан, курортта ял итеп ятулардан юкка гына баш тарта Искәндәр. Юкка гына өенә, сөйгән хатыны, үзенең Мараты янына ашыга... Анда аны, укучыга мәгълүм булганча, зур бәхетсезлек каршы ала... Бу турыда аңар таксидан төшеп куанакуана парадный ишектән кереп килгәндә әйтәләр. Искәндәр исән калган әйберләренә капланып күз яшьләрен түгә дә күрше карчыкның үзе үлгәндә сугыштагы улы белән килененә язып калдырган хатын сорап алып укый. Бу хатта йорттагы һәрбер кешенең язмышына бәйнәбәйнә тукталганнан соң (кайсы сугыш кырында һәлак булган, кайсы әле кайтып җитмәгән, кайсы эвакуацияләнгән җирендә яшәп калган), Искәндәр семьясы турында болай диелгән була:

«..Башта Искәндәр Зәбирович үзе һәлак булды. Без 1941 елның декабрь урталарында аның үлүе турында извещение алдык. Аннан, яңа ел житәрәк, зур бер бомбежка вакытында Мәрьям яраланды һәм шуннан аягына баса алмады. Кечкенәләрен, Маратны, яхшы күңелле бер хатын килеп чыгып, эвакопунктка урнаштырган иде. Ладогага батып һәлак булган булса кирәк. Мин моны шуңардан чыгып әйтәм, аны үзе кебек кечкенә балалар белән бергә шул ук төндә эвакуацияләгәннәр иде; олауларга төяп Ладога аша алып чыгып барганда, таң алдыннан, Гитлер козгыннары бомбага тотканнар. Бер бала, бер хезмәткәр дә исән калмаган...»

Искәндәр шул көннәрдә эвакопунктта хезмәт иткән өлкән врачны эзләп табып сорашып карады. Врач күрше карчык язып калдырганнарга өстәп бары шуны гына әйтә алды:

— Әйе, балалар шундый бәхетсезлеккә дучар булды. Алтмыш бала иде, иптәш. Балагызны хәтерлим. Мин аны эвакопунктка алырга үзем рөхсәт биргән идем...

— Бәлки, исән калучылар булгандыр?

— Нибары ике бала, иптәш. Юк, юк, кузгалмагыз. Икесе дә кыз балалар. Ладога буе колхозчылары асрамага алып калды.

«Ә бәлки өченчесе дә булгандыр? Анысы ир баладыр? Мараттыр?..» Искәндәр шунда ук врач әйткән колхозга китә. Юк, анда өченчесе юк иде. Марат юк иде анда. Искәндәр, моторка яллап, Ладога күленә, «Тормыш сукмагы» турысына, һәлакәт булган җиргә килә. Бомбежка дәһшәтен, сөекле улының боз астына китүен, йөрәгә алынган сабыйның соңгы тапкыр «әни!» дип, ә бәлки «әти!» дип кычкырганын күз алдына китергән хәлдә зәңгәр сулы тирән күлгә озак карап тора.

Шулай да була бит: кеше кайчакта үз күз алдында үлгән, үзе җирләп кайткан әти-әнисенең, баласының үлеменә дә озак вакытлар ышанасы килмичә йөри. Искәндәр белән бигрәк тә шулай була. Мараты кайчан да булса бер табылыр кебек тоела аңар. Ул үзенең сугыш вакытында Казан шәһәренә эвакуацияләнгән заводына барып эшкә керә. Анда килгәч тә әле озак вакытлар үзенең авыр хәсрәт белән телгәләнгән йөрәген, ниндидер, сизелер-сизелмәс өмет чаткысы белән яктыртып яши. Ниһаять, бу өмет бөтенләй сүнде дигәндә, күргәз-

мәдәге рәсемгә килеп юлыга һәм өмет шәме янадан кабынып китә. «Шул булса, ой, шул булса!..»

Ләкин авырып яткан Маратны күреп сөйләшү аның инде төзәлеп килгән ярасын кузгатып кына калды. Маратны янынннан ул сабыйларча нәүмизләнеп кайтып китте.. Касимоводагы агасы үзенең Җиһангир исемле олы улыннан бик зарланып яза иде — («...Икебез ике якка тарткалап бозып бетердек ахрысы... Бозык малайларга ияра башлады. Инде хәзер укымый да. Нишләтергә дә белмибез... Берәр кыш синең янда торып торса нишләр икән?..») — Искәндәр, Касимоводан шул малайны алып кайтып, бер ФЗӨгә бирде дә, шуны кеше итүгә өмет баглап, шуңардан әз булса да юаныч табып, тыйнак кына тормыш белән яши башлады.

3 ЧЫНАЯК КИТЕГЕ

1955 нче елның июль урталары иде. Идел буе. Яр башында шул ук маякчы будкасы. Таң аткан инде, кояш та чыккан, ләкин аны юка ак болытлар каплап алган, күренми. Менә аргы яктан, нәкъ моннан 12 ел элекке кебек итеп, көймә-ә!.. дип кычкырдылар, бирге яктан нечкә, нәфис тавыш белән аһа-һа-һау-у! дип җавап кайтардылар. Ул да түгел, нәкъ моннан 12 ел элекке кебек итеп, көзге төсле тигез, тын суны очлы күкрәге белән ярып, аргы якка маякчы көймәсе йөзеп китте.

Көймә сораучылар ишкәкченең бик пөхтә киенгән, буйга житеп беткән сылу гына бер кыз икәнен күргәч, аны мәшәкатьләп йөрүләре өчен уңайсызланып, бер-берсенә карашып алдылар. Кыз исә, көймәне ярга матур гына китереп туктатты да, әле һаман аптырашып карап торган юлчыларга:

— Рәхим итегез,— диде.

Юлчылар рюкзак, чемоданнарын күтәрделәр дә аватүнә көймәгә кереп урнаштылар. Берсе, эшләпәсе астыннан иртә агарган чал чәчләре күренеп торганы, күзлеклесе, шунда ук:

— Бирегез, туташ, үзем ишим,— дип кызның нәфис кулларындагы тупас ишкәкләргә үрелде, кыз исә, ишкәк сапларын кыса төшеп:

— О, юк, рәхмәт, үзем дә бик тансыкладым әле,— диде һәм, ишкәкләрен җиңел йөртә-йөртә, сорагапны да көтмәстән, үзе турында сөйләп китте.

— Маякчы кызы мин. Әле кичә генә кайттым, каникулга. Авыл хуҗалыгы техникумында укыйм...

Юлчыларның икенчесе — борын төбендәге бала йоны яңа каралып килгән яшь кенә бер егет булып, өстендә электроэнергия техникумы студентлары формасы иде. Күрәсең, егет формага яңарак тиенгән: бик пөхтәләп, мөмкин кадәр купшы итеп кигән, һава шактый бөркү булуга карамастан, ялтыр төймәле кара сукно шинелен дә салмаган: таушалмасын диптер инде, скамьяга да артын бик басмый гына утырган иде. Студент кызга карап-карап торды да:

— Әминә, бу сез ич! — диде.

— Мин. Кара, танып була икән... Ә сез — Марат, шулай түгелме?

Әйе, бу Марат иде. Ул, җавап урынына, олыларча таң калып:

— Карале-е, ни арада соң сез?..— дип сөйләнә башлаган иде дә, Әминә, аның нәрсә әйтәсен аңлап, сүзен бүлде:

— Ә үзегез?

Марат, елмаеп:

— Ә мин карт инде,— дигән булды.

— «Ка-арт...» — Кыз үзенең көмеш тавышы белән тыйнак кына көлеп куйды.

— Юк, чын шулай,— диде Марат.— Хәтерегездәме, йөгергәндә мин сезне узгач, сез елый башладыгыз, апагыз чыгып, син кечкенә әле, ул зур дип юатты.

— Абау-ау, шунысына хәтле онытмаган... Ә хәтерегездәме, Илдар абый пристаньга әтиегезне алырга чыгып киткәч, яр читеннән балык сөзеп йөрдек.

— Минем штан белән...

Кыз уңайсызланып аска карады. Марат үзе дә колакларына кадәр янып чыкты. Ул, сүзне икенчегә бору өчен:

— Аннан суга таш атып уйнадык,— диде.

— Анысы башка вакыт, Марат.

— Ә, әйе, малайлар белән су керергә килгәч... Зифа апа да бар иде. Ул да атты. Аныкы коймак ашады, безнеке ашамады.

— Әйе, әйе...

— Ә Зифа апа кайда хәзер, Әминә?

Әминә, яшь чыршы, ак каен агачлары арасыннан

матур тәрәзәләре белән Иделгә карап торган маякчы өенә күрсәтеп:

— Өйдә,— диде.— Маякчы инде ул хәзер. Әни урынында. Ә әни пристаньда эшли, начальник булып.

— Әнә ничек!..

— Иделне бик ярата бит. Апаны әйтәм. Унны бетергәч, сельсоветка да алмакчылар иде, кая ул!..

— Теләмәде?

— Ю-ук,— дип сузды кыз, аннан сагышлы итеп әйтеп куйды:— Әйе... уникe ел үткән бит, Марат.

— Ике кәҗә гомере... Юк, көлеп әйтүем түгел... Ә үзе кичә генә кебек...

Кыз инде бөтенләй диярлек ишми, Маратның да койрыкта гаме юк иде. Агым көймәне, үз хөкеменә буйсындырып, шактый түбән алып төшеп киткән иде. Югартын төшеп килгән аккоштай ак пароходның кисәтеп кычкыртканын ишеткәч кенә, иске дуслар, исләренә килеп, көймәне шактый ерак калган маякчы будкасына таба турыладылар. Марат, юлдашының каш астыннан шаян елмаеп карап торган күзләре белән очрашкач, үзенең мәнсезлегеннән ахыр чиктә уңайсызланып, аны кызга тәкъдим итте.

— Таныш булыгыз... Зинһар өчен... Минем кунагым. Бер заводның баш инженеры. Искәндәр Зәбирович Алпаров...

...1953 елгы вакыйга (күргәзмәдәге рәсем, аның авторын эзләп табып сөйләшү) Искәндәр Зәбировичны ымсындырып кына калдырды. Гөлсем ападан Маратка килгән хатларны укыгач, икенче бервакыт ферма мөдирләренең белемнәрен күтәрү курсларына килгән Саниянең Марат белән ничек җылы итеп күрешкәнен күргәч, Маратның тумыштан Айтугановлар токымы булуында шиге калмады. Ә Маратны һаман да ничектер якын күрә иде. Аның янында, урамда очраган һәрбер үсмер янынннан үтеп киткән кебек, гамьсез узып китә алмады. Тыйнак, итагатьле, ягымлы булуы өстенә Марат аның Маратына яшьтәш тә иде бит әле. Искәндәр Зәбирович эштән бушаган араларда Маратның һәрвакыт бераз елмаеп торган йөзен, «әтием үлде» дигәндә ничек күңелсезләнгәнен күз алдына китерде дә, хәзер минем улым да шуның хәтле буласы икән, ул да шулай дәртләнеп берәр техникумда, яисә урта мәктәптә укып йөрер иде микән дип уйланып утырды. Искәндәр әледән-әле тех-

ңикумга шалтыратып, Маратның өлгереш, дисциплинасы турында белешеп торды. Урамда-мазарда очраганда туктап аның белән сөйләшми калмый иде.

— Ә «Эльбада очрашу»ны күрдеңме әле? Карарга кирәк, бик гыйбрәтле картина... Юк, аңа вакыт тапмыйча ярамый... Әйдә, киттек. Минем бар... Ярар, ярар, стипендия алгач түләрсең... Әнә шул скамьяда утырып тор, мин Җиһангирне алып чыгам.

Ул Маратны Җиһангир белән бергә киного гел алып йөри, театрга да алып бара, кайтышлый чәйгә алып керә, еш кына кунарга да алып кала иде. Ә хәзер исә аның Марат кунагы булып, Маратларга кунакка кайтып барышы иде.

...Марат, таныш булыгыз диюгә, кыз, тиз генә торып, Искәндәргә кул бирде. «Мин бик шат»ны да әйтте кыз. Ә Маратка таба борылып утыргач, тагын үткәннәргә күчте:

— Беләсезме, Марат, сез иң кызыгын оныткансыз бит,— диде ул.

— Ничек?

— Өй түрендәге ак каенга карагыз әле. Юк, төбенә карагыз.

Марат, башы күкләргә житеп үскән, ак кәүсәсе әле әз генә дә кутырламаган каен төбенә карады да иңбашларын җыерып куйды:

— Хәтерләмим, Әминә.

— Ә мин хәтерлим. Без анда сезнең миңа биргән чынаяк тәтиен күмгән идек.

Марат, койрык ишкәген судан алып, сикереп торды:

— Фантик, фантик!.. Карагыз әле, ул хәзер дә шундадыр, бәлки!

— Ә кая китсен ул? Дөресен әйткәндә, мин аны үзем дә оныткан идем инде. Үзегезне күргәч искә төште.

— Ай, Әминә-ә!..

— Нигә?

— Кызык ич.

— Казып карыйкмы?

— Әйдә, казыйк!..

Көймә яр читенә житкәндә генә комга терәлде. Марат (кыз алдында берәр егетлек күрсәтергә кирәк ич), су читенә ялт сикереп төшеп, көймәне өстери башлады. Шулчакта узып китеп барган пароходның беренче дулкыны килеп житеп, Маратның чалбар балагын, шинель

итәген чылатты. Анысыннан кагынып кына торганда, тагын бер дулкын су читендәге ташларга бәрелеп чәчрәп, Маратны баштанаяк коендырып ташлады. Марат кыз белән Искәндәргә кушылып көлгән булды. Ә эченнән киемнәрен кызганды: «Ах, кайтып житкәндә генә...» — Шулай да Марат фантикны онытмады. Балак очларын сыккалады, шинелен селкеп чемоданнар өстенә җәеп салды да шаркылдап көлеп торган кызны житәкләп, ул әйткән ак каенга таба йөгерде.

Каен төбе гомер казылмаган кебек булып чирәм белән капланган иде. Кыз, чамалап торды-торды да, менә шунда дип, туфли очы белән кечкенә генә түгәрәк сызды.

Шактый тирән күмелгән икән, кәсен кисеп алып, кәрәкне тирән батыргач кына дымлы соры туфракта чынаяк тәтие елтырап күренде. Марат, кәрәген ташлап, чынаяк китегенә үрелә башлаган иде, тезләнеп, җиргә кадәр иелеп карап торган кыз аның кулын тотып алды:

— Чур, минеке! Биргән бүләкне кире алмыйлар. Үзегезнекен кая куйдыгыз? Мин биргәнне? Анысын да оныттыгыз? Әбәү-ү...

Марат, уңайсызланып:

— Хәтерләмим бит, Әминә,— диде.

— Сәдәбемне бирдем мин сезгә. Күлмәгемнән өзеп... Әни, кер юганда күргәч, орышты.— Кыз, көмеш тавышы белән бер шаркылдап көлде, аннан, чынаяк тәтиен чирәмгә сөртә-сөртә:

— Күрегез әле, печтик кенә дә бозылмаган, хәтта бизәге дә...— дип өстәде.

Марат тагын чынаяк тәтиенә үрелде, кыз исә, шаян елмаеп, тәтине күкрәгенә кысты:

— Ай, юк. Кире бирергә ярамый, шулай бит, Искәндәр абый!

Искәндәр абый җавап бирмәде, ул бәхетле яшьләргә сокланып карап тора иде, чынаяк китеген күргәч, кинәт бик житдиләнеп, әсәрләнеп китте.

Моны күреп кыз тынды, кызга карап торган Марат та туктап калды.

— Кая, бирегез әле, бир...

Аптырап калган Әминә Маратка карап алды да чынаяк китеген Искәндәрнең сизелерлек калтыраган учына салды. Искәндәр чынаяк китеген әле бер, әле икенче ягын әйләндереп карады да бизәкләре арасыннан тыры-

шып-тырышып нидер эзләде, күзлеген сөртеп киеп тагын эзләде. Таба алмагач:

— Карагыз әле, шунда берәр сүз язылмаганмы? — дип яшьләргә бирде.

Яшьләр, бик кызыксынып, иңбашлары, хәтта яңаклары белән бер-берсенә сыенышып, чынаяк китегеннән ниндидер язма эзләргә керештеләр һәм бик тиз таптылар да.

Үтә күренмәле, юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә оста куллар, бик килештереп, алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин, заман үтү белән, сүзләре ашалып беткән иде. Яшьләр бары бер баш М., бераз киткәч кечкенә м ның беренче ыргагын гына укый алдылар.

Искәндәр, бер сүз дә әйтмичә, чынаяк китеген алып күзләренә китерде.

«Шул бит бу. Бәхәссез шул. Мәрьямгә мин бүләк иткән чынаяк! Баш М янында, бераз киткәч кечкенә м ның беренче ыргагы. Бу бит Мәрьям дигән сүз. Тулы текстын да хәтерлим: «Туган көнең белән тәбрик итәм, Мәрьям. Синең Искәндәрең. 22 апрель, 1941 ел». Хәтерлим, аңар бу чынаяк белән бер йотым су да эчәргә насыйп булмады; минем кулдан куана-куана алганда төшереп ватты. Ә Маратка шул гына кирәк тә, шунда ук җыеп алып, ишек алдына алып чыкты да иптәшләренә өләште, барысына да җитмәгәч, ваклап бүлде чынаяк китекләрен. Ә соң бу китек нинди юллар белән *бу Марат* кулына килеп кергән? Ленинградтан эвакуацияләнгән берәр бала аркылы? Белмим, белмим... Һәрхәдлә, бу — Маратның *минем Маратым* булуына өстәмә бер дәлил!»

Шулай итеп, Искәндәрдә тагын өмет шәме кабынды. Ул Маратка, *үз Маратын* танырга тырышып, бераз карап торды да тирән дулкынланып:

— Әйдә, тизрәк авылга, ат көтеп тормыйбыз, әйберләрне хәзергә Әминәләрдә...— ди башлаган иде, шул чак якын гына чылтыр-чылтыр кыңгырау тавышы ишетелде. Ул да түгел, урман авызында, куе чирәм арасыннан тәгәрмәч эзләре генә төсмерләнгән тар юлда пар ат күренде. Кешесе тарантасының чуманына баскан килеш, болай да җан-фәрманга чапкан атларга, дилбегә очы белән селтәнә-селтәнә, һайт-һайтлап килә иде.

Марат камырлы кулын пычак белән кыра-кыра чыгып килгән Зифага әз генә баш иеп алды да, чынаяк тәтиен генә түгел, дөньяларын да онытып, сабыйларча уйнаклап, пар атка каршы йөгерде:

— Илдар, Илдар абый!..

— Абыйсы...— диде Әминә ике туганның дуслыкларына сокланып.— Күптән көтеп йөри иде...

Искәндәр Зифа белән баш иеп кенә исәнләште дә Әминәгә мөрәҗәгать итте:

— Бертуган?

— Әйе-е...

— Күптән беләсезме?

— Әйе-е...

Марат туктап та җитмәгән тарантаска ыргылып менеп, Илдарны кочып алгач, аннан икесе дә чуманга, чуманнан җиргә авып төшеп, әүмәкләшә башлагач, соңра икесе дә бик җылы итеп күрешкәч, Искәндәрдә егетләрнең бертуган булуларына шик тагын бетә язды. Ә соң чынаяк китеге!? Шайтан белсен, нәрсә бу!.. Тизрәк әнисенә, әнисе янына!..

Ул, әле һаман да бер-берсеннән арылыша алмаган Марат белән Илдарны көтеп тормастан, әйберләрен тарантаска орды-бәрде төйи башлады. Илдар исә, аны шунда ук туктатып:

— Юк, Искәндәр абый, болай пожардан ташынган кебек була ич. Хәзер үзем...— диде. Һәм, кунакларның әйберләрен тарантас артына бик пөхтәләп өеп бәйләде дә, чуман астындагы чалгыны алып, күп итеп печән чапты, аны күпертә-күпертә тарантаска салды:

— Менә инде рәхим итегез, Искәндәр абый... Ярамый бит, анда бөтен авыл...

Аннан Маратка карап-карап торды да:

— Ну, энекәш, сагындырдың да соң бу юлы, булмаса булган икән, тагын бер күрешик әле,— диде.

Ул Маратны этеп җибәрде, үзе дә бер-ике адым артка чигенеп, елмаеп карап торды һәм, атылып килеп, энесен кочып алды.

— Туган бит, Искәндәр Зәбирович, бер ел күрешмәгән... Сез гафу итегез инде...

Аларга рәхәт. Маратка бигрәк тә. Менә хәзер, алъяпкыч итәгенә кулларын сөртә-сөртә әнисе килеп чыгар

капкадан, Саниясе кайтып керер йөгереп. Иптәшләре килер... Искәндәр чамадан тыш дулкынланып барды. Өмет шәме бер сүнде, бер кабынды аның. Яше, рәсем, чынаяк китеге... Бу турыда уйлаганда өмет шәме дөрләп кабынды; Искәндәр ингә иң селкенеп килгән Маратны «улым!..» дип кочып алырга житте. Ләкин шунда ук башына моңар каршы булган дәлилләр бәреп кереп, шәмне өреп сүндерде. Ләкин нәрсә булса да тизрәк, тизрәк!..

Искәндәр кузла башыннан каерылып, энесе белән дәртле сөйләшеп барган Илдарга вакыт уздыру өчен колхоз турында сораулар бирде. Илдарның җаваплары арасында бик кызыклары да бар иде:

«Инешкә пароход кертәбез бит, энекәш! Түгел, кичә Казаннан килеп проектын төзеп киттеләр. Куйбышев хикмәте. Ашлыкны басудан туры баржага хәзер. Теге без пароход йөртеп уйнаган ермак авызында пристань була. Һәйбәт... Ә анысы үзеннән-үзе билгеле; тугыз авылга житәрлек итеп корабыз. Бер дә һавадагы торна түгел, син бетереп кайтуга өлгерә. Күңелеңне киң тот, халык сиңа тапшырырга чамалап тора...» Тик боларның берсе дә Искәндәр Зәбировичка кызык тоелмады, юаныч бирмәде. Борчылганнан-борчыла барды ул.

— Житәбезме әле?

— Әнә шунда гына...

«Тизрәк, тизрәк!..» — Ул, печән арасыннан табып алган күкчәчәк сабагы белән, Маратларга күрсәтмичә генә, атларга кизәнеп, телен шартлатып куйды. Атлар моны санга сукмагач:

— Куа төш, егетем, бик сусатты,— дигән булды.

— На-а, малкайлар...— Илдар дилбегә очын уйнатып алды. (Атларны ашыктыру өчен түгел, Искәндәрнең күңелен күрү өчен.) Һәм:— Сусынны момент басабыз аны, Искәндәр абый...— диде дә, кузла башыннан тагын Маратка таба ава төшеп, өстәп куйды:— Бал эчеттем, энекәш, һәйбә-әт... Сабантуе житә бит. Туйлар китте бездә хәзер, Фәрит тә өйләнә. Түгел, Трактор Фәрит. Теге, энесен трусигына чабата киндерәсе белән тагып... Ха-ха-ха...

Искәндәр абый чәй янында ук, үзен борчыган серне чишү теләге белән, Гөлсем апага авыл хәлләренә, мәк-

тәп, укыту мәсьәләләренә төреп берничә сорау биреп караган иде инде. Марат күрешергә кергән иптәшләре белән ишек алдына, җиләскә чыгып киткәч, Илдар белән Сания дә, бүген тиз кайтасыларын әйтеп эшкә китеп баргач, сорауларны ачыграк итеп бирде. Гөлсем апа андый сораугa үзе сәбәпче булды. Ул сүз арасында:

— Сез Ленинградныкымыни? — дип сорады.

— Бөтенләй түгел. Касимово шәһәреннән мин... Әллә сезнең Ленинградта булганыгыз бармы, Гөлсем ханым?

— Укыдым мин анда.

— Әнә ничек. Күптәнме?

— Күптән. Сугышка кадәр.

— Ә сугыш вакытында булмадыгызмы?

«Бу сорау нигә? Нигә ул миңа шулай карый? Касимовосы нигә тагын?..» — Гөлсем апага ниндидер шом җиле кагылып китте. Искәндәр моны сизде. Ул хисләрен инде артык яшереп тора алмады. Бу вакытта аның нервлары ахыр чиктә тартылган, Гөлсем апага төбәлгән күзләре, «Я, әйтегез инде, әйт...» дия иде. Гөлсем апа исә әйтмәде, аның соравына сорау белән җавап бирде:

— Сезне нидер борчый шикелле, Искәндәр Зәбирович? — диде ул.

— Борчый шул, Гөлсем ханым.— Искәндәр абый ялт сикереп торды, трубкасына тәмәке салып кабызды, аннан шуның белән кулын җылытырга теләгән кебек трубкасын учында кысты. Һәм хатынының үлеме, улының да үлгән булырга тиешлеге турында сөйләде дә:

— ...Ә минә кайбер нәрсәләр аның исән булуы турында әйтеп тора,— диде. Ул Маратның альбомыннан күргәзмәдә торган рәсемне алды.— Мәсәлән, миңа бу рәсем, яки менә бу чынаяк китеге...

Гөлсем апа сүзнең нәкъ үз Мараты турында барганын аңлады. «Ләкин, баланың атасы үлгән ич...» Ул Искәндәрне Маратның этисе дип түгел, аның документы белән йөрүче берәр самозванец, уза-китсә, Искәндәрнең Касимовадагы агасы, бүген-иртәгә акча таба башлаячак егетне үзенә дауларга килгән кеше дип белде. Шуңа күрә әллә ни коелып төшмәде.

— Шуннан...— диде ул, бик үк дусларча булмаган тонга күчеп.

— Телем бармый, Гөлсем ханым.

— Нигә икән?

— Сез шундый олы җан...— Искәндәр абый әйтер сүзен әйтә алмады. Ул, башын әкрен генә артка ташлап, күзләрен йомды. Ике бөртек яше бераз вакыт керфекләрендә асылынып торды да күзлеге аша шактый тирән булып күренгән вак җыерчыкларга тәгәрәп төште.

— Тынычланыгыз, иптәш,— диде Гөлсем апа — Алайса, әйтим инде, миндә дә кайбер дәлилләр бар, һәм аларның берсе дә сезнең файдага сөйләми. Искәндәр Зәбирович Алпаров дөньяда юк. Ул 1941 нче елның 15 нче ноябрендә Ватан сугышында һәлак булды.— Гөлсем апа сандык төбеннән, Маратның авыр елларда сатыла язып калган кыйммәтле нәрсәләре арасыннан метрика белән кара печатьле извещениене алып күрсәтте.— Менә документ, менә тагын бер документ... Бәлки хәтерегез калыр, ләкин хакыйкатьне әйтми булмый; Алпаровның изге исемен үз файдагызга хезмәт иттерергә йөрү — кимендә...

Гөлсем апага Искәндәр абыйның күзләре хәзер куркыныч булып күренде. Шикләнә калган хатын, тынычрак булсын өчен, ишек алды як тәрәзәне төртеп ачты. Аннан Маратларның шат тавышлары ишетелә иде.

Документларны күрүгә телсез-авызсыз калган Искәндәр абый, Гөлсем апаның шикләнгәнен сизеп, мич кырыена ук китеп басты һәм болай диде:

— Олы җан, олы җан икәнсез, Гөлсем ханым, табынам мин сезгә, аяк астыгызда туфрак булырга әзер мин сезнең... Баланы ач үлем дәһшәтеннән йолып калгансыз, алай гына да түгел, бала өчен иң аяныч күңел китеклеген — аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез. Мин төшенәм: аның өчен 13 ел буена сезгә көн саен күпме эш эшләргә кирәк булган. Ә сугыш елларында!.. Ышанам, хәзер сезгә бала үз балаларыгыз кебек үк үз. Ләкин авыр булса да әйтим, ханым, бала минеке бит.

— Бу ялган!

— Сез минем Мәрьямне таныйсыз, шулай бит?

Искәндәр чемоданын ачып, ак киндергә төрелгән берничә рәсем чыгарды. Арадан берсен, урта кул китап бите кадәресен алып, Гөлсем апага сузды. Башка дәлил кирәк түгел, баланы даулаучының нәкъ Марат әтисе икәнен шушы рәсем үзе генә дә исбат итә ала иде: озынча өстәл тулы аш-су, табын әйләнәли кунаклар торып баскан, кулларында мөлдерәмә тулы рюмкалар, ә табынның ту-

рендә яшь Искәндәр һәм аның кәләше Мәрьям туташ. Актан киенгәннәр, башларында кыр чәчәкләреннән үрелгән такыялар. Күрәсең, кунаклар бик оялткандыр үзләрен, бер-берсенә астан гына елмаешып карап торалар иде.

«Коточкыч бит бу!..» — Гөлсем апа Маратның скамьяда онытылып калган формалы фуражкасын әкрен генә алып күкрәгенә кысты.— «Шулай ук аерылабызмыни инде, улым?..» — Күз аллары карангыланды ананың, башы әйләнде, чайкалып ава башлаган гәүдәсен тотып калу өчен тәрәзә челтәренә ябышты. Искәндәр аны, йомшак кына тотып, скамьяга утыртты.

«...Ничек инде мин Маратсыз?.. Ә бәлкем...» — Гөлсем апа алдында ниндидер өмет чаткысы күреп күзләрен ачты.— «Бәлки суд яклар! Партия? Ә бәлки үзе үк?..» — Гөлсем апа яшь пәрдәләгән күзләре белән бала атасына карады:

— Шәфкатьсез булмагыз. Китегез, Искәндәр Зәбирович. Мин бит аны... Ай, сез белмисез... Мин бит аны...

Искәндәр Гөлсем апаның өзгәләнгәнен күреп икеләнә калды. «Әйе, баланы үземә алу — минем өчен тиңсез бәхет булачак. Ә бала өчен? Әнисенең фаҗигале үлеме турында белү, әнием дип йөргән хатынның бала алдында фәкать бер яхшы апа гына булып калуы? Өстәвенә бу изге ана өчен моның нәтиҗәсе нинди булачак? Бу — аның дөнья бәясе торырдай изгелеге бәрабәренә йөрәген мәңгегә ачы яралап ташлау була түгелме соң? Үз бәхетем өчен ике кеше бәхетен тартып алу була түгелме? Тагын Илдар белән Сания бар бит әле... Әйе, әйе... Әллә чыннан да китәргәме?.. Маратка бернәрсә дә әйтмичә генә китәргәме әллә?..»

Искәндәрнең уйлары турында әле бернәрсә дә белмәгән Гөлсем апа, бөтен йөрәге белән әрнеп, тагын бер тапкыр:

— Шәфкатьсез булмагыз,— дип пышылдады.— Үтенәм сездән... зинһар өчен... Кирәкме, алдыгызга тезләнимме?.. Үтермәгез мине, Искәндәр Зәбирович...

Шул чак әкрен генә ишек ачылып, Марат килеп керде. Ул, күрәсең, тыңлап торган, дулкынланганын яшерергә тырышып, бераз ятсынып, шул ук вакытта бик җылы итеп, үз итеп әтисенә карап торды, аннан, чабып килеп әнисен кочып үпте һәм, аның алдына тезләнеп, болай диде:

— Бер дә шомланмагыз, әнием, мин мәңге сезнеке. Әгәр сез минем үз әнием булсагыз, мин сезгә бер бурычлы булыр идем. Инде ят кеше була торып, мине үзегезгә ул иткәнсез икән, авыр еллар аша алып чыгып, мине үз балаларыгыздан аермыйча, шушы көнгә китереп җиткергәнсез икән, мин сезгә мең бурычлы. Ышаныгыз, әнием, бу хәл минем сезгә булган мәхәббәтемне меңләтә көчәйтә. Ышаныгыз, әнием җаным...

Гөлсем апа, Маратны сабый чагындагы кебек алдына алып, чәчләреннән, күзләреннән, яңакларыннан үбә-үбә елады, ә теленә «рәхмәт, улым, рәхмәт, күз нурым»нан башка сүз килмәде. Марат, әнисен тынычландыргач, әкрен генә, һаман да ятсынып кына әтисе янына килде. Искәндәр, дулкынлануыннан нишләргә белмичә аны күтәреп алды да әйләндерә-әйләндерә килеп, аның белән бергә диванга ауды.

Гөлсем апа нәрсәгәдер өйалдына чыгып кергән арада алар әле һаман шул диванда утыралар, Марат та, әтисе кебек үк, тиңсез бәхетле, әтисен табу исереклегеннән яңа гына айнып килә һәм, ниндидер сүзенең дәвамы буларак:

— ...Ләкин, әтием, күңелегезгә авыр алмагыз, үлгәндә дә мин әниемне ташламыйм. Хәзер берәр могҗиза булып, син кайткан кебек үз әнием кайтып керсә дә, мин шуны ук әйтер идем, әти, ачуланма...— дия иде.

4 ТӨШЕРИК ШУНДА ПӘРДӘНЕ

Искиткеч хәбәр Маратның күршергә килгән иптәшләре аша шунда ук бөтен авылга таралып өлгерде. Хәбәр Илдар белән Саниягә дә сәгате-минуты белән барып җитте. Туганнар бу хәбәрне икесе дә энеләре өчен сөенеп, үзләре өчен көенеп каршы алдылар. Сания иштүенә басуга, Илдар янына, йөгерде. «Ни булып калыр икән инде?..» — Алар Әкбәрнең (теге вакыт Маратларны «каз боты» белән сыйлаган Әкбәрнен) сабантуена дигән балын авыз итеп утырган Маратны эзләп таптылар да аның уйларын белгәннән соң, тынычланып, икесе ике ягыннан эләктереп алып, бөтен көчкә җилтерәтеп өйгә алып кайтып киттеләр:

— Иһи-и! Болай булгач, пир на весь мир ясыйбыз, энекәш! Ипи әгәр, ясыйбыз... Юк, бүген. Хәзер үк...

Шыпырдама, сеңел!.. Һии, сабантуена хәтле тагын әчеп өлгерә ул...

Илдар үз дигәнендә торды... Ә сабантуена яңа бал куелды. Ләкин монысы да сабантуен көтмәс ахрысы. Көннәрдән беркөн шау-гөр килеп су буеннан, уеннан кайтып килгән өч туган, этелә-кысыла ишектән кереп барышлый шып туктап, бер-берсенә карашып куйдылар. «Монысын ничек аңларга?» — Анда, Айтугановларның рәсемнәре арасында Мәрьям ханым һәм Искәндәр Зәбирович рәсемнәре дә урын алган; Маратның Нева белән Аккош күлен, Айтугановлар белән Алпаровлар семьясын бутап бетергән рәсеме дә элеп куелган; Мәрьям белән Искәндәрнең туй рәсемнәре дә шунда булып, янында нәкъ шул рәсем кадәр урын калдырылган иде. Анысы нигә икән? Бәлки тагын шундый бер рәсем, яңа туй рәсеме өчендер? Нигә, булуы мөмкин ич. Миңа калса, мин үзем шул теләктә.

Ә кем каршы килер икән? Юк, син дә каршы килмә, укучым. Марат? Әйттең сүз! Бу аның өчен бары нур өстенә нур гына булачак. Илдар белән Сания? Ай-һай, үз әниләренең һәм сөйгән энеләренең мәңге бәхетле булуларына каршы килерләр микән? Ниһаять, Ил исеменә, совет кешесенең намусына тап төшермәс өчен озак еллар буена Гитлер, Черчилль төрмәләрендә газап чиккән, үлемгә Интернационал җырлап барган Искәндәр Зәбировичның бәхетле булуына каршы килерләр микән?.. Көнләшерләр, дисез? Анысы башта бераз булыр инде. Ләкин мин ышанам, Гөлсем апаның, бу изге җанның, олы җанның мәхәббәте барысына да житәр. Нигә, хәтерләгез әле, Марат килгәч шулай булды ич...

Менә хәзер инде пәрдәне төшерсәк тә ярый, укучым. Һәм бик вакыт. Югыйсә, үзең дә сизенәсеңдер, хикәя Гөлсем апа белән Искәндәр абыйларның туйларына килеп терәлде. Һәм, әгәр дә мәгәр туй була калса, маякчы кызларының да чакырылулары бик мөмкин. Беркөн иртән Идел буенда кайнашканда Искәндәр абый Әминәсен бик яратып калган, бу сылуга Гөлсем апаның үзенең дә күзе төшеп йөри икән, туй булса, Марат янына кертер дә утыртыр. Анысы-анысы әле, барган-кайткан

авылдашлар Илдарны маякчы өе тирәсендә еш кына күрәләр икән. Әбәт вакытында кеше, ипи белән сөтен тота да, тизрәк арыш күләгәсенә поса, ә бу, мотоциклына атлана да, әйдә пошел, Идел буена!.. Имеш, комбайнда бик тузан, эссе дә... Эссе булса, инеш әнә генә бит. Нигә шунда гына төшми ул?.. Туй-мазар була калса, Илдар, мөгаен, исемлеккә Зифаны кыстырмый калмас...

Саниями? Нәрсә әйтим. Әдәпле, бик тыйнак кыз. Ләкин... Син Харисны хәтерлисеңме, укучым? Үги Харисны, әнисеннән куркып, урманнан гербарийлар җыймыйча кайткан Харисны?.. Ул хәзер колхозда балта остасы. Әнә теге тау битендәге кызыл түбәле матур өй аныкы була инде; быел үзе җиткереп керде. Юк, хәзер үги әнисе белән тормый... Ә апасын белмим, хәзер кайда йөри торгандыр. Харис башка чыккач, әнисе базардан базарга йөри-йөри төрмәгә кереп утыргач, тәрәзә төбеннән төште төшүен. Ләкин бу вакытта соң иде инде. Кулы эшкә бармады. «Картаеп каткач буыннар, эш белү унайсыз ул». Ишегенә йозак салды, иннеген-кершәнен күп итеп ягынды да авылдан ук чыгып китте. Харис турында әйтүем шуның өчен: Сания, семьяда үзгәреш булырга торганны сизенгәч, чәен аннан-моннан гына эчте дә, ялт барып, Харисны уяттырып чыгарды. Нигә һәм ни өчен? Ни өчен алар инде ике-өч сәгатьтән бирле читәнгә сөялеп пышым-пышым сөйләшеп торалар? Бәлки яңа салыначак ферманың проектын тикшерәләрдер? Ай-һай, булыр микән... башка берәр *ферма* проекты түгел микән... Күр, Харисының авызы колагына җиткән! Саниясе дә (карале син аны тыйнак кызны!), тегесе бармак очы белән генә кагылды исә, башын аның күкрәгенә куярга тора... ә Харисы... Ләкин җитте, җитте. Төшерик, укучым, шунда пәрдәне.

(1953—1955)

ЭЧТӘЛЕК

ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

Беренче кисәк

1. Сабантуе түгел бу 7
2. Алалар, алалар 13
3. «Кит, тешемне куэгаттың!» 17
4. Кермик без анда 19
5. Гадәттән тыш ашыгыч 27
6. Нульләр, цифрлар 34
7. Тегеләр чишкән 35
8. Эх, Петя, Петя 41
9. Яна дуслар 44
10. Авызыннан җил алсын 49
11. Мин аны юкка җәберләдем 56
12. Хуш, авыл! 59
13. Серле яулык 65
14. Күнелсез булмады 71
15. Ярыймыни, абый? 75
16. Держи, сынок! 80
17. Әти төсле солдат 87
18. Менә бәхет! 92
19. Хәлимгә ямансу булып китте 96
20. Маскировка җепләре 106

Икенче кисәк

1. Исәнме, авыл! 117
2. Хәлим кайткан, малайлар! 123
3. Барысы да җиңү өчен 135
4. Шәпи нигә укымый? 142
5. Бу йорт безнең шефлыкта 150
6. Кем соң син? 158
7. Синнән тиеш түгел, Рәхимә 161
8. Шәехтай, Шәехтай! 169
9. Ике дус 180
10. Ияде нишләргә? 187
11. Уп агач булса да 195
12. Син дә ботак чабучымы? 199
13. Хәлимгә уңайсыз булып китте 208
14. Гыйбрәтле сүз әйттен 211
15. Без дә тик ятмыйбыз 220

16. Әйдә соң 226
17. «Хәзер күңелем боек чагы» 231
18. Ибрай бияләйләре 243
19. Шәехтайның яшерен дусты 246
20. Менә кем икән ул! 250
21. Син ялгышкансың, бабай 256

Өченче кисәк

1. Яз җитә бит 268
2. Инде кайдан алабыз!.. 276
3. Караңгы кичтә 279
4. Беренче буразналар 284
5. Эти сорап язган 296
6. Дөрес инде, дөрес 301
7. Бетереп кайтабыз 307
8. «Тегеләр разведчигы» 311
9. Уңышны кешеләр хәл итә 322
10. «Кече Илшат» кешеләре 329
11. Безгә йөз кирәк 340
12. Ишкәнсез икән 346
13. Зәңгәр конверт 349
14. Рәхмәт, гүзәл балалар! 359
15. Соңгы сүз 366

МАРАТНЫҢ ЯЗМЫШЫ

Беренче кисәк

1. Иләмсез кара төн иде 377
2. Тәти апа, өйгә кайтыйк 390
3. Өченчең белән котлыйм 400
4. Ансат булмас, ахрысы 410
5. Күршенең нинди юк 413
6. Әниемне сагынам 418
7. Шуннан соң менә нәрсә булды 423
8. «Мин килмесәк» 430
9. Хуш, Ягедни! 433

Икенче кисәк

1. Бер дә кайтмыйк, яме, әнием 437
2. Каз боты 445
3. Нишләткәч он була ул? 452
4. Башак кая киткән? 457
5. Ошады, Василий дәдә 462
6. Корткыч өнкәре 469
7. Безнең түбә кызыл 474
8. Тир белән тапсын ашарын 480
9. Ачыксалар карлыгачның балалары 490
10. Ятим кошларга менә ни булды 495

11. Идел буенда 500
12. Солдат балалары 508
13. Шуннан соң менә ни булды 511

Өченче кисәк

1. Гадәттән тыш вакыйга 518
2. Маратның әтисе 524
3. Чынаяк китеге 535
4. Төшерик шунда пәрдәне 546

Гариф Губай (Губайдуллин Гариф Шакирович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ. Том 2.

(на татарском языке)

Художество редакторы *А. Г. Садыйков*

Техник редакторы *В. Н. Галкина*

Корректоры *Р. С. Хәмидуллина*

Наборга бирелде 31/X-1968 ел. Басарга кул куелды 14/IV-1969 ел. ПФ 09009. Учетн.-изд. таб. 28,96. Якынча басма таб. 29,10. Типография кәгазе № 2, 84×108 1/32. Тираж 13000. Заказ Д-1810. Бәясе 1 сум 02 тиен.

Татарстан китап нәшрияты
Казан, Бауман урамы, 19

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды.
Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.